АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова**

# ЛЕКСИКОЛОГИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В трех томах

II том

Казань
2016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ

Өч томда

II том

Казан
2016

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**
**Т 23**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Фәнни редактор** – филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина**

**Рецензент –** филол. фән. докт., проф. **К.Р. Галиуллин**

**Т 23 Татар лексикологиясе:** өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Т. II. – 392 б.
ISBN 978-5-93091-213-5

Монография – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тормышка ашырыла торган «Татар лексикологиясе» проектының икенче томы. Әлеге хезмәттә татар теле сүзлек составының килеп чыгышы, генетик катламнары тасвирлана; сүзлек составы кулланылыш даирәсе ягыннан өйрәнелә: гомумкулланылыш сүзләре, чикле кулланылыштагы лексиканың территориаль һәм иҗтимагый яктан бүленгәнлеге, аларның төрләре, функциональ мөмкинлекләре, татар теленең терминологиясе мәсьәләләре хәзерге тел белеме казанышларына нигезләнеп бирелә. Татар теленең сүзлек составы экспрессив-стилистик яктан характерлана, кулланылыш активлыгы турында мәгълүмат бирелә.

Хезмәт тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**

**ISBN 978-5-93091-213-5**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016

## КЕРЕШ

Татар теленең сүзлек составы гасырлар дәвамында формалашып, үсеш-үзгәреш кичергән хәлдә, бербөтен система буларак, бүгенгәчә килеп җиткән. Лексик системаның бөтенлеге аның бертөрле булуы дигән сүз түгел, сүзлек составының тулылыгы һәм системалылыгы аның төрле формаларда һәм төрле иҗтимагый һәм территориаль катлам вәкилләре сөйләмендә татар теленең табигыйлеген, байлыгын һәм функциональ мөмкинлеген тулысынча файдаланып яшәвендә чагылыш таба.

Тел галимнәрен һәрвакыт милли телнең барлыкка килү, яшәеш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү мәсьәләсе кызыксындырып килә, чөнки телнең функциональ структурасы, әлеге структураның татар телендә сөйләшүчеләрнең аралашу мөмкинлекләре телнең байлыгын һәм яшәеш потенциалын билгели.

Милли телнең нигезен тәшкил иткән татар әдәби теле үзенең күп функцияле булуы белән аерылып тора, ягъни ул татар телендә сөйләшүче һәркемнең ихтыяҗын канәгатьләндерергә сәләтле. Ләкин татар теленең лексик фондында әдәби тел кысаларына сыймаган, әмма татар халкының аралашу мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүдә актив роль башкара торган берәмлекләр шактый. Шулай ук татар әдәби теле сан һәм сыйфат ягыннан үзенең составын даими рәвештә башка телгә яки аерым катламнарга караган сүзләр белән тулыландырып тора. Бу төр лексиканың барлыкка килүен, кулланылышын, аралашудагы ролен, мәгънәви мөмкинлекләрен өйрәнү татар теле белемендә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе санала. Әлеге мәсьәләләрне ачыклау лексик системаның тулы, бербөтен, даими хәрәкәттә булуын, үсеш-үзгәреш юнәлешләрен билгеләү өчен аеруча мөһим.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән әлеге коллектив монография – өч томлык «Татар лексикологиясе» хезмәтенең икенче томы. Ул татар теленең лексик составы формалашу, үзгәрү һәм үсү тарихын, лексиканың кулланылыш үзенчәлекләрен яктыртуга багышлана.

Академик лексикология проектының җитәкчесе – академик М. Зәкиев, фәнни редакторы – филология фәннәре докторы Г. Галиуллина.

Хезмәтнең беренче бүлегендә татар теленең сүзлек составы килеп чыгышы, генетик катламнары тасвирлана. «Тел белемендә сүзлек составының килеп чыгышын өйрәнү тарихы» бүлекчәсен һәм «Төрки-татар чыгышлы лексика» бүлеген филология фәннәре кандидаты Х. Кузьмина, «Татар телендә фин-угор алынмалары» бүлеген филология фәннәре докторы И. Насипов, «Татар телендә гарәп һәм фарсы алынмалары» һәм «Рус һәм Европа телләреннән кергән алынмалар» бүлекләрен филология фәннәре докторы Д. Рамазанова язды.

Хезмәтнең икенче бүлегендә татар теленең сүзлек составы кулланылыш даирәсе ягыннан өйрәнелә. Биредә сүзлек составында гомумкулланылыш сүзләре, чикле кулланылыштагы лексиканың территориаль һәм иҗтимагый яктан бүленгәнлеге, аларның төрләре, кулланылыш үзенчәлекләре, татар теленең терминологиясе мәсьәләләре хәзерге тел белеме казанышларына нигезләнеп бирелә. «Тел белемендә кулланылыш даирәсе ягыннан сүзлек составын өйрәнү тарихы» «Татар теле лексикасын кулланылыш даирәсе ягыннан төркемләү мәсьәләсе» бүлекчәләрен филология фәннәре кандидаты Э. Сафина, «Гомумкулланылыш лексикасына гомуми билгеләмә» бүлекчәсен һәм «Татар телендә иҗтимагый диалект лексикасы» бүлеген филология фәннәре докторы Г. Галиуллина, «Җирле диалект лексикасы» бүлеген филология фәннәре кандидаты А. Хөсәенова, «Татар теленең терминологиясе» бүлеген академик М. Зәкиев язды.

Өченче бүлектә татар теленең сүзлек составы экспрессив-стилистик яктан характерлана. Бүлекнең авторы – филология фәннәре кандидаты Г. Хаҗиева-Демирбаш. «Татар телендә эмоциональ-экспрессивлыкны белдерүче чаралар» бүлекчәсен филология фәннәре кандидаты Н. Галиева язды.

Дүртенче бүлектә сүзлек составының кулланылыш активлыгы турында мәгълүмат бирелә. Бүлекнең авторы – филология фәннәре кандидаты Р. Мөхиярова.

Хезмәтнең кереш, йомгак һәм борынгы алынмаларга кагылышлы өлешләре филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина тарафыннан башкарылды.

Хезмәтнең библиография өлешен И. Хамматуллина эшләде.

«Татар лексикология»сенең икенче томы гомуми тел белеме фәнендә таралыш тапкан төркемләүләргә, фәнни нигезләмәләргә таянып башкарылды. Тел белемендә яшәп килгән аерым карашлар, гипотезалар, фәнни нигезләнмәгән яки өлешчә расланган фактлар хезмәткә кертелмәде. Китап киң катлам укучыларына аңлаешлы телдә язылган, сирәк кулланылыштагы терминнар хезмәтне чуарламый, һәрбер терминга аңлатма, билгеләмәләр бирелә. Фактик материаллар – татар әдәбияты үрнәкләреннән, сөйләм теле – төрле типтагы сүзлекләрдән тупланды.

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ: ТАРИХИ-ГЕНЕТИК ТАСВИРЛАУ

## § 1. Тел белемендә сүзлек составының килеп чыгышын өйрәнү тарихы

Теләсә кайсы телнең сүз байлыгы кешене уратып алган әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәрнең тасвирламасын теркәп барырга һәм аларны тел системасы ярдәмендә киләчәк буыннарга тапшырырга ярдәм итә, шуңа күрә сүз һәм аның мәгънәсен өйрәнү бик борынгыдан ук башланган. Антик чорда ук кешеләр сүзнең килеп чыгышы турында уйланганнар, аның номинатив, туры һәм күчерелмә мәгънәләре турында фикер йөрткәннәр (Цицерон, Платон, Аристотель һ.б.). Борынгы төрки халыклар исә сүзләрнең тәэсир итү көчен ырымнарда, каргыш-теләкләрдә һәм кара ышануларда, йолаларда ук кулланганнар (Әхмәтҗанов, 2001: 141–153). Сөйләмнән максатка ярашлы сүзләрне аерып чыгару, аларны аерым контекстка салу, бер-берсе белән мәгънәви бәйләнешләр барлыкка китерү, сүзләрне кабатлаганда ритм һәм рифма таләпләрен искә алу сүз байлыгына, телнең кеше тормышындагы роленә игътибарны арттырган. Нәтиҗәдә телнең атау һәм аралашудан кала башка функцияләре дә (эстетик, магик, тәрбияви һ.б.) үсә башлаган, телнең югары формасы – әдәби тел барлыкка килгән. Язу барлыкка килү кешелек цивилизациясе тарихында иң зур казанышларның берсе була. Сүз байлыгы сүзлекләрдә, язма әдәби чыганакларда, археографик материалларда язма рәвештә теркәлеп калган. Бу истәлекләр нигезендә без төрки лексиканың гасырлар дәвамындагы хәрәкәтен күзәтәбез. Алай гына да түгел, телнең үсеш-үзгәреше ул җәмгыятьнең, иҗтимагый вакыйгаларның үзгәрешен күрсәтә торган фактор да. Телдәге сүзләрнең кулланылышына карап, без

халыклар арасындагы икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләр, таралу, яшәү шартлары, мәдәни тормыш турында мәгълүмат туплый алабыз.

Фәнгә төркиләрнең безнең эрага кадәр III–II меңьеллыкларда – неолит дәверендә һәм аннан соңгы бронза чорында ук яшәгәнлекләре билгеле булса да, теркәлеп калган иң борынгы төрки язулар, яңа табылган мәгълүматларга караганда, безнең эрага кадәр V–IV гасырларда кулланышка кергән (Аманжолов, 2003: 305). Бу – рун язулы текстларга охшаган, әмма килеп чыгышы билгесез булган язмалар (Казакъстан, Әфганстан, Үзбәкстан территорияләрендә табылган язулар). Борынгы төрки телнең диалекттан өстен булган койне (гомумхалык сөйләме) шәкелендә язылган рун язулы тулы текстлар Орхон-Енисей язмалары исеме белән дөньяга билгеле. Аларның язылу вакыты турында фәндә төрле фикерләр әйтелгән. Фәнни хезмәтләрдә ул хакта төрки дәүләтләрнең төзелү тарихы белән бәйләп, V(VI)–VIII гасырларга ишарә ителсә дә, күпчелек галимнәр бу язмаларның безнең эраның VII гасырларыннан да иртәрәк язылмавын күрсәтәләр (Кляшторный, 1964: 44; Кляшторный, 2003: 11).

Рун язулы истәлекләрдә төрки халыкларның сүз байлыгы теркәлеп калган. Истәлекләрне тикшерүче галимнәр В. Томсен, В. Радлов, А. Вамбери, П. Мелиоранский, С. Малов, А. Щербак, Д. Насилов, И. Батманов, С. Кляшторный, А. Аманжолов, И. Кормушин һ.б. борынгы төрки нигез лексиканың хәзерге төрки телләрдә саклануын күрсәтәләр һәм кайбер сүзләрнең килеп чыгышын, беренчел мәгънәләрен ачыклыйлар. Татар теле белеме фәнендә әлеге язмаларны лексик һәм грамматик яссылыкта себер халыклары, хосусан алганда, себер татарлары диалекты белән җентекле рәвештә чагыштырып өйрәнүче галим Г. Әхәтов була (Ахатов, 1975: 35–36). Борынгы руник язмаларны татар укучысына тәкъдим итүдә Казан университеты профессоры Ф. Нуриева зур хезмәт куя (Нуриева, 2003: 144). Шулай ук Татарстан территориясендә табылган язуларга Һ. Йосыпов, Х. Курбатов, Ф. Хәкимҗанов, В. Хаков игътибар иткәннәр.

Төрки халыкларның язу тарихында уйгыр язуы да аерым урын били. Уйгыр язулы истәлекләр, башлыча, будда, манихей һәм христиан диннәренә бәйле изге китапларның тәрҗемәләре булып тора. Билгеле булганча, төркиләр борын-борыннан ук төрле дин

тотканнар. Мәсәлән, Зәңгәр күккә (Күк Тәңри) ышану һәм шаманчылык белән бергә, борынгы төркиләр будда динен дә тотканнар. Будда дине аларга Тибеттан һәм Һиндстаннан килеп кергән. Соңрак иранлылардан (башлыча, согыдлылардан) манихейлыкны, несториан сүриялеләрдән христиан динен кабул иткәннәр. Боларның барысы да язма истәлекләрнең сүз байлыгында үзенең чагылышын тапкан. Бу язу белән язылган язмалардан «Манихейлыларның тәүбә догасы» яки Хуастуанифт исеме белән билгеле булган дини эчтәлекле манихей истәлеге, төрки телгә турыдан-туры согыд теленнән тәрҗемә ителгән «Сихерчеләр табынуы», будда диненә караган «Алтын йарук» («Алтун өңлүг йарук йалтырыклыг копта көртүлмис ном ил ики атлыг ном» – «*Барлык нәрсәдән дә бөегрәк, алтын нурлар белән балкый торган патша китап»*) язмаларын күрсәтергә мөмкин. Тикшерүче галимнәр – В. Радлов, С. Малов, Ә. Тенишев, В. Насилов, Н. Яхонтова һ.б. (Абилов, 1984: 51).

X гасырдан соң XX гасырга кадәр гарәп язуында дөнья күргән язмаларның сүз байлыгы туплана. Бу вакыт – иске төрки әдәби телләр, аерым төрки һәм аерым төрки милли әдәби телләр формалашкан дәвер булып тарихта калган. Күренекле тел белгече, татар әдәби теленең барлыкка килү һәм яшәеш шартларын өйрәнгән галим В. Хаков бу вакыт аралыгындагы тел үсешен аерым чорларга бүлеп тикшерә һәм тикшерү барышында лексик үзенчәлекләрнең үзгәрешенә дә туктала. Болгар дәүләте әдәби теле (X–XIII гасырның урталары), Алтын Урда чоры дәүләте әдәби теле (XIII гасырның икенче яртысы – XV гасырның беренче яртысы), Казан ханлыгы чоры әдәби теле (XV гасырның икенче яртысы – XVI гасырның беренче яртысы), татар милли әдәби теленең үсеше өчен әзерлек чоры (XVI гасырның икенче яртысы – XVII–XVIII гасырлар), татар милли әдәби теленең нормалашу һәм үсеш чоры (XVIII гасырның ахырыннан XX гасыр башына кадәр), XX гасыр әдәби теле (XX гасырның 20 нче елларыннан хәзерге көнгә кадәр) дип аталган чорларны билгели (Хаков, 2003: 14). Шул ук вакытта татар милли әдәби теле формалашу чорын XIX гасырның икенче яртысына нисбәтле рәвештә күрсәтү дә тел белемендә яшәп килә. Әлеге чорларда теркәлгән язма истәлекләрнең теле буенча шактый күп фәнни хезмәтләр язылган, диссертацияләр якланган һәм алар нигезендә монографияләр эшләнгән. Бу хезмәтләрнең һәрберсендә дә диярлек язма истәлекләрнең лексик байлыгы тасвирлана, автор

кулланган сүзләрнең мәгънә төсмерләренә, генетик чыгышына, тематик төркемнәргә, кулланылыш даирәсенә игътибар ителә.

Төрки-татар язма истәлекләре лексикасын өйрәнү тарихы Г. Гайнетдинова тарафыннан яктыртылган (Гайнетдинова, 2016: 37–40). Язма ядкәрләрнең сүз байлыгын, ономастика һәм лексикография өлкәсен өйрәнгән галимнәрнең кайберләрен атап үтәбез: Ш. Абилов, Җ. Алмаз, Ә. Алиева, Я. Әхмәтгалиева, М. Әхмәтҗанов, Н. Баскаков, И. Батманов, И. Бәширова, И. Березин, Г. Благова, А. Боровков, Н. Гаджиева, М. Гайнетдинов, Г. Гайнетдинова, Г. Гайнуллина, М. Гайнуллин, Г. Галиуллина, И. Галәветдинов, Т. Гарипов, К. Дәүләтшин, А. Зайончковский, М. Зәкиев, Л. Җәләй, Н. Исәнбәт, Р. Исламов, А. Исламова, А. Йосыпов, Ә. Йосыпова, Э. Кадирова, А. Кононов, Х. Кузьмина, Г. Кулиев, А. Курышҗанов, Х. Курбатов, А. Маннапова, К. Мусаев, Р. Мөхәммәтрәхимова, Ә. Нәҗип, В. Насилов, Х. Нигъмәтов, М. Нигъмәтуллов, М. Ногман, А. Нуриева, Ф. Нуриева, Л. Покровская, С. Поварисов, О. Порохова, В. Псянчин, А. Самойлович, Г. Саттаров, Ф. Сафиуллина, Э. Севортян, Ә. Тенишев, Э. Фазылов, Ф. Фәсиев, Р. Фәхретдинов, М. Хәйруллин, Ф. Хәкимҗанов, В. Хаков, Ш. Ханбикова, Ф. Хисамова, З. Хисамиева, А. Шәйхулов, А. Щербак, Г. Һадиева, Б. Яфаров һ.б. (Каримуллин, 2000: 157). Бу исемлекне татар теленең диалектларын өйрәнгән галимнәрнең исемнәре белән тулыландыру урынлы булыр, чөнки тел тарихы белән диалектология фәннәре аерылгысыз бәйләнештә яшиләр: Г. Әхәтов, Р. Әхмәтьянов, Р. Барсукова, Ф. Баязитова, М. Булатова, Ф. Йосыпов, Л. Мәхмүтова, И. Насипов, Д. Рамазанова, З. Садыйкова, Д. Тумашева, Т. Хәйретдинова һ.б.

Татар теленең сүз байлыгын тарихи яссылыкта өйрәнгәндә, сүзлекләр аеруча мөһим урын тота. Сүзлекләрне өйрәнү тарихы әлеге хезмәтнең I томында тәфсилле яктыртылды (Татар лексикологиясе, 2015: 14–20). Этимология фәнендә сүзнең эчке һәм тышкы төзелешенә зур әһәмият бирелә. Татар теленең лексик байлыгын этимологик юнәлештә өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләре шулай ук алдагы җыентыкта күрсәтелде (шунда ук: 278–282).

Татар теленең сүзлек составы озак гасырлар дәвамында, төрле географик, икътисади, сәяси, мәдәни шартларда формалашкан. Дөньядагы бер генә телнең дә сүзлек составы саф, асыл хәлдә, ягъни беренчел халәтендә яши алмый. Халыклар бер-берсеннән матди

байлык кына түгел, рухи байлык – сүз байлыгы да алышалар. Хәзерге татар теленең лексикасын борынгы төрки язмаларның сүз байлыгы белән генетик аспектта чагыштырып карасак, башка телләрдән бик күп яңа сүзләр алынганын күрәбез. Бу – тел тарихында бара торган гадәти, норматив күренеш. Кайбер очракта телдәге алынмаларның сан ягыннан күплеге галимнәрне борчуга сала, бу факт телнең көчсезләнүен күрсәтә кебек. Әмма мисаллар моның киресен сөйли. Мәсәлән, бүгенге көндә алынмаларга иң бай телләрнең берсе – инглиз теле. Белгечләр әйтүенчә, инглиз теленең ике йөз меңгә якын сүздән торган актив лексиконының 70% ка якыны – алынмалар (Пахотин, 2003: 5). Шул ук вакытта ул глобаль тел дә булып тора, ягъни дөньядагы иң киң кулланышлы, иң көчле телләрнең берсе.

Күп очракта алынмалар телне йөртүче халыкның тарихи бәйләнешләры турында сөйлиләр. Төрки халыкларның да гасырлар тирәнлегеннән күтәрелгән данлыклы тарихлары бар. Алар цивилизация үсешенең төрле этапларында берничә тапкыр дөньяви масштабка күтәрелгән пассионар халык буларак билгеле (Гумилев, 1992: 20), шуңа күрә төрки тел үзенең үсеш чорларында алынмаларга шактый баеган. Татар теле борынгы төрки тел мирасын үзендә яхшы саклаган. Шул ук вакытта ул, башка төрки телләрдән аермалы буларак, тылмач тел функциясен башкарган, димәк, бу аның алынмаларга сыгылмалыгын тагын да арттырган. Кайбер алынма сүзләр ерак тарихта ук телгә кереп үзләштерелгән булганга күрә, телнең төп лексик үзәген тәшкил итәләр. Аларның алынмалык табигатен сөйләмдә тануы да шактый катлаулы. Мәсәлән, шундыйлардан *җиңги* (санскр. *jeni* – хатын), *чыра(г)* (санскр. *surya* – кояш), *камфара* (санскр. *karpuura*-), *сандал* (санскр. *candana*-) һ.б. сүзләрне күрсәтергә була. Мондый алынмаларның турыдан-туры яисә монгол телләре аша бик ерак тарихта ук телгә кергән булулары мөмкин.

А. Нуриева татар телендәге алынмаларны 6 төркемгә бүлеп карарга тәкъдим итә: 1) кытай, санскрит, борынгы иран алынмалары; 2) монгол алынмалары; 3) гарәп, фарсы алынмалары; 4) фин-угор алынмалары; 5) рус (славян) алынмалары; 6) төрки телләрдән кергән алынмалар (Нуриева, 1975: 9). Татар теле белеме фәнендә, нигездә, монгол, гарәп-фарсы, фин-угор, рус (славян) алынмаларын өйрәнгән хезмәтләр язылган. А. Нуриева «төрки телләрдән

кергән алынмалар» диюе белән галимнәр күзлегеннән беркадәр читтәрәк калган мәсьәләне яктырта. Чыннан да, хәзерге татар телендә кардәш төрки телләрдән, бигрәк тә янәшә территориядә яшәгән төрки халыкларның теленнән кабул ителгән алынмалар бар. Мәсәлән, XX гасырда башкорт теленнән диалектлар аша татар әдәби теленә «беренче тапкыр» мәгънәсендә *тәүге* сүзе килеп керде һәм актив кулланыла башлады. Татар һәм башкорт телләренең үзара бик якын булуы бу сүзнең алынма икәнен яшерә. Шулай ук күрше чуваш теленнән алынган *сыра* сүзе дә (гәрчә чыгышы белән иран телләренә мөнәсәбәтле булса да) татарның үз сүзләре рәтендә карала. Шул рәвешле, мондый сүзләрне табу һәм аларның кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү дә кирәк.

Теләсә кайсы телдә алынмалар барлыкка килсен өчен, аерым шартлар һәм сәбәпләр булырга тиеш. Телдә алынмалар барлыкка килүнең төп сәбәбе итеп, кешенең көнкүрешендә кулланыла башлаган яңа әйберләрне һәм төшенчәләрне атау кирәклеге күрсәтелә. Шул ук вакытта лингвистик, иҗтимагый, психик, эстетик һ.б. сәбәпләр дә исәпкә алына. Кешенең яңа тел формаларына, төшенчәләрне ваклап аңлатуга, тел чараларын төрлеләндерүгә, кыскалыкка һәм ачыклыкка, уңайлылыкка ихтыяҗлар да алынмаларның телгә керүенә сәбәп булып торалар. Мондый сәбәп һәм шартларны галимнәр ике зур төркемгә берләштергәннәр. Э к с т р а л и н г в и с т и к шартларга, мәсәлән, халыкларның тарихи контактлары, яңа предмет һәм төшенчәләрне атау, халык тарафыннан яңа предмет уйлап табылу һәм аны башкаларга тәкъдим итү, сүзләр һәм гыйбарәләр модасы, тел чараларын экономияләү, чыганак телнең дәрәҗәсе (авторитеты), җәмгыятьтәге аерым социаль катламның алынмаларга басым ясавы һ.б. сәбәпләр карый. Э н д о л и н г в и с т и к шартлар телнең эчке мөмкинлекләкләре нигезендә барган күренешләрне билгелиләр: туган телдә яңа предмет өчен эквивалент сүз булмау нәтиҗәсендә алынмага өстенлек бирелү; телнең кыскалыкка омтылу күренеше нигезендә берничә сүз белән бирелә торган аңлатма урынына бер сүздән торган алынма куллану (кыска дистанцияләргә йөгерү – *спринт*); фәнни терминология алу, ягъни мәгънәне ачыклау өчен берничә мәгънәле туган тел сүзе урынына бер мәгънәле чит тел сүзе алу (басу – *компрессия*); синонимнар барлыкка килү (тел белеме – *лингвистика*) һ.б. Шул рәвешле, телдә алынмалар барлыкка килүнең сәбәпләре шактый төрле.

Татар тел белемендә алынмаларны өйрәнү күптәннән башлана. Аерым алганда, телдә киң кулланылган гарәп-фарсы алынмаларын төрле чорларда К. Насыйри, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Ә. Максуди, Ш. Рамазанов, К. Хәмзин, Г. Сәйфуллин, М. Мәхмүтов, И. Әүхәдиев, Й. Вәлитова, Л. Таҗиева, Җ. Зәйнуллин, И. Сираҗиев, Л. Вәлиуллина, Ә. Йосыпова һ.б. өйрәнгәннәр.

Татар теленә ерак гасырларда килеп кергән монгол алынмалары күп түгел. В. Рассадин Көнбатыш себер татарлары телендә барысы 80 ләп, Идел буе татарлары телендә 60 сүз бар дип күрсәтә (Рассадин, 1980: 45). Татар теленә мөнәсәбәтле рәвештә монгол алынмалары Р. Әхмәтьянов хезмәтләрендә тикшерелә. Аерым күзәтүләр А. Дыбо, О. Мудрак, А. Нуриева, И. Насипов хезмәтләрендә бар.

Татар теленә үтеп кергән фин-угор алынмаларын өйрәнүнең торышы да җитәрлек күләмдә түгел. Бу өлкәдә И. Насипов фундаменталь эзләнүләр алып бара. Аерым күзәтүләр Ә. Тенишев, Л. Җәләлетдинов, Л. Мәхмүтова, Н. Борһанова, Д. Тумашева, Л. Арсланов, Р. Әхмәтьянов, Ф. Баязитова, Н. Исәнбаев, Н. Ишбулатов, С. Миржанова, Д. Рамазанова, Р. Рәхимова, А. Рәхимова, З. Садыкова, И. Тараканов, Т. Хәйретдинова хезмәтләрендә күренә.

Рус (славян) һәм һинд-европа алынмаларын өйрәнү шактый яхшы башкарылган. Ә. Ахунҗанов, Ф. Фәсиев, Ф. Сафиуллина, Р. Нурмөхәммәтова, Р. Бурнашева, Р. Йосыпов , М. Хәйруллин, Ә. Йосыпова, Р. Мөхиярова һ.б. хезмәтләрендә рус-европа алынмалары төрле аспектта яктыртыла.

Шул рәвешле, татар теленең тарихи лексикологиясенә караган материалларны галимнәрнең аерым темага багышланган хезмәтләрендә табарга мөмкин, әмма татар теле сүз байлыгының гасырлар дәвамындагы хәрәкәтен системалы рәвештә тасвирлау киләчәк эше булып кала.

## ТӨРКИ-ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ ЛЕКСИКА

### § 2. Татар теленең сүзлек составы формалашу этаплары

Тел һәм сөйләм һәрвакыт үзгәреп тора. Иң беренче чиратта, телне, әлбәттә, халык үзгәртә, үзенең тормышы, көнкүреше үзгәрүе нәтиҗәсендә телгә дә үзгәрешләр кертергә мәҗбүр була. Иҗтимагый-тарихи вакыйгалар, җәмгыятьтәге үзгәрешләр телгә һәм аның

үсешенә билгеле күләмдә йогынты ясыйлар. Җәмгыятьтә вакыйгаларның барышына, иҗтимагый төзелешнең үзенчәлекләренә карап, телнең үсешендә төрле баскычлар – ыруг, кабилә, халык һәм милләт оешу, шуларга яраклы рәвештә кабилә шивәләре, халык теле, милләт теле барлыкка килү. Телгә тәэсир иткән факторлар икегә – тышкы (экстралингвистик) һәм эчке (эндолингвистик) факторларга бүленәләр. Телнең эчке формасын (күбрәк фонетикасын, морфологиясен) үзгәртә торган факторлар эндолингвистик факторларга керә (мәсәлән, элизия күренеше, экономия принцибы нигезендә барлыкка килгән үзгәрешләр һ.б.). Эчке факторлар телнең грамматик яктан камилләшүендә зур роль уйныйлар.

Экстралингвистик (иҗтимагый) факторлар исә телнең грамматик системасына аерым үзгәрешләр кертсәләр дә, аны төптән үзгәртә алмыйлар, әмма лексикасын һәм синтаксик төзелешен сизелерлек дәрәҗәдә үзгәртергә сәләтле. Тышкы факторлар рәтенә без җәмгыять тарихында барган үзгәрешләрне кертеп карыйбыз (халыклар арасындагы сәяси мөнәсәбәтләр, субстрат телләрнең, дин теленең йогынтысы һ.б.). Шул ук вакытта тотрыклы тәэсир иткән экстралингвистик факторлар телнең эчке төзелешенә дә йогынты ясарга мөмкин. Мәсәлән, хәзерге вакытта татар теленә рус теленең көчле йогынтысы бара. Бу татар телендәге [т] һәм [д] авазларының бик йомшак әйтелешенә китерә (*әт'и, дид'е*). Күренгәнчә, телнең үзгәреше төрле сәбәпләр аркасында килеп чыгарга мөмкин.

Алда әйтелгәннәрдән чыгып, татар теленең сүз байлыгы формалашу этапларын күз алдына китергәндә дә без аны, иң беренче чиратта, экстралингвистик факторларга, ягъни җәмгыятьтә барган иҗтимагый вакыйгаларга мөнәсәбәтле рәвештә тасвирлыйбыз. Бу факт язма тел материаллары белән дә раслана. Әйтик, Идел буенда ислам дине таралу, әдәби телдә генә түгел, халык сөйләм телендә дә бик күп гарәп-фарсы сүзләренең кулланылышын китереп чыгара. Димәк, сүзлек составы формалашу этаплары социолингвистик яссылыкта яктыртылырга хаклы.

Телдәге сүзлек составының төп һәм периферия катламнары аерып чыгарыла. Төп катлам – лексик фондның үзгәрешләргә бирелми, яисә аз бирелә торган, тел үсешенең иң борынгы чорларына караган өлеше. Гадәттә, мондый сүзләрнең телдә кайчан барлыкка килүен дә билгеләп булмый. Төп сүзлек составы кардәш

телләрнең барысында да кулланыла, мәгънәви һәм фонетик яктан да тотрыклылык белән сыйфатлана. Аңа бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән һәм тормыш өчен иң әһәмиятле төшенчәләрне белдерә торган тамыр сүзләр һәм ясалма нигезләр, генетик чыгышын билгеләп булмый торган, телнең үз сүзләренә әйләнгән алынмалар керә.

Периферия (читтәге) катлам исә лексик фондның аерым бер чорда телгә килеп кергән яисә телнең үз мөмкинлекләре нигезендә ясалган, үзгәрешләргә күбрәк бирелә торган өлешен тәшкил итә. Мондый сүзләрнең фонетик тышчасы яки мәгънәсе үзгәрергә, телдән төшеп калырга, яңадан кайтырга, башка сүзләр белән лексик-синтаксик мөнәсәбәткә керергә мөмкин. Кайбер очракта читтәге катлам сүзләре дә төп фондка күчә ала.

Татар теленең сүз байлыгы да, башка телләрдәге кебек үк, гомуми кануннар буенча үсә:

1) яңа күренешне, төшенчәне, предметларны атау өчен телнең үз мөмкинлекләре нигезендә яңа сүзләр ясала;

2) күренеш, төшенчә, предметлар халыкның көнкүрешеннән югалу сәбәпле, сүзләр телдән төшеп кала яисә аерым бер стильдә генә кулланылуын дәвам итә;

3) аерым сүзләрнең мәгънәсе үзгәрә;

4) башка телләрдән алынмалар керә;

5) мөстәкыйль мәгънәле сүзләр ярдәмлекләргә әйләнәләр (Нуриева, 1975: 5).

Лексика – борынгы төрки нигез телне торгызу (реконструкция ясау) өчен иң авыр өлкәләрнең берсе. Фонетик һәм морфологик реконструкция ясаганнан соң гына сүзнең эчке мәгънә үзгәрешләрен ачыклау максаты куела. Шул рәвешле, борынгы нигез телнең лексик байлыгын торгызу категориаль һәм лексик-семантик аспектларда башкарыла.

Тарихи планда татар теленең сүз байлыгы формалашу этапларын түбәндәгечә тасвирлап була:

1) алтай тел бердәмлеге (гомумалтай) чоры сүз байлыгы;

2) борынгы төрки нигез тел чоры сүз байлыгы;

3) борынгы төрки телләр чоры сүз байлыгы;

4) иске төрки телләр чоры сүз байлыгы;

5) иске татар теленең үсеш чоры сүз байлыгы;

6) татар милли теле үсеше чоры сүз байлыгы.

## Алтай тел бердәмлеге (гомумалтай) чоры сүз байлыгы

Төрки телләр лексикасының формалашу этаплары турында сөйләгәндә, фәндә төрки телләрнең үсеш тарихында алтай һәм урал-алтай гипотезалары яшәве турында искә алып китәргә кирәк. Билгеле булганча, алтай гипотезасын яклаучылар төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләренең һәм соңгы елларда алар белән бергәлектә карала торган корея, япон-рюкю телләренең уртак нигез телгә барып тоташуы турында сүз алып баралар (Г. Рамстедт, Н. Поппе, М. Рясянен, Җ. Киекбаев, Н. Баскаков, О. Суник, В. Цинциус, А. Дыбо, О. Мудрак һ.б.). Бу фикергә каршы чыгучылар әлеге телләрдәге охшашлыкны алынмалык табигате белән бәйләп аңлаталар (В. Котвич, Дж. Клоусон, Г. Дерфер, А. Щербак, Г. Санжеев, Р. Байтасов һ.б.) яисә ностратик охшашлык турында сүз алып баралар (В. Иллич-Свитыч, Н. Поппе, С. Старостин). 1844 елда ук инде урал телләрен өйрәнүче галим Матиас Кастрен, алтай телләренең уртак нигезен төрки, монгол, тунгус-маньчжур, самодий, фин-угор телләре бердәмлеге тәшкил иткән, дигән фикер әйтә. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында әлеге гипотезаны тулыландырып, урал-алтай гипотезасы барлыкка килә. Соңрак самодий, фин-угор телләре дә урал тел төркеменә берләштереп өйрәнелә башлагач, әлеге гипотеза урал-алтай бердәмлеге атамасын ала (Рясянен, 1968). Хәзерге вакытта урал-алтай телләре арасындагы охшашлыклар ностратик теориягә – дөньядагы аерым тел бердәмлекләренең (безнең ареалга караган алтай, картвель, дравид, һинд-европа, урал һәм афразия телләренең) бер баба телдән үсеп чыгуы турындагы теориягә нигезләнеп аңлатыла.

Глоттохронологик исәпләүләргә нигезләнеп, телләрнең килеп чыгуын өйрәнүче галим С. Старостин борынгы ностратик баба телнең таркалу этапларын түбәндәгечә күрсәтә:

1) б.э.к. XI меңьеллыкларда ностратик телдән баба картвель һәм баба дравид телләре аерылып чыга;

2) б.э.к. X меңьеллыкта баба һинд-европа һәм урал-алтай бердәмлекләре аерыла;

3) б.э.к. IX меңьеллыкта урал-алтай бердәмлеге таркала (Старостин, 2007: 448).

Алтай бердәмлеге исә неолит дәверендә, ягъни б.э.к. VI–V меңьеллыкларга чаклы яшәгән һәм шуннан соң таркала

башлаган (Гоголев, 2015: 65). С. Старостинның иң борынгы ностратик баба телдә фаразый иҗат иткән дүртьюллыгы билгеле:

***Ḳelнä weṭei ʕaḲun kähla
ḳaλai palhʌ-ḳʌ na wetä
śa da ʔa-ḳʌ ʔeja ʔälä
ja-ḳo pele ṭuba wete

*Тел – вакыт елгасы аша күпер,*
*Киткәннәрнең йортына безне илтә;*
*Әмма анда барып җитә алмас*
*Кем тирән судан курка* (тәрҗ. – *Х.К.*).

Әлбәттә, татар теленең сүз байлыгын өйрәнгәндә, без бу кадәр тирәнлеккә төшә алмыйбыз. Әлеге хезмәттә тел тарихына караган кайбер терминнарның мәгънәләрен ачыклап китү сорала. Телнең барлыкка килүе турында бик күп теорияләр бар (Якушин, 1984: 38). Рус телендә язылган хезмәтләрдә «праязык», «язык-основа», «протоязык», «прототюркский язык» дигән терминнар кулланыла. Фәндә ике төрле фикер бар: 1) «праязык» һәм «протоязык» төшенчәләре бер үк; 2) «праязык» дип, борынгы *нигез* тел гаиләлегендә кулланылган телгә әйтәләр, ә «протоязык» дип, тел бердәмлегендә яшәгән телне атыйлар. «Праязык» дигән терминны алга таба иң борынгы нигез тел дип, ә «протоязык» терминын борынгы нигез телгә кадәр яшәгән телгә мөнәсәбәтле рәвештә «баба тел» («прототюркский язык» – баба төрки тел) дип атарбыз (Сравнительно..., 2006: 8), (http://www.russika.ru/t.php?t=1849).

Бүгенге көндә гомумалтай катламына караган сүзләрнең фонетик, морфологик һәм лексик-семантик үзенчәлекләрен реконструкцияләгән «Алтай телләренең этимологик сүзлеге» басылып чыкты (Starostin S., 2003). Шулай ук 2006 елда чыккан «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка» дип аталган коллектив хезмәт тә бу өлкәдә зур казаныш булып тора.

Глоттохронология мәгълүматлары буенча, гомумалтай нигез тел бердәмлеге чоры б.э.к. V меңьеллыклар тирәсендә таркала башлаган. Хәзерге вакытта аның өч төркемгә бүленүе раслана: 1) көнбатыш (төрки-монгол) бердәмлеге (б.э.к. IV меңьеллык уртасында төрки телләр һәм монгол тел гаиләләренә таркала);

2) үзәк бердәмлек (тунгус-манчьжур тел гаиләсе барлыкка килә); 3) көнчыгыш бердәмлек (б.э.к. III меңьеллык уртасында японрюкю һәм корея тел гаиләсенә таркала). Фәндә Моррис Сводешның лексик-статистик юл белән тел туганлыгын исәпләү өчен 100 (соңрак 200, 300) сүздән торган исемлеге билгеле (Сводеш, 1969: 23–52).

Гомумалтай катламына караган уртак лексика туганлык терминнарында, соматик терминнарда, җир-су атамаларында һ.б. очрый (Рамазанова, 2013: 175–178; Дыбо, 1996).

С. Старостин алтай бердәмлегенә караган телләрнең уртак лексикасына этимологик күзәтү ясап, лексик-статистик метод белән М. Сводеш исемлегенә нигезләнгән анализ ясаган (Старостин, 1991: 185):

а) борынгы төрки нигез тел (пратюркский) һәм борынгы монгол нигез телләре (прамонгольский) өчен 100 сүзнең 20 сендә уртак тәңгәл килү очраклары бар: «барысы, күп» (Kop *qou < *kopʿu); «су» (*sub – *u-sun <*su-sun; < *suwA); «озын» (*uŕ - *uŕ-tu < *uŕA); «төтен» (*tüt-ün – *uta-ɣan < *tuta-ɣan; < *tʿutʿV); «йолдыз» (*jul-du-ŕ < *pʿiul-du- : *hol-dun; < *pʿiūl’V); «таш» (*dāl :*čila-ɣun<*tiōl’a); кабык (*kāpuk:*qau-da-<*k(ʿ)āpʿɨ); «түгәрәк, йомры»(*tä(ŋ)gir-/*da(ŋ)kir: *tögürig < *tʿöŋkV); «кем» (*ki-m ~ *ke-m : *ke-n < *kʿe-); «яфрак» (ǰapur-gak:*lab-či-n <*liapʿV); «орлык» (*uru-k: *hüre<*pʿür/a/); «коры» (*kūr-: *qaur-<*kawVrV); «җылы»(*jɨlɨ-g: *dula-ɣan < *dūlɨ-); «ир» (*ǟr: *ere < *ǟre); «кара» (*kara: *qara < *k(ʿ)ara); «нәрсә» (*nä: *ja-ɣun < *ŋia; «яңа» (*jaŋɨ: *sine< *za(i)ŋi); «мин» (*bä- : *bi < *bä-); «без» (*bi-ŕ: *bi-da < *b/ü/-); «йомырка» (*jumurtka< *umurtka: *ömdege-n < *omu(r)-tkV).

Борынгы төрки нигез тел һәм борынгы нигез тунгус-маньчжур телләре өчен 18 уртак лексема табылган: «барлык, күп» (*kop: *kupu- < *kop’u); «чәч» (*kɨl: *xiń-ŋa < *k’lV); «бар» (*jē- : *ǯe- < *ǯē-); «яндыру» (*jak-: *deg-ǯe < dakV); «таш» (*dāl’: *ǯola < *tiōl’a); «түгәрәк, йомры» (*tä(ŋ)ir: *toŋol < *tʿöŋkV); «каурый» (*jüg: *dek-te <*d/i/gu); «бавыр» (*bagɨr : *pākin < *pэkʿɨ-); «таза» (*dōl: *ǯalu< *čэlu-); «кул» (*äl:*ŋāla < *ŋālä); «эт» (*ɨt: *ŋinda < *ŋinta); «йокы» (*u-: *ŋuja < ŋüja); «син» (*sä : *si <*sä); «койрык» (*kuduruk: *xürgü<*kʿudu-rgi); «муен» (тюрк. *boj(ɨ)n : *moŋan <*möj(u)ŋa); «мин» (*bä: *bi < *bä); «без» (*bi-ŕ : *bu(e) < *bü-); «йомырка» (*jumurtka: *umūkta <*omu(r)tkV).

Борынгы нигез монгол теле һәм урта чор корея теле 16 тәңгәллеккә ия: «күз» (*ni-dün: nú-n< *ńiā); «ике» (ǯiw-rin: tūrh<*diüwV); «йолдыз» (*ho-dun < *hol-dun : p□rh < *pʿiūl’V); «исем» (*nere: *nirhu-m<*närV); «таш» (čila-ɣun: tōr(h)<*tiōl’a); «кабык» (*qauda: kàpʿr < *k(ʿ)āpʿɨ); «сөяк» (*ja-sun <*hian-sun: s-pj<*pʿeńiV); «кызыл» (*hula-ɣan: pr-k<*p(ʿ)üla-); «түгәрәк, йомры»(*tögürig: toŋkor-<*tʿöŋkV); «яфрак» (*labčin: níp(h)<*liapʿV); «борын, танау» (*qaŋ-bar: kó(h) <kʿ/u/aŋa); «мөгез» (*eber: s-pər < *epʿVrV); «теге» (*teэ- : tj< *tʿa); «без» (*bi-da: u/-ri/< *bü-); «тел, кәләчи» (*kele-n: hj< kʿäliä); «яңа» (*sine: sái<*za(i)ŋi).

Түбәндәге лексик тәңгәллекләр дә алтай бердәмлеге чорына карый (Байтасов, 2014: 49):

Төрки *suqï* «кытыклау», татар. *сука-лау* «пахать» (чуваш. *суха*, рус. *соха*), маньчж. *сухэ* «балта», япон. *suk*- «сукалау», «кашу», *suki* «көрәк», «сука», индонезия *sungkal* «төрән»;

төрки *üjür* «тары», япон *pije* «тавык тарысы», корея *пхи* «тары», цоу (на Тайване) *fiesï* «чистартылган дөге (яки тары)»;

төрки *arpa* «арпа», мари *арва* «кибәк», япон *ара* «чумиза», тагальское *ара* «бодай кибәге» (корея телендә *аль* «бодай», «уылдык бөртеге»);

төрки čaymur «шалкан», япон *kabu* «шалкан», тагаль *kabuti* «гөмбә», индонезия *gambas* «кече кабак»;

татар. *иген* «иген», коми *ид* «арпа», япон *ine/ina* «дөге (тамырда)», корея *и-* «дөгенеке», тагаль *hinog* «өлгергән, җитешкән», илокано *innapou* «пешкән дөге», индонезия *idjo* «дөге үсентесен сатып алу»;

төрки *kömäč* «көлдә пешкән күмәч», япон *kömö* «бөртекле дөге (чистартылган)», вьетнам *cŏm* «пешкән дөге»;

тува *куду-рук* «койрык», татар. *көрпә*, япон *kudak* «вату», *kudu* «ташландык», «отходы», удмурт. *кыд* «көрпә», «кабык», тагаль *kud kod* «порошок хәленә кадәр төю», «тегермәндә тарттырылган»;

төрки *budyai*, татар. *бодай,* монгол. *buhudai*, маньчж. *мучжи* «арпа», нанай. *муди* «солы», япон *mugi* «ашлык», корея *миль* «бодай».

Мисаллардан күренгәнчә, фонетик яктан охшаш сүзләрдә мәгънәви якынлык көчле.

**Борынгы төрки нигез тел чоры сүз байлыгы**

Хәзерге тюркологик әдәбиятта «гомумтөрки борынгы нигез тел» (пратюркский язык) термины белән «борынгы төрки тел» (древнетюркский язык) терминнары хронологик чик буенча берберсеннән аерыла (Дыбо, 2007: 766). Гомумтөрки борынгы нигез телдән б.э.к. III–II меңьеллыкларда борынгы төрки телләр аерылып чыккан.

Борынгы төрки нигез телгә хас булган лексика борынгы төрки язма истәлекләр һәм хәзерге төрки телләр материалы нигезендә торгызылган. «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: лексика» хезмәтендә меңнән артык борынгы төрки нигез тел сүзләре реконструкцияләнгән (Сравнительно..., 2001: 791). Әлеге хезмәттән кайбер мисалларны китерәбез: **aba* (әти), *ajaz, ajar* (салкын, суык), **ajgici* (киңәшче),**anyzaq* (коры җил), **ajaran* (әйрән), **bökä* (зур елан), **čajan* (чаян), **čiči* (баллы), **ädük* (итек), **jelin* (җилен) һ.б.

Борынгы төрки нигез телдә саннар **bir, *ėki, *üč, *tȫrt, *bēš, *altï, *yeti,*sekiz, *tokuz, *on, *yėgirmi, *otuz, *kïrk, *elig, *altmïš, *yetmïš, *sekizon, *tokuzon, *jür (*yüz)* шәкелендә кулланылган.

**Борынгы төрки телләр чоры сүз байлыгы (V–XI гасырлар)**

Борынгы төрки телләр чоры кайбер хезмәтләрдә борынгы төрки нигез тел чоры белән бергә карала яисә һун чоры (б.э.ның V гасырларына кадәр) дип атала (Баскаков, 2006: 32; Севортян, 1971: 3–12). Язу системасына ия буларак, борынгы төрки тел фактик материалга бай. Фәндә бу телне атау өчен «орхон-енисей теле, орхон-енисей язма истәлекләренең теле» дигән атамалар очраса да, Ә. Тенишев билгеләмәсе буенча, «борынгы төрки телләр» атамасын куллану уңышлырак, чөнки биредә сүз бер тел турында гына бармый, ә берничә тел күрсәтелергә тиеш (Лингвистический..., 1990: 143). Шул рәвешле, борынгы төрки телләр – борынгы төрки халыкларның коммуникатив функциясе югалган язма истәлекләр телен атау өчен кулланыла торган шартлы термин. Монда рун, уйгыр, гарәп язулы текстлар карый. Хронологик чикләр турында төрле фикерләр әйтелә: мәсәлән, С. Малов V гасырдан алып, XV гасырга кадәр араны борынгы төрки язма тел чоры дип билгели һәм шушы аралыктагы XI–XIV гасырларны *д-тел*дән *й-тел*гә күчү һәм дин алыштыру чоры дип күрсәтә (Малов, 1952). Ә. Тенишев билгеләмәсендә руник

койне, ягъни борынгы уйгыр, кыргыз, кыпчак телләренең нигезен борынгы угыз теле тәшкил иткән һәм аның язма башлангыч чоры VII–IX гасырларга карый (Лингвистический..., 1990: 143). Борынгы төрки сүзлектә исә VII–XIII гасырларда язылган язма истәлекләр материалы тупланган (Древнетюркский..., 1969: 677). Ә. Тенишев билгеләмәсендә әрмән мәхкәмә язуларының да борынгы булуы искәртелгәнгә күрә, хронологик соңгы чикнең кайбер урынчылык өчен XV–XVII гасырларга тоташуы турында фикер йөртергә дә мөмкин.

Бу тел беренче тапкыр данияле галим Вильгельм Людвиг Петер Томсен тарафыннан өйрәнелә һәм рун язмаларының шифры ачыклана (1893), россияле галим Василий Васильевич Радлов тарафыннан укыла (1894). Язу системасына ия булганга күрә, без шул чорда теркәлеп калган лексик берәмлекләрне бүгенге татар теле лексикасы белән чагыштырып өйрәнү мөмкинлегеннән файдаланабыз. Татар теле диалектларына мөнәсәбәтле рәвештә, әлеге эш Г. Әхәтов хезмәтендә башкарылган (Ахатов, 1976: 35–36).

Борынгы төрки чор лексикасы тормыш, көнкүреш, яшәеш өчен иң мөһим төшенчәләрнең атамаларыннан тора: *sač* (чәч), *taš* (таш), *qaz* (каз), *jer* (җир), *quduğ* (кое), *kümüš* (көмеш), *bulut* (болыт), *toquz* (тугыз), *bütün* (бөтен) һ.б. Борынгы чорга караган сүз байлыгы исем һәм фигыльләрнең тамырларында, табигать күренешләре, географик һәм астрономик терминнар, үсемлек, җәнлек, кош-корт, хайван, бөҗәк, тән әгъзалары атамаларында, төс исемнәре һәм сан атамаларында, алмашлыкларда табыла.

Борынгы төрки тел хәзерге һәрбер төрки телнең нигезендә ята (бу катлам сүзләре төрки телләрдә бары фонетик яктан гына аерылалар (Нуриева, 1975: 24)). Төрки телләр арасындагы якынлык шуның белән аңлатыла да. Хәзерге вакытта халыкларның һәм телләрнең үзара кардәшлеген билгеләү өчен заманча технологияләр барлыкка килде. Шундый алымнарның берсе ярдәмендә төрки телләрнең матрицасы эшләнгән. Бу таблицага таянып, телләр арасындагы уртаклыкны билгеләп була. Мәсәлән, лексик билгеләр буенча (алынмаларны кертмичә, 215 сүздән торган М. Сводеш исемлеге нигезендә төзелгән таблица) татар теленә иң якын тел – башкорт теле (охшашлык 95%ка якын), ә иң ерак тел – тува һәм саха (якут) телләре (охшашлык 60,2% һәм 60,7%). Шул ук вакытта төрек белән азәрбайҗан, уйгыр белән үзбәк, казакъ белән кыргыз телләренең якынлыгы күзгә ташлана (Булыгина, Соловьев, 2013: 73).

1 нче таблица. *Төрки телләрнең матрицасы*

| | Chuvash | Sakha | Tuvan | Khakas | Altay | Kyrgyz | Kazakh | Uzbek | Uyghur | Karachay | Bashkir | Tatar | Turkmen | Azeri |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Sakha | 51.9% | | | | | | | | | | | | | |
| Tuvan | 49.3% | 57% | | | | | | | | | | | | |
| Khakas | 52.8% | 61.3% | 71.9% | | | | | | | | | | | |
| Altay | 50.9% | 55.9% | 69.3% | 75.6% | | | | | | | | | | |
| Kyrgyz | 57.9% | 59.6% | 63.3% | 70.3% | 74.6% | | | | | | | | | |
| Kazakh | 58.2% | 59.4% | 61.6% | 68.1% | 69.9% | 92% | | | | | | | | |
| Uzbek | 61.1% | 57.8% | 58.2% | 65.3% | 66.3% | 82.9% | 82.8% | | | | | | | |
| Uyghur | 59.2% | 59% | 61.7% | 65.7% | 70.2% | 83.8% | 81.9% | 86.3% | | | | | | |
| Karachay | 57.5% | 60.8% | 58.7% | 65.1% | 65.2% | 77.8% | 78.3% | 74.6% | 77.1% | | | | | |
| Bashkir | 58.3% | 59.4% | 59.9% | 67.1% | 69% | 82% | 79.9% | 76.1% | 78.5% | 77.4% | | | | |
| Tatar | 59.4% | 60.7% | 60.2% | 68.2% | 70.1% | 83.9% | 82.1% | 78% | 79.6% | 79.2% | 94.9% | | | |
| Turkmen | 55.6% | 55% | 54.7% | 61.2% | 59.5% | 71.2% | 71.9% | 75.9% | 71.7% | 69.2% | 71.9% | 69.8% | | |
| Azeri | 55.6% | 51.8% | 51.8% | 56.4% | 58.4% | 66.9% | 67.8% | 70% | 68.8%. | 66.9% | 66% | 68.4% | 78.2% | |
| Turkish | 54.9% | 52% | 50% | 53.8% | 54.4% | 64.9% | 64.8% | 67.2% | 66.7% | 64.2% | 62.8% | 65.6% | 73.6% | 86% |

2 нче таблицада төрки халыкларның кардәшлеген күрәбез. Хәзерге заман фәнендә кешенең һәм милләтләрнең килеп чыгышын популяцияле генетик үсешкә нигезләнеп аңлата торган эзләнүләр (гаплотөркемнәр теориясе) барлыкка килде. Түбәндәге таблицадан күренгәнчә, генетик мәгълүматлар башкортларның (фин-угор субстраты йогынтысы), казакъларның (монгол субстраты йогынтысы) һәм якутларның (палеазиат һәм монгол субстраты йогынтысы) төрки нигездән ерактарак урнашуын чагылдыра (Булыгина, Соловьев, 2013: 69–81).

2 нче таблица. *Y-гаплотөркемнәр ешлыгы мәгълүматлары буенча күп үлчәмле шкалага салу киңлегендә төрки халыкларның урнашуы (стресс 0.06)*




Шул рәвешле, хәзерге чор эзләнүләре борынгы этник һәм лингвистик процессларны аңларга ярдәм итә. Борынгы төрки халыкларның сәяси, мәдәни һәм икътисади тормышы, миграциясе телдә (бигрәк тә лексик планда) бик күп үзгәрешләр китереп чыгарган һәм хәзерге телләрнең лексик фонды ясалуга зур өлеш

керткән. Мондый үзенчәлекләр чиктәш фәннәр кысаларында яңа технологик алымнар белән шактый төгәл ачыклана ала. Соңгы вакытта татар теленә караган эзләнүләрнең дә җанлануы күзәтелә (Е. Булыгина, В. Соловьев һ.б. хезмәтләре).

### Иске төрки телләр чоры сүз байлыгы (XI–XV гасырлар)

Бу чор татар тарихында Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда дәүләте чоры буларак билгеле.

Х гасырда төрки кабиләләрнең хәрби берләшмәләре урынына беренче феодаль дәүләтләр барлыкка килә. Көнчыгыш Төркстаннан алып, Көньяк Тянь-Шань буйларына кадәр булган җирләрдә караханиларның беренче дәүләтләре төзелә. Бу дәүләтнең сәяси һәм мәдәни үзәге Кашгар һәм Баласагун шәһәрләре була. Әлеге үзәкләрдә караханид гомумхалык сөйләмә теле оеша. Нигезен уйгыр-карлук кабилә телләре тәшкил итсә дә, аңа барлык башка төп регионнардагы төркиләрнең телләре дә катнаша. Бу телдә аралашучыларны борынгы язма әдәби тел канәгатьләндерми, чөнки ул сөйләмә телдән шактый ераклашкан һәм аралашу вазифасын үтәргә сәләтсез булып кала. Димәк, Х гасырда борынгы төрки телне караханид гомумхалык теленә якынайту һәм гарәп-фарсы алынмаларын активлаштыру нәтиҗәсендә яңа әдәби тел формалаша, ул чагыштырмача тиз арада язма әсәрләр аркылы барлык төрки регионнарга тарала һәм киң күләмдә кулланыла башлый. Бу әдәби тел тюркологиядә гомуми иске төрки әдәби тел дип атала. Ул XI–XV йөзләрдә төрле регионнарда – Караханид, Сәлҗук, Идел-Болгар, Дәште Кыпчак, Алтын Урда, Харәзем һ.б. территорияләрдәге төркиләр өчен уртак, гомуми булуы белән характерлана (Зәкиев, 1987: 119).

Димәк, алда сөйләгәннәрдән нәтиҗә ясап, иске төрки әдәби телнең төп билгеләрен күрсәтергә мөмкин: 1) караханид-уйгыр дәүләте гомумхалык сөйләмә теленә нигезләнгән булуы; 2) киң территориядә яшәгән төркиләр өчен уртак, аңлаешлы характерда булуы; 3) төрки халыкларда уртак дин – ислам дине кабул ителү нәтиҗәсендә уртак язу системасына ия булу.

Иске төрки чор сүз байлыгына язма истәлекләрнең – әдәби һәм фәнни әсәрләрнең, сакланып калган сүзлекләрнең һәм гомумхалык сөйләмә теленең лексикасы карый. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (1233), авторы билгесез «Ана вә угыл» дастаны, Котбның

«Хөсрәү вә Ширин» (1342), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353), авторы билгесез «Кисекбаш китабы», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1370), Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» (1391), Сайадиның «Дастаны Бабахан» һ.б. әсәрләрдә шушы чорның лексик байлыгы тупланган. «Татар әдәби теле тарихы» (2015) хезмәтендә әлеге чор теленә хас үзенчәлекләр төгәл һәм җентекле яктыртыла (Татар..., 2015: 133), шуңа күрә биредә лексикага кагылышлы төп тенденцияләрне генә әйтеп узабыз. Беренчедән, әлеге чор язма истәлекләренең телен, шул исәптән лексикасын да, галимнәр катнаш характерда булган дип исәплиләр (Наджип, 1979: 87). *Катнаш* дигән термин үзе үк бәхәсле саналса да, бу чор язма истәлекләрнең телендә угыз, уйгыр, карлук, кыпчак тел элементларының фонетик, морфологик һәм лексик планда аралашып, катнашып килүе һәм күп вариантлылык барлыкка китерүе бәхәссез. А. Нуриева бу чор сүзләрен генетик төркемчәләргә бүлгәндә, үтә сак якын килергә киңәш итә, чөнки төрки телләрдә кайбер сүзләр фонетик билгеләре буенча гына аерылырга мөмкин, ә тамыры гомумтөрки катламга карый (Нуриева, 1975: 29). Иске төрки телдә төп лексик фондны, һичшиксез, гомумтөрки катлам сүзләре тәшкил итә, шуңа өстәмә рәвештә аерым лексик берәмлекләр теге яисә бу этник төркем (кабилә, халык) телен чагылдыралар. Мәсәлән, Н. Баскаков угыз һәм кыпчак сүзләрен түбәндәгечә аера: *илгәри (угыз) – бурун (кыпчак), курт (угыз) – бөри (кыпчак), әл (угыз) – кул (кыпчак), алын (угыз) – маңгай (кыпчак), көпәк (угыз) – ит/эт/ыт (кыпчак), өзгә (угыз) – башка (кыпчак), капу (угыз) – ишек (кыпчак), ийги (угыз) – яхшы (кыпчак)* (Баскаков, 1962: 245). Әмма бу сүзләрнең күбесе хәзерге телләрдә вариатив рәвештә кулланылалар. Мәсәлән, кыпчак төркеменә караган татар телендә бу сүзләрнең угыз вариантлары да кулланыла: *элгәре, үзгә* сүзләре төп лексик фондны тәшкил итә; *капу* сүзеннән ясалган бик күп сүзләр хәзерге татар телендә кулланышта йөри (*капка, каптыргыч, кабак (күз кабагы), капчык, капкан* – этимонында «ачу/ябу» мәгънәсе булган лексемалар); *ийге – игелек, изгелек, игелекле* сүзләрендә очрый. Бу күренешкә күренекле тел тарихы белгече В. Хаков та игътибар итә: «Әмма мәсьәләнең катлаулылыгы шунда ки, еш кына кыпчак теленә хас дип каралган элементлар башка төрки телләр өчен дә уртак булып чыга. Язма истәлекләрдә күпчелек очракта кыпчак-угыз телләренә

хас күренешләрнең бик тыгыз аралашып килүе күзәтелә», – дип яза ул (Хаков, 1970: 168).

Икенчедән, иске төрки телләр лексикасы, төп төрки лексик үзәк белән беррәттән, төрле төркем телләргә караган алынмаларның шактый күп кулланылуы белән аерылып тора. Әлеге чорда төрки халыкларның күбесе бер дин – ислам дине астына берләшкән, шуңа күрә гарәп-фарсы алынмалары әдәби телләргә генә түгел, гомумхалык сөйләменә дә үтеп кергән. Шуның белән бергә, иске төрки лексикада элегрәк чорда кергән санскрит, кытай, монгол алынмалары да яшәвен дәвам итәләр. Ә. Тенишев уйгыр язмаларында бигрәк тә санскрит һәм кытай телләренгән кергән сүзләр еш очравы турында яза (Тенишев, 1997: 35). Дини һәм фәлсәфи, фәнни һәм әдәби өлкәләргә караган язмаларда күпсанлы алынмалар кулланылган: *ačari ~ ačary* (санскр. *acarya*) – остаз, укытучы; *adištit* (санскр. *adhisthita*) – рәхәтлек; *vixar* (санскр. *vihāra*) – монастырь; *vačir* (санскр. *vajra*) – алмаз, жезл, скипетр; *nirvan* (санскр. *nirvāna*) – нирвана, тынлык; *vidja* (санскр. *vidyā*) – белем, зирәклек; *aditja* (санскр. *āditya*) – кояш, яктылык чыганагы; *bušy* (кыт. *буши, po-ši*) – хәер; *baqšy* (кыт. *боши, bag-ši*) – остаз; *vū* (кыт. *фу, bvy*) – амулет; *lū* (кыт. *лун, luŋ*) – аждаһа, елан; *niv* (фарс. *nēv*) – батыр, герой; *kägdä ~ kägädä* (гар.) – кәгазь; *qajät* (гар.) – биек; *qaq* ~ haq (гар.) – хак, бәһа, кыйммәт һ.б.

Караханид-уйгыр, харәзем, чагатай, сәлҗук, мәмлүк-кыпчак язмаларында гарәп алынмалары төп урынны алып торалар: *din* (гар.) , *ajat* (гар.) – билге, галәмәт; *va'z* (гар.) – вәгазь; *du'a* (гар.) – дога; *mürüvvät* (гар.) – батырлык, дан; *rahmat* (гар.) – рәхмәт; *sa'adät* (гар.) – бәхет һ.б.

XIII гасырда Идел буенда Алтын Урда дәүләте төзелгәч, иҗтимагый-сәяси, икътисади мөнәсәбәтләр белән бәйле рәвештә, Идел буе төрки язма телендә дә үзгәрешләр барлыкка килә. Бу чорда кыпчак теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелә. Шигъри әдәби әсәрләрнең телендә Көнчыгыш (фарсы, гарәп) илләреннән кергән тел бизәкләре (сурәт барлыкка китерү өчен, сүзләрнең күчерелмә мәгънәләреннән иркен файдалану) җирле төрки тел мөмкинлекләре белән аралашып яшәвен дәвам итә.

Шул рәвешле, иске төрки әдәби телнең региональ вариантларга бүленүе, аерым әсәрләр телендә теге яки бу вариантның өстенлек итүе бу чорның үзенчәлеге булып тора.

## Иске татар теленең үсеш чоры сүз байлыгы (XV–XVIII гасырлар)

XV гасырның беренче яртысында Казан, Кырым, Әстерхан һәм Себер ханлыклары бүленеп чыга. Империя таркалу нәтиҗәсендә оешкан яңа ханлыклар арасында иң көчлесе, һичшиксез, Кырым ханлыгы булган. Казан ханлыгы исә, турыдан-туры Идел буе Болгар дәүләтенең варисы булган хәлдә, XIV гасырның икенче яртысы – XV гасырларда икътисади яктан алга киткән дәүләтләрнең берсе булган. Казан ханлыгы составына җирле төрки халык берләшкән. А. Курбский (XVI г.) язуынча, Казан ханлыгында татар теленнән кала, тагы биш тел яшәгән: мордва, чуваш, черемис, ар һәм башкорт телләре. Бу факт ханлыкның этник составы төрле булганлыгын күрсәтә.

Билгеле булганча, Алтын Урдада дәүләт теле функциясен кыпчак теле башкарган. Кыпчаклар Казан ханлыгы территориясендә дә актив урнашып калганнар. Шуңа күрә дә татар халкы теле үсешендә болгар һәм кыпчак компонентлары төп роль уйнаган дип карала. XV–XVI гасырларда уртак төрки телдән аерым иске төрки телләр бүленеп чыга. Алар беренче вакытта үз гомумхалык сөйләмә телләренә ныклап нигезләнеп китә алмыйлар, шуңа күрә халык сөйләмә нормаларына караганда, үзара якынрак булалар, ягъни аларда гомумилек, уртаклык нык саклана. Соңрак исә аерым төрки халыклар этник яктан яхшы формалашканнар, алар үз дәүләтләре территориясендә үзләренең шәһәр койнесына һәм фольклор теленә нигезләнгән гомумхалык сөйләмә телләрен кулланганнар, гомуми уртак иске төрки телне дә шул гомумхалык нормаларына якынайта барганнар. Шул юл белән аларның һәркайсында язма әдәби тел барлыкка килгән (Зәкиев, 1998).

Иске татар теле, әйтеп үтелгәнчә, XV йөздә Казан ханлыгында татар халкы белән бергә формалаша. Татар халкы, электән үк язу куллану традициясе булган кабиләләрдән оешканлыктан, башта ук язма әдәби телгә ия була. Иске татар әдәби теле дә гомуми уртак иске төрки телне, бигрәк тә аның Идел-Урал локаль вариантын, гомумхалык сөйләмә теленә билгеле дәрәҗәдә якынайту нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ләкин башлангыч чорда алар үзара ныклап якынаеп китә алмыйлар, киресенчә, XIX гасырның икенче яртысына кадәр язма әдәби тел гомумхалык сөйләмә теленнән шактый ерак тора.

Әлеге чорның лексик байлыгы язма истәлекләр һәм фольклор телендә чагылыш тапкан. Бу чорда иҗат иткән шагыйрьләрдән Мөхәммәт Әмин хан, Мөхәммәдъяр, Өммикамал, Максуди, Кол Шәриф һ.б.ны әйтергә мөмкин. Фольклор әсәрләре халык арасында популяр булган, хан тарафыннан бирелгән ярлыклар сакланып калган. «Хан кызы бәете», «Ханәкә солтан бәете», «Алпамша», «Амәт», «Идегәй», «Казан алынганы бәете», «Шаһгали бәете» дастаннары һәм бәетләре телдән-телгә сөйләнеп йөргән.

Казан ханлыгының шигъри мирасында Мөхәммәдъяр иҗаты иң югары урында тора. Аның «Төхфәи Мәрдан» («Егетләр күрке» – 1539) һәм «Нуры Содур» («Йөрәкләр нуры» – 1542) әсәрләре билгеле. Бу әсәрләрнең сүз байлыгы Э. Кадирова тарафыннан җентекле өйрәнелгән (Кадирова, 2001).

Казан ханлыгы чорында әдәби тел стильләре үсеп китә һәм лексик яктан формалаша. Мәсәлән, рәсми-канцелярия стиленә караган ярлыкларның теле үзенчәлекле: *суйургал* – бүләк итеп бирелгән җир биләмәсе; *угыл* – шаһзадә, принц; *хатун* – бикә, принцесса; *чүрә* – ирекле ялчы (кол түгел); *атлыг* – исемле; *йасак* – салым; *төтен саны, йир хәбләсе* – салым атамалары, *ирәк* – крепость һ.б. *Тәңре, тархан, йул, эз, йөк, кура, ык, үксез, башлыг, ил агалары, урман, кунак, илче, тәкый, санлыг, тамга, иген-саба, көч* һ.б. төрки сүзләр кулланылган. Дини вәгазьләр стиленә караган «Коръән тәфсир»еннән алынган өзек шул чор лексик байлыгын күз алдына китерергә ярдәм итә: «jäğni Aja dähi mänäzil täqdir qylduq. Küktä gah artar, gah tular, gah äkselür, ayuŋ axyrynda kälbe ajdur, här kön ber mänzilä inär vä ber mänzilä çyqar ta şul qarargahenä irşür ki. Andan ütä käçmäk juq. Andan dünüb kirü jaqyn mänzilenä kälür vä dähi dimeşlär. Kem ay mänzillärene utuz köndä däver idär. Nätikem könäş ber jylda säir idär. Mukail äjdür: Ajuŋ ine säksän farsahdur, däkürmidür könäş ine dähi...., amma ikeseneŋ ruşanlyğy jaradyldyğy vaqty ber di. Ajuŋ tuqsan tuquz bähşen alyb könä virdelär ve güneş daha fazla ışık saçmaya başladı. Anuŋ ruşanlyğy zijara uldy. Aj ber könäş nurilä qaldy vä dähi aj mänzilenä irçäk incälüb sarar, şul hurmäneŋ qorymyş incä bodağyna täşbija qyldy...» (Кадирова, 2014: http://www.science-education.ru/120-15716). Биредә кулланылган сүзләрнең күбесе төрки-татар нигезле булып тора: *кук, көн, инәр, чыкар, кәлүр, кем, ай, әйдүр, көнәш, бер, йылда, йарадылдыгы, туксан тукыз, ышык, сачмайа, шул, бодагына, кылды* һ.б.

XVII–XVIII гасырларда иҗат иткән татар әдипләре һәм шагыйрьләре әсәрләренең теле дә халык яшәгән иҗтимагый шартлар белән аерылгысыз мөнәсәбәттә үскән. Ф. Хисамова XVII–XVIII гасыр телендә ике тел юнәлешен аерып чыгара: 1) Алтын Урда чорының кыпчак нигезле төрки теленә барып тоташкан һәм гомумхалык сөйләм теле үзенчәлекләрен үзенә алган региональ әдәби тел. Күбрәк дәрәҗәдә уйгыр-караханид теле, азрак күләмдә угыз теле чагылган тел үрнәге. Бу вариантта Мәүлә Колый, Утыз-Имәни, Габди, Габдессәлам иҗат иткән, прозада «Кәлилә вә Димнә» әсәре, «Мәҗмугыл-хикәят», Кадыйр Галибәк әсәре язылган, рәсми-канцелярия стилендә эш кәгазьләре төзелгән; 2) эш кәгазьләре теленә караганда, XVIII гасырның икенче яртысыннан чагатай әдәби теле традицияләре көчәя. Бу тенденция лексикада гарәп-фарсы элементларының күп кулланылуында чагыла.

XVI–XVIII гасырларда татарларда гыйльми әдәбияттан да җирле авторларның әсәрләре булган, ләкин әлегә алар тиешенчә өйрәнеп тикшерелмәгәннәр. Татарларның гыйлемгә, фәнгә ихтыяҗын, иң беренче чиратта, Көнчыгыш фәне классиклары үтәгән. Күп кенә татар галимнәренең әсәрләрен гарәп телендә иҗат итүләре дә билгеле. Бу, әлбәттә, татар әдәби теле лексикасының гарәп-фарсы алынмалары белән кирәгеннән артык чуарлануына юл ача.

XVIII гасырда татар теле тарихында сәяхәтнамә, васыятьнамә һәм елъязмалар жанрлары барлыкка килә. Иң беренче төрки язма сәяхәтнамәләрдән 1698 елда төзелгән Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети сәяхәтнамәсен, 1751–1783 елларда төзелгән «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе»н, 1783 елда сәяхәткә чыккан Мөхәммәтәмин бине Гомәр сәяхәтнамәсен күрсәтергә мөмкин. Лексик-грамматик яктан сәяхәтнамәләрнең теле, нигездә, гомумхалык теленә якынлыгы белән аерылып тора. Бу бигрәк тә әсәрләрнең лексикасында, халык теленә хас ирекле синтаксик конструкцияләрдә, фразеологик әйтелмәләрнең күп кулланылуында чагыла. Сәяхәтнамә телендә угыз һәм кыпчак формалары аралашып килә, лексикасында кыпчак лексик берәмлекләре өстенлек итә, гарәп-фарсы алынмалары шактый тотрыклы (Алеева, 1990): *«Йәнә һәркем ирсә Истанбул қапқа қәлғасының олуғлықыны сурсаңыз, мәглүм қыйлайық. Өч йөз алтмыш қапқасы вардыр. Һәр қапқаның аралары сикезәр чақырымдыр. Йәнә шәһәр ичиндә урамының хисабы сиксән*

*мең урамдыр. Йәнә шәһәрнең ичиндә йите таг вардыр. Йәнә йити дәрйасы вардыр...*» («Мөхәммәт Әмин сәяхәтнамәсе»).

Бу чордагы иң күренекле шагыйрьләрнең берсе – Мәүлә Колый (Бәйрәмгали Колыев). Генетик эшләнеше белән М. Колый әсәрләренең теле, бер яктан караганда, гарәп-фарсы элементлары белән чуарланганнар, ә, икенче яктан, кайбер хикмәтләр гомумхалык теленә бик якын торалар. Мәсәлән:

*Галимнәр күк йөзендә қойаш йаңлыйг,*
*Шәкердләр тулуб торган айга йаңлыйг,*
*Мөэминнәр күк йөзендә йолдыз йаңлыйг,*
*Наданнар қоңгыз-қортқа охшар булгай.*

Яисә:

*Кыш килдисә, көннәре суық булыр,*
*Йақтысы аз, қараңгысы чуқ-чуқ булыр,*
*Карыйлық адәмигә қыш тик кәлүр,*
*Шатлық китәр, золмәт қыйлур қодрәт берлә.*

Әсәрнең лексикасында язма китап теле традициясе дә зур урын ала: *ултур, тултур, анлар*, *йер, йил,агыз, агыр, йукары, чыкыб. сәңәк (сөйәк), агыз, тәвә, тун* һ.б.

Шул рәвешле, XV–XVIII гасыр татар әдәби телендә лексик яктан без ике тенденцияне күзәтә алабыз: 1) классик иске төрки телгә (китап теленә) караган сүз байлыгы кулланыла; 2) татар халкы этник яктан формалашу белән бергә, региональ, Идел буе татар теленә хас лексик берәмлекләр әдәби телдә тотрыклы урын ала.

### Татар милли теле үсеше чоры сүз байлыгы (XIX–XXI гасырлар)

Әлеге чор эчендә берничә кечерәк этапны аерып чыгарырга мөмкин:

1) XIX гасыр татар теле лексикасы;

2) XX гасырның беренче чирегендә әдәби тел лексикасындагы үзгәрешләр;

3) 1920–1940 елларда татар әдәби теле сүз байлыгы формалашу;

4) 1941–1960 елларда классик татар әдәби теле лексикасы;

5) Торгынлык чоры (1960–1985) татар әдәби теле лексикасы;

6) Яңарыш чоры татар әдәби теле лексикасы;

7) XXI гасыр татар әдәби теле лексикасы.

XIX гасыр, бигрәк тә аның икенче яртысы һәм XX йөз башы – татар халкы һәм татар әдәби теле тарихында үзгәрешләргә бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чорлардан санала. Әлеге гасыр дәвамында әдәби тел нормаларының үсешенә нәшрият, китап басу эшенең киңәюе, матур әдәбият, фәнни һәм публицистик әсәрләрнең киң күләмдә чыга башлавы, шулай ук татар халкының тарихы, мәдәнияте, этнографиясе өйрәнелә башлау да тәэсир итә (Хаков, 2003: 153). Әдәби телнең тулысы белән татар халкының гомумхалык сөйләменә нигезләнеп үсә башлау вакыты да шушы чорга карый. Мондый әдәби тел бары милләтләр формалашу вакытында гына барлыкка килә. Катлаулы гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышы чикләнү, әдәби сөйләмгә күбрәк халык телендә йөргән сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең килеп керүе, сөйләмдәге катлаулы лексик конструкцияләрнең төшеп калуы, мәгънә белдерүнең гадиләшүе – болар барысы да милли телнең үсешендә бара торган кануный үзенчәлекләр. Тел милләт ихтыяҗларына җавап бирерлек берәмлекләрне нормалаштыра, аларның сөйләмдә тотрыклануына китерә.

XX гасырның беренче чирегендә әлеге күренешләр дәвам итә һәм көчәяләр. Моңа гасыр башында барган иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның да (1905 елгы беренче буржуаз инкыйлаб, рус-япон сугышы, беренче татар газетасы чыгу һәм татар матбугаты барлыкка килү, Беренче Бөтендөнья сугышы, 1917 елгы инкыйлаби вакыйгалар һ.б.) тәэсире зур була. Инкыйлабтан соңгы елларда әдәби телнең лексик байлыгы тулысынча гомумхалык сөйләменә корылырга тиешлеге көн тәртибенә куела. Гарәп-фарсы сүзләре рус һәм рус теле аша кергән һинд-европа алынмалары тарафыннан кысрыклап чыгарыла (моны ислам дине белән көрәшүнең бер чагылышы буларак та бәяләргә мөмкин). Беренче чорда рус сүзләре татар теленә үзләштерелеп кабул ителсә, XX гасырның икенче яртысында алар инде чыганак телдәгечә әйтелә һәм языла башлыйлар. 1920–1940 елларда татар әдәби теле, тулысынча диярлек, югары стильгә караган «китап сүзләре»ннән арына. 1941–1960 елларда татар әдәби теле лексикасына телнең үз җирлегендә ясалган һәм чит телләрдән алынган яңа сүзләр-терминнар килеп керә, беренче орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләр эшләнә. Бу процесс алдагы этапта да дәвам итә. 1960–1985 еллар хәзерге татар теле лексикасының төп норматив берәмлекләре тотрыклануы белән аерылып тора, монда шул чор язучыларының өлеше бик зур

була. Аңлатмалы һәм ике тел сүзлекләре эшләнә, лексикография фәне алга китә. 1985–2000 еллар татар лексикасына шактый зур үзгәрешләр алып килә. Бу – илдә барган үзгәртеп кору, СССР таркалу, Татарстанның чагыштырмача мөстәкыйльлек алу еллары. Иң беренче чиратта, 1920–1940 елларда телдән төшерелгән кайбер гарәп-фарсы алынмалары махсус кире кайтарыла. Мәсәлән: *һәндәсә* (геометрия), *рәкым* (цифр, сан), *фәза* (пространство), *рәкымче* (математик), *кәшефчелек* (уйлап табу), *бикләү* (ятлау), *мөгамма* (проблема), *даир* (бәйләнешле) һ.б. Телнең үз мөмкинлекләре ярдәмендә яңа сүзләр-терминнар ясау күренеше башлана (*боралак* (вертолет), *сайлак* (меню), *басак* (принтер), *буяу* (тонер), *төймәсар* (клавиатура), *буяк* (картридж), *янар* (фонарь), *кирмән* (кремль), *пулат* (палата), *уын* (ванна), *өтке* (утюг), *әрлус* (рельс), *көл аслык* (колосник), *канаусыз* (канализация), *сала* (поселок) һ.б.), дәүләт һәм шәһәр исемнәрен үзгәртеп язу күзәтелә (Россия – *Русия*, *Рәсәй*, Европа – *Аурупа*, Германия – *Алмания*, Венгрия – *Маҗарстан*, Грузия – *Гөрҗестан*, Свердловск – *Свирдлау* һ.б.). Бу – татар әдәби телен рус алынмаларыннан арындыру максатында эшләнде, әмма гарәп-фарсы һәм ясалма татар сүзләренең күбесе телдә тотрыклылана алмадылар. XXI гасырда элек төшеп калган рус сүзләренең шактый өлеше яңадан татар теленә әйләнеп кайтты, алай гына да түгел, әдәби телнең төрле стильләренә (фәнни, публицистик, рәсми-канцелярия стильләренә) шактый күләмдә яңа һинд-европа һәм рус алынмалары килеп керде.

Шул рәвешле, татар теле сүз байлыгы үзенең формалашу тарихында шактый үзенчәлекле юл кичкән. Телнең сүзлек хәзинәсе туктаусыз хәрәкәттә тора. Телдәге сүзләр гасырлар дәвамында эволюцион үсеш кичерәләр: мәгънә ягыннан тараялар яки киңәяләр, яисә телдән төшеп калалар һәм яңадан әйләнеп кайталар. Телгә яңа алынмалар, неологизмнар килеп керә. Боларның барысы да җәмгыятьтәге иҗтимагый-тарихи вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә тора.

## § 3. Хәзерге татар телендә кулланылган борынгы төрки сүзләрнең лингвистик үзенчәлекләре һәм лексик-тематик төркемнәре

Хәзерге татар теле сүз байлыгының төп катламы борынгы төрки сүзләрдән тора. Алда әйтелгәнчә, әлеге катлам сүзләре VII–XI гасырларда язылган рун, уйгыр һәм гарәп язулы истәлекләрдә

теркәлеп калган, шуңа күрә без сүзләрдәге мәгънә үсешен хәзерге татар теле белән тарихи-чагыштырма яссылыкта өйрәнә алабыз. Лексик мәгънәләрнең үсеше берничә юнәлештә бара:

1) төрки сүзләрнең бер өлеше семантик үзгәреш кичермәгән хәлдә татар телендә сакланып калган: *ат, таш, арка, ак, кара, тай, күз, аз, канат, кылыч, таң, күк, таң* һ.б. Гадәттә, мондый сүзләр бер яисә ике иҗектән тора, тамыр сүзләргә карый, фонетик яктан инлаутта *т//д, к//г, қ//ғ* оппозициясендә саңгырау тартык аваз килүе белән аерылып торалар. Сирәк кенә булса да, сүз башы яңгырау булырга мөмкин: *дүрт, дөя* (татар телендә *тәвә* варианты белән берлектә кулланыла *(тәвә кошы)*);

2) кайбер сүзләр тарихи үсеш барышында искереп, телдән төшеп калганнар: *сү (гаскәр), сүңүш (сугыш), талуй (диңгез), каңым (атам), йаблак (начар), кү (дан, хәбәр), чыгай (ярлы), йалавач (илче), бәрк (йорт), тугъ (байрак), йазы (дала)* һ.б.;

3) еш кына, сүзләрдә мәгънә тараю күзәтелә: мәсәлән, борынгы төрки телдә *тон* (тун) сүзе гомумән «кием» мәгънәсендә кулланылса, хәзерге татар әдәби телендә ул бары «мехтан эшләнгән кышкы кием» мәгънәсендә йөри; *йорт (ил, дәүләт, Ватан)*, *тарыг* (чәчеп үстерелә торган бөртекле культуралар), *йылкы* (атлар) сүзләренең дә мәгънәсе тарайган;

4) сүзләрнең тарихи үсешендә мәгънә киңәю очраклары да күзәтелә: *ил* (халык) сүзе хәзерге вакытта «дәүләт» мәгънәсендә; *күн* сүзе элек «кояш» мәгънәсен генә белдерсә, хәзерге вакытта *көн* шәкелендә «тәүлекнең якты вакыты, тәүлек» мәгънәсендә кулланыла; борынгы төрки *йер* сүзенең «туфрак, урын, торак, планета» мәгънәләре үсеш алган;

5) борынгы төрки сүзләрнең тамыр составында фонетик үзгәрешләр барлыкка килгән очракта да сүзләр төрле мәгънәдә кулланыла башларга мөмкин. Мәсәлән, татар телендәге *игелек* һәм *изгелек* сүзләренең семантикасы аерыла, әмма аларның борынгы тамырлары бер үк – *ий-/из-*. *Яшь* һәм *ел* сүзләрендә дә шушы ук күренеш белән очрашабыз: борынгы *йа-//йә-* тамырына ламбдаизм һәм шетацизм закончалыкларына буйсынган төрле кушымча ялганып, мәгънә үсеше аерымланган: яшь – «возраст», ел – «год» мәгънәсендә кулланыла;

6) татар телендәге борынгы төрки тамырларга аерым морфологик күрсәткечләр ялгану да үзенчәлекле мәгънә барлыкка ки-

терә. Мәсәлән, бер тамырдан булган *имеш* һәм *икән* сүзләрендә мәгънә аерымлыгы күзәтелә (*-мыш* кушымчасы угыз төркеме телләренә, *-кән* кушымчасы кыпчак төркеме телләренә карый, грамматик-семантик яктан икесе дә билгесез үткән заман кушымчасы булып торсалар да, *-меш* кушымчасындагы билгесезлек мәгънәсенә шикләнү төсмере дә өстәлә). Сорау алмашлыкларындагы *кай-* яки *нә-/ни-* тамырына нинди кушымча ялгануга карап, шулай ук сүзнең мәгънәсе үзгәрә: *кайда*? (где), *кайдан* (откуда), *кайчан* (когда), *кайсы* (который), *нинди* (какой), *нигә* (зачем), *нидер* (что-то), *никтер* (почему-то), *ничек* (как), *нәрсәдер* (*нә ирсәдер* – что-то) һ.б. Шунысы кызыклы: татар телендә *ни/нә* алмашлыгы аерым тамыр сүз буларак яшәсә дә, *кай-* тамырының мөстәкыйль кулланылышы югалган.

Татар телендә сакланып калган борынгы төрки сүзләр үзара синоним булырга мөмкин. Мәсәлән, *карау, күрү, багу (диал.); кардәш, туган; киңлек, иркенлек; аз, ким, очсыз; сөйләү, әйтү*; *йөз, бит; явыз, усал* һ.б. Еш кына әдәби телдә кулланылган мәгънәдәш сүзләрнең санын борынгы төрки диалекталь вариантлар да тулыландыра: *кул, әл; маңгай, алын; тәрәзә, чүрәзә; әтәч, кучат; җиләк, эләк; көнбагыш – айбагар* һ.б. Татар теленең диалектларында төрле кабилә яки сөйләшкә караган борынгы сүзләр сакланып калган. Аларны әдәби телдәге лексик вариантлар белән чагыштырма аспектта өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, Идел буенда угыз кабиләләренең яшәве турындагы фикер шактый бәхәсле саналса да, М. Нигъмәтуллов хезмәтләрендә анализланган тел материалы бу фикернең нигезле булуын дәлилли (Негматуллов, 1989: 220).

Татар телендәге мәгънәдәш сүзләрнең барлыкка килү юлларының берсе булып, сүздәге тарихи аваз һәм мәгънә үзгәрешләре тора. Мәсәлән, *багланыш* һәм *бәйләнеш* сүзләрендәге палатальләшү (нечкәрү) һәм *г//й* чиратлашуы нигезендә татар телендә ике сүз барлыкка килгән. *Тугры – туры, сыман – сымак, таба – табан, белән – илә* кебек сүзләр дә тарихилык нигезендә барлыкка килгәннәр.

Татар теленең борынгы төрки катламына караган сүзләр арасында мәгънәләре бер-берсенә капма-каршы булган сүзләр еш очрый: *ак-кара, ачы-төче, иртә-кич, киң-тар, ачу-ябу, ут-су, эч-тыш, озын-кыска, өс-ас* һ.б. Бу сүзләр безнең чорга бары фонетик яктан гына үзгәреп килеп җиткәннәр, аларның күбесен борынгы төрки ядкярләрдә очратырга мөмкин. Антонимик мәгънәле

борынгы сүзләрнең иң зур төркемен билге белдергән сүзләр алып тора: *югары-түбән, тәмле-тәмсез, аз-ким, таза-ябык* һ.б.

Борынгы төрки язмаларда омонимнар шактый очрый: *ай* (күк җисеме// елның бер ае), *йаз* (ел фасылы // язу // дала), *йагы* (гаскәр // дошман), *кот* (бәхет// җан), йаш (яшь// ел) һ.б. Сүз төркемнәрендә синкретизм көчле: *йүз* (исем, сан, боерык фигыль), *ат* (исем, фигыль), *бат* (рәвеш, фигыль), *уч* (исем, фигыль), *сач* (исем, фигыль) һ.б. (Хаков, 2003: 32).

Телдәге лексик берәмлекләрне анализлау барышында аларны төркемләү мәсьәләсе килеп туа. Лексикология фәнендә, гадәттә, гомум кабул ителгән семантик классификация киң таралыш алган, ягъни телдәге барлык сүзләр дә бер-берсенә мәгънәви мөнәсәбәте ягыннан төркемләнергә мөмкин. Шул ук вакытта морфологиядәге сүз төркемнәре дә семантик категорияләр булып тора, чөнки аларны уртак категориаль мәгънә берләштерә. Мондый төркемләү дә шактый киң таралган. Озак еллар дәвамында лексик катламда сүз төркемнәре сүзләрнең лексик-семантик төркемнәре буларак тикшерелде. Соңгы елларда исә фәндә лексик-тематик бүленешкә өстенлек бирелә. Тюркологиядә күпчелек тикшеренүчеләр тарафыннан А. Шәйхулов классификациясе яклана (Шайхулов, 1983: 35–41). Әлеге классификациядә телдәге сүзләр дүрт төркемгә бүленеп анализлана: Табигать. Кеше. Җәмгыять. Танып-белү. Мондый бүленеш сүзләрне үз эчендә тагы да кечерәк төркемнәргә аеруга юл ача.

Борынгы төрки телнең сүз байлыгы язма истәлекләр теле буенча тупланган һәм лингвистик яктан эшкәртелгән хәлдә «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика» (Сравнительно..., 201:724) хезмәтендә укучыга тәкъдим ителә. Биредә тупланган сүзлек материалында борынгы төрки халыкларның тормыш-көнкүреше чагыла. Төрки хуҗалыкның нигезен терлекчелек һәм игенчелек тәшкил иткән. Борынгы төркиләр шулай ук металл эшкәртүдә дә оста булганнар; археологик казулар вакытында, төрле эш һәм сугыш коралларыннан башка, металл эретү корылмаларының калдыклары да табыла тора. Йон, тире, күн эшкәртү, алардан кием-салым тегү, каеш-дирбия әйберләре җитештерү шактый зур үсеш алган булган. Җитештерү һәм сәүдә үсеше акча әйләнешенә китергән: дәүләт башлыклары исеменнән төркиләр VII йөздән үк үз акчаларын суга башлаганнар. Мәсәлән, Сөяб, Тараз, Утрар шәһәрләрендә сугылган акчалар билгеле.

Борынгы төркиләрдә, шулай ук, таштан кеше сыннары ясау сәнгате шактый камилләшкән булган. Аларда гадәттә биленә корал аскан һәм кулына савыт тоткан сугышчы сурәтләнә – мондый сыннар (балбаллар) сугышларда һәлак булганнар хөрмәтенә куелган. Тау-ташларга һәм кыяларга чокып рәсем ясау сәнгате дә төркиләрдә таралыш алган. Аларда сугышчы җайдаклар, шулай ук барс, тау кәҗәсе, дөя һәм башка җәнлек сурәтләре ясалган. Бизәкләү-гамәли сәнгатенең күп кенә төрләре өчен чәчәк орнаменты бик тә хас булган; гомумән, чәчәк бизәге төрки-дала сәнгатенең бай һәм аерылгысыз өлеше саналган һәм ул төрки халыкларның сәнгате өчен әле дә шулай. Моңа алтын-көмештән, башка төрле металлдан, пыяла, күн, тукыма, агачтан, балчыктан ясалган зәркән (ювелир) әйберләр, савыт-саба, эш һәм сугыш кораллары, өс-баш һәм аяк киемнәре, бала уенчыклары, ат дирбияләре, арба-чана, кеше тормышы өчен кирәк булган бүтән күп төрле әйберләр керә. Боларны эшләүдә сәнгатьнең нәкыш, кою, бөртекләү, каралту, кырлау, басма, алтын-көмеш йөгертү, асылташлар белән бизәү, каю, чигү һәм башка бай алымнары кулланыла (Фәхретдинов, 2001: 94). Бу шөгыль-гамәлләрнең күпчелеге татар телендәге төрки сүзләрдә чагыла.

Хәзерге татар телендә сакланып калган борынгы төрки сүз байлыгын да түбәндәге тематик төркемнәр буенча төркемләргә мөмкин:

**Табигать.** Табигать күренешләре: *көн, күк, йолдыз, Чулпан йолдыз, җир, су, таш, ай, җил, яңгыр, кояш, болыт, тузан, кар, елга, туфрак, яшен, елдырым, аяз, томан, ява, яшен, урман, кыр,кыя, үзән, Идел, болак, күл, диңгез, баткак, ком, куз* һ.б.

Хайван, җәнлек, бөҗәк, кош-корт исемнәре: *айгыр, аю, арыслан, балык, бүре, кош, үгез, тай, ат, ау, бөркет, елан, эт, төлке, юлбарс, болан, дуңгыз, куян, арыслан, аю, йомран, ас, киек , сыер, бозау, куй, тәкә, мәче, тургай, чыпчык, карга, лачын* һ.б.

Үсемлек исемнәре: *агач, каен, тирәк, имән, тал, артыш, миләш, йөзем, җиләк, балтырган, камыш, кыяк, туз, тары, бодай, арпа, ясмык, солы, суган, бөртек* һ. б.

**Кеше.** Кешенең тән төзелешенә караган сүзләр: *баш, аяк, маңгай, каш, күз, кул, сын, арка, теш, бавыр, бугаз, муен, чәч, колак, авыз, тел* һ.б.

Кардәшлек атамалары: *ата (әти), ана (әни), бабай, хатын, кыз, апа, ага, олан, ул, эне, туган, кардәш, ыру, абый, аба, килен, балдыз, кияү* һ.б.

Алмашлыклар: *мин, без, син, сез, ул, алар, үз, бу, теге, шул, нәрсә, кайда, кайчан* һ.б.

**Җәмгыять**. Җәмгыять төзелеше белән бәйле сүзләр: *ил-көн, ыруг, бәк, улус, кол, кырнак, кәнизәк, ярлы, түләү, очсыз, ант, угры, карак, талау, яу* һ.б.

Тормыш-көнкүреш, ашау-эчү, хезмәт төшенчәләрен белдерә торган сүзләр: *алтын, көмеш, тимер, тамга, он, аш, азык, ил, эш, уймак, без, туку, туплау, эрләү, талку, җилем, чүкеч, балта* һ.б.

Эш, хәрәкәт белдерә торган сүзләр: *авыру, җылау, тулу, яту, тору, яшәү, йоклау, йөрү, килү, китү, керү, үлү, туу, төшү, тору, язу, сызу,* һ.б.

**Таныпбелү.** Урын, вакыт төшенчәсен белдерә торган сүзләр: *көн, төн, ел, ара, ал, арт, эч, урта, ян* һ.б.

Әйберләрнең санын белдерә торган сүзләр; *бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, егерме, утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан, йөз, мең* һ.б.

Әйберләрнең, күренешләрнең сыйфатларын, үзенчәлекләрен белдергән сүзләр: *ак, кара, ал, ач, әче, аз, күп, иске, ялгыз, каты, сары, яшел, тере, олы* һ.б.

Абстракт төшенчәләрне белдергән сүзләр: *изгелек, мәңге, көч, исәнлек, бәхет, аң, акыл, белем* һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, борынгы төрки телдән үк килә торган сүзләр татар халкының тормыш-көнкүрешен төрле яклап колачлый.

Шул рәвешле, борынгы төрки сүз байлыгы татар теленең төп лексик фондын тәшкил итә. Татар теленең үсеш чорларында бу катлам югалмыйча, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Төп төрки лексик фондның бүгенгәчә структур һәм мәгънәви яктан тотрыклы саклануы телнең көче, аның мөмкинлекләре һәм халык аңындагы югары дәрәҗәсе турында сөйли.

## §4. Төрки-татар чыгышлы сүзләрнең башка телләрдә кулланылуы

Тарихның төрле этапларында төрки халыклар үзләренә чиктәш территорияләрдә яшәгән башка халыклар белән тыгыз икътисади, мәдәни һәм сәяси элемтәдә торган. Б.э.ның IV–VII гасырларында көнчыгыштан һуннар кузгалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән Бөек халыклар күчеше, X–XI гасырларда төрки халыкларның миграциясе, монгол яулап алулары белән бәйле күчешләр, XV–

XVII гасырларда төрки ханлыкларның юкка чыгуы нәтиҗәсендәге үзгәрешләр төрки лексиканың башка телләр системасына үтеп керүенә китергән. Беренче чиратта, төрки халыклар үзләренең иң якын күршеләре булган славян һәм фин-угор халыклары теленә йогынты ясаган.

Славян халыклары телендәге төрки алынмаларны өйрәнү рус белгечләрен күптәннән кызыксындырган. Мәсьәләне төрле яклап өйрәнгән галим И. Добродомов рус язучысы В. Тузовның XVIII гасырда ук (1769) «Поденьщина» дип аталган журналда рус сүзләрен көнчыгыш телләрдән кергән сүзләр белән янәшә куеп чагыштыруы турында яза. *«Сундук, лошадь, бирюк, камыш»* кебек сүзләрне Василий Тузов төрки чыгышлы дип билгеләгән. Шул ук вакытта ул рус һәм төрки телләрдә охшаш яңгыраган кайбер сүзләрне *(щи, ашчы)* уртак лексика дип ялгышлык та җибәргән.

И. Срезневский редакторлыгында 1854 елда чыккан «Чагыштырма һәм аңлатма сүзлеккә һәм грамматикага материаллар» хезмәтендә танылган галимнәр И. Березин, А. Бобровников, В. Григорьев, А. Казимбәк, И. Ковалевский, П. Петров, А. Шёгрен тарафыннан тупланган сүзләр күрсәтелә.

Төрле елларда әлеге мәсьәләгә Ф. Миклошич, Ф. Корш, П. Мелиоранский, А. Зайончковский, Д. Ушаков, Н. Дмитриев, В. Радлов, М. Фасмер, Ф. Эрдман, А. Щербак, А. Калинин, В. Аракин һ.б. мөрәҗәгать итәләр.

1976 елда Е. Шипова тарафыннан рус телендәге төрки алынмаларның сүзлеге төзелә (Шипова, 1976: 3)

Славян телләрендәге төрки алынмаларга Европада беренчеләрдән булып, чех галиме Йоханес Пайскер игътибар итә. Әмма аның славян һәм төрки халыкларның борынгы бәйләнешләре турындагы фикерләрен Карл университеты галиме Любор Нидерле тәнкыйтьләп чыга, чөнки фәндә бу чорда «Көнбатыш Европадагы славян халыкларының теленә алынмалар борынгы алман теленнән үтеп кергән, ә төрки контактлар булмаган» дигән караш өстенлек иткән. Шулай да кайбер мисаллар бу карашның нигезен какшаталар. Чех галиме Machek Vaclav (Махек Васлав) төзегән этимологик сүзлектә аерым сүзләрнең төрки чыгышлы булуы күрсәтелгән (Machek V, 1958: 868). Мәсәлән, *čakan* сүзе төрки «чәкән» – сугыш балтасы мәгънәсендә иң борынгы алынмаларның берсе булырга мөмкин. Мондый алынмаларны поляк теленә украин теле аша, ә чех яки словак

телләренә венгр теле аша кергән дип караучылар да бар. Шулай да иң күп төрки алынмалар украин һәм рус телләрендә сакланган.

Украин телендә *бабай* (дед), укр. *бачити*, пол. *baczyć*, рус, слц. *bačit'* төрки телләрдәге *bak*- ‘карау’ фигыленнән алынган. Укр. (көнб. диалект) *батяр*, пол. *batiar*, *baciarz* «яшь кеше» мәгънәсендә кулланыла, гомумтөрки *batyr – батыр* сүзеннән. Рус, укр. *ватага* «толпа, группа» сүзе дә борынгы төрки **vătağ, utağ* – «учак, йорт» сүзеннән булуы ихтимал.

Иске сл. *klobúk, koblúk*, рус *колпак*, укр. *ковпак* «зур түбәле калпак» – төрки *калпак* сүзеннән; укр. *кияк, киях, кiях* «рогоз (*үлән атамасы*)» – *кыяк*, кыяклы үлән; сл. **kŭniga* (рус, укр. *книга*, пол. *kniga*, ч. *kniha*) – төрки *кенәгә – kün←*koniv ← *konig* сүзеннән булуы мөмкин.

Рус телендәге төрки алынмаларны өйрәнү лексик-семантик төркемнәрне билгеләү, аларның кулланышка керү чорын ачыклау, семантик үсеш кырын һәм кулланылыш ешлыгын билгеләү, морфологик төзелешен һәм этимологиясен билгеләү һ.б. юнәлешләрдә бара. Галимнәр төрки алынмаларны үзләштерүнең сыйфатламаларын (критерийларын) түбәндәгечә күрсәтәләр: 1) төрки алынмаларны тәрҗемә яки оригиналь әсәрләрдә, вакытлы матбугатта, фәнни хезмәтләрдә кулланылышы буенча билгеләү; 2) рус телендә эквиваленты булмаган һәм шуңа күрә мәгънәсе тасвирлама рәвештә бирелә торган алынмалар; 3) төрки алынмаларны фонетик яктан үзгәртеп үзләштерү; 4) төрки алынмаларга рус теленең морфологик күрсәткечләрен кушып куллану.

Хронологик яктан төрки алынмаларның рус теленә үтеп керү чорлары түбәндәгечә билгеләнә:

1) борынгы славян нигез теленә *(праславянский язык)* алынган төрки сүзләр (*чекан, болван, товар*);

2) монгол яуларына кадәр борынгы рус теленә алынган төрки сүзләр (*боярин, шатёр, богатырь, ватага, жемчуг, кумыс, лошадь, лошак, орда*);

3) Алтын Урда чорында борынгы рус теленә үтеп кергән төрки сүзләр (*ям, ямщик, ярлык, казак, кочевать, есаул, караул, хорунжий, кинжал, атаман, сабля, кошевой, деньга, казна, казначей, тамга (таможня), барыш, хозяин, харч, кабала* һ.б.);

4) XVI–XVII гасырларда иске рус теленә алынган төрки чыгышлы сүзләр (*артель, чулан, юфть, амбар, арап, барабан, барс,*

*бахрома, бахча, бирюза, угор, буланый, бурав, войлок, вьюк, епанча, ишак, каблук, кайма, кандалы, каурый, кистень, колчан, кушак, лапша, лафа, палач, саранча, сундук, таз, толмач, тулуп, чалма, чалый, чемодан, чердак, чобот, яр, балаган, балда, беркут, изюм, кавардак, каланча, капкан, караван, севрюга, сурьма, табун, туман, утюг, халат, чугун, шайка, шалаш* һ.б.);

5) XVIII—XX гасырларда рус теленә кергән төрки сүзләр (*баклажан, башка, изъян, кабан, кадык, камыш, карандаш, кибитка, парча, плов, сурок, сычуг, тормоз, туша, фарфор, ханжа, бакалея, дымка (ткань), ай (доля), тюк, шаровары, балык, буран, ералаш, кутерьма, айда, алыча, балбес, карапуз, кетмень, кизил, кобура, папаха, сарыч, тюбетейка, хурма, чекмень, якшаться, люля-кебаб, чурек, тахта* һ.б.).

Әлбәттә, төрки алынмаларның славян телләренә керү вакытын төгәл билгеләү бик катлаулы һәм бу өлкәдә галимнәрнең фикере аерыла. Кайбер алынмаларның үзләштерелү чоры һаман да билгесез булып кала (*бабай/бабайка*). Аерым сүзләр төрек теленнән Көнбатыш Европа телләренә күчеп, рус теленә алынганнар (*диван, жасмин, каракуль, киоск, софа, тюльпан, тюрбан, фисташка, халва* һ.б.). Гадәттә, күпчелек төрки алынмалар рус теленә Чыңгыз хан яуларыннан соң кереп калган дип күрсәтелә. Мәсәлән, А. Калинин XIII–XIV гасырларда рус теленә үтеп кергән алынмалардан түбәндәгеләрне күрсәтә: *тулуп, сарафан, башлык, чулок, армяк, колпак; лошадь, табун, аркан, буланый; амбар, сарай, утюг, сундук, войлок, чемодан, бадья, чугун, очаг, наждак; изюм, балык, шашлык, баклажан, лапша; деньги, аршин, безмен, товар* һ.б. (Калинин, 1978: 15). Елъязмаларда һәм фольклор әсәрләрендә урын алган иң борынгы төрки алынмаларга В. Аракин *боярин, казак, казна, орда, шатёр, ярлык*, *атаман (ватаман), барс, башмак (башмачики), войлок, караул, колпак, кушак, куяк, табун, чулок* кебек сүзләрне кертә (Аракин, 1984: 15–28).

Рус теле белемендә төрки алынмаларның рус теленә күпләп алынуы Алтын Урда чорына карый дигән фикер киң таралыш тапкан. Төрки алынмаларның хронологиясенә караган материалларны өйрәнү нәтиҗәләре бу фикерен расламый. Фәнни тикшеренүләр күрсәткәнчә, рус әдәби телендәге төрки алынмаларның дүрттән бер өлеше генә Алтын Урда чорына каравы теге яки бу дәрәҗәдә исбатланган (Галиуллин, 2000: 29).

Бүгенге көндә дә кайбер сүзләр аерым хезмәтләрдә төрки сүзләр буларак күрсәтелсәләр дә, аларның чыганак телләре гарәп, фарсы яисә фин-угор булуы мәгълүм: *лагуна, баламут, барбарис, багульник, бардак, бергамот, бирка, бурка, бурлак, бусы, вишня, вол, гашиш, гоголь, гурт, ендова, калач, кайф, карась, каторга, кисет, клянчить, ковш, колбаса, колики, кольчуга, лебеда, лимон, лохань, магарыч, маяк, мех, мусор, набекрень, осина, осот, пирог, тьма, упырь, ураган, урон, факир, чайка, шакал, шаль, шафран, шериф, шершавый, шишка, щи, ящик* һ.б. Болар телдә «ялган тюркизмнар» дип билгеләнә.

Атаклы тюрколог Н. Баскаковның төрки чыгышлы рус фамилияләре турында фундаменталь хезмәте билгеле (Баскаков, 1979: 279). Аның бу хезмәтендә Алтын Урда дәүләтеннән, Казан, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыкларыннан рус патшасына хезмәткә күчкән һәм шуның нәтиҗәсендә исемнәре рус әйтелешенә яраклаштырылган нәсел вәкилләре исемлеге китерелә. *Дашков, Бутурлин, Мамонов, Сабуров, Талызин, Скрыпеев, Ушаков, Корсаков, Турчанинов, Черкасский, Шереметев, Салтыков, Апраксин, Бахметев, Котенин, Аракчеев, Чемоданов, Карамышев, Болдырев, Тютчев, Чичерин, Куракин, Булгаков* һ.б. Баскаков хезмәтендә 300 дән артык шундый фамилия китерелә. Шул ук вакытта Мәскәү шәһәренең үзендә дә төрки чыгышлы топонимнар сакланып калганлыгы күрсәтелә: *Татарская улица, Туркменский проезд, Боярский переулок; Уланский переулок, Басманная улица, Ямская улица, Илимская улица, Колпачный переулок, Шаганский переулок, Аксакова переулок, Алымова улица, Алебьева улица, Бабаевская улица, Барыковский переулок, Бахметьевская улица, Бабичева улица, Бирюзова маршала улица, Бирюлевопоселок, Булатниковская улица, Булгаковский переулок, Бутаково, Аркадия Гайдара улица,Гоголя улица, Дашков переулок, Ермолова генерала улица, Ибрагимова улица, Измайловская площадь, Казакова улица, Кантемировская улица, Карамышевский проспект, Карташевский переулок, Ковылинский переулок, Козлова улица, Кочновский переулок, Кулаковский переулок, Кутузова проспект, Мичуринский проспект, Наримановская улица, Нарышкинский проспект, Огарева улица, Сабурово, Салтыковская набережная* һ.б. Бу атамаларның барысының да төрки-татар чыгышлы сүзләр яисә кеше исемнәре икәнлеге күренә.

Тюрколог Н. Баскаков хезмәтен тарихчы галим А. Халиков тулыландыра. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» дип аталган китабында ул архив материаллары нигезендә Н. Баскаков исемлегенә кермәгән төрки нәсел исемнәрен фәнни әйләнешкә өсти (Халиков, 1992: 3–191).

Р. Юналеева хезмәтләре рус телендәге төрки алынмаларның хронологик һәм тематик бүленеше ягыннан бик кызыклы. Галим фикеренчә, рус теленә үтеп кергән төрки алынмалар нәкъ менә рус-төрки тел багланышлары чорларын күрсәтәләр (Юналеева, 2000: 172). Алар арасында язма рәвештә теркәлеп калган иң борынгы сүзләр буларак, ул XII гасырга караган *япунчица, клобук* сүзләрен күрсәтә. XIV гасырда истәлекләргә *капторга, алам, бугай, сарафан, калита,* XV–XVI гасырларда *терлик, тесьма, кафтан, кушак, кайма, колпак, шлык, каптур, капа, фата, юшман, штаны, кутас, армяк, зепь, науруз, чалма, тафья* сүзләре; XVII гасырда *бешмет, бурка, емурлук, шабур,бутурлук, калауз, аракчин, мисюрка, шишак*, XVIII гасырда беренче сүзлекләрдә *казакин, киса,* XIX гасырда *архалук, очкур, башлык, тюбетейка* сүзләре теркәлүен билгели. Әлбәттә, алынмаларның күбесе сөйләм теле аша кергәннәр (*деньга, тамга, кафтан, товар, караул, сан, осанка, сановник, баклажан, чемодан, ишак, кадык* һ.б.). Аларның Көнбатыш Европа алынмаларыннан аермалыгы да шунда чагыла. Рус теленә күп санда Европа алынмалары үтеп керә башлагач, лексик артыклык күренеше барлыкка килә, төрки алынмаларны Европа алынмалары кысрыклап чыгара башлый. Мәсәлән, *башмак – ботинка, штаны – панталоны – брюки* һ.б.

Шул рәвешле, XIX гасырда рус халкының даһи шагыйре А. Пушкин «едва ли полсотни татарских слов перешло в русский язык» дип белдергән булса, фәнни эзләнүләр төрки телләрнең рус теленә шактый зур йогынты ясаганлыгын күрсәтәләр.

Төрки лексика фин-угор халыклары теленә дә үтеп кергән. Әлеге мәсьәләне өйрәнү XVIII гасырдан алып, фин-угор галимнәре тарафыннан да, тюрколог галимнәр тарафыннан да башкарылган. Чагыштырма-тарихи алымга нигез салучыларның берсе – күренекле галим, офицер Филипп Иоганн (Юхан) Табберт фон Страленберг хезмәтләреннән башлап, фин галиме Рясянен Арво Мартти Октавианус, венгр галимнәре Дьюла Немет һәм Рона-Таш Андраш, рус галимнәре И. Тараканов, А. Дыбо,

Ю. Норманская, татар галимнәре Р. Әхмәтьянов, А. Шәйхулов, И. Насипов, Н. Исанбаев һ.б.ның хезмәтләрендә әлеге мәсьәлә ачык яктыртыла.

А. Дыбо фин-угор (мордва, мари, удмурт, ханты, манси, венгр) телләренә төрки алынмаларның үтеп керүенең хронологик чикләрен билгели (Дыбо, 2013: 7–68). *Alaša* (алаша), *ajgor* (айгыр), *ulov* (үлү), *uźum* (йөзем), *tüs* (төс), *tušman* (дошман), *ulav* (олау), *košma* (кошма), *novta* (нукта), *komlɛ, komula* (колмак), *koźa* (хуҗа), *tugan//duga* (туган), *kujar* (кыяр), *aru* (ару), *śetəń* (читен), *konak* (кунак), *gubon* (күбенү), *košardoms* (кушу) кебек төрки чыгышлы сүзләрнең мукшы һәм эрзя телләрендә урын алуын күрсәтә һәм, аваз үзгәрешләренә бәйле рәвештә, әлеге алынмаларның иске төрки тел чорында да (XV гасыр), аннан соң да алынуына ишарә итә.

Мари теленә татар теленнән *azú (*азау*), jáštyk (*ястык*), äkamät (*әкәмәт*), jémyž (*җимеш*), inanaš (*инану*), šižaš (*сизү*), pota (*пота*), kotyr (*кутыр*), kürt (*көрт*), korsak (*корсак*), tüé (*дөя*), kötyrmá (*күтәрмә*), pölek (*бүләк*), küpčyk (*күпчек*), pólyš (*булыш*), nukta (*нукта*), purly (*бурлы*), jylym (*җылым*)* сүзләре кергән һәм, беркадәр яңгырашын үзгәртеп, мари телендә кулланылган.

Удмурт теле түбәндәге алынмаларны үзләштергән: *bez* (биз), *ḋesta* (дистә), *keźə* (киҗе), *biran* (бирән), *ińi* (инде), *ińtəgənə* (интек), *sendra* (сәндерә), *peri* (пәри), *kisi̯* (кесә), kindi̯kei̯ (кендек әбисе), *buga* (буга), *kurai̯* (курай),*ozgarənə* (узгәрү), *bozgo* (бусага), boi̯orok (боерык), *közlək* (күзлек) һ.б.

Венгр (маҗар) телендәге төрки алынмалар фәндә шактый зур кызыксыну уята. Гадәттә, венгр (маҗар) телендәге төрки алынмаларны болгар-чуваш теориясе белән бәйләп аңлатырга омтылыш бар (Дыбо, 2013: 19). *Kobak* (кабак), *csibuk* (чыбык), *csabak* (чабак), *koboz* (кубыз), *kéve* (күбә), *bálvány* (балбал), *bodor*/*budrig* (бөдрә), *búza* (бодай), *szérű* (җәйрән), *homok* (ком), *hajó* (каек), *ковъчегъ* (кабырчык) һ.б. сүзләр тел үсешенең борынгы чорларында ук венгр теленә төрки телләрдән алынган.

Себер төрки-татар телләре аша ханты-манси телләренә дә алынмалар килеп кергән (Kannisto, 1925). Артур Каннисто шундый 500дән артык алынма сүз күрсәтә. «Манси теленең көнбатыш диалекты вәкилләре турыдан-туры себер татарлары белән аралашып яшәмәгән, әмма аларның телендә дә татар алынмалары булу бу сүзләрнең көнчыгыш мансилардан алынуы турында сөйли булса

кирәк», – дип яза А. Дыбо (Дыбо, 2013: 16). Ә көнчыгыш манси-лар турыдан-туры себер татарлары белән аралашканнар. Нәтиҗәдә түбәндәге кайбер лексик берәмлекләр ханты-манси телләренә килеп кергән төрки алынмалар буларак санала: *šaj* – күлмәк (себ. татар. *шәй* – бизәнү әйбере), *šatxan* (шалкан/шалгам), *tüšak* (түшәк), *tukmar* (чукмар), *taŋ* (чаң), *əpråk* (чүпрәк), *jobańǯi* (ябанцы) һ.б.

Төрки чыгышлы сүзләрнең тунгус-манчьжур телләрендә (эвенк, эвен, нанай, ульчи, удәгәй, ороч, орок, негидаль телләре) кулланылуы турында да мәгълүматлар бар (Бурыкин, 2003: 38–48). Кайбер галимнәр бу сүзләрне алтай теориясенә бәйле рәвештә ностратик охшашлык белән аңлаталар (Цинциус, 1972: 172), әмма шулай да кайбер сүзләрнең төрки телләрдән кергәнлеге, Бурыкин сүзләренчә, шик уятмый (*тэмэн* «дөя» – бор. төрки *teve* «тәвә»; *adzir morin* яисә *achir morin* «яшь айгыр» – бор. төрки *adgir, ajgir* «адгыр, айгыр»; эвенк. *zildavki* «йолдыз» – бор.төрки *julduz* «йулдуз» һ.б.)

Төрки чыгышлы сүзләрнең монгол телләрендә дә кулланылуы турында эзләнүләр бар (В. Рассадин, Б. Владимирцев, Б. Серебренников, А. Булакаева-Баранникова, А. Нуриева, Э. Ишбердин, Р. Әхмәтьянов, Д. Рамазанова һ.б. хезмәтләре). Татар-монгол уртак лексикасы турында 2016 елда Д. Рамазанова мәкаләсендә җентекле анализ бирелә (Рамазанова, 2016: 26–36).

Шул рәвешле, төрки-татар сүз байлыгы тел яшәешенең төрле этапларында славян, фин-угор, тунгус-маньчжур телләренә алынмалар буларак кергән һәм кулланылган.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АЛЫНМА ЛЕКСИКА

Югарыда каралган лексика татар теленең лексикасында генетик фондны тәшкил итсә, контактлы фондны төрле бәйләнешләр нәтиҗәсендә үтеп кергән алынмалар хасил итә. Телнең сүзлек составының килеп чыгышын өйрәнү тарихына багышланган бүлекчәдә алынмаларның төрләренә гомуми характеристика бирелде, алга таба татар телендә киң таралыш тапкан алынмаларның зур төркемнәре тәфсилле яктыртылачак. Аларга күчкәнче, телебезнең лексик фондына борынгы чорларда ук үтеп кергән, хәзерге торышында алынма булуы махсус өйрәнүләр белән генә ачыклана торган сүзләргә күзәтү ясыйк.

Төрки халыкларның формалашуы барышында борынгы чорда ук көнчыгыш халыклары белән булган багланышлар зур роль уйнаган, телдәге алынмаларның иң борынгылары да шулар белән бәйле. Төрки телгә кытай, һинд, иран, монгол һәм башка телләрдән алынмалар үтеп кергән. Мәсәлән, шундыйлардан һинд, кытай сүзләрен билгеләп китәргә кирәк: *тәңре, җиз, сан, энҗе, хан, чәй, җуа, юан, шан, чын, чиру, эрдәнә, алма, дию* һ.б.; монгол теле белән уртак сүзләр: *чаган, нукта, дилбегә, нокер* һ.б. Әлеге бәйләнешләр һәм шуларга мөнәсәбәтле рәвештә үтеп кергән алынмалар төрки телләр әле аерылмаган чорда ук кабул ителгәннәр.

Татар теле белемендә борынгы алынмалар мәсьәләсе Р. Әхмәтьянов хезмәтләрендә шактый тулы яктыртылган (Әхмәтьянов, 2015: 30–37). Биредә без бу төр алынмаларга бәйле кайбер мәгълүматларны китерәбез.

Татар телендә борынгы һинд-иран, санскрит алынмалары төркеме билгеле. Бу төр лексика рәтендә төрле лексик-тематик төркемнәргә караган сүзләр очрый: *бул* (у) > санскрит телендәге *bhu* сүзеннән булырга мөмкин, дигән фикерләр бар (Мусаев, 1984: 129; Әхмәтьянов, 2015: 214). А.В. Дыбо бабатөрки телдә үк борынгы иран теленнән кергән булырга тиешле алынмалар рәтендә түбәндәге сүзләрне карый: *тана* > **dāna (dainu-kā); тура (шәһәр, башня)* > **dura; колмак* > *kumlak (hauma-aryaka); *бөтнек* > **bütnük (bodina-ka); арпа* > *arpa / arba* һ.б. (Дыбо, 2009). Бу аңлатмалар, нигездә, Р. Әхмәтьянов сүзлегенә дә туры килә (Әхмәтьянов, 2015).

Төрки һәм монгол лексиканы алтаистика фәнендә шактый яктыртылды, дип әйтергә була. Мәсәлән, бу өлкәдә танылган галимнәрдән Г. Рамстедт, В. Котвич, Е. Поливанов, Б. Владимирцов, А. Щербак, Б. Юнусалиев, Б. Орузбаева, В. Рассадин, К. Мусаев һ.б.ны атарга кирәк. Татар теле белемендә әлеге мәсьәлә Р. Әхмәтьянов, А. Нуриева, В. Хаков һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә яктыртылган. Бу телләрдәге уртаклыкны кардәшлек нәтиҗәсе буларак та, уртак мәдәни һәм тарихи шартлар нигезендә барлыкка килүе турында да фикерләр даими әйтелеп бара. Соңгы еллардагы яңа хезмәтләр татар-монгол бәйләнешләре мәсьәләсен өйрәнүне тирәнәйттеләр, гомумалтай чорында ук уртак булган лексика турында да мәгълүматлар шактый артты.

Монгол һәм төрки лексик параллельләр белән беррәттән, хәзерге татар теле лексик фондында монгол теленнән булуы бәхәс

уятмый торган алынма сүзләр дә кулланыла. Алар – төрки телнең борынгы чорында ук кереп, хәзерге төрки телләрдә дә сакланып калган алынмалар. Татар телендә монгол алынмалары, башлыча, гомумкулланылыш лексикасында күзәтелә һәм алар төрки телләрнең төп фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләренә тулысынча буйсындырылганнар, мәсәлән, *каурый (каурсын)* сүзе монгол телендәге *гуурс* сүзенә барып тоташа; бер төркем фигыльләрнең килеп чыгышы монгол теле нигезендә дип аңлатыла: *сора(у)* < монгол телендәге *sor ~sura ~ sora; аула (у)* > монгол телендәге *abla ~ avla; кара* < *qara; яса* < *jasa* һ.б. (Щербак, 1986: 52; Әхмәтьянов, 2015). Шактый күләмдәге монгол алынмалары диалектларда гына кулланыла: *сөбә, мүлчәр, мүктәрге, канят/канәт, канҗыга, кашага* һ.б.

Хәзерге татар теленең лексик фондында гомумтөрки чорда үтеп кергән кытай алынмаларын да очратырга мөмкин. Н. Баскаков билгеләвенчә, бу төр лексика төрки тел белемендә җентекле тикшерелмәгән (Баскаков, 1987: 69). Татар теле белемендә дә бу проблеманы яктырткан монографик хезмәтләр юк. Кытай алынмалары таралыш тапкан кайбер тематик төркемнәрне карап үтик:

1) титуллар, төрле иерархик дәрәҗәләрне белдергән сүзләр: *бәк < bek ~ beg; чура < čur ~ čora ~ šora; каган < qaγan; кам < qam; тархан < tarxan; тегин < tegin; хан < xan;*

2) рухи мәдәният белән бәйләнешле сүзләр: *битик < bitik ~ bičik; бурхан < burqan ~ burxan'; чын < čyn ~ čin; көй < küg ~ küj;*

3) төрле матдә, металл, әйбер атамалары: *алтын <altyn ~ altun; чәй < čaj; чин* (савыт, фарфор) *< čini; чуен < čojun; энҗе < indħü ~ indħi; су > suγ ~ suw;*

4) тормыш-көнкүреш атамалары: *чан < čan; эш < iš ~ is; үтүк < ütük ~ ötük; пай < paj; кап < qap; таң < taŋ* һ.б.

Соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә бу төркем тагын да киңәйтелгән. Аерым алганда А. Дыбо бабатөрки һәм гомумтөрки чорларда төрки телләргә алынмаларны җентекле тикшереп, бабатөрки реконструкцияләрне торгызуга кагылышлы мәсьәләләргә өстәмәләр, төзәтмәләр кертә (Dybo, 2014: 7–17).

Әлбәттә, бу сүзләрнең килеп керүе төрки тел үсешенең иң борынгы чорларына карый һәм хәзерге татар телендә алынма буларак каралмый, бәлки төрки чыгышлы төп сүзлек фондының состав өлеше буларак бәяләнә.

## Татар телендә фин-угор алынмалары

### § 5. Фин-угор алынмаларының үтеп керү тарихы

Төрки халыклар үз тарихында фин-угор халыклары белән күп гасырлар дәвамында даими һәм үзара тыгыз мөнәсәбәттә була. Аларның сәяси, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләре бу халыклар телләренең сүзлек составында чит тел сүзләре буларак урын ала.

Идел буе татарлары һәм аларның аерым этнолингвистик төркемнәре формалашуга фин-угор этнокомпонентының йогынтысы турында фәнни әдәбиятта күп язылды. Мәсәлән, Казанның танылган галиме Е. Казаков Идел болгарларының олы бер фин-угор дөньясы белән үзара бәйләнешен археологик материал нигезендә тикшерә. Ул төрки һәм фин-угор халыкларының IX–XIV гасырларда Идел–Урал төбәгендә тыгыз мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә бу төбәктә бүген яшәүче халыкларның күпчелек этномәдәни сыйфатлары формалашкан, дигән фикергә килә (Казаков, 2007).

Фин-угор элементлары татарларның хуҗалык итүендә һәм тормыш-көнкүрешендә (Халиков, 1995), тукучылыкта (Сафина, 1996), милли киемендә (Суслова, Мухамедова, 2000; Суслова, 2004), бизәнү әйберләрендә (Суслова, 1980), декоратив халык сәнгатендә, сынлы сәнгатьтә һәм архитектурада (Червонная, 1987), традицион рухи мәдәнияттә (Шарифуллина, 2004) һ.б. өлкәләрдә билгеләнә.

Идел–Урал татарлары һәм Көнбатыш Себер татарлары мәдәниятендә фин-угор компонентының урыны татар халкының аерым субэтносларының һәм этнографик төркемнәренең этнолингвистик үзенчәлекләре формалашуын тикшергәндә ачык күренә. Мәсәлән, Идел–Урал татарлары арасында фин-угор сыйфатлары бигрәк тә мишәрләр һәм Касыйм татарларында ачык чагыла, аларның формалашуы һәм үсеше XV гасырда Мещера территориясендә барлыкка килгән Касыйм дәүләте белән бәйле (Шарифуллина, 2004: 544).

Мишәр һәм Касыйм татарларының традицион мәдәниятендә фин-угор элементларының булуы XIX–XX гасырда күп кенә галимнәр тарафыннан (Б. Куфтин, С. Толстов, В. Вельяминов-Зернов, В. Гордлевский һ.б.) билгеләнә. Моннан соңгы тарихи-этнографик тикшеренүләр мишәр һәм Касыйм татарларының традицион мәдәниятендә фин-угор элементлары турындагы фикерләрне киңәйтергә мөмкинлек бирә (Мухамедова, 1972). Аларның ата-бабаларының фин-угор халыклары белән күпгасырлык аралашуы

традицион рухи мәдәниятләрендә, шул исәптән туй йолаларында да кайбер уртак сыйфатларның барлыкка килүенә китерә (Шарифуллина, 2004: 545).

Татар халкының этнолингвистик төркемнәреннән булган мордва-каратайларның, Чепца буе татарларының, бисермәннәрнең һ.б.ның формалашу проблемасы тагын да катлаулы. Бу, шулай ук, аларның тел үзенчәлекләрендә дә чагылыш таба.

Идел һәм Урал буенда төрки халыкларның формалашуына фин-угор дөньясының йогынтысын лингвистик планда Идел–Кама буенда яшәүчеләрнең телләре берлеге кысаларында тикшерү максатка ярашлы. Б. Серебренников тәкъдим иткән бу фаразның тормышчанлыгын XX гасыр азагы һәм XXI гасыр башы этнолингвистик тикшеренүләр нәтиҗәләре дәлилли (Р. Әхмәтьянов, Т. Гарипов, М. Зәкиев, А. Шәйхулов һ.б.) (Насипов, 2013: 14–19). Идел-Кама телләре берлегенә төрки телләрдән башкорт, татар һәм чуваш телләре, фин-угор телләреннән мари, мордва (мокша һәм эрзя) һәм удмурт телләре керә, дип билгеләнә. Бу телләр берлегенең кайчан барлыкка килүе турында галимнәр конкрет белдермиләр, шулай да бу мәсьәләдә капма-каршы ике фараз булуын әйтергә кирәк. Кайбер галимнәр, Идел-Кама телләре берлеге бик борынгы чорда ук формалашкан, аның аерым сыйфатларын ностратик телләрнең баба теле һәм урал-алтай телләренең баба теле чоры белән үк бәйле, дип карыйлар (Закиев, 1986: 58; 1987: 176–180; Ахметьянов, 2004: 177–182). Икенче бер галимнәр, Идел буенда төрки кабиләләр фин-угор кабиләләре белән тик VIII гасыр урталарыннан Бөек Болгар дәүләте чорында гына тыгыз аралаша башлыйлар, дип белдерәләр (Мухамедьяров, 1986: 50). Ничек кенә булмасын, татар теленә фин-угор сүзләре борынгы чорлардан ук үтеп керә башлаган.

Татар телендә мари алынмалары Л. Арсланов, Р. Әхмәтьянов, Ф. Баязитова, Д. Рамазанова, Т. Хәйретдиноваларның хезмәтләрендә тасвирланган. Кайбер мари алынмалары Н. Борһанова, О. Бятикова, Л. Мәхмүтова, Р. Рәхимова, З. Садыйкова, А. Шәйхулов хезмәтләрендә анализланган. Татар телендә мари алынмалары И. Насипов хезмәтләрендә системалы рәвештә тикшерелә. Мондый лексик берәмлекләрне өйрәнү өчен кыйммәтле чыганаклар булып татар, шулай ук башкорт, чуваш, рус һәм фин-угор телләренең аңлатмалы, диалектологик һәм этимологик сүзлекләре санала.

Бу яктан С. Апсатарова, Л. Арсланов, Р. Әхмәтьянов, И. Галкин, Ф. Гордеев, Л. Грузов, Е. Гуляев, В. Егоров, Н. Егоров, Ф. Егоров, А. Илиева, Н. Исәнбаев, Д. Казанцев, Г. Лукоянов, В. Лыткин, Н. Пенгитов, М. Рясянен, А. Саваткова, Н. Мөкимова һ.б.ның тикшеренүләрен аерым билгеләргә кирәк.

Төрки-мордва тел бәйләнешләре тарихын һәм мордва телләрендә төрки алынмаларны Н. Бутылов тәфсилле өйрәнгән. Татар телендә мордва телләреннән алынмалар Л. Арсланов, Р. Әхмәтьянов, Ф. Баязитова, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова, Д. Рамазанова, Т. Хәйретдиноваларның аерым хезмәтләрендә тасвирланган. Аерым сүзләр О. Бятикова, Р. Рәхимова, З. Садыйкова, Ә. Тенишев, А. Шәйхулов басмаларында урын алган. Татар телендә мордва алынмалары И. Насипов хезмәтләрендә системалы рәвештә карала. Мондый лексик берәмлекләрне тикшерү өчен татар теленең, шулай ук башкорт, чуваш, рус һәм фин-угор телләренең аңлатмалы, диалектологик һәм этимологик сүзлекләре кыйммәтле чыганак булып тора. Бу яктан бигрәк тә Р. Әхмәтьянов, В. Егоров, М. Федотова, В. Лыткина, Е. Гуляев, Н. Мөкимова һ.б.ның хезмәтләрен күрсәтергә кирәк.

Төрки-удмурт тел бәйләнешләрен өйрәнү тарихы һәм удмурт телендә татар алынмаларын фәнни тасвирлау И. Тараканов хезмәтләрендә тулы чагылыш таба. Шулай ук, бу яктан М. Рясянен, М. Федотов, В. Кельмаков һәм Р. Насыйбуллин хезмәтләре дә аерым игътибарга лаек. Бу проблематиканың аерым аспектлары Идел–Урал буе төрки (башкорт, чуваш) телләренең башка фин-угор телләре белән үзара бәйләнешләрен тикшерүгә багышланган хезмәтләрдә (Ф. Баязитова, Д. Рамазанова, Н. Ишбулатов, Н. Максутова, С. Миржанова, Н. Мөкимова һ.б.) каралган. Татар телендә удмурт алынмалары И. Насипов хезмәтләрендә системалы рәвештә тикшерелә. Татар лексикасын тематик төркемнәргә бүлеп өйрәнүгә (Ф. Баязитова, Н. Борһанова, О. Бятикова, Д. Рамазанова, Р. Рәхимова, З. Садыйкова, Т. Хәйретдинова) һәм Урал–Идел буе халыкларының гомум лексикасын тикшерүгә (Р. Әхмәтьянов, А. Шәйхулов) багышланган монографияләрдә, шулай ук татар теленең этимологик (Р. Әхмәтьянов) һәм диалектологик сүзлекләрендә (Л. Мәхмүтова, Ф. Баязитова, Н. Борһанова, Д. Рамазанова, З. Садыкова, Т. Хәйретдинова, Г. Якупова, Л. Бикмаева, А.Г. Шәйхулов) татар телендәге удмурт алынмалары турында кыйммәтле мәгълүматлар тупланган.

Татар теленең көнчыгыш диалектында фин-угор алынмалары мәсьәләсен һәм себер татарларының фин-угор халыклары белән бәйләнешен башкарак яссылыкта карау дөресрәк булыр. Себер татарларының фин-угор халыклары белән этнолингвистик бәйләнешләренә үз вакытында себер-татар диалектын тикшерүче бик күп галимнәр (Х. Алишина, Р. Барсукова, Ф. Вәлиев, Б. Вәлиев, Л. Дмитриева, С. Исхакова, А. Насыйбуллина, Г. Ниязова, Д. Рамазанова, А. Рәхимова, Н. Томилов, Д. Тумашева һ.б.) игътибар иткәннәр. Себер халыклары белән фин-угорларның бәйләнешләре дә бик борынгы чорлардан ук булуы ихтимал. Урал телләре гаиләсенә кергән телләрдә сөйләшүче халыкларның формалашуын Көнбатыш Себер белән бәйләп караучы гипотеза турында бик күп фәнни чыганакларда язылган. Бу гипотеза буенча, Урал халыкларының борынгы ватаны Көнбатыш Себердә булган. Якынча IV гасыр урталарында Урал гомумилеге, көньяк кабиләләрнең кысрыклавы нәтиҗәсендә, икегә таркала: көнчыгыш төркем – самодиларның бабалары дип фаразлана – Енисейга күченә, көнбатыш төркем, кысрыклаучы кабиләләр белән бераз кушылып, көнбатыш юнәлештә Урал аръягына, Идел–Кама һәм Уралга күченә, соңрак чорда бу төбәктә Идел–Ука һәм Урал–Кама мәдәни өлкәләрен барлыкка китерә (А. Халиков, П. Хайду , Р. Күзеев һ.б.).

Шулай итеп, Идел–Урал буенда һәм Көнбатыш Себердә төркиләр фин-угор халыклары белән бик борынгы чорлардан ук аралашкан. Төркиләрнең йогынтысы фин-угорларга көчлерәк булса да, фин-угорлар да төрки халыкларның этник һәм тел үзенчәлекләренең барлыкка килүендә аерым урын алып тора. Бернидәр дәрәҗәдә бу йогынты татар телендә һәм аның җирле сөйләшләрендә алынма сүзләр буларак чагылыш таба.

### § 6. Фин-угор алынмаларының лексик-тематик төркемнәре

Татар телендә кулланылган фин-угор алынмаларының лексик-тематик үзенчәлекләрен тасвирлау бу телләрнең бәйләнеш үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Чөнки лексиканың тематик төркемнәре бу халыкларның аралашуы нинди иҗтимагый-сәяси, хуҗалык-икътисади һәм табигать шартларында баруын ачык чагылдыра, рухи һәм матди лексикада булган үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Татарларның фин-угорлар белән озак гасырлар дәвамында аралашуы бертөрле шартларда бара, һәм бу аларның

телләрендә уртак рухи һәм матди лексиканы барлыкка китерә (Әхмәтьянов, 1981, 1989). Шулай да, башка телләрдән кергән алынмалардан аермалы буларак, татар телендә фин-угор алынмаларының тематик төркемнәрендә үзенчәлекләр булуын да билгеләргә кирәк.

Татар телендә кулланылган фин-угор алынмаларының лексик-тематик яктан төп үзенчәлекләре – алар арасында ил, дәүләт төзелешенә, дәүләтара һәм икътисади-сәнәгать, дин һәм сәнгать өлкәләренә караган, иҗтимагый зат буларак кеше һәм милек мөнәсәбәтләрен көйләүче һ.б.ш. сүзләрнең бөтенләй булмавы күзгә ташлана. Бу, беренче чиратта, Идел–Урал төбәгендә фин-угорларның башта Бөек Болгар дәүләте, аннан Алтын Урда дәүләте, соңрак – Казан ханлыгы составында иҗтимагый-сәяси яктан төркиләргә буйсынган хәлдә яисә озак дәверләр бер дәүләттә яшәве белән бәйле булса кирәк. Ә бу тематик лексиканы татар телендә төрки-татар нигезле яисә башка алынма сүзләр тәшкил итә.

Бер үк вакытта татар телендә күпчелек фин-угор алынмаларының кешенең тормыш-көнкүрешенә, аны чолган алган дөньяга һәм табигатькә мөнәсәбәтле булуы белән бәйләргә мөмкин. Алар арасында түбәндәге тематик төркемнәрне аерып күрсәтергә була:

1) үсемлекләр дөньясына караган сүзләр (*алабай, бәлчә, бәпчек, быры, гомы, дива, зый, козавыз, курыс, логы, мәл, мәшкә, миләш, мөҗе, норды, паңгы, паршпил, пешник, пизел, порни, пут, пучы, пуштурын, пыкыш, пышни, сәрдә, сөян, терке, туез, чыҗым, шәмкә, шуйыт, шылан, ылыс* һ.б.);

2) хайваннар дөньясына караган сүзләр (*бәртәс, кәлчәк, күтәмә, меле, өнчерә, шамбы; дегәшкәй, зәлкә, кесия, кошы, кукунай, күкшә, пакарач; купшанкы, ләпәк, прамыш, шура; куҗылы, кучкук, папа, чүнәри; ләтчә, мис, мирән, мыры, пошы, шәшке* һ.б.);

3) тормыш-көнкүреш сүзләре (*бүкән, тәңкәл, биштәр, кумта, сәүри, ләнгәз, лыбы, печтер, тырыс, шабалка; игәрцә, кугыл, пилмән, пыды, пыры, шужы; киндерә, кышон, нашмак, сүрәкә, чулык, чукыл, ыштыр* һ.б.);

4) хуҗалык итү өлкәсе сүзләре (*кәрәз, келем, көшел, кәлигә, кусыл, маңис, морда, мошко, нәрәтә, пугриҗ, ятьмә; күргид, лапас; чидун* һ.б.);

5) кешенең эчке һәм тышкы халәтенә бәйле сүзләр (*җен, йар, йуж, кел, лавыр, лепкә, элпә; ныҗы; зебет, кереч, кукша, кәттә, кыбры, лапшык,шакшы, шүяк, намыстымыс, сүпрес* һ.б.);

6) ышануга, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәргә бәйле сүзләр (*акашка, атакыш, гырбыр, кечтун, печмән, шыйлык, сүбәт; бутыш, йома, кукамай, шекә, шөшле, шүберле* һ.б.);

7) җир, су шартларына һәм һава торышына бәйле сүзләр (*алан, котыр, мәте, лап, лабра, нәште, лыпыш, шөлтеш, бәке; сайкыт* һ.б.).

Татар телендә фин-угор алынмаларының лексик-тематик үзенчәлекләрен тасвирлаганда, кешенең гаиләдәге мөнәсәбәтләренә, кан-кардәшлек һәм туганлык терминнарына махсус тукталу зарур. Бу лексик катлам бар телләрдә дә сүзлек составының иң тотрыклы өлешен тәшкил итә. Бик борынгы чорларда барлыкка килеп, гаилә һәм туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүче сүзләр аз үзгәрә, бу төркемгә чит телләрдән лексик берәмлекләр сирәк үтеп керә. Булганнары да нәсел-ыруның үз эчендәге гаилә мөнәсәбәтләренең үзгәрүенә бәйле барлыкка килә, я кардәшлек термины чит нәсел-ырудан өйләнешү (күбрәк килен төшерү) юлы белән алына. Шуңа күрә мари һәм удмурт телләреннән татар теленә кардәшлек һәм туганлык сүзләре бик аз кергән. Мәсәлән, мари теленнән *кәкәм*, *кәбәм* «сеңелләргә һәм энеләргә дәшү сүзе», удмурт теленнән *бочон* «баҗай, баҗа», шулай ук *пыртус* «асрамага алынган; йортка кергән (ир)» кебек сүзләрне генә күрсәтергә мөмкин.

Татар телендә мордва телләреннән алынмаларга килгәндә, гаилә һәм туганлык мөнәсбәтләрен белдерүче сүзләр алынмаларның күпчелеген тәшкил итә. Бу кан-кардәшлек һәм туганлык терминнары мордва-каратайлар сөйләшендә сакланган. Монда *мазинай* һәм *дугинай* кебек ясалма сүзләрне дә кертәбез. Кан-кардәшлек терминнарыннан мордва телләренә мөнәсәбәтле сүзләрдән тик 2 алынма берәмлек кенә – *акыли* һәм *узакай* – башка татар теле сөйләшләрендә очрый.

Мордва-каратай сөйләшендә лексиканың башка тематик төркемнәренә карган 14 мордва алынмасы теркәлгән: *вырав*, *кукунай*, *кумадун*, *кырд'ны, ләпәнә*, *паз, пакарач*, *пытыршан*, *сав*, *үченбаш*, *чүрәле*. Мордва-каратайлар телендәге тагын 3 сүз мишәр диалектының башка сөйләшләрендә кулланыла: *ат'акыш*, *покма́р*, *шәнчек*.

Бу хәл мордваларда зур патриархаль гаиләнең таркалу һәм үз кан-кардәшлек терминнарының архаиклашуы, татар-мордва икетеллелегенең башта – төп җирлегендә, соңрак – көнчыгышта таралышы белән генә түгел, ә төп торак пунктларда, бигрәк тә катнаш

авылларда бу ике халыкның туганлашуының артуы белән дә аңлатыла (Исәнбаев, 1989: 54, 107–108). Шуның өстенә мордва-каратайларның килеп чыгышының генетик аспектын махсус өйрәнү, кызганычка каршы, әлегә чаклы тиешле дәрәҗәдә башкарылган дип әйтеп булмый. Бу мәсьәләдә галимнәр арасында әле һаман да фикер төрлелегe хөкем сөрә (Мәхмүтова, 1978: 80; Арсланов, 1991: 35–36; Әхмәтьянов, 1991: 39). Шуңа күрә И. Насипов, татар телендә мордва-каратай сүзләренең субстарт күренеш булуы ихтимал, дип белдергән иде (Насипов, 2013: 95).

Шулай итеп, татар теле тарафыннан үзләштерелгән фин-угор сүзләренең саны, шул исәптән аларның лексик-тематик төркемнәре, мари, мордва һәм удмурт телләрендәге төрки-татар алынма лексемаларына караганда, чагыштырмача бик аз. Әмма бу сүзләр татарларның фин-угор халыклары белән борынгыдан һәм озак гасырларга сузылган даими тыгыз мәдәни-икътисади мөнәсәбәтләре булуын дәлилләп тора. Әлеге сүзләрнең татар теленә алынуы турыдан-туры аралашу процессы нәтиҗәсе, һәм алар, нигездә, сөйләм теле аша җирле сөйләшләргә үтеп кергәннәр.

## § 7. Татар телендә кулланылган фин-угор алынмаларының лингвистик үзенчәлекләре

Идел–Кама төбәгендә төрки телләрнең фин-угор телләренә йогынтысы көчлерәк була: мари телендә өч меңгә якын татар лексик берәмлекләре, удмурт телендә – ике меңгә якын, ә хәзерге мордва телләрендә дүрт йөзгә якын төрки тамырлы лексемалар билгеләнә (Серебренников, Исанбаев, 1979: 3–7; Исанбаев, 1989; Тараканов, 1982; Бутылов, 2005). Алынмалар күләме бу халыкларның аралашу дәрәҗәсен ачык чагылдырып тора.

Көнчыгыш фин-угор телләрендә төрки алынмалар, бәлки, күбрәк тә булгандыр, әмма аларның күпчелеге соңрак чорда, иҗтимагый-тарихи шартларга бәйле рәвештә, рус теленнән алынган сүзләр белән кысрыклап чыгарылган. Ә менә комиларның ата-бабалары кайчандыр Кама елгасының урта агымында яшәсәләр дә, коми һәм удмуртлар якын тугандаш халыклар булсалар да, коми телендә төрки алынмалар тагын да азрак билгеләнә. Комиларның ата-бабалары X гасырда ук төньякка күченгәннәр, дип санала, димәк, алар удмуртлар һәм төрки-татарлар белән шул чорга кадәр аралашканнар (Ахметьянов, 2004: 177).

Фин-угор телләренә йогынтысы буенча Идел буе төрки телләрен түбәндәге тәртиптә урнаштырып булыр иде: 1) чуваш теле; 2) татар теле; 3) башкорт теле. Мондый тәртипнең хаклыгы төрки телләрнең мари теленә йогынтысына мөнәсәбәтле чуваш-мари тел бәйләнешләренә багышланган хезмәтләрдә нигезләнә (Ф. Гордеев, Д. Казанцев, Г. Лукоянов, М. Федотов, Н. Мөкимова һ.б.). Әмма үз вакытында күренекле мари телчесе Н. Исәнбаев, татар теле үзенең мари теленә йогынтысы нәтиҗәләре буенча чуваш теле белән җитди чагыша ала, дигән (Исәнбаев, 1978: 49).

Мари һәм удмурт телләре татар теленең урта диалекты сөйләшләре белән тыгызрак бәйләнештә булсалар, мордва телләре мишәр диалектының сөйләшләре белән ныграк аралашканнар, ә эрзя теленә караганда, мокша телендә төрки (мишәр) алынмалары күбрәк (Махмутова, 1976: 153).

Идел буе фин-угор телләре арасыннан мари телен төрки телләрнең көчле йогынтысына бирелгән тел дип күпчелек галимнәр хаклы билгели. Өстәвенә, бу йогынты фонетик-грамматик дәрәҗәдә дә, лексик-семантик дәрәҗәдә дә чагыла. «Башка телләрдән алынма лексикада каралган... 88 сүз ясагыч суффикслардан мари теленә 24 суффикс алынган, шулардан 21 е төрки телләрдән һәм тик 3 се генә рус теленнән яки рус теле аша кергән... Төрки чыгышлы суффикслар... аерым очракларда үз мари суффикслары белән чагыша башлый» (Галкин, 1966: 160).

М. Федотов мари телендә 1352 чуваш алынмасын терки (Федотов 1990: 5). Н. Исәнбаев мари телендә татар һәм башкорт телләреннән кергән 3000 сүзне билгели: «Татар һәм башкорт алынмалары, шикле сүзләр һәм төрки булмаган сүзләр (ягъни мари теленә татар теле аша кергән якынча 500–550 гарәп-фарсы, монгол һ.б. телләр сүзләре) белән бергә, өч мең лексик берәмлекне тәшкил итә» (Исанбаев, 1994: 163; 1989: 2).

Төрки телләрдә мари алынмалары шактый азрак санда. М. Рясянен, чуваш телендә мари теленнән кергән бәхәссез 50 гә якын сүзне һәм бу телләр өчен уртак булган 50 дән артык сүзне аерып чыгарган (Rasanen, 1920: 238–274). М. Федотов мари-чуваш алынмалары сүзлегенә 247 сүзне керткән. Бу сүзләр үзләренең фоно-семантик үзенчәлекләре буенча гомум төрки формаларга якын торган мари телендәге чуваш һәм татар алынмаларыннан да, башка кардәш фин-угор сүзләреннән дә нык аерылып тора, кайбер

очракта аларның кайсы телгә мөнәсәбәтле булуын билгеләве дә кыен, ә кайчак бөтенләй мөмкин түгел. Этимологик анык булмау сәбәпле, бу сүзләрне үзара аралашкан якларның кайсы белән бәйләп карасаң да бәхәсле (Федотов, 1990: 298–322).

Л. Арсланов белән Н. Исәнбаев татар телендә мари теленнән алынган 70 сүзне күрсәтәләр. Шул ук вакытта алар мари һәм татар телләрендә чыгышлары ачык булмаган күп кенә уртак лексемаларны билгелиләр. Монда бер үрнәк буенча ясалган күпсанлы кушма сүзләрнең һәм тезмә терминнарның булуын да исәпкә алырга кирәк (Арсланов, Исәнбаев, 1984: 104–114). Әмма бу берәмлекләр арасында фин-угор телләре өчен уртак (гомум фин-угор, гомум пермь, борынгы пермь) сүзләр булуын да билгеләү зарур.

Тикшеренүләр татар телендә 100 гә якын лексик берәмлекне мари теленнән алынма буларак билгеләргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән: *актанасты* «өйалды асты» (мар. *агытан* «әтәч» + тат. *асты*); *алабай* «акчәчәк, ромашка» (мар. *вуй* «баш»); *бәке* «бәке» (мар. *вӓкы*); *бәртәс* «бәртәс, опты – балык төре» (мар. *пӓрдӓш*, *пардаш*); *бәлчә* «тәлгәш» (мар. *велше*); *биштәр* «биштәр, туздан асма савыт» (мар. *пестер, пӧштыр*); *бутыш* (крш.) «табигатьне илаһилаштыручы мәҗүси зат», «су анасы» (мар. *вадаш* «илаһи зат»); *җен* «сухожилие, пищевод» (мар. *шүн, шӧн*, *сүн*, коми, удм. *сӧн*); *игәрче* «икмәк, көлчә, җәймә» (мар. *эгерче*); *яры* «яры, элпә» (мар. *йар*); *йома* «мари алласы, илаһи зат» (мар. *юмо*); *кәкәм* «сеңел, энекәш» (мар. *кӓкӓм* «апа»); *кәлчәк* «кәлчәк – балык төре» (мар. *кылчак*); *кәрәз* «кәрәз»; (мар. *кӓраш*, морд.м. *кяряст*); *кәттә* «билгеле, ихтирамлы; егет» (мар. *катчы* «егет»); *кесийә* «песнәк» (мар. *кӗсиа,* удм. *киса*); *киндерә* «ау» (мар. *кӓдырӓ*); диал. *кирәм* «үрмә; аркан; баудан баскыч» (мар. *керем*); *көшел* «сугылган иген өеме; күбә» (мар. *кышыл*); *күкшә* «күкшә – кош», «пеләш» (мар. *кукшо*); *күтәмә* «күтәмә – вак балык» (мар. *котама*); *кугыл* «пирүк» (мар. *кагыль*; удм. *кукли*); *кукамай* «әби, карт әни», «убырлы карчык» (мар. *кугавай*, *кугуавай*; удм. *гугама*); *қупшанқы* «коңгыз» (мар. *капшанкы*); диал. *қыбры* «купшы, көяз» (мар. *ковра*); диал. *қыйшаннау* «кылану», *қыйшаннақ* «кыланчык» (мар. *койышланаш*); диал. *лабра* «пычрак», «шапшак» (мар. *лавра*; удм. *напра*); *лапас* «хуҗалык корылмасы» (мар. *лепас*; удм. *лабас*, морд.м. *лапаз,* коми *лобос*); диал. *лапшык* «тузган, тетелгән» (мар. *лапцака*); диал. *лапы* «чыбык-чабык» (мар. *лупо*); диал. *лач*

«чи, пешеп җитмәгән (икмәк)» (мар. *лаза*, *лазыра* «сазлык»); диал. *ләпәк* «вак чебен» (мар. *лыве*, *лыпы*); диал. *ләтчә, йәтчә* «ләтчә – зоол.» (мар.); *лепкә*, *лүпкә* «маңгай; баш түбәсе» (мар. *лепка*); диал. *лыбы* «юкә кабыгыннан сумка» (мар. *лупо* «чыбык-чабык»); диал. *лыпыш* «мәте һәм ком кушмасы», «язгы пычрак» (мар. *лапаш* «боламык»); диал. *меле* «җилембалык, ак чабак – вак балык» (мар. *мыле*; коми *мали*); диал. *миран* «куян» (мар. *мера́н*); диал. *намыстымыс* «оятсыз» (мар. *намысдыме*); *нашмак* «киленнең баш киеме», «бит челтәре; яулык» (мар. *нашмак* «ир хатынының баш бизәге»); диал. *ныҗы*, *нежҗе* «зур чуан, сызлавык», «явыз рух» (мар. *мыж* «чир», *мужо* «каргыш, чирле рухы»); диал. *онго* «урак яки чалгы кыршавы» (мар. *онго* «кыршау», «элмәк», удм. *угы* «алка»); диал. *печмән* «өч тапкыр уздырыла торган язгы бәйрәм» (*бәләкәй печмән*, *икенче печмән*, *өченче печмән*) (мар. *пысман,* удм. *бесмен*, *бисьмен* «буразна», «чик»); диал. *печтер* «кабыктан тырыс, тубал» (мар. *пӧштыр*); диал. *пыкыш* «чикләвек орлыгы» (мар. *пӱкыш* «чикләвек»); *сөян* «кайрысы алынган юкә» (мар. *суйем;* удм. *суыны,* коми *сувйыны* «каезлау»); диал. *сүрәкә* «керәшен хатын-кызларының баш киеме», «чигүле яулык», урта диал. «калфак» (мар. *сорока* «кияүдәге хатын-кызның баш киеме»); диал. *тәңгәл* «урындык» (мар. *тенгыл* «эскәмия»); диал. *терке* «яшь нарат» (мар. *тырке*); *тырыс* «каен тузыннан тырыс, тубал» (мар. *тырыс*); *чәберчек* «орлыксыз йомырка», «бозылган, сасыган йомырка» (мар. *шувырчык*); *шакшы* «пычрак», «шакшы, начар» (мар., удм. *шакшы*); *шамбы,* диал. *жумба* «балык» (мар. *шамба, шамбе* «налим»; ханты. *соппы*); диал. *шәмкә, шәмкәлек* «яшь наратлык» (мар. *ша́нгы* «чыбык-чабык», *пуша́нгы*, *пуше́нге* «агач»); *шәшке* «шәшке», (мар. *шашке*, удм. *шашака*); диал. *шекә* «гном, кәрлә бабай, шүрәле» (мар. *шика*); *шөлтөш* «кар, боз боткасы» (мар. *шултыш*, коми *шоль*, манс. *сульх*); диал. *шөшле* «без (чабата үрү өчен)» (мар. *сӱзлӧ*); диал. *шуйәк* «шамакай, ялганчы» (мар. *шая*, *шояче*); диал. *шүберле* «явыз рух» (мар. *шӱвыр* «сорнай», *шӱгарла* «кабер рухы», *шӱгар* «зыярат, кабер»); диал. *шуйыт* «тмина, әнис орлыгы» (мар. *шуй* + тат. *ыт*/*ут* «үлән»); диал. *шыйлыҡ* «язгы кыр корбан чалу йоласы», «туй йоласы», *шыйлыҡ бутҡасы* «бәйрәм (сабантуй) боткасы» (мар. *шелык* «тәхет», диал. «мәҗүси мариларның табыну урыны», *шилык* «(ихатада) туй урыны»); *ыштыр* «киез оек, чолгау» (мар., удм. *ыштыр*); *элпә* «яры, элпә;

эмаль» (мар. *ӓлпа*); *ятьмә*, диал. *җәтмә*, *әтмә* «ятьмә», «ау, морда» (мар. *атма*) һ.б.

Югарыда күрсәтелгән лексик берәмлекләрнең яртысыннан артыгы татар теленең урта диалекты сөйләшләрендә кулланыла, мари алынмалары урта диалектның тау ягы сөйләшләре төркемендә күбрәк табыла. Монда мари алынмаларының керәшен сөйләшләрендә актив булуы күзгә ташлана. Мишәр диалектында исә алар бик аз теркәлгән: *игәрца, кәттә, кесийә, бутыш, кукша, ныжсы/неже, пыкыш.*

Татар әдәби телендә мари теленнән алынган якынча 20 ләп сүз кулланыла, алар аңлатмалы һәм ике телле сүзлекләрдә *(биштәр, бәке, бәртәс, зый, яры, кәрәз, көшел, кукшә, күтәмә, лапас, лапшык, леп, лепкә, сөя, тырыс, чәберчек, шамбы, шакшы, шөшле, ыштыр, элпә)* теркәлгән:. Бу сүзләрнең кулланыш ешлыгы төрлечә, аларның күпчелеге бүген татар теленең пассив лексик составына карый һәм искергән сүзләр буларак күрсәтелә. Аларның күбесе сөйләшләрдә (нигездә, урта диалектка караганнарда) фонетик, сүз ясалышы яисә семантик үзенчәлекләре буенча аерыла торган диалекталь эквивалентларга ия. Тик ике сүз генә (*нашмак, шөлтөш*) татар сүзлекләрендә урын алмаган, ләкин аларны башка чыганаклар буенча билгеләп була.

Татар теленең сүзлек составында 30 га якын лексик берәмлек гомум фин-угор алынмалары санала ала, ягъни алар мари теле белән дә, удмурт теле белән дә, мордва, коми һ.б. телләр белән дә бәйле. Шул ук вакытта таралыш җирлекләре аларны теге яки бу конкрет тел белән бәйләргә мөмкинлек бирми: бу сүзләр контакт зоналардагы күпчелек татар сөйләшләрендә теркәлгән, ә кайберләре гомумхалык лексемалары санала. Алар арасыннан мари телендәгеләре: *алан*, *букән*, *бышымны чабата*, *курыс*, *лап*, *мәшкә, миләш, мошко*, *мөҗө, поши, соса*, *төш*, *чыҗым*, *ылыс*.

20 гә якын фин-угор сүзе татар теленә рус теле аша кергән. Алардан 14 сүз балык атамаларына һәм 2 сүз балыкчылык әйберләре исемнәренә карый. Шулар арасыннан мари телендә 2 сүз теркәлгән: *нәрәтә*, *морда*.

Татар телендә 63 лексик берәмлек мордва-мокша һәм мордва-эрзя (морд.м., морд.э.) телләреннән алынма дип билгеләнә. Шулай итеп, татар телендә мордва алынмалары дип түбәндәге лексик берәмлекләрне санарга мөмкин: диал. *аба* «кайнана, биана» (морд.

*ава* «хатын-кыз; хатын», морд.м. «ана», «биана»); диал. *аван'и, аваня* «кече балдыз» (морд.э. *авне*); диал. *ад'а, аджа, әдҗә* «ана» (морд. *ада*); диал. *ака* «апа» (морд.м. *ака* «апа; түтәй»); *ака*»өлкән апа», «картәни», «түтәй» (морд.м. *ака* «апа; түтәй»); диал. *акыли* «ирнең олы апасы», «ирнең абыйсының хатыны» (морд.м. *акля* «ирнең апасы», *акле* «өлкән килен»); диал. *ал'а* «ирнең олы абыйсы» (морд. *аля* «ир»; морд.м. «ата»); диал. *ат'акыш* «маска киеп, өйдән-өйгә йөрүче святка (яңа ел) уенында катнашучы»; диал. «ахмак; аңгыра; булдыксыз» (морд. *а́тякш* «ир; ирдәүкә»); диал. *аука* «нәнәй, дәү әни» (морд. *ава* «ана»); диал. *ашава* «исем» (морд.э. *аша* «ак» + *ава* «хатын-кыз», *ашава* «яшь кыз»); диал. *баса* «(ата) киндер» (морд. *пан, поч*); диал. *пыжу* «шиңү, бәлҗерәү» (морд. *пужемс*); *дугинай* «кадерле; чибәр кыз» (морд.э. *дугиней*, морд.м. *дуганняй* «сеңелнең абыйсына дәшү сүзе»); *важҗи* «әтинең яисә әнинең кече апасы» (морд.); *верәш* «әнинең олы абыйсының хатыны» (морд.м. *ур'аш*, мокш.э. *уряж*); *вырав*, *вырнавкыс* «чигү төре» (морд.э. *веравт* «хатын-кыз күлмәгенең иңсәсендә һәм якасында тәресыман чигү», морд.э. *верявкс* «рус тәресе сыман чигү»); *дуги* «кыз» (морд.э. *дуга* «абый, энекәш», «апа, сеңел», морд.м. *дуган* «ападан кече бәләкәй абый»); диал. *кәркеш* «җеп; бау; бөрмә», «бөрмәле чабата; чабата бавы» (морд.м. *кярькс* «үрмә, бәй» > *кярькс*- (*-амс*) «үрү, бәйләү»); диал. *кифтай* «кече каенага, биага – ирнең иң бәләкәй абыйсы» (морд. *кифта, кефта* «биага»); диал. *җойгорош* «бәхет кошы (*колын, бозау*)» (морд. *койгорож* «кош-елан», морд. *гуй*, *куй* «елан» + *корош* «филин»*, корож* «ябалак; сыч»); диал. *җукунай* «күке» (морд.м. *куку*, морд.э. *куко*); диал. *җумадун* «чуан, сызлавык; шеш» (*командоньбал* морд. «эре чуа, сызлавык; шеш», «төче авыруы – золотуха», «колак арты бизе шешү – свинка»); диал. *кырд'ны* «чигү төре», *кырдйы* «үрнәк» (морд.э. *курзя* «үрмә бау төсле чигү»); диал. *кытсас'* «мазнастан соң икенче энекәш» (морд.); диал. *лаwсә* «берүк вакытта кухня өстәле һәм шкафы буларак файдаланыла торган кечкенә сәкенең савыт-саба кую өчен өске киштәсе» (морд.э. *лався* «кухня шкафы», «киштә», морд.м. *лавця* «киштә», «кием кую өчен киң эскәмия»); диал. *ләлә* «олы абый», «әтинең яисә әнинең абыйсы; дәдә» (морд.э. *леля* «олы абый», «дәдә»); диал. *ләпәнә* «пич арасына урнаштырылган, бер үк вакытта кухня өстәле һәм шкафы буларак файдаланыла торган кечкенә сәкенең (путмараның) савыт-саба кую өчен өске киштәсе»,

«киштә», «путмараның икенче киштәсе» (морд. *лапана* «стена арасындагы ачык киштә»); диал. *мазай* «ирнең абыйсы», диал. *мазинай* «матур, гүзәл, чибәр» (морд. *мазы*, *мази* «чибәр, сылу»); диал. *лапама́* «нык зур» (морд.м. *ла́пама* «кер уклавы»); *мазнас*, *мазнач* «ир энеләренең иң кечесе» (морд.м. *мазня* «ир энеләренең иң зурысы»); диал. *макшу* «(яшелчә) пыжу, шиңү» (морд.м. *ма́кша,* морд.э. *ма́кшо* «черек»); диал. *порн'у* «төнәү», «күксү, сасу», «изелеп пешү, черү», *пырн'ыгу* «изелү, тирләү» (морд. *пурьгиямс, пургиясь* «(су) күксү, сасу»); диал. *паз, баз* «алла» (морд. *паз*); диал. *пажҗи*, *пази* «(ата) киндер», «сүс» (морд.э. *пазе,* морд.м. *пазяй,* мар. *пачаш* «сүс; тәрәшле сүс»); диал. *пакарач* «чукмар баш, бака баласы» (морд.м. *пакарязь*); диал. *паңгы* «гөмбә» (морд.м. *панга*, морд.э. *панго*); диал. *пәеч* «бала башындагы кутыр, касмак», «кайнаган сөт элпәсе», «юшкын» (морд.м. *пяезь* «сөт, татлы кайнатма өстенә җыела торган күбек»); диал. *петәй*, *пети* «сыер җилене», «хатын-кыз имчәге» (морд.э. *потя* «(хатын-кыз, хайван) имчәге»); диал. *пизел* «миләш» (морд.м., морд.э. *пизел*, мар. *пизле, пызле*); диал. *пут'ма́р* «пич арасына урнаштырылган, берүк вакытта кухня өстәле һәм шкафы буларак файдаланыла торган кечкенә сәкенең (путмараның) савыт-саба кую өчен өске киштәсе», «киштә», «путмараның икенче киштәсе», «пич арасындагы бәрәге тартмасы» (морд.э. *потмар* «савыт-саба шкафы»; морд.м. «ләвкә астындагы савыт-саба шкафы»); диал. *прамыш* «кигәвен», «сагызак», «вак кигәвен» (морд.э. *брумо* «төклетура, кормыш»); диал. *пукыл'* «кисәк», «кантар, зур кисәк», «киләп, җеп бәйләме» (морд. *поколь*); диал. *пусча*, *пуча*, *пуча* «картәти» (морд.э. *покштя*); диал. *пытыршан* «угыз, угыз азыгы» (морд.); диал. *сав* «киҗе мамыктан чигүсез алъяпкыч» (морд.м. *шава*, морд.э. *ишава* «чигүсез»); диал. *тәтә* «әти», (морд.э. *тетя*, *тетей* «әти»); диал. *удаwа*» «тол хатын», «тол ир» (морд.э. *од ава* «үги ана»); диал. *уку* «әни абыйсының кызы» (морд. *ука* «энекәш», «сеңлекәш»); диал. *учакай*, *утсякай*, *үзакай* «олы апа», «түткәй», «картәнинең апасы яисә сеңлесе» (морд.м. *оцю* «зур, олы» + *акай* «апа»); диал. *үчәләй* «дәдә», «картәнинең абыйсы» (морд.м. *оця*, морд.м. диал. *оцяля* «әтинең олы абыйсы»; чагышт. морд.э. *аля* «ир», «дәдә»); диал. *үченбаш* «дога», «ялвару» (морд. *оцю* «зур, олы» + *паз* «алла»); диал. *чакан'а* «чөгендер яфрагыннан әзерләнгән азык» (морд.); диал. *челги* «миң», «сыткы, бетчә», (морд.м. *цилге*, морд.э. *сильге* «миң»); диал. *чирах-*

*ман* «боз, рашка» (морд. *цярахман*); диал. *чүрәле* «чигү атамасы» (морд. *чура*, морд.э. *шуре*, морд.м. «җеп»); диал. *чыткыс'* «очлары чуклы хатын-кыз билбавы» (морд.); диал. *шава* «әнинең картәнисе» (морд.м. *шщава*); диал. *шәнчек* «кечкенә юкә сондык»; диал. *ыразныс'* «ирнең бәләкәй абыйсы»; *ышшаба,ыщщаба, шаба*»эщщәнәнең хатыны», (морд.м. *щаба* «картәни»); диал. *эстернәч* «ир сеңелләренең олысы» (мокш. диал. *стердня*, *стередня* «ирнең бәләкәй апасы»); диал. *эшшенә, эщщәнә* «әнинең (олы) абыйсы» (морд.м. *щеня* «әни яклап дәдә») һ.б.

Югарыда каралган мордва алынмалары арасыннан бер генә берәмлек тә татар әдәби теленең норматив лексикасына керми. Алардан 47 сүз, ягъни 74% мордва-каратайлар сөйләшендә кулланылса, 26 сүз урта һәм көнбатыш диалектларның башка сөйләшләрендә кулланыла. Әгәр сан ягыннан лексиканың бу өлешен лингвогеографик яктан анализласак, аларның тик дүртесе генә көнбатыш диалектта гомумкуланылыш сүзләре, калганнары сөйләшләр буенча тарала. Шуны да билгеләргә кирәк, мордва алынмалары көнбатыш диалектта һәм мишәрләр йогынтысында формалашкан урта диалект сөйләшләрендә теркәлә (Махмутова, 1976: 298). Бу мордва телләрендә төрки-татар алынмаларының нәтиҗәләре белән дә дәлилләнә: мордвалар мишәрләр белән тыгызрак аралашкан, ә мишәр диалекты сүзләренең дә мордва-мокша телендә мокша-эрзя теленә караганда күбрәк булуын күрсәтә (Хайрутдинова, 2000: 153).

Татар теленең сүзлек составында гомум фин-угор алынмаларыннан түбәндәге лексик берәмлекләр мордва телләре белән бәйле: *бышымны чабата, дегәшкәй; лап*, *мәте*, *мәшкә, миләш, мошко*, *мөҗө*, *чыжым* (Гаффарова, Насипов, Рамазанова, 2007: 45).Татар теленә рус теле аша кергән фин-угор сүзләре арасында мордва телләренә мөнәсәбәтле сүзләр юк.

Идел–Кама төбәгендә татар теле көнчыгыш фин-угор телләреннән удмурт теле белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Удмурт теле, коми теле белән бергә, фин-угор телләренең фин-пермь тармагына карый. Күпчелек тюркологлар һәм фин-угор телчеләре дөрес билгеләвенчә, удмурт теле төрки телләрнең лексикада гына түгел, ә фонетика, морфология һәм синтаксиста да көчле йогынтысын кичергән Идел буе фин-угор телләренең берсе. Мәсәлән, Э. Беке фин-угор һәм төрки телләрдә 20 дән артык охшаш синтаксик күренешләрне күрсәтә. Шуларның 16 очрагында синтаксик

конструкцияләрне куллану татар теленең шундый ук синтагмалары белән тулысынча туры килә. Фин-угор һәм төрки телләр өчен бик күп охшаш синтаксик үзенчәлекләр (73 кә якын күренеш) шулай ук Фокош-Фукс хезмәтләрендә билгеләнә (Тараканов, 1982: 15).

Б. Серебренников фикеренчә, удмурт теленә болгар теле, ә соңрак татар теле дә көчле йогынты ясаган, бу аның лексикасында гына түгел, ә грамматик төзелешендә дә чагылган. Төрки телләр, бер яктан, удмурт телендә төрки телләр йогынтысына бирелмәгән, фин-угор телләрендә булмаган үзенчәлекләрнең барлыкка килүенә китерсә, икенче яктан, төрки телләр гомумпермь чорында формалашкан кайбер типологик бертөрле үзенчәлекләрнең саклануын тәэмин иткән (Серебренников, 1960: 109). Галим татар һәм удмурт телләренең структур-типологик охшашлыгына күп тапкыр басым ясый. Ул удмуртларның татарлар белән күп гасырлар дәвамында интенсив бәйләнешләре булуын, аның нәтиҗәсендә ике телдә дә уртак үзенчәлекләрнең барлыкка килүен билгели. Мәсәлән: 1) фонетикада – удмурт телендә басымның соңгы иҗеккә төшү күренешенең барлыкка килүен; 2) морфологиядә – татар моделе буенча тезмә фигыльләр (хәл фигыль + ярдәмче фигыль), исем фигыль мәгънәсенең тартым кушымчалары белән ясалышы, үзенчәлекле изафет конструкцияләр ясалышы, хәл фигыльнең кулланылыш ешлыгы артуы, ике исемнең килеш кушымчасы ярдәмендә бәйләнеше һ.б.; 3) синтаксиста – җөмләдә фигыльдән ясалган тезмәләрнең таралышы, җөмлә азагына хәбәрне кую тенденциясе һ.б. Дөрес, бу үзенчәлекләр удмурт телендә, мари теленә караганда, азрак дәрәҗәдә үсеш алган (Серебренников, 1960: 265–269). Шуңа күрә удмурт һәм татар телләренең үзара йогынтысы мәсьәләләрен карау, Идел–Кама төбәгендә тел бәйләнешләрен тикшерүдә әһәмиятле роль уйный.

Татар теленә һәм аның аерым сөйләшләренә хас лексик һәм фонетик-грамматик үзенчәлекләр татар сөйләшләре белән контакт зоналарда бәйләнештә торган удмурт теленең күпчелек сөйләшләрендә дә чагыла. Татар теленнән ике меңгә якын алынма лексик берәмлек теркәлгән (Тараканов, 1982). Удмурт теленә татар теленең урта диалекты сөйләшләре көчлерәк йогынты ясаган.

Татар телендә йөздән артык лексик берәмлек удмурт алынмасы яисә удмурт теле белән бәйле берәмлек дип карала ала. Андый

бирәмлекләргә түбәндәге сүзләрне кертергә мөмкин: *алан* (удм., мар. *алан*); диал. *бәпчек* «яңа сабак, үренте» (**paƀ* = *бәп-* + афф. *-чек/-шек;* удм. *пубы;* коми *паб*); диал. *божо йачкалау* «киенү, маскарад ясау» (удм. *вожо* «коточкыч алла һәм өрәк», *вожоаськыны* «киенү, маскарад ясау»); диал. *бочон* «бажа»; диал. *бугур* «йомгак» (удм. *бугор*); диал. *бүкән* «урындык» (удм. *пукон*; мар. *пӱкен*; коми *пукон*); диал. *быры* «җир җиләге» (удм. *боры*); диал. *бышымны чабата*/*қынҗырық* «күн өсле чабата» (удм. *быш*, коми *пыш*; мар. *муш*; морд. *мушка*, *мушко* «сүс, тәрәшле сүс, киндер»; **рӣ́č* «киндер»); диал. *быры* «җир җиләге» (удм. *боры*); диал. *геби* «гөмбә» (удм. *губи*); диал. *гомо* «күпшәле үсемлек», *аңгыра гомо* «түндербаш», *йонно гомо* «урман елан күпшәсе» (удм. *гумы*); диал. *гырбыр* (б.-крш.) «сабан ашлыгы чәчелгәннән соң уздырылучы бәйрәм» (удм. *гербер* «сабан»); диал. *дегәчи* «каз» (удм. *диго, дигонь*; морд.э. *дига*, *дьига*); диал. *җен* «җен, үңәч; сеңер» (удм. *сӧн*, мар. *шӧн*); диал. *зебет* «тыйнак, сабыр» (удм. *зӥбыт*); диал. *зый* «агач (камбиаль) катламы» (удм. *сӥ*; мар.г. *ши, шый,* мар.л. *ший*; коми *си*); диал. *йуж* «кар кабыгы, бозлавык» (удм. *юж*); диал. *йумал* «баллы; төче» (удм. *юмал*); диал. *кәлигә* «гәрәнкә, бүкән шалкан» (удм. *каляга*); диал. *кел* «кавык; кибәк» (удм. *киль*); диал. *келем*»киндер» (удм. *кенэм*); диал. *кереч* «пычрак» (удм. *кырсь*); диал. *кесийә* «песнәк» (удм. *киса*, мар. *кӗсиа, кисӓ, кӗса*); диал. *кечтун көн* «үлгән кешене искә алу мәҗлесе» (удм. *кисьтон*); диал. *қозаwыз* «кыр наратбашы, кыр чыршы үләне» (удм. *кызаузы* «чыршы үсентесе»); диал. *қотқузы* «чабата; чабата бөрмәсе» (удм. *котгозы* «чабата җебе»); диал. *қ'отор* «әйләнә-тирә» (удм. *котыр*); диал. *қошо* «саескан» (удм. *кочо*); диал. *көбәк* «мылтык көбәге» (*күп*,* удм. *гумы* «көбәкле агач»); диал. *қужҗылы* «урман кырмыскасы» (удм. *кузьыли*, коми. *кодзыль*); диал. *қыжҗылы* «очкын» (удм. *кизили*); диал. *қуқамай* «дәү әни, картый», «убырлы карчык» (удм. *гугама*, диал. *кукамай*, мар. *кувай*, *кугавай*); диал. *қуқыл* «пирүк» (удм. *кукли*, мар.г. *кагыль*); диал. *қуқчалау* «чуку, чемченү» (удм. *кукчаны*, *кокчаны*); диал. *қумта* «кечкенә савыт; сумка» (удм. *куды*, мар. *комдо*, коми-зыр. *куд*, хант. *хайнт* «кабык савыт, туез савыт»); диал. *қургид* «абзар» (удм. *коргид* = *кор* «бүрәнә» + *гид* «абзар»); диал. *қурыс* «курыс, кабык» (удм. *курьес*, *кур*; мар. *кур*, *кыр*; коми *кыр*, *кырсь*); диал. *қусыл* «баганаларны бәйли торган җеп» (удм. *кусул*); диал. *қутыртлау* «уратып алу, бүлү» (удм. *котырт*); диал. *қучқуқ*

«черки» (удм. *кузькук*); диал. *қышон* «сөлгегә охшаш баш киеме» (удм. *кышон* «кияүдәге бисермән хатын-кызының сөлгегә охшаш яулыгы»); диал. *лабра* «пычрак», «шапшак хатын-кыз» (мар. *лавра*, удм. *напра*); диал. *лаwыр* «күзгә чыга торган арпа» (удм. *лаур* «туберкулез», «төче авыруы»); диал. *ляқыт* «яраклы, уңайлы» (удм. *лякыт* «әдәпле, ихтирамлы»); диал. *лап* «үзәнлек; тигез җир» (удм. *лап*; мар. *лап*; коми *ляпкыд*; морд.э. *лапужа*, морд.м. *лапе* «яссы, ялпак»); диал. *лапас* «лапас, хуҗалык корылмасы» (удм. *лапас*; мар. *леваш*; морд.м. *лапаз*; коми. *лобос*); диал. *ләнгәз* «савыт» (удм. *лянэс*; мар.г. *лäнгыш*; коми *лянöс*; хант. *йинет*); диал. *ләп* «ирекле» (удм. *ляб* «көчсез»); диал. *ләпшү* «хәлсезләнү; таушалу» (удм., коми *ляб*; морд.м. *ляпе*); диал. *лого* «әрекмән» (удм. *люгы*); диал. *мажис* «тырма» (удм. *мажес*); диал. *мял* «нарат җиләге, көртмәлек» (удм. *мульы* «җиләк», «җимеш төше»; коми. *моль* «сәдәф, төймә; төш»); *миләш* «миләш» (удм. *пальэзь*; мар. *пилзе, пизле*; морд. *пизёл, пизыль*; коми. *пелысь*, *пелыш*); диал. *мис* «инә кәҗә, сарык» (удм. *мэс*); диал. *морда* «балыкчылык коралы; сөзгеч» (удм. *мурдо*, мар. *морда*, коми *морда*); диал. *мошко 1* «киндер; сүс» (коми, удм. *пыш*, мар. *муш*, морд.м. *мушка*, морд.э. *мушко*, **ри́č*); диал. *өмөҗө* «кура җиләге» (удм. *эмезь*; мар. *ынгыж*; морд.м. *инези*, морд.э. *инзей*; коми *öмидз*); диал. *мыры* «кысыр» (удм. *муры*); диал. *нашмак* «туйда киленнең маңгаен һәм йөзен каплап торучы тасма сыман баш киеме», «бит челтәре; яулык» (удм., мар.г. *нашмак* «головное украшение замужней женщины»); диал. *нәрәтә* «җылым, сөзгеч, ау – балыкчылык кораллары» (мар., удм. *нäрäтä*); диал. *нергә* «туйда киленгә кияүнең эти-әнисе бирә торган бүләк» (удм. *нерге* «чин, йола»); диал. *нурды* «курпы» (удм. *норди*); диал. *өнчөрө* «мелкая рыба, малек» (удм. *чорыг*; коми. *чери* «рыба»)»; диал. *папа* «кошчык» (удм. *папа*); диал. *паршпилʹ* «балтырган» (удм. *парсьпель*); диал. *пәтрә* «чарлак, чорма» (удм. *патра*); диал. *пешник* «кыр наратбашы, чыршы үләне» (удм. *пешник*); *пи* «кеше; бала» (удм., коми *пи* «бала; малай»); диал. *пигун* «кош мамыгы» (удм. *пигон*); диал. *пилмән* «пилмән» (удм., коми *пель* «колак» + *нянь* «икмәк»; удм. *пельнянь* «пилмән, пирүк»); диал. *порни* «үлән» (удм. *порни*); диал. *поши* «болан» (удм. *пужей*, коми. *пэж*, мар. *пучо, пучы*); диал. *пугриҗ* «кыяр» (удм. *огреч*); диал. *пуйы* «лампы куыгы» (удм.); диал. *пут* «алабута» (удм. *пот*); диал. *пуштурын* «мәтрүшкә» (удм. *пычытурын, пыштурын*); диал.

*пучы* «кызыл тал, песиле тал; тал» (удм. *пучы* «бөре», «тал»); диал. *пыды* «чәй чүбе» (удм. *пыды* «барда», «чүп, сыекча»); диал. *пыртус* «йортка кергән (ир)» (удм. *пыртос*); диал. *пыры* «чәй чүбе» (удм. *пыры*); диал. *пышни* «җитен кибәге, талкыш» (удм. *пыши* «киндер, җитен талкышы»); диал. *сайҗыт* «салкынча, җиләс (һава)» (удм. *сайкыт* «саф (һава)»); диал. *саламат* «он боламыгы» (удм.); әд. *сәрдә* «сәрдә» (удм. диал. *сюрд*, *сурд*; коми *сорд*; **cörd* «куаклык, кечкенә урман»); диал. *сәүре* «әчегән сөт салу өчен каен тузыннан кечкенә чиләк, күәс» (удм. *сарба*, *сарва*); диал. *серек* «почмак; өй ягы» (удм. *сэрег*); *соса* «каек, көймә – тукуда» (удм. *суса, сусо,* мар.г. *шуша,* коми., коми-перм. *суса,* хант. *супса, супыс*); диал. *сүбәт* «яңа туган бала туе», «өй туе» (удм. *сюан*); диал. *сюпрэс* «шаян, шук» (удм. *чупрэс*); диал. *тебет* «биләүсә, бала чүпрәге» (удм. *тэбэт*); диал. *төш* «төш» (удм. *тысь,* мар. *туш*, коми. *тусь*); диал. *туҗ* «лабаз (базарда бөртекле ашлык, он сату өчен ябык бина)» (удм. *тузь*); диал. *чидун* «утлык, улак, ялгаш» (удм. *сюдон*); *чукул* «чуклы яулыкка охшаш борынгы хатын-кыз баш киеме» (удм. *сюлык*); диал. *чүнәри* «үрмәкүч» (удм. *чонари*; коми *черань*, **č'eran*); диал. *чыҗым* «үсемлек мыегы» (удм. *чыжы* «туган», «нәсел»; мар. *шочаш* «туу, барлыкка килү», *шож* «арпа»; **čiž* «туу», «арпа оны»); диал. *шабала* «аш чүмече» (удм. *шабала*; коми *шабала* «төрән»); *шаҗшы* «шапшак», «яла» (удм. *шакшы,* мар. *шакше*); диал. *шелеп* «йомычка» (удм. *шелеп*); диал. *чыжы* «угыз, уыз» (удм. *чöжы*, коми *чöж-: чöжйöв*); диал. *шура* «күркә» (удм. *шора*); *шылан* «наратбаш, чыршы үләне» (удм. *шилан*, мар. *шылан*); *шырбыз (йафрак)* «бака яфрагы – үлән» (удм. *шырбыж*); *ыштыр* «чолгау» (удм., мар. *ыштыр*); *ылыс* «ылыс» (удм. *лыс*, мар. *лусь*, коми *лыс*, **lüs*); диал.*эмиспикур* «матча» (удм. *эмеспи* «кияү егете», *кор* «бүрәнә») һ.б. (Насипов, 2012).

Югарыда күрсәтелгән лексик берәмлекләрдән тик 20 гә якыны гына татар теленең гомумкулланылыштагы сүзе, һәм алар татар теленең аңлатмалы һәм ике телле сүзлекләрендә теркәлгән: *алан*, *зый*, *көбәк*, *кукамай*, *лапас*, *миләш,*, *мурда*, *пилмән*, *поши*, *сәрдә*, *соса*, *төш*, *шакшы*, *шылан*, *ыштыр*, *ылыс*. Аларның кулланылыш ешлыгы төрлечә. Күбесе бүген татар әдәби теленең пассив лексик составына карый һәм норматив сүзлекләрдә искергән сүзләр буларак билгеләнә. Боларның, барысының да диярлек, җирле сөйләшләрдә (нигездә, урта диалектта) фонетик, сүз ясалышы яисә

семантик үзенчәлекләре буенча аерыла торган диалекталь эквивалентлары бар. Норматив сүзлекләрдә диалекталь буларак тик *дегәнкәй*, *курыс*, *ләпшү, пима* сүзләре генә билгеләнә. Күренүенчә, бу удмурт сүзләренең мари телендә, сирәгрәк – мордва һәм коми телләрендә лексик параллельләре очрый.

Татар телендә удмурт алынмаларының күбесе татар теленең нократ сөйләшендә кулланыла. Мәсәлән: *бугур*, *быры*, *геби*, *гомо*, *зебет*, *зәлкә*, *йуж*, *йумал*, *кал’ага*, *келем*, *кереч*, *ҡозаwыз*, *ҡотҡузы*, *ҡ'отор*, *ҡошо*, *ҡужҙылы*, *ҡуҡыл'*, *ҡуҡчалау*, *ҡургид*, *ҡусыл*, *ҡутыртлау*, *ҡучҡуҡ*, *ҡышон*, *лаwыр*, *л'акыт*, *лап*; *л'әп*, *лого*, *мажис*, *мис*, *мошко 1*, *мыры*, *нашмак*, *нергә*, *нор*,*нурды*, *өнчөрө*, *папа 1*, *папа 2*, *паршпил'*, *патре*, *пешник*, *пи*, *пигун*, *порни*, *пугриҗ*, *пуйы*, *пукен*, *пут*, *пуштурын*, *пучы*, *пучы бәйрәме*, *пыды*, *пыртос*, *пыры*, *пышни*, *сайҡыт*, *саламат*, *сәүрә*, *сирәк*, *сүбәт*, *сюпрэс*, *тибәт*, *тужҗ*, *чидун*, *чукул*, *чүнәри*, *шабалка*, *шелеп*, *шужы*, *шура*, *шырбыз* һ.б. Нократ сөйләшендә фин-угор сүзләре тагын да күбрәк кулланылуы ихтимал. Югарыда бирелгән лексик берәмлекләр рәтенә шикле яисә удмурт теленә мөнәсәбәте тулысынча билгеләнмәгән, этимологияләре өстәмә өйрәнүне таләп итүче сүзләр кертелмәде. Күренекле татар диалектологы Ф. Баязитова андый сүзләрнең күбесен удмуртизмнар арасында карый (Баязитова, 2006). Мәсәлән: *акыл'тылатып* «ару, хәлсезләнү»; *амма* «бертуган апа»; *амыкуй* «апага дәшү сүзе»; *анатлау* «ташлап калдыру»; *бичий* «туган тиешле»; *зиллекәй* «сыерчык»; *зыпут эти* «җыерылу, җыерчыклану»; *йокалай* «җыю»; *кукука* «курчак»; *кызу* «пар»; *кыйбуды* «асты өскә килү»; *л'аба* «күперчек, басма»; *мыну* «курчак»; *нанай печин* «эт шомырты»; *чырыш богол аш* «боламык, аш»; *пугриҗ* «балык»; *патачкалап* «болганчык»; *пыт'ырып* «олтырак»; *пошу'лаган* «текмә, ямаулы»; *мол'ок* «катканак»; *уналсын* «терелгән»; *пуш* «чыбык, таяк» (удм. *пуч*); *т'ут'у: каз т'ут'у* «ата каз»; *о'молот* «кибән бавы»; *маштылай* «тырмалау» (удм. *мажсаллян*); *ыдбурча* «йорт алды корылмалары»; *коркапрум* «өй туе»; *козулы* «парлы»; *чидун* «улак»; *ут'у* «көтүлек»; *өмез, умез* «төрән»; *бече* «туганлык, нәсел» һ.б. берәмлекләр.

Ф. Баязитова әйткәнчә, нократ сөйләшендә хәзерге татар телендә дә, хәзерге удмурт телендә дә кулланылмый торган бик борынгы сүзләр очрый. Мәсәлән: *шәйкә* «лакан, казан, савыт»; *тетеләр* «таратып ташлау»; *кадига* «гәрәнкә, бүкән шалканы»; *тә-*

*бис* «савыт»; *чәрки* «күн аяк киеме» һ.б. (Баязитова, 2006: 46, 54, 66, 147).

Шулай ук өстәмә этимологик тикшеренүләр сорый торган сүзләр дә бар, мәсәлән, *ақашқа* «язгы чәчү алды бәйрәме» (удм. *акашка, акаяшка* «беренче буразна (язгы чәчү алды бәйрәме)», «пасха», *акашка уй* «пасха төне») (Баязитова, 1991: 131); *зәлкә, кара зәлкә* «сыерчык» (удм. *зиллкей* «сыерчык») (Баязитова, 1991: 130); *дива* «кыр казы» (удм. бавл. *кирдʹуа* «кыр сарымсагы») (Тараканов, 1982: 165); *туйыз* «каен тузы» (удм. *туй* «каен тузы»; коми *туйыс* «туез») (Хайрутдинова, 2004: 168) һ.б.

Чепца буе татарлары (нократ сөйләше вәкилләре) яши торган төбәктә татар һәм удмурт географик терминнарыннан ясалган топонимик атамалар күп таралган. Мәсәлән, микротопонимнардан *ачкон'ук, кат'кыз, суганбыр* – ялан атамалары; *гундурлут чокор, гондыр аджон*, *лепетешур*, *сорот*, *кондор* – чокыр атамалары; *карйол урман*, *душко урман*, *йыбык урман* – урман исемнәре һ.б. (Баязитова, 2006: 26).

Татар теле урта диалектының башка сөйләшләрендә удмурт алынмалары аз очрый: казан арты сөйләшләре төркемендә – *бәпчек*, *җен*, *кечтун көн*, *пучы*, *чыжым*; тау ягы сөйләшләре төркемендә – *кесийә*, *ләнгәз*, *нәрәтә*. Кайбер удмурт алынмалары татар теленең маргиналь, нигездә, Урал буенда таралган сөйләшләрендә кулланыла: *бәпчек, бүкән, җен, кәлигә, қумта, лабра, мал', мәшкә, меле, мөҗө, туйыз.*

Шунысы игътибарга лаек, өйрәнелгән материаллар арасында мишәр диалекты сөйләшләрендә таралган сүзләр очрамый. *Ләнгәз* сүзе, күрәсең, мишәр диалекты сөйләшләренә урта диалект сөйләшләреннән мари теле аша үтеп кергән. *Нәрәтә* һәм *мәшкә, мәшкәкләү* сүзләре стәрлетамак сөйләшенә урта диалектның минзәлә сөйләше аша керүе ихтимал.

Көнбатыш диалектның кайбер сөйләшләрендә *мәләш, мыши/моши, сәрдә, пима* сүзләренең кулланылышы, бәлки, шул ук сәбәпләр белән аңлатылырга мөмкин: *мәләш* «миләш»; *мыши*, *моши* «болан»; *сәрдә* «сәрдә»; *пима* «киез итек», «киез башмак», *чобар пима* «чуар киез итек».

Шулай итеп, татар теле тарафыннан үзләштерелгән фин-угор сүзләренең саны, мари, мордва һәм удмурт телләрендәге төрки-татар алынма лексемаларына караганда, чагыштырмача бик аз.

Әмма бу сүзләр татарларның фин-угор халыклары белән борынгыдан һәм озак гасырларга сузылган даими тыгыз мәдәни-икътисади мөнәсәбәтләре булуын дәлилләп тора. Бу сүзләрнең татар теленә алынуы турыдан-туры аралашу процессы нәтиҗәсе, һәм алар, нигездә, сөйләм теле аша җирле сөйләшләргә үтеп кергәннәр.

Татар теленең сүзлек составындагы фин-угор алынмаларының күбесе башкорт һәм чуваш телләрендә дә кулланыла. Шуңа күрә аларның кайберсе татар телендә икенчел алынмалар булуы да бик ихтимал, бу бигрәк тә чуваш телендәге лексик параллельләргә кагыла.

Татар телендәге фин-угор алынмаларының бүгенге көнгә билгеләнгән саны чагыштырмача аз булу, гомумән алганда, бу алынма берәмлекләрне төркемләү һәм анализлауны да, фин-угорларның татарларга лингвистик йогынтысы дәрәҗәсен билгеләүне дә катлауландыра. Шуңа күрә Идел–Кама төбәгендә фин-угор этносының төрки дөньяга йогынтысы мәсьәләсен лингвистик материал нигезендә генә билгеләү мөмкин түгел, моның өчен башка бик күп фән өлкәләре тикшеренү нәтиҗәләрен дә исәпкә алып эш итәргә кирәк. Шулай да, билгеләнгән фин-угор алынмаларын өйрәнү бу лексик берәмлекләрнең үсешен күзәтү өчен бик кирәкле. Алар татар халкының формалашуында булган бик әһәмиятле иҗтимагый-тарихи процессларның күрсәткече булып тора.

Көнчыгыш диалектта алынма сүзләрнең үзләштерелүендә, татар теленең башка (урта һәм көнбатыш) диалектлары белән чагыштырганда, зур аермалы үзенчәлекләр бар. Бу үзенчәлекләр фин-угор алынмаларына да кагыла. Көнчыгыш диалекттагы фин-угор алынмалары татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларындагы фин-угор алынмаларыннан үтеп керү шартлары, үзләштерелеше, тел үзенчәлекләре, саны һәм сыйфаты ягыннан гына түгел, ә бәйләнештә торган тел чыганаклары белән дә аерыла. Әгәр татар теленең урта һәм көнбатыш диалектлары сөйләшләре мари, мордва (мокша һәм эрзя) һәм удмурт телләре, борынгырак чорда – күпмедер коми теле сөйләшләре белән бәйләнештә булсалар, көнчыгыш диалект сөйләшләре инде себер фин-угор телләре һәм коми теле белән тыгыз мөнәсәбәттә торганнар.

Көнчыгыш диалектта фин-угор алынмалары, шулай ук Себер татарларының фин-угорлар белән этногенетик бәйләнешләре мәсьәләләре бүгенге көнгә чаклы махсус тикшеренү объекты

булмаган. Шуңа күрә монда аерым мисалларга гына игътибар юнәлтү максатка ярашлы булыр. Мәсәлән, бу яктан түбәндәге лексик берәмлекләрне күрсәтергә мөмкин: *маса* «киндер»; *кәләгә* «гәрәнкә, бүкән шалканы»; *миләч* «миләш»; *мочор*, *мыцыр* «миләш», *мышыр* «шадра»; *мәнтәш* «тиз чери торган» (коми *мандач*, *мендач* «саз нараты») (Аникин, 2003: 360); *терге* «яшь нарат»; *кәреш* «чөгә – балык» (рус теле аша *хариус*) (Фасмер IV, 1986: 224); *ләрге* «балык» (хант. *ларег* «шартлака – балык») (Бятикова, 2005: 76); *муқсыл* «муксун» (коми-зырян. *муксун*, ханты, манси *моксун*) (Бятикова, 2005: 73); *пыжьян*»сөләйман балыгы» (ханты *пыжьян*) (Фасмер III, 1986: 418; Бятикова, 2005: 73); *миши* «болан»; *пистер* «кәрзин» (Фасмер III, 1986: 250; Аникин, 2003: 445); *ләте* «утырма, юшкын» (морд.э. *мода* «җир, туфрак», финн. *muta* «ләм, лай») (Әхмәтьянов, 2001: 143); *нәште* «ләм» (хант., эвен., манс. *няша*) (Фасмер III, 1986: 408) һ.б.

Аңлашыла ки, көнчыгыш диалекттагы фин-угор алынмалары әлеге мисаллар белән генә чикләнми. Урта һәм көнбатыш диалектлары сөйләшләрендә фин-угор алынмаларының саны шулай ук бик үк зур булмавын исәпкә алсак, бу үзенчәлекне көнчыгыш диалект сөйләшләре өчен дә характерлы дип карап була. Бер үк вакытта шуңа да игътибар итәргә кирәк: югарыда каралган алынма лексик берәмлекләрнең күбесе татар теленең өч диалекты өчен дә характерлы. Аларның кайберләрен, көнчыгыш диалектка урта һәм көнбатыш диалекты вәкилләре аша үтеп кергән, дип фаразларга да мөмкин. Ничек кенә булмасын, көнчыгыш диалектның сүзлек составында фин-угор алынмалары махсус өйрәнүне сорый.

Шулай итеп, татар телендә фин-угор алынмаларының саны зур түгел. Шуңа күрә татар телендә алынма сүзләрнең лексик составын өйрәнгәндә, башка телләрдән кергән алынмалардан аермалы буларак, фин-угор алынмаларын тикшергәндә, әдәби телдәге сүзләр белән беррәттән, җирле сөйләшләр материалына да таянып эш итәргә туры килә. Чөнки алар кулланылыш даирәсе һәм таралышы буенча аерыла: бик аз гына сүзләр әдәби телгә дә үтеп кергән, кайбер сүзләр берничә сөйләштә кулланыла, икенчеләре – сөйләшләрдә вариатив төрлеккә ия һәм билгеле төбәктә генә таралган. Теге яки бу сүзнең конкрет үзенчәлеге, беренче чиратта, татарларның аерым төркемнәренең билгеле бер фин-угор халыклары белән этнолингвистик аралашу үзенчәлекләренә бәйле.

## Татар телендә гарәп һәм фарсы алынмалары

Татар теленең лексик фонды формалашуда гарәп-фарсы алынмалары төрле чорда төрлечә роль уйнаганнар.

Гарәп-фарсы алынмаларының татар теле лексик фондының формалашуы һәм үсешендәге ролен ачыклау максатыннан, «Борынгы төрки сүзлек» («Древнетюркский словарь», 1969) материаллары нигез итеп алынды. Бу, әлбәттә, бик шартлы рәвештә генә алына, чөнки әлеге сүзлекнең төзүчеләре аңлатканча, ул VII–XIII гасырлар аралыгында язылган язма чыганаклардагы лексиканы эченә ала. Сүзлектә алынма сүзләр, төгәлрәк әйткәндә, гарәп-фарсы һәм санскрит телләреннән кергән сүзләр шактый зур урынны алып тора. Димәк, төрки телләргә гарәп-фарсы сүзләре инде бик күптәннән кергәннәр һәм бу процессның башлангыч чоры чикләрен билгеләү шактый катлаулы.

### § 8. Гарәп һәм фарсы алынмаларының татар теленә үтеп керү тарихы

Татар теленең лексик фондында гарәп-фарсы алынмаларының кайчан урын алуы турында фикер йөрткәндә, югарыда күрсәтелгәнчә, шартлы рәвештә борынгы төрки лексикага, ягъни VII–XIII гасыр язма истәлекләргә таянып төзелгән «Борынгы төрки сүзлек»кә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Кызганычка каршы, әлеге язма истәлекләрнең лексикасын генетик аспектта махсус өйрәнү тиешле дәрәҗәдә башкарылган дип әйтеп булмый.

Татар тел белемендә гарәп-фарсы алынмаларын төрле яссылыкта өйрәнүгә Ш. Рамазанов (1954: 58–77); М. Мәхмүтов (1966; 1993: 793–853), Ф. Хисамова (1981, 1990, 2012), Ф. Сафиуллина (1999: 58–66), Р. Абдуллина (1997; 2013), Л. Таҗиева (2000), Р. Мөхиярова (2000), И. Сиражиев (2002), Х. Кузьмина (2003), Э. Динмөхәммәтова (2004), Р. Нурмөхәммәтова (2007: 70–123), Ә. Йосыпова (2008) һ.б. галимнәр үзләренең хезмәтләрен багышлаганнар. Татар теленең лексик фондында гарәп-фарсы алынмаларының кайчан урын алуын, төрки телләргә әлеге алынмаларның кайчан үтеп керүен, бу процессның башлангыч чорының чикләрен билгеләү мәсьәләсе һаман да актуальлеген югалтмый.

Галимнәрнең, төрки-гарәп багланышлары болгарлар мөселман динен рәсми рәвештә кабул иткәнче үк башланган, дигән фикере

чынбарлыкка туры килә. Төркиләр белән гарәп илләре арасында икътисади-мәдәни багланышлар шактый элек урнашкан булырга мөмкин һәм мондый процесста тел-лөгать алмашу табигый хәл.

Әйтеп үтелгәнчә, «Борынгы төрки сүзлек»тә гарәп-фарсы алынмалары шактый зур күләмне алып торалар. Мәсәлән, сүзлекнең беренче 100 битендә 116 алынма теркәлгән: шулардан 78 е гарәп, 38 е фарсы дип тамгаланган. Алар түбәндәге ядкәрләрдән алынган: М. Кашгари сүзлеге (1072–1074 еллар); Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» әсәре (ул 1069–1070 елларга карый дип санала, сүзлектә аның XII–XIII йөзләргә караган күчермәләре файдаланылган); Угыз каган турындагы риваять (XIII йөз); Әхмәт Югнәкинең «Һибәтел-хакаикъ» әсәре (XIII йөзнең беренче яртысына карый); XII–XIV гасырларга караган медицина, юриспруденция һ.б. эчтәлектәге документлар һ.б.

Мәгълүм булганча, гарәп-фарсы алынмалары чагылыш тапкан ядкәрләр X йөздән соң иҗат ителгән булганнар, ә сүзлектәге материаллар шул ядкәрләрнең XII–XIV йөз күчермәләреннән алынган (Древнетюркский словарь, 1969: 27–28). Сүзлектән күренгәнчә, Күлтәгин (732 ел), Кол Чура (721 ел), Билге Каган (735 ел), Енисей ядкәрләре (язылу вакытлары күрсәтелмәгән), Онгин ядкәре (731 ел), Тоньюкук ядкәре (чама белән 712, 726 еллар), Турфан оазисы (Күк төркиләр) ядкәре (906 елга кадәр язылган) һ.б. ядкәрләрдә гарәп-фарсы алынмалары теркәлмәгән (Древнетюркский словарь, 1969: 21–28).

Әлеге сүзлектә урын алган чыганакларга «Төрки-гарәп» (1245 ел) сүзлеген дә өстәргә мөмкин. Мисыр һәм Сүриядәге мәмлүкләр дәүләтендә төзелгән бу кыпчак сүзлеге, А. Курышжанов тарафыннан тикшерелгән (Курышжанов, 1970: 70–224). Хезмәтнең сүзлек өлешендә барлыгы 155 биттә 86 гарәп-фарсы (27 гарәп һәм 59 фарсы) сүзе теркәлгән. Ә 1303 ел ядкәре «Codex Cumanicus»ның 75 битендә 114 гарәп, 101 фарсы сүзләре теркәлгән, димәк Болгар чорында гарәп-фарсы алынмалары нык арткан дип исәпләргә нигез бар (Махмутова, 1982: 79–153).

Шулай итеп, «Борынгы төрки сүзлек» гарәп-фарсы сүзләренең төрки телләргә кайчан керә башлавы турындагы сорауга төгәл җавап бирә алмаса да, бу күренешләр I меңьеллыкның соңгы чирегендә барлыкка килгән булырга тиеш, дип фаразлый алабыз. Ә Идел буенда мөселман динен рәсми рәвештә кабул итү

гарәп-фарсы алынмаларының татар халкының бабалары теленә үтеп керүен активлаштырган.

Болгар дәүләтендә ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәнче үк, Идел ареалына, Төньяк Кавказ тирәләрендәге төркиләргә, болгарлар, хазарлар һ.б. чорында ук ислам дине йогынтысы керә башлаган булырга тиеш, дигән фикерләр бар. Әлбәттә, бу эштә сәүдә итү, ислам дине атрибутлары булдыру (мәчет салу, мәдрәсәләр ачу, гарәп телен һәм язуын өйрәнү кебек шөгыльләр) зур урын тоткан. Мәдәни бәйләнешләрнең һаман саен көчәя баруы һәм ислам диненең рәсми рәвештә активлашуы да үзара мөнәсәбәтләрнең тирәнәюенә китерә. Болгар дәүләте шәһәрләрендә әдипләр яшәгәннәр, галимнәр, шагыйрьләр иҗат иткән. Әдәбият, тел һәм лөгать алмашу да телгә бик күп булып гарәп-фарсы сүзләре үтеп керүгә китергән.

Иҗтимагый-тарихи шартлар, бигрәк тә дин берлеге, ислам динен тарату максаты белән һәр авылда мәчетләр салыну, күп кенә авылларда мәдрәсәләр ачылу, гарәп телен һәм язуын өйрәтү даими тәртип булып урнаша. Шушы тәртип берничә гасырлар буе яшәп килә, татар тарихы барышында аерылгысыз юлдаш булып дәвам итә. Алтын Урда, аның дәвамчысы Казан ханлыгы чорларында бабаларыбызның теленә гарәп-фарсы сүзләренең үтеп керүе интенсив рәвештә дәвам итә. Гарәп һәм фарсы телләрен уку-өйрәнү нәтиҗәсендә иске татар әдәбиятының йөзек кашы саналган «Кыйссаи Йосыф», «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләре, Мөхәммәдъярның мәшһүр поэмалары һәм аннан соңгы чорда иҗат иткән У. Имәни, Г. Кандалый хезмәтләре, гомумән XX гасыр башына кадәр иҗат ителгән ядкәрләребез телендә дә үз чагылышын таба. Гарәп-фарсы сүзләре һәм сүзтезмәләре телебездә даими рәвештә кулланышта булалар, татар теле тукымасында эшкәртелеп, телебезнең фонетикасына яраклашалар, сүз ясауда катнаша башлыйлар. Шулай итеп, гарәп һәм фарсы сүзләре татар теленең төп лексик фондында урын алалар. Аларның күбесе кулланылышта чит тел сүзе итеп түгел, бәлки үз сүзебез кебек кабул ителә.

Биредә 1303 елда төзелгән «Коман мәҗмугасы»ндагы («Codex Cumanicus») гарәп-фарсы алынмаларына да күз салып үтү урынлы булыр. Л. Мәхмүтова тарафыннан эшкәртелгән бу сүзлекнең 75 битендә 114 гарәп, 101 фарсы (тагын рус – 8, грек – 3, монгол – 1) сүзләре теркәлгән. Күргәнебезчә, «Борынгы төрки сүзлек» белән

чагыштырганда, «Codex Cumanicus»та гарәп-фарсы алынмалары бермә-бер күбрәк дияргә мөмкин. Бу шулай ук төрки телләргә гарәп-фарсы сүзләре үтеп керү Болгар чорында нык артканлыгы турында сөйли. Моңа аеруча көнчыгыш әдәбиятының көчле йогынтысы булышлык итә, XIII гасырның беренче яртысында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» әсәре, мәсәлән, татар халкының өстәл китабына әверелә. Ул әсәрнең теле, бер яктан, татар теленең лексик-стилистик үзенчәлекләрен, сурәтләү чараларын, кыскасы, татар теленең шул чорга хас бөтен байлыгын үзендә чагылдырса, икенче яктан, әсәрнең тукымасына гарәп-фарсы алынмалары да киң үтеп керә.

Галимнәр бу әсәрнең телендә шул чордагы халык сөйләмендә булган мәкальләр, әйтемнәр, үткен гыйбарәләр, күп төрле бай сурәтләү чаралары чагылыш тапканлыгын ассызыклыйлар, шуңа күрә дә, татар әдәбияты нәкъ шушы чорда туган дигән фикергә киләләр (Хаков, 2003: 19). В. Хаков, әлеге мәсьәләләр белән күп еллар җентекле рәвештә шөгыльләнгән белгеч буларак, болай дип дәвам итә: «Незначительное место в нем занимают арабско-персидские заимствования» (шунда ук).

«Кыйссаи Йосыф»та төрки лексиканың күпчелекне алып торганы билгеле. Мәсәлән, Х. Кузьминаның исәпләүләренә караганда, әсәрдә төрки лексика 60% ны тәшкил итә. Икенчедән, гарәп-фарсы алынмалары «Кыйссаи Йосыф» әсәренең төрле өлешләрендә төрле күләмдә күзәтелә: кереш өлешендә алар 54% ны тәшкил итә, ә 7 нче бүлектә алар бары 25% кына. Гомумән, әсәрдә гарәп-фарсы алынмалары уртача 40% ны алып торалар (Кузьмина, 2003: 126).

Татар, шулай ук башка төрки телләр өчен ят булган авазларга башлана торган сүзләрнең дә иске татар әдәби телендә шактый зур өлешне алып торуларын истә тотарга кирәк. Мәсәлән, «Нәһҗел фәрадис» әсәрендәге [м] авазына башлана торган 277 сүздән 14 е генә төрки сүзләрне тәшкил итә, ә калганнары гарәп-фарсы алынмалары: *мәчет, мәхәббәт, мәхкам* (көчле) һ.б.

Алга таба XIV–XVII гасырларда иҗат ителгән иске татар әдәбияты әсәрләре телендә дә гарәп-фарсы алынмалары күп кулланылган, әмма аларның да махсус тикшерелгәне юк әле.

Ә. Нәҗип гарәп-фарсы алынмаларының татар әдәбияты әсәрләренә һаман да керә килүен һәм, мәсәлән, «Төхфәи мәрдан» (1539–1540) әсәре гади татар теле элементларына никадәр бай

булмасын, анда гарәп-фарсы сүзләренең шактый зур урын алуын күрсәтә (Наджип, 2003: 361).

Татар теленең функциональ стильләре арта һәм үсә баруы да гарәп-фарсы алынмаларының татар телендә, бигрәк тә аның әдәби төрендә, күбәя баруына китерә. Мәсәлән, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, көчләп чукындыруга каршылык йөзеннән дин көчәя һәм бу процесста дини лексиканың да күләм ягыннан киңәя, семантик яктан тирәнәя баруы да бәхәссез.

XV гасырларда ук татар әдәби теленең функцияләре киңәя, арта бара. Татар әдәби теле стилистик яктан өлгергән юнәлеш булып формалаша. Ул сурәтләү чараларына, чагыштыруларга, метафораларга, эпитет һәм башка сурәтләү чараларына бай булган, образлы теле формалашып җиткән сәнгать әсәрләре иҗат итеп була торган, яңгырашлы рифма һәм ритмга ия булган аһәңле телгә әверелә бара. Әлбәттә, монда гарәп-фарсы алынмаларының да роле зур. Татар әдәбияты көнчыгыш илләре классик әдәбиятына ияреп үсә һәм байый, аларга хас образлылык алымнарын үзләштерә, аларны иҗади баетып, халык теле бизәкләре белән нәфисләндереп тагын да үстерә бара.

И. Сираҗиев, XVII–XIX йөзләрдә Урта Азиядән һәм Төркиядән килгән суфичылык шигърияте һәм матур әдәбият үтеп керү татар сүзлек составында гарәп-фарсы сүзләренең күпләп урын алуына булышлык иткән, дип яза (Сиразиев, 2002: 18).

XIV–XV йөзләрдән үк татар теленең функцияләре арта һәм киңәя бара. Казан ханлыгының башка ханлыклар, Рус дәүләте белән алып барган хат алышуларда татар теле дипломатия, хатлар һәм башка төрле рәсми язма документлар теле, дәүләтләр арасында язышулар теле булып формалаша. Көнчыгыш илләре белән мөнәсәбәтләр урнаштыруда, сәүдә һәм алыш-бирешне киңәйтү һәм үстерүдә дә татар теленең роле гаять зур була. Бу турыдагы документлар шактый күләмдә архивларда сакланып калганнар, аларның бер өлеше рус һәм татар галимнәре тарафыннан өйрәнелгән.

Гарәп-фарсы алынмаларының татар теленең лексик фонды формалашудагы ролен ачыклау өчен, нигездә ике тармакның теленә күзәтү ясау кирәк, чөнки безгә килеп җиткән чыганаклар төп шушы ике стильдә язылган: 1) матур әдәбият (иске татар әдәбияты ядкәрләре), 2) илләр, дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылышлы, дипломатик һ.б. язма документлар.

Димәк, язма әдәби тел стиленең үсеш-үзгәреше турында әйтеп узган катлаулы һәм прогрессив үсешнең икенче төре – ил эчендә һәм дәүләтара эш кәгазьләре стиленең үсеше. Бу стильнең үсеш тенденцияләренә аерым тукталу урынлы булыр. Мәсәлән, бу хакта Ф. Хисамованың «XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре» (1981), «Формирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв.» (1990) һәм М. Госманов (1972) хезмәтләреннән билгеле.

XVI–XVII йөзләрдә кулланылган региональ әдәби тел үзенең структур үзенчәлекләре белән Казан ханлыгы һәм Алтын Урда чорларындагы язма әдәби телгә барып тоташа, гомумхалык татар теленә бик якын (Хисамова, 1990: 126). Аның Болгар дәүләте чорында ук әлеге регионда үзенә хас мәдәни һәм язма-әдәби традицияләре формалашкан булган. XVII гасырга караган язма эш кәгазьләре (грамоталар, дипломатик хатлар, шәхси-юридик һ.б. төрле документлар) телендә гарәп-фарсы алынмалары шактый актив кулланылганнар, алар состав-күләмнәре ягыннан, нигездә, хәзерге телдәгечә. Кайберләре исә (*вәли, гакыйл, дәбир, аҗдадлар, пәнаһ, әгъзәм* һ.б.) хәзерге чорга килеп җитмәгәннәр (Хисамова, 1990: 154).

Ә инде XIX йөз эш кәгазьләрендә, иске татар язма әдәби тел белән чагыштырганда, гарәп-фарсы алынмалары чагыштырмача сирәгрәк кулланылганнар. Аларның төп өлеше хәзерге татар телендә дә сакланып килә: *сәбәп, хәбәр, гомер, вакыт, дус(т), дошман, сәүдә, әлбәттә* һ.б. Кайбер гарәп-фарсы алынмалары семантик үзгәреш кичегәннәр. Мәсәлән: *хәзинә* – подарок, дань, грамота, указ, письмо (хәзерге татар телендә: *хат*); *дәфтәр* – список, торговая книга (хәзер: *дәфтәр*) һ.б.

Ф. Хисамова рәсми эш кәгазьләренең структур яктан төзелешен өйрәнеп, аерым өлешләренең, нигездә, гарәп-фарсы алынмаларыннан торуын, аларның даими эпитетлар буларак кулланылуын билгели: *мөнәүвәр, газим, әгъзам, иқлим шаһ шаһы* һ.б. (Хисамова, 1981: 14–15).

Шулай итеп, XVIII гасырга караган язмаларда, крестьяннар сугышына кагылышлы булган һ.б. язма документлар һәм борынгырак чордагы татарча рәсми эш кәгазьләре арасында традицияләр уртаклыгы, күчемлелек чагылыш таба һәм гарәп-фарсы алынмаларының рәсми эш кәгазьләре стилендә дә актив кулланылуына китерә.

XVIII гасырда Иран, Азәрбәйҗан илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр активлаша һәм шуңа бәйле рәвештә төзелгән эш кәгазьләрендә иран сүзләре күбәя. Петр I нең «Манифест»ы да, нигездә, шуңа якын телдә язылган дип санала (История татарского..., 2003:457–460). Бу ядкәрдә процентлап санаганда гарәп, бигрәк тә фарсы сүзләре, төрки-татар сүзләренең күләме белән чагыштырганда, күбрәк (Хисамова, 2003: 461).

М. Мәхмүтов, XVII–XIX гасыр классиклары үзләренең әсәрләрен гарәп-фарсы һәм Урта Азия классик әдәбияты тәэсирендә, аларга ияреп иҗат иткәннәр, шуңа күрә әлеге чор әсәрләрендә бигрәк тә тар даирә мәгърифәтчеләренә аңлаешлы булган гарәп-фарсы алынмалары аеруча күп кулланылган, дип яза (Мәхмүтов, 1965: 795–796).

XIX гасырда гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышы турында шул чорда чыккан татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр буенча да фикер йөртергә мөмкин. Билгеле, сүзлекләр махсус белемгә ия затлар, укытучылар тарафыннан төзелгәннәр һәм алар, чыганак буларак, нигездә, югары стиль белән гади сөйләм стиле арасында эшләнгәннәр.

Шулай да, бу икетелле сүзлекләрдә гарәп-фарсы алынмалары төрле мәнфәгатьләрдән чыгып бирелгәннәр. Әлеге сүзлекләр һәм аларда алынма сүзләрнең бирелеше мәсьәләре Ә. Йосыпова тарафыннан җентекле һәм тирән итеп тикшерелгән (Юсупова, 2002). Түбәндә, әлеге хезмәткә нигезләнгән, кайбер мисаллар анализлана.

А. Троянский үзенең «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских» дигән 2 томлык хезмәтендә «в словарь включены только некоторые арабские и персидские слова» дип күрсәтә. Шуңа карамастан, әлеге сүзлектә гарәп-фарсы алынмалары шактый зур урын алып тора. Сүзлектә 374 гарәп һәм 162 фарсы (I китап, 1833 ел), 283 гарәп һәм 23 фарсы (II китап, 1835) сүзләре теркәлгән. Ә. Йосыпова хаклы рәвештә, А. Троянский татар телендә сирәк очрый торган сүзләрне генә китергән, ә татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары болар белән генә чикләнми, дип ассызыклап күрсәтә (Юсупова, 2008: 34).

С. Күкләшевның «Словарь къ татарской хрестоматии» (Казань: Тип-я имп. ун-та, 1859) дигән хезмәте, галимнәр билгеләвенчә, шул чорга хас татар әдәби теле сүзлегенең үрнәге булып тора. Гарәп-фарсы алынмаларының составы ягыннан да сүзлек хәзерге

татар әдәби теленнән әллә ни аерылмый: *җәрәхәт, бәһә, әхтәр* (йолдыз), *хайван*, *ханә* (йорт), х*ыял, хата, хәлифәт, хуш, рух* һ.б.

К. Насыйриның «Татарча-русча лөгать китабы» 1878 елда басылып чыккан, анда 2923 сүз теркәлгән, гарәп-фарсы сүзләре шактый бай төркемне тәшкил итә. Галимнең «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» дигән сүзлегендә 18410 сүз чагылыш тапкан. Бу төркемдә гарәп-фарсы алынмалары күбесенчә үзенчәлекле терминнар буларак теркәлгәннәр (Юсупова, 2008: 99).

Гарәп-фарсы алынмалары И. Гиганов сүзлекләрендә дә (1901) шактый зур урын ала. И. Гиганов (1804 ел; 12000 сүз теркәлгән) сүзлегендә дә алынма сүзләр бик күп, аларның зур күпчелеге гарәп-фарсы алынмаларын тәшкил итәләр, аларның байтагы татар телендә ныклап урнашканнар, татар теленең үз сүзләре кебек кабул ителәләр.

XIX гасырның икенче яртысында XX гасыр башында татар телендә гарәп-фарсы алынмалары бик күп була, алар әдәби телдә генә түгел, халыкның җанлы сөйләм телендә дә актив кулланылалар.

XX гасыр башында җәмгыятьтә барган иҗтимагый-мәдәни процесслар татар телендә гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышына да үзгәрешләр кертә. Бу чорда татар әдәби телен баету, аны чистарту, халык теленә якынайту хәрәкәте бер төркем тар кулланышлы гарәп-фарсы алынмаларының пассивлашуына китерә. Мәсәлән, галимнәрнең тикшеренүләренә караганда, 1913 елгы татарча-русча сүзлектә урын алган гарәп-фарсы алынмаларының (алар 1000 гә якын) 400 гә якыны 30 нчы еллар лексикасында күзәтелми башлаган (Нурмөхәммәтова, 2007: 74).

XX гасырның 20 нче елларында җәмгыятьтә барган сәяси, икътисади һәм мәдәни вакыйгалар, аеруча Октябрь инкыйлабыннан соң булган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, бер төркем гарәп һәм фарсы алынмалары кулланылыштан төшеп кала. Телебезнең сүзлек составында дин һәм дини йолаларны, иске тормышны белдерә торган сүзләр пассивлаша. Кайбер гарәп-фарсы алынмалары рус һәм Европа телләреннән кергән алынмалар белән алыштырыла. Татар әдәби телендә яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләрне белдерә торган яңа сүзләр ясала һәм актив кулланышка кертелә. Әдәби тел халыкка аңлашылмаган чит формалардан әкренләп арындырыла, халык теленә нигезләнеп, нормалаштырыла. Шуның белән бергә, татар

теле закончалыкларына яраклашып беткән, күп еллар буе кулланылып килгән һәм татар теленең төп сүзлек фондында урын алган, актив лексикага әверелгән гарәп-фарсы алынмалары телебезнең сүзлек составында яшәешләрен дәвам итәләр һәм алар инде тәмам үзләшеп җитеп, үз сүзләребез кебек кабул ителәләр.

Шулай итеп, татар теленең төп сүзлек фондында билгеле бер өлешне гарәп-фарсы алынмалары алып тора һәм алар XX гасырның икенче яртысында да шул статусларын саклыйлар.

XX гасырда, аеруча аның икенче яртысында, гарәп-фарсы алынмаларын куллануны нормалаштыру, аларны фәнни өйрәнү буенча зур эш башкарыла: бер яктан, күпсанлы сүзлекләр басылып чыга, алар татар теленә ят калыпларда булган алынмаларны барлау гына түгел, аларны фәнни эшкәртүнең нәтиҗәле алымы да булып торалар; икенче яктан, гарәп-фарсы алынмаларын үзләштерүнең нормага салынган принципларын фәнни нигездә аңлату буенча да күпсанлы хезмәтләр дөнья күрә. Бу мәсьәләләр аеруча Ф. Сафиуллина (1999: 58–86), Р. Мөхиярова (2000), Р. Нурмөхәммәтова (2007: 30–103), Р. Абдуллина (2013) хезмәтләрендә тирән эшләнгән.

Р. Нурмөхәммәтова статистик характердагы анализга зур урын биреп, 1913 елгы татарча-русча сүзлектә 1200, 1927 һәм 1931 елгы шундый ук сүзлекләрдә – 1300, 1950 елгы татарча-русча сүзлектә чама белән 1000 тамыр рәвешендәге гарәп-фарсы алынмалары теркәлгәнлеген билгели (Нурмөхәммәтова, 2007:74).

Шулай итеп, XX гасырда гарәп-фарсы алынмалары татар лексик фонды эчендә стабильләшкән, киң семантик һәм структур системаны тәшкил итә торган төркемгә әвереләләр.

XX гасырның 80–90 нчы елларында илебездә барган иҗтимагый-икътисади үзгәртеп корулар җәмгыятебезнең бөтен тармакларына да теге яки бу дәрәҗәдә кагылды, телебез өлкәсендә дә аннан файдалану даирәсен киңәйтү процессы башланды.

Тарих барышында урнашкан, фонетик-грамматик яктан үзләштерелгән, семантик яктан хәтта үзенең мәгънә кыры формалашкан гарәп-фарсы сүзләрен дә рус алынмаларына алыштыру процессы XX гасырның урталарында шактый активлашкан, татар теленең үз сүзләре була торып та, алар урынына рус алынмалары куллану көчәйгән иде. Әмма җәмгыятьтә барган үзгәрешләр телгә дә үтеп керде, аны яңарту-торгызу процессы башланды, яңа сүзләрне татар теленең үзенең эчке ресурсларын файдаланып ясау

хәрәкәте көчәйде. Татар теленең үз сүзләрен кире кайтарып, аны алынмалардан арындыру көн тәртибенә баса. Менә шундый ситуациядә кайчандыр кулланыштан төшерелгән гарәп-фарсы алынмаларын активлаштыру, татар теленең үз сүзләре рәтендә аларны да кире кайтару, ягъни татар лексик фондында гарәп-фарсы алынмаларының икенчерәк юнәлештәге, халыкның милли үзаңы уянуга бәйле яшәеше башлана.

Шул ук вакытта халыкара һәм рус алынмалары урынына гарәп-фарсы сүзләрен куллану белән мавыгу көчәйде (Мәхмүтов, 1993:799; Мөхиярова, 2000:64). Р. Мөхиярова күрсәткәнчә, гарәп-фарсы алынмалары белән мавыгу 80–90 нчы еллар татар әдәби теленең язма формасының барлык функциональ стильләре өчен дә хас, мәсәлән: *вакыф* – фонд, *вәсика* – документ, *гаделия* – юстиция, *иҗазатнамә* – диплом, аттестат, *зарб* – удар, *кафия* – рифма, *моназарә* – дискуссия, *мөддәт* – суд, *мөһәндис* – инженер, *нәмает* – демонстрация, парад, *сәрмая* – капитал, инвестиция, *тәшкиләт* – структура, *тәхлил* – анализ, *фәтташ* – ревизор, инструктор һ.б. (Мөхиярова, 2000: 64).

80–90 нчы еллар өчен характерлы тагын да бер моменты билгеләп үтәргә кирәк: үзгәртеп кору чоры башлангач, кыскартылган формадагы рус-европа чыгышлы сыйфатларны да гарәп-фарсы алынмалары белән алыштыру активлаша: *васикави* – документаль, *җисмани* – физик, *гаммави* – массовый, *җәмгыяви* – социаль, *инкыйлаби* – революцион, *тәрәккый* – прогрессив; *гамәли* – практик, *икътисади* – экономик, *мантыйкый* – логик, *нәзари* – теоретик, *сәнәгати* – индустриаль, *сәяси* – политик, *һөнәри* – профессиональ, *шәхсән* – индивидуаль һ.б.

Җәмгыятьтә барган демократлашу процессында диннең җанлануы, дини китаплар басылу һ.б.ш. факторлар дини атамаларның, төшенчәләрнең активлашуына китерде. Шушы ук сәбәпләр белән бәйле рәвештә архаизм һәм тарихи дип билгеләнгән гарәп-фарсы алынмалары актив лексика рәтенә бастылар: *ураза, иман, шәкерт, имам-хатип, мәдрәсә* һ.б.

Гарәп-фарсы алынмаларының активлашуына халыкның үзенең үткәненә, югала язган гореф-гадәтләре белән зур кызыксыну уяну, мөселман илләре белән сәяси, мәдәни, икътисади бәйләнешләрнең җанлануы кебек факторлар да булышлык итте. Икенче яктан, гарәп-фарсы сүзләрен куллануларгы җанланыш халкыбызга, аеруча

яшь буынга тарихи әсәрләребезне, XIX йөздә – XX йөз башларында иҗат ителгән әсәрләрне, хезмәтләрне укырга мөмкинлек бирде.

Шулай итеп, 80–90 нчы елларда гарәп-фарсы алынмаларының кире кайтуы, яңа атамалар ясау кирәклеге, халыкның үзенең тарихи үткәне белән кызыксынуы көчәю, гасырлар буе иҗат ителеп килгән мәдәни мирасыбызның киң катлам укучыларга кайтарылуы, ислам диненең яңарышы гарәп-фарсы алынмаларының әдәби тел лексикасында активлашуы өчен уңай шартлар тудырды (Мөхиярова, 2000: 67).

80–90 нчы елларда гарәп фарсы алынмаларының состав ягыннан үзенчәлекле, ягъни XX йөз башыннан пассив сүзләр рәтенә күчкән, әдәби телдә бөтенләй диярлек кулланылмаган һәм шуңа күрә аңлатмалы сүзлектә дә чагылыш тапмаган күп кенә сүзләре яңадан кулланылышка кертелүен ассызыклау кирәк. Икенчедән, аңлатмалы сүзлектә искергән, тарихи, борынгы дип тамгаланган сүзләр 80–90 нчы елларда активлашып китәләр.

Шулай итеп, тормышның барлык өлкәләрендә дә барган үзгәртеп кору хәрәкәте гарәп-фарсы сүзләрен куллануны җанландырып җибәрделәр. Хәзерге татар телендәге XX гасыр ахырында кабат кулланылышка кайтарылган гарәп һәм фарсы сүзләре татар теле лексик фондының аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр.

## § 9. Гарәп һәм фарсы алынмаларының лексик-тематик төркемнәре

Татар теле лексик фондының үсеш-үзгәрешендә гарәп-фарсы алынмаларының ролен тирәнрәк аңлау, аларның урынын ачыграк күз алдына китерү өчен, әлеге алынмаларны лексик-темантик аспектта төркемләп карау зарур. Бу очракта гарәп-фарсы алынмаларының составын үз эчендә дә, татар лексикасына мөнәсәбәттә дә төгәлрәк күзалларга мөмкинлек туа.

Хәзерге татар теленең лексик фондында урын алган, тамыр рәвешендәге гарәп-фарсы алынмаларын тематик яктан түбәндәге төркемчәләргә бүләргә мөмкин.

1. Кешенең эчке һәм тышкы сыйфатларын, психологик халәтен белдерә торган сүзләр: *дус, дошман, гадәт, вөҗдан, хыянәт, дәрман, дәрт, мәхәббәт, ләззәт, нәфрәт, хөрмәт, хафа, рәхим, рух, сер, сәер, шәфкать, шөбһә, шөһрәт, нәзакәт, җитди, дәһшәт, михнәт, нахак, дикъкать, мәкер, мәрхәмәт, фаҗига, игътибар,*

*ихтыяр, хәсрәт, хыял, холык, зәвык, золым, хакыйкать, гакыл, зәгыйфь, зифа, залим, ихлас, һәвәскәр, гадел, дивана, надан, сабыр, карун, ахмак, бичара, әдәп, ихлас, пөхтә, фәкыйрь, инсаф* һ.б.

2. Гаилә кору белән бәйле лексика һәм туганлык атамалары: *гаилә, никах, ятим, сабый, варис, нәсел, нәсел-нәсәп, талак, васыять, гакыйкъ, гомер, җенес, бәндә, вәгъдә* һ.б.

3. Табигать күренешләренең атамалары: *табигать, дәрья, һава, хайван* һ.б.

4. Тормыш-көнкүреш, хуҗалык эшләре, йорт-җир белән бәйле сүзләр: *вазифа, мирас, ярдәм, ихтыяҗ, һөнәр, хуҗа, хезмәт, бәрәкәт, мөнәсәбәт, җәбер, ният, хат, хата, рәхәт, начар* һ.б.

5. Ашамлык, ризык атамалары: *ризык, мәҗлес, хәмер, хәлвә, нигъмәт, шикәр, ширбәт, хәрам, хәләл* һ.б.

6. Гореф-гадәтләрләрне белдергән сүзләр: *гореф-гадәт, бәхет, ядкәр, хәят, тәбрик, тәртип, вакыйга, хаҗәт, рәхмәт, сәлам, бәхәс, нәзер, әманәт* һ.б.

7. Мәгариф, фән өлкәләренә караган сүзләр: *мәктәп, дәфтәр, дәрес, хәреф, рәсем, нокта, әлифба, имла, имтихан, хисап, мөгаллим, химия, фигыль, мәсьәлә, инша, ысул, җисем, гамәл, мәгълүмат, мәгънә, фән, гыйлем, тәгълимат, мәгърифәт* һ.б.

8. Әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә караган сүзләр: *әдип, матбугат, нәшер, нәшрият, мөхәррир, шагыйрь, шигырь, иҗат, мәдәният, мәдәни, дастан, мәкалә, әсәр, мәсәл, мәдхия, тәрҗемә, сәнгать, сәхнә, тәнкыйть, сәхифә, зыялы, риваять, рәссам* һ.б.

9. Илләр гизү, сәүдә һ.б. белән бәйле сүзләр: *сәяхәт, сәүдә, сәүдәгәр, милек, кыйммәт, ришвәт, файда, мал, зарар, гер, сәфәр, мөсафир, кәрван, мөсафирханә* һ.б.

10. Хокук, хәрби, медицина өлкәләре белән бәйле сүзләр: *дару, шифа, сәламәт, газап, табиб, җәрәхәт; хаким, хөкем, казый, җинаять, шаһит, җәза, җәллад, хокук; солых, гаскәр, һәлак, һөҗүм, әсир, хәрабә, хәрби, хәнҗәр* һ.б.

11. Дингә бәйле сүзләр: *дин, Алла, тәмуг, Ходай, рамазан, Коръән, фәрештә, хәер, намаз, тәүбә, сәхәр, шайтан, ахирәт, хаҗ, газраил, кыямәт, дога, әҗәл, тәкъдир, әүлия, пәйгамбәр, гөнаһ, гает, иман, сөннәт, мулла, хәзрәт, мәхәллә, мәчет, азан, манара* һ.б.

12. Иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *җәмгыять, сәясәт, икътисади, дәүләт, хөкүмәт, таҗ, патша,*

*тәхет, ватан, халык, сыйныф, сыйнфый, инкыйлаб, хөррият, хөр, солтан, әмир, мәнфәгать, фәрман, әмир, дәрәҗә, даирә, рәис, кабилә, фетнә, гариза, игълан, имза, дәгъва* һ.б.

13. Төрле өлкәләргә караган абстракт яки конкрет төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *инсаният, рухият, сәләт, тәэмин, сәбәп, тәкъдим, тәэсир, хәзинә, сыйфат, шарт, хәйран, шәхес, мөһим, әһәмият, мәслихәт, гаҗәп, гади, камил, лаек, хәбәр, гомумән* һ.б.

14. Көн исемнәре: *шимбә, якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга*.

15. Вакытны белдерә торган сүзләр: *заман, гасыр, даими, вакыт, сәгать, чор, хәзер* һ.б.

16. Кыйммәтле ташларны, казылма байлыкларны белдерә торган сүзләр: *җәүһәр, якут, гәрәбә, зөбәрҗәт, мәгъдән* һ.б.

17. Кеше исемнәре: *Габдулла, Әхмәт, Гариф, Зариф, Хәсән, Мөхәммәт, Әминә, Гадел, Гадилә, Сабир, Әдибә, Газизә, Гайнекамал, Мәликә, Шәмсениса, Нурлыхода, Бибигайшә, Мәфтуха* һ.б.

Телебезнең тарихи үсеше яссылыгында карасак, кулланылышка килеп кергән гарәп һәм фарсы сүзләренең лексик-тематик төркемнәре төрле чорда төрлечә булуын күрәбез. Әлеге процессны тулысы белән күзаллау максатыннан, татар теле формалашу һәм үсешенең төрле этапларында кулланылышта йөргән алынма лексиканың составы һәм төп төркемнәренә күзәтү бирү кирәк санала.

Алдагы бүлектә искәртеп үткән «Борынгы төрки сүзлек»тәге (Древнетюркский словарь, 1969) гарәп-фарсы алынмаларын лексик-тематик яктан күзәтү түбәндәге нәтиҗәләргә китерә.

Тормыш-көнкүреш, йорт-җир белән бәйле лексик-тематик төркемдә бу төр алынмалар табылмый, шулай ук кием-салым, ашсу белән бәйле төркемдә дә алар бик чикле: *касаб* – парча, тукыма, *мал* – милек, байлык, *мәнсез*, *шикәр*, *evin* – орлык, ашлык (тат. *әвен*, рус. *овин*), *joγurt* – ачыткан сөт, катык, *talqan* (рус. *толокно*), *laqša* – бодай оны, токмач (рус. *лапша*) кебек очраклар хәзерге татар телендәге алынма дип йөртелгән кайбер сүзләрнең килеп чыгышына якын. *Zibas* (одежда, плать килүне таләп итәе) һәм *liv* (еда, явства) кебек гарәп-фарсы сүзләре борынгы төрки *кием, тун, аш* сүзләре белән янәшә кулланылганнар, телнең тарихи үсеше дәвамында пассивлашып, кулланылыштан төшеп калганнар.

Терек һәм терек булмаган табигать белән бәйле лексик-тематик төркемдә дә гарәп-фарсы алынмалары, көнчыгышка хас хай-

ваннар дөньясы исемнәрен (*фил, тәвә* һ.б.) исәпкә алмаганда, шактый чикле: *гөл*, *мая*, *гөләф.*

Туганлык атамалары системасы, нигездә, төрки лексикадан тора. Гарәп-фарсы алынмалары гомуми туганлыкны белдерә торган төркемчәдә генә күзәтелә: *nasab*, *näsäb* – нәсел, нәсел-нәсәп; хәзерге вакытта нәсел-нәсәпне белдерә торган *кавым* сүзе борынгы төрки телдә «халык», «кешеләр» мәгънәсендә булган.

Кеше әгъзалары белән бәйле лексик-семантик төркем шулай ук төрки сүзләрдән тора. Биредә фарсы *җан* сүзен генә күрсәтеп үтәргә кирәк, борынгы төрки телдә, *җан* сүзе «күңел»; «тормыш» мәгънәләрен белдергән.

Кешенең эчке дөньясын, килеш-килбәтен, холкын, рухи халәтен белдерә торган лексик-семантик төркемдәге кайбер гарәп-фарсы алынмалары да борынгы төрки телдә үк кулланылышта булганнар: *дәрт* – чир, авыру, *гамь* – кайгы, моңсулык, *газаб* – көчле ачу, ярсу, *һуш* – аң, *хәл*, *хәсрәт*, *хирыс* – хирыслык, *хөрмәт*, *хәйлә*, *хәйләсез*, *нәкәс*, *ният*, *кодрәт*, *кодрәтле, рәхәт, рәнҗү, рия, сәламәт, сер, тәкәббер, тәүфыйкъ, тиле, зәхмәт, дәрман, дару, хәрәм, нәфес, нәфис, гомер, кыйммәт, куәт, җан* һ.б.

Бу төркемдә табыла торган гарәп-фарсы алынмаларының кайберләре борынгы төрки телдә төп тамыр формасында кулланылганнар. Мәсәлән: *šär* – усаллык, явызлык, зыян; чагыштыр: тат. *ширлек* – әшәкелек, зыян, *ширлекле* – зыян китерүчән, *rän* – кайгырту, борчылу, үпкәләү, татар телендә бу сүздән ясалган *рәнҗү* фигыле кулланыла; *hoš* – аң, хәзерге татар телендә *һуштан язу* – аңны югалту һ.б.

Борынгы төрки телдә гарәп-фарсы алынмаларының зур өлеше мәдәният, рухи мәдәният, иҗтимагый тормыш белән бәйле лексик-семантик төркемнәрдә табыла. Мәсәлән, «Борынгы төрки сүзлек»тә мондый гарәп-фарсы сүзләре очрый:

– дини атамалар: *дин, дога, дога кылу, гыйлем, иман, шәригать, тәсбих, тәүбә, кәфен, нәби, кыямәт, өммәт, вафа*;

– уку, белем алу: *хәреф, дәфтәр, хисап, имтихан, шагыйрь, китап, каләм, хат, надан*;

– иҗтимагый тормыш: *амәнәт, әмер, хаким, халәл, хөкем, тәхет, таҗ, тәртип, тылмач, якшәмбе, караван, нәсәп* (нәсел-нәсәп), *низам, халык, дус, дошман, һәдия, риза, дөнья, табигать, мәшрикъ* һ.б.

– иҗтимагый-икътисади өлкә: *фәкыйрь, фәкыйрьлек, кара* – масса, толпа, *фетнә, гүр, һөнәр*;

– фәлсәфи һ.б. сүзләр: *хакыйкать, философ, фикер, камил, вакыт, фал, изге фал, фида кылу, хаҗ, шигырь, пәри, рәхмәт, риза, сәгадәт, сәбәп, сәфәр, сәлам.*

XVII гасырга караган язма эш кәгазьләре (грамоталар, дипломатик хатлар, шәхси-юридик һ.б. төрле документлар) телендә кулланылган гарәп-фарсы алынмалары түбәндәге лексик-тематик төркемнәрдә шактый актив кулланылганнар:

1) феодаль иерархия, хөкүмәт башлыклары белән бәйле лексика: *падишаһ*, (самодержец), *хөкемдар, хәкимләр, солтан, кодрәт, галәм, әгъзәм хәзрәтләре* (его величество);

2) хәрби лексика: *гаскәр*, *сикълэт вә хәрабәләк* (зло и разрушения), *минйәт* (служба, постройки) һ.б.;

3) тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр: *хәзинә, хат* (грамота), *аҗдадлар* (бабаларыбыз), *сихәт вә сәламәт, мәгълүм кылу, кәфен, фагил итү* (бәхил итү), *мирас, кәбен* (никах), *бәдруй* (некрасивая), *дивана* һ.б.;

4) административ-территориаль атамалар: *мәмләкәт, шәһәр, мәшрикъ, шималь, әмер кылу, боеру, сәясәт бикләре*(администрация вәкилләре) һ.б.;

5) социаль төркемнәр, хезмәткәрләр белән бәйле сүзләр: *дәбир* (хат йөртүче), *дәфтәр* (реестр), *мәтаг* (товар), *шәригать* (суд), *гарз* (челобитная), *таиф әдәмнәр* (подданные), *васыятьнамә* (завещание), *казый* (судья), *гакыйл ир* (җитлеккән, балигъ ир-ат), *вәли* (опекун) һ.б.

XVIII гасыр эш кәгазьләренең лексик составын конкрет күзалларга мөмкин булсын өчен, берничә лексик-семантик төркемнән мисаллар тәкъдим итәбез.

1) иҗтимагый-сәяси лексика: *падишаһлыклары вә хөкүмәт гәһлыкҗлары* (патшалыклар һәм дәүләтләр), *wилайәт, илайәт* (өлкәләр, җирләр), *әразый Парс* (фарсы өлкәләре/җирләре), *мәмләкәте Ширwан* (Ширван провинциясе), *шәһре Шәмәхә* (Шемаха шәһәре), *тәҗҗәрәт* (сәүдә), *әһле тәҗҗәр* (сәүдәгәрләр), *дәстгяһ биләре* (идарә хезмәткәрләре), *забәп* (башлык, түрә), *wәли* (губернатор), *ханәләр* (йортлар) һ.б.

2) хәрби лексика: *сәрғәскәр* (генерал), *қурчы башы* (офицер), *ағайан қул туфәңчиән* (пехота җитәкчесе), *дошман*, *зурбәләр* (бун-

товщиклар), *һөҗүм вә син-сәнф идүб* (һөҗүм итү һәм тар-мар итү), *тыйг вә атәш илә* (ут һәм кылыч белән) һ.б.

3) дини атамалар: *муллалар*, *имамлар*, *арбаб ходдам җуамигы* (мәчеттә хезмәт итүчеләр) һ.б.

4) этикет белән бәйле сүзләр: *Без Питрус әwwәлге импиратур туаиф Руси* (мы Петр Первый император Российский), *шәwкәтлү wә газәмәтлү, сәгәдәтлү wә мәһабәтлү оло, оло мәхуббымыз ќадими дустыбыз шаһ галиҗаһ хәзрәтләре* (пресветлейший могущественный, благополучнейший старый наш верный приятель шахское Величество), *фазыйләтлү гөләмә wә муллал*ар (почтенные учителя (ученые) и муллы), *хөрмәтлү имамлар* (почтенные духовные служители) һ.б.

4) эш кәгазьләрендәге трафарет атамалар: *хат һөмайунымыз шаһәдәт идәрүз* (с этим императорским указом), *тәхт тәсәррруфында улан* (находящийся во владении); *вәгдә-и кәримә-и хаќанымыза* (нашего всемилостивейшего хана), *хаќанымыза* (нашего всемилостивейшего хана), *һөмайунларымыз муҗәбенчә* (в силу императорского Указа), *мөстәќил илчемез* (наш полномочный посол), *шәриг шәриф илә* (по почтенному закону шариата), *асла бер зарар wә бер зыйан улынмайа* (не чинить никакого вреда и обид) һ.б. (Хисамова, 2003: 461–463).

XX гасыр башында җәмгыятьтә барган иҗтимагый-мәдәни процесслар татар телендә гарәп-фарсы алынмаларының лексик-тематик төркемнәренең үзгәрүенә дә китерә. Аларның мәгънә ягыннан бүленгән берничә төркеменнән мисаллар китерик.

1. Дин белән бәйләнешле лексика: *дүзах* – тәмүгъ, *раббе* – алла, *мәләк* – фәрештә. *имамәт* – имам вазифасы, *мөслим* – мөселман һ.б.

2. Иҗтимагый, икътисади өлкә лексикасы: *борһан* – аргумент, *бәһрә* – файда, өлеш, *таҗир* – купец, коммерсант.

3. Зат, аның шөгыль-кәсебе: *арбаб* – юлбашчылар, *бәккаль* – рус. бакалейщик, *пәдәр* – ата, *хәммал* – грузчик, *халә* – рус. тетя, *дөхтәр* – кыз, *сәйяд* – аучы һ.б.

4. Кешенең тән төзелешенә, эчке һәм тышкы халәтенә бәйле сүзләр: *зиммә* – җилкә, арка, *чәшем* – күз, *мигъдә* – ашказаны, *бәшарәт* – шатлык, тантана, *бөһтан* – яла, *хәмиять* – егәр, көч, *тыйрә* – бәхетсезлекне сизенү, *нәфсаният* – эгоизм һ.б.

5. Мәгариф, әдәбият, сәнгать һ.б.: *истилахат* – терминология, *тәзкирә* – истәлек, һәйкәл, *хатимә* – йомгак, *хордәбин* – микроскоп, *намә* – хат, исемлек, язу, *замир* – алмашлык һ.б.

6. Тормыш-көнкүреш: *атәш* – ут, *хамиз* – кислота, *сөфрә* – эскәтер, *сайкал* – рус. блеск, *зарф* – посуда, *фәнҗан* – стакан, бокал, *аб* – су, *зәхирә* – азык, *гасәл* – бал һ.б.

7. Абстракт мәгънәле сүзләр: *бәхил* – саранлык, *төһмәт* – рус. вина, злословие, *сабат* – пөхтәлек, дан, милек, *хәмакать* – аңгыралык, *зан* – фикер, уй, *фәсахәт* – нәфислек, чәчәнлек һ.б.

8. Табигать күренешләре, үсемлекләр һәм хайваннар: *асман* – күк, күк йөзе, *афтаб* – кояш, *хәрарәт* – эсселек, *рих* – ис, җил, *сәярәт* – планеталар, *гакрәб* – чаян, *кәркәдән* – рус. носорог, *хәҗәр* – минерал, *ләгыль* – якут, *Сыйн* – Кытай һ.б.

9. Урын һәм вакыт белән бәйле лексика: *сания* – секунд, *зәвал* – (көннең) кичкә авышуы, *сабах* – иртә, *зөһер* – өйлә, *мөһләт* – срок; *җаддә* – шәһәр, бистә, *җаниб* – як, юнәлеш, урам, *бәхер* – диңгез, *җәзирә* – утрау һ.б.

Гарәп һәм фарсы сүзләренең тематик составы үзгәрешендә тагын бер хәлиткеч чор булып XX гасырның 80–90 нчы еллары исәпләнә. Әлеге чорда XX йөз башыннан пассив сүзләр рәтенә күчкән, әдәби телдә бөтенләй диярлек кулланылмаган һәм шуңа күрә аңлатмалы сүзлектә дә чагылыш тапмаган күп кенә сүзләр яңадан кулланылышка кертелә. Икенчедән, билгеләп үтелгәнчә, аңлатмалы сүзлекләрдә искергән, тарихи, борынгы дип тамгаланган сүзләр кабат активлашып китәләр. Шулай итеп, әлеге чордагы гарәп-фарсы алынмаларының составы башкачарак төс ала. Р. Мөхиярова аларны түбәндәге тематик төркемнәргә бүлеп күрсәтә:

1) абстракт төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *рухият, зарурият, миллият, зиһният, мәгънәвият, мәшгулият; бәян, вазгыять, вөҗүд, горуһ, зольмәт, иҗтиһат, инсаният, ихсан, кабилият, кәррә, кыйтга, мантыйк, мәҗбүрият, мәнфәгать, моназарә, мөддәт, нам, нәҗасәт, ригая, сафа, сәгадәт, тәэссорат, фал, фәһем, фигълият, хилаф, хиссият, хосус, шан, шәкел, шәүкәт, шәхсият* һ.б.

2) билге белдерә торган сүзләр: *дәүләти, зәүкый, мәхкәм, мәсләки, сәнәгый, хәбәри, хәер хаһ, хисси, гаклый, тәхълидән, тәхминән, хәрфи / хәрфән; әгъла, әсасый, бакый, бәйнәлмиләл, галиҗәнап, гамәли, гидай, җисмани, икътисади, инкыйлабый, ка-*

*дими, кануни, лязим, мәзлүм, монафикъ, мөбәрәк, назари, сәяси, тәрәккый, фидаи, хилаф, бинипая, бихисап, галибанә, биһуш, дустанә, мотлак, нисбәтән, шәхсән* һ.б.

3) иҗтимагый-сәяси тормышка бәйле атамалар: *гаделия, гамәлият, мәрасим, мохтарият, мөһаҗәрәт, тәшкиләт, фәгалиятъ, хәйрия, һәйәт, вилаять, җиһад, җөмһүрият, иганә, икътисад, инкыйлаб, ислах, иттифак, кәсәбә, мәмләкәт, мәзһәб, мөнбәр, мәкам, пайтәхет, сәрмая, сәясәт, хакимият, химая, хөррият, һиҗрәт, шигарь, гавәм, мәгърип, шәрык* һ.б.

4) кешене һөнәре, вазифасы, характерлы сыйфаты буенча атый торган сүзләр: *җәррах* – хирург, *мигъмар* – архитектор, *мәэмүр* – чиновник, *мөәррих* – тарихчы, *рәфыйка* – кәләш, хатын, *фәтташ* – ревизор, инспектор, контролер һ.б.

4) әдәбият һәм тел белеме атамалары: *хашия*, *вәзен, җилд, ләкаб, мәҗмуга, өслүп, тәхәллүс, хәтимә, гыйбарә, нәхү, сарыф, шивә*.

5) гомум фәнни атамалар: *гонсыр, кәшфият, тыйбб; назария, һәндәсә* һ.б.

6) уку-укыту өлкәсенә караган сүзләр: *көллият, дарелфөнүн; җәдвәл, инша, талибә, талип, тәгълим, шәкерт* һ.б.

7) матбугат белән бәйле сүзләр: *абунә, матбага, мөхбир, мөштәри* һ.б.

8) дин белән бәйле сүзләр: *бәйтулла(һ), гөнаһкяр, имамәт, мөтәвәллият, мөхтәсиб, саим, сәхабә, фидаять; алиһә, вәгазь, бәддога, газават, гареш, дәфен, җәбраил, зәкят, исламият, канун, мәхәллә, мөрит, фәтва, хаҗ, хаҗи / хаҗия, хәрәм, хөтбә* һ.б.

9) төрле язмалар, документ, рәсми кәгазь атамалары: *вәрака, вәсика, дәстүр, гуаһнамә, иҗазәтнамә, кануннамә, солыхнамә, бәяннамә, дәгъвәтия; лаихә, нотык, фәрман, шикаять, васыятьнамә, шикаятьнамә, низамнамә, шартнамә* һ.б.

10) оешма, бина исемнәре: *шәрабханә, тәҗрибәханә, вакыф, фирка, ширкәт, шура, дәресханә, кәһвәханә, кярханә, мосафирханә, шифаханә, һөнәрханә* һ.б.

11) тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр: *аләт* – эш коралы, *дәстерхан* – ашъяулык, *кальб* – йөрәк, күңел, *гонҗә*, *җәсәд, зынҗыр, каберстан, кәбап, мәгъдән, мәктүп, мөһир, низаг, сәйран, тәгам, һәдия* һ.б.

12) модаль сүзләр: *бәс, вакыйган, хакыйкатән* һ.б.

13) алмашлыклар: *бәгъзе, җәмгы(се)*.

14) ымлык: *афәрин*.

15) ярдәмлек сүз төркемнәре: *вә, мисле* (бәйлек), *гайре* (кисәкчә) һ.б. (Мөхиярова, 2000: 71).

Шулай итеп, XX гасыр башларында, хәзерге татар әдәби теле аякка басканда, кулланылыштан төшеп калган бер төркем алынма лексика XX гасыр ахырында кабат актив сүзлек составына кире кайтты, әмма аларның барысы да тел кулланучыларның киң катламына аңлаешлы түгел, аларның мәгънәләрен аңлар өчен тәрҗемә сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Тагын шуны искәртү зарур: аларның бик азы гына хәзерге көнгә хәтле үзләренең кулланылышын теге яки бу дәрәҗәдә саклап кала алды. Мәсәлән: *миллият, рухият, дәүләти, сәнәгый, хәбәри, инкыйраз, хәйрия, гавәм, таифә, шәрык, милләтпәрвәр, сәнгатькяр, моһаҗир, гонсыр, көллият, абунә, мөхбир, коръәнхафиз, мөхтәсиб, фидая, солыхнамә, даруханә*. Бер төркеме исә, киң таралыш тапмыйча, аерым кешеләр телендә генә кулланыла.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, җәмгыятьтәге кискен борылышлар, чорлар алмашыну кебек зур вакыйгалар телнең яшәешендә, лексик фондның, состав ягыннан гына түгел, мәгънәви сыйфаты, эчтәлеге ягыннан да үзгәрешләр китереп чыгара.

## § 10. Гарәп һәм фарсы алынмаларының лингвистик үзенчәлекләре

Татар телендә кулланыла торган гарәп һәм фарсы алынмалары, килеп керү чорлырыннан алып, бүгенгәчә лингвистик яктан төрле үзгәрешләргә дучар булганнар. Аларны үзләштерү кинәт кенә булмаган, бу – гасырлар дәвамында барган процесс. Гарәп-фарсы алынмалары татар телендә фонетик, семантик, грамматик яссылыкларда төрле дәрәҗәдә үзләштерү кичергәннәр. Гарәп-фарсы алынмаларының татар теленә фонетик һәм семантик-грамматик адаптациясе мәсьәләләре Р. Абдуллина, Э. Денмөхәммәтова, М. Мәхмүтов, Р. Нурмөхәммәтова, И. Сираҗиев, Ә. Йосыпова һ.б. галимнәр тарафыннан җентекле тикшерелгән.

Үзләштерү процессы дәвамлы һәм төрле чорда төрлечә булганлыктан, биредә диахроник яссылыкта мәгълүмат бирү кулай булачак.

Алынмаларның фонетик үзләштерелүе күп гасырлар буена дәвам иткән. Биредә берничә төп моментны күрсәтеп үтү белән чикләнергә туры килә.

1. Билгеле булганча, татар телендә, башка барлык төрки телләрдәге кебек, сүзләр сингармонизм законына буйсына. Татар теленә кабул ителгән гарәп-фарсы алынмалары да шушы законга буйсыналар: *мумкин – мөмкин, мухбир – мөхбир* һ.б. Сөйләм телендә мондый күренеш ешрак күзәтелә, мәсәлән, [*сәләмәт*] – сәламәт, [*бәлә*] – *бәла*, [*җәза*] – *җәза*.

2. Гарәп сүзләрендәге озын һәм кыска сузыклар татар телендә бер генә төрдә, озынлык-кыскалыкта аерылмый торган сузык булып әйтеләләр: *хәл-әхвәл, мәхрүм, хөкүмәт, маһир, мәгариф, Талип* һ.б.

3. [а] авазы калын тартыклар булган сүзләрдә [а] булып (*вакыт, зарар, фараз* һ.б.), ә нечкә тартыклар булган сүзләрдә [ә] (*сәфәр, бәхет, мәдрәсә* һ.б.) булып кабул ителгән. Моннан тыш, гарәп-фарсы алынмаларындагы озын *а* сузыгы да татар телендә *а* булып урнашкан: *Алла, вәкарь* һ.б.

4. [и] сузыгы (*хикмәт, варис* һ.б.) тирән тел арты авазлары янында [ый] (*гыйбрәт, зыян* һ.б.) булып киткән. Шунысы игътибарга лаек: Идел буенда татар телендә барган *у~о*, *ү~ө* ике яклы күчешләре гарәп-фарсы алынмаларының татар теленә яраклашуында да чагылыш тапкан (Юсупова, 2008: 250): *дога* (сөйләшләрдә: *дийа / дуwа* вариантларында да), *кодрәт, хөкем, вөҗдан* һ.б.

5. Тартыкларның татар консонантизмына җайлашуы шулай ук әйтелешләре буенча якын булган авазларга тәңгәлләшү юлы белән барган: *Ходай, әгъза, әкият* һ.б. Гарәп телендә ике яки өч вариантта әйтелә торган *з, с, т* тартыклары татар теленә бер генә вариантта үзләштерелгән: [т] < ت, ط; [с] < س, ث, ص; [з] < ذ. Мәсәлән, заһар (ضور), зар (زار), забих (ذابع), самир (ثامر), самит (صامت), салих (سالح), табан (تابان), табиб (طبيب) һ.б.

6. Биредә татар теленең лексик фонды күзлегеннән әһәмиятле булган бер күренешкә игътибар итәргә кирәк. Билгеле булганча, гарәп-фарсы алынмаларындагы сүз башында яки уртасында әйтелә торган увуляр ـع, ـغ авазлары, еш кына, тотрыксызлык күрсәтәләр һәм татар телендә әйтелмиләр яки төшеп калалар. Бу аеруча татар теленең көнбатыш диалектында, керәшен сөйләшләрендә, Себер татарлары диалектларында күзәтелә, урта диалектның

күпчелек сөйләшләрендә, шулай ук әдәби телдә исә алар саклана: *гает – айыт, галим – алим, гаеп – айып, Гайнулла – Айнулла, Гайшә – Айша* һ.б. Мондый күренеш татар телендә фонетик вариантлар барлыкка килүгә сәбәпче булган: *гарь – әр, хаҗәт – әҗәт* һ.б. Тора-бара бу парларның компонентлары төрле мәгънә күчешләренә дучар булганнар, мәсәлән: *хикәят – әкият, хәлвә – әлбә, хәрәм – әрәм, хикмәт – әкәмәт, мәгънә – мәне* һ.б. Нәтиҗәдә мондый сүзләр татар теленә хас сүзлек фондының баюына, семантик мөмкинлекләренең киңәюенә булышлык иткән.

7. Гарәп телендә сүз азагында яңгырау әйтелә торган тартыклар татар телендә саңгырау парларына әйләнәләр: *мәктәп* (әл мәктәбе), *китап* (әл китабун), *иҗат* (иҗадун), *максат* (максадун) һ.б.

8. Гарәп телендәге икеләтелгән тартыкларның берсе төшеп калырга мөмкин: *сиррун* – тат. сер, *әһәммият* – тат. әһәмият, *хассун* – тат. хас.

9. Гарәп-фарсы алынмаларындагы татар теле өчен ят булган *һ* авазы төшә, сүз уртасында аның урынына *г, й* авазлары әйтелергә мөмкин: *Зегрә – Зөһрә, Майтап – Маһитап, әйбәт – һәйбәт, әвәс – һәвәс, чәлпәрәмә – чәһеләпарә, чәршәмбе – чәһәршәмбе*.

9. Авазлар төшү нәтиҗәсендә барлыкка килгән фонетик вариантлар, мәгънә үзгәрешләре кичереп, мөстәкыйль сүзләргә әверелеп киткәннәр: *гамәл* һәм *әмәл*, *әкият* һәм *хикәят*, *мәгънәсез* һәм *мәнсез*, *хәрам* һәм *әрәм*, *гарьләнү* һәм *әрләнү*, *хаҗәт* һәм *әҗәт*, *сәләхият* һәм *сәләт*, *әвәс* һәм *һәвәс*, *тәгам* һәм *тәм* һ.б.

10. Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә басым да үзгәрә, ул татар телендәге кебек, соңгы иҗеккә күчә: *мәдрәсә – мәдрәсә, шагыйрь – шагыйрь, мәктәбе – мәктәп* һ.б.

Гомумән алганда, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынмалар фонетик яктан шактый үзгәргәннәр, шул рәвешле татар теленең әйтелеш нормаларына буйсынып яраклашканнар.

Алынмалар семантик яктан шактый үзгәреш кичергәннәр. Әйтергә кирәк, бу шактый дәвамлы барган процесс санала. Татар теле тукымасына урнашкан алынмаларның төрле чорларда килеп керүен һәм кулланылыш активлыгының да тотрыклы булмавын исәпкә алсак, бу лексик берәмлекләрнең семантик потенциалындагы үзгәрешләрне ачык күзалларга мөмкин.

Алынмаларның мәгънә ягыннан үзгәреш динамикасын күзаллау максатыннан, без «Борынгы төрки сүзлек»кә (1969) мөрәҗәгать итәбез.

Сүзлектәге гарәп-фарсы алынмалары, нигездә, барысы да хәзерге татар теленә килеп җиткәннәр. Әлбәттә, шушы чорда аларның кайберләре семантик һәм структур үзгәрешләр кичергән.

Семантик аспектта караганда, борынгы төрки телдәге гарәп-фарсы алынмалары тел үсеше процессында төрле мәгънә күчешләре кичергән[1]. Түбәндәге таблицада, семантик үзгәрешләрне тулы күзаллау максатыннан, борынгы төрки телдә һәм хәзерге татар телендә кулланылган мәгънәләр бирелә.

| Борынгы төрки телдә | Хәзерге татар телендә |
|---|---|
| Fasl – пора, сезон | Фасыл – 1) время года, 2) раздел, глава, часть |
| Därd – боль, недуг, болезнь | Дәрт – 1) душевный подъем, пыл, чувство; страсть, задор; 2) желание, охота, стремление |
| Ḥikmät – знание медицины (медицина буенча белем) | Хикмәт – 1) мудрость премудрость; 2) тайный, сокровенный смысл; 3) чудо, диво |
| Näfis – ценный, дорогой | Нәфис – 1) изящный, прелестный, элегантный, 2) художественный (фильм); 3) тонкий |
| Nävbät – караул, дежурство | Чират; дериватлары: *нәүбәттәге, үз нәүбәтендә* |
| Qavm – народ, люди | Кавем – нәсел, кавем |
| Ränǯ – забота, беспокойство, обида | Рәнҗү – сильно обидеться; обида; *диал.* болеть, страдать |
| Tävfiq – содействие, помощь | Тәүфикъ – благочествие, благонравие; дериватлары: *тәүфикъсыз, тәүфикълы* һ.б. |
| Zäḥmät – труд, тяжесть, мука, забота, огорчение, вред | Зәхмәт – 1) страдание, мука, испытание; 2) забота, хлопоты; 3) болезнь, хворь; 4) вред, вредное влияние |

---

[1] Мәгънә үзенчәлегендә төгәлсезлекләр китмәсен өчен, кайбер мисалларның оригиналдагыча русча тәрҗемәсе китерелә.

| | |
|---|---|
| Darman, daru, därma – лекарство | Дәрман – 1) сила, энергия, мощь; 2) возможность, состояние; дару – лекарство |
| Räḥmät – милость, милосердие | Рәхмәт – 1) благодарность; 2) спасибо, благодарю; 3) благодать, божья благодать |
| Qïjamät – воскресенье | Кыямәт – 1) судный день, светопредставление; 2) столпотворение, светопредставление, переполох |
| Qïjmät – цена, ценность | Кыйммәт, кыйбат – 1) дорогой, дорогостоящий; 2) ценность, достоинство, значение; 3) значение; 4) стоимость |

Структур яктан караганда, төп сүз формасында теркәлгән алынмалар хәзерге татар телендә дериватлар яисә парлы сүзләр составында кулланылалар: *mülk* – владение, государствао, тат. милек, мөлкәт; *xat* – 1) почерк; 2) письмо, документ, тат. хат; *γam* – печаль, грусть, тат.: *гамьсез* – бездумный, нераздумывающий.

Мисаллардан аңлашылганча, борынгы төрки телдәге гарәп-фарсы сүзләрендә барлыкка килә торган мәгънә үзгәрешләре төрле юнәлештә бара: мәгънәнең тараюы (*кавем, фасыл, нәүбәт, рәнҗү, зәхмәт*) яки киңәюе (*нәфис, кыйммәт, кыямәт, рәхмәт*), яңа коннотатив мәгънә төсмере өстәлү (*хикмәт, зәхмәт*) һ.б.

Семантик үсеш-үзгәрешнең антонимик дәрәҗәгә (*дәрт*) җитүендә чыганак телдәге күп мәгънәле сүзнең яңа телдә бер генә мәгънә төсмере белән үсеп китүенә дә бәйле.

Борынгы төрки телдәге кайбер абстракт мәгънәле гарәп-фарсы сүзләренең мәгънәсе конкретлашкан, яисә, кулланылышы чикләнеп, диалектларда гына сакланган. Мәсәлән:

| Борынгы төрки сүзлектә | Хәзерге татар телендә |
|---|---|
| Dävlät – бәхет, уңыш, иминлек | Дәүләт – 1) дәүләт; 2) байлык |
| Ɣazab – ярсулык, ачу | Газап – мучения, страдание, мука, пытка |
| Josuγ – бәла, бәла-каза | *Диал.* йосук/йусык – порядочный, воспитанный; дериватлары – *йусыклап, йусыклы* |

Гарәп-фарсы, аеруча гарәп сүзләре яисә аның аерым формалары, татар теле лексикасының, состав ягыннан гына түгел, семантик яктан да баюына булышлык итә. Кайбер язма ядкәрләрне карап үтү дә татар язма әдәбияты телендә гарәп-фарсы алынмаларының ни дәрәҗәдә киң кулланылуын күзалларга ярдәм итә: Мисал өчен, XIV йөз язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф»та Йосыф түбәндәгечә сурәтләнә:

Әүwәл улдыр: қадде йахшы зариф үзлү,
Икенчи – бәңзе йақту, күрклү йүзлү,
Үченчи – теле фәсих, сәхих сүзлү, –
Йетмеш ике телни тәмам белүр имди.
Түртенчи – шәфәғәтлү, мөрәүwәтлү,
Бишенче – алып йөрәклү һәм һәйбәтлү,
Алтынчи – қамулардан бик қуwәтлүәw, –
Қырық ирдән қуwәте артуқ имди.

XVIII гасыр әдәбиятында күренекле урын биләгән Утыз Имәни әл Болгарый:

Осуле фәйләсуфә мәфтүн улмыш,
Аларның җәһл-ү-көфрен гыйлем белмеш.
Мөдәррисләр пәйедин чук гъәбиләр,
Чыкыблар раһе хакъдин бер тарафга,
Килә белмәс, чагырсаң, раһе хакъга.
Тулыбдыр күзләригә хаке бидгъәт,
Кабул итмәс нәчә дирсәң шәригъәт,
Шәригъәт сүзләрени тәэвил идәр,
Үзинең кәҗ йулига дугъры кидәр
(Имәни, 1986: 41).

XIX гасыр шагыйре Г. Кандалый:

Йөзең раушан, телең сөчек,
Буең зифа, билең нәзек,
Кулыңдадыр көмеш йөзек, –
Гаҗәб һиммәт ирер, җаный
(Кандалый, 1988: 128).
Сиңа җаным кыйлам сәлам,
Догаларым сәңа салма, –
Мөбарәк җәмалең кирәм…
(Кандалый, 1988: 129).

XX гасыр ахырындагы иҗтимагый борылышлар телебезгә яңадан кайтарылган гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышында да үзгәрешләр китереп чыгарды. Галимнәр, бу җәһәттән карaганда, кайбер сүзләрнең стильара лексикага күчүенә игътибар итәләр. Мәсәлән, аңлатмалы сүзлектә «китап теле», «югары стиль» билгеләре белән тамгаланган *дивар, матәм, мәдәни, мәдәният, мәхкәмә, рәссам, табиб, фараз, хәбәрдар* кебек сүзләр хәзер төрле стильдә иҗат ителгән язмаларда активлашып киттеләр, үзләренең *стена, траур, культура(лы), суд, художник, врач, прогноз* кебек синонимнарын кысрыкладылар (Мөхиярова, 2000: 96).

*Кавем, хаста* сүзләре, кайчандыр, гади сөйләм сүзләре рәтендә йөргәннәр, хәзер исә алар стильара лексикага карыйлар. Шунысы игътибарга лаек, әлеге сүзләр диалектларда мөстәкыйль мәгънәле, актив кулланылышлы стильара сүзләр булып кулланылалар иде. Бу факт та аларның статусы күтәрелүдә билгеле дәрәҗәдә роль уйнаган булырга мөмкин.

*Мөхәррир, канун, рәис, сыйныф, ришвәт, сәяхәтнамә* һ.б. сүзләр хәзерге татар телендә аеруча активлашып киттеләр, мәгънә функцияләрен ныгыттылар яисә баеттылар.

Гомумән, үзгәртеп кору һәм аннан соңгы чорда гарәп-фарсы алынмаларын куллануда күп кенә яңа күренешләр, кире кайткан алынмаларны семантик үзләштерүдә аерым үзенчәлекләр барлыкка килде. Шуларга тукталып үтик[1]:

| Сүз | Татар телендә кулланылган традицион мәгънәләре | XX гасыр ахырыннан активлашкан мәгънәләре |
|---|---|---|
| Гыйбарә | тексттан өзек, өземтә | формулировка |
| Казый | шәригать законнары буенча хөкем итүче | спорт уеннары судьясы |
| Мәкам | көйле тавыш һ.б. | хокукый хәл |
| Мәхәллә | шәһәрнең яки авылның бер мәчеткә караган өлеше | дини этник принципта төзелгән оешма |
| Мөнбәр | мәчет эчендә мулла басып укый торган биек урын | *күч.* дәрәҗәле урын һ.б. |

[1] Мисаллар Р. Мөхиярованың «XX гасырның 80–90 нчы елларында татар әдәби теле лексикасы» (Яр Чаллы, 2000: 107–112) хезмәтеннән алынды.

| | | |
|---|---|---|
| Һөнәри | эш, кәсеп, профессия | профессиональ |
| Мәҗмуга | җыентык, сайланма әсәрләр | журнал |
| Мәрд | ир, егет; батыр, кыю | мәрдән – гражданин |
| Өммәт | нинди дә булса дин тарафдары | халык |
| Сәрмая | төп капитал | инвестиция |
| Гамәлият | җитештерү процессы; операция; эш-хәрәкәт, процесс | операция |
| Зиһният | акыл, фикерләү юнәлеше | интеллект |
| Көллият | төрле уку йортлары | колледж |
| Хаким | судья; өстенлек итүче; хуҗа, түрә, башлык | шәһәр администрациясе башлыгы |

Гарәп-фарсы алынмаларының грамматик һәм сүз ясалышы ягыннан үзләштерелүен түбәндәге төп билгеләргә берләштерергә мөмкин:

1. Сүз алдындагы гарәп теленә хас *әл, ал* артикльләре һәм сүз азагындагы кайбер кушымчалар төшерелә: *ихлас* (әл ихлас), *китап* (әл китабун) һ.б.

2. Билгеле булганча, гарәп теленә род (җенес) категориясе хас, ә татар телендә мондый категория юк. Шуңа күрә гарәп теле өчен характерлы җенес төрләнешләрендәге сүзләрнең күпчелеге, нигездә, беренче төрдә генә алынган: *галим* (галимә), *рәис* (рәисә), *хатип* (хатибә), *әдип* (әдибә), *хаким* (хакимә), *ятим* (ятимә) һ.б. Соңгы елларда әлеге типтагы парларның хатын-кызларны белдерә торган төрләре дә активлаша бара, һәм ул аеруча кеше исемнәрендә актив күзәтелә: *Хәлим – Хәлимә, Латыйф – Латыйфа, Нәгыйм – Нәгыймә, Әмин – Әминә, Сәлим – Сәлимә* һ.б.

3. Гарәп-фарсы алынмалары нигезендә *-намә, -ханә, -гәр, -дар, -стан* компонентлы үзенчәлекле модельләрдә яңа сүзләр ясала: *васыятнамә, сәяхәтнамә, шәһадәтнамә, фалнамә, сораунамә, ышанычнамә, эшнамә, ярлыкнамә, чакырунамә, кайгынамә* һ.б.; *дәресханә, хастаханә, һөнәрханә, әҗәтханә, мосафирханә, кизүханә, икмәкханә, эчкеханә, чәчтарашханә, чәчханә* һ.б.; *сәүдәгәр;*

*хәйләкәр, хезмәткәр, һәвәскәр, ядкәр* һ.б.; *диндар, тарафдар, хөкемдар* һ.б.; *Татарстан, Төркестан, гөлстан* һ.б.

4. Гарәп-фарсы элементлары ярдәмендә (аерым алганда, *-ый/-и* кушымчасы ярдәмендә) яңа сүзләр ясала: *вазифаи/вазыйфый, вәсикави, гаммави, җәллади, җәмгыяви, кабихи, кыйблави, хакимияти, сәнгати, сәнәгати, идеяви, мөхәррият, илһамият, ләззәтият, сөйләмият* һ.б.

5. Фарсы теленә хас *би-* алкушымчасы белән дә татар теле җирлегендә яңа сүзләр ясау очраклары бар: *бихисап*, *бихәбәрдар, бихафа, бимәркәзләү* һ.б.

6. Гарәп-фарсы алынмалары кушма сүзләр составында яисә парлы сүзләрнең компонентлары булып киләләр: *шәһәрара, асылташ, хәлиткеч, дөньякүләм* һ.б. Парлы сүзләрнең бер компоненты булып гарәп-фарсы, икенче компоненты булып төрки сүзләр килергә мөмкин: *дус-иш, сый-хөрмәт, кайгы-хәсрәт* һ.б.

XX гасыр ахырында кайбер рус һәм Европа алынмаларын алыштыру өчен татар телендә инде нык урнашкан сүзләрне кушып, ягъни синтаксик ысул белән яңа сүзләр ясау (*каләмхак* – гонорар, *мөхбир-әгъза* – член-корреспондент), күпмәгънәле гарәп-фарсы алынмаларының әлеге кулланылмыйча кала килгән мәгънәләреннән берсенә фонетик үзгәрешләр (*матдә* – материя, *маддә* – статья, *мәдхия* – ода, *мәдһия* – гимн һ.б.ш.) кертү һ.б. юллар белән яңа сүзләр ясау да күзәтелә.

7. Гарәп-фарсы алынмалары нигезендә һәм татар теленең *итү, кылу, булу, ясау* һ.б. ярдәмче фигыльләре ярдәмендә күпсанлы аналитик төзелешле сүзләр ясала. Алар шулай ук татар теленең сүзлек фондын баетуга булышлык итә: *ярдәм итү, дәвам итү, тәмам итү, игътибар итү, сарыф итү, сәүдә итү, хөрмәт итү, игълан итү, хасил итү, хезмәт итү, шөкер итү* һ.б.; *гыйбадәт кылу, мәсхәрә кылу, тамаша кылу, фида кылу, хаҗ кылу, хилаф кылу, сәяхәт кылу* һ.б.; *гашыйк булу, мәхрүм булу, пәйда булу, тәмам булу, һәлак булу, нәүмиз булу; җавап бирү, җәза бирү, сәлам бирү, фатиха бирү, вәгъдә бирү; гыйбрәт алу, гыйлем алу, ләззәт алу* һ.б.

8. Гарәп-фарсы алынмалары нигезендә, татар теленең үз сүзләрендәге кебек үк, төрле сүзьясалыш ысуллар белән дә яңа сүзләр ясала. Аеруча кушымчалар белән дериватлашу актив. Татар теленең продуктив кушымчалары, алынма сүзләргә ялганып, телебез җирлегендә шактый яңа лексик берәмлекләр (исем, сыйфат, фи-

гыль һ.б. сүз төркемнәренә караган сүзләр) ясый. Мәсәлән, *-чы/-че* кушымчасы татар әдәби телендә иң продуктив булуы белән аерылып тора. Гарәп-фарсы тамыр сүзләреннән яңа исемнәр ясауда да аның активлыгы күзгә ташлана. Аның ярдәмендә төрле тематик төркемгә карый торган исемнәр ясала: *сәяхәтче, тәрбияче, тәнкыйтьче, әдәбиятчы, бәетче, кәсепче, тәрҗемәче, рәсемче, фалчы, сәгатьче, сихерче* һ.б. Гарәп-фарсы сүзләреннән ясалган сыйфатларның иң күбесе *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчасы белән ясала һәм алар төрле мәгънәләр белдерәләр: *әдәпле, намуслы, җаваплы, тәүфыйклы, шәфкатьле, әхлаклы, сабырлы, хикмәтле, гөмбәзле, шифалы, җиһазлы, зарарлы, ләззәтле, һавалы, низамлы, сурәтле, хәтерле, иҗтиһатлы, фәһемле, шәүкәтле, мөрәвәтле, гайрәтле, шөбһәле, һавалы, мәкерле, хөрмәтле* һ.б.; *хәтерсез, рухсыз, шәфкатьсез, ихлассыз, кинәсез, пәрвайсыз, тәкатьсез, тәкәллефсез, сыйфатсыз, әмәлсез, ләззәтсез, мәсләксез, рәвешсез* һ.б.

Шулай итеп, гарәп-фарсы алынмаларының татар теле лексикасын, семантик системасын үстерүдә рольләре зур.

Алынмалардан сүзләр ясау телнең лексик составының, аның даими яшәешле булган төп фондының үсүендә зур әһәмиятле фактор булып тора. Аеруча тамыр рәвешендә кабул ителгән гарәп-фарсы алынмалары татар лексикасының баюына китерәләр, чөнки алар нигезендә яңа сүзләр ясалу мөмкинлеге бар, бу исә телнең семантик системасында яңа потенциаль мөмкинлек дигән сүз.

## Рус һәм Европа телләреннән кергән алынмалар

### § 11. Татар теленә рус һәм Европа алынмаларының үтеп керү тарихы

Һәр телнең сүзлек составы зур тарихи үсеш-үзгәреш барышында формалаша. Галимнәрнең бердәм күрсәтүенчә, бер генә халык та аерым, изоляцияләнеп яши алмаган, күрше халыклар белән төрле өлкәләрдә тормыш-көнкүреш тәҗрибәсе алмашып торган. Мәдәни-икътисади, иҗтимагый-сәяси бәйләнешләр барыннан да тизрәк телнең лексик составында чагылыш тапкан.

Алынмаларның иҗтимагый һәм тарихи җирлеге төрле булган. Бер халыктан теге яки бу сүзләр матди байлык элементлары алышканда керә, ә икенчеләре мәдәни яки сәяси

бәйләнешләр, рухи мәдәният алмашу нәтиҗәсендә телебезгә үтеп керәләр.

Татарларның бабалары – болгарлар белән русларның бабалары – славяннар бик борынгы заманнардан ук якын күршеләр булып, үзара тыгыз бәйләнештә гомер кичергәннәр. Дистәләгән гасырлар дәвамында әлеге ике халык арасында төрле характердагы бәгланышлар булып торган. Мәсәлән, Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында әлеге ике халык үзара мөнәсәбәтләрен бердәм күршеләр буларак төзегәннәр. Шуңа бәрабәр партнерларның үз туган телләре дә чит алынмалар хисабына баеган, әмма мөстәкыйль алгарыш кичергән.

Тик бер моментны ассызыклап үтәргә кирәк: татарларның телләренә бабалары чорыннан ук керә барган рус алынмаларының кабул ителү вакытын, хронологиясен билгеләү мөмкин түгел.

Татар һәм рус халыкларының бабалары төркиләр белән славяннарның борын-борыннан күршеләр булып аралашып яшәүләре төрки халыкларның Көнчыгыш Европага килү вакыты белән бәйле. Галимнәр күрсәтүенчә, Европада беренче борынгы төрки дәүләтләр II–III гасырларда ук барлыкка килгәннәр (Зәкиев, 2008: 140–142; 427). К. Лайпанов һәм И. Мизиев «О происхождении тюркских народов» (1993) дигән хезмәтләрендә Идел–Урал регионында төркиләр б.э.к. IV меңьеллыкта ук булганнар дигән фикердә торалар (Лайпанов, Мизиев, 1993: 16–28). Бу факт татар-рус бәйләнешләренең күп гасырлар буена дәвам итүе турында сөйли һәм алар сәүдә итү, уртак географик шартларда тормыш-көнкүреш тәҗрибәсе уртаклашу, бәрелешләр, сәяси-икътисади-мәдәни һ.б. шартлардан чыгып, һәр дәвердә төрлечә характерда булган.

Халыкларның аралашуы тел өлкәсендә дә яңалыклар барлыкка килүгә сәбәпче була. Телләрнең үзара тәэсир итешүе лексика өлкәсендә аеруча тиз һәм көчле чагылыш таба. Үзара мөнәсәбәттә булган телләрнең икесенә дә чит тел сүзләре тизрәк үтеп керә. Рус телендә төрки-татар сүзләре, татар телендә славян-рус сүзләре яшәп килүенә галимнәр күптән игътибар иткәннәр. Вл. Даль, И. Срезневский һ.б. танылган галимнәрнең сүзлекләрендә аеруча зур мәгълүмат тупланган. Е. Шипованың «Словарь тюркизмов в русском языке» (1976) дигән хезмәтендә ике меңгә якын сүз теркәлгән. Р. Юналиева хезмәтләрендә дә (2000, 2005) бу төр лексика турында шактый бай материал бирелә.

Татар тел белемендә рус һәм рус теле аша кергән Европа алынмаларын Р. Бурнашева (1952), Ә. Ахунҗанов (1968), Р. Йосыпов (1980), И. Абдуллин (1990), Ә. Йосыпова (1994, 2008, 2012), Ф. Сафиуллина (1999; 2002), М. Хәйруллин (2000, 2001), Р. Мөхиярова (2000), Р. Нурмөхәммәтова (2007), Е. Абдуллин (2007) һ.б. өйрәнгән.

Ә. Ахунҗанов татар теленә рус алынмалары керү вакытын 5 дәвергә бүлеп карый:

I дәвер (IX–XVI йөзләр);

II дәвер (Казан ханлыгының яулап алынуыннан XVIII гасыр азагына кадәр);

III дәвер (XVIII гасыр азагыннан беренче рус инкыйлабына кадәр);

IV дәвер (XIX йөз азагыннан Октябрь инкыйлабына кадәр);

V дәвер (Октябрь инкыйлабыннан соң) (Ахунзянов, 1968: 66–67).

Бу бүленеш татар лексикологиясендә шактый дәрәҗәдә әһәмиятле роль уйнады. Шуның белән бергә, татар тел белеменең хәзерге торышыннан чыгып күз салганда, әлеге бүленешкә кайбер үзгәрешләр дә кертергә мөмкин.

Ф. Сафиуллина бу бүленешкә XX гасырның 80 нче еллар азагында башланган туган телне демократияләштерү процессын хаклы рәвештә аерым чор итеп карарга тәкъдим итте (Сафиуллина, 1999: 67).

Мең еллар буе телебезгә керә килгән рус алынмаларының төгәл вакытын һәм хронологиясен төгәл һәм ачык билгеләү мөмкин түгел. Шуңа күрә китерелгән бүленеш, нигездә, чынбарлыкка туры килә дип санарга мөмкин.

XX гасырның 60 нчы елларыннан соң фәндә яңа мәгълүматлар билгеле булды һәм I дәверне, зур тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә һәм славян теленә төркиләрдән, шул исәптән болгарлардан да сүзләр керүе турында соңгы тикшеренүләргә нигезләп, икегә бүлеп карарга була: борынгы чор һәм XII–XIII йөзләрдән XVI йөзгә кадәр булган чор. Бу чорлар монгол яулары, Болгар дәүләте җимерелү һәм «Игорь полкы турында җыр» әсәре язылу кебек әһәмиятле тарихи вакыйгаларны колачлый.

Беренче дәвер – борынгы чор – буенча язма чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Ә. Ахунҗанов китергән сүзләрнең (*арыш, сука,*

*салам, буразна, ужым, әвен, мич, эскерт, умарта, кәбестә, керән, борыч, изба, бүрәнә, матча, фонарь лакан, мичкә, бәрән, гөрәнкә* һ.б.) кайберләренең татар теленә үтеп керү вакытын анык билгеләп була. Мәсәлән, *гөмбә, көнҗәлә* сүзләре көнчыгыш славяннарда (Фомина, 1978: 138) борын сузыклары юкка чыкканчы булган *губа, куделя* вариантларыннан дип саналалар, *борыч, гөрәнкә, матча, кәбестә, умарта, ужым* сүзләре XI–XII гасырлардан ук төрле язма чыганакларда теркәлгәннәр. *Эскерт, буразна, салам* сүзләре хәзерге Идел буендагы телләрдә – татар, чуваш, башкорт телләрендә генә күзәтелә. Ә. Ахунҗанов өйрәнгән һәм татар теленә I дәвердә кергәннәр дип күрсәтелә торган сүзләрнең бер төркеме Коман мәҗмугасында (XIII гасырның азагы – XIV гасырның башында төзелгән) теркәлгәннәр: *кучкар, лахан, фанар, мич, ызба, салам*, ә 1245 елда төзелгән кыпчак сүзлегендә *учак, борыч* сүзләре теркәлгән. Бу факт әлеге сүзләрнең күрсәтелгән сүзлекләр төзелгән вакыттан күпкә элек Идел буе болгарлары телендә киң кулланылышта булулары турында фараз итәргә мөмкинлек бирә.

I дәвернең икенче яртысы Болгар дәүләтенең җимерелүе, Алтын Урда дәүләтенең яшәеше һәм элекке Болгар дәүләте хәрабәләрендә әкренләп оешкан Казан ханлыгы дәүләтчелеге шартларында уза. Ә. Ахунҗанов материалларыннан күренгәнчә, әлеге чорда түбәндәге рус алынмалары кергән: *кораб, керән, әвен, эскерт.*

Татар теленә XVI гасырга хәтле кергән *арыш, мүк, элән* (җитен), *сука, буразна* һ.б. алынма сүзләр дә шушы ук чорга карый булса кирәк. Танылган этимолог Р. Әхмәтьянов *әвен* сүзенең рус алынмасы булуы бәхәсле икәнлеген искәртә (Әхмәтьянов, 2015: 123). Шушы ук рәткә тагын бик күп телләрдә таралган *бәрән* сүзен дә өстәргә кирәк (Әхмәтьянов, 2015: 175).

II дәвер үзенчәлекле тарихи эпоханы тәшкил итә. Казан ханлыгының үз бәйсезлеген югалтуы, Рус дәүләте составында, аңа буйсынган хәлдә булуы татар теленә рус теле элементларының үтеп керүен бермә-бер интенсивлаштыра торган сәбәп була. Административ, идарә эшләре, көнкүреш белән бәйле эш кәгазьләре, кыскасы, һәртөрле документлар рус идарәчелеге органнарында рус телендә языла башлыйлар.

Бу чорда рус алынмалары татар теленә нигездә ике юл белән керә: 1) язма эш кәгазьләре аша, 2) сәүдә һәм башка төрле аралашу барышында.

Дәүләт идарәсе, иҗтимагый тормыш, төрле грамоталар язу, инструкцияләр, законнар чыгару һ.б. төрле язма документлар әзерләү, аларны халыкка җиткерү барышында рус сүзләрен татарча язылган төрле язмаларда куллану гадәти күренешкә әверелә.

Алтын Урда чоры документлары, битигләр, хан ярлыклары гарәп-фарсы, госманлы төрекләре алынмалары катнашкан татар телендә төзелсә (шундыйлардан 1523 елда язылган Сәхиб-Гәрәй ярлыгы безнең чорларга килеп җиткән), Рус дәүләте составындагы чор документлары, рус сүзләрен дә кулланып, саф татар телендә языла торган булганнар. 1701 елдан башлап татар телендәге эш кәгазьләрен канцелярияләрдә рус теленә тәрҗемә итү мәҗбүригә әйләнә. Шулай итеп, татар теленә рус сүзләре керүнең бер ысулы, юнәлеше формалаша башлый.

Документларда, аеруча татар халык сөйләм телендә язылганнарында, рус сүзләре күпләп кулланыла башлый, рус административ терминологиясен һәм тормыш-көнкүреш лексикасын эш кәгазьләрендә чагылдыру татар теленә рус сүзләренең үтеп керү тарихын өйрәнү өчен ышанычлы материал булып тора (Ахунзянов, 1968: 89–90). Мәсәлән, Аликей Аталык тарафыннан 1636 елда калдырылган васыятьтә «Михаил Федорович всей русиның ярлыгы һәм уложениясе берлән», «сатып алган немеч марҗам» кебек канцелярия стиленә хас трафарет әйләнмәләр күзәтелә (Ахунзянов, 1968: 90).

1613 елгы «Мәскәү боярларының Нугай морзаларына язылган грамота»сында *уйбуда* (воевода), *жатман* (гетман), *нәймич* (немец), *каруль* (король), *йәүни* (явный) һ.б. рус алынмалары теркәлгән. 1695 елда С. Маленькийга бирелгән грамотада *купчина, буса* (корабльнең бер төре), 1673 елгы грамотада *боярин, воевода, дьяк* сүзләре кулланылган.

XVIII гасыр азагына караган документларда түбәндәге сүзләр теркәлгән: *указ, команда, округ, уезд, дзам* (юл)*, паспорт, пошлина, почта, печать* һ.б. (Ахунзянов, 1968: 93–94).

1701 елдан башлап, татар телендәге эш кәгазьләре мәҗбүри рәвештә рус теленә тәрҗемә ителә башлагач, татар теленә рус сүзләре керү тагын да активлаша, ныгый бара.

XVI гасыр азакларыннан башлап, XVII гасырларда жанр ягыннан төрле характерда төзелгән, татарчага тәрҗемә ителгән күпсанлы эш кәгазьләре сакланган. Мәсәлән: Нугай морзаларына,

Иранга, Һиндстанга, Бохарага һәм башка чит җирләргә баручыларга, шаһларга һ.б.га бирелгән грамоталар; патша тарафыннан игълан ителгән указларның, Петр I чыгарган «Манифест»ның, башка төр язмаларның татарчага тәрҗемәләре; Пугачев күтәрелешенең татар телендә алып барылган эш кәгазьләре, төрле сәүдә документлары һ.б. Бу документларда рус сүзләренең күпчелеге әйтелеш буенча языла торган булганнар. Мәсәлән, Нугай морзаларына 1613 елда Мәскәү боярлары тарафыннан язылган грамотада мондый рус сүзләре һәм гыйбарәләре кулланылган: *уйбуда* – воевода, *нәймичдән*, *жатман* (гетман), *каруль* (король), *Либка* – Литва, *йәүни* (явно), *ор* (вор), *бояр* һ.б. Петр I «Манифест»ында *чиру* // армия (Ахунзянов, 1968: 91) кебек алынмалар кулланылган.

Көнчыгыш илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр дә татар телендә языла торган булганнар, аларда да инде рус сүзләре кулланылган булуы билгеле: *купчина* (сәүдәгәр), *бус* – судно, *дьяк, воевода, боярин* һ.б.

Соңга таба рус алынмаларының кулланылышы арта: *указ, команда, округ, уезд, паспорт, пошлина, почта, почтовый, печать, июль* һ.б. сүзләр актив кулланылышка керә. Пугачев күтәрелеше документларында аеруча армия, сугыш белән бәйле рус алынмалары активлашып китә: *Всероссийский император Петр Федорович, именной указ, военная коллегия, полковой сотник, указ, копия, порох, армия, генерал, майор, капитан, крестьянин* һ.б. *Крестьян* сүзе татарларга шушы күтәрелеш чорында килеп кергән булса кирәк.

Пугачев явы документларының бер төркеме төрле гаризалар, актлар, атаманнарның рапортларыннан гыйбарәт. Аларда көндәлек тормыш-көнкүреш, хуҗалык эшләре белән бәйле рус сүзләре күп чагылган: *полковник, капрал, бригадир, старшина, рипурт/работ, ордер, булын/пулун полон* (плен), *челобитная* (гариза, үтенеч язуы), *изменник, завуд, чайник, стопка, хомут, пихутный ыстаршина, правуз* (кичү), *хутор, скамья, сухари, губернатор, атаман, полк, крепость, бунтовщик, пичәт, бунт, ыстина* һ.б

Бу документларда татарча әйтелештә язылган сүзләрнең аеруча үзенчәлеклеләре: *правуз* (перевоз), *порам* (паром), *глаунай пулкувник, мисти* (милостивый), *былгадир, чулупитә* (челобитная), *явышнай* (явочная) һ.б.

Тагын шунысын ассызыклап үтәргә кирәк: XVII гасырга Мәскәү приказ теленең нормалары һәм структурасы формалашып

җитә. Рус эш кәгазьләренә хас терминнар татар эш кәгазьләрендә дә кулланылалар. Мәсәлән: *илче/пасланник, язучы/дийак* сүзләре параллель йөртелә башлый. Шәхси исемнәр, идарә органнарының русча исемнәре, халыкара мөнәсәбәтләрне белдерә торган атамалар эш кәгазьләре текстында урын алалар. Дәүләтара мөнәсәбәтләрне белдергәнгә күрә, эш кәгазьләрендә иҗтимагый-сәяси һәм иҗтимагый-икътисади лексика активлаша: географик, административ-территориаль атамалар, сәүдә, идарә һәм югары хакимият органнары белән бәйле лексика һ.б.

XVII йөздә рус алынмалары иске татар әдәби теленә дә керә башлый, эш кәгазьләрендә күп кенә яңа, моңарчы кулланылмаган рус сүзләре, атамалары, ай исемнәре күренә: *кенәз, акалнычай* (окольничий), *wайыwуда* (воевода), *папаримыскай* (папа римский), *пулкуник* (полковник), *истирәлче* (стрелец), *июнь, агуст, нуябрь* һ.б. Бу сүзләр эш кәгазьләре стиленең үсеш-үзгәрешендә чагылыш таптылар, XVIII–XIX йөзләрдә төзелгән сүзлекләрдә дә шактый зур урын алдылар (Юсупова, 2008: 289–329).

Нәтиҗәдә, XVI–XIX йөзләрдә кергән рус сүзләренең бер төркеме, чагыштырмача сирәк кулланылганга күрә, еллар үтү белән архаизмнарга әйләнәләр (*откуп, дворянская опека, асессор* һ.б.), бер төркеме исә халык, сөйләм телендә нык урнашып кала (*губерния, надзиратель, расчет, пай, офицер, порука, понятой* һ.б.), рус алымнарының бер өлеше бөтенләй татарлашып беткән, аларның алынма икәнлеге дә сизелми (*сумала, дегет, фабрик, стена, сохари, рәт* һ.б.), алар татар теле таралган барлык төбәкләрдә дә кулланыла.

XVIII гасыр азагына караган документларда, мәсәлән, Екатерина II законнарының татар теленә тәрҗемәсендә түбәндәге рус алынмалары кулланылган: *икунамия* (экономия) *дирикторы, залук, расчут, ыштыраф, капитал, заклад, доход, расход, фабрика, завуд, банкрот, ярминкә, пригувыр, суд, сутлашу, сутлашучы, сутка тарту, дегет, сумала, биршук* (вершок)*, фанар, пристен.* Шунысы игътибарга лаек: әлеге документта төрки телле язма эш кәгазьләрендәге традицион татар сүзләре урынына рус алынмалары кулланылганлыгы күзгә ташлана: *канцелярия* (диванханә), *ыштатный команда* (махсус гаскәр), *гуруднич*ә (шәһәр назире), *пунәтуй* (шаһит), *пугриб* (баз), *сажин* (ике колач), *журнал* (дәфтәр), *дунус* (хәбәр), *доктор* (табип), *землемер* (җир үлчәүче), *крепость* (кальга), *университет* (олуг мәдрәсә), *семья* (гаилә).

Бер төркем рус алынмалары татар телендә яшәп килә торган гарәп-фарсы алынмаларын алыштырган: *ревизия* (игадә), *отставка* (газәл ихтыяр), *комендант* (калгабан рәисе), *завод* (кярханә), *фабрика* (сәнагатьханә).

Китерелгән материалларның зур күпчелегендә алынма сүзгә татар яки гарәп-фарсы эквивалентлары белән *ягъни…* рәвешле аңлатма (*доктор, ягъни табип, землемер, ягъни җир үлчәүче мөхәндис, комендант, ягъни калгабан рәисе, университет, ягъни олуг мәдрәсә* һ.б.) бирәләр, ә кайбер алынмаларга аңлатма бирелми (мәсәлән, *семья, сажень* һ.б.). Ә. Ахунҗанов әлеге мисалларда тәрҗемәчеләрнең рус алынмасын кулайрак дип табуларын, аларга өстенлек бирергә омтылуларын ассызыклап күрсәтә.

Бу чорда рус алынмалары фонетик яктан үзләштерелгәннәр, шул вариантта, сөйләм телендә генә түгел, язуда да кулланылганнар. Әйтергә кирәк, рус сүзләренең язма эш кәгазьләрендә теркәлгән әйтелеш үзенчәлекләре хәзерге татар сөйләм телендә, ягъни җирле сөйләшләрдә һаман да сакланып килә.

Шулай итеп, II дәвердә Казан ханлыгының җимерелүе, бәйсезлеген югалтуы рус дәүләте составындагы тәртипләргә күчәргә мәҗбүр булуы, бөтен эш кәгазьләрен рус телендә формалаштыру кебек факторлар татар теленә рус алынмаларының күпләп керүенә китерә.

XVIII йөз азагы – XIX йөзләрдәге татарча язма эш кәгазьләрендә яңа рус алынмалары теркәлгән: *банкрот, приговор, донос, взыскание, устав, донесение, протокол, прошение* һ.б. Язма эш кәгазьләрендә зур өлешне көндәлек тормыш белән бәйле сүзләр алып тора: *деготь, смола, сажень, вершок, фонарь, пристань* һ.б. Шулай итеп, яшәү-тормыш шартлары, гамәли ихтыяҗлар татар теленә рус сүзләренең интенсив рәвештә үтеп керүенә, гади халыкка авыр аңлашыла торган гарәп-фарсы алынмаларын рус сүзләре белән алыштыруга китергән. Мәсәлән, *семья* (гаилә), *мөхәндис* (инженер), *ревизия* (игадә), *ыштыраф* (җәримә) һ.б. *Дегет, сумала, стена, рәт, сухари, мидаль, фабрик, завут/завод* кебек сүзләрнең алынма икәнлеге телдә сизелми дә башлый.

XVII–XIX йөзләрдә татар телендә кулланылышта булган рус сүзләре сүзлекләрдә дә чагылыш тапкан. Билгеле булганча, Рус дәүләте Кавказ, Урта Азия, гомумән көнчыгыш халыклары белән дипломатик, сәүдә һәм башка төрле мөнәсәбәтләр урнаштыру ча-

раларын күрә. Бу мөнәсәбәтләрдә аралашу теле, дипломатия теле булып татар теле хезмәт итә. Югары әзерлекле тәрҗемәчеләр, тылмачлар булдыру үзәк мәсьәләләрнең берсенә әверелә. Моның өчен Казан, Тубыл, Самара, Омск һ.б. шәһәрләрдә гимназияләр ачыла, семинария училищеларында татар теле укытыла башлый. Анда татар телен яхшы белгән зыялылар, дин әһелләре, миссионерлар укыта, алар тарафыннан күп кенә русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр төзелә. Ә. Ахунҗанов (1968), Ә. Йосыпова (2008), Ф. Хисамова (1981; 1990) хезмәтләрендә ул сүзлекләргә тирән эчтәлекле анализ бирелгән.

XX гасыр башында татар теленә рус алынмалары керү башка төрле шартларда бара. Татар теленең генә түгел, рус сүзләрендә дә әдәби норма үзәк урында тора. Авыл тормышында барган зур үзгәрешләр нәтиҗәсендә татар теленә, русларныкы белән бергә, Европа алынмаларының күпләп керүе күзәтелә: *партия, коммунист, агроном, бригада, автоматика, двигатель, курорт, класс, клуб, комбайн, комбайнер, силос, ударник, пьеса, театр. телефон* һ.б. Мондый алынмалар татар халык җырларында да актив сүзләр рәтендә кулланылалар.

Рус һәм Европа алынмаларын кабул итү Октябрь инкыйлабына кадәрге чорда татар теленең сөйләм теле закончылыкларына буйсындырыла, бу фонетик закончалыклар хәтта язма эш кәгазьләрендә дә чагыла. Октябрьдан соң исә алынмаларны, нигездә, әдәби нормалашкан язма тел аша кабул итү төп урынны алып тора.

В. Хаков, XIX йөз азагында татар әдәби теленең сүзлек составы яңа мәгънәләрне һәм төшенчәләрне белдерә торган яңа сүзләр исәбенә баеды, дип күрсәтә (Хаков, 1963). Мәсәлән: *арестант, жандарм, коридор, карантин, электр, почта, телеграф, мода, пианино, консул, аквариум, салон, скрипка, павильон, салон, балет, панорама, микроскоп, композитор, бюст, профессор, эрмитаж* һ.б. Татар демократик матбугатының үсүе публицистик стильнең җәелүенә, үсүенә китерә һәм шушы процесста да, гарәп-фарсы сүзләре кысрыкланып, рус алынмаларының активлашуы күзәтелә. Бу исә киләчәктә демократик татар әдәби теле формалашуда зур роль уйный. Мәсәлән, *социал-демократическая партия, пролетариат, самодержавие, забастуфка* кебек сүзләр XX гасыр башындагы прокламацияләр, листовкаларда актив кулланыла башлыйлар.

Шулай итеп, IV дәвер дип билгеләнгән әлеге чорда төрле тармакларга караган рус һәм Европа алынмаларының татар лексик фондына керә һәм урнаша баруы дәвам итә. Алар арасында буржуаз җәмгыять һәм сәяси тормыш белән бәйле яңа сүзләр дә күзәтелә.

Җәмгыять ихтыяҗларына җавап рәвешендә үсеш-үзгәреш кичерә барган телебезнең лексик фонды иҗтимагый факторларга тизрәк сизгерлек күрсәтә. Шул ук вакытта, тарих барышында җәмгыятьтә барган зур үзгәрешләр фонында телнең сүзлек составы капма-каршы ике күренешкә дучар ителә. Беренчедән, үзгәрешләр алып килгән идеологик эчтәлекле неологизмнар барлыкка килә; икенче яктан, искелек белән бәйле сүзләр искерә, кулланыштан төшә бара.

Инкыйлабтан соңгы җәмгыяви үзгәрешләр рус алынмаларының эчтәлеген яңарта. Яңа төшенчәләрне белдерү зарурлыгы, Европа мәдәниятенә омтылыш, цивилизацияле илләргә тиңләшергә тырышу белән бәйле рәвештә татар телендә яңа лексика барлыкка килә. Иң әһәмиятлесе шунда: кулланышка интернациональ сүзләр актив рәвештә керә башлый.

Һәр тарихи этапта алынмалар кабул итүнең үзенчәлекле билгеләре бар. Мәсәлән, инкыйлабка кадәр рус алынмалары татар теленә, нигездә, сөйләм теле аша керсәләр, аннан соң бу процесс, башлыча, язма тел аша бара һәм русча язылышта һәм әйтелештә кулланыла.

Инкыйлабка кадәр СССР территориясендә яшәүче, руслардан кала, башка милләт халыкларының телләрендә рус теленнән кергән алынмалар уртача 25–50 сүз тәшкил иткән булса, 40 нчы еллар башына күпчелек төрки телләрнең лексик системасында бу сан 500 гә җитә (Закономерности…, 1969: 32).

Р. Нурмөхәммәтова XX гасырның беренче яртысында татар әдәби теле лексикасының үсеш тенденцияләрен тикшерүгә багышланган хезмәтендә 1913 (С. Рахманколый), 1927 (төз.: М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев), 1931 (төз.: М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев), 1950 елларда (төз.: Р. Газизов, Н. Исәнбәт, Г. Ишмөхәммәтов) чыккан «Татарча-русча сүзлек»ләрдәге рус-европа алынмаларын статистик аспектта тикшерә. Әлеге сүзлекләрдә теркәлгән рус-европа сүзләренең санын түбәндәгечә билгели: 1913 елда – 80 сүз, 1927 елда – 1100 сүз, 1931 елда – 1900 сүз, 1950 елда – 2000 нән артык. Шулай итеп, татар телендә рус алынмаларының

саны 1913 елда сүзлектә урнаштырылган барлык сүзләр санының 0,8% ын тәшкил итсә, 1950 елда исә алынмалар 10% ны тәшкил итәләр (Нурмөхәммәтова, 2007: 125).

Әлеге чорда гарәп-фарсы һәм рус-европа алынмалары арасында конкурентлык та барлыкка килә. Мәсәлән, 1931 елгы сүзлектә чагылыш тапкан параллельләр шул турында сөйли: *көтепханә* – библиотека, *җәдвәл* – таблица, *җәзбә* – циркуль, *җөмһүрият* – республика, *дәһри* – атеист, *әмер* – приказ, *әсас* – базис, *гәрәбә* – янтарь, *һәйкәл* – памятник, *ислах* – реформа, *мантыйк* – логика, *матбуга* – типография, *маузуг* – тема, *мәләкә* – практика, *мохтарият* – автономия, *нәсия* – заем, *низам* – закон һ.б.

1927 һәм 1931 еллардагы сүзлекләрне чагыштырып чыгу алынма сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын рус телендәгечә куллану тенденциясе җиңә баруын күрсәтә. Сүзләрне үзгәртмичә кабул итү алымы өстенлек итә, шул язылыш әдәби тел нормасына әверелә (Хаков, 1985: 81). 1931 елгы сүзлектә рус һәм Европа алынмаларында әйтелеш белән язу очраклары да күзәтелә: *гәзит* – газета, *лингвис* – лингвист, *марксис* – марксист, *аптик* – аптека, *брониноc* – броненосец һ.б. 1950 елгы һәм аннан соңгы татарча-русча сүзлекләрдә рус-европа алынмалары бары русча әйтелештә генә биреләләр.

Яңа татарча-русча сүзлекләр чыккан саен, аларда рус-европа сүзләре сан ягыннан арта баралар. Мондый күренеш илдә барган сәнәгать-техниканың үсеше, авыл хуҗалыгындагы зур үзгәрешләр һ.б. белән бәйле. Р. Нурмөхәммәтова тикшеренүләре яңа рус-европа алынмалары арту тормышның барлык тармакларында да күзәтелүен дәлилли (Нурмөхәммәтова, 2007: 139–141).

Шул ук вакытта күп санлы алынмаларны лексикографик эшкәртү мәсьәләләре дә туа. Аеруча алынма сыйфатларны нормалаштыру зарурлыгы көн тәртибенә баса. Нәтиҗәдә түбәндәге кагыйдәләр кабул ителә һәм сүзлектә чагылыш таба.

*-ический, -истский* кушымчаларына беткән сыйфатларны татар теленә *-к* кушымчасы белән тәрҗемә итү: анатомический – *анатомик*, антогонистический – *антогонистик*, марксистский – *марксистик* һ.б.

*-онный, -ивный, -альный, -льный, -арный* кушымчаларының *-ный* өлеше кыскартыла: комиссионный – *комиссион*, оппозиционный – *оппозицион*; коллективный – *коллектив*, активный – *актив*

һ.б.; диагональный – *диагональ*, реальный – *реаль*, монументальный – *монументаль* һ.б.; легендарный – *легендар*, молекулярный – *молекуляр*, элементарный – *элементар* һ.б.

Татар теленең алынмалар исәбенә баюы дәвам итә. Рус-европа алынмаларының бер өлеше татар телендә үзләшеп бетә, аларның кулланылыш активлыгы арта. Алынмалар XX гасыр урталарыннан татар телендә яңа сүзләр ясауда да актив катнаша башлыйлар. Бу күренешнең мисаллары 1931 елгы сүзлектә үк теркәлгән. 1950 елгы сүзлектә рус-европа тамыр сүзләреннән яңа сүзләр ясалуның активлашуы ачык чагыла.

Шулай итеп, рус-европа алынмалары XX гасыр буена арта бара, алар инде үзләшеп беткән гарәп-фарсы алынмалары һәм хәтта чын татар сүзләре урынына да кулланыла, сүзлекләрдә урын ала башлыйлар.

XX гасыр азагындагы үзгәртеп кору чорында, җәмгыятьнең бөтен өлкәләрендә, шул исәптән туган телне торгызу, аны демократияләштерү юнәлешендә башланган хәрәкәт татар теленең сүзлек фондының үсеш-үзгәреше, алгарышы мәсьәләләрендә турыдан-туры чагылыш тапты.

Илдә иҗтимагый-сәяси, спорт, мәдәни-икътисади тормыш Көнбатыш үрнәгендә үзгәртеп корыла башлады һәм шул өлкәләр белән бәйле рус-европа алынмаларының күпләп татар теленә үтеп керүенә китерде. Бу процесс гаять тиз бара, ә алынмаларны татарчалаштыру, татарча эквивалентларын тәкъдим итү юнәлешендә эш акрын бару сәбәпле, чит тел сүзләре эшкәртелмәгән вариантта телебезгә үтеп керүләрен дәвам итәләр.

Галимнәрнең күзәтүенчә, соңгы елларда кергән алынмаларның 70% ы инглиз теленнән икәнлеге ачыкланган, ә француз (*анклав, кадастр, коллаж, сертификат, сутенер, дискета, интерпол*), итальян (*мафия, мафиози, пицца*), алман (*менталитет, путч, паритет*), испан (*хунта, фейхоа*) телләреннән сүзләр аз кергән (Мөхиярова, 2000: 129).

Татар теле лексик фондының үсеш-үзгәрешендә үзгәртеп кору чоры белән бәйләнешле тагын бер әһәмиятле юнәлеш – электән үзләштерелгән рус-европа алынмаларында семантик-стилистик үзгәрешләр барлыкка килү. Яңа тормыш шартлары, ориентация үзгәрү, чит илләр белән товар алмашу кебек күренешләр алынма сүзләрнең мәгънәләре тараю яки киңәю, пассивлашкан мәгънәләр-

нең актуальләшүе кебек семантик тайпылышлар китереп чыгара. Мәсәлән, *демократия* сүзенең «сәяси корылышның югары идарә халык кулында булырга тиеш дип каралган төре» (ТТАС, 2005: 141) дигән аңлатмасы урынына җанлы сөйләмдә «ни теләсәң шуны эшләү яки әйтү мөмкинлеге» дигән мәгънә төсмере үсә бара. Шундый ук характерда мәгънәсен киңәйткән мондый сүзләрне күрсәтергә мөмкин: *банкрот, квота, калькулятор, конверсия, лицензия, реабилитация, репрессия, чек, юрисдикция* һ.б. Ә *дотация, инвестор, коммерсант, суверенитет, компенсация, недоимка* кебек сүзләрнең кулланыш даирәләре киңәйгән, стиль ягыннан да алар башка тармаклар белән бәйле, я нейтраль сүзләр рәтенә урнашканнар.

Кайчандыр капиталистик җәмгыятьтә генә кулланыла торган яисә искергән яки тарихи *мэр, префект, колледж, лоббист, коммерция, меценат, акциз, акционер, концерн, биржа, офис, казначейство, фермер, антрепенер, губерна, департамент, вице-губернатор, гимназия, лицей, колледж, бакалавр* кебек чит ил реалиясе буларак кына билгеле булган сүзләр активлашып киттеләр яки кулланылышка кире кайттылар.

Болардан тыш, бик сирәк һәм тар даирәдә генә кулланылган һәм хәзер тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә актуальләшеп киткән бер төркем сүзләрне аерып чыгарырга кирәк: *декларация, референдум, парламент, фракция, премьер-министр, вице-премьер, президент, президент киңәшчесе, вексель, кооператив, полис, гран-при, коттедж, депозит, дивиденд, инвестиция, инфляция, эмиссия, босс, делец, демократ, наместник* һ.б.

## § 12. Рус һәм Европа алынмаларының генетик һәм лексик-тематик катламнары

Татар телендәге бу төр алынмаларга генетик яктан күптөрлелек хас, чөнки татар теленең лексик фондында рус теле аша кергән Европа алынмалары да бар. Алар арасында француз, алман, инглиз, итальян, испан һәм башка көнбатыш телләрдән кергән сүзләр очрый. Татар телендә борынгы грек һәм латин чыгышлы сүзләр кулланышта булуын да искәртеп үтик. Алар да, башлыча, рус теле аша кергәннәр.

Интернациональ (халыкара) сүзләр. Тел белемендә кардәш булмаган өч яки аннан артык тел өчен һәм әйтелеше, һәм

мәгънәсе ягыннан аңлаешлы булган, халыкара эчтәлектәге, фән һәм техника, сәясәт, мәдәният, сәнгать өлкәләренә караган алынма сүзләр интернациональ лексика дип атала (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 197).

Интернационализмнарның гомумкешелек фондын баетуда роле зур. Генетик-типологик яктан төрле булган телләрдә гомумтерминологик фондның кулланылышта булуы закончалыклы күренеш дип санала. Бер мәгълүмати киңлектә һәм алга киткән интеграция шартларында, компьютерлаштыру һәм интернет челтәре киңәя барган чорда интернационализмнар шулай ук арта бара (Хайруллин, 2006: 248, 361).

Шулай итеп, килеп чыгышы ягыннан халыкара сүзләр татар телендә дүрт төркемгә бүленеп карала: 1) Европа телләреннән кергән сүзләр, 2) рус теленнән кергән алынмалар, 3) гарәп һәм фарсы сүзләре, 4) кытай һәм япон алынмалары.

Халыкара лексиканың чикләре, характеры турында төрле фикерләр бар. Мәсәлән, Россия составындагы халыклар өчен уртак булган сүзләрнең интернациональ булу-булмавы да төрле бәхәсләр уята. Шулай ук гарәп-фарсы сүзләренең кардәш булмаган өч яки аннан да артык телләрдә кулланылуы мәгълүм. Совет чорында телебезгә килеп кергән *комсомол, колхоз, коминтерн, тракторист, комбайнер, агитатор комиссар, спутник, космонавт* кебек сүзләр күп халыкларның төп лексик фондында урын алдылар. Уртак лексик фондта төрле милләтләрнең исемнәре дә урын алды: *татар, чуваш,башкорт, кыргыз, якут, чукча, ороч, ульч, мари, балкар* һ.б.

Телдәге һәрбер күренеш кебек, интернациональ лексика да төрле үзгәрешләр кичерә. Мәсәлән, югарыда күрсәткән *комсомол, колхоз* кебек сүзләр искергән лексика составына күчеп, кулланылыштан төшеп калдылар.

Аерым телләр тарихында интернациональ сүзләрне телнең үз сүзләре белән алыштырырга омтылышлар ясалды: мәсәлән, татар телендә *президент* урынына *илбашы*, *физик* урынына *тәнси* һ.б. шундый тәкъдимнәр булды, тик алар халыклашып китмәделәр.

Түбәндә төрле чыганакларга караган халыкара сүзләрнең лексик-тематик төркемнәренә кыскача күзәтү ясала.

**Латин** сүзләре сәнәгать, техника, хәрби өлкә белән бәйле лексемаларны тәшкил итәләр. Мәсәлән: *аппарат, агрегат, генератор, комбинат, вибрация, мотор, мануфактура, инкубатор,*

*авиация, адъютант, агрессия, дивизия, интервенция, позиция, оккупация, мобилизация, эвакуация* һ.б.

Административ-дәүләт эшләрен, иҗтимагый-сәяси, икътисади төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *республика, диктатура, демократия, социализм, империализм, конституция, либерализм, материализм, гуманизм, декларация, директива, делегат, интернационал, пролетариат, территория, пленум, конгресс, президиум, реакция, депрессия, колония, дебет, кредит, ревизия, актив, пассив, аккредитив, конкуренция консул, нейтралитет, прогрессив, эволюция, эмигрант* һ.б.

Фән, медицина белән бәйле төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *академия, абстракция, атрибут, аспирант, объект, диспут, дискуссия, максимум, минимум, конференция, препарат, обсерватория, форум, молекула, индукция, субъект, инстинкт, университет, факультет, декан, доктор, доцент, кандидат, лаборант, интернат, аттестат, конспект, рецензия, консультация, амбулатория, ампула, вакцина, инфаркт, витамин, операция* һ.б.

Әдәбият, сәнгать һәм мәдәнияткә караган төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *культура, публикация, легенда, автор, вокаль, вариация, оригинал, орнамент, иллюстрация, статуя, композитор, репетиция* һ.б.

Рус теле аша **грек** сүзләре дә алынган. Аларны түбәндәгечә төркемләп була:

1) фән-техника, медицина төшенчәләрен белдерә торган сүзләр: *астрономия, ботаника, биология, гигиена, география, геодезия, логика, геология, диалектика, морфология, филология, гидрология, зоология, физиология, орфография, педагогика, оптика, философия, экономика, эстетика; атмосфера, аэростат, барометр, анахронизм, гипотеза, гипноз, галактика, механика, микроскоп, магнит, призма, метод, планета, семафор, электр; диагноз, поликлиника, психика, склероз* һ.б.;

2) иҗтимагый тормыш-сәясәт белән бәйле төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *монархия, гегемония, катастрофа, гимн, династия, демократия, антогонизм, анархизм, автономия, монополия, утопия, политика, тиран, деспот, стратегия, метрополия, патриотизм, кризис; амнистия, программа, система, стихия, фантазия, синдикат, стадион, пирамида, категория, график, варвар, ипподром, период, автомат, автобиография, амнистия* һ.б.;

3) әдәбият, сәнгать, мәдәният өлкәсенә караган сүзләр: *диалог, антитеза, баритон, анапест, амфибрахий, аллегория, драма, пародия, псевдоним, поэма, ода, сарказм, метафора, лирика, ритм, музей, симфония* һ.б.

Татар телендә чыгышы белән **француз** теленнән булган һәм рус теле аша кергән сүзләр дә шактый табыла. Алар шулай ук тормыш-көнкүрешнең төрле өлкәләре белән бәйле:

1) әдәбият-сәнгать өлкәсенә караган сүзләр: *ансамбль, дирижер, премьера, антракт, авансцена, бюст, бенуар ложасы, беллетристика, бельэтаж, грим, жанр, декорация, декада, увертюра, мотив, репертуар, фельетон, марш, куплет, сюжет, пейзаж, пьеса, романтизм, персонаж* һ.б.;

2) иҗтимагый-сәяси тормыш, идеология өлкәсенә караган сүзләр: *ассамблея, апартамент, бюро, бюрократ, буржуа, авангард, баррикада, декрет, блок, дипломат, паспорт, жандарм, коммюнике, раса, идеализм, идеал, партия, революция* һ.б.;

3) хәрби лексика: *батарея, блиндаж, амбразура, траншея, батальон, гарнизон, атака, контузия, кавалерия, гвардия, тир, маневр* һ.б.;

4) тормыш-көнкүрешнең төрле якларын белдергән сүзләр: *девиз, деталь, баланс, афиша, анонс, аллея, брошюра, жаргон, жонглер, интендант, карьера, культиватор, комиссар, конвой, карантин, лупа, лотерея, мораль, массаж, медальон, миссионер, парад, прожектор. парашют, перрон, патруль, метро, минерал, туризм, трамплин, тонна, тамбур, пляж, монтаж, манеж, вестибюль, визит, витрина, газон, бандероль, дуэль, конвой, монтер, мандарин, пилот, педант, реплика, резерв, ферма, фонд, тираж* һ.б.

Татар теленә рус теле аша **алман** теленнән дә алынмалар үтеп кергән, алар бигрәк тә хәрби өлкәгә, һөнәр исемнәренә карыйлар: *биржа, вахта, абзац, ландшафт, ракета, шлагбаум, турнир, бруствер, гастроль, лейтмотив, ракета, гауптвахта, шпион, гаубица, фокус, цейтнот, штанга, шаблон, штамп, масштаб, штат, тахта, рейс, штурм, флагман, граф, полиция, шаблон* һ.б.

Телебезгә **инглиз** теленнән рус теле аша спорт, сәүдә, иҗтимагый-сәяси һәм диңгез эшләре белән бәйле сүзләр кергән: *бокс, теннис, волейбол, футбол, баскетбол, чемпион, рекорд, старт, финиш, хоккей, тренер, матч, спорт, блокада, бойкот, мичман, комбайн, аврал, танкер, лайнер, гангстер, пионер, лидер, троллей-*

*бус, лифт, диспетчер, импорт, джунгли, фильм, клоун, айсберг, доллар, буфет, сейф, памфлет* һ.б.

Татар телендә **итальян** сүзләре дә бар, алар аеруча музыка, сәнгать, кулинария белән бәйле: *либретто, квартет, ария, кантата, мандолина, маэстро, соло, соната, тенор, фортепьяно, фуга, трио, арлекин, барокко, карикатура, новелла; вермишель, макарон, фонтан, авария, валюта, галерея, газета, гранит* һ.б.

Рус теле аша **голланд** теле сүзләре дә үтеп кергән, алар диңгездә йөрү белән бәйле лексикага карыйлар: *штурман, катер, каюта, боцман, верфь, вымпел, гавань, киль, лоцман, матрос, трюм, рейд, мачта* һ.б.

Татар телендәге рус-европа алынмалары составында берникадәр **испан** сүзләре дә күзәтелә: *серенада, армада, кокос, какао, томат, матадор, тореадор, коррида* һ.б.

Соңгы елларда татар телендә **кытай** һәм **япон** алынмалары да шактый еш очрый. Алар, нигездә, экзотизмнар, ягъни халыкның көнкүреш әйберләре, кием-салым, йола-гадәт атамалары буларак телебезгә үтеп кергән: *маоизм, тайфун, цзофан, дзю до, харакири, цунами, самурай* һ.б.

Алынма сүзләрнең телебезгә үтеп керү чорлары һәм юллары да төрле. Биредә, гомуми күзаллау булсын өчен, сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп, аларда теркәлеп калган сүзләргә күзәтү ясалды, чөнки алар татар телендәге рус алынмаларының күләме, мәгънә сыйфаты, кулланыш активлыгы турында мәгълүмат алырга мөмкинлек бирәләр.

Беренче русча-татарча кульязма сүзлек (1740) М. Котельников тарафыннан төзелә. Анда *пристау, палач, крушка* (кружка), *пичкә, пләгә* (фляга), *папугай* һ.б. рус-европа алынмалары теркәлгән. Шушы ук елларда төзелгән П. Рычков, М. Габдрахмановның русча-татарча-калмыкча сүзлегендә *салдат, башнә* (башня), *чәркә* (чарка), *бәләк* (валек), *рәт* (ряд) һ.б. рус сүзләре чагылыш тапкан.

1785 елда С. Хәлфиннең русча-татарча 2 томда кульязма сүзлеге төзелә, ул шул чорның иң зур күләмле (17000 сүзне эченә алган) сүзлеге була. Ә. Ахунҗанов андагы рус-европа алынмаларын алты зур төркемгә бүлә һәм мисаллар китерә:

1. Административ атамалар: *правинса* (алда телгә алынган алынмалар китерелми. – *Д.Р.*), *пумистия, пусилиния* (поселение),

*ербовый кәгазь* (гербовая), *пушна* (пошлина), *магистрат, квитансы, кантур, пуп, камургир* (камергер), *пудрятчик, пуддич* (подьячий), *кантурчы* (конторщик), *дияк* (дьяк), *пратакалист* һ.б.

2. Сословиеләр һәм эш вазифалары атамалары: *бургамистер, бухгалтер, заводчы* (заводчик).

3. Предприятие, завод һ.б.ш.ларның исемнәре: *завут* (завод), *фабрик, карап* (корабль) һ.б.

4. Хәрби терминология: *адутант* (адъютант), *гарнизун, янарал* (генерал), *драгун, кавалир, капрал, падпалкауник, падпрапршик, пулк* һ.б.

5. Төрле гомуми төшенчәләр: *задаткы* (задаток), *чират, дистә, дапрус алучы* һ.б.

6. Көнкүреш лексикасы: *багур, бутылькә, бураңка, гер, жулап* (желоб)*, зирсал* (зерцало), *капста, картуз, кузла* (козлы), *караваm, фатир, калиткә, кләшшә* (клещи), *лимун, лум, линт* (лента), *мунчала, матча, мүк, маятник, борыч, насус, рәшәткә, рүмкә, патнус, ыступа* (стопа), *өстәл, эскәтер, тәмәке* (табак), *тәрилкә, чирпак* һ.б.

1804 елда Санкт-Петербургта И. Гигановның «Словарь российско-татарский, собранный Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И. Гигановым и муллами Юртовскими» дигән сүзлеге чыга, материал Себер татарларыннан тупланган, анда *бораy, машина, пядря* (ведро), *шуруп, тугрәп* (погреб), *лакан* (лохань), *лиман* (гавань) һ.б. алынмалар бар.

1835 елда А. Троянскийның «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских» дигән сүзлеге (2 томда) чыга, анда татар өлешендә инде татар теленең үз сүзе булып киткән рус алынмалары да теркәлгән. Мәсәлән: *келәт* (клеть), *мүк, мәк, гөслә, гөсләче, камыт, бүрәнә, пот* (пуд), *дегет, камыт, опра (апара), арыш* һ.б.

Л. Будагов, В. Радлов, Н. Остроумов, А. Воскресенский, К. Насыйри һәм башка галимнәрнең сүзлекләрендә дә татар теленә кереп урнашып килә торган яки урнашкан рус-европа алынмалары шактый теркәлгән.

Инкыйлабка кадәр кабул ителгән һәм 1913 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә (Рахманколый С. Татарча-русча лөгать, 1913) теркәлгән рус алынмаларын түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүләргә мөмкин.

1) туганлык атамалары: *түти* – тетя; *симия* – семья, семейство.

2) кеше һәм аның эчке дөньясы белән бәйле лексика: *урыс* – рус, *керәшен, әфисәр, җулик* – жулик.

3) кешенең эшчәнлеге, кәсеп-һөнәре белән бәйле сүзләр: *ыструк* – рубанок, *тәҗе* – тяж, *ыстинә* – стена, *зал, самауар, торба* – труба, *кәрзин* – корзина, *лакан* – лохань, *яшчик* – ящик, *ышкаф*, *түк* – тюк.

4) финанс, сәүдә, медицина, аш-су һәм хәрби өлкәләргә караган лексика: *налук* – налог, *сурт* – сорт, *җәдрә* – ядро, *чират, гер, груш* – грошь; *эспирт* – спирт, *жаркуй* – җаркое.

5) фән-мәгариф, матбугат, музыка белән бәйле сүзләр: *җәгъръфия* – география, *газита* – газета, *газ, эскрибкә* – скрипка.

6) үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы белән бәйле лексика: *арыш, әфлисун, салат, салам, кәбестә, керән, лимун* – лимон, *бәһимут* – бегемот.

7) ил, шәһәр исемнәре: *Әстерхан, Русия.*

8) вакытка бәйле сүзләр: *сикунд, минут.*

Сүзлектә тагын генетик чыгышлары ачык булмаган, бәхәсле сүзләр бар: *сука, кукшин, алабута, кәҗә.*

Әйтергә кирәк, 1913 елда төзелгән һәм татар теле сүзлек фондының инкыйлабка кадәрге торышын чагылдырган сүзлектә рус-европа алынмалары сан ягыннан гарәп-фарсы алынмаларыннан күпкә ким. Алар арасында зур күпчелекне рус сүзләре тәшкил итә. Бу чорда Европа сүзләре бик аз.

1927 елгы (төз.: М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Кулиев) һәм 1931 елгы (төзүчеләре шулар ук) татарча-русча сүзлекләрдән күренгәнчә, Көнбатыш Европа телләреннән 20–30 нчы елларда татар теленә рус-европа алынмалары актив рәвештә, күпләп кергән. Алар тормышның төрле өлкәләренә карый:

1) административ-дәүләт эшләре, иҗтимагый-сәяси тормыш белән бәйле сүзләр: *абонент, авангард, анархизм, апелляция, антогонизм, буржуазия, власть, виза, демократия, империя, конституция, марксизм, социалистик, фракция, паспорт, райком, совет* һ.б.

2) фәнни төшенчәләрне белдергән сүзләр: *аксиома, анализ, анатомия, археология, астрономия, атом, синоним, синтаксис, теория, физика, формула* һ.б.

3) мәдәният, сәнгать, әдәбият өлкәләренә караган сүзләр: *актер, аккорд, альманах, антракт, ария, балет, журнал, лирика, музыка, нота, опера, поэзия, роман, романтизм, рояль* һ.б.

4) сәнәгать һәм техникага, авыл хуҗалыгына бәйле сүзләр: *автобус, амортизация, аппарат, велосипед, верстак, домна, завод, индустрия, каучук, комбайн, металлургия, мотор, мотоциклет, радио, ракета, самолет, станок, транспорт, фабрика, колхоз, питомник, силос, ферма, фураж, плантация, агрономия* һ.б.

5) хәрби өлкә, диңгез эшләре белән бәйле сүзләр: *авиация, автомат, армия, арсенал, батарея, бомба, гильза, демобилизация, залп, команда, компас, маневр, снаряд, солдат* һ.б.

6) медицина өлкәсе белән бәйле сүзләр: *аптека, амбулатория, бинт, бронхит, аспирин, гигиена, диета, наркоз, компресс, паралич, плеврит, рахит, санитария, экзема, шприц* һ.б.

7) мәгариф, физик культура, спорт өлкәләренә караган сүзләр: *алфавит, аудитория, гербарий, глобус, институт. каникул, карта, класс, конспект, лекция, педагог, рабфак, реферат, студент, хрестоматия, акробат, гимнастика, футбол* һ.б.

8) финанс, сәүдә, юриспруденция белән бәйле лексика: *банк, аванс, баланс, банкир, банкнот, бюджет, валюта, вексель, гонорар, дивидент, доход, задаток, заем, компенсация, конфискация, кредит, расход, ревизия, смета, такса, финанс, адвокат, суд, судья, юрист, юстиция* һ.б.

9) һөнәр, профессия, вазифа белән бәйле сүзләр: *агент, арбитр, балерина, букинист, бухгалтер, ветеринар, врач, дирижер, доктор, доцент, драматург, землемер, инспектор, кассир, кондитер, кондуктор, консул, корректор, мастер, медик, ректор, министр, фельдшер, репортер* һ.б.

10) тормыш-көнкүрешкә караган сүзләр: *абажур, асфальт, багаж, багор, балкон, бутерброд, ванна, веранда, вермишель, водопровод, гәрниз* (карниз), *гүрничә* (горница), *дача, замазка, калош, какао, квартира, макарон, помада, прәннек, торт, форточка* һ.б.

11) табигать күренешләре, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына караган сүзләр: *акация, абрикос, бамбук, буйвол, климат, вулкан, ландыш, сезон, сирень, селедка, флора, фауна, фрукт, шукә* (щука) һ.б.

Материаллардан күренгәнчә, дәүләт төзелешенә караган, иҗтимагый-сәяси, техника һәм сәнәгать, хәрби идарә, медицина,

мәдәният өлкәләре белән бәйле рус-европа сүзләре сан ягыннан иң зур күләмле лексиканы тәшкил итәләр. Бу исә җәмгыятьтә барган зур үзгәрешләрнең кайсы өлкәдә аеруча актив барганын күрсәтә.

Хәзерге татар телендәге рус-европа алынмаларының нинди өлкәләрдә кулланылуын тематик төркемнәр кысасында карау татар теле лексик фондында аларның урынын билгеләргә ярдәм итә. Биредә Р. Мөхиярова тарафыннан төзелгән тематик классификация нигез итеп алынды.

1. Иҗтимагый-сәяси лексика: *диаспора, анклав, диссидент, импичмент, инаугурация, коррупция, лобби, необольшевик, партократ, патернализм, плюрализм, политолог, популист, презентация, путч, рейтинг, саммит, спикер, аккредитация, брифинг, пресс-релиз, респондент* һ.б.

2. Икътисади-финанс, базар мөнәсәбәтләре белән бәйле сүзләр: *аудит, бартер, брокер, ваучер, деноминация, дилер, дистрибьютер, инвестор, индексация, инфраструктура, кадастр, лизинг, маркетинг, менеджмент, менеджер, мониторинг, офшор, сертификат, спонсор, трансфер, холдинг, чартер, челнок, штрих-код, экю* һ.б.

3. Техника һәм җитештерү өлкәсе белән бәйле сүзләр: *дискет/дискета, дисплей, драйвер, интернет, компьютер, листинг, принтер, блокиратор, пейджер, радиотелефон, телекс, ксерокопия, ризограф, плейер, видео, денди, тамагочи, тетрис, картридж* һ.б.

4. Мәдәният, сәнгать өлкәсенә караган сүзләр: *аудиоальбом, видеосалон, видеоклип, ди-джей, дискотека, коллаж, продюсер, рок, рок-фестиваль, синтезатор, хит-парад, шоу* һ.б.

5. Физкультура, спорт өлкәсенә бәйле сүзләр: *ралли, авторалли, армрестлинг, мини-футбол, каратэ, тхеквандо, айкидо, кикбоксинг, аэробика, шейпинг, бодибилдинг.*

6. Криминаль дөньяга караган лексика: *киллер, мафия, мафиози, наркотик, наркоман, наркомания, наркомафия, наркобизнес, токсикомания, рэкет, рэкетир, секс-бизнес, сутенер, интерпол* һ.б.

7. Аномаль күренешләр һәм традицион булмаган медицинага караган сүзләр: *аура, вампир, зомби, контактер, полтергейст, уфолог, экстрасенс, гербалайф* һ.б.

8. Кулинария, көнкүрештәге үзгәрешләр һәм яшәешнең төрле өлкәләренә караган сүзләр: *гамбургер, пицца, сандвич, гриль-бар,*

*макдональдс, пиццерия, хот-дог, киви, фейхоа; визажист, дизайн, дизайнер, евроремонт, иномарка, кемпинг, имидж, инновация, менталитет, номинация, нонсенс, социум, эйфория, агрофирма, минимаркет, скаут, супермен, тинейджер, панк, хиппи*.

9. Гади сөйләм алынмалары һәм жаргон сүзләр: *бакс, братва, дебошир, дедовщина, крыша, ломка, попса, тусовка* һ.б. (Мөхиярова, 2000: 100).

Шулай итеп, рус һәм рус теле аша Европа телләреннән кергән алынмалар, нигездә, төрле фән атамаларына, техника-сәнәгать өлкәсенә, җәмгыять төзелешенә, медицина һәм юриспруденциягә бәйле лексиканы тәшкил итәләр, гомумән тормыш-көнкүрешнең башка төрле өлкәләренә дә үтеп керәләр. Татар телендә аларның кулланылыш даирәсе һәм активлыгы елдан-ел арта.

## § 13. Хәзерге татар телендә рус һәм Европа телләреннән кергән алынмаларның лингвистик үзенчәлекләре

Сүзләр, бер телдән икенчесенә барлык мәгънәләре белән үтеп керми, бәлки кабул ителгән чор өчен актуаль булганы, яисә артефакт үзенчәлеге белән бәйле мәгънәсе генә алына.

Инде искәртеп үтелгәнчә, рус-европа алынмаларының инкыйлабка кадәр, аеруча борынгы чорда кабул ителгәннәре татар теленең фонетик төзелешенә яраклаштырылганнар, гарәп-фарсы алынмалары кебек үк, тулысынча үзләштерелгәннәр, алар нигезендә татар теле чаралары (кушымчалар, ярдәмче фигыльләр һ.б.) ярдәмендә яңа сүзләр дә ясала, ә XX йөздә кабул ителгәннәре язудагыча үзләштереләләр.

Билгеле булганча, чит тел сүзләре кабул иткән телдә үзгәрешләр кичерәләр: алынмалар составындагы ят авазлар кабул итүче телдәге аларга якын булган авазлар белән алыштырыла (*яшчик* – ящик), протеза (*эскәтер*, *эспирт*), эпентеза (*жирәбә, керән, керәшен*), апокопа (*минут, гәзит, кәрзин*), сингармонизм законына буйсындыру (*әфисәр* – офицер, *пирчәтке* – перчатка), сүз басымының татар телендәгечә соңгы иҗеккә төшүе (церковь – *чиркәү*, бочка – *мичкә*, гостинец – *күчтәнәч*) кебек фонетик үзгәрешләр күзәтелә.

Рус һәм Европа телләреннән кергән сүзләр морфологик яктан да үзгәрешләр кичергән. Аерым алганда, род кушымчалары төшеп калу (минута – *минут*, солома – *салам*, рама – *рам*), күплек сандагы исемнәрнең берлектә кабул ителүе (обои – *обой*, каникулы – *ка-*

*никул*), *-ист, -чик, -тель, -щик* суффиксларының *-чы/-че* сүз ясагыч кушымчалары белән алмашынуы (нефтяник – *нефтьче,* тракторист – *тракторчы*, баянист – *баянчы* һ.б.) һәм башка морфологик үзенчәлекләр күзәтелә.

Татар теленә алынган рус сүзләре язма тел аша гына түгел, сөйләм теле аша да шактый актив үтеп керә, аларның байтагы татар диалектларында, сөйләшләрендә дә иркен кулланыла. Алынмалар аеруча халыкның сөйләм теленә җиңел кабул ителә, чөнки җирле сөйләшләрдә ике телнең бер-берсенә тәэсир итүе әдәби тел нормаларына, нигездә, буйсынмый. Тагын шуны истә тотарга кирәк, татар теле зур территориягә таралган һәм төрле төбәкләрдәге татарлар русларның төрле сөйләш вәкилләре белән контактта яши. Бу исә татар диалектларында рус алынмаларының состав ягыннан үзенчәлекле булуына китерә. Татар теленең төрле диалектларында аерым төшенчәләрне белдерү өчен кулланылган алынмаларны карап үтик:

| Көнбатыш диалект | Урта диалект | Көнчыгыш диалектлар |
|---|---|---|
| *путалак* | *түшәм* | *түбә* |
| *ызба* | *өй* | *өй* |
| *тырба/торба* | *мөрҗә* | *мира(лык)* |
| *парня* | *такыр басу* | – |
| *элән* | *җитен* | *лән* |
| *кылат* | *кибән* | *богыл* |
| *герәплә* | *тырма* | *тырнаwыч* |
| *кулча* | *бožра* | |
| *сигелцә/сигелтчә* | *ыңгырчак* | |
| *убыт* | *тугым* | |
| *варега/варик* | *бияләй* | |
| *фартык/партык* | *алъяпкыч* | *партук* |
| *гурла* | *бугаз* | *кикердәк* |
| *кучат* | *әтәч* | *кураз* |
| *частакул* | *читән* | |
| *полок* | *ләүкә* | *полок* |
| *матлык* | *матча* | *аргалык* һ.б. |

Диалектологик сүзлек материаллары күрсәткәнчә, диалектларда күпсанлы рус алынмалары кулланыла. Алар, әдәби телдә эквивалентлары булуга карамастан, җирле сөйләшләрдә кулланылуларын дәвам итәләр.

Тагын шуны да ассызыклап үтик: җирле сөйләшләрдәге рус алынмалары инкыйлабка кадәр кергәннәр, чөнки алар, беренчедән, иске тормыш, крестьян хуҗалыгындагы борынгы җир эшләрен белдерәләр; икенчедән, аларның әйтелешләре татар теле фонетикасына көчле охшашлану кичергәннәр (*ыркача* < рукавица, *уклича* < околица, *дастук* < заступ, пырдымсыз < *пардын* + *-сыз* һ.б.).

Татар телендә кулланылган Европа алынмаларының да үзенчәлекле күрсәткечләре бар. Мәсәлән, француз сүзләренә *-уа, -уэ* (*вуаль, бенуар, репертуар, тратуар, буржуа, дуэль*), *-ер* (*шофер, актер)*, *-анс* (*баланс*), *-аж, -яж* (*пляж, гараж, тираж, монтаж*) кебек аваз тезмәләре хас.

Алман сүзләрендә исә сүз башында *шт-, шп- (шк-)* аваз тезмәләре күзәтелә: *штаб, штанга, штиль, штурм, штат, шпион, шкаф* һ.б. Бу төркем кушма сүзләр составында *ланд-, -мейстр* компонентлары күзәтелә: *гроссмейстер, балетмейстер, капельмейстер, ландшафт* һ.б.

Инглиз сүзләре төрле позициядә *дж-* тезмәсе, *-инг* форманты кулланылу белән характерланалар: *джем, джемпер, коттедж, джунгли, допинг, спиннинг, браунинг* һ.б. Инглиз теленнән кергән алынмаларның кайберләре рус теленә берлек формасында алыналар (*бокс, кекс, джинс*) һәм яңа телдә аларның күплек саны кабул иткән телгә хас күплек кушымчалары белән ясала: *кекс – кексы, джинс – джинсы, бокс – боксы* һ.б.

Итальян сүзләре еш кына *-о, -ио, -е* авазларына тәмамланалар. Мәсәлән: *ариозо, форте, адажио, барокко.* Мисаллардан аларның күпчелеге музыка сәнгате белән бәйле икәне күренә.

Сүз *акв-* (су), *кап-* (баш) элементлары белән башланган булса, *-ура, -ум, -ус, -ент, -тор, -ция* аваз тезмәләренә тәмамланса, мондый сүзләрне шикләнмичә латин сүзе дип карарга мөмкин: *аквариум, акватория; капрал, капитан, кәбестә* (капуста) һ.б.; *диктатура, цензура, пленум, президиум; градус, конус; консультация, реакция; диктор, автор, документ, доцент.*

Грек алынмалары еш кына *-ос, -лог* элементларына тәмамланган була: *космос, эпос, термос; монолог, минералог, диалог* һ.б.

Рус һәм Европа алынмалары XX гасыр урталарыннан татар телендә яңа сүзләр ясауда да актив катнаша башлыйлар. Бу күренешнең мисаллары алда телгә алынган 1931 елгы сүзлектә үк теркәлгән. 1950 елгы сүзлектә рус һәм Европа телләреннән кергән тамыр сүзләрдән яңа лексик берәмлекләр ясалуның активлашуы ачык чагыла. Аеруча татар теленең продуктив кушымчалары ярдәмендә күп сүзләр ясалган:

-лык/-лек (*активлык, докторлык, актуальлек, минутлык, делегатлык*),

-лы/-ле (*акцияле, запаслы, квалификацияле, лаклы*),

-сыз/-сез (*грамотасыз, доходсыз, квалификациясез, паспортсыз*),

-чы/-че (*архивчы, гвардияче, маякчы, мехчы, скрипкачы*),

-лап/-ләп (*статьялап, потлап, сменалап*),

-ча/-чә (*геройларча, большевикларча, европача, русча*),

-лаш/-ләш (*активлашу, вариантлашу, пассивлашу, реальләшү*),

-ла/-лә (*анализлау, гипнозлау, иллюстрацияләү, парлау, финанслау*) һ.б.

Рус-европа алынмалары катнашында кушма сүзләр дә ясала, аларның бер өлеше ярымкалька, ә кайберләре исә рус теленнән үзгәртмичә кабул ителә: *драмтүгәрәк, политбүлек, районара, крайбашкарма, политуку, колхоз, комсомол, политрук, рабфак, совхоз, райком* һ.б.

Рус-европа сүзләре ярдәмендә *рәвештә, ясау, итү, бирү* тибындагы сүзләр белән кушма фигыльләр яисә кушма рәвешләр ясала: *регуляр рәвештә, объектив рәвештә*; *анализ ясау, операция ясау, ремонт ясау*; *председательлек итү, партизанлык итү, шпионлык итү*; *дежурить итү, мариновать итү, маскировать итү*; *заявка бирү, заказ бирү, сигнал бирү*; *банкрот булу* һ.б.

Рус-европа телләреннән рус теле аша кергән алынмаларның, нигездә, исем сүз төркеменә каравы мәгълүм. Шул ук вакытта алынмаларны даими үзләштерү, аларның кулланылышы активлашу процессы бара һәм, нәтиҗәдә, алар яңа мәгънә төсмерләре алырга мөмкин, яисә алар нигезендә төрле чаралар белән төрле сүз төркеменә караган яңа сүзләр ясала башлый, мәсәлән, *мафиячел*, *деноминацияләү* яки *деноминация ясау* һ.б.

Китерелгән материаллар, санап киткән үзенчәлекләр татар теленең сүзлек фондының баюына, төрле юнәлешләрдә үсә баруын дәлилли.

Билгеле бер чор белән бәйле рәвештә өр-яңа рус-европа алынмаларын үзләштерүдә дә үзенчәлекле күренешләр барлыкка килде. Мәсәлән, татар телен кайтару максаты белән хәзерге чор алынмаларын сөйләм теле үзенчәлекләренә яраклаштырып формалаштыруга омтылыш очраклары да булды. Мәсәлән: *Рәсәй* – Россия, *гәзит/газет* – газета, *әфисәр* – офицер, *дискет/дискета* вариантлары янәшә кулланыла башлады.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, чит илләр белән бәйләнешләр, сәүдә, сәнәгать һәм җитештерү товарлары алмашу татар теленә бик күп рус-европа алынмаларының үтеп керүенә, татар теленең сүзлек фондында алынмалар катламының баюына китерде.

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ: КУЛЛАНЫЛЫШ ДАИРӘСЕ

## § 14. Тел белемендә кулланылыш даирәсе ягыннан сүзлек составын өйрәнү тарихы

Телнең сүзлек составы ничек кенә бай булса да, бу әле меңләгән сүзне үз эченә алган лексиканың, ягъни аңлатмалы, терминологик, диалектологик һ.б. сүзлекләрдә теркәлгән атама һәм терминнарның барысының да бердәй дәрәҗәдә актив кулланылуы дигән сүз түгел. Бер төркем сүзләр һәр кешенең лексиконында булырга, икенчеләре исә билгеле бер өлкәдә, төбәктә яшәүчеләрнең яисә билгеле бер һөнәр ияләренең сөйләмендә генә ишетелергә мөмкин.

Татар теленең сүзлек байлыгын һәм аның үсеш-үзгәрешен тулысынча күзаллау өчен хронология буенча барлык сүзлекләрне, грамматика дәреслекләрен, кулланмаларны җентекләп өйрәнү зарур. Бу җәһәттән, галимнәр эшне гомумтөрки сүзләрдән гыйбарәт татар лексикасын теркәгән борынгы басма чыганакларга – М. Кашгариның XI елда төзелгән «Диване лөгатет төрк» сүзлегенә, «Борынгы төрки сүзлек»кә мөрәҗәгать итүдән башлыйлар. Әлеге сүзлекләрдән башланган тәҗрибә XVII–XIX гасырларда төзелгән күптөрле ике телле һәм аңлатмалы сүзлекләрдә дәвам итеп, телне өйрәнүчеләр өчен шактый күп мәгълүмат бирә.

XVIII йөз ахырында дини белем бирү үзәкләрендә һәм гимназияләрдә татар теле дәресләре укытыла башлау татар теле буенча дәреслек һәм ярдәмлекләрнең, татарча-русча, русча-татарча сүзлекләрнең күпләп басылуына этәргеч булып тора. С. Хәлфиннең беренче хезмәтләреннән соң (1778, 1785), XIX гасыр башында рус хезмәтләре үрнәгендә И. Гиганов (1801, 1804), А. Троянский (1814, 1824, 1860), И. Хәлфин (1809), М. Иванов (1842) һ.б.ның

грамматикалары дөнья күрә. Аларда, әлбәттә, мисал буларак татар теленең гомумкулланыш сүзләре китерелә, әмма лексика аерым төрләргә беленеп тикшерелми. К. Насыйри (1860) грамматикасында әдәби телнең сүзлек составы тагын да киңрәк яңгыраш ала.

Сүзлек составын өйрәнүгә XX гасыр урталарында аеруча зур игътибар бирелә башлый. Югары уку йортларында лексикологияне өйрәтер өчен төрле дәреслек-әсбаплар, программалар, кулланмалар эшләнә. Мәсәлән, 1965 елда басылып чыккан «Хәзерге татар әдәби теле: югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылары өчен» дәреслеге, Г. Әхәтовның «Хәзерге татар теленең лексикологиясе» (1979, 1985), Ф. Сафиуллинаның «Хәзерге татар әдәби теле: күнегүләр һәм кызыклы материаллар җыентыгы» (1992), «Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология: югары уку йорты студентлары өчен» (1999), Г. Саттаровның «Хәзерге татар теле лексикасыннан контроль эшләр башкару өчен методик күрсәтмәләр» (1997), И. Галимовның «Мавыктыргыч лексикология: татар урта гомуми белем мәктәпләре, педагогия колледжлары һәм училищелары өчен уку ярдәмлеге» (2001), Г. Галиуллинаның «Хәзерге татар әдәби теле лексикологиясе: методик күрсәтмәләр» (2002), «Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә» (2007), «Хәзерге татар теле лексикологиясе: уку-укыту кулланмасы» (2013), И. Бәшированың «Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» (2006), «Татар әдәби теле. Семасиология» (2010) һ.б. – татар лексикологиясен укытуда мөһим чыганак ролен үтәгән хезмәтләр.

Хәзерге татар теленең сүзлек составын тулы, төзек система буларак тасвирлаячак күп томлы «Татар лексикологиясе»нең семасиология, фразеология, этимология турындагы зур бүлекләрне үз эченә алган беренче томының (2015) дөнья күрүе татар теленең лексик байлыгын өйрәнү өчен гаять зур һәм әһәмиятле чыганаклардан саналырга хаклы.

Узган гасырның урталарында Татарстан фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында актив рәвештә татар теленең төрле өлкәләргә караган лексикасы өйрәнелә башлый. Үсемлек, кош, балык, яшелчә һәм җиләк-җимеш атамалары, умартачылык, җир эшкәртү лексикасы һ.б. фәнни яктан җентекләп тикшерелә. Бүгенге көнгә кадәр лек-

сикология буенча диссертацияләр яклана, монографияләр басыла килә.

Кулланылыш даирәсе ягыннан караганда, ягъни гомумкулланыш һәм территориягә, иҗтимагый тирәлеккә бәйле рәвештә, кулланылышы чикләнгән (диалекталь, һөнәрчелек һәм жаргон, арго сүзләр) лексиканы өйрәнү тарихы төрлечәрәк. Мәсәлән, татар телен өйрәнү XVII гасырдан башлана дип санасак, җирле сөйләшләргә игътибар итә башлау да, нигездә, шушы чорга карый. Хәтта беренче татар теле сүзлекләре дә аерым сөйләшләргә нигезләнеп төзелә. Шундыйлардан Дамаскин (1785), И. Гиганов (1804), Н. Остроумов (1876, 1892), А. Воскресенский (1894) сүзлекләрен күрсәтергә мөмкин. Бу сүзлекләр сергач мишәрләре, Көнбатыш Себер татарлары һәм керәшен татарлары сөйләшләре лексикасына нигезләнеп төзелгән һәм алар тарихи яктан зур әһәмияткә ия (Татар теленең диалектологик сүзлеге: 1969: 5).

Татар теленең диалекталь лексикасы башка галимнәрнең хезмәтләрендә дә берникадәр чагыла. Мәсәлән, В. Радлов, Н. Катановның мәшһүр сүзлекләрендә, Г. Ахмаров һ.б.ның мәкаләләрендә шактый бай материал теркәлгән. Кулланылышы чикләнгән сүзләр XIX гасыр ахырындагы хезмәтләрдә тагын да киңрәк яктыртыла. Мәсәлән, аерым бер территориядә кулланыла торган лексика А. Бессоновның «О говорах казанского наречия» (1898), «О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям» (1881), Г. Әхмәровның «О языке и народности мишарей» (1903) хезмәтләрендә карала. Аерым төркем буларак диалекталь лексиканы өйрәнү һәм анализлау XX йөз башына туры килә. Бу вакытта махсус диалектологик экспедицияләр оештырыла һәм анда тупланган материаллар төрле рәвештә хезмәтләрдә, аерым алганда Җ. Вәлидинең «О диалектах Казанского татарского языка» (1927), «Наречие каринских и глазовских татар» (1930) дигән мәкаләләрендә урын ала.

1939 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты оешу, 1944 елда Казан университетында татар филологиясе факультеты ачылу татар теленең лексикасын өйрәнүгә тагын да зуррак этәргеч бирә, нәкъ шул елларда татар диалектологиясе фән буларак формалаша. Бу җәһәттән Л. Җәләй хезмәтләре (аеруча «Татар теле диалектологиясе» (1947) китабы) әһәмиятле роль уйный. 1950–1970 елларда диалектология буенча күпләп фәнни хезмәтләр языла. Мәсәлән:

Д. Сарманаева «Диалектальные особенности языка среднеуральских татар» (1950), Л. Дмитриева «Язык татар Западной Сибири (барабинцев и тобольских татар)» (1951), Л. Мәхмүтова «Особенности касимовского говора татарского языка» (1952), Д. Тумашева «Татарские диалекты Западной Сибири» (1952), Н. Борһанова «Нократ һәм Глазов татарларының тел үзенчәлекләре» (1952), Л. Җәләлетдин «Татар теленең урта диалекты» (1954), Г. Әхәтов «Диалект западносибирских татар» (1964), Д. Тумашева «Диалекты сибирских татар в отношении к татарскому и другим тюркским языкам» (1969), Д. Рамазанова «Говоры татар Среднего Прикамья» (1970), Ф. Йосыпов «Татар теленең Көньяк Урал һәм Урал арты (Чиләбе, Курган) өлкәләрендә таралган сөйләше» (1972), Ф. Баязитова «Татарские говоры Нижнего Прикамья» (1973) һ.б.

Диалекталь лексиканы туплауда, җентекләп өйрәнүдә даими рәвештә оештырылган диалектологик экспедицияләрнең роле гаять зур. Шул рәвешле тупланган бай материал 1948, 1953, 1958 елларда басылган диалектологик сүзлекләрдә урын ала. Татарстан фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты телче-диалектологлары озак еллар дәвамында экспедицияләрдә берәмтекләп җыйган лексик байлыкның күпсанлы сүзлекләрдә (1965, 1969, 1979, 1993) дөнья күрүе лексикология өчен бик зур казаныш. Ике китаптан торган «Татар халык сөйләшләре» (2008) хезмәте дә татар теленең зур байлыгын үз эченә ала. 2009 елда дөнья күргән «Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә барлык татар диалектларының лексик байлыгы чагылыш таба. Диалектолог галимнәрнең фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе булып 2015 елда «Атлас татарских народных говоров» басылып чыгу – татар теленең диалекталь лексикологиясен тагын бер баскычка югарырак күтәрде.

Һөнәрчелек лексикасына багышланган хезмәтләр XIX гасыр ахырында күренә башлый. Татар телендә кулланыла торган мондый төр лексиканы өйрәнүдә аеруча Р. Рәхимованың өлеше зур. Аның 1983 елда басылган «Татар теленең һөнәрчелек лексикасы» китабы һәм күпсанлы мәкаләләре татар һөнәрчеләре телендәге сүзлек составын шактый тулы тасвирлаган хезмәтләрдән санала. Беренче чиратта, әлбәттә, татар халкы аеруча үз иткән һөнәр һәм кәсепләргә кагылышлы лексикага игътибар юнәлтелә. Мәсәлән, халкыбызның элек-электән килгән күн эшкәртү, итекчелек, тегү-

челек һөнәренә бәйле сүзләре берәмтекләп туплана һәм җентекләп өйрәнелә. Р. Рәхимованың «Профессиональная лексика татарского языка, относящаяся к ткачеству, одежде, обуви и головным уборам» (1975), «Из древнетюркского пласта кожевенной лексики татарского языка» (1986), «О татарской отраслевой терминологии» (1988) һ.б. күпсанлы мәкаләләре дә һөнәрчелек лексикасына автор тарафыннан булган зур игътибар турында сөйли.

Һөнәрчелеккә кагылышлы сүзләр теге яки бу өлкә лексикасын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләрдә дә (мәсәлән: Ф. Гаффарованың «Татар телендә җир эшкәртү лексикасы» (2000), Д. Рамазанованың «Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте» (2002), З. Садыйкованың «Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке» (2003), А. Сәгыйтованың «Татар телендә агач архитектурасы лексикасы» (2004) һ.б.) фәнни дәрәҗәдә шактый җентекле тикшерелә. Моннан тыш, халык телендә сакланып калган һөнәрчелек лексикасына төрле сөйләшләрне өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдә дә зур игътибар бирелә. Мәсәлән, З. Садыйкованың Оренбург татарлары телен анализлауга багышланган «Говоры оренбургских татар» (Садыйкова, 1985: 127–133) хезмәтендә мамык шәлләр бәйләүчеләр телендә кулланыла торган *(кәләбә мамык путин, сүренте, йатак, дебет, запраткы, катлык),* Д. Рамазанованың «Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте» (2002) хезмәтендә зәркәнчелектә *(каралтынны беләзек, сырга, чип, чипле манит, яка чылбыры, кысмаллы беләзек),* тегүчелек эшендә *(шартланка, запун, эзәр, җияк, әдеп)* кулланыла торган сүзләр шактый урын алган.

Кулланылышы тагын да чикләнгән жаргон һәм арго сүзләрдән халкыбыз чагыштырмача соңрак файдалана башлады. Уртак кызыксынулар белән яшәүче кешеләр төркемендә, мәсәлән, билгеле бер һөнәр ияләре, уен белән мавыгучылар, урам яшьләре, укучылар, студентлар һ.б. арасында гына кулланыла торган мондый үзенчәлекле сүзләрнең бүгенге көндә активларының күбесе рус теленнән яисә рус теле аша чит телләрдән кергән (*телик, шпоры, бан, чат, ник* һ.б.) булса да, татар телендә жаргоннар XX гасыр башында ук шәкертләр, руханилар, укымышлылар сөйләмендә активлаша башлый. И.Низамов фикеренчә, Октябрь инкыйлабына кадәр булган мәктәп-мәдрәсәләрдә гарәп теле зур урын тота, хәлфәләр арасында

да, шулай ук, төрекчәләп сөйләү модада була. Шуңа күрә гарәп, фарсы, төрек сүзләре һәм әйтелмәләре белән катнаш гарәпчә-татарча сөйләм шул чорның мөселманча белем алган югары катлаулары арасында үзенә аерым жаргон тәшкил итә (Низамов, 2008: 179). Инкыйлабка кадәр жаргон сүзләр сәүдәгәрләрнең бер җирдән икенче җиргә йөреп, алып-сату эшләрендә ярдәм иткән яшерен тел (һөнәри серләрне яшерү өчен) вазифасын да үтиләр. Мәсәлән, өязгә чыгып тегүчелек белән шөгыльләнгән кешеләрнең үзара серләрен белдерә торган жаргон сүзләре хакында Р. Рәхимова мәкаләсендә (1975) мәгълүмат табарга була.

Мәгълүм булганча, жаргон сүзләр куллану кешенең интеллектын һәм культура дәрәҗәсен төшереп кенә калмый, әдәби нормаларны бозуга, телнең ямьсезләнүенә, тупаслануына китерә. Хикәяләүне чынбарлакка якынрак итү өчен язучылар һәм журналистлар, еш кына, жаргон һәм арго сүзләрен үзләренең әсәрләренә дә кертеп җибәрәләр. Тик шунысын да ассызыклыйк: галимнәр һәм тел белгечләре мондый төр сүзләрне куллануны хупламыйлар.

Рус телендә арго һәм жаргон сүзләрне куллану гына түгел, фәнни яктан өйрәнү дә бик алга киткән. Соңгы елларда дөнья күргән мәкаләләр әлеге «яшерен сүзләрне» фәнни яктан өйрәнүгә кызыксынуның тагын да артуы хакында сөйли (Э. Шаламованың «Профессионализмы и профессиональный жаргон в автомобильной лексике» (2014), И. Раханскаяның «Современный русский компьютерный жаргон в сети интернет» (2014), В. Минаеваның «Понятие социальный жаргон и сферы его использования (на материале английского языка)» (2014), В. Костинның «Компьтерный жаргон» (2015), А. Гердтның «Жаргон и социальная группа» (2016) һ.б. хезмәтләр шундыйлардан). Татар теленең жаргон сүзләрен өйрәнүгә багышланган фәнни мәкаләләр әлегә бик күп түгел. Мәсәлән, Г. Әхмәтгалиеваның «Татарская молодежная лексика в социальной сети “В контакте”» мәкаләсе (2015) социаль челтәрләрдә кулланыла торган жаргон сүзләрнең, Н. Гордееваның «Отражение языка города Казани в текстах радиорекламы: стилистический аспект» (2012) мәкаләсе жаргон һәм башка сөйләм сүзләренең радио телендә актив кулланылышы турында.

Кулланылыш даирәсе ягыннан сүзлек составының һәр төркеменә һәм аларны өйрәнү тарихына аерым тукталу татар телендә аларга игътибарның, мөнәсәбәтнең, карашның ни дәрәҗәдә бу-

луын күрсәтә. Диалекталь һәм һөнәри лексиканың тарихы, жаргон һәм арго сүзләр белән чагыштырганда, борынгырак санала. Бу аларны өйрәнү җәһәтеннән караганда да аңлашыла кебек.

## § 15. Татар теле лексикасын кулланылыш даирәсе ягыннан төркемләү мәсьәләсе

Тел белеме һәм лексикология буенча хезмәтләрдә, гадәттә, әдәби телнең сүзлек составы килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм кулланылыш активлыгына карап төркемләнә һәм аларның һәркайсы аерым өйрәнелә. Кулланылыш даирәсе ягыннан телнең сүзлек составын иҗтимагый-территориаль яктан диалект лексикасына, социолингвистик яктан – терминологик, һөнәри, жаргон, арго төрләренә бүленеш сакланып килә.

Төрки телләр белемендә һәм рус телендә бөтен кеше дә куллана ала торган сүзләр – гомумкулланыш лексикасы, территориягә бәйле рәвештә кулланыла торганнары – диалекталь лексика, иҗтимагый яктан кулланылышы чикле сүзләр – һөнәри лексика, жаргон, арго сүзләр төркемендә өйрәнелә. Сүзлек составында үзгәрешләр булып торса да, әлеге бүленеш, нигездә, дистә еллар дәвамында үзгәрешсез кала бирә. Мәсәлән, тел белеме буенча төрле еллардагы хезмәтләрдә түбәндәге бүленеш саклана: 1) гомумкулланылыш сүзләр, 2) кулланылышы чикләнгән сүзләр (һөнәри һәм терминологик лексика, диалекталь лексика, жаргон һәм арго лексика) (Фомина, 2003: 210, Байрамова, 2004: 16–19, Николенко, 2005: 80–81) һ.б.

Ф. Сафиуллина, М. Зәкиев, Г. Әхәтов, Г. Галиуллина һ.б.ның татар тел белеме буенча хезмәтләрендә кулланылыш даирәсе ягыннан сүзлек составы, нигездә, шундый ук төркемнәргә бүлеп өйрәтелә. Мәсәлән, Ф. Сафиуллина белән М. Зәкиев «Хәзерге татар әдәби теле» (1994) китабында кулланылыш даирәсе (авторларда: кулланылыш сферасы) ягыннан татар теленең сүзләрен берничә төркемгә бүлеп, «иң кирәкле, тормышта иң әһәмиятле» сүзләрне үз эченә алган зур төркемне «гомумхалык теле сүзләре» дип атыйлар һәм милли әдәби телнең үзәге булган әлеге гомумхалык сүзләре нигезендә генә телебез үсә һәм камилләшә ала, дигән фикерне җиткерәләр. Аерым бер коллектив телендә яки аерым бер сөйләштә, иҗтимагый катлам телендә генә кулланылган сүзләр икенче төркемгә туплана һәм диалекталь лексика, һөнәрчелек лексикасы,

арготик (жаргон) сүзләргә аерыла. Бу төркемнәр арасында даими рәвештә үзгәрешләр, күчешләр дә булып тора: кайбер һөнәрчелек лексикасы яки диалекталь лексика гомумхалык теленә күчәргә дә мөмкин (Сафиуллина, Зәкиев, 1994: 65).

Г. Әхәтовның «Татар теленең лексикасы» («Лексика татарского языка») хезмәтендә кулланылыш даирәсе (авторда: куллану сферасы) ягыннан татар теленең лексик байлыгы 4 төркемгә бүленә: 1) гомумхалык лексикасы, 2) диалектизмнар, 3) профессиональ терминнар, 4) жаргоннар (Әхәтов, 1995: 78).

Г. Әхәтов фикеренчә, «сүз, гомумкулланылышта яки әдәби телдә булмавына карамастан, территориаль яктан чикләнмәсә, аерым профессия кешеләре өчен генә хас булмаса, гомумхалык лексикасына карый». Профессиональ терминнар дигән өченче төркемдә Г. Әхәтов профессиональ-терминологик лексика өлешен аерып тикшерә һәм үзләрен ике төркемчәгә бүлә: 1) терминнар, 2) профессонализмнар (Әхәтов, 1995: 84).

Ф. Сафиуллинаның югары уку йортлары өчен «Татар лексикологиясе» (1999) хезмәтендә әлеге төркемләүне «Кулланылыш сферасына карап хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы» дигән бүлегендә табарга була. Биредә гомумкулланылыштагы лексика, диалекталь сүзләр, һөнәрчелек лексикасы, жаргон һәм арго сүзләргә бәяләмә бирелә, һәр төркемдәге лексикага әдәби әсәрләрдән мисаллар китерелә.

Югары сыйныф укучылары һәм студентлар өчен Г. Галиуллина төзегән «Татар лексикасы. Лексикология» хезмәтендә кулланылыш ягыннан сүзлек составы түбәндәгечә карала: гомумкулланылыш сүзләре, диалекталь сүзләр (морфологик, алынма, этнографик диалектизмнар), һөнәри сүзләр, терминнар, жаргон, арго (Галиуллина, 2007: 50). 2013 елда басылып чыккан «Хәзерге татар теле лексикологиясе» дигән уку-укыту кулланмасында автор татар теле лексикасын кулланылыш даирәсе ягыннан чикле һәм иректе кулланылыштагы сүзләргә аерып, территориаль яисә иҗтимагый яктан чикле сүзләр рәтенә диалекталь лексика, һөнәри лексика, жаргон, сленг һәм арго сүзләрне кертә (Галиуллина, 2013: 61).

Чагыштыру өчен рус теле белеме, лексикологиясе буенча соңгы елларда чыккан хезмәтләргә күз салыйк. Югары уку йортлары студентларына бүгенге көндә дә рус теленең лексикасы кулланылыш даирәсе ягыннан ике төркемгә – гомумкулланышлы һәм

чикләнгән дәрәҗәдә кулланылышлы төрләргә бүлеп өйрәтелә. Беренче төркемгә телнең төп лексик составын тәшкил иткән һәм кешеләрнең яшәү урынына (территориясенә), эшчәнлек төренә бәйсез рәвештә кулланыла торган сүзләр керә. Болар – китап, журнал, газета, театр, кино, радио, телевидение, мәктәп һ.б. телендә һәм сөйләмендә, ягъни көндәлек тормышта кулланыла торган сүзләр. Ә кулланылышы чикләнгән лексика аерым бер территория (диалекталь сүзләр) һәм билгеле бер һөнәр ияләре телендә (һөнәрчелек лексикасы, техницизмнар) кулланылганнарына һәм иҗтимагый үзенчәлекләр, уртак кызыксынулар белән бәйле жаргон, арго сүзләргә аерылалар (Лобачева, 2015: 37). Н. Лобачева, шөгыльләре, кызыксынулары яисә җәмгыятьтәге урыннары уртак булган кечкенә социаль төркем сөйләмендә кулланыла торган жаргон сүзләр 1917 елга кадәр барлыкка килгән һәм аларны башкалар аңламасын өчен ят сүзләр кулланып сөйләшә торган хакимлек итүче сыйныфлар уйлап чыгарган, дигән фикердә (Лобачева, 2015: 39). Рус теле белемендә бу төр лексиканы яшьләр жаргоны (сленг) һәм профессиональ жаргонга бүлеп карыйлар. Рус теле белемендә техника өлкәсендә кулланыла торган тар мәгънәле махсус терминнар (*поршень, шестерёнка* һ.б.) да, техницизмнар дип исемләнеп, аерым төркемдә карала.

Л. Крысин рус теленең кулланылышын яктырткан хезмәтләрнең күбесендә әдәби тел, территориаль диалектизмнар, шәһәр сөйләме, иҗтимагый жаргоннар кебек бүленеш хөкем сөрүен ассызыклый. Әлеге бүленеш, махсус лингвистик һәм социолингвистик хезмәтләрдә генә түгел, югары уку йортлары өчен язылган барлык дәреслекләрдә һәм кулланмаларда да чагыла (Крысин, 2004: 324).

Татар тел белеме буенча хезмәтләрнең барысында да, гадәттә, кулланылыш ягыннан лексиканың төркемнәргә бүленеше китерелә һәм мисаллар бирелә. Кайберләрендә бер-ике җөмлә һәм берничә мисал белән генә әдәби телгә диалектларның, жаргоннарның тәэсире күрсәтелә. Бу яктан рус тел белеме буенча хезмәтләр мәгълүмат күләме белән шактый аерыла. Мәсәлән, Л. Крысин хезмәтләрендә әдәби телгә диалектларның, жаргоннарның тәэсире – һәммәсе дә аерым параграфта карала.

Тел белеме буенча дәреслекләрдә, хезмәтләрдә искәртелгәнчә, кулланылыш ягыннан төркемләүдә чикле һәм чиксез кулланылыштагы сүзләр дә булырга мөмкин. Ягъни, аерым төркемнәргә

бүлдек тә, теге яки бу сүз шул төркемнеке генә булып санала, шул даирәдә генә кулланыла дип аңларга кирәкми. Мәсәлән, җинаятьчел даирәләр дөньясына хас ясалма, ягъни алар үзләре уйлап чыгарган кайбер арго сүзләр сөйләм теленә кереп китәргә, һәм хәтта *гади сөйләм* дигән тамга белән сүзлекләрдә дә бирелергә мөмкин. Элек аерым бер һөнәр ияләре (табиплар, физиклар, химиклар һ.б.) сөйләменә генә хас һөнәри сүзләрнең кайберләре (мәсәлән, *скальпель, диагноз, наркоз* һ.б.) киң катлам телендә кулланыла башлады. Һөнәри лексика, диалект һәм жаргон сүзләр кебек үк, тар даирәдә генә кулланылса да, әдәби тел нормаларына каршы килмәгәнлектән, алар теге яки бу дәрәҗәдә әдәби сүзлек составына да кертеп карала ала.

Үзара тәэсире, мөнәсәбәте буенча гомумкулланыштагы сүзләр белән диалект сүзләр бер-берсенә бик якын торган төркемнәрдән санала. Диалектларның кушылуына шәһәр теле дә сәбәпче. Шәһәрдә интердиалект хөкем сөрә, шуңа күрә, кала халкы куллана торган сүзлек составы үзара тотрыксыз, үзара бер-берсен алыштырырга мөмкиннәр. Радио, телевидение, вакытлы матбугат һәм югары катлам – интеллегентлар сөйләше дә, авылга караганда, шәһәрдә көчлерәк сизелә. Авылда, киресенчә, җирле сөйләм теле әдәби телнең үсешенә тоткарлык ясый. Бу – диалект сүзләрнең югалуына, әдәбиләшүенә яисә әдәби тел тәэсирендә бөтенләй онытылуына, юкка чыгуына китерә (Крысин, 2004: 327). Диалект сүзләрнең әдәби телдә актив кулланыла башлавында язучыларның, шагыйрьләрнең дә өлеше зур. Мәсәлән, язучылар тарафыннан диалектлардан алынган *өрфия, күлләвек, ымсыну, дуадак* һ.б. сүзләр күптән әдәби телнең үз сүзләре кебек кабул ителә. Г. Бәширов, М. Мәһдиев әсәрләрендә Казан арты, М. Хәбибуллин, М. Галиев, А. Гыйләҗев әсәрләрендә урта диалектның минзәлә сөйләшенә хас үзенчәлекләргә күпләр игътибар итәдер. А. Хәлим, Н. Гыйматдинова, Р. Идиятуллин, Р. Зәйдулла һ.б. каләм ияләре кулланган диалект сүзләр дә киләчәктә әдәби телдә актив кулланыла башларга мөмкин.

Әлеге хезмәттә телебезнең кулланылыш даирәсе ягыннан лексик составы татар теле белемендә һәм рус, төрки телләр белемендә әлегә кадәр булган бүленешне исәпкә алып, гомумкулланылыш лексикасы, җирле диалект лексикасы, иҗтимагый диалект лексикасы, һөнәри лексика дип төркемләнде.

## ГОМУМКУЛЛАНЫЛЫШ ЛЕКСИКАСЫ

### § 16. Гомумкулланылыш лексикасына гомуми билгеләмә

Татар теленең төп лексик фондын гомумкулланылыш лексикасы тәшкил итә. Гомумкулланылыш (гомумхалык) лексикасы дип милли телнең нигезен тәшкил иткән, татар телендә сөйләшүчеләрнең барысына да аңлашыла торган, кулланылышында иҗтимагый һәм территориаль чикләр булмаган сүзләрне атыйлар. Бу төр лексика милли әдәби телнең үзәге санала, гомумкулланылыш лексикасы барлык стильләрдә һәм телнең төрле катламнарында иркен кулланыла. Гомумкулланылыш лексикасыннан башка бер генә милли тел дә яши һәм үсә алмый, шулай ук аралашуның бер генә формасы да бу сүзләрдән башка була алмый. Гасырлар дәвамында формалашкан, үскән һәм үзгәргән татар милли теленең төп төшенчәләре, тотрыклы формада сакланып, буыннар аралашуында төп рольне уйный. Әлбәттә, аның тотрыклылыгы саклану – бу төркем сүзләрнең эчтәлеге яки формасы үзгәрми, дигән сүз түгел, киресенчә, җәмгыятьтә, телнең үз эчендә барган үзгәрешләр төп лексик фондка да төрле яклап тәэсир итә. XX гасыр башында гомумкулланылышта булган сүзләрнең байтагы хәзерге татар телендә кулланылмый яисә пассив кулланылышта, мәсәлән, *хадим, чикмән, сәйран, сәке, чабата, сыктау* һ.б. Шулай ук хәзерге телебезгә зур катлам лексика соңгы берничә дистә еллар дәвамында гомумкулланылыш сүзләре рәтенә, төп фондка күчте: *президент, күпмилләтле, үзбилгеләнү, компьютер, менеджер, хәбәрдарлык, эшкуар, ташлама* һ.б. Мондый процесслар телнең лексик байлыгының хәрәкәтчән, динамикада икәнен күрсәтә. Шуңа карамастан, бу төр лексиканың эчке табигате озак вакытлар дәвамында тотрыклылыгын саклый, яңа мәгънәләр белән баеса да, төп лексик мәгънә үзгәрешсез кала. Шуның исәбенә татар телендә сөйләшүчеләр, нинди иҗтимагый яки территориаль диалект вәкиле булуларына карамастан, бу сүзләрнең мәгънәсен төгәл аңлыйлар.

Гомумкулланылыш лексикасы, башлыча, нейтраль мәгънәле, барлык стильләрдә дә иркен кулланыла, алар арасында килеп чыгышы ягыннан төрле чыганакларга караган сүзләр бар. Мәсәлән: *баш, тәрәзә, урман, йоклау, эшләү, ашау, ямьсез, матур, китап, дәфтәр, кышын, җәен, машина, өстәл, арыш, нефть, алма, пилмән, миләш, пошИ* һ.б.

Түбәндәге өзектә, нигездә, нейтраль мәгънәле гомумкулланылыш сүзләре кулланыла, алар территориаль яки иҗтимагый яктан чикләнмәгән, татар телендә сөйләшүче кешеләргә, яшь үзенчәлекләренә, дөньяга карашларына, яшәгән урыннарына бәйсез рәвештә җиңел аңлашыла: *Дөньяда иң тәмле ризык нәрсә? Әгәр бу хакта Галәү бабайдан сорасагыз, ул ике дә уйламыйча: – Көлгә күмеп пешергән бәрәңге, – дияр. Тик бүген Инсафның тамагыннан аш үтми. Башында һаман бер уй, бер кайгы: аның өч ел буе назлап-иркәләп үстергән тае, ак бәкәлле елгыр кара айгыры югалды. Тартай болынында башка атлар белән утлап йөргән җиреннән, шүрәле урлагандай юкка чыкты. Шул кыбырсыкны эзләп, атна-ун көн эчендә айкамаган урман-кыры, әйләнмәгән болынтугае калмады малайның. Инде тәмам төшләренә керә башлады* (Г. Сабитов).

Гомумкулланылыш лексикасы рәтендә эмоциональ бизәкле, коннотатив эчтәлекле сүзләр дә бар. Мәсәлән, түбәндәге өзекләргә игътибар итик: *Минем әбием барлык күршеләр белән дә дус, тату яшәде. Беркайчан да юкка-барга күрше белән* ***телгә килм****әс, әйтәсе сүзен уйлап әйтер, күршеләр арасында кайчакта була торган кычкырышуларга,* ***телләшүләргә*** *катнашмый иде. Шулай да ул, нишләптер, бездән биш йорт аша яшәгән Тәзкирә әби белән уртак тел таба алмады. Дөресрәге, ул аның белән бөтенләй аралашмый иде. ... Бер урамда яшиләр бит, очрашмый тора алмыйлар, әлбәттә, тик, очрашканда, чит кешеләре кебек, «исәнме-саумы»дан ары китә алмадылар. Менә инде күп еллар узды, әбием дә, урыны оҗмахта булсын, серен үзе белән алып китте* (Х. Ширмән). Әлеге өзектә кулланылган зур күпчелек сүзләр стилистик яктан битараф, аерылып бирелгәннәре исә, коннотатив эчтәлектә булуларына кармастан, татар телендә сөйләшүче һәркем өчен аңлаешлы, ягъни бу сүзләрнең эмоциональ-экспрессив эчтәлеге сүзнең мәгънәсен аңлауга комачауламый. Өзектә тотрыклы гыйбарәләр дә кулланылган: *телгә килмәс, уртак тел таба алмады, «исәнме-саумы»дан ары китә алмадылар, серен алып китте.* Аларның да мәгънәләре, катлаулы структурага ия булуларына карамастан, барлык кешеләргә дә аңлашыла.

Шулай итеп, гомумкулланылыш лексикасы составында төрле чыганакларга караган гади сүзләр белән бергә, фразеологик әйтелмәләр, тотрыклы гыйбарәләр дә, нейтраль мәгънәле сүз-

ләр белән беррәттән, эмоциональ-экспрессив эчтәлектәгеләре дә кулланыла.

Гомумкулланылыш лексикасы лексик-тематик яктан шактый зур төркемнәрне үз эченә ала. Бу төр лексика составына тормыш-көнкүрештәге әһәмиятле төшенчәләрне атый торган көнкүреш сүзләре, сәяси, мәдәни, икътисади һәм башка өлкәләргә караган сүзләр керә. Аларның кайберләренә аерым тукталып үтү урынлы булыр.

1. Тормыш-көнкүрештәге әһәмиятле төшенчәләрне белдергән сүзләр төркеме:

1) туганлык терминнары: *әти,әни, әби, бабай, кыз, ул, апа, сеңел, абый, җиңги, кияү* һ.б.;

2) ризык атамалары: *ашамлык, аш, су, бәлеш, ит, икмәк, шикәр, ярма* һ.б.;

3) табигать күренешләрен белдергән сүзләр: *кояш, яңгыр, ай, йолдыз, кар, кыш, буран, җил, урман, чәчәк, үлән, агач* һ.б.;

4) тән әгъзалары атамалары: *кул, аяк, күкрәк, йөз, күз, авыз, беләк, бармак, тырнак* һ.б.;

5) төсне белдергән сүзләр: *ак, кара, зәңгәр, кызыл, күк, яшел, сары, алсу* һ.б.;

6) фигыльләр: *бару, сикерү, ял итү, рәхмәт әйтү, йөзү, йөгерү* һ.б.;

7) саннар, күләм-чаманы белдергән сүзләр: *бер, ике, биш, ун, кырык, мең, аз, күп, тиз, акрын, салмак, шактый* һ.б.;

8) тормыш-көнкүреш предметлары атамалары: *өстәл, телефон, карават, тәрәзә, ишек, кашык, ашъяулык* һ.б.;

9) абстракт төшенчәләрне белдергән сүзләр: *матур, яшьлек, сәламәтлек, яхшы, начар, куркак, батыр, герой* һ.б.

2. Алмашлыклар: *мин, син, ул, без, сез, алар, бөтен, бу, теге, менә, әнә, һәр, үз, һәммә, шул* һ.б.

3. Ярдәмлек сүзләр: *әмма, ләкин, генә, белән, турында, өчен, фәкать, карамастан* һ.б.

4. Фразеологик әйтелмәләр: *берне биш итү, балтасы суга төшү, уйга бату, телсез калу, шабыр тиргә бату, кул сузу* һ.б.

Югарыда аталган төркемнәр гомумкулланылыш лексикасының бер өлеше генә, алда әйтелгәнчә, бу төр сүзләрнең рәтен күпләп дәвам итәргә була, алар кеше, җәмгыять тормышының һәр өлкәсендә кулланылалар.

Шулай итеп, татар милли теленең нигезен гомумкулланылыш сүзләре хасил итә, алар иркен кулланылышта яшиләр, телнең лексик фондын чикле һәм иркен кулланылыштагы сүзләргә бүлгәндә, алар норма, чыгыш ноктасы вазифасын үтиләр.

## ҖИРЛЕ ДИАЛЕКТ ЛЕКСИКАСЫ

### § 17. Татар теленең диалект лексикасы турында гомуми мәгълүмат

Диалект (грек. *dialektos* – сөйләш, шивә) – билгеле бер телнең территориаль, һөнәри яки социаль уртаклык белән бәйләнгән, даими һәм турыдан-туры аралашып яшәүче теге яки бу дәрәҗәдә чикләнгән кешеләр тарафыннан кулланыла торган сөйләмнең аерым бер төре (Әхәтов, 1984: 4). Диалектларны җирле (территориаль) һәм иҗтимагый (социаль) төрләргә аералар.

Җирле (территориаль) диалект дип территориаль яктан бәйле, даими рәвештә үзара аралашып яшәгән чагыштырмача чикле сандагы кешеләр тарафыннан кулланыла торган гомумхалык теленең төрен атыйлар. Диалектология фәне төрле төбәкләрдә таралган җанлы сөйләм телен – җирле сөйләшләрне өйрәнә.

Билгеле булганча, сөйләм телен территориаль-лингвистик яссылыкта тикшерү нәтиҗәсендә диалект, сөйләш, урынчылык дигән мөстәкыйль тел берәмлекләре аерылып чыгарыла. Һәр диалект, сөйләш, урынчылык төрле фонетик, грамматик һәм лексик үзенчәлекләрне теркәгән изоглоссалар комплексы белән бәяләнә.

Уртак сыйфатлары белән берләшкән диалектлар җыелмалары – зур диалектлар – шивәләр, ә кечкенә диалектлар – сөйләшләр дип аталырга мөмкин (Рамазанова, 2010: 29).

Сөйләш – билгеле бер территориядә яшәүче кешеләр аралашуында кулланыла торган, ягъни территориаль яктан чикләнгән җирле сөйләм. Сөйләш диалекттан, гадәттә, таралышы ягыннан кечерәк санала, чөнки сөйләшләрнең таралышы чикле, ул бер авыл яки кечкенә бер территория белән чикләнергә мөмкин (Әхәтов, 1984: 6). Мәсәлән, Рязань өлкәсендәге Әҗе авылы сөйләше. Диалект исә әһәмиятле уртак диалекталь үзенчәлекләре белән үзара якын сөйләшләрне берләштерә. Мәсәлән, урта диалект Татарстан Республикасында таралган мамадыш, балтач, Башкортстан

Республикасындагы бөре, златоуст сөйләшләрен, Рязань өлкәсендәге бастан сөйләшен һ.б.ны берләштерә.

Урынчылыклар дип билгеле бер территориядә яшәүче кешеләр аралашуында кулланыла торган, ягъни территориаль яктан чикләнгән җирле сөйләмне атыйлар. Урынчылык сөйләштән таралышы ягыннан кечерәк була. Бер сөйләш берничә урынчылыктан торырга мөмкин, ләкин бу шарт мәҗбүри түгел. Алар кайбер диалекталь күренешләрнең таррак күләмдә таралган булуы белән яки икенчел дәрәҗәдәге күренешләр сакланып килү белән аерылалар. Кайбер үзенчәлекләр күрше сөйләшләр йогынтысында һәм сөйләш таралган территориянең аерым бер төбәгендә генә барлыкка килергә мөмкин. Мәсәлән, Урта диалектның минзәлә сөйләше таралган территориянең аерым төбәкләрендә яшәүче төркемнәрнең сөйләшендә, төрле факторлар (тарихи, мәдәни, географик һ.б.) йогынтысы астында, үзләренә хас үзенчәлекләр барлыкка килгән. Бу исә, үз чиратында, минзәлә сөйләшендә берничә урынчылыкны (төп урынчылык, әгерҗе, яңавыл, бәләбәй урынчылыклары) аерып чыгарырга мөмкинлек бирә (Рамазанова, 1998: 67–69).

Диалектология фәне халык сөйләм теленең әдәби телгә керми калган күренешләрен тикшерә, фәнни анализлый, аларның таралыш территориясен билгели. Шулай итеп, диалектология җирле телне территориаль аспектта өйрәнә, аның диалектларга, сөйләшләргә, урынчылыкларга бүленешен ачыклый, шуларны тасвирлый.

Территориаль яссылыкта караганда, диалект, тел берәмлеге буларак, зуррак төрне хасил итә һәм уртак үзенчәлекләре булган берничә сөйләшне үз эченә берләштерә. Сөйләшләр исә, диалект белән чагыштырганда, ваграк тел берәмлеге булып торалар. Алар, күренешләре буенча берникадәр аерымланган булсалар да, әһәмиятле уртак диалекталь үзенчәлекләре белән үзара берләшәләр.

Соңгы еллардагы тикшеренүләр хәзерге татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм формалашуындагы һәрбер диалектның ролен төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирә. Татар диалектологлары, барлык татар диалектларының нигезен борынгы кыпчак теле тәшкил итә, дигән нәтиҗә ясыйлар (Тумашева, 1977: 260; Махмутова, 1969: 26). Шундый бәйләнештә һәр диалект үз үсеш юлын үтә. Төрле этник төркемнәр катнашлыгына нигезләнеп, үз эчендә сөйләшләргә бүленә (Юсупов, 2010: 191).

*Диалект, сөйләш, урынчылык* төшенчәләре, мөстәкыйль диалект берәмлеген аерып чыгару өчен, аерым, шушы берәмлек өчен генә характерлы бер системаны тәшкил итәргә тиешләр. Шул вакытта гына диалект, сөйләш яки урынчылык телнең диалектлары системасында мөстәкыйль берәмлек булып санала ала һәм алар билгеле территория белән дә бәйле була.

Татар теленең диалектларын өйрәнүнең камил һәм ышанычлы алымнарыннан берсе – лингвистик география ысулы (Рамазанова, 2008: 8). Чөнки җирле сөйләшләрне бу ысул белән өйрәнү махсус төзелгән программа, ягъни бөтен территориядә бер сораулык нигезендә алдан төзелгән челтәр буенча башкарыла. Бу ысул белән эшкә керешкәнче, диалектлар һәм сөйләшләр, аларның үзенчәлекләре, халыкның таралыш ареаллары индивидуаль метод ярдәмендә билгеле бер дәрәҗәдә ачыкланган булырга тиеш. Шушы чорда тупланган мәгълүматлар, алынган нәтиҗәләр лингвогеографик ысул белән эшли башлау өчен кирәкле җирлек тудыралар, махсус программа һәм өйрәнелергә тиешле авыллар челтәрен төзү өчен нигез булалар. Нәтиҗәдә, татар халкы таралган бөтен территориядә бер-береннән билгеле бер ераклыкта урнашкан авылларның сөйләшләре махсус сораулык нигезендә өйрәнелә. Икенче төрле, өйрәнелә торган һәр авылда программада күрсәтелгән сорауларның барысына да тулы җаваплар алдан әзерләнгән блокнотларга теркәлә. Эш урынына кайткач, блокнотка тупланган җаваплар карточкаларга салына, диалекталь күренешләр фәнни анализлана һәм өйрәнелгән территориядә таралган сөйләшләр ачыклана, аларның таралыш чикләре билгеләнә, үзенчәлекләр системасы тасвирлана.

Материалларны карточкаларга салу юлы белән тупланган картотека нигезендә тел үзенчәлекләре картага төшерелә, ягъни тел күренешләренең чикләрен, таралышын күрсәткән лингвистик карталар төзелә. Бу карталарның җыелмасы диалектологик атлас дип атала.

Теге яки бу диалекталь үзенчәлек картаның аерым бер өлешендә генә урнашырга мөмкин, ә калган өлештә аңа әдәби вариант каршы куелган була. Үзенчәлекнең таралыш чиген күрсәткән сызык изоглосса дип атала.

Изоглосса – (грекча *изос* – бердәй, *глосса* – тел) телдәге теге яки бу күренешнең лингвистик картада таралыш чиген күрсәткән сызык дигән сүз. Бер үк картада берничә күренешнең таралышы

төшерелергә мөмкин. Әгәр дә аларның таралу чикләре бергә туры килсә, изоглоссалар бәйләме барлыкка килә. Димәк, монда диалектның, сөйләшнең һ.б.ның таралыш чиге ята (Рамазанова, 2008: 8). Икенче төрле татар диалектологиясендә диалектларны билгеләүдә нигез итеп территориаль-лингвистик яки этник принциплар алына. Территориаль-лингвистик принцип ул – җирле диалектның, сөйләшнең яки урынчылыкның тел үзенчәлекләрен һәм аларның территориаль таралыш үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итү. Этник принцип исә – теге яки бу төбәктә яшәүче халыкның этник үзенчәлекләренә, диалект яки сөйләшнең формалашу үзенчәлекләренә игътибар бирү (Бурганова, Махмутова, 1962: 7–18).

Нәтиҗәдә татар телендә өч диалект аерылып чыга: *урта, көнбатыш, көнчыгыш (тубыл-иртыш, бараба* һәм *том) диалектлары.* Бу төркемләнеш татар халкының этник бүленешенә дә туры килә: урта диалект вәкилләре *Казан татарлары* дип йөртеләләр. Көнбатыш диалект вәкилләрен *мишәрләр* дип йөртү гадәткә кергән. Тубыл-иртыш (Төмән, Омск өлкәләре), бараба (Новосибирск өлкәсе), том (Томск һәм Кемерово өлкәләре) диалектлары вәкилләре исә Себердә яшиләр һәм *Себер татарлары* дип йөртеләләр (Рамазанова, 2008: 4).

**Урта диалект.** Россиядә татарлар көнбатышта – Рязань, көньякта – Әстерхан, төньякта – Киров, көнчыгышта Иркутск һәм Красноярск өлкәләренә кадәр җәелгән гаять зур территориядә таралып яши. Аларның шулай сибелеп утырулары, әлбәттә, тарихи сәбәпләргә бәйле. Төрле административ бүленешләр гамәлгә ашырылганда, татар халкын бүлгәләп, төрле үзәкләргә кертеп калдыру сәясәте нәтиҗәсендә, Идел–Урал регионында компактлы утырган татар халкы егермеләп өлкә һәм республикалар составына бүленеп кала. Яңа җирләрне үзирекле яки дәүләт күзәтүе астында үзләштерү, чик буенда хәрби сызыклар һәм ныгытмалар төзү һ. б. ш. тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә, татар халкы яңа регионнарга – Урал арты, Себер, Оренбург, Түбән Идел якларына күчеп утыра.

Сөйләшләрнең хәзерге системасы барлыкка килүдә XVI–XX гасырлар дәвамында булган тарихи вакыйгалар хәлиткеч роль уйнаган. Татар халкының этногенезында катнашкан төп этник компонентлар (аларны мишәрләр һәм Казан татарлары дип атау гадәткә кергән) нигезендә татар теленең ике диалекты формалашкан: көнбатыш (мишәр) һәм урта диалектлар. Себер татарларының

җирле сөйләм теле элек көнчыгыш диалект дип аталган булса, соңгы еллардагы эзләнүләр анда өч (тубыл-иртыш, бараба һәм том) диалект бүленеп чыгуын күрсәтте.

Урта диалект вәкилләрен Казан татарлары тәшкил итә. Тарихи яктан алар болгар бабаларыбызның дәвамчылары булып торалар. Болгарлар исә үз чиратында төрле төрки (угыз, кыпчак) кабиләләрнең көчле Болгар дәүләте составында берләшүе нәтиҗәсендә формалашканнар.

Урта диалектка түбәндәге сөйләшләр керә: казан арты сөйләшләре төркеме (дөбъяз, мамадыш, лаеш, балтач – Татарстан), бәрәңге сөйләше (Мари-Эль), тау ягы сөйләшләре төркеме (норлат – Татарстан, Чувашстан; кама тамагы, тархан – Татарстан), керәшен сөйләшләре төркеме (казан арты керәшеннәре сөйләше – Татарстан; түбән кама керәшеннәре сөйләше – Татарстан, Башкортстан; нагайбәк сөйләше – Чиләбе өлк.), минзәлә (Татарстан, Башкортстан), бөре (Башкортстан), касыйм (Рязань өлк.), бастан (Рязань өлк.), нократ (Удмуртия, Киров өлк.), пермь (Пермь крае), златоуст (Башкортстан), красноуфим (Екатеринбург өлк.), эчкен (Курган өлк.), каргалы, богрыслан (Оренбург), камышлы (Самара өлкәсе), әстерхан (Әстерхан, Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае), татар-каракалпаклар (Волгоград, Саратов өлкәләре), турбаслы, тепекәй, учалы, сафакүл (Башкортстан) (Рамазанова, 2008: 21).

Бу сөйләшләр, зур территориягә таралган булсалар да, төп үзенчәлекләре белән үзара берләшәләр. Урта диалект сөйләшләренең зур күпчелеге әдәби телгә аеруча якын тора.

**Мишәр диалекты** – Идел һәм Урал буе мишәрләре субэтник төркеменең сөйләшләре җыелмасы. Мишәр диалекты шулай ук «көнбатыш диалект» буларак та билгеле. *Мишәр диалекты* термины беренче тапкыр Л. Җәләйнең «Татар телендә диалектлар» (1938) дип аталган фәнни хезмәтендә кулланыла. Система буларак, мишәр диалекты Л. Мәхмүтова тарафыннан тасвирлана. Мишәр диалектының таралышын күрсәткән диалектологик карталарның системалы җыелмасы Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласында урын ала. Мишәр диалектында *ц*-лаштыручы һәм *ч*-лаштыручы сөйләшләрдән торган 2 төркем аерып карала. *Ц*-лаштыручылар төркеменә – сергач (Түбән Новгород өлкәсе), чүпрәле (Татарстан һәм Чуваш Республикалары), байкибаш (Башкортстан) сөйләшләре; *ч*-лаштыручылар төркеменә исә темников,

ләмбрә (Мордовия), кузнецк (Пенза өлкәсе), хвалын, мәләкәс, карсун (Ульяновск өлкәсе), подберезенск-керәшен, чистай-керәшен (Татарстан), стәрлетамак (Башкортстан), шарлык (Оренбург өлкәсе), куршин (Тамбов өлкәсе), волгоград (Әстерхан һәм Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае) сөйләшләре керә. Кама аръягында формалашкан чистай сөйләше катнаш характерда, биредә *ц*-лаштыручылар да, *ч*-ләштерүчеләр дә яши. Мишәр диалектының барлык сөйләшләренә дә хас гомуми үзенчәлекләр бар.

Болардан тыш, әлеге төркемгә Әҗе (рус. Азеево; Рязань өлк.), Сыркыды (Сургодь; Мордовия), Күршә (Татарщино; Тамбов өлк.), Тархан (Тархань; Тамбов), Искил (Тат. Лундан; Мордовия) кебек аерым-аерым утырып калган авыллар керә. Бу авыллар Цна һәм Мокша елгалары бассейнында, Кадом өязендә, ягъни мишәрләр элек яшәгән борынгы территориядә урнашканнар. Урта диалектның касыйм һәм бастан сөйләшләре белән бергә нугай теле йогынтысына дучар булганга күрә, аларда уртак күренешләр барлыкка килгән. Шуңа күрә күрсәтелгән авылларның сөйләше татар теленең төньяк-көнбатыш зонасын хасил итә (Махмутова, 1978: 261).

*Ч*-лаштыручы төркем сөйләшләр, күрәсең, борынгы чорда ук ике типка – темников һәм ләмбрә типларына – бүленгән булганнар.

Темников тибына темников сөйләше үзе (хәзерге Мордовиянең көнбатыш районнарында таралган) һәм Мордовиянең көньяк Пенза өлкәсенең Рузаевкага хәтле булган чиге буйлап утырган авылларның сөйләше керә; Пенза өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге кайбер авылларның сөйләше дә шунда ук карый.

Ләмбрә тибына исә ләмбрә (Мордовиянең көнчыгышында таралган) сөйләше керә (Борһанова, 1962: 93–125).

*Ч*-ылаштыручылар арасында катнаш сөйләшләр дә бар. Болар – кузнецк (Пенза өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлешендә) һәм хвалын (Ульяновск өлкәсенең көньягында) сөйләшләре. Аларның чиген билгеләве шактый кыен, чөнки аларның бер-берсенә акрынлап күчү процессы бара. Алар икесе дә темников һәм ләмбрә сөйләшләре үзенчәлекләрен эченә алганнар, әмма хвалын сөйләшендә ләмбрә һәм берникадәр сергач сөйләшләре белән уртаклык, кузнецк сөйләше белән чагыштырганда, ачыграк чагылган. Кузнецк сөйләшен исә көнбатыш һәм көнчыгыш урынчылыкка бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе темников сөйләшенә хас үзенчәлекләрнең көчлерәк булуы белән көнчыгыш урынчылыктан аерыла төшә.

Яңа территорияләргә чагыштырмача соңрак (хәзерге Саратов өлкәсенең көньягына һәм Волгоград өлкәсенә) күчү нәтиҗәсендә барлыкка килгән авылларның (Алтавыл, Алтата һ.б.) сөйләшләре мөстәкыйль сөйләш яки урынчылык булып формалашып җитмәгәннәр. Аларга хас кайбер үзенчәлекләр табылса, текстта шул авылларның исеме аерым атап барыла.

Ульяновск өлкәсенең төньяк-көнбатышындагы карсун төркеме белән дә шундыйрак хәл. Әмма ул борынгырак чорда (XVII гасыр) Карсун сызыгын төзегәч барлыкка килгән. Аларның сөйләше мөстәкыйль сөйләш булып формалашып җиткән дип әйтүе кыен, шулай да анда аерымлыклар күзәтелә, алар аерым утырган бер компакт төркемне тәшкил итәләр. Шуларны исәпкә алып, бу төркем мөстәкыйль – карсун сөйләше дип тәкъдим ителә. Башкортстанның көньяк-көнбатышындагы (стәрлетамак) һәм Оренбург (шарлык) өлкәсендәге мишәр сөйләшләре дә *ч*-лаштыручы төркемгә карыйлар. Алар һәркайсы төрле күрше сөйләшләр йогынтысында формалашкан.

**Көнчыгыш диалект** – Себер татарлары шивәләре җыелмасы. XX гасырның 70 нче елларына кадәр бу диалектлар көнчыгыш диалект дип исәпләнеп йөртелделәр. Бу термин беренче мәртәбә Л. Җәләй тарафыннан кертелгән (Җәләй, 1938) һәм анда Төмән, Омск, Томск, Новосибирск өлкәләрендә яшәүче Себер татарларының теле күздә тотыла.

Себер татарлары гаять зур территориягә таралып яшиләр. Бу исә төрле төркемнәр арасындагы аерымлыкларның саклануына, аерым төбәкләр эчендә яңа күренешләр барлыкка килүгә китерә. Территориаль-лингвистик принципка нигезләнеп, Д. Тумашева себер диалектларының түбәндәге бүленешен фәнгә кертеп җибәрде: тубыл-иртыш диалекты зур территорияне эченә ала, һәм үзе дә биш сөйләшкә: төмән, тубыл (Тубыл, Вагай, Яркәү районнары), саз ягы (Тубыл, Уват районнары), тәвриз (Омск өлкәсенең Тәвриз, Усть-Ишим, Знаменское районнары), тара (Омск өлкәсенең Тара, Большеречье, Колосовка районнары) сөйләшләренә бүленә. Том диалекты явештә-чат (Томск өлкәсенең Томск районы) һәм калмак (Кемерово өлкәсенең Юрга районы) сөйләшләренә бүленә. Бараба (Новосибирск өлкәсенең Бараба, Куйбышев, Кыштау, Венгерово, Уба, Чан районнары) диалекты бер компакт төркемнең сөйләшен тәшкил итә.

Тоташ территориядә таралган диалектлар яки сөйләшләрнең чикләрен төгәл билгеләве авыр, моның сәбәпләре шунда: алар арасындагы чик кисеп куйган кебек була алмый. Мәсәлән, сөйләшкә хас үзенчәлекләрнең берсе теге яки бу торак пункттан соң инде күзәтелмәскә мөмкин, икенчесенең исә бу торак пунктны үтеп әле дәвам итүе дә бар. Шушы ук торак пунктта күрше сөйләшкә хас үзенчәлек тә табылуы ихтимал. Кыскасы, бер сөйләштән икенче сөйләшкә яки бер диалекттан икенче диалектка күчеш әкренләп бара. Күчеш зонасындагы авылларда янәшә таралган күрше сөйләшләрнең икесе өчен дә характерлы булган үзенчәлекләр кулланылырга мөмкин. Бу территорияне с ө й л ә ш а р а яки д и а л е к т а р а з о н а дип атау кабул ителгән, ә андагы сөйләш к а т н а ш с ө й л ә ш була.

Төп таралыш территориясенең чигендә урнашкан сөйләш, ч и к с ө й л ә ш е дип атала. Мәсәлән, Тау ягында урта диалект сөйләшләре әкренләп мишәр диалектына күчә баралар. Диалектара зона Буа төбәгенә туры килә һәм анда тархан сөйләше таралган. Тархан сөйләшендә урта диалектка хас увуляр *к, г, х* авазлары һ.б. күп кенә үзенчәлекләр сакланса да, мишәр диалектының күпчелек сөйләшләре өчен характерлы булган иренсезләштерү (*кен* – көн, *сет* – сөт һ.б.), *ү~өй* күренешләре һ.б. кайбер үзенчәлекләр дә күзәтелә. Шуңа күрә, тархан сөйләше, аеруча аның көнбатыш өлеше, катнаш сөйләш булып тора.

Билгеле диалект вәкилләренең, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә төп яшәү җирлегеннән күченеп китеп, яңа төбәктә формалашкан җирле сөйләме к ү ч м ә с ө й л ә ш дип атала. Мәсәлән, Казан ханлыгы басып алынгач, патша хөкүмәте яңа җирләрне үзләштерү буенча зур эшчәнлек алып бара. Хәзерге Кама аръягында, Оренбург далаларына Рус дәүләтенең чиген яклау сызыклары, төрле ныгытмалар һ.б. төзелә, үзәк губерналардан руслар, татарлар һ.б. халыклар, әлеге ныгытмаларга күчереп утыртылалар. Алар арасында йомышлы мишәрләр (*ч*-ләштерүчеләр, *ц*-ләштерүчеләр) дә, Казан арты, Мамадыш өязе татарлары да була. Нәтиҗәдә, бу төбәкләрдә катнаш чистай сөйләше, күчмә шарлык сөйләшләре формалаша. Шушы рәвешле барлыкка килгән катнаш сөйләшләрдән тагын камышлы, богырыслан, стәрлетамак сөйләшләре бар (Рамазанова, 2008: 5).

Диалектлар һәм әдәби тел арасында, үзенчәлекле аерма булу белән бергә, үзара тыгыз мөнәсәбәт тә яшәп килә.

Татар теленең диалекталь лексикасы соңгы елларда монографик хезмәтләрдә, фәнни мәкаләләрдә төрле дәрәҗәдә яктыртылган: көнбатыш диалектлар лексик системасы – Д. Рамазанова (1991, 1999), Ф. Баязитова (2003), И. Насипов (1994, 2007), А. Казиханова (2011), Г. Хәйбуллина (2013), Э. Кадирова, Г. Галиуллина, Ф. Сәйфулина, Ә. Йосыпова (2015), Э. Кадирова, Г. Галиуллина, Ә. Йосыпова (2016); урта диалект лексикасы – Д. Рамазанова (1987, 2013, 2014), Ф. Йосыпов (2003, 2004, 2006), Г. Мөхәммәтова (2006), М. Булатова (2012, 2016), А. Хөсәенова (2015): себер диалектлары лексикасы – А. Рәхимова (1991, 1999, 2001), Д. Тумашева (1992), Х. Алишина (1994), Д. Тумашева, А. Насыйбуллина (2000), Р. Барсукова (2002), Ф. Йосыпов (2013, 2014) һ.б. Әлеге эшләрдә аерым лексемаларга чагыштырма-тарихи, генетик һәм ареаль тасвирлама да бирелгән.

Диалекталь лексиканы өйрәнү тел гыйлеменең тарихи юнәлешләреннән: тарихи лексикология, тарихи диалектологиянең бик күп мәсьәләләрен хәл итүдә объектив һәм төпле мәгълүматлар бирә. Теге яки бу диалектның яисә ареалның лексикасын өйрәнү телне яки диалектны система буларак тануга ярдәм иткән, фактик материалларны фәнгә керткән бер чыганак булып тора.

Шулай итеп, җирле диалект лексикасын өйрәнү тел тарихын, аның үсү-үзгәрү юлларын ачыклау өчен бик әһәмиятле. Әдәби тел һәм җирле диалектлар арасында тыгыз мөнәсәбәт диалекталь лексиканы өйрәнү әһәмиятен ассызыклый. Җирле диалектлар, сөйләшләр хәзерге татар әдәби телен баетуда төп чыганак булып тора. Диалекталь лексикологиянең диахрон аспекттагы тикшеренүләреннән ачыкланганча, әдәби телнең көчле йогынтысы нәтиҗәсендә сөйләшләрдә әдәби телгә якынлашу тенденциясе күзәтелә.

## § 18. Диалектизмнарның төрләре

Диалектологиянең төп өйрәнү объектларыннан берсе – диалектизмнар. Диалектизм дип билгеле бер территориядә генә таралган, әдәби телдә кулланылмый торган тел үзенчәлекләрен атыйлар (Галиуллина, 2013: 111). Тел белемендә диалектизмнарның берничә төрен аерып карыйлар.

Фонетик диалектизмнар – әдәби телдән аваз төзелешләре белән аерыла торган үзенчәлекләр (Әхәтов, 1995: 79). Күренекле татар диалектологы профессор Д. Рамазанова билгеләвен-

чә, фонетик диалектизмнар төрле аваз тәңгәллекләре, авазларның нинди позициядә килүләре, гомумтөрки характердагы фонетик закончалыклар белән бәйләнгән (Рамазанова, 2008: 5). Мәсәлән, сузыкларда ***а*** авазына иренләшү хас*: Сугыштан җа*$^{o}$*ра*$^{o}$*ланып кайтты дагын, ба*$^{o}$*ла*$^{o}$*лы иде, ққа*$^{o}$*ла*$^{o}$*да эшләде* һ.б.

Фонетик диалектизмнарга аваз тәңгәллекләре, аваз чиратлашуы, аваз өстәлү, аваз төшеп калу, саңгыраулашу һ.б. үзенчәлекләр керә. Бу төр үзенчәлекләр сузыклар өлкәсендә дә, тартыклар өлкәсендә дә күзәтелә.

*Сузыклар өлкәсендә* түбәндәге үзенчәлекләрне күрсәтү зарур:

1. Сузыклар тәңгәллеге, ягъни диалекталь сүздә әдәби телдәге сузыкка икенче сузык тәңгәл килә. Мәсәлән: **и~ә:** *күчтинәч* (казан арты) – күчтәнәч; **а~ы:** *ққапққан* (кмшл.) – капкын һ.б. Бу күренеш хәл фигыль кушымчаларында да күзәтелә, ягъни *-ганчы/-гәнче* кушымчасы *-гынчы/-генче* булып әйтелә: *торгынчы* – торганчы, *җыйылгынчы* – җыелганчы, *күргенче* – күргәнче, *белген-че* – белгәнче. Басымлы һәм басымсыз *а* сузыгы, нечкә тартыклар янәшәлегендә килгәндә, татар теленең *ә* авазы белән тәңгәлләшә: (урта диалектта) *кәнсәләр* – канцелярия, *әрмийә* – армия, *әдерис* – адрес.

Рус телендәге басым төшкән *о* сузыгы, татар теленең күп сөйләшләрендә (урта, мишәр диалектларында) *у* га күчә: *тучны* – точно, *ахуты* – охота, *гармун* – гармонь, *лимун* – лимон, *пучты* – почта. Киресенчә, рус телендәге басым төшкән *у* авазын татар телендәге *о* белән алмаштыру очраклары да бар. Мәсәлән: *сослон* – суслон, *сохари* – сухари. Бу авазларның бер-берсенә күчеше артикуляцион һәм акустик яктан якын авазлар булулары белән аңлатыла.

2. Сингармонизм – сузыкларның, бер-берсенә йогынты ясап, үзара охшашланулары. Иренләшү гармониясе *о–ө* авазларының үзләреннән соңгы иҗекләрдә килгән *ы–е* авазларына тәэсир итеп, аларны иренләштерү күренешләрендә чагыла: *орчоққ* – орчык, *ққош ққоно* – кыш көне, *өмөт* – өмет (Рамазанова, 2008: 137).

3. Аваз өстәлү һәм аваз төшеп калу күренешләре. Протеза күренеше янәшә ике тартыкка яки татар теле өчен чит булган авазларга башланган сүзләрдә күзәтелә: (стәрлетамак сөйләше) *эрәт – рәт, эскәтер – скатерть*; билгеле бер төркем татар сүзләрендә: (стәрлетамак сөйләше) *өтөрмә – төрмә, эчерү – черү* (казан арты, керәшен сөйләшләре) *эрәққәт – рәхәт, эшәл – шәл, эшәм – шәм* һ.б. Эпентеза – янәшә тартыклар арасына сузык аваз өстәлү күренеше:

(урта диалект) *күреше* – күрше, *җөрөмей* – йөрми, (мишәр диалекты) *ҡарышы* – каршы, *митыр* – метр, *пылак* – флаг, (көнчыгыш диалект) *керәплә* – грабли һ.б.

4. Дифтонглар – ике сузык, яки сузык һәм сонантаның бер иҗектә килүе. Әдәби телдәге дифтонглардан тыш күпчелек сөйләшләрдә (мәсәлән, түбән кама һәм нагайбәк керәшеннәре сөйләшләрендә) *-ыw/-ew, -ей* дифтонглары кулланыла, *-ей* дифтонгы ачык иҗектә килгән тар *и* сузыгы урынына әйтелә: *ней* – ни, *бейем* – бием, *кечтей* – кечти (кечкенә), *үгей* – үги; стәрлетамак сөйләшендә, даими рәвештә *-әй* дифтонгы әйтелә: *үгәй – үги, песәй – песи, тәпәй – тәпи* һ.б.

*Тартыклар тәңгәллеге*, ягъни диалекталь сүздә әдәби телдәге тартык авазга икенче тартык аваз тәңгәл килә. Киң таралган аваз тәңгәллекләренә тукталып үтик:

**п~ф.** Бу үзенчәлек татар сүзләрендә дә, төрле алынмаларда да закончалыклы тарихи күренеш булып тора: (урта диалект) *тупыраҡ* – туфрак, *җапыраҡ* – йафрак (яфрак), *керпек* – керфек; (мишәр диалекты) *сәпәр* – сәфәр, *көпөрлек* – көферлек, *пирештә* – фәрештә, (себер диалекты) *пурмы* – форма, *пылак* – флаг, *Пидыр* – Федор һ.б.

**җ~й.** Урта диалект сөйләшләренә *җ*-ләштерү характерлы, ягъни күпчелек очракта *җ* авазы *й* авазына тәңгәлләшә. Мәсәлән: *җәшел* – йәшел (яшел), *җул* – йул (юл), *җурған* – йурган (юрган), *җегет* – йегет (егет), *җаман* – йаман (яман) һ.б. Мишәр диалектына сүз башында *й*-ләштерү (бу күренеш әдәби телдә *җ* белән башлана торган сүзләрдә дә күзәтелә): *йаулык* – яулык, *йул* – юл, *йил* –җил, *йиләк* – җиләк, *йер* – җир һ. б.

**ҡ, к~х.** Бу тәңгәллек урта диалектның кайбер сөйләшләрендә (мәсәлән, керәшен татарлары сөйләшләрендә) очрый: *ҡатын* – хатын, *ҡалыҡ* – халык, *ҡат* – хат, *маҡырым* – мәхрүм, *аҡыҡ* – ахак, *җомаҡ* – оҗмах, *аҡирәт* – ахирәт, *көкөмәт* – хөкүмәт, *кәреп* – хәреф, *паскы* – пасха, *китырый* – хитрый. Мишәр диалектында тирән тел арты *ҡ, ғ, х* авазлары урынына тел арты *к, г, х* авазларын куллану: *кала* – кала, *ак* – ак, *сакла* – сакла, *карга*– карга, *барган* – барган, *хал'* – хәл, *хайлә* – хәйлә һ.б. **ҡ~х** тәңгәллеге төрле дәрәҗәдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә таралган, керәшен сөйләшләрендә, кама тамагы, пермь сөйләшләрендә һәм себер диалектарында исә системалы рәвештә күзәтелә.

**к~т.** Бу үзенчәлек билгеле бер сүзләрдә генә очрый: *кенәген/төнәген* – кичә, *келәү* (итү) – теләк итү, *келәнче* – теләнче, *келәнү* – теләнү, *укмурт* – удмурт (биредә *д > т > к).* Киресенчә дә булырга мөмкин: **т~к:** *читләwек* – чикләвек һ.б.

Фарингаль *h* авазы, күпчелек татар сөйләшләрендәге кебек, бөтенләй әйтелми. Сүз башында бу аваз төшә: *әр* – һәр, *аман/әмән* – һаман, *әрбер* – һәрбер, *аwа* – һава, *өнәр* – һөнәр, *ич* – һич, *әwәс* – һәвәс. Ике сузык арасында килгәндә *h* тартыгы *ғ/г* белән алмашына яки бөтенләй төшә: *җиғаз* – җиһаз, *бәгә* – бәһа, *җәгәннәм/җәннәм* – җәһәннәм, *шәгәр/шәр* – шәһәр, *зәгәр* – зәһәр. Бу үзенчәлек – татар теле диалектларына хас булган уртак күренеш.

Метатеза (янәшә яки арадаш торган авазларның урыны алышу) күренеше түбәндәге мисалларда күзәтелә: (урта диалект) *җерегеменче* – егерменче, (мишәр диалекты) *күгәлә* – күләгә, *күсәртү* – күрсәтү.

Морфологик диалектизмнар – әдәби телдән төрләндергеч яки ясагыч кушымчалар белән аерыла торган үзенчәлекләр (Әхәтов, 1995: 79–80). Морфологик диалектизмнар дигәндә, беренче чиратта, татар теленә хас морфологик категорияләрнең формалашуындагы яки аларның мәгънә төсмерләрендәге аерымлыклар күздә тотыла. Мәсәлән, инфинитивның урта диалектта *-мағa/-мәгә, -ма/-мә (укымага китте, чийә ашама йарата),* себер диалектларындагы *-ғале/-гәле (укығале китепте, цийә ашағале йарата)* формалары – диалекталь күренеш. Бер үк мәгънәне белдерә торган сүзләр сөйләшләрдә бер үк тамырдан төрле кушымчалар ярдәмендә ясалырга мөмкин. Мәсәлән, әдәби телдә *йоткылык – йотма;* әдәби телдә *эремчек – эрек* һ.б.

I һәм II зат берлек сан тартым кушымчалары алган исемнәрнең төшем килеш формасы әдәби телдәгечә дә *(-ны/-не),* угыз формасында да (*-ы/-е)* ясала: *кулыңы, узеңе.* Мәсәлән, шарлык сөйләшендә *Йәшеме алдап йаздырып җалдым.*

Икеләтелгән тартым кушымчасын ялгау аеруча алмашлыкларда, тагын *бер, каршы* сүзләрендә күзәтелә: *ансысы* – анысы, *босысы* – бусы, *берсесе* – берсе (казан арты, керәшен, тау ягы сөйләшләрендә). Ел фасыллары белдерә торган сүзләрдән *-лый/-ли(й)* кушымчалары ярдәмендә дәвамлы вакыт рәвешләр ясала: (мамадыш сөйләше) *Җышлый* (кыш буе) *балаларда, җалада торам, җәйли* (җәй буе) *мона тушы өйдә торам инде.*

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльләрнең *-ган/ -гән* кушымчалы формаларына зат кушымчалары урынына тартым кушымчалары ялгану мамадыш сөйләшенең үзенчәлекле билгеләреннән берсе булып тора: *килгәнем* (килгәнмен), *килгәнең* (килгәнсең), *килгәнебез* (килгәнбез), *килгәнегез* (килгәнсез); *алганым* (алганмын), *алганың* (алгансың), *алганыбыз* (алганбыз), *алганыгыз* (алгансыз). Тамырлары ***-р*** сонорына беткән хикәя фигыльләрнең киләчәк заман I зат берлек сан формасы тулы һәм кыска вариантларда кулланыла: *Барсысын да сөйләрем* (сөйләрмен), *гөлкәйем*.

Хикәя фигыльләрнең *-гәч/-қач* кушымчалы формаларына *-тын/-тен* аффикслары ялгану Урал ареалындагы мишәр һәм урта диалект сөйләшләренә хас үзенчәлек. Мәсәлән: *килгәчтен*, *қайтқачтын.*

Йөкләтү юнәлешенең ясалашында *-гыр/-гер, -қыр/-кер* (урта диалектта), *-гыз/-гез* (мишәр сөйләшләрендә) вариантлары күзәтелә: *Туйларны хәдер ничек үткәзми* (үткәрми) *калым инде. Бутыйларын кигерәм* (кидерәм), *жәлли ийем шул.*

Инфинитивның *-мага/-мәгә* формасы, нигездә, билгеле тәгъбирләрдә генә күзәтелә: *асрамага бала бирү* – асрарга, *утырмага бару* – кул эше белән, еракта яшәгән туганыңа барып, берничә атна торып кайту (минзәлә сөйләше).

Лексик диалектизмнар дигәндә әдәби телдә булмаган, бары сөйләшләрдә генә күзәтелә торган сүзләр күздә тотыла (Рамазанова, 2008: 5). Мәсәлән, (касыйм сөйләше) *алсын* – килендәш; (пермь сөйләше) *иләсә* – бияләй; (нократ сөйләше) *башбата* – кабер ташы; (мишәр диалекты) *кәркеш* – чабата киндерәсе, *кизек* – ягу өчен сугыла торган тирес кирпич; (мамадыш сөйләше) *хәмдәш* – туган-тумачалар, *сөлән* – чылбыр; (шарлык сөйләше) *ултар* – абзар алдындагы бүлеп чыгара торган урын; (богырыслан сөйләше) *чөм* – утырта торган бәрәңге күзе; (тау ягы сөйләше) *кон* – төс, *кәй* – ямьсез, начар,; (казан арты сөйләше) *кутаз* – кыңгырау; (сергач сөйләше) *цәпе* – тастымал; (бөре сөйләше) *чети* – тинтәк, ахмак; (себер диалекты) *агуын* – кыр тавыгы, *шәлтәп* – бишек; (хвалын сөйләше) *буй* – күлмәкнең кысасы, өске өлеше; (темников сөйләше) *сакма йага* – изү; (стәрлетамак сөйләше) *кийенчәк* – киемнән тыш һәртөрле бизәнү әйберләре, муентәңкә(се), *пөтөн тәңкә, мунса* – тәңкәләр тезеп эшләнгән, муенга киелә торган бизәнү әйбере; (богырыслан, стәрлетамак сөйләшләре) *пи-*

*тырас* – калган камырдан пешерелгән кечкенә икмәк; (темников, ләмбрә, кузнецк сөйләшләре) *мешке* – эремчек, *җәймә* – яхшы он һәм күкәйдән генә әзерләнгән төче камырны, юка гына итеп җәеп, майда пешерелгән камыр ашы (ул – ритуаль ашларның берсе: 40 җәймәне махсус сандыкка тутырып, туйга кода күчтәнәче итеп алып барганнар; (стәрлетамак сөйләше) *тәкә* – кечкенә сумса, *куптермә* – борчак оныннан пешерелгән калынрак коймак; (минзәлә, нократ сөйләшләре) *ак//сийыр агы* – сөт һәм аның продуктлары; (мишәр диалекты) *тилгән* – карчыга; (стәрлетамак сөйләше) *кормош* – шөпшә, *ак таракан* – кыргаяк һ.б.; (стәрлетамак, минзәлә сөйләшләре) *кырмаюык, кырмалау* – тигәнәк; (бөре сөйләше) *кәберкә//кәбәркә* – мич белән стена арасындагы урын; (байкибаш сөйләше) *уша* – мич буенда яки ишек ягы стена буенда комган, киез итек кебек әйберләр кую өчен җайланган тар такта, *купы* – аш савыты, *кәлземә//кәлҗемә* – черегән бәрәңге күмәче һ.б.

Семантик диалектизмнар әдәби телдәге шундый ук сүздән мәгънәсе белән аерылып торган берәмлекләр. Аларны *омоним диалектизмнар* буларак та карыйлар (Әхәтов, 1995: 80). Мәсәлән: (минзәлә сөйләше) *қойо* – кечкенә елга; (себер диалекты) *қура* – абзар; (златоуст сөйләше) *қарағай* – нарат; (шарлык сөйләше) *почмак* – кухня, *чокыр* – чынаяк; (мамадыш сөйләше) *сакал* – ияк, *сәке* – кече бүлмә; (каргалы сөйләше) *шеш* – туйның соңгы көнендә пешерелгән бәлешкә камырдан ясап кулган фигуралар: ул туй мәҗлесенең беткәнен аңлата; (шарлык сөйләше) *песәй* – ыргак»; (касыйм сөйләше) *роза* – төче камырдан пешерелә торган кунак ашы: берничә кашык каймак яки сөт һәм йомыркага гына басылган ак он камырын юка гына итеп җәяләр дә аны тар тасмалар итеп кисәләр, киселгән тасмаларны трубкасыман итеп төреп, кызган майга салып пешерәләр; (балтач сөйләше) *думбра* – төклетура; (норлат, каргалы сөйләшләре) *матур* – әйбәт, яхшы, хуш исле; (златоуст сөйләше) *песнәк* – сукыр лампа; (тархан сөйләше) *куркыныч* – карачкы; (бараба диалекты) *киндер* – кычыткан; (себер диалекты) *алаша* – тәбәнәк; (казан арты керәшеннәре сөйләше) *арғыш* – туйда иң олы, дәрәҗәле кеше, туй башлыгы; (нагайбәк керәшеннәре сөйләше) *сәрән суғу* – пасха бәйрәме көнне атка атланып йомырка җыеп йөрү кебек сүзләр белән аерымлана; (стәрлетамак сөйләше) *тезмә* – матча кашагасы; (мамадыш сөйләше) *башмақ* – йон оек, *күн калуш* – күн ботинка, *беләк* – икмәкнең башы;

(минзәлә сөйләше) *төрмә* – эченә киндер орлыгы яки эремчек салып пешерелгән бөккән; (стәрлетамак сөйләше) *қағу* – утау; (бөре, минзәлә сөйләше) *бәйләм* – бәйләнгән оек, *бөтөн ойок* – озын кунычлы йон оек; (мәләкәс, чистай, пермь сөйләшләре) *сеңер* – будырмалы резин тасма, будыргыч; (стәрлетамак сөйләше) *кызыл тун* – камка, чуар таракан һ.б.

Диалектизмнар арасында фразеологик төрләр дә булырга мөмкин. Фразеологик диалектизмнар – җирле сөйләштә генә кулланыла торган, әдәби телдә бөтенләй булмаган тотрыклы сүзтезмә. Мәсәлән, Себер татарлары телендә: *арка-биле юан* (таза), *йөрәк әйләнү* (күңел болгану), *ит кошрау* (ачу килү), *кылыч та камчыдай* (нечкә билле), *ис асу* (ару), *шешә баш* (аңгыра) (Әхәтов, 1975; 1995). Фразеологик әйтелмәләр составында диалекталь сүзләр кулланышына түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *бортак авыз* (авызын-телен тыя белмәүче), *адраеп йөрү* (гайрәтләнеп, этәчләнеп йөрү*), азау тешен ашаган* (күп яшәгән), *аздакы көянтәсе* (усал карчык), *беткеле түгел* (бетә торган түгел), *дәгел кебек* (зифа буйлы) һ.б. (Татар теле лексикологиясе, I т., 2015: 212).

Алынма диалектизмнар – җирле сөйләштә генә кулланыла торган, әдәби телдә бөтенләй булмаган алынма сүз (Насипов, 2007: 24). Мәсәлән, *кузн’ак* (< рус. *козанок*) (стәрлетамак сөйләше) – аяк бармагының сөякләре; *кукал* (< рус. *куколь*) (мәләкәс сөйләше) – бакра, бакра орлыгы; *куфай* (карс., клд.) *куфайка,* (тау ягы-тархан сөйләше) *куфайкы,* (казан арты-мамадыш сөйләше, казан арты-балтач, казан арты-әтнә сөйләше), *куфайын* (клд.) (< рус. *куфайка*) – билгә кадәр итеп бәйләнгән хатын-кыз киеме, кофта; *кусар* (< рус. *косарь*) (мәләкәс сөйләше) – балчык кыра торган пычак, чыра пычагы; *кыwашна* (стәрлетамак сөйләше), *кыwашн'а* (клд.), *куwашна* (мәләкәс, стәрлетамак сөйләшләре), *қуwашна* (златоуст, турбаслы сөйләшләре) (< рус. квашня) – күәс, күәс чиләге; *қуҗылы* (< удм. *кузьыли*, коми. *кодзувкот, кодзыль*) (глазов, нократ сөйләшләре) – урман кырмыскасы; *шура* (< удм. *шора*) (нократ сөйләше) – күркә; *шамба* (казан арты-лаеш сөйләше), *шамбы* (гайн.) – чуртан, җәен, *жумба* (казан арты-балтач, казан арты-әтнә сөйләшләре) – җәен, (казан арты-мамадыш сөйләше) чуртан, *шамбы, жумба* (казан арты-дөбъяз сөйләше), *жумба* (минзәлә сөйләше), *жумба, жомба* (түбән кама-керәшен сөйләше), *шамбы, жомби* (гайн.), *шамбы* (златоуст сөйләше), *шамбы, жамбы, йаллы*

*шамбы* (богырыслан сөйләше) җәен (< мар. *шамба, шамбе*); *қошо, кушу* (глазов, нократ сөйләшләре), *кошо* (балез.) (< удм. *кочо*) – саескан; *низга* (< гар.) (бөре, златоуст сөйләше) – бәхәс, тавыш, низаг; *кәркеш* (< мордв.) (стәрлетамак сөйләше) – киндерә, *сылаугыч* – алды чигүле яки тәңкә һәм сәйлән белән бизәлгән, түбәтәй формалы хатын-кыз баш киеме; *пәҗи* (< мордв.) (мәләкәс сөйләше) – киндер (үсемлек) һ.б.

Алынма диалектизмнар, рус теленнән тыш, башка телләрдән дә керәләр, мәсәлән, фин-угор телләреннән кергән сүзләр; *лапақай* (шарлык сөйләше) – тәбәнәк буйлы кеше, *пима* (стәрлетамак сөйләше) – киез итек, *прамыш* (каргалы сөйләше) – кечкенә кигәвен, *мәте* (мамадыш сөйләше) – сыек пычрак һ.б. Гарәп-фарсы алынмалары: *мәһәр* (пермь сөйләше) – кияү тарафыннан кызга китерелгән әйберләр, *питырас/питырач* (чистай, стәрлетамак сөйләше, карсун, шарлык сөйләше) калган, кырып җыйган камырдан пешерелгән икмәк; *тақыйа* (мишәр диалекты) – башлык һ.б.

С и н т а к с и к  д и а л е к т и з м н а р – җирле сөйләшкә хас сүз тезмә, җөмлә төзелешенә караган үзенчәлекләр (Насипов, 2007: 24). Алар сүзтезмәләрнең ясалышы белән бәйле үзенчәлекләр санала. Исемле исем сүзтезмәләрнең (изафәләрнең) кушымчасыз тибын куллану: (пермь сөйләше) *милеш бәлеш*– миләш бәлеше, *утын чана* – утын чанасы. Әлеге изафә нигезендә яңа сүзләр дә ясалган: (пермь сөйләше) *қапқал* – капка алды, *этпорон* – диал. эт борыны – гөлҗимеш; *үкәртә* (< өй кәртәсе < өй киртәсе) – ишек алды; *дымқорт* (дым корты) – кыргаяк һ.б.

*Бер* саны, кайбер сыйфатлар һәм алмашлыклар, ияртүче кисәк белән бергә килгәндә дә, тартым кушымчасы ала: *берсе китап, олосы малайым, кечесе сеңлем, тегесе чебеч* һ.б.

Исем фигыль сүзтезмәләрендә килеш кушымчаларының төшеп калуы: (стәрлетамак сөйләше) *аwыл қайтам* – авылга кайтам; *Эстәрле барам* – Эстәрлетамакка барам; *бала күлмәк* – бала күлмәге.

Әдәби телдә юнәлеш килешен сорый торган бер төркем фигыльләр *(сугу/чапқыту, тийү, өрү)* даими рәвештә төшем килешен башкаралар: *Мине* (миңа) *ул суқмады, мин аны* (аңа) *суқмадым, шулый тордоқ без. Тагы җыласа, тагы чапқытам мин аны* (аңа), *арқырайып йөрмәсен. Сез аны* (аңа) *тимәң. Төлкө кешене* (кешегә) *тими. Сезне* (сезгә) *өрер у берәр әшнә торганчы.*

Хәбәрлек кушымчылары исем хәбәрләргә дә ялгана: *Алар өйдә йуклар. Син бәг усалсың икән элсә. Мин җылакмын үзем бик. Иптәшләр өчәүләрийек без. Ничәүсез сез? Без алты бертуган, исәмбез.*

Минзәлә сөйләшендә дә сорау җөмләләр әдәби телдәгечә үк оештырыла: *Карточкага төшү картайгачыннан нигә кирәк соң ул? Тәрәзәне ачмалы итәсегедме?* Сорау интонация ярдәмендә генә дә белдерелергә мөмкин: *Сабантуйга бармайсыз* (бармыйсызмы)? *Синнән дурлар, кечеләр* (зурлармы, кечеләрме)? *Әнәң алып бармай* (бармыймы)? *Син дә бардың* (бардыңмы) *балыкка?*

Кушма җөмләләрнең төрләре, аларның компонентларын үзара бәйләгеч чараларның составы ягыннан сөйләшләр, нигездә, әдәби телдән аерылмый. Шулай да кайбер үзенчәлекләрне күрсәтеп китик.

Иярченле кушма җөмләләрдә баш һәм иярчен җөмләләр мөнәсәббәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнәләр: (темн.) *Кырбан биргәннәр, йаңгыр йаусын ыштубы, йаңгыр намазы укыйлар.*

Иярчен сәбәп җөмләләрнең баш җөмләгә *-лык/-лек* кушымчасы һәм *белә(н)* бәйлеге ярдәмендә бәйләнүе актив: (минзл.) *Ирем көннәште, сабранҗаларга барганның белә* (барганга күрә).

Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә иярчен җөмләләр баш җөмләдән алда килә: (саз ягы сөйләше) *Көннө йылытты, қойош цыхқаң* һ.б.

Әдәби тел сөйләшләргә даими рәвештә йогынты ясый, җирле сөйләмгә тиз үтеп керә. Җирле диалектизмнар шул сәбәпле, кулланыштан төшеп, онытыла, бетә баралар. Лексик үзенчәлекләргә караганда, фонетик, грамматик диалектизмнар аеруча тотрыклы булулары белән аерылып торалар.

Матур әдәбият телендә лексик-семантик диалектизмнарга шактый киң урын бирелә. Фонетик диалектизмнар да сөйләмгә җирле колорит бирә. Алар төрле эчтәлеккә ия булып торалар. Стильләрдә (аеруча матур әдәбиятта) морфологик диалектизмнар да кулланыла. Әсәрдә катнашучыларның сөйләмен индивидуальләштерү өчен персонаж сөйләме төрле диалектизмнарны эченә алырга мөмкин. Матур әдәбият әсәрләрендә диалектизмнар телнең тарихын ачыклауда, әдәби телне баетуда зур эш башкаралар.

Диалектизмнарны өйрәнү, барлау һәм саклау мәсьәләсе тел белемендә актуальлеген югалтмый, чөнки диалекталь лексика әдәби телебезнең баю чыганакларының берсе булып тора.

## § 19. Җирле диалект һәм гомумкулланылыш лексикасының үзара мөнәсәбәте

Кулланылыш даирәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы берничә төркемгә аерыла. Алдагы бүлекчәләрдә күрсәтелгәнчә, иң зур урынны гомумхалык теле сүзләре алып тора. Алар барлык даирәләрдә дә кулланыла һәм бу төр лексика әдәби телнең нигезендә ята.

Диалект лексикасының кулланылыш даирәсе шактый тар, чөнки диалектлар, нигездә, сөйләшү өчен генә кулланыла. Әдәби тел исә, сөйләм теле булу белән бергә, матур әдәбият, радио-телевидение, публицистикада, фәнни әдәбиятта һәм башка шундый сфераларда да кулланыла, ягъни аның функциональ мөмкинлекләре бик киң.

Әдәби тел диалектларга туктаусыз йогынты ясый, ул шушы телдә сөйләшә торган халык өчен аралашу чарасы булып хезмәт итә. Икенче яктан, диалектлар да әдәби телгә йогынты ясыйлар, бу бигрәк тә лексика өлкәсендә чагыла. Яңа төшенчәләр туу белән, аларны атау өчен аеруча кулай булган сүзнең җирле сөйләшләрдән табылуы ихтимал. Кайбер лексик берәмлекләр, әдәби телдәге эквивалентлары белән чагыштырганда, күңелгә ятышлырак, кыскарак һәм төгәлрәк эчтәлекле булырга мөмкин. Сүзлекләрдә, әдәбиятта еш очраган, һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган (мәсәлән, *җайдак, буйдак, мизгел, өрфия, онта, күлдәвек, болдыр, күбә, аҗаган, тумачи,игәч, тудыка, тоҗым, әзмәвер, ару, күлләвек* һ.б.ш.) сүзләр инде әдәби телебездә дә актив кулланыла (ТТАС, I т., 1977: 11).

Диалектлар белән сөйләшләр әдәби телнең лексикасын үстерүдә ышанычлы чара булып тора. Әдәби телнең лексикасын баетуда диалекталь сүзләрне файдалану тел үсешен аңлы рәвештә көйләүгә керә (Татар грамматикасы, 1998: 207). Күренекле тел галиме М. Зәкиев тә әдәби телне баетуда диалектларның иң әһәмиятле чыганак булуларын ассызыклый (Закиев, 1965: 250).

Җәмгыять төзелешендәге төрле тарихи, сәяси, икътисади үзгәрешләрнең телгә ясаган җитди тәэсире халыкның территориаль һәм социаль аспектта күченүләре һәм аралаша башлаулары белән дә бәйләнгән. Төрле иҗтимагый һәм җирле диалект вәкилләре яңа тел шартларына килеп керәләр, аларның сөйләме чит сөйләм йогынтысын кичерә һәм үзләре дә башкаларның сөйләменә тәэсир

итә. Аерым алганда, 1917 елгы һәм аннан соңгы вакыйгалар телнең халыкчан юнәлештә үсүен тизләтәләр. Бер яктан, зыялы сөйләмнең китапча формалары юкка чыга. Икенче яктан – «дөрес» (әдәби) сөйләмнең түбәнге чикләре көндәлек аралашу теле белән кушылып китә (Меченковская, 1996: 152).

Диалекталь сүзләрнең лексикада урыны әдәби телләрнең халыкка якынаюын, әдәби тел нормаларының халыкка якын нигезләрдә корылуын билгели. Халыкчан тел формалашкан чорда әдәби телләргә, телнең эчке сүз ясалышы һәм тышкы алынмалар нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүзләр белән бергә, җирле халыкның көнкүрешен, гадәтләрен, һөнәр-кәсеп үзенчәлекләрен чагылдырган бай диалекталь лексика да үтеп керә.

XX гасырның беренче яртысында чыккан татарча-русча сүзлекләрдәге (аерым алганда, С. Рахманколый белән А. Кәрамның «Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств каждого языка, со включением иностранных слов, вошедших в употребление в русском языке» (1913) сүзлегендәге) лексик байлыкны барлап, тикшереп чыгу шуны күрсәтте: бу чор сүзлекләрендә диалекталь сүзләр шактый күп теркәлгән һәм алар арасында **лексик** диалектизмнар өстенлек итә: *бадиян, җамаяк, кәнди, кагыт, кәлҗемә, котырчык, мәмәч, паңгы, инче, кач, келәү, куркылык, бабачы, җайдак, иранай, иркәк, кортка, сәвәләй* һ.б. шундый тормыш-көнкүрешнең төрле өлкәләренә караган сүзләр сүзлекләрдә урын алган. Аларның кайберләре әдәби телгә дә кереп киткән. Сүзлекләргә теркәлгән аерым сүзләрне карап үтү кызыклы булыр: *бадъян* – чокып ясалган зур булмаган агач савыт (ТТАС, I т., 2015: 377), *бабачы* – балаларны сөннәтле итүче кеше, сөннәтче (ТТАС, I т., 2015: 370), *кәнди* – кечкенә аш савыты, кечкенә коштабак (ТТАС, II т., 1979: 252), *кәлтә* – кыска, көтек (ТТАС, II т., 1979: 251), *мәмәч* – агач кайрысы астындагы сыекча, су (ТТАС, II т., 1979: 419) һ.б.

XX гасырның беренче яртысындагы татар әдәби телендә диалекталь лексика шактый урын тоткан. Диалектизмнар арасында предметны, күренешләрне белдерүче сүзләр аеруча күп. Шулай ук төрле сыйфатлау сүзләре, фигыльләр дә шактый. Диалекталь сүзләрнең күләме буенча фикер йөрткәндә, шуны искәртү кирәк: С. Рахманколый белән А. Кәрамның «Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств каждого

языка, со включением иностранных слов, вошедших в употребление в русском языке» (1913) сүзлегендә алар азрак, ә Җ. Вәлидинең инкыйлабтан соң дөнья күргән «Татар теленең тулы сүзлеге» (1927 – I томы, 1929 елда – II томы) басмаларында җирле сөйләм берәмлекләре ешрак очрый. Бу күренешне әдәби телләрнең халыкчанлашуы белән аңлатырга мөмкин.

XX гасырның 40 нчы елларыннан фәнни яктан эшкәртелгән һәм билгеле системага салынган сүзлекләр төзелә башлый (Г. Нугайбәк, Ф. Әмирхан, М. Корбанов, С. Фәйзуллин, Р. Газизов, М. Гыймадиев «Татарча-русча сүзлек», 1938–1951; Г. Әмиров, А. Әсәдуллин, Ү. Байчура, Ш. Ханбикова, Л. Мәхмүтова «Татарско-русский словарь», 1966).

XX гасыр урталарыннан сүзлекләр төзү эшен Тел, әдәбият һәм тарих институты башкарып килә (русча-татарча сүзлекләр: 1956 – I том, Р. Газизов, М. Гимадиев; 1955– II том, Р. Газизов, Л. Мәхмүтова, Э. Ахунҗанов, Ф. Газизова; 1959 – III том, Р. Шакирова, Э. Ахунҗанов, Л.Т. Мәхмүтова, Ф. Фәсиев, Р. Шәкүров, Г. Әмиров; Ф. Ганиев: 1984, 1985, 1991, 1997; И. Абдуллин, Ф. Ганиев, М. Мөхәммәдиев, Р. Юналиева, 1988, 1995, 2014; Ш. Асылгәрәев, Ф. Ганиев, М. Зәкиев, К. Миңнуллин, Д. Рамазанова, 2007). Аңлатмалы сүзлекләрдә, лексик байлыкның бер өлеше буларак, диалектизмнар да бирелә (Л. Мәхмүтова, М. Мөхәммәдиев, К. Сабиров, Ш. Ханбикова, I том, – 1977, II том – 1979, III том – 1981; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, I том: 2015).

Сүзлекләрдә урын алган диалекталь берәмлекләрнең күп өлеше урта диалект сөйләшләренә карый. Мәсәлән, *мәлсез* – вакытсыз. *Мәлсез чәчәк ярылмас* (Русча-татарча сүзлек, 2007: 30). *Мәрә* – 1. түгәрәк (уенда), 2. мишень (уктан атар өчен); *мәрәй* – 1. мишень, 2. җирдә уен өчен төшерелгән түгәрәк, 3. уен майданы, 4. түгәрәккә эләгү максаты булган уеннар исеме, 5. аткы (уенда) (шунда ук: 31); *олан* – бала, күплек санда *оланнар* – 1. бала-чага, балалар, 2. туганнар, иптәшләр (өлкән кешенең олыларга мөрәҗәгать иткәндә), *оланлык* – балачак (шунда ук: 93); *пияш* – 1. мич кырындагы багана (әйберләр куяр өчен махсус урыннар ясалган), 2. пассив, тыңлаучан кеше (шунда ук: 147); *сәркәш* – җигүле үгез (шунда ук: 226); *тигезү* – тидерү (шунда ук: 371); *уңалу* – терелү, тазару (шунда ук: 478). Алар арасында саф лексик диалектизмнар күбрәк, шулай ук кайбер җирле фонетик үзенчәлекләр дә урын алган, аларның

күбесе *җ*-ләштерү һәм *й*-ләштерү күренешенә карый: *җегерләү* – эрләү (Русча-татарча сүзлек, 2007: 389), *йонтаслану* – йөнтәсләнү (шунда ук: 485) шулай ук башка аваз чиратлашулары да, аваз үзгәрешләре дә күзәтелә. Семантик диалектизмнар да очрый, морфологик диалектизмнарны юк дияргә мөмкин, мәсәлән *җәйләү* – чәй чыянагы (шунда ук: 385), *йомшак* – калач, йомшак ак икмәк (шунда ук: 481) һ.б.

Җирле диалект һәм гомумкулланылыш лексикасының үзара мөнәсәбәте сүзлекләргә диалекталь сүзләрне теркәүдә ачык чагыла. Әлеге чагылышның объектив сәбәпләре дә ачыклана: җирле сөйләм сүзләрен активлаштыру, әдәби телне баету; сүзлекләрдә төрле диалект һәм сөйләш вәкилләренең куллану мөмкинлеге исәпкә алынган; кайбер сүзлекләр төзелгән чорда әдәби тел һәм диалектлар чиге билгеләнеп бетмәгән булган; авторларның билгеле бер диалект, сөйләш вәкиле булуы сүзлеккә сүзләр сайлаганда шулай ук тәэсир иткән булырга мөмкин; сүзлекләргә диалекталь сүзләрне теркәү авторларның әдәби телне начар белүләрен күрсәтми, чөнки күпчелек диалекталь элементлар янында аларның әдәби телдәге синонимнары бирелгән яки шуларга сылтама тәкъдим ителгән; бу эштә татар вакытлы матбугаты үсү дә үз өлешен керткән: алар әдәби телгә төрле диалекталь, гади сөйләм сүзләре үтеп керүгә юл ачкан.

## § 20. Җирле диалект лексикасының функциональ-стилистик вазифасы

Җирле сөйләм, гадәттә, персонаж телендә ишетелә, аның кайсы тарафтан булуын, тел культурасын тойдырырга, типиклаштырырга, индивидуальләштерергә булыша. Безнең язучылар аеруча көнбатыш диалектын яратып кулланалар. Соңгы елларда, мәсәлән, татар әдәби теленә *тоҗым, өрфия, күлләвек (күлдәвек, күләвек), сыкы, ымсыну, отыры, дуадак* кебек сүзләр килеп керде. *Тоҗым* сүзен әдәби телгә кертеп җибәрүе турында Г. Бәширов болай дип яза: *«Көз көне һава коры һәм аяз вакытта басуларда хасил булып, камылларга, коймаларга һәм агач кәүсәләренә сарыла торган җеп сыман бу ак нәрсәне Арча ягында шулай атыйлар. Әмма күп урында, үзенә аерым исеме булмаганлыктан, аны үрмәкүч пәрәвезенә охшатып, күрәсең, я пәрәвез, я, Тукай районының кайбер авылларындагы кебек, әби җебе дип йөртәләр. Әмма болар бер-*

*се дә, билгеле,* ***тоҗымның*** *нәкъ үзен әйтеп бирә алмый»* (Бәширов, 1974: 13). Бу сүзнең инде әдәби телгә кереп китүе турында башка язучылардан алынган мисаллар дәлилләп тора. *«Октябрь башында да, әбиләр чуагындагы кебек, сукаланган басу өсләрендә* ***тоҗым*** *җепләре уйнаклый иде әле»* (В. Гали), *«...Һавада тоҗым җепләре очып йөри»* (Г. Әпсәләмов).

XIX йөз шагыйре Ә. Уразаев-Кормаши поэмаларында Себер татарлары диалекты төсмерләнә:

*Зөһрә бер шигырь әйтте:*
*Тәкъдир җитеп* ***сөепмен****, күп бәетләргә* ***сөйләпмен****,*
*Хур кызыннан гүзәлне сукканында* ***көепмен****.*
*Таһир җавап бирде:*
*Күп гөнаһны* ***кыйлыпмын****, инде алдына* ***килепмен****,*
*Җаным сөйгән Зөһрәҗан, кич дип, өмет* ***кыйлыпмын****.*

Җирле сөйләмнең матур әдәбиятта билгеле бер әһәмиятле урыны диалект һәм милли телнең үзара бәйләнеше, йогынтысы белән билгеләнә. Диалектлар – халыкның тел диңгезен тулыландырып торучы чишмәләр алар. Ул чыганаклардан уртак телгә мәшәкатьсез аңлашылырдай сүзләр, гыйбарә, фразалар керә тора. Язучы да, берәр сүз әдәби телдә булмаганда, җирле сөйләмгә мөрәҗәгать итә һәм кайбер сүзләр әдәби сүзгә әйләнә (Хатипов, 2002: 121).

Әдәби әсәрдә кулланылган диалектизмнар шул якның милли колоритын сурәтлиләр.

Диалекталь сүз әдәби телгә түбәндәге очракларда килеп керә: 1) әдәби телдә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаса; 2) персонажның сөйләм үзенчәлеген сурәтләү өчен; 3) язучының үз хикәяләвендә милли колорит бирү өчен; 4) этнографик лексиканы бирү максаты белән.

Беренчесенә генә тукталыйк. *Тегермән стеналарына кунып кала торган он тузаны* дигән төшенчәне белдерү өчен әдәби телдә сүз юк. 1956 елда ук инде С. Хәким болай дип язган булган:

*Сүтәләр өч ташлы тегермәнне,*
*Стенадан, калын түшәмнән*
*Беркемнең дә кулы кагылмаган,*
*Соңгы ачлык узгач түшәлгән*
***Онта*** *коела, күксеп беткән* ***онта****...*
(«Кадерле почмак»).

Диалекталь сүзләрне куллану әсәрнең темасына, сурәтләү объектына, авторның максатына, аның эстетик идеалына, осталыгына бәйле. Татар язучыларының күпчелеге авылдан чыкканга күрә, һәр язучы үзе яшәгән төбәкнең диалекталь лексикасын куллана. Бу – автор сөйләмендә дә, персонаж сөйләмендә дә күзәтелә, хәтта аерым очракларда публицистикада да урын ала. Г. Бәширов, М. Мәһдиев әсәрләрендә ул Казан артын күзалларга мөмкинлек бирсә, М. Хәбибуллин, М. Галиев, А. Гыйләҗев иҗатында урта диалектның минзәлә сөйләшенә хас үзенчәлекләрне хикәяләүгә алып керә. Х. Сарьян, Ә. Еники әсәрләрендә диалекталь сүзләр типтәр сөйләшләрен күз алдына китереп бастырырга мөмкинлек бирә. Ф. Сафиуллина хезмәтендә (Сафиуллина, 1999: 91) диалекталь лексиканың татар поэзиясенә үтеп керүенә берничә мисал китерә:

*Урманлы үрләр өстендә*
***Нажҗәгай*** *уйный төннәрдә* (Г. Афзал).

*Нажҗәгай* минзәлә, *нажҗәгый* стәрлетамак, *нажҗәқай* пермь сөйләшләрендә әдәби телдәге *аҗаган* төшенчәсен бирү өчен кулланыла. ***Нажҗақай*** *уйный, диләр қартлар, арыш пешә, дип әйтәләр* (пермь сөйләше) (ТТЗДС, 2009: 492).

*Күкерт кебек кабынып китәм*
***Елдырымнан*** (Р. Харис).

*Йылдырым* 1. пермь сөйләшендә аҗаганны белдерә. *Йылдырым у безнеңчә ашлық җиткезә торған, йәшен ул дөберди*; 2. Тубыл сөйләшендә – яшен (ТТЗДС, 2009: 262).

*Актанышның ап-ак буранында*
***Сырындылар*** *тездән тирән булды* (Х. Әюп).

*Сырындық* красно-уфим сөйләшендә – кар өеме, көрт. *Қар сырындығына кереп батканнар* (ТТЗДС, 2009: 596).

*Тагын күз алмыйча карыйм –*
*Яшел яфрак* ***өрфиясенә*** (Р. Гатауллин).

*Өрфия* минзәлә, стәрлетамак, богырыслан, каргалы сөйләшләрендә – калайдан ясалган юка тәңкә (ТТЗДС, 2009: 513).

*Зәңгәр юлдан чыкты романтика,*
***Күлләвектән*** *кояш чәчрәтеп* (Ф. Сафин).

*Күлләwек* каргалы, богырыслан, шарлык сөйләшләрендә уйсулык, үзәнлек. *Менә бу борыннан күлләwектән китәбез* (ТТЗДС, 2009: 350).

*Елга буендагы* ***муелларда***
*Елмаюың калган уелып* (М. Әгъләмов).

*Муйыл* ләмбрә, сергач, стәрлетамак, кузнецк, минзәлә, златоуст, эчкен, турбаслы, түмән, тепекәй, тубыл, тәвриз, саз ягы сөйләшләрендә – шомырт. *Муйыл ашап тешләрем каралды* (ТТЗДС, 2009: 485).

Поэзиядә диалектизмнарны әсәрләр тукымасында куллану традицияләре бөек классикларыбыз шигырьләрендә үк чагыла. Д. Рамазанова Г. Тукай әсәрләрендә диалектизмнар чагыштырмача аз очравын ассызыклый, һәм Г. Тукай әсәрләре телендәге җирле үзенчәлекләргә күзәтү ясау да аның бай мирасының әлегә кул тимәгән сәхифәләре бар икәнен күрсәтә. Әдибебезнең иҗаты, фикер-фәһем тирәнлеге генә түгел, шуларны белдерә торган сүзләрнең һәм формаларның күптөрлелеге дә гаять тирән кызыксыну уята дигән фикерне күтәрә галимә (Рамазанова, 2010: 34–37). Г. Тукай әсәрләрендә диалектизмнар куллануга кайбер мисаллар китерик.

Күршеләрнең рәнҗи ирде җаннары,
***Түзмәерди*** *җаннары, вөҗданнары*
(*түзмәерди* – түзми иде).

*Дәрдеманд мәсьүл улырмы? Мөбтәлаем,ниләем?*
*Җиseme җанымлә бәрабәр бер бәлаем, ниләем?*
*Агыйделнең аръягында атлар йөри* ***чабында;***
*«Чүкеч» сабын кимереп елый, «Яшен» суккан чагында.*

*Чабын* (Тукай, Т. II; 15, 279) – әдәби телдә – чабынлык. Чабын – 1. лаеш, минзәлә, стәрлетамак сөйләшеләрендә – чабынлык (покос, место косьбы). *Элек чабын ийе, печән чабалар ийе* – стәрлетамак сөйләше; 2. лаеш, минзәлә сөйләшендә – болын, печәнлек (луг). *Әле чабында печән чабабыз* – лаеш сөйләше; 3. минзәлә сөйләшендә – печәне чабып алынган җир (скошенный луг) (ТТЗДС, 2009: 722).

*Гаҗәпләнеп* ***бүз тургайга****: басып сайрый кургайга;*
*Һич кешгә белдермәймен – зарый кылам Ходайга.*

*Бүз тургай, бастурғай* камышлы сөйләшендә – бүдәнә, бытбылдык (перепёлка). *Бастурғай дигән қош бар* (ТТЗДС, 2009: 102),

*бистурғай* камышлы сөйләше – тургай (жаворонок) (ТТЗДС, 2009: 124), *бустыр’ай* касыйм сөйләше тургай (жаворонок) (ТТЗДС, 2009: 139), *бүзтурғай* әстерхан сөйләше – чыпчык (воробей) (ТТЗДС, 2009: 141).

*Үзеңдә ялкаулык,*
*Хатыныңда **аңкаулык**...*

*Аңкаулык* – аңгыралык, ахмаклык; *аңқау* богырыслан, әстерхан сөйләшләрендә – аңсыз, надан. *Аңқау бит инде әwәлге халық, башы эшләмәгән бәрәңге чәчәргә* – богырыслан сөйләше (ТТЗДС, 2009: 46).

Әдипләр иҗатында, әдәби тел белән бергә, поэтик таләпләр нигезендә җирле сөйләш сүзләре һәм грамматик күренешләр дә урын алырга мөмкин. Шагыйрьләр, язучылар әсәрләрендә кулланылган диалектизмнар – аларның туып-үскән төбәк сөйләше белән бәйләнешен билгеләүче күренеш.

*Безнең тугайның үләне – сарут белән **кәрешкә**,*
*Язлар үтте, җыен бетте, инде без төштек эшкә* (М. Гафури).

*Кәрешкә* минзәлә, стәрлетамак сөйләшләрендә ‘тычкан борчагы’ мәгънәсен аңлата.

*Чыгалмый **мурдада** тәмам адашты:*
*Кереп килгән ишек юк, кайда качты?* (М. Гафури).

*Мурда* – балык тотар өчен эшләнгән корылма. Гадәттә, балыклар анда керәләр, әмма кире чыга алмыйлар. *Мурда* сүзе рус теленнән кергән (морда), тепекәй сөйләшендә кулланыла. Минзәлә һәм пермь татарлары сөйләшләрендә әлеге предмет *кубыр* дип атала. ***Мурдағыз** йукмы? Зөфәр, мурданы кара* (ТТЗДС, 2009: 487).

*Яхшыга җәннәт, яманга ут белән вәгъдә кыйла,*
*Чөнки бездә иң матур сүзләр **гелән** шулай була* (М. Гафури).

*Гелән* сүзе урта диалектның минзәлә сөйләшендә, мишәр диалектының карсун, стәрлетамак сөйләшләрендә *һәрвакыт* мәгънәсендә кулланыла. «*Китәм, сүләшеп йөдәтмә **гелән*** – минзәлә сөйләше; ***гелән** кер йуу булмый* – стәрлетамак сөйләше; *йыклаганда раwан җаным **гелән** сине эзлидер* (халык җыры) – карсун сөйләше» (ТТЗДС, 2009: 153).

Әйтеп үтелгәнчә, диалектизмнар язучылар тарафыннан да төрле максатларда файдаланыла: әйтик, әдәби телдә теге яки бу төшенчәне белдерергә сүз булмаса, әсәрдә тасвирлана торган вакыйгаларда җирле колоритны чагылдыру өчен, персонажларның образларын тирәнрәк, үтемлерәк итеп ачу таләп ителгәндә. Мондый очракларда язучының үз диалекты да аның әсәрләрендә чагылыш табарга мөмкин. Мәсәлән, М. Гафури иҗаты тел ягыннан бай. Анда без, әдәби телдәге сүзләр белән беррәттән, җирле сөйләшләргә караган сүзләр белән дә очрашабыз. Ул лексик диалектизмнарны я каһарманнарның характерларын тулырак сыйфатлау өчен файдаланган, яисә аның әсәрләрендә үзенең туган җире сөйләше чагылыш тапкан. Мәсәлән аның «Кара йөзләр» повестенда мондый төр диалектизмнар еш очрый: ***Күбәләр*** *түшәлеп беткәч, кибән тирәсенә җыелдык, шунда Галимә апа, әтисенең кулындагы озын кибән сәнәген алып, зур итеп күтәрде* (М. Гафури).

*Күбә* минзәлә, каргалы, тепекәй, стәрлетамак сөйләшләрендә печән чүмәләсе (копна сена) мәгънәсен аңлата. «*Wахыт булмаганда күбә йасап тормыйбыз, чәнчем көйө төйәп җибәрәбез фурманга кәбән ҡойар өчөн. Күбә зурраҡ була, кәбән бәләкәйрәк була* – минзәлә сөйләше. *Песәннеке күбә була, сүмәлә арышныҡы гына була, күбәне ҡалай ҡуйасың, пер арбага петмәгәннәре дә була* – тепекәй сөйләше (ТТЗДС, 2009: 342).

*Галимә апа, Фәхри бабайның (атасының) сүзләрен ишетү белән, пичкә таба* ***сырыкты****, калтырана башлады*» (М. Гафури).

*Сырыкты, сырыгыу* – урта диалектның златоуст сөйләшендә *сыену* (прибегать к покровительству кого-либо, обращаться к кому-либо за покровительством) мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән: *Өйне саттым да балаларга* ***сырыгырга*** *булдым* (ТТЗДС, 2009: 596).

Диалектизмнар язучының үзе туып үскән төбәгендәге сөйләшкә зур ихтирамын күрсәтә. М. Мәһдиевның «Бәхилләшү» романында шундый юллар бар*: Казанның ортопедлары могҗиза ясадылар: ике кулының икесен дә урталай ярып җәплекә эшләделәр һәм кашык тотарлык, каләм тотарлык уентык эшләделәр*. Монда диалекталь төсмерле сүз – *җәп.* Тау ягы, дөбъяз сөйләшләрендә – тармак, үрелгән, ишелгән әйберләр турында (ТТЗДС, 2009: 184). *Йәп* сүзе 1. Тау ягы сөйләшендә – үсеп утырган агачның ботагы: *ике йәпле тал ийе*. 2. мәләкәс сөйләше – чәч толымын аңлата: *бер*

*йәпкә берсен, бер йәпкә берсен тага идем чулпыны* (ТТЗДС, 2009: 242).

Соңгы елларда татар теленең торышы, аның үсеш мәсьәләләре белән кызыксыну аеруча активлашты. Татар халкының милли үзенчәлекләре, матди һәм рухи мәдәнияте белән бәйле төшенчәләрнең, диалекталь сүзлекләрдә генә түгел, башка төр сүзлекләрдә дә берникадәр урын алуы моның ачык мисалы. Диалектизмнарны әдәби текстларда куллану мисаллары шулай ук татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә дә урын алып тора.

Рус галиме Л. Самотик диалектизмнарның әдәбияттә куллану функцияләренең, чагыштырма рәвештә, тулырак классификациясен бирә (Самотик, 1998: 42):

1. Модель ясау функциясе – чын, саф халык сөйләшен күрсәтү – матур әдәбиятта реалистик методны булдыручы чара.

2. Модель ясау функциясе читләшү алымы ярдәмендә барлыкка килә. Әлеге алым аеруча автор сөйләмендә кулланыла (диалектизмның чыганагы билгеләнә), яисә кыек читләшү аша, бу очракта әдәби сүз график яктан аерыла (куштырнаклар, курсив), яисә астөшермәләр ярдәмендә, әдәби тел синонимы ярдәмендә бирелә.

3. Номинатив функциясе – лексика өлкәсендә төп функциясе. Этнографизмнар аша махсус мәгънәгә ия була.

4. Эмотив функция – диалектизмнар аша хәбәр ителгәнгә геройның һәм әсәр авторының субъектив мөнәсәбәте ачыклана.

5. Кульминатив функция – укучының игътибарын сүзгә җәләп итү функциясе. Сүзнең график тышкы бөтенлеген бозу ярдәмендә барлыкка килә, икенче төрле әйтсәк, орфография һәм грамматика кагыйдәләреннән читләшү, яисә әдәби телгә чит булган сүзләр – лексик диалектизмнарны куллану.

7. Эстетик функция – диалектизмга әдәби лексика белән чагыштырма рәвештә специфик үзенчәлекләре булган сүз буларак карау.

Димәк, матур әдәбиятта диалектизмнарның мәгънә төрлелеге күзәтелә. Автор аның мәгънәсен астөшермә формасында, сүздән соң җәя эчендә бирергә яки куштырнаклар эчендә күрсәтергә мөмкин; диалекталь сүзнең мәгънәсе автор яки персонаж тарафыннан тасвирлап күрсәтелергә дә мөмкин. Диалектизмнарны тикшерү, язучының тел-стиль үзенчәлекләрен генә түгел, татар әдәби теленең формалашу тарихын өйрәнү өчен дә зур әһәмияткә ия.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИҖТИМАГЫЙ ДИАЛЕКТ ЛЕКСИКАСЫ

## § 21. Телнең иҗтимагый диалект лексикасы турында гомуми мәгълүмат

Хәзерге тел белемендә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып милли телләрнең иҗтимагый яктан төрлелеген өйрәнү тора. Телнең иҗтимагый яктан төрлелеге турында гомуми тел белемендә беренчеләрдән булып танылган тел галиме, Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган И. Бодуэн де Куртенэ әйтә. Телнең горизонталь (территориаль) һәм вертикаль (иҗтимагый) яктан бүленгәнлеге, тел яшәешенең бары тик җәмгыятьтә генә мөмкинлеге фикере соңрак социолингвистика фәне формалашуына да тәэсир итә (Бодуэн де Куртенэ, 1963: 90). XX йөзнең беренче яртысында бу мәсьәләгә А. Мейе, танылган швейцар галиме Ф. де Соссюр укучылары А. Сэшеэ, Ш. Балли, Ж. Вандриес, А. Матезиус и Б. Гавранек, Э. Сепир, Дж. Фёрс һәм башкалар игътибар итәләр.

Рус тел белемендә иҗтимагый диалект лексикасы хакында Е. Поливанов, А. Селищев, Р. Шор, Л. Якубинский, Б. Ларин, В. Жирмунский, М. Петерсон, А. Баскаков, В. Виноградов, Г. Винокур, М. Бахтин, В. Бондалетов, Л. Крысин, В. Михальченко һ.б.ның хезмәтләре игътибарга лаек.

Татар тел белемендә әлеге мәсьәлә В. Богородицкий, М. Зәкиев, В. Хаков, Ф. Сафиуллина, Р. Йосыпов, Л. Бәйрәмова, Ф. Сәгъдиева, З. Исхакова, А. Фәйзуллина, Д. Вахитова, Н. Галиева һ.б.ның хезмәтләрендә төрле дәрәҗәдә яктыртыла. Татар тел белеме фәнендә сөйләм теленең кулланылыш үзенчәлекләренә, әдәби тел нормаларына багышланган хезмәтләрләрдән сөйләм теленең аерым бер ярусын үзәккә алып, монографик планда эшләнгәннәре күп түгел. Беренчеләрдән булып диярлек, бу мәсьәләне монографик планда эшләүгә Ф. Сафиуллина алынды. Аның «Синтаксис татарской разговорной речи» (Казань, 1978) хезмәте бүгенге көндә дә гаять актуаль булуы белән, фәнни яктан бик югары дәрәҗәдә эшләнгәнлеге, сөйләм теле синтаксисына хас киң таралган үзенчәлекләрне һәм нечкәлекләрне тирәнтен анализлавы белән аерылып тора. Моннан кала, XX–XXI гасыр чикләрендә сөйләм теленә кагылышлы аерым мәсьәләләр М. Зәкиев, И. Низамов, Р. Йосыпов, Ф. Хисамова, Ф. Сәгъдиева, М. Сәйхунов һ.б. тарафыннан яктыртылды. Шулай да хәзерге татар теле белемендә телнең иҗтимагый яктан

төркемләнүен, әлеге төркемнәрдә телнең кулланылыш үзенчәлекләрен тулаем яктырткан монографик хезмәтләр юк.

Бүгенге җәмгыятьтә телнең иҗтимагый яктан төрлелеге шактый киң таралган күренеш санала, чөнки төрле социаль төркемнәр барлыкка килү һәм активлашу, әдәби тел нормаларының сакланмавы, әдәби телгә куелган таләпләрнең үтәлмәве тел берәмлекләренең кулланылыш даирәсе киңәюгә, тел системасының чикләре бозылуга китерә. Әлеге сәбәпләр аерым катламнар телендә генә кулланыла торган берәмлекләрнең кулланылыш даирәсе һәм активлыгы артуга китерә. Моңарчы бары тик бер катлам теленә генә хас берәмлекләрнең гомумкулланылыш даирәсенә үтеп керүе, шул сәбәпле иҗтимагый диалект берәмлекләренең кулланылыш вазифасы артуы, әдәби телдә төрле вариантлар кулланылу күзәтелде. Еш кына, кайсы иҗтимагый катламга карауларына бәйсез рәвештә, татар телендә сөйләшүче кешеләр сөйләмендә иҗтимагый диалектлар һәм әдәби тел берәмлекләренең ситуатив бәйләнгәнлеген очратырга мөмкин. Мәсәлән, *Әгәр шушы минутта берәрсе фотоны кире бирәм дисә, ике дә уйлап тормый идәндә* ***мүкәйләп*** *йөрер, ялыныр, ялварыр да иде кебек* (Ф. Сафин). *Чит илдән кайтканнар мактанып йөргәнгә дә кызыкмыйм. Күпләр мине үртиләр, акчаң бар бит, нигә аны кызганасың, нигә* ***загранитсыны*** *күреп, дөнья белән танышып кайтмыйсың, диләр* (Т. Миңнуллин). *Гомумән, безнең студентлар* ***универда*** *күңелләренә хуш килгән урыннарга яңа исемнәр уйлап табарга яраталар* («Ялкын»). Бу инде тел кулланылышындагы чикләрнең үзгәрүен, үзара кисешкәлеген дәлилли.

Әлеге проблема өстендә эшләүче галимнәр фикеренчә, бүгенге җәмгыять төзелеше белән телнең иҗтимагый структурасы арасындагы мөнәсәбәт гаять катлаулы, ул озак дәверләр буена формалашкан һәм үсеш кичергән. Иҗтимагый яктан төрлелеге телнең бүгенге халәтен генә билгеләп калмый, бәлки шул дәвамлы процессның үзенчәлеген, үсеш-үзгәрешен дә ачыклый. Телнең билгеле бер чордагы иҗтимагый төрлелеге турында сүз алып барганда, аны аерым бер чор кысасында гына карамыйча, бөтен бер тел системасы эчендә, хәрәкәттә карау отышлы, чөнки шул вакытта гына тел элементларының аерым бер катлам кешеләре телендә кулланылу сәбәпләрен һәм үзенчәлекләрен ачыклау мөмкин. В. Жирмунский билгеләвенчә, «иҗтимагый яктан аерымлануы ягыннан тел системасын тасвирлаганда, без аның үткәнен һәм киләчәген истә

тотарга тиеш, бары тик шул чакта гына телнең иҗтимагый үсеш перспективасын тулысынча күзалларга мөмкин булачак» (Жирмунский, 1968: 14). Телнең һәрвакыт динамикада, үсештә яшәве, система буларак, аның үзгәрүчәнлеген күрсәтә. Билгеле булганча, татар теленең яшәү формалары берничә төрле: әдәби тел, сөйләм теле, территориаль һәм иҗтимагый диалектлар, шәһәр койнесе, һөнәри өлкәләрдә кулланыла торган тел катламнары. Аларның һәркайсының үзләренә хас үзенчәлекләре, билгеле бер чикләре, кулланучысы бар. Әгәр тел үсешенең һәм кулланылышының алдагы чорларында (мәсәлән, XIX–XX гасыр уртасы) бу төр катламнар арасында чикләр шактый тотрыклы булса, хәзерге татар телендә бер катламнан икенчесенә сүзләр бик иркен үтеп керә. Әдәби телнең диалектларга, аеруча җирле диалектларга тәэсире аларның сафлыгына, самимилегенә зур йогынты ясый.

Әдәби тел термины, беренче чиратта, эшкәртелгән, нормаларга буйсынган, стилистик яктан аерымланган һәм күп функцияле тел чараларына карата кулланыла. Әдәби тел кысаларына керсен өчен, милли телнең барлык өлкәләре – фонетика, лексика, сүз ясалышы, грамматика, стилистика – эшкәртелүгә һәм нормалаштыруга дучар ителә. Шулар нигезендә әдәби телнең нормалары, ягъни теге яки бу тел чарасын куллануга караган кагыйдәләр җыелмасы формалаша. Аерым бер тел чарасының нормага әйләнүе өчен төп шарт – аның аралашуда даими кулланылышы, җәмәгатьчелек тарафыннан норма буларак кабул ителүе. Шушы шарт үтәлгәндә генә тел чаралары норма вазифасын үти башлый.

Билгеле булганча, әдәби тел кодификацияләнгән һәм сөйләмә формаларда яши. Хәзерге лингвистикада сөйләм культурасын өйрәнүче галимнәр телнең кодификацияләнгән формасы дип телдә кабул ителгән нормаларга буйсынган, күбрәк рәсми аралашуда кулланыла торган телне атыйлар.

Соңгы вакытта әдәби телнең сөйләмә формасында вариантлылык, нормалардан читләшү гадәти хәлгә әйләнде. Болар телебездә ике катлам арасында яши торган, гади сөйләм теле, диалект үзенчәлекләрен үз эченә алган, шулай ук әдәби телгә нигезләнгән катнаш формалар барлыкка китерде. Хәзерге телләрнең иҗтимагый яшәешен өйрәнүче галимнәр әдәби телләрнең күбесенә төрлелек хас булуын искәртәләр. Әдәби телнең локаль һәм иҗтимагый вариантлашуын шул телдә сөйләшүчеләрнең территориаль һәм

социаль яктан төрле булулары нәтиҗәсе икәнлегенә басым ясыйлар (Современный русский язык: социальная и функциональная дифференциация, 2003: 38).

Әдәби телнең вариантлашуы, шулай итеп, телдә сөйләшүчеләрнең иҗтимагый һәм яшь үзенчәлекләренә, шулай ук аралашу ситуациясенә, функциясенә бәйле була. Татар телендә сөйләшүчеләрнең территориаль яктан да шактый төрле булуын исәпкә алсак, хәзерге татар әдәби телендә нормаларның тиешенчә сакланмавына китергән төп сәбәпләрне билгеләү авыр түгел. Нигездә, бу факторлар телнең иҗтимагый яктан төрле катламнарга бүленүендә дә зур роль уйныйлар.

Сөйләм теле – алдан әзерләнмәгән, диалогик формада яшәеш тапкан, әзер клише, шаблоннар иркен кулланыла торган тел ул. Сөйләм теленең төп вазифасы – аралашуны тәэмин итү. Аның түбәндәге төп үзенчәлекләре бар: аралашуның табигый булуы; аралашучылар арасында якын яисә нейтраль мөнәсәбәтләр булу; сөйләмнең алдан әзерләнмәве; аралашучыларның сөйләм процессында турыдан-туры катнашуы; телнең сөйләмә формада булуы; телдән тыш ситуациягә бәйле булуы; вербаль булмаган чараларның катнашуы. Саналган үзенчәлекләр сөйләм теленең төп яшәеш кануннары санала. Әлбәттә, сөйләм теленең үзенә хас нормалары бар, әмма алар, кодификацияләнгән телдән аермалы буларак, аз эшкәртелгән, шулай ук аеру критерийлары эшләнмәгән[1].

Сөйләм теле нормаларның тиешенчә сакланмавы һәм үз эченә, гомумкулланылыштагы сүзләрдән тыш, иҗтимагый һәм территориаль диалектларны, гади сөйләм элементларын алу белән аерылып тора.

Алдагы бүлекләрдә әйтелгәнчә, диалект дип телнең территориаль, иҗтимагый яки профессиональ яктан берләшкән кешеләр тарафыннан кулланыла торган төрен атыйлар (Словарь социолингвистических терминов, 2006: 54).

Иҗтимагый диалект (социаль диалект, социолект) дигәндә исә социаль, профессиональ һәм яшь үзенчәлекләренә бәйле барлыкка килгән төркемнәрдә кулланыла торган милли телнең бер төре күзаллана. Әлеге термин аерым бер иҗтимагый төркемнәргә хас тел үзенчәлекләрен (башлыча лексик үзен-

[1] Сөйләм теленә хас лексика һәм аның үзенчәлекләре алдагы бүлекләрдә тулырак бирелә.

чәлекләрен) гомумиләштереп атау өчен кулланыла. Тел белемендә иҗтимагый диалектларның үзенчәлекләрен социолингвистика фәне өйрәнә.

Иҗтимагый диалектизмнарның төп билгеләре булып түбәндәгеләр тора:

1) бу күренеш, нигездә, лексик катламда күзәтелә;

2) әдәби нормаларда читләшү киң таларган;

3) башлыча сөйләм телендә генә кулланыла;

4) эмоциональ-экспрессив төсмергә ия;

5) билгеле бер дәрәҗәдә фамильяр төсмергә ия;

6) үз эчендә киң катламга аңлаешлы һәм бары тик аерым бер төркем кешеләр сөйләмендә генә кулланыла торган төрләргә бүленә;

7) төшенчә белән сүз мәгънәсе бәйләнеше ныклы һәм даими түгел;

8) иронияле, кинаяле мәгънәнең еш кулланылышы.

Хәзерге татар телендә иҗтимагый диалект лексикасы куллану шактый иркен, бу төр лексика тәэсир итү, башкалардан аерылып тору, мәзәк өчен, аерым бер төркем вәкиле булуны күрсәтү өчен, әңгәмәдәш белән уртак тел табу максатыннан, сөйләменең тәэсирлелеген арттыру, баету максатыннан һәм тыңлаучылар тарафыннан үз кеше буларак кабул ителү өчен кулланыла.

Иҗтимагый диалектларның тел үзенчәлекләре диалектларның төрләренә бәйле төрле формада һәм эчтәлектә була. Шулай да барлык төр иҗтимагый төркемнәрдә телнең төп функциясе булып символ, билге булуы һәм аеру функциясе санала, ягъни тел берәмлекләре, аеруча лексик берәмлекләр, төркем кешесенең «үз кеше» булуына ишарә итәләр. Мәсәлән:

*Шуннан китте чит телдә сатулашу. Ну бу Гатаны! Барысын да аңлый бит! – **Багана ярымга бирәм**, – диде көмеш тешле. – **Мәгәрич** сездән, пальто башына бер «данар» өстәмичә булдыра алмассыз.*

*– Бәясе кыйммәтрәк, – диде Гата, пальтоларны әйләндергәләп. – Ну, анысын, сатулашырбыз. Әмма мәгәричен дә инде чамасыз сорыйсың. Ике пальтога бер «**почмак**» җитмәгәнмени?*

*Бәхәскә олы татар да кушылды.*

*– Ну, шту сез, егетләр! Шушындый малны кулга төшергәч, мәгәричтән бер «**пәнҗеки**» жәлләп торырга! Нужәли инде без*

*ахырдан, әнә теге **фәртмагка** кереп, тахил шәрабыннан авыз итмибез? Ә аның йөз граммына, беләсезме, күпме «**корт**» кирәк? Йөз граммы бер **почмак** табер **сикәш**! Белдеңме?*

*– Хәзер акчаның кадере юк, – диде олы татар. Менә сугышка хәтле бер «**йәк**» белән туйганчы ашап чыгып була иде, ә хәзер аңа ике **фифруз** бирәләр. Уйлап кара, зажигалка ташы борча кадәр бер таш – берсе бер «**чарки**». Мәскәүнеке булса «**шаш**». Я, кая китә инде ул? Ул, инде, кәнишне, биргән кешегә күп-күбен.*

*Шулай ди-ди, ул Гата кулыннан ике пачка акча алды* (М. Мәһдиев).

М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» әсәреннән алынган бу өзектә аерып бирелгән сүзләр билгеле бер дәрәҗәдә символ вазифасын үтиләр һәм киң катлам кешеләр телендә кулланылмыйлар.

Иҗтимагый диалектизмнарның эчтәлегенә карап, бу төр лексиканы кулланучының нинди социаль төркемгә каравын билгеләү авыр түгел. Мәсәлән: *Бу айда **стипуха** соңрак күчте; иртәгә **физра** буламы?; Ял көннәреннән соң кире **общагага** кайту аеруча авыр* (сөйләм теленнән) кебек гыйбарәләрне кулланучыларның студент яшьләр төркеменә каравын билгеләү авыр түгел.

Әйтелгәнчә, иҗтимагый диалектизмнар, социаль төркемнәрнең нинди булуларына бәйле, лексик һәм фразеологик составы, фонетик яңгырашлары, сүз ясалыш һәм төрләнеш үзенчәлекләре белән бер-берсеннән аерылып торсалар да, аларның барысына да хас уртак үзенчәлекләр була. Иҗтимагый төркемнәр сөйләмендә кулланыла торган лексик берәмлекләрне гомумкулланылыш теленнән аера торган кайбер лексик-семантик билгеләргә һәм үзенчәлекләргә тукталып үтик.

Иҗтимагый диалектизмнар лексик берәмлекләрнең коннотатив эчтәлеккә бай булулары белән аерылып торалар. Бу төр лексиканы кулланучы, беренче чиратта, әйләнә-тирә мохиткә, сөйләнелә торган субъект яки объектка карата үзенең мөнәсәбәтен (башлыча тискәре, иронияле мөнәсәбәтен) белдерә. Бу төр лексиканың төп үзенчәлекләреннән берсе – эмоциональ-экспрессиянең көчле булуында: *Син бит Равилнең теге чактагы «**төнге кошла**ры»ның берседер* (Н. Гыйматдинова). *Дөресен генә әйткәндә, халык «**фанера**» тыңлаудан арды, туйды хәзер, кешенең тере тавыш белән башкарылган җырларны күбрәк тыңлыйсы килә* (Intertat.ru). *Ялгышкансың, абзыкай, диярләр дә, аркаңа – **козырь тузы**– шелтә*

*чәпәрләр.* (Т. Галиуллин). *Акча да юк, капитал да* ***тю-тю****!* (сөйләм теленнән). Бу мисалларда аерылып бирелгән сүзләр тискәре эмоция белдерү өчен, сөйләмнең экспрессиясен көчәйтү максатыннан кулланылганнар.

Иҗтимагый диалектизмнарның зур күпчелеге семантик, метафорик күчеш нигезендә барлыкка килә: *Янәсе мин эшмәкәр булсам, әти минем «****түбә****»м була* (Х. Ширмән). *Түбә* сүзе татар әдәби телендә «нәрсәнең дә булса өске өлеше, башы; өйне, торакны өстән каплап торган каплама» (ТТАС, 2005: 599) мәгънәсендә теркәлсә, «Русча-татарча актуаль лексика сүзлеге»ндә «талау, кыерсытулар, тикшерүләрдән яклыйбыз дип, эшмәкәрләрдән яки тыелган эшләрдә катнашкан затлардан акча түләтүче җинаятьче яки җинаятьчел төркем» мәгънәсендә бирелә (Русча-татарча актуаль лексика сүзлеге, 2014: 221). *Ярты бәясенә машина сатып җибәргәч, Гаяров Сәетнең якын киңәшчесе, «****түшәме****» булып китте* (Т. Галиуллин) мисалындагы *түшәм* сүзе дә күчерелмә мәгънәдә килеп, күрсәтелгән мәгънәгә ия.

*Студентларны иң куркыткан «төш» сессия булса, егетләрне армиядәге «****бабайлык****» өркетә* («Ватаным Татарстан») мисалындагы аерып бирелгән сүз, шулай ук семантик күчеш кичергән һәм «армиядә өлкән солдатларның яңа килгәннәргә мыскыллы карашы» мәгънәсен белдерә.

***Тәрәзәләрен*** *томаларга! – диде Вышка. Ул арада Рашатның күзләрен кара тасма белән каплады* (Ф. Садриев) мисалында *күзләр* сүзе урынына кулланылган *тәрәзә* сүзе шактый тар кулланылышта санала, ул киң катлам телендә таралыш тапмаган.

*Егетләрнең рульдә утырганы тәрәзәдән муенын сузып: – Бер «****чистай малае****», абзый, яме? Ату келтерефүн арбаңны этеп тә тору юк. Бушка тир агызмыйлар бездә. Әллә айдан сикердеңме син*! (Н. Гыйматдинова) мисалында «чистай малае» дип исерткеч эчемлек атала.

Әйтергә кирәк, хәзерге татар телендә кулланыла торган бу төр социаль диалектизмнарның байтагы рус теленнән калькалаштырылган.

Рус телендә кулланылган иҗтимагый диалектизмнарны татар телендә үзгәрешсез куллану күзәтелә: *Алдан яисә арттан Замир «****пушка****» сы белән килеп чыкса, хәнҗәр шул якка очарга әзер иде*

(Т. Галиуллин). *Рядовойлар арасында аның исеме – «**макаронник**», флотта – «**сундук**»* (М. Мәһдиев). *Ни күрим, ишектән безнең* ***Гайканы****, безгә яңарак кына кушылган теге өч тәңкәлек маңка малайны кертеп җибәрделәр. Во,* ***фраер****... Гайка! – дип кычкырды* ***Боксер*** (М. Кәбиров).

Эндәшү, мөрәҗәгать этикетына бәйле сүзләрнең ironияле, түбәнәйтелгән, инвектив лексика белән чуарланган вариантлары: *братан, кореш, салага*, *селәгәй* кебек сүзләр һәм кеше исемнәренең үзгәртелгән вариантлары, кушаматлар кулланылу:

*–* ***Ро****?! –* ***Вышка*** *кулларын як-якка җәйде. – Акланырга кирәкми. Мин бит синнән сорау алмыйм. Якын дустым буларак кына белешүем.*

*– Рәхмәт инде, – дип, Рашатның авыз эченнән генә мыгырдаганы ишетелде.*

*– Әйдә, бер сыйлыйм әле үзеңне.*

*– Тиясең син.*

*– Син нәрсә?!* ***Кореш****?! Тырнак белән дә чиртмим!*

*– Ике көн көт... Беркөн алдаганым өчен гафу ит. Шулай килеп чыкты. Ике көннән тиенен тиенгә бирәм* (Ф. Садриев).

Бу төр күбрәк жаргон һәм арго лексика оставында күзәтелә.

Фамильяр төсмергә ия күп кенә сүз һәм гыйбарәләр шактый киң эмоциональ төсмерне үз эченә ала, болар арасында, әйтеп үткән тупас, ironияле төрләр белән бергә, яшьләр телендә кулланыла торган шаярту төсмеренә ияләре дә очрый. Мәсәлән: *салют, крейзи, сорри* һ.б. алынмалар бу рәткә керәләр.

Рус яки рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләрне кыскартып куллану: *инет* (интернет), *универ* (университет), *дискәтүк* (дискотека), *комп* (компьютер), *сәпид* (велосипед), *ноут* (ноутбук), *стипа* (стипендия), *ВК* (в контакте) һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бу төр – яшьләр сөйләменә хас күренеш.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, иҗтимагый диалект лексикасы хәзерге татар телендә аерым социаль катлам телендә генә кулланылып калмыйча, татар телендә сөйләшүче киң катлам кешеләргә дә аңлашыла. Иҗтимагый диалект лексикасының сөйләмдә кулланылышы стилистик максатлардан, сөйләмгә яңалык, оригинальлек бирү, аерым бер кәеф рухы тудыру, я булмаса, җанлылык, образ тудыру максатларыннан чыгып башкарыла.

## § 22. Иҗтимагый диалектизмнарның төрләре

Кулланылышы ягыннан аерым территория яисә иҗтимагый катлам белән чикләнгән сүзләрне чикле лексика, әлеге факторлар белән кысрыкланмаган, яисә территория һәм иҗтимагый катламның нинди булуына карамастан, телдә киң таралган лексика ирекле лексика дип атала. Чикле лексикага территориаль һәм иҗтимагый диалект лексикасын кертәләр.

Тел белемендә иҗтимагый диалектларның түбәндәге төрләре аерыла:

1) һөнәрчелек жаргоны. Мәсәлән: аучылар, балыкчылар, итек басучылар, тегүчеләр, күн эшкәртүчеләр һ.б. һөнәр ияләренә хас лексика;

2) аерым бер социаль төркемгә хас жаргон һәм сөйләмнәр (сленглар). Мәсәлән: укучылар, студентлар, спортчылар һ.б. төркемнәр телендә кулланыла торган лексика;

3) арго яки яшерен сүзләр. Мәсәлән: сыйнфый йөзен югалткан социаль катлам вәкилләре, караклар һ.б. теле;

4) халыкның билгеле бер икътисади, каста, дини һ.б. төркемнәренә хас гомумхалык теле вариантлары (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 133).

Һөнәрчелек (профессиональ) жаргоны (*jargon* – француз сүзе) дип билгеле бер профессия вәкилләренең сөйләм телендә рәсми булмаган ситуациядә аерым предмет, күренеш, төшенчәләрне атау өчен кулланыла торган сүзләрне атыйлар. Бу төр сүзләр бары тик бер һөнәр ияләренең телендә генә кулланыла, башкаларга, нигездә, аңлаешсыз санала.

Профессиональ жаргонны кулланучыларның телендә һөнәрчелек лексикасы белән бер үк дәрәҗәдә профессиональ жаргоннар һәм гомумкулланылыш сүзләре дә актив кулланыла. Алар рәсми булмаган сөйләмдә иркен рәвештә жаргон кулланса, рәсми ситуациядә, язма сөйләмдә исә шулай ук үзләренең һөнәрләренә бәйле булган терминологияне һәм профессиональ лексиканы да киң куллана, ә инде башка катлам кешеләре белән аралашканда әдәби телне, я булмаса гади сөйләм теле элементларын кулланып сөйләшергә мөмкин. Һөнәрчелек жаргонын хәзерге җәмгыятьтә төрле профессия вәкилләре (мәсәлән: машина йөртүчеләр, медицина хезмәткәрләре, типография һәм матбугат хезмәткәрләре һ.б.) телендә күзәтергә мөмкин. Бүгенге көндә шактый актив компьютер

технологияләре, бизнес өлкәләрендә һөнәрчелек жаргоннары кулланылышы активлаша. Ә инде борынгыдан килгән төрле кәсепчелек белән бәйле жаргоннар кулланылыштан төшеп кала бара.

Һөнәрчелек жаргонында аралашу чараларына түбәндәге үзлекләр хас:

1) гомумкулланылыш берәмлекләре белән тәңгәл килгән һәм профессиональ жаргоннарның лексик-грамматик төзелешенең нигезен хасил иткән тел чаралары куллану;

2) аерым һөнәр өлкәсендә рәсми кабул ителгән тел чараларын,терминнарны алыштыра торган, я булмаса, рәсми кабул ителгән терминнары булмаган төшенчәләрне атый торган арго сүзләр һәм гыйбарәләр куллану.

Бу төр аралашу чараларының кулланылышы һәр төрле һөнәр ияләре арасында бер дәрәҗәдә булмаска мөмкин. Мисал өчен, укытучылар, матбугат хезмәткәрләре һәм башка төр гуманитар өлкәләрдә хезмәт күрсәтүчеләрнең телендә беренче төр чаралар өстенлек тотса, махсус киң катлам кешеләренә артык билгеле булмаган һөнәрләр өлкәсендә икенче төркем аралашу чаралары киң таралышка ия.

Һөнәрчелек жаргоннарының аермалы ягы шунда – аларда күчерелмә мәгънәлелек, эмоциональ-экспрессив төсмердәге сүзләр һәм гыйбарәләр куллана. Күп кенә галимнәр профессиональ жаргоннарның һөнәри лексикадан аермасын нәкъ менә шул үзенчәлектә күрәләр. Мәсәлән, шәл бәйләүчеләр телендәге *сукыр тишек, куш токмач, камфит сыры, тизәк өеме, оялы кош теле, кырын токмач* кебек һөнәрчелек жаргоннарына югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләр хас. Шоферлар телендәге *тәгәрмәч* (машина), *кирпеч* (юл юклыгын күрсәткән билге), *юл* (рейс) һ.б., табиплар телендәге *гөберле бака* – стенокардия, *самоделкин* – травматолог, *телевизор* – рентгеноскопия, *колак* – фонендоскоп һ.б. да әлеге төркемгә керә.

Әйтергә кирәк, татар телендә кулланылган жаргоннарның шактый зур өлеше рус теленнән яки рус теле аша Европа телләреннән кергән вариантта кулланыла. Мәсәлән, программистлар телендә кулланыла торган *виндуза* – OS Windows, *глюк* – программдагы ялгыш, *док/дока* – документация, *инет* – интернет, *кило* – килобайт, *комп* – компьютер шундыйлардан.

Һөнәрчелек жаргоннарын һөнәри (профессиональ) лексика белән бутамаска кирәк. Һөнәри лексика дип уртак һөнәргә

ия булган бер төркем кешеләрнең аралашуында куллана торган сүзләрне атыйлар (Словарь социолингвистических терминов, 2006: 175). Билгеләмәдән аңлашылганча, һөнәрчелек жаргоннары һәм һөнәри лексика арасында аерма юк дәрәҗәсендә, әмма һөнәри лексика, жаргоннардан аермалы буларак, күбрәк туры мәгънәдә кулланыла. Мәсәлән: матбугат хезмәткәрләре телендә – *рубрика, багана, башлам;* медицинада – *яман шеш, күз алмасы, калак сөяге, скальпель;* полиция хезмәткәрләре телендә – *зыян күрүче, кинолог, орган* һ.б. Жаргоннарның зур бер өлеше әдәби тел нормаларына туры килмәскә мөмкин, ә һөнәри лексика исә әдәби тел кысаларында яши. Һөнәри лексика махсус терминологик сүзлекләрдә урын ала, гомумкулланылыш сүзләре рәтенә дә күчә. Һөнәрчелек жаргоннары исә әдәби телдә киң таралыш тапмый, фәнни төшенчәләрнең атамалары була алмыйлар. Аларның төп функциясе булып башкалардан «үз» кешеләрен аеру тора.

Шулай да тел белемендә *һөнәри лексика* һәм *һөнәри (профессиональ) жаргон* төшенчәләрен капма-каршы куюю каралмаган, еш кына алар арасындагы чикләрне аерып булмый. Шунлыктан фәнни хезмәтләрдә аларны бергә карау яисә һөнәри лексиканы, терминнар белән беррәттән, махсус лексика составында өйрәнү күзәтелә.

Шулай итеп, һөнәрчелек жаргоннары – хәзерге җәмгыятьтә аралашуның актив чараларыннан санала. Фән, техника алга киткән саен, аларның бер өлеше үз һөнәр әһелләренең телендә генә калып, гомумхалык теленнән ераклашса, икенчеләре исә, киресенчә, профессиональ өлкә кысасыннан чыгып, сөйләм теленең һәм әдәби телнең аерылгысыз бер өлешенә әйләнергә мөмкин.

Мәгълүм булганча, жаргоннар, билгеле бер һөнәрчелек өлкәсендә генә түгел, җәмгыятьтән кешеләрнең иҗтимагый аерымлануы нигезендә дә барлыкка килергә мөмкин. Мондый төр жаргоннарны социаль жаргон дип, ягъни иҗтимагый, яшь үзенчәлекләре, көнкүреш үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, уртак кызыксынулары белән бергә вакыт үткәрүче кешеләр теленә хас үзенчәлекләрне атыйлар (Словарь социолингвистических терминов, 2006: 206).

Тел белемендә *социаль жаргон* төшенчәсен белдерү өчен *социаль жаргон, жаргон, сленг* кебек терминнар кулланыла. Мәсәлән, «Языкознание. Большой энциклопедический словарь» (2000) сүзлегендә *сленг* төшенчәсенә түбәндәге аңлатма бирелә: Сленг (англ. *slang*) – 1) шул ук жаргон (ватан тел белемендә инглиз телле

илләргә карата кулланыла); 2) сөйләм предметына карата тупас-фамильяр, аерым очракларда юмористик мөнәсәбәт белдергән сөйләм теленең аерым бер катламын хасил итә торган жаргон сүзләр җыелмасы (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 461). Жаргон (франц. *jargon*) дип төрле профессия (мәсәлән, программистлар жаргоны), җәмгыятьтәге урыны (XIX йөздә яшәгән дворяннар жаргоны), кызыксынулары (филателистлар жаргоны), яшь үзенчәлекләре (яшьләр жаргоны) буенча берләшкән аерым социаль төркемнәр сөйләмен атыйлар (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 151). Шул ук вакытта, югарыда аталган терминнарга аерым билгеләмәләр бирелә һәм ватан тел белемендә «сленг» төшенчәсе күбрәк яшьләр сөйләменә карата кулланыла (Словарь социолингвистических терминов, 2006: 133 һ.б.). Социаль жаргоннар, үз чиратында, һөнәрчелек жаргоннарыннан аерып күрсәтелә.

Һөнәрчелек жаргоннары кебек үк социаль жаргоннар да кешеләрнең «үз» яки «чит» булуларын аеру өчен кулланыла. Бу төр тел берәмлекләренең аралашудагы роле шактый вакыт, әдәби тел яки һөнәрчелек жаргоннарына караганда, азрак дәрәҗәдә дигән фикер яшәп килде, әмма соңгы еллар күзәтүләре күрсәткәнчә, хәзерге җәмгыятьтә бу төр лексик чараларның роле арта бара. Аның төп сәбәбе – билгеләп үтелгәнчә, хәзерге көндә әдәби тел нормаларының сакланмавында һәм җәмгыятьтә төрле социаль катламнар (мәсәлән, җинаятьчеләр, наркоманнар, картада уйнаучылар һ.б.) барлыкка килүдә. Әйтик, эчкечеләр телендә эчемлекне атый торган *акбаш, Бөгелмә малае, зәмзәм суы, өч борын, алъяпкычлы иптәш, сәмәй, көмешкә* һ.б. сүзләр; җинаятьчеләр телендә *атлет* – сугышчы, *бригада* – зур булмаган җинаятьчел төркем, *лабаз* – кибет, *хуҗа* – төрмә яки колония җитәкчесе, *баланда* – төрмә ризыгы, *пятерик* – тиз әзерләнә торган аш, *шконка* – йокы урыны, *дальняк* – бәдрәф, *ат куу* – үзара мәгълүмат тапшыру һ.б.

Соңгы елларда жаргон лексикасы бер төркем кешеләр телендә генә кулланылып калмыйча, киң катлау теленә дә үтеп керә башлады, бу, аеруча, төрле җинаятьчел төркемнәр, яшьләргә хас тел берәмлекләренә карый. Мәсәлән; *түбә, бакс, тусовка, мәгәрич, мент, арба* һ.б.

Жаргоннар – алар әдәби тел кысаларыннан читләшкән, аңа параллель формада яшәгән, үзенә хас лексик һәм фразеологик фон-

ды, стилистик һәм функциональ чаралары булган, рәсми булмаган аралашуда кулланыла торган тел чаралары.

Татар телендә соңгы елларда яшьләр сленгы шактый актив кулланыла башлады. Аның төп үзенчәлекләре түбәндәгеләр:

1) татар теленең үз лексик фондындагы гомумкулланылыш сүзләрен күчерелмә мәгънәдә куллану (*кәбестә* – акча, *кисәк* – мең сум акча, *сәдәф* – таблетка, *сызу* – качу, *чеби* – кыз, *койрык* – «икеле» билгесе, бурыч);

2) телнең үз сүз ясагыч мөмкинлекләреннән файдалану (*кычкрафон* – микрофон, *йөзекләнү* – өйләнү, *әйдаман* – вожатый, *тәгәрмәч* – машина)

3) сүзләрне кыскарту (*комп* – компьютер, *стипа* – стипендия, *физра* – физкультура, *лаба* – лаборатор эш, *фан* – фанат, *комбай* – көнбагыш, *шпора* – шпаргалка, *сәлкеш* – сәләтле кеше);

4) рус яки инглиз телендәге сленгларны куллану (*киндер* (kinder) – кечкенә бала, *данслау* (to dance) – бию, *задрот* – зур хезмәт куеп, максатына ирешүче, күп укучы яки эшләүче, *респект* (respect) – хөрмәт, *ДУ* – универсиада авылы, *дискәтүк* – дискотека, *сорри* (sorry) – гафу);

5) тышкы һәм эчке формаларын үзгәртмичә, гади сөйләм сүзләрен куллану (*кәефләнү* – вакытны әйбәт үткәрү, *бөке* – юлдагы пробка, *мөгезле* – троллейбус);

6) калькалаштыру алымын куллану (*текә*/*кәттә* – крутой, *чәйнек* – чайник (башлап өйрәнүче).

Яшьләр сленгының башка төр жаргоннардан аермалы булган тагын бер үзенчәлеге – аның шактый иркен гомумкулланылыш сүзләр рәтенә күчүендә, чөнки сленгларның зур бер өлешен неологизмнар һәм коннотатив мәгънәгә ия гомумкулланылыш сүзләре хасил итә. Яшьләр телендәге бу төр лексика яңалык, модага иярү төсмере бирү, гомум кабул ителгән тел өлгеләреннән читләшергә омтылу, аерым бер кәеф, атмосфера тудыру өчен кулланыла.

Яшьләр сленгы арасында студентлар, укучылар жаргоны (*препод* – укытучы, *баскет* – баскетбол, *берләр* – беренче курс студентлары, *тәрәзә* – дәресләр арасындагы буш вакыт) һәм көнкүреш (*мотор*/*арба* – машина, *инет* – интернет, *фейс* – йөз, *чиз* – елмаю, *шәпский* – әйбәт һ.б.) төрләре аерыла.

Мисаллардан күренгәнчә, татар яшьләре сленгының зур күпчелеге алынмалардан тора, шул ук вакытта татар теле җирлегендә

яңа берәмлекләр ясау, я булмаса, тәрҗемә итү кебек алымнар да кулланыла. Хәзерге вакытта кесә телефоннары, SMS аралашулар, электрон почта, ICQ һәм Интернет–чатларның актив кулланылуы яшьләр сөйләменә зур йогынты ясый. Яшьләр сөйләмендә чит тел элементларының күпләп кулланылуы, ике яки берничә телнең сүз ясалыш чараларыннан яңа берәмлекләр ясау (*шәпский, шикәрний, матурчик, лайкка басу, лайк кую, лайклау* һ.б.) билгеле бер дәрәҗәдә ясалма, катнаш тел барлыкка китерә.

Арго (франц. *argot* – яшерен, ябык) – бердәй иҗтимагый шартларда көн итүче тар даирә кешеләренең сөйләмендә кулланыла торган сүзләр яки гыйбарәләр җыелмасы. Социаль жаргоннарның бер төре буларак, аргога түбәндәге үзенчәлекләр хас:

1) тар даирәдә генә кулланылу;
2) ясалма булу;
3) сөйләү объектын яшерү максатында кулланылу;
4) сөйләм теле чараларын киң куллану.

Арго сүзләр инкыйлабка кадәр тегүчеләр, итек басучылар, сатучылар, тукучылар телендә кулланылып, һөнәрнең серен саклау алымы да булганнар (Сафиуллина, 1999: 96). Хәзерге көндә арго – җинаятьчеләр телен тәшкил итә торган лексика санала, нигездә, алар түбәнәйтелгән стильдә тискәре коннотатив мәгънәгә ия: *йомдыру* (үтерү), *фраер* (җинаятьчеләр төркеменә ят кеше), *академия* (төрмә), *калым* (табыш), *көпшә* (пистолет), *браслет* (богау), *тукран* (әләкче), *чуму* (урлау), *бәйләү* (бүтән җинаять кылмау), *барыга* (алыпсатар, спекулянт) һ.б.

Хәзерге татар теле белемендә иҗтимагый диалект лексикасы, аерым алганда социаль жаргоннар, сленгларга багышланган махсус монографик хезмәтләр юк. Тикшеренүчеләр һәм киң катлам халык арасында татар телендә бу төр лексиканың юклыгына ишарә иткән фикерләр дә күренгәли, әмма, мисаллардан аңлашылганча, телебезнең лексик каттламында иҗтимагый диалект лексикасы бар һәм аның кулланылу, яшәеш тарихы да шактый киң икәнлеге мәгълүм.

## § 23. Иҗтимагый диалект лексикасының функциональ-стилистик вазифасы

Иҗтимагый диалект лексикасы, чикле лексика саналса да, телнең төп лексик фонды белән даими алмашыну процессын кичерә. XX гасырда әлеге процесс шактый акрын барса, XX гасыр ахы-

ры – XXI гасыр чикләреннән башлап, хәзерге көнгәчә гомумкулланылыш сүзләре рәтенә бу төр чикле сүзләрнең үтеп керүе бик артты. Моның сәбәбе берничә: инде әйтеп үтелгәнчә, җәмгыятьтәге үзгәрешләр, аерым иҗтимагый төркемнәрнең абруе арту, яңа катламнар барлыкка килү, чикләр ачылу, шул исәптән әдәби тел чикләренең җуела төшүе, нормаларның сакланмавы кебек сәбәпләр иҗтимагый диалект лексикасының киң катлам кешеләренә дә аңлашыла башлавына, актив сүзлек составына күчүенә этәрде.

Бу төр сүзләр сөйләм телендә шактый иркен кулланыла башлады. Мәсәлән: *блатлы кеше, мотор, шеф, жулик, общага, физра, акбаш, мент, мультик, текә, кәттә* һ.б.

Түбәндәге мисаллар да иҗтимагый диалект лексикасының сөйләм телендә актив кулланылуын һәм аның киң катлам кешеләренә аңлаешлы булуын дәлилли: ***Вебкаңны** куш, хәзер скайп аша шалтыратам. Бу юлга **кирпеч** элгәннәр икән. Безнең сайтта **зарегать ителсәгез**, төп мәгълүматны карый аласыз. Март уртасында **стипуха** килергә тиеш иде, ник килмәде икән? Теге **кәттә** егетләр бүген күренмәделәрме? **Физрадан** соң салкын тидердем. Бүген соңгы дәрестән **сыздым*** (сөйләм теленнән). *Башкаладагы мәктәпләр дә төрле катламнарга бүленә: череп баеганнарныкы, **текәләрнеке**, уртача хәллеләрнеке…* («Идел») һ.б.

Иҗтимагый диалектизмнар составындагы тотрыксызлык, синонимик парлары булу (*кәбестә, кисәк, бакс, утын* – акча төшенчәсен белдерү), күчерелмә мәгънәлелек кебек үзенчәлекләр бу төр лексика белән гомумкулланылыш сүзләрнең уртаклыгына да этәрә, шул сәбәпле бер төркем иҗтимагый диалект лексикасы (аеруча татар теленең үз җирлегендә барлыкка килгән диалектизмнар) белән гади сөйләм сүзләре арасында уртаклык барлыкка килә. Мәсәлән, *сызу* (качу), *чәлү* (урлау), *сугылу* (кереп чыгу), *тавык, чеби* (кыз), *шалкан* (баш), *шуышу* (бару), *чичмән* (амбал), *барып җитү* (аңлау) һ.б.

Вакытлар үтү белән, иҗтимагый диалект лексикасының бер өлеше әдәби телгә дә үтеп керергә мөмкин. Аеруча һөнәрчелек жаргоннары һәм яшьләр сленгы бу төр үзгәрешкә дучар була ала. Шулай ук бер төрдәге диалектизм икенче төргә күчәргә мөмкин, мәсәлән, яшьләр сленгының төрләре үзара кисешеп, интержаргон, ягъни уртак лексика барлыкка китерә. Бу аеруча компьютер, интернет белән бәйле сленгларда күзәтелә. Шулай ук сленглар рәте

арго элементлары белән чуарланырга мөмкин. Мәсәлән, наркоманнар яки башка тар катлам жаргоннарында мондый күчеш бар: *братан, сәдәф, глюк, кайф*, *түбә (киту)* һ.б.

Иҗтимагый диалект лексикасы, сурәтләү чарасы буларак, матур әдәбиятта да шактый актив кулланыла, аеруча хәзерге татар әдәбиятында мондый әсәрләрне еш очратырга була. Аерым бер иҗтимагый катламнарга хас яшәеш үзенчәлекләрен, геройларның характерын, хәзерге чорны тасвирлаган аерым жанрларда бу төр лексика күпләп кулланыла. Татар әдәбиятында М. Насыйбуллин, И. Салахов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Т. Галиуллин, Р. Мирхәйдәров, Н. Гыйматдинова һ.б.ның әсәрләрендә иҗтимагый диалектларның төрләрен очратабыз.

Мәсәлән: *Яруллович, күн куртканы хәзер бөтен* ***шпана*** *кия. Малай, мин дә киттем бит* ***ментовкадан****. Арттан төртүче –* ***нема****. Гадәти бер* ***мент****. Көнбатышка «флик» диләр. Ул заманда чит ил «арбалары» безнең илгә бик сирәк үтеп керә һәм Горькийда ясалган җиңел автомобильнең абруы отыры зур иде. Син нәрсә,* ***падло*** (Т. Галиуллин). Әлеге мисалларда кулланылган *шпана, мент, ментовка, нема* жаргон сүзләре җинаять дөньясын сурәтләү өчен кулланыла һәм алар тискәре коннотатив эчтәлеккә ия.

*Шаярма! Хәтәр Хәйрулла диләр аны! Елтыр ыштаныңны төшереп, ат кыргычы белән төярмен,* ***селәгәй****. Яхшыдан яман туган нәрсә.* ***Сыптыр*** *моннан!* (Г. Сабитов). Бу өзектә гади сөйләм элементларына якын торган көнкүреш сленгы кулланылган.

*Егетләрнең рульдә утырганы тәрәзәдән муенын сузып: – Бер* ***«чистай малае»,*** *абзый, яме? Ату келтерефүн арбаңны этеп тә тору юк. Бушка тир агызмыйлар бездә. Әллә айдан сикердеңме син!* (Н. Гыйматдинова) мисалындагы «чистай малае» диалектизмы тар кулланылыштан чыгып, мәгънәсе ягыннан татар телендә сөйләшүче киң катлам кешеләренә дә таныш. Шул ук авторның икенче бер әсәрендә «исерткеч эчемлек» төшенчәсенең башка синонимы бирелә, ул шулай ук киң даирәдә кулланыла: *Олы йортта өстәлгә уф-уф итеп самовар килеп утырды. Бал-май куелды. Хуҗа кеше бер «****акбаш****»ны ачты* (Н. Гыйматдинова).

И. Салаховның «Колыма хикәяләре»ндә төрмә жаргоны шактый күп кулланыла. Мәсәлән: – *Габдулла, син «****бүре күзе»****н каплап тор әле. Соңгы хәбәрне, – ул миңа карап елмайды, – шагыйрьнең килүен иптәшләргә белдерергә кирәк... Хәл алу белән «җәмәгать»*

*эшенә тотына. Я хәбәр ала, я үзе башка камераларга яңа ишеткән хәбәрләрен тапшыра. Я «**балык ауларга**» тотына. Папирос кәгазенә берәр хәбәр яки берәр сорау язып, шырпы кабына сала да, җеп белән тәрәзәдән түбән камера калфагына төшерә яки шундый ук почтаны ала... – Шыш, **контрлар**! – Ишеккә приклад белән суктылар. Башым чыңлап китте. – Еланнар, монда да пышылдаша башладыгызмы? Күрше «**табут**» ишегенә дә приклад төште. «**Козгын**» чинап-улап күтәрелә башлады* (И. Салахов).

Р. Мирхәйдәров әсәрләрендәге жаргоннар, нигездә, рус теленнән калькалаштырылган вариантлар: *– Тынычлан, Ертык, безгә **юеш эш** кирәкми,–дип гасабиланып җавап бирә Төрек, – бар, эшләвеңне бел дә, **ментларга** ычкындырма, артык изге булып кыланасың... вөҗданлы кеше имеш...; Соңгы очрашуларның берсендә «**Әти**» моңсу гына «Мондый мин-минлек яхшыга илтми», дип куйган иде* (Р. Мирхәйдәров)

Татар әдәбиятында һөнәрчелек жаргоннары да очрый: ***Боевой разворот** вакытында ике йөз җитмеш метр биеклекне югалттык. Тизлек тә кинәт кимеп китте. **Штопорга юлыгу** куркынычы янамыймы?*(М. Юныс). *Берничә урында кирәкмәгән **подъездлар** ясадыгыз, ә куплетлар азагында икесендә дә төгәл җырламадыгыз. «**Ре**» урынына беренче куплет азагында «**до диез**» яңгырады, ә икенче куплетны «**ми бемоль**» белән тәмамладыгыз* (З. Хәким). *– **Шлюпка тревогасы**! Кораб бата! Тревога! Экипажга уң якка җыелырга!* (М. Юныс).

Иҗтимагый диалектизмнарны матур әдәбият тукымасына кертү стилистик яктан да, әсәрнең тематикасы белән дә турыдан-туры бәйле булырга тиеш. Шулай булмаганда, матур әдәбият телен ят элементлар белән чуарлау нәфис сүзнең кыйммәтен, әсәрнең зәвыгын, әдәби телнең дәрәҗәсен төшерүгә кайтып кала. Соңгы елларда басылып чыккан әсәрләрдә мондый мавыгуны еш очратырга мөмкин. Мәсәлән: *– Илнур **брат**, **выручи**, Сашкага операция ясаганнар, сукыр эчәккә. Мондый җаваплы эшкә синнән дә кулай кандидатура юк* (Т. Әхмәтова). *Ни булып беткәнен белми өйгә кайтмаска инде... О-о-о! Ничегрәк атлый **матуркачыбыз**? **Фаворитка** имеш!* (Г. Мирһади). *Студентлар «**общага**»сында шаяруларның чуты юк инде ул* (Р. Ханнанов).

Иҗтимагый диалект лексикасы, гади сөйләм теле элементлары кергән әсәрләрнең еш күренүе вакытлар дәвамында татар әдәби

теленең нормаларын юкка чыгаруга, телебезнең аһәңлелеген, бай лексик фондын ярлыландыруга, тел культурасының бозылуына китерергә мөмкин. Белгәнебезчә, башта ят булган тел берәмлекләре, киң даирәдә кулланыла башлагач, гадәти күренешкә әйләнә, актив таралыш таба, бу, үз чиратында, әдәби телгә үтеп керүгә бер адым булып тора. Әлбәттә, телнең лексик фондында иҗтимагый диалект лексикасының үз урыны, кулланучысы, билгеле бер стилистик вазифасы бар, әмма ул киң катлам тел вәкилләре тарафыннан гадәти берәмлекләр булып кулланылырга тиеш түгел.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ

### § 24. Татар теле терминологиясен өйрәнү тарихы

Борынгы җәмгыятьтә үк тормышның барлык өлкәләрендә тәҗрибәле кешеләр – иген игүчеләр, кош-корт, җәнлек аулаучылар, су көченнән файдаланучылар, кабиләләрнең үзара аралашуларын тәэмин итүчеләр, кием-салым, савыт-саба ясаучылар, кабилә биләмәләрен саклаучылар һәм башка бик күп төркемнәр барлыкка килә. Мондый төркемнәрдә үзләре еш куллана торган һөнәри сүзләр барлыкка килә. Һәрбер һөнәрчелекнең, эшне башкару алымнары белән бергә, шул өлкә өчен кирәкле кораллары, чималлары, җитештергән продукцияләре була. Боларның һәммәсенә исем кушыла. Нәтиҗәдә һәрбер һөнәри төркемдә үзенә хас профессионализмнар, аның номенклатурасы барлыкка килә. Боларны язма әдәби тел туганчы ук формалашкан терминнар дип атарга мөмкин. Мәсәлән, хәзерге чорда *икмәк, җир, су, игү, сөрү, сибү, уру, сугу* кебек гомумхалык сүзләре бик борынгы чорда терминнар буларак та кулланылганнар дип расларга нигез бар.

Борынгы чорда төрле кабиләләрнең исемнәре дә термин буларак кулланылган булырга тиешләр. Хәзер төрки исемен йөрткән кабиләләр, *тюрк/төрки* этнонимы урнашканчы бик күп мең еллар элек, башка исемнәр белән аталганнар. Конкрет эзләнүләр күрсәткәнчә, бу кабиләләрнең борынгы исемнәре, атамалары буларак, *ар/ир* ‘кешеләр, ирләр’, *ас/яс/ос* ‘яшьләр’, *сак/сака/дак/сой* ‘ыру, кабилә, балалар’, *сөн/һөн/хун* ‘кешеләр’, *ок/ак* ‘ыру, кабилә’, *би/бек/пи* ‘байлар’, *мен/мин/ми* ‘безнекеләр’, *гот/кот* ‘кот’ кебек беренче этнонимнар кулланылганнар. Соңрак төрле исемдәге кабиләләр кушылу-аерылу процессында аларның икенчел, өченчел

этнонимнары туган: *тауир/тавр, суас* ‘елга аслары’, *кусак/казах* ‘ак саклар’, *кусян/косан/казан* ‘ак сөннәр’, *татар* ‘ят ирләр’, *куман* ‘ак миннәр’, *ассөн/усунь* ‘ас сөннәре’, *буртас* ‘бурта-умарта аслары’, *суас* ‘елга аслары’ һ.б. (Закиев, 2003: 41–47). Бу этнонимнар үзләре үк – терминнар. Димәк, төркиләрдә терминнар да бик борынгыдан килә.

Гомуми лингвистикада хәзерге әдәби тел терминологиясе фәнен төзү процессы бара. Борынгы һәм иске телләрдәге терминнар әле бер халыкта да җентекләп өйрәнелмәгән. Терминология фәне тарихы күп халыкта тудырылган, ә терминнар тарихы фәне бер халыкта да юк диярлек. Кешелек тарихын, телләр тарихын объектив өйрәнү өчен, бу юнәлештә эш алып барылырга тиеш. Дөресен әйткәндә, XIX гасырда формалашу процессын кичергән хәзерге татар әдәби телендә язылган әсәрләрнең дә терминология тудырудагы рольләре бөтенләй өйрәнелмәгән.

Шулай итеп, татар терминнарының үсеш тарихы буенча эшлисе эшләр шактый әле, дип әйтергә була.

Татар терминологиясе тарихында, XIX гасырның 90 нчы елларыннан башлап, хәзерге көнгә кадәр күпләгән терминологик сүзлек һәм бу өлкәгә кагылышлы мәкалә басылып чыккан. Монографик хезмәтләрдән Ф. Фәсиев (1969), Р. Әхмәтьянов (2003, 2015) тикшеренүләрен атарга кирәк. Бу китапларда татар терминологиясенең күп кенә теоретик һәм практик мәсьәләләре яктыртылган.

Фән буларак татар терминологиясенең формалашу һәм үсеш тарихын күзаллау өчен, аны аерым чорлар кысасында карау зарур. Аны түбәндәге хронологик вакыт аралыкларында өйрәнү кирәк санала: 1880–1919 еллар, 1920–1930 еллар, 1931–1990 еллар, XX гасырның 90 нчы елларында һәм XXI гасырда үсеше.

Татар терминологиясенең 1880–1919 елларда үсеше.

Татар теле терминологиясе һәм татар терминологик сүзлекләре турында фикер йөртү XIX йөзнең икенче яртысында милләт формалашуга бәйле рәвештә башлана. Бу чорда әле татар әдәби теле итеп иске төрки телне шул килеш алырга, яисә иске татар телен төрек элементлары белән баетып кулланырга (М. Акъегетзадә, З. Бигиев), әдәби телне, татар, башкорт, казакъ өчен уртак итәргә (Акмулла, Курмаши) омтылучылар күренә. Каюм Насыйри исә әдәби нормаларга нигез итеп татар теленең урта диалектын

тәкъдим итә. Бу фикер белән Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов та килешәләр.

Татарча беренче терминологик сүзлекнең дөньяга килүе К. Насыйри эшчәнлеге белән бәйләнгән. 1890 елда К. Насыйри «Истиляхате җәгърәфия» («География терминнары»), 1894 елда «Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек» хезмәтләрен нәшер итә.

Теге яки бу атаманы сүзлеккә керткәнче, К. Насыйри аның халык телендә кулланылу-кулланылмавын тикшерә, әзер сүзләрне ала, яисә халыктагы сүзләргә нигезләп, яңа атама ясый. Үзенең «Хисаблык» («Арифметика», 1899) китабында ул бу турыдагы фикерләрен ачык итеп әйтә: моңа кадәр бездә хисаплык буенча үз телебездә язылган китап юк иде, шуңа күрә аның атамалары да булмады. Бу китапны үз телебездә төзегәндә, без атамаларны үз телебездән табып алырга тырыштык. Мәсәлән, гарәп атамасы *исме гадәт* урынына – *сан* сүзен, *җәмыгъ* урынына *җыю* атамасын керттек, дип аңлатма бирә ул. «Хисаблык» китабында сөйләмә телдән алынган тагын шундый атамалар бар: *бүлү* (элекке *тәкъсим* урынына), *калдык* (элекке *бакыя фарыкъ* урынына), *чыгыш* (элекке *хасиле зареб* урынына), *бүлүче* (элекке *мәксүмегаийә* урынына).

Каюм Насыйриның география, биология, авыл хуҗалыгы, медицина һәм башка өлкәләрдә кулланган терминнары татар теленең терминнар ясаудагы зур мөмкинлекләрен күрсәтәләр.

К. Насыйри барлык алынмаларны телдән чыгарып ташларга омтылган пуризм юнәлешенә дә бирелеп китми, җәмгыятьнең төрле өлкәләрендә кулланылган гарәп-фарсы һәм рус алынмаларын да телебезнең терминологиясендә калдыру ягында тора. Рус теле аркылы көнбатыш телләреннән кергән терминнарга да үз сүзлекләрендә урын бирә: *азот, фосфор, бандероль, пакет, барометр, телескоп, артиллерия, капитан* һ.б. (Абдуллин, Закиев, 1975: 62–63).

XX гасыр башында да телебездә терминнар куллану һәм яңаларын ясау К. Насыйри күрсәткән юл белән бара. Ш. Абызгильдин 1907 елда Оренбургта «Лөгать русчадан-татарчага» (42 б.) исеме белән иҗтимагый-сәяси терминнар сүзлеге чыгара. 1918 елда драматург Галиәсгар Камал «Кесә өчен русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать» нәшер итә. Боларның икесендә дә терминнар сайлауның К.Насыйри тәкъдим иткән принциплары кулланылган.

Танылган татар язучыларыннан Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, Ш. Камал, Г. Ибраһимов та татар

әдәби телен һәм аның терминологиясен үстерүгә бәя биреп бетергесез өлеш керттеләр. Туган тел сүзләрен иркен куллану белән бергә, алар гарәп-фарсы һәм рус алынмаларына да кирәк кадәр урын бирделәр.

Галимҗан Ибраһимов танылган язучы гына түгел, ул тарихчы да, әдәбият галиме дә, иҗтимагый-сәяси проблемаларны өйрәнүче философ та, әйдәп баручы лингвист та иде. 1911 елда аның башка галимнәргә үрнәк булырлык «Татар сарыфы» һәм «Татар нәхүе» дигән китаплары дөнья күрде. Татарстан автономияле республикасы төзелгәч, ТАССР Мәгариф халык комиссаиаты каршында ул терминология комиссиясен төзүдә һәм аның эшен оештыруда да актив катнашты. Иске татар теленнән яңасын булдыру эшен «татар телен җиңеләйтү» дип атап, әдәби тел һәм терминология нормаларын тәртипкә салырга тырышты. 1924 елның сентябрь аенда ул журналистларга терминологик комиссия кабул иткән чаралар турында махсус очрашулар оештырды (Закиев, 1987: 350–351).

Татар терминологиясе буенча диссертация яклаган Ф. Фәсиев безнең иҗтимагый-сәяси терминология үсешендә зур роль уйнаган өч юнәлешне күрсәтә: 1) татар әдәбияты классиклары иҗаты, 2) инкыйлаб алдыннан һәм аннан соң үсеп киткән демократик матбугат, 3) рус социал-демократик әдәбиятының татарчага тәрҗемәләре. Чыннан да, бездә иҗтимагый-сәяси терминнар рус теленнән күпләп алындылар яисә калькалаштырылдылар: *дума, партия, министр, социал-демократ, социализм, коммунизм, дәүләт советы, диктатура* һ.б. Иҗтимагый-сәяси әдәбиятның үсеше элекке гарәп-фарсы алынмаларының активлашуына да китерде: *сыйныф, шура* (совет), *иттифак* (союз), *сәясәт* (политика), *хакимият* (власть), *инкыйлаб* (революция), *икътисад* (экономика), *сәркатип* (секретарь) һ.б. Болар белән рәттән халык сөйләмә теленнән дә сүзләр алынды: *көрәш, тормыш, иптәш, эшче, игенче, ирек, юксыл* (пролетариат) һ.б. (Фасеев, 1961: 20–21).

Татар терминологиясенең 1920–1930 елларда үсеше. 1920 елның 27 маенда РСФСР составында Татарстан автономияле республикасы төзелә. Менә шул чорда татар әдәби теле дә һәм аның терминологиясе дә чын үсеш кичерәләр.

1920 елда Г. Ибраһимов ТАССР мәгариф халык комиссариатында эшли башлый. Аның инициативасы белән бу министрлыкта академүзәк оештырыла. Бу үзәк тарих, мәгариф һәм мәдәният

эшләрен югары баскычка күтәрергә тиеш була. Гыйльми үзәк составында тагын терминологик комиссия төзелә һәм ул татар терминологиясе мәсьәләләре буенча гыйльми эш җәелдереп җибәрә, терминологияне тиешле югарылыкта тоту өчен, терминнар төзү һәм куллануның төп принципларын эшли. Шул принципларга таянып, яңа терминнар төзү эше башлана, 1920 ел ахырына ул комиссия 15 мең яңа термин тәкъдим итә. Яңа терминнар сүзлекчәләре, 1925 елдан башлап, ел саен чыгарыла торалар. Менә аларның кайберләре: Сәяси лөгать / төз.: Г. Нигъмәти, М. Мөхәммәдов, С. Шәрәфетдинов, 1925; Максутов Х. Фәнни камус – русча, татарча һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә сәнагый ихтиляхлар камусы, 1927; Максутов Х. Физика атамалары, 1927; Максутов Х. РСФСР кодексларында очрый торган атамалар лөгатьнамәсе, 1927; Гали М. Газета укучыларның кесә сүзлеге, 1928; Гали М. Русча-татарча атамалар сүзлеге: физика, математика, астрономия буенча, 1931; Гали М. Русча, латинча һәм татарча атамалар сүзлеге: кеше морфологиясе, анатомия, гистология, 1931; Гали М. Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары, 1931; Валитов Г. Химия атамалары, 1931.

Мондый сүзлекләр башта терминология комиссиясендә тикшерелә торган булганнар, терминологик комиссиянең тәкъдиме белән генә басылганнар. Бу эшләр академик үзәк җитәкчесе Галимҗан Ибраһимов, «Татароведение җәмгыяте» һәм фәнни терминология комиссиясе рәисе Гаяз Максуди тарафыннан оештырылалар.

Бу чорда татар терминологиясе өлкәсендә гарәпчеләр, татарчылар, русчылар дип йөртелә торган төрле юнәлеш вәкилләренең дә эшчәнлеген билгеләп үтү зарур.

*Гарәпчеләр* терминнарны, беренче чиратта, гарәп һәм фарсы телләреннән алырга, хәтта халыкка аңлаешлы татар сүзләре урынына да гарәп-фарсы алынмаларын кулланырга тәкъдим итәләр: *үзәк* урынына *мәркәз, үсемлек* урынына *нәбатат, кешелек* урынына *бәшәрия.* Гарәпчеләр халыкара терминнарны кабул итүгә каршы төшәләр, алар урынына да гарәп-фарсы сүзләрен алырга омтылалар: *революция* урынына *инкыйлаб, совет* урынына *шура, математика* урынына *рыязыят, астрономия* урынына *гыйльме һәйәт, психология* урынына *гыйльме рух* сүзләрен кулланырга өндиләр.

*Татарчылар* пуристлык юнәлешен алга сөрәләр, алынмаларны кулланмыйча, алар урынына татар сүзләре ясарга тәкъдим

итәләр: *фамилия* урынына *урпак, документ* урынына *бетү, секретарь* урынына *язгын, мөдир* урынына *узман* сүзләрен алырга өндиләр.

*Русчылар* телдә урнашкан иске алынмалар һәм татар-төрки сүзләре урынына рус телендә кулланыла торган сүзләрне генә алырга кирәк дигән караштa торалар. Мәсәлән, *мөнәсәбәт* урынына *отношение, җәмгыять* урынына *общество, уңай* урынына *положительный, икътисад* урынына *экономика* сүзләрен куллануны тәкъдим итәләр (Фасеев, 1961: 22).

Язучылар һәм интеллигенция арасында терминологияне күбрәк латин яки грек сүзләренә нигезләргә тырышучылар да күренеп ала. Ләкин бу чорда (1920–1930 елларда) татар терминологиясен халыкка якынайту юнәлеше өстенлек ала.

Татар терминологиясенең 1931–1990 еллардагы үсеше.

Бу өченче чорда татар терминологиясе СССРда бер телле, бер мәдәниятле бердәм совет халкын төзү шартларында үзгәреш-үсеш кичерә.

Мәгълүм булганча, 1930 елның июлендә ВКП(б)ның XVI съезды үткәрелә. Бу съезд социализмның барлык юнәлешләр буенча да алга омтылышы буларак билгеләнә. Милли стратегиядә Сталин илебезнең бердәм совет халкын төзү чорына керүен әйтә. Милләтләрне үстерү сәясәтенә чик куела. Милли үсеш белән шөгыльләнүчеләр репрессиягә тартылалар. СССРда репрессиянең иң нык җәелгән чоры 1937–1938 елларга туры килсә, Татарстанда ул 1930 елдан соң ук башланып китә. Татар телен һәм халкын саклау, үстерү эше белән шөгыльләнүчеләр репрессиягә эләгәләр. Репрессиядән куркып, кайбер татар интеллигентлары бер телле, бер мәдәниятле совет халкын төзү идеясен яклап чыгалар. Шулай итеп терминологиядә дә русчылар юнәлеше өстенлек ала. Ләкин Бөек Ватан сугышы бердәм совет халкын төзү сәясәтенә үсәргә ирек бирми. Милли үсеш проблемаларына уңай караш милли терминнарны үстерү эшенә дә уңай тәэсир итә.

Бөек Ватан сугышының бик кызган чорында, 1943 елның 8 июнендә Татарстан дәүләт терминология комиссиясе утырышы җыела, шунда «Татар әдәби теле терминологиясендә төп принциплар» дигән дәүләти документ кабул ителә. Өч айдан соң, ягъни 1943 елның 9 октябрендә терминология комиссиясе тагын утырышка җыела, анда «Татар әдәби теле терминологиясе өстендә

эшләү өчен практик күрсәтмәләр-инструкция»не тикшереп кабул итәләр.

Сугыш чоры булуга карамастан, терминология комиссиясе эштән туктамый. 1944 елда бу принциплар һәм инструкция аерым брошюра итеп бастырып чыгарыла, аның исеме – «Татар әдәби теленең гамәлдәге терминологиясен тәртипкә салу, яңа терминнар эшләп чыгару һәм терминологик сүзлекләр төзү эшендә төп принциплар һәм инструкция».

Кызганычка каршы, мондый принципларның һәм инструкциянең бездә яңартылып басылганнары юк. Югыйсә, татар терминологиясен төзү, баету эшендә аларның бүген дә актуальлеген югалтканы юк әле. Бу принциплар һәм инструкцияләрнең проектлары Шиһап Рамазанов тарафыннан төзеләләр һәм аның «Татар теле буенча очерклар» китабына да кертелгәннәр (Рамазанов, 1954: 133–145).

Бу чорда басылып чыккан һәм татар терминологиясе үсешенә сизелерлек өлеш керткән хезмәтләр түбәндәгеләр: Дистанов Г. Химия терминнары: русча-татарча сүзлек. Камай Г. редакциясендә (1934), икенче басмасы 1978 елда чыга; Корбан М., Сафин М., Сәгъди Җ., Асманов Н., Шәфиев Н., Саттаров С. Табигать һәм биология терминнары (1935); Халиков Х., Алексеев И., Ишаев З. Элементар математика терминнары җыентыгы (1935); Халиков Х. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге (1939); Галиев М., Мөштәри Х., Хөснуллин Х. Физика һәм метеорология терминнары (1939); Кадыйров К., Корбан М., Курамшин Т. һ.б. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге (1939); Махианов Ф., Шәфиев Г., Нугайбәк Г. Политик-экономик терминнар (1941); Алексеев И., Халиков Х. Русча-татарча математик терминнар сүзлеге (1949); Галиев М. Русча-татарча физика һәм геофизика терминнары сүзлеге (1949); Әхмәтов Г., Гыймадиев М. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге (1950); Горохов В., Касыймов Х., Хангилдин В. Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге (1950) һ.б.

Мәгълүм булганча, 1950 елда тел гыйлеме буенча дискуссия оештырыла, ул Сталинның тел гыйлеме буенча язылган мәкаләсе басылу уңае белән башлана. Бу дискуссиядән соң төзелгән терминологик сүзлекләр түбәндәгеләр: Дусаев З. Русча-татарча география сүзлеге (1953); Р. Шакирова редакциясендә чыккан «Тел

белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге» (1953); Гыйззәтуллин Н. Әдәбият белеме сүзлеге (1958). Бу сүзлекләрне табып, аларның библиографиясен Ф. Сафиуллина төзегән (Сафиуллина, 1999: 203–204).

XX гасырның 60–80 нче елларында да шактый күп терминологик сүзлекләр төзелеп нәшер ителәләр: Тимергалин А., Галиев М. Русча-татарча техника терминнары сүзлеге (1963); Закиров В., Мортазин З. Русча-татарча математик терминнар сүзлеге (1970); Тимергалин А., Әхмәтов Г., Садыйков Ш. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге (1971); Миңлебаев Р., Макалеев И. Русча-татарча биология терминнары сүзлеге (1972); Галиев М. Русча-татарча физика терминнары сүзлеге (1972); Галиев М., Тимергалин А. Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге (1974); Русско-татарский словарь (юридических) терминов // РСФСРның җинаять-процессуаль кодексы (Казан, 1975: 239–244); Дистанов Г. Русча-татарча химия терминнары сүзлеге (1978); Галиев М., Тимергалин А. Русча-татарча физика терминнары сүзлеге (1981); Ситдиков Ф., Бакиева Н., Гарифуллин Ш., Макалеев И., Фәйзрахманова Р. Русча-татарча биология терминнары сүзлеге (1985); Ханбикова Ш., Ханбиков Я. Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге (1985); Әдәбият белеме сүзлеге / төзүче-редакторы А. Әхмәдуллин (1990).

Шулай итеп, Телләр турындагы закон мәйданга килгәнче, республикада 30 дан артык терминологик сүзлек төзеп бастырыла. Шулардан физика һәм авыл хуҗалыгы терминнары буенча – 4, математикадан – 3, биологиядән – 2, әдәбият белеменнән – 2, педагогика һәм психология буенча – 2 сүзлек дөнья күрә.

Татар терминологиясендә 20 фәнни юнәлеш буенча сүзлекләр бар. Ул юнәлешләр: анатомия, астрономия, биология, география, геофизика, гистология, сәнгать белеме, урман хуҗалыгы, әдәбият белеме, математика, метеорология, политология, авыл хуҗалыхы, техника, физика, химия, юриспруденция, тел гыйлеме.

Терминологиягә багышланган фәнни хезмәтләр дә аз түгел. Шулардан Ф. Фәсиевнең 1961 елда Мәскәүдә Тел гыйлеме институтында татар терминологиясе буенча яклаган кандидатлык диссертациясен һәм аның 1969 елда нәшер ителгән «Татар терминологиясе нигезләре» дигән монографиясен мисал итеп китерергә була.

Татар терминологиясенең XX гасырның 90 нчы елларында һәм XXI гасырда үсеше.

1989–90 елларда элекке союздаш республикаларда, ә 1990 елдан автономияле республикаларда милли телләрне тергезү, саклау һәм үстерү буенча законнар кабул ителә башлады. 1991 елда СССР таркалгач, барлык Союздаш республикалар аерым дәүләтләр булып яшәүгә күчтеләр һәм үзләренең тел һәм терминнар турындагы мәсьәләләрен дә мөстәкыйль хәл итә башладылар.

1990 елның 30 августында Татарстан Югары Советының икенче сессиясендә «Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгы турында Декларация» кабул ителде. Дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең кулланылышы, башка милли телләрне саклау һәм үстерү гарантияләнде. Декларациянең төп положениеләрен нигезгә алып, «Татарстан халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законы әзерләнде һәм кабул ителде. 1994 елда «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы» кабул ителде. Әлеге программа 2004 һәм 2013 елларда кабат яңартылып кабул ителде. Аларда татарча терминологияне үстерүгә аерым басым ясала.

XX гасырның 90 нчы елларында татар телендә укытуга игътибар арту нәтиҗәсендә татарча дәреслекләр төзү эше киңәйтелде. Техника, физика-математика, химия-биология, медицина фәннәре буенча терминнарны да тәртипкә китерү эше башланды, аңлатмалы һәм ике, өч телле татар терминнары сүзлекләре әзерләп нәшер ителде. Мәсәлән: Шакирҗанов Р. Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге (1992); Мостафина Г. Тарих терминнарының кыскача русча-татарча сүзлеге (1993); Гимадеев М., Амиров Н., Зыятдинов К. Краткий русско-татарский толковый словарь медицинских терминов с эквивалентами на английском, французском и латинском языках (1994).

1995 елда И. Низамов «Краткий русско-татарский общественно-политический словарь» әзерләп чыгарды. Бу үз чоры өчен иҗтимагый-сәяси терминнарның иң бай сүзлеге иде. Шул ук елда И. Алмазов һәм Д. Рамазанованың «Русско-татарский словарь музыкальных терминов» сүзлеге дөнья күрде.

1996 елда да аерым тармак терминологиясе буенча сүзлекләр дөнья күрде. Мәсәлән, К. Әмировның «Русско-татарский юриди-

ческий словарь»; биология галимнәре А. Халидов һәм А. Казанцеваның «Русско-татарский и татарско-русский словарь биологических терминов»; физика галимнәре Г. Даутов, Д. Галимов, З. Вагыйзов «Русча-татарча һәм татарча-русча физика терминнары сүзлеге»; К. Гарифуллин, Н. Хәйруллин, Ф. Фәтхуллин, Н. Гарифуллин, А. Ганиев, Ф. Зыятдинов, З. Әхмәтьянова, Р. Борһанова һәм М. Ханнановларның «Финансово-экономические и юридические термины»; В. Кафиатуллинаның татарча төзелеш терминнарын чит телләр белән чагыштырып эшләнгән «Англо-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики» (Вып. I), «Немецко-татарско-русский учебный словарь общестроительной лексики» (Вып. II); Р. Сәйфуллин, Г. Хисамиевларның «Физика, химия һәм химия технологиясе буенча русча-татарча-инглизчә аңлатмалы сүзлек»ләре басылып чыкты.

Бу елларда Татарстан Республикасы җитәкчелеге дә татар терминологиясен үстерүгә бик зур әһәмият бирде. Татарстан Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән бергәләп, «Татар терминологиясен камилләштерү проблемалары» дигән махсус конференция үткәрделәр. Әлеге конференция башка өлкәләрдәге сүзлекләрне эшләргә дә уңай тәэсир итте. Бу басылып чыккан түбәндәге тәрҗемәи һәм аңлатмалы сүзлекләрдә ачык күренә: Ф. Сафиуллинаның «Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге» (1998); Ф. Ситдыйков һәм Р. Зәкиев редакциясендәге «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек» (1998); Ф. Газизованың «Русча-татарча икътисад атамалары сүзлеге» (1999); А. Юлдашев, А. Әфләтунов, А. Җумагулов, Р. Нуруллиннарның «Русча-татарча техник терминнар сүзлеге» (2000); М. Гыймадиев, Н. Әмиров, К. Зыятдиновлар тарафыннан эшләнгән «Медицинадан татарча-русча аңлатмалы сүзлек» (2003); И. Гайсин редакциясендә «Агрохимия һәм туфрак белеме терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» (2003); Җ. Хөсәенов әзерләп бастырган «Географиядән русча-татарча аңлатмалы белешмә-сүзлек» (2003); Р. Шәмсетдинованың «Русско-татарский толковый словарь медицинских терминов» (2004); Г. Хисамиев редакторлыгында «Химиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек» (2004); Ф. Нәбиев редакторлыгында «Ветеринария медицинасының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» (2004); Х. Сәлимовның «Тел гыйлеме терминнары сүзлеге» (2005); Җ. Сөләйманов, А. Галимҗанов, М. Вәлиевләрнең

«Информатика һәм мәгълүмат технологияләре терминнары» (2006); И. Алмазов белән Д. Рамазанова әзерләгән «Музыкаль сүзлек» (2007); Д. Заһидуллина, В. Әминова, М. Ибраһимов, Н. Йосыпова, Ә. Закирҗанов Т. Гыйләҗев, Г. Гайнуллиналар тарафыннан әзерләнгән «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр» басмасы (2007); Л. Галиева һәм И. Галәветдинов редакторлыгында «Математик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» (2013).

Төрле телләрдәге терминологик сүзлекләр төзү Казан федераль университетында активлаштырылды. Университет галимнәре көче белән түбәндәге сүзлекләр нәшер ителде: «Татарча-русча-инглизчә тел белеме терминнары сүзлекчәсе» / төзүче-авторлар Р. Җамалетдинов, Ә. Йосыпова, Г. Галиуллина, Р. Нурмөхәммәтова, Э. Денмөхәммәтова (2014); «Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме терминнары сүзлекчәсе» / төзүче-авторлар Ф. Сәйфуллина, Ә. Закирҗанов, Л. Минһаҗева, Н. Йосыпова, Г. Гайнуллина, Т. Гыйләҗев (2014); «Русча-татарча-инглизчә экономика терминнары сүзлекчәсе» / төзүче-авторлар Р. Зарипова, А. Хөсәенова, А. Данилов (2014); «Русча-татарча-инглизчә математика терминнары сүзлекчәсе» / төзүче-авторлар Л. Салехова, Н. Туктамышов (2014); «Русча-татарча-инглизчә геодезия терминнары сүзлекчәсе» / төзүче-авторлар З. Азизова, Л. Бикташ (2014); Ә. Габидуллинның «Физика-техника терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге (10 меңгә якын термин)» (2014).

Мәгълүм булганча, татар телен тергезү, өйрәнү, саклау һәм үстерү юлында терминологик сүзлекләр чыгаруның әһәмияте гаять зур.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, «Татарстан халыклары телләре турында Закон»ны тулырак итеп гамәлгә кую максатыннан, республикадагы халык хуҗалыгының барлык юнәлешләрендә эшләүчеләр белергә тиешле татар сүзләренең минимумын туплаган сүзлекләр эшләүне кирәк тапты. Бу төр сүзлек-минимумнар һәр өлкәдә актив кулланыла торган сүзләрнең мәгънәләрен аңлатып эшләнде. Алар русча-татарча сүзлекләр рәвешендә төзелделәр. Аларны халык хуҗалыгының уналты юнәлеше буенча түбәндәге авторлар төзеделәр: Ф. Баязитова ЗАГС хезмәткәрләре өйрәнергә, белергә тиешле сүзләрдән сүзлек-минимум (1994), Р. Шәмсетдинова – медицина эшчеләре өчен (1995), Д. Рамазанова – мәдәният хезмәткәрләре

өчен (1995), Т. Хәйретдинова – иҗтимагый туклану оешмаларында эшләүчеләр өчен (1995), Ф. Гаффарова, З. Садыйкова – авыл хуҗалыгы эшчеләре өчен (1995), М. Мөхәммәдиев – урман хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен (1995), Р. Абдуллина – көнкүреш сферасында эшләүчеләр өчен (1995), Д. Рамазанова белән Ф. Таһирова – транспорт эшчеләре өчен (1996), М. Газизов һәм Р. Фәхретдинов – нефть сәнәгате эшчеләре өчен (1996), Р. Гатауллина – элемтә хезмәткәрләре өчен (1996), Р. Әхмәтьянов һәм Р. Шакирҗанов – төзүчеләр өчен (1996), Р. Хәлиуллин белән Н. Мифтахова – химия сәнәгате эшчеләре өчен (1996), Д. Рамазанова – музыкаль мәдәният хезмәткәрләре өчен (1997), М. Гыймадиев һәм А. Щековских – табигатьне саклау өлкәсендә эшләүчеләр өчен (1997), Ф. Сафиуллина, К. Галиуллин – мәгариф эшчеләре өчен (1997), Г. Саберова – урман хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен (1997).

Халык хуҗалыгының төрле юнәлешендә эшләүчеләр өчен төзелгән бу сүзлек-минимумнар яңа терминнар булдыруга, терминнарның кулланылышын активлаштырырга ярдәм иттеләр. Болар билгеле дәрәҗәдә терминнар составына кайбер үзгәрешләр дә керттеләр. Бу үзгәрешләрнең күбесе совет чорында рус теленнән кергән кайбер терминнарны иске гарәп-фарсы алынмалары яки әдәби тел сүзләре белән алмаштыру юнәлешендә барды. Мәсәлән, *издательство – нәшрият, логика – мантыйк, редактор – мөхәррир, культура – мәдәният, художник – рәссам, революция – инкыйлаб, приказ – фәрман, врач – табиб, правительство – хәкимият, председатель – рәис, политика – сәясәт, больница – хастаханә, санаторий – шифаханә* кебек алмаштырулар кертелде, ләкин, стиленә карап, рус алынмалары да актив кулланылышта калды.

Йомгаклап әйткәндә, татар терминологиясенең формалашуы һәм үсеше шактый бай тарихка ия, бу фәнни өлкәнең яшәеше, үсеш-үзгәреше, беренче чиратта, сүзлекләрдә теркәлгән берәмлекләрдә чагылыш таба.

### § 25. Татар теле терминологиясенә гомуми билгеләмә

Термин (лат. *terminus* – чик) – билгеле бер фән яки эшчәнлек өлкәсенә караган төшенчәләрне белдергән сүз яисә сүзтезмә (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 508).

Нинди дә булса бер фәннең терминнар җыелмасын терминология дип атыйлар.

Һәр фәннең үз терминнары җыелмасы була, ягъни һәр фән үз терминологиясе белән характерлана. Фәннәр өч төркемгә аералар, шуңа карап, гомуми терминнар дә өчкә бүленә:

1. *Табигый-фәнни терминологиягә* астрономия терминологиясе, химия терминологиясе, биология терминологиясе, авыл хуҗалыгы терминологиясе һәм башка табигый-фәнни терминологияләр керә.

2. *Фәнни-техник терминология* составына физика, математика, технология, төзелеш, авиация, тимер юл, нефть сәнәгате һ.б. өлкәләрдә кулланыла торган терминнар керә.

3. *Гуманитар белемнәр терминологиясе* тарих, фәлсәфә, хокук белеме, филология, сәнгать белеме, культурология, икътисад, социология, педагогика, психология, экология кебек фәннәрнең терминологияләрен берләштерә.

*Филологик терминология* составына әдәбият белеме, фольклористика, лингвистика, чыганаклар белеме, текстология, лингвистик география, палеография (язу белеме) терминнары җыелмалары керә. Филологик терминология үз эчендә тагын да ваграк төркемнәргә аерыла. Мәсәлән, лингвистик терминология – фонетика терминологиясе, лексикология терминологиясе, морфология терминологиясе, синтаксис терминологиясе, стилистика терминологиясе кебек төркемнәргә бүленә. Мондый терминнар җыелмасын гомумиләштәреп терминологик система дип атарга тәкъдим итүчеләр дә бар (Исхакова, 1987: 3). Галимнәр, телнең гомуми лексик системасына термин фәкать конкрет бер терминологик система берәмлеге буларак кына керә, дип раслыйлар.

Термин турында язылган энциклопедик мәкалә авторы Н. Васильева термин үзенчәлекләрен түбәндәгечә санап күрсәтә: 1) системалылык; 2) билгеләмәсе-дефинициясе булу (күпчелек терминнар өчен); 3) терминның үз фәне терминологиясе составында моносемантизмга (бер мәгънәлелеккә) омтылуы; 4) терминның экспрессиясе булмау, ягъни тойгысыз кулланылуы; 5) стилистик яктан битараф булуы (Лингвистический энциклопедический словарь, 1990: 506).

Шуны да истән чыгармаска кирәк: кайбер терминнар төрле фәннәрдә кулланылалар һәм төрлесендә төрле мәгънә белдерәләр, мәсәлән, *функция* термины а) иҗтимагый мөнәсәбәт өлкәсендә ‘йөкләнгән бурыч’, ‘вазифа’, ‘эш-хезмәт’ мәгънәсен бирә; ә) ма-

тематикада ‘үзгәрешләре бер-берсенә бәйләнешле булган күренешләр’ мәгънәсендә кулланыла; б) физиологиядә ‘организмның, төрле органнарның үз эшләрен үтәве’ мәгънәсен белдерә; в) лингвистикада ‘тел берәмлегенең ниндидер башка бер функциядә килүе’ мәгънәсен бирә һ.б.

Терминнарның югарыда саналган үзенчәлекләре үз терминологияләре составында гына саклана, гадәти сөйләмгә чыгып китсә, термин гомумкулланылыш сүзенә әйләнә, ягъни детерминологизациягә бирелә: мәсәлән, *шайба, клюшка* кебек спорт терминнары гомумкулланылыш сүзләре рәтенә күчтеләр.

Терминның бер төшенчәне белдерергә, ягъни моносемантизациягә омтылышы да үз фәне терминологиясе составында гына күзәтелә. Башка фәндә кулланыла башлый икән, аның төшенчәсе дә үзгәрә, башка сүзгә –терминга әйләнә. Моңа мисал итеп, *операция* һәм *ассимиляция* терминнарын китерергә мөмкин. *Операция* термины: 1) гуманитар белемнең иҗтимагый-сәяси өлкәсендә ул *эш-хәрәкәт, чара* төшенчәсен, 2) хәрби өлкәдә *ниндидер максатка ирешү өчен оештырылган хәрби эш* төшенчәсен, 3) медицинада – *савыктыру максаты белән ясалган хирургик эш* төшенчәсен, 4) финанс, икътисад өлкәсендә – *финанс документларын әзерләү* төшенчәсен, 5) сәнәгать өлкәсендә *нәрсәне булса да ясау, кору эшен бер җирдә, бер вакытта башкарып чыгу* төшенчәсен белдерә.

*Ассимиляция* термины: 1) тел гыйлеме өлкәсендә бер авазның икенчесенә тәэсир итүен, мәсәлән, *урманда* сүзендә яңгырау (*н*) авазыннан соң урын-вакыт килеше кушымчасындагы беренче аваз яңгырау әйтелә (*-да*), *тышт*а сүзендә *тыш* тамырындагы саңгырау (*ш*) шул ук килеш кушымчасын саңгырау аваз белән башларга этәрә (*-та*). Биредә саңгыраулыкта яки яңгыраулыкта авазлар яраклашуы – *ассимиляция* барлыкка килә; 2) иҗтимагый-сәяси өлкәдә бер милләт кешеләренең телләрен, гореф-гадәтләрен алмаштыру нәтиҗәсендә башка милләт кешеләре булып үзгәрүен белдерә һ.б.

А. Калинин, рус телендә терминнарны буташтыру нәтиҗәсендә дә кайбер терминнарның бер мәгънәлелеге бозыла, дип яза. Мисал итеп ул *синтагма* терминының кайберәүләр тарафыннан дөрес кулланылмавын китерә: *синтагма* ул сөйләмдә җөмләнең интонацион буыннары, ләкин аны ялгыш *сүзтезмә* мәгънәсендә куллану да очрый, ди ул.

Терминологиянең тагын бер кимчелеген А. Калинин шунда күрә: кайбер терминнарның синонимнарын да булдыралар. Мәсәлән, рус телендә *сказуемое* терминына синоним итеп, *предикат* сүзен дә кулланалар. Татарчада да *хәбәр* сүзе урынына *предикат* терминын куллану очраклары күренә. А. Калинин, *многозначность – полисемия* (татарчада: *күпмәгънәлелек – полисемия*), *орфография – правописание* (татарчада: *орфография – дөрес язылыш*), *азбука – алфавит* кебек синонимнарның кулланылышын терминологик системаның бозылуы, дип карый (Калинин, 1966: 138).

Хәзерге лингвистикада терминнардагы тулы синонимлык кимчелек санала, ә өлешчә генә синонимлыкны телне бизәкләү чарасы итеп карыйлар. Алар терминологиядә *дублетлар* дип йөртеләләр.

Терминнарны тагын гомуманлаешлы (общепонятные) һәм тар махсус (узкоспециальные) дигән төрләргә дә бүләләр. Гомуманлаешлы терминнар билгеле бер фән өлкәсендә белгеч булмаган затларга да аңлашыла, тар махсус терминнар исә фәкать теге яки бу өлкәдәге белгечкә генә аңлашыла.

Терминологлар тагын фундаменталь-теоретик терминнарны номенклатурадан аерып йөртергә тәкъдим итәләр. Беренче төре төп фәннең гомуми теоретик төшенчәләрен белдерә: *теорема, аксиома, диогональ, төрләнеш, материя* һ.б. Икенче төре – теге яки бу белем, эшчәнлек өлкәсендәге әйберләрнең, эшләнгән продукциянең, коралларның исемнәре була.

Кайбер галимнәр, мәсәлән, татар терминологы Ф. Фәсиев фикеренчә, номенклатурага караган терминнар башта халык телендә гадәти сүз булып йөриләр, ләкин фәннәр барлыкка килгәч, алар, теге яки бу фәндә кулланылып, фәнни номенклатура, ягъни фәнни термин булып та үзгәрәләр. Мәсәлән, анатомиядәге *сөяк, умыртка, кабырга, тире* (тән тиресе), *тырнак* кебек номенклатуралар башта гомумкулланылыш сүзе булып йөргәннәр. Химиядәге *тимер, күмер, су, тоз* терминнары да башта гадәти сүз булып халык телендә кулланылганнар. Мондый сүзләр термин буларак кулланылсалар, аларның төшенчәләренә фәнни билгеләмә бирелә.

Фундаменталь-теоретик терминнар, нигездә, термин буларак кына саклана, халык теленә бик сирәкләре генә үтеп керә, ә номенклатура халык телендә гадәти сүз буларак саклана.

Аерым профессиягә хас булган сүзләр (профессионализмнар), рәсми кабул ителмичә генә, теге яки бу эш, профессия кешеләре тарафыннан сөйләмә телдә кулланыла торган сүзләр дә термин төшенчәләрен белдерүдә катнаша ала (Калинин, 1966: 143). Профессионализмнар терминнар белән янәшә кулланыла: термин – рәсми телдә, профессионализм – теге яки бу профессия кешеләренең сөйләмә телендә. Мәсәлән, балыкчыларның, аучыларның үзара гына аңлашу өчен кулланыла торган профессионализмнары бар.

Термин – ул кайсы да булса бер фән яки эшчәнлек өлкәсендәге махсус төшенчәне белдерә торган сүз яки сүзтезмә, дидек. Махсус төшенчәләрне төрле шартлы билгеләр, символлар, формулалар да белдерәләр. Мәсәлән, математикада √ – тамыр билгесе, Cu – бакырның (купрум дигәннең) кыскартылып язылган билгесе һ.б. Ләкин болары терминнар составына керми.

Күп фәннәрдә һәм кеше эшчәнлегендә махсус төшенчәләр бик күп, аларны тел чаралары белән белдерү өчен бер генә телдә дә сүзләр җитми, шуңа күрә аларның зур бер өлеше сүзтезмәләр белән белдерелә. Җөмләләр белән бирелә торган махсус төшенчәләр дә бар: *җир тетрәү* ‘землетрясение’, *кояш тотылу* ‘затмение солнца’. Болары да термин-сүзтезмә рәтеннән карала. Ләкин термин булып килү өчен, бу төр җөмләләр ныгып калган тезмәгә әйләнгән булырга тиешләр.

Шулай итеп, телнең сүзлек составында гадәти сүзләрдән аерылып тора торган *термин-сүзләр* дә урын алган. Гадәти сүзтезмәләрдән аермалы буларак, *термин-сүзтезмәләр* дә телдә зур урын били. Аларның структур-ясалыш үзенчәлекләре алдагы бүлекчәләрдә киңрәк яктыртылыр.

Терминда атау мәгънәсе өстенлек алганлыктан, ул башлыча исем сүз төркеме белән бирелә. Сыйфатлар, рәвешләр термин буларак сирәк кулланылалар, ә менә фигыльдән ясалган исемнәрнең термин буларак кулланылулары бик еш күзәтелә.

Рус тел гыйлемендә бу мәсьәлә махсус тикшерелгән. Н. Щеглова «К вопросу о грамматических средствах терминологизации русских глаголов в профессиональной речи XVII–XVIII веков» дигән мәкаләсендә, иң элек, термин булып килүче төп сүз төркеме дип, исемне таный. Бары исем генә әйберләр, хәрәкәтләр турындагы төшенчәләрне белдерүче лексик-грамматик чара була ала,

дип белдерә ул (Щеглова, 1968: 89). Шушы фикернең дөреслеген рус терминологиясе белгече В. Даниленко да ныгыта (Даниленко, 1971: 42–47). Шуның белән бергә, бу ике автор да аерым очракларда сыйфатлар, рәвешләр һәм фигыльләрнең дә термин буларак кулланылуларын таный.

Татар телендә исем фигыль дип аталган фигыльләр генә, термин булып килгәндә дә, фигыльлекләрен югалтмыйлар: *аралашу* ‘коммуникация’, *атау* ‘номинация’, *әйтү* ‘артикуляция’, *башкарылу* ‘управление’, *белдерү* ‘выражение, объявление’, *җайлашу* ‘аккомодация’, *гадиләшү* ‘опрощение’, *җләштерү* ‘джоканье’, *саклау* ‘блюсти’, *алып бару* ‘ведение’ һ.б. Термин була ала торган бу төр исем фигыльләр теләсә нинди фәнгә караган терминнар арасында да бик еш күренәләр. Мәсәлән: *абстраклаштуру* ‘абстрагирование’, *адвербиальләшү* ‘адвербиализация’, *рәвешләшү* ‘адвербиализация’, *актуальләштерү* ‘актуализация’, *грамматикалашу* ‘грамматикализация’, *дифтонглашу* ‘дифтонгизация’, *калькалаштыру* ‘калькирование’ һ.б.

Шулай итеп, татар телендә, махсус төшенчәләрне атауда, ягъни терминнар буларак, исемнәр һәм исем фигыльләр кулланыла, сирәк кенә булса да, сыйфатлар һәм рәвешләр дә термин булып килә алалар.

Терминнар турында сөйләгәндә, синонимнар һәм дублетлар мәсьәләсенә дә аерым тукталу кирәк. Югарыда билгеләнгәнчә, гомуми тел гыйлемендә терминнарның синонимлыгы мәсьәләсе күп галимнәр тарафыннан телгә алына. Синоним дип мәгънә төсмерләре ягыннан охшаш яки тәңгәл килгән сүзләрне атыйлар (Татар лексикологиясе, 2015: 159). Синонимик сүзләрнең гомуми мәгънәсе туры килсә дә, алар бер-берсеннән стилистик һәм семантик мәгънә төсмерләре белән аерылып торырга тиешләр. Менә шундый синонимнар гына чын синоним оя төзиләр.

Терминологиядә мәгънәсе белән бер-берсенә тулысынча туры килә торган, ягъни абсолют синонимнар гына кулланыла. Танылган тел белгече О. Ахманова аларны синоним дип атамаска, бары *дублетлар* (икәү булса), *триплетлар* (өчәү булса), *тетрет* (дүртәү булса), *пентет* (бишәү булса) дип атарга тәкъдим итә (Ахманова, 1966). Ләкин О. Ахманова аларны киң мәгънәсендә синонимнар рәтендә өйрәнә, дөресрәсе, аларны да ул «синонимнар» дип атап йөртә, ләкин «синоним» сүзен куштырнаклар эченә ала.

Татар терминологиясендә дублет терминнар түбәндәге очракларда күзәтелә: 1) алынма сүз – татар теленең традицион сүзе: *президент – илбашы,* 2) икесе ике телдән алынган дублет: *автономия – мөхәррият*, 3) тулы сүз (сүзтезмә) – кыскартылган сүз (бер сүз): *рәвешкә күчү – рәвешләшү,* 4) тулы атама – аббревиатура: *Россия Федерациясе – РФ*, *Татарстан Феспубликасы – ТР* һ.б.

Шулай итеп, терминологиядә синонимнар булырга тиеш түгел; гомуми лингвистика карашынча, терминологиядә синонимнарның булуы терминологияне боза. Татар терминологиясендә дә синонимнарның, хәтта дублетларның, триплетларның булуы бер фәнни махсус төшенчәне төп-төгәл итеп белдерү өчен, бер ныклы термин урнашып җитмәгән дигән фикер тудыра.

### § 26. Татар телендәге терминнарның чыганаклары

Телнең фәнни һәм фәнни-популяр стильләре үсү барышында, телдәге терминнар да баеп, күбәеп тора. Яңа терминнар ясау, терминнарны күбәйтү, үстерүнең бер актив юлы – әдәби телдәге, гомумкулланылыштагы, аерым очракларда, диалектлардагы сүзләрне термин итеп куллану. Гадәти сүзләрне терминлаштыру күренешен без К. Насыйри, Г. Алпаров, Г. Ибраһимов, Ш. Рамазанов, Ф. Фәсиев, Р. Әхмәтьянов хезмәтләрендә һәм соңгы елларда төрле өлкә терминнарын өйрәнүгә багышланган монографияләрдә күрәбез.

Татар телендәге әдәби тел, гомумкулланылыш, диалекталь сүзләрнең термин рәтенә күчү процессын терминлаштыру (терминологизация) термины белән атап йөртәләр.

Ф. Фәсиев гомумкулланылыштагы сүзләрне терминлаштыруны гадәти сүзләрне, теге яки бу фәнни төшенчәләрне белдерүгә семантик яраклаштыру, дип аңлата. Үзенең терминнарны өйрәнүгә багышланган диссертациясендә гомумкулланылыш сүзләренең терминлашуы дүрт төрле була дип белдерә: 1) әдәби телдә нормалашкан сүзләрне терминлаштыру (*аклау* – реабилитация, *алкыш* – аплодисменты, *илче* – посол һ.б.); 2) телдә кабул ителгән гарәп-фарсы һ.б. тел алынмаларын терминлаштыру (*гомумиләштерү* – обобщение, *сәүдә* – торговля һ.б.); 3) җанлы телдәге, әле әдәбиләшеп җитмәгән сүзләрне терминлаштыру (*түбә* – вершина, *күзәнәк* – клетка һ.б.); 4) диалекталь сүзләрне терминлаштыру (*җайдак* – всадник, *тәңгәл* – адекватный, тождественный, *элемтә* – связь, *онык* – внук һ.б.) (Фасеев, 1961: 30).

Гомумкулланылыштагы сүзләрнең терминлашуын төрле телләрдә төрле дәрәҗәдә тикшергәннәр. Татар телендә бу мәсьәлә шактый җентекле өйрәнелгән. Хәзерге татар лингвистикасында аның өч төрле реальләшүен күрсәтү гадәткә кергән.

Шуларның беренчесе, югарыда әйтелгән әдәби тел яки гомумкулланылыш сүзенең терминлашуы: *чор* – период, *аклау* – реабилитация, *керем* һәм *чыгым* – приход и расход.

Ф. Фәсиев аңлатканча, иске татар телендәге сүзләр дә, термин буларак кулланылгач, хәзерге әдәби телгә яңадан кайттылар: *аерылмыш* – грам. определяемое, *ачыкланмыш* – поясняемое слово, *саналмыш* – исчисляемое, *бәйләныш* – связь, *булмыш* – бывший, *аталмыш* – называемое, *яшәмәктә* – в существовании һ.б.

Гомумкулланыш сүзләренең терминлашуын һәр фәннең терминнары арасында табарга була.

XX гасырның 90 нчы елларыннан бу юл белән терминнар ясау барлык фәнни юнәлешләрдә активлашты. Мисал итеп биология өлкәсендә гадәти сүзләрне терминлаштыруны китерик. Флора яки фаунаны тәшкил итә торган әйберләр, күренешләрнең исемнәре, кеше органнары атамалары биология фәнендә терминнарга (күбрәк очракта номенклатурага) әйләнәләр. Түбәндәге мисаллар Ф. Ситдыйков, Р. Зәкиев, А. Халидов, И. Макалеев, Р. Фәйзрахманова, И. Рәхимов, Ф. Иштирәкова төзегән «Биологический русско-татарский словарь» (Казань, 1998, 665 б.) басмасыннан, шулай ук Ф. Ситдыйков, Н. Бакиева, Ә. Гарифуллина, И. Макалеев, Р. Фәйзрахманова төзегән «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге»ннән (Казан, 1985, 200 б.) алынды.

астра – *кашкарый,*
акация – *сәрви,*
астрагал – *мәче борчагы,*
базилик – *рәйхан,*
баклажан – *баклажан,*
бамбук – *бамбук,*
барсук – *бурсык,*
белоус – *бүтәкә үләне,*
береза – *каен,*
беркут – *бөркет,*
близнецы – *игезәкләр,*
блохи – *борчалар,*
бобовые – *кузаклылар,*
бодяк – *билчән,*
божьи коровки – *камкалар,*
бородавка – *сөял,*
борщевик – *балтырган,*
брожение – *әчү,*
брусника – *нарат җиләге,*
бузина – *аю баланы,*
вайда – *тәкә сакалы,*
валериана – *песи үләне,*
василек – *күк баш,*
веки – *күз кабаклары,*

вид – *төр*,
вкус – *татым,*
гвоздика – *канәфер чәчәге*,
глаз – *күз,*
гниение – *черү,*
голодание – *ачыгу,*
горнастай – *ас,*
гречиха – *карабодай,*
грибы – *гөмбәләр,*
дерево – *агач,*
дудник – *курай үләне,*
душица – *мәтрүшкә,*
ежевика – *кара бөрлегән,*
жабрица – *бака кабырчыгы,*
жабы – *гөберле бакалар,*
жасмин – *ясмин,*
железы – *бизләр,*
желтуха – *сары,*
желудь – *имән чикләвеге,*
зародыш – *яралгы,*
здоровье – *сәламәтлек,*
иван-чай – *хан үләне,*
караси – *табан балыклар,*
кочан – *кәбестә башы,*
легкие – *үпкәләр,*
моли – *көяләр,*
молозиво – *угыз,*
нервы – *нервлар,*
одуванчик – *тузганак,*
ольха – *зирек,*
растения – *үсемлекләр,*
сапсан – *чын лачын,*
тетерева – *көртлекләр,*
тополь – *тополь,*
угри – *сыткы, сыткыч,*
утки – *үрдәкләр,*
фасоль – *фасоль,*
фиалка – *миләүшә,*
хищные – *ерткычлар,*
чайки – *акчарлаклар,*
щавель – *кузгалак*
һ.б.

Татар теле терминологиясен баетуның икенче бер әһәмиятле чыганагын башка телләрдән сүзләр алу тәшкил итә. Билгеле булганча, татар теленең лексик фондында гарәп, фарсы, рус һәм Европа телләреннән кергән алынмаларның актив кулланылуы күзәтелә. Алынма терминнар турында сөйләгәндә, әлеге чыганакларның бу өлкәдә дә актив роль уйнавын билгеләү кирәк.

Күренекле галимә Ф. Сафиуллина татар лексикасында һинд, кытай берәмлекләренең булуын да күрсәтә: *алма* ‘яблоко’, *әрдәнә* ‘штабель, поленница’, *җиз* ‘латунь, желтая медь’, *тәңре* ‘бог, всевышний’, *сан* ‘число, часть тела’, *энҗе* ‘жемчуг’, *хан* ‘хан’, *чәй* ‘чай’, *дәү* ‘большой’, *юан* ‘толстый’, *чын* ‘действительный’, *чирү* ‘войско’, *дию/дөю* ‘демон’ һ.б. Болардан кала, монгол теленнән кергән дип каралган берничә берәмлек барлыгы билгеләнә: *чаган* ‘клен’, *нокта* ‘точка’, *дилбегә* ‘вожжи’, *будага* ‘каша’, *манглай* ‘лоб’, *шава/саба* ‘посуда’, *мәргән* ‘снайпер’, *кенҗе* ‘младий’ һ.б. (Сафиуллина, 1999: 58–59).

Рус-татар икетеллелеге нәтиҗәсендә, безнең телебезгә рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш телләреннән терминнар күпләп алына. Бу мәсьәләләрне махсус өйрәнгән Ф. Фәсиев алынма терминнар арасында халыкара терминнарның күпләп очравын билгеләп үтә. Аның фикеренчә, бу төр терминнар татарчага тәрҗемә ителмичә һәм татарча параллельләре белән бергә дә кулланылырга мөмкиннәр, мәсәлән, *социаль – иҗтимагый, практика – гамәл, практик – гамәли, дефис – сызыкча, коммюнике – рәсми белдерү, плебицит – бөтенхалык сайлавы* һ.б. Ф. Фәсиев фикеренчә, чит ил терминнары, халыкара сүзләр булмасалар, еш кына татар сүзләре белән дә алмаштырылалар: *дефект – кимчелек, эффект – нәтиҗә, рентабельный – табышлы, фешенебельный – шәп, зиннәтле* һ.б. (Фасеев, 1961: 34).

Татар телендә термин буларак кулланыла торган, шулай ук терминнар рәтеннән гомумкулланылыш сүзләренә күчкән шактый күләмдә алынма берәмлекләр файдаланыла. Мисал өчен, фин-угор алынмаларының байтагы бүгенге көндә терминнар кысасыннан чыгып, гомумкулланылыш сүзләренә әйләнгәннәр[1].

Телебездәге терминнарның шактый зур өлешен гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итә. Бу төр алынмаларның гомуми лексик фондка үтеп керүе һәм кулланылу үзенчәлекләре «Татар телендә гарәп һәм фарсы алынмалары» бүлегендә тирәнтен анализланганлыктан, биредә алынма терминнарның кайбер үзенчәлекләре генә күрсәтелә.

Гарәп-фарсы алынмалары VII–VIII гасырларда күпләп кулланыла башлый. Башта дини төшенчә белдерүче сүзләр керә: *дин* ‘религия’, *дога* ‘молитва’, *дога кылу* ‘читать молитву’, *гыйлем* ‘наука, знание’, *иман* ‘вера в бога, доверие’, *шәригать* ‘письменный свод мусульманских законов, шариат’, *тәүбә* ‘покаяние’, *кыямәт* ‘судный день’ һ.б. Соңрак, дини сүзләр белән бергә, белемгә бәйләнешле сүзләр алына: *хәреф* ‘буква’, *дәфтәр* ‘тетрадь’, *хисап* ‘арифметика’, *имтихан* ‘экзамен’, *китап* ‘книга’, *каләм* ‘карандаш’, *шигырь* ‘стих’ һ.б.

Иҗтимагый-сәяси сүзләр дә башта гарәп-фарсыдан алына, бүгенге көндә дә алар актив лексик фондта саналалар: *әмер* ‘приказ,

---

[1] Бу төр лексика «Татар телендә фин-угор алынмалары» бүлегендә җентекле тикшерелде.

распоряжение’, *хаким* ‘повелитель, правитель’, *хөкем* ‘суд, суждение’, *хөкемдар* ‘повелитель’, *тәхет* ‘трон, престол’, *тылмач* ‘переводчик’, *халык* ‘народ’, *дошман* ‘враг’, *дөнья* ‘мир, свет, вселенная’, *табигать* ‘природа’ һ.б.

XX гасырның 80–90 нчы елларында үзгәртеп коруларга бәйле рәвештә Совет чорында рус алынмалары белән алмаштырылган гарәп-фарсы алынмалары, шул исәптән терминнар да, яңадан кайтарыла башладылар. Беренче чиратта кайбер илләрнең иске әйтелешләре кайтарылды*: Германия – Алмания, Европа – Аурупа, Египет – Мисыр, Дели – Дәһли, Тегеран – Тәһран, Рим – Рум.*

Кайбер гарәп-фарсы алынмаларының иске вариантлары кулланыла башлады: *хисләр дөньясы – хиссия, рухи дөнья – рухият, милли дөнья – миллият*. Аерым очракларда татар сүзләре дә гарәп-фарсы алынмалары белән алмаштырылды: *кешелек – инсаният* ‘человечество’, *тырышу – иҗтиһат* ‘старание’. Болары параллель дә кулланыла, ләкин боларны уңай күренеш дип бәяләп булмый.

Халыкара сүзләрнең кайберләре гарәп-фарсы алынмалары белән алмаштырылды: *карта – харитә, география – җәгъръәфия, ситуация – вазгыять, экономика – икътисад, закон – канун, типография – матбага, материк – кыйтга, печать – мөһер, автономия – мөхтәрият* һ.б. Боларны да параллель куллану сакланган.

Татар телендәге рус һәм Европа телләреннән кергән алынмалар Э. Ахунҗанов, М. Хәйруллин хезмәтләрендә киң яктыртылганнар. Рус алынмалары, Казан ханлыгы таркалгач, татар теленә күпләп керә башлаганнар. Рус теле аркылы интернациональ сүзләр дә алынма буларак күпләп кабул ителгәннәр.

Халыкара термин-сүзләр, нигездә, грек яки латин телләренә барып тоташа. Татар телендә алар бик күп, түбәндә кайбер төркемнәрне тәкъдим итәбез:

1. Грек сүзенә нигезләнгән интернациональ алынмалар түбәндәге юнәлешләрдә кулланылалар:

а) фәннәр исемнәре буларак: *агротехника, анатомия, астрономия, ботаника, биология, гигиена, география, геодезия, метафизика, логика, геология, идеология, диалектика, гидрология, морфология, филология, зоология, физиология, хирургия, орфография, педагогика, оптика, патология, философия, экономика, эстетика* һ.б.;

ә) фәнни-төшенчәләрне белдерүчеләр буларак: *атмосфера, аксиома, аэростат, барометр, анахронизм, гипотеза, гипноз, догма, галактика, механика, микроскоп, магнит, призма, метод, планета, параллель, семафор, электр* һ.б.;

б) иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдерүчеләр буларак: *автономия, анархизм, антагонизм, демократия, деспот, династия, гимн, катастрофа, гегемония, монархия, монополия, кризис, патриотизм, метрополия, стратегия, тиран, политика, утопия* һ.б.;

в) әдәбият, сәнгать, мәдәният терминнары буларак: *анапест, амфибрахий, аллегория, антитеза, диалог, баритон, драма, пародия, псевдоним, поэма, ода, талант, сарказм, метафора, лирика, ритм, музей, симфония* һ.б.;

г) медицина төшенчәләрен белдерүчеләр буларак: *агония, диагноз, миокардит, поликлиника, психика, склероз* һ.б.;

д) иҗтимагый тормышның төрле өлкәләре терминнары буларак: *амнистия, автобиография, автомат, амфибия, демагог, варвар, график, ипподром, период, категория, пирамида, программа, система, стихия, синдикат, стадион, лабиринт, епископ, фаэтон, хамелеон, фантазия* һ.б.

2. Латин сүзенә нигезләнгән интернациональ алынмалар түбәндәге юнәлешләрдә кулланылалар:

а) сәнәгать һәм техника өлкәләрендә: *агрегат, арматура, аппарат, генератор, вибрация, комбинат, мотор, радиация, радио, мануфактура, локомотив, инкубатор* һ.б.;

ә) административ-дәүләти һәм иҗтимагый-сәяси юнәлешләрдә: *диктатура, республика, демократия, социализм, империализм, конституция, материализм, либерализм, гуманизм, декларация, директива, делегат, оппортунизм, интернационал, пролетариат, территория, пленум, конгресс, президиум, реакция, депрессия, конкурент, колония, консул, нейтралитет, прогрессив, эволюция, эмигрант* һ.б.;

б) фәнни төшенчәләр буларак: *академия, абстракция, атрибут, аспирант, объект, диспут, дискуссия, максимум, минимум, конференция, препарат, обсерватория, форум, молекула, индекс, субъект, инстинкт, университет, факультет, декан, доктор, доцент, кандидат, лаборант, интернат, аттестат, конспект, конкурс, рецензия, консультация, химия* һ.б.;

в) әдәбият, сәнгать һәм мәдәният төшенчәләрен белдерәләр: *автор, вокал, вариация, культура, публикация, легенда, нигилизм, оригинал, орнамент, иллюстрация, статуя, квартет, композитор, репетиция* һ.б.;

г) хәрби төшенчәләрне белдерәләр: *авиация, адъютант, ветеран, агрессия, дивизия, интервенция, позиция, контрибуция, оккупация, снайпер, мобилизация, демобилизация, эвакуация* һ.б.;

д) медицина төшенчәләрен белдерәләр: *ампула, ампутация, амбулатория, витамин, операция, медицина, вакцина, инфекция, инфаркт* һ.б.;

е) финанс төшенчәләрен белдерәләр: *дебет, кредит, ревизия, аккредитив, актив, пассив* һ.б.

Рус теле аркылы татар теленә француз, алман, инглиз телләреннән кергән терминнар да шактый. Мәсәлән, инглиз теленнән спорт, диңгез транспорты, сәүдә өлкәсенә караган терминнар: *футбол, баскетбол, чемпион, рекорд, старт, финиш, волейбол, теннис, бокс, импорт, блокада,* һ.б.; алман теленнән алынган терминнар: *вексель, ордер, парламент, ракета, рейс, шахта, штат, масштаб, штамп, шаблон* һ.б.; сәнгатькә, музыкага, кулинариягә мөнәсәбәтле итальян алынмалары: *ария, барокко, кантата, либретто* һ.б.

Әйтергә кирәк, санап үтелгән алынмаларның байтагы термин кысасыннан чыгып, гомумкулланылыш сүзләре рәтенә күчте.

Татар телендә калькалаштырылган терминнар да шактый кулланыла. К а л ь к а французчадан *calque – копия* дигәнне аңлата, ул чит тел сүзен яки сүзтезмәсен сүзгә-сүз, өлешен өлешкә тәрҗемә итүгә кайтып кала. К а л ь к а л а ш т ы р у исә башка телнең структурасын һәм семантикасын күчереп алу дигән сүз.

Терминнар ясалышында сүзьясалыш калькалары – сүзнең һәр морфемасын, тамырларын, кушымчаларын тәрҗемәләү (рус. *ледокол* – тат. *бозваткыч*); семантик калька – бу сүзнең күчерелмә мәгънәсен алуга кайтып кала (*борын* ‘нос’, ‘мыс’, *култык* ‘подмышка’, ‘залив’, *бугаз* ‘гортань’, ‘пролив’).

Ярымкалькалар да очрый. Бу очракта сүз тоташ та, өлешчә генә дә тәрҗемә ителергә мөмкин: *спецвагон – махсус вагон, земной шар – җир шары, воздушный флот – һава флоты*, *подъемный кран – күтәрү краны, литейный цех – кою цехы, левые эсеры – сул эсерлар, внутрисоюзный – союз эчендәге, лесозавод – агач заводы.*

Калькалаштырылган терминнарга мисаллар: *озеленение – яшелләндерү, самоопределение – үзбилгеләнү, ледокол – бозваткыч, күпьеллык – многолетний, двуличие – икейөзлелек, подвижность – хәрәкәтчәнлек, объединение – берләшмә, водоросль – суүсем, животноводство – терлекчелек, единство – бердәмлек, соглашательство – килешүчәнлек, вероятность – ихтималлык, военизация – хәрбиләштерү, деятельность – эшчәнлек, воспламеняемость – кабынучанлык, показатель – күрсәткеч, сознательность – аңлылык.*

Кушма сүзләрне сүзгә-сүз тәрҗемә итүдән дә калька ясала ала: *пятилетка – бишьеллык, надстройка – өскорма, многолетний – күпьеллык, многоточие – күпнокта, восьмилетний – сигезьеллык, самодеятельность – үзешчәнлек, великодушие – олыҗанлылык, рукопись – кульъязма, представление – күзаллау, самосознание – үзаң, самоцель – үзмаксат, многомиллионный – күпмиллионлы.*

Рус сүзләрен калькалаштырганда, кушма яисә ярымкушма терминнар туа: *скороспелый – тиз өлгерүчән, самотеком – үз агымы белән, здравомыслие – сәламәт акыллылык, самодвижущийся – үзе хәрәкәт итә торган, хладнокровие – салкын канлылык, предвыборный – сайлау алды, взаимообусловленность – үзара шартлылык, самолюбие – үзен ярату, вышеуказанный – югарыда күрсәтелгән.*

Шулай итеп, татар телендә терминнарның чыганаклары булып гадәти әдәби сүзнең терминлашуы, кардәш булмаган телләрдән терминнар алу һәм калькалаштыру юллары тора.

### § 27. Терминнарның структур-ясалыш үзенчәлекләре

Терминнарны, иң элек, ике төркемгә бүләләр: термин-сүзләр, термин-сүзтезмәләр. Махсус мәгънәләр, төшенчәләр һәрбер фәндә дип әйтерлек телдәге сүзләр саныннан күбрәк. Шуңа күрә күп кенә махсус төшенчәләрне сүзтезмәләр белән дә белдерергә туры килә. Бу бүлекчәдә һәр ике төрнең дә структур-ясалыш үзенчәлекләре тикшерелә.

Ф. Ганиев составлары ягыннан сүзләрне синтетик, аналитик һәм аббревиатур дигән төрләргә бүлә. Ф. Фәсиевнең термин-сүзләрне тамыр һәм ясалма төрләргә бүлүе (Фасеев, 1961: 30–34) Ф. Ганиевтә менә шул төрләр эчендә карала (Ганиев, 1974: 41–48).

**Синтетик** сүз-терминнарга, барыннан да элек, тамыр терминнар керә: *җөмлә, фигыль, аваз, нокта* һ.б.

Тамыр сүзләрнең бер өлеше гомумкулланылыш сүзләре термины рәтенә күчүе семантик ысул ярдәмендә башкарыла. Мәсәлән, татарча *кыр* сүзенең һәм терминының түбәндә 4 мәгънәсе бирелгән, аларның барысының да бер сүз булуы татарча сөйләшүчегә ачык.

*Кыр* 1) поле, нива // полевой; *иген кырлары* ‘возделанные поля’, *кыр белгече* ‘полевод’; *кыр эшләре* ‘полевые работы’; *кыр чәчәкләре* ‘полевые цветы’, *кыр станы* ‘полевой стан’; *кыр тычканы* ‘полевая мышь, полевка’; 2) участок, земля: *безнең кыр* ‘наш участок’; 3) физ.-мат. поле; *векторлар кыры* ‘векторное поле’, *магнит кыры* ‘магнитное поле’; 4) дикий, некультированный, полевой; *кыр аты* ‘кулан, дикая лошадь’, *кыр казы* ‘дикий гусь’, *кыр ишәге* ‘онагр, дикий осел’, *кыр кынасы* бот. ‘недотрога’, *кыр кәҗәсе* ‘серна, косуля; антилопа’; *кыр мәчесе* зоол. ‘оцелот’, *кыр сабаны* бот. ‘огневик, барская спесь’, *кыр сарыгы* ‘дикая овца, аргали’, *кыр солысы* ‘овес дикий’, *кыр суганы* ‘дикий лук’, *кыр тавыгы* ‘тетерев’ һ.б.

Ясалма термин-сүзләр дә синтетик сүзләргә карый. Алар кушымчалар ярдәмендә ясалалар. Мәсәлән: *-лык/-лек*: *кешелек* ‘человечество’, *бердәмлек* ‘единство’; *-лашу/-ләшү*: *берләшү* ‘объединение’, *күмәкләшү* ‘коллективизация’; *-лаштыру/-ләштерү*: *дәүләтләштерү* ‘национализация’, *электрлаштыру* ‘электрификация’; *-ландыру/-ләндерү*: *яшелләндерү* ‘озеленение’; *-чанлык/ -чәнлек*: *уалучанлык* ‘ломкость’, *ярсучанлык* ‘раздражимость’; *-ыш/-еш*: *үсеш* ‘развитие’, *чагылыш* ‘отражение’; *-ма/-мә*: матем. *аңлатма* ‘выражение’, *өстәмә* ‘дополнение’; *-ымта/-емтә*: геом. *кисемтә* ‘отрезок’, матем. *биремтә* ‘данное’, *сөземтә* ‘резюме’, *сызымта* ‘очертание’; *-ымча/-емчә*: *кушымча* ‘кушымча, аффикс’; *-ынча/-енчә*: *төшенчә* ‘понятие’; *-ынты/-енте*: *йогынты* ‘влияние’, *үсенте, үренте* ‘рассада’, *чыгынты* ‘выступ’; *-гы/-ге, -кы/-к*: *яралгы* ‘зародыш’ һ.б.ш.

Термин ясаучы кушымчаларны функциональ яктан Ф. Фәсиев шулай төркемли:

**1.** Зат исемнәре ясаучылар: 1) актив затлар: *-чы, -учы, -ман, -кар, -дар, -ист, -ант, -тар, -ир, -ник* һ.б.: *җырчы* ‘певец’, *йөзүче* ‘пловец’, *атаман, төркмән, гыйлемдар* ‘ученый’, *хезмәткәр* ‘труженик’, *лаборант, агитатор, бригадир* һ.б. Бу төркемгә рус алынмасы булган *-ман, -мен, -ист* һ.б. кушымчалар да кергән;

2) гомумиләштерелгән затлар: *-лы, -даш, -ый,-ский; иделле* ‘волжанин’, *мәскәүле* ‘москвич’, *таулы* ‘горец’, *җирле* ‘местный’, *ватандаш* ‘соотечественник’, *Болгарский* (фамилия).

**2.** Әйбер исемнәре ясаучылар: 1) функциональ яктан актив әйберләр ясыйлар: *-ак, -вык, -выч, -гыч, -кыч, -гы, -кы, -ач, -ыч, -мак, -мар, -гак, -как: урак* ‘серп’, *иләк* ‘решетка’, *янавыч* ‘брусок, оселок’, *шакылдавык* ‘колотушка’, *тамызгыч* ‘пипетка’, *пычкы* ‘пила’, *чалгы* ‘коса’, *капкач* ‘крышка’, *чүкеч* ‘молоток’, *чүмеч* ‘ковш’, *тукмак* ‘колотушка’, *чукмар* ‘палица, булава’;

2) функциональ пассив предметлар (материаллар) ясыйлар: *-лык, -лау, -чык, -ча, -са, -сым, -ка, -ма, -мак, -мар, -ан, -ган* һ.б.: *яулык* ‘платок’, *күзлек* ‘очки’, *түшлек* ‘подбрюшник’, *сораулык* ‘вопросник’, *уклау* ‘скалка’, *китапчык* ‘книженка’, *җепсә* ‘спица, конек’, *аксым* ‘белок’, *ботка* ‘каша’, *түмәр* ‘чурбан’, *ярма* ‘крупа’, *кисмәк* ‘кадка’, *таган* ‘таган’.

**3.** Урын исемен ясаучылар: 1)нәрсәгәдер бай булган урын исеме: *-лак, -лавык, -давык, -лан, -лы, -лык, -сар, -зар: бозлавык* ‘гололедица’, *бозлык*‘ледник’, *аулык* ‘место охоты’, *алан* ‘лесная поляна’, *ялан* ‘поле, степь’, *имәнлек* ‘дубняк’, *каенсар* ‘березовка’, *чишмәле* ‘с родником’.

2) рельеф атамасын ясыйлар: *-лак, -лык, -лау, -лавык, -ганак: кашлак* ‘косогор’, *тарлавык* ‘ущелье’, *ерганак* ‘рытвина’, *таулык* ‘гористая местность’, *түбәнлек* ‘низина’, *уйсулык* ‘низменность’;

3) зур булмаган урын исеме: *-ча, -чык, -са, -ка, -дык, -лык: бакча* ‘сад’, *мәйданчык* ‘площадка’, *иңсә* ‘затылок, плечо’, *бүлемтек* ‘подотдел’, *култык* ‘залив’;

4) гадәти булмаган урын исеме: *-гак, -галак, -канак, -авык, -ламык: баткак* ‘вязкий, топкий’, *сайгак* ‘половица’, *сызлавык* ‘нарвы’, *шугалак* ‘каток’;

5) эш урыны исеме: *-ак, -лавыч, -лау, -лак, -лык, -чылык, -у, -дык, -ура: җәйләү* ‘летняя стоянка’, *кышлау/кышлак* ‘зимняя стоянка’, *торак* ‘общежитие’, *ятак* ‘постель’, *урындык* ‘сиденье’, *кичү* ‘переправа’;

6) процесс тәэсир иткән урын исеме: *-а, -ан, -ык, -ым, -ма, -гын, -тык, -ынты: ызан* ‘межа’, *ярык* ‘щель, трещина’, *ертык* ‘рваный’, *кисентек* ‘делянка, вырезка’, *ермак* ‘канавка’;

7) ил исемнәрен ясый: *-ия, -стан: Англия, Россия, Башкортостан, Татарстан* һ.б.

**4.** Процесс исемнәрен ясаучылар: 1) процесс исемнәрен: *-у/-ү: баету* ‘обогащение’, *кайнату* ‘кипячение, кайнау’, *көйләү* ‘настройка’, *сырлау* ‘нарезка’, *кабызу* ‘зажигать’;

2) актив процесс исемнәрен: *-лау, -ату, -айту, -ландыру, -лаштыру, -ация: тозлау* ‘солить’, *фикерләү* ‘мыслить, думать’, *өйрәтү* ‘учить’, *озату* ‘провожать’, *тарайту* ‘сузить’, *тулыландыру* ‘пополнять’, *электрлаштыру* ‘электрифицировать’, *кинофикацияләү* ‘кинофицировать’;

3) пассив процесс исемнәрен: *-айу, -ану, -лану, -лашу: уйлану* ‘размышлять’, *көчәю* ‘усиливаться’, *тураю* ‘выпрямляться’, *камилләшү* ‘совершенствоваться’;

4) процесс нәтиҗәсе исемен: *-ма/-мә, -ымта/-емтә, -ым/-ем/ -м: өстәмә* ‘надбавка’, *кушымта* ‘смесь, приложение’, *басым* ‘ударение, давление’.

**5.** Билге исемнәрен ясаучылар: 1) объектив билге исемнәрен: *-ынкы, -чан, учан, -чыл, -кын, -даш, -чак: җәенке* ‘распространенное’, *киеренке* ‘напряженный’, *сузылучан* ‘растяжимый’, *хезмәтчел* ‘труженик’, *кискенлек* ‘резкость’, *аваздаш* ‘тождественный по звучанию’;

2) функциональ билге исемнәре: *-лык, -гыч/-кыч, -учы: төрләндергеч* ‘(аффикс) словоизменительный’, *ясагыч* ‘(аффикс) словообразующий’;

3) субъектив билге исемнәрен: *-ган, -чак, -мчак, -мсак, -гай (лык): уйчан* ‘задумчивый’, *ашамсак* ‘любитель поесть’, *сөйләмчәк* ‘разговорчивый’, *аумакайлык* ‘шаткость, неустойчивость’, *ялагайлык* ‘подхалимство’;

4) ким билге исемнәрен: *-гыл, -гын, -гылт, -гырт, -лтым, -лҗым, -лтрак, -мык, -мтырак, -мты, -сым, -сыл, -сы* һ.б.: *талгын* ‘теплый, спокойный’, *кызгылт* ‘красноватый’, *сусыл* ‘сочный, водянистый’, *салкынча* ‘прохладный’, *төксе* ‘мрачный’;

5) күләм-сан билгеләре атамаларын: *-чел, -ге, -гән: беренчел* ‘первичный’, *меңләгән* ‘многотысячный’;

6) конструктив билге атамаларын: *-ышлы, -ма, -малы, -арлы, -улы, -лык, -лы: ачылмалы* ‘открывающийся’, *йөзмә* (мост) ‘плавающий’, *унарлы* ‘десятичный’, *сызыклы* ‘линованный’, *тәүлеклек* ‘суточный’;

7) урын яки вакыт исемнәрен: *-гы/-ге, -дагы/-дәге, ый: алгы, алдагы* ‘передний’, *кырый-кырыйдагы*‘ крайний, боковой’,

*көзге-җәйге* ‘осенний-летний’, *миладu* ‘христианское летосчисление’һ.б.

**6.** Абстракт сүз ясаучы кушымчалар: 1) гомумиләштерелгән сүзләрне ясыйлар: *-лык, -ыч, -ыш, -ма: чынбарлык* ‘действительность’, *яшәеш* ‘бытие’, *үсеш* ‘развитие’, *күренеш* ‘явление’, *таяныч* ‘опора, подпорка’, *үтенеч* ‘просьба’, *тигезлек*‘равнина’, *бәхетсезлек*‘несчастье’;

2) хезмәт юнәлеше исемнәрен ясый: *-лык,-чылык, -янлык, -изм: очучылык* ‘профессия пилота’, *җәнлекчелек* ‘звероводство’, *шахтерлык* ‘шахтерское’*, группачылык* ‘групповщина’;

3) үсемлекләр һәм хайваннар исемен: *-лар, -сыманнар: сөйрәлүчеләр* ‘пресмыкающиеся’*, имезүчеләр* ‘млекопитающие’, *кысласыманнар* ‘ракообразные’, *ылыслылар* ‘хвойные’;

4) гыйльми юнәлешләрнең исемен: -*ять, -ия, -логия, -ика, -белем: табигыять* ‘естествознание’, *химия, биология, грамматика, тел белеме* ‘языкознание’, *әдәбият белеме* ‘литературоведение’.

Принципта теләсә нинди исем ясагыч кушымча терминнар ясалышында да кулланыла ала: 1) *-чы/-че*: *терлекче* ‘животновод’, 2) *-чылык*: *кошчылык* ‘птицеводство’, 3) *-лек*: *кешелек* ‘человечество’, *бердәмлек* ‘единство’, 4) *-ләш*: *берләшү* ‘обьединение’, *күмәкләшү* ‘коллективизация’; 5) *-лаштыру/-ләштерү*: *дәүләтләштерү* ‘национализация’, *электрлаштыру* ‘электрификация’; 6) *-ландыру/-ләндерү: яшелләндерү* ‘озеленение’; 7) *-чанлык/-чәнлек*: *уалучанлык* ‘ломкость’, *ярсучанлык* ‘раздражимость’; 8) *-ым/-мә: аңлатма* ‘объяснение’, *өстәмә* ‘дополнение’; 10) *-ымта/-ымтә: кисемтә* ‘отрезок’ (геометр), *биремтә* ‘данное’, *сызымта* ‘очертание’; 11) *-ымча/-емчә: кушымча* ‘кушымча’; 12) *-ынча/-енчә: төшенчә* ‘понятие’; 13) *-ынты/-енте: йогынты* ‘влияние’, *үсенте* ‘рассада’, *чыгынты* ‘выступ’; 14) *-гы/-ге, -кы/-ке: яралгы* ‘зародыш’, *тойгы* ‘чувство’, *сөйләк* ‘сказ’, *очрак* ‘случай’ һ.б.

Кушымчалау юлы белән сыйфатлар ясау: *чигүле* ‘вышитый’, *буяулы* ‘выкрашенный’, *перспективасыз* ‘бесперспективный’, *түләүсез* ‘бесплатный’, *чабулык* ‘предназначенный или пригодный для полы’, *киселмәле* ‘разрезной’, *ясалма* ‘искусственный’ һ.б.

Аерылып чыгарылмый торган кушымчалар сыйфатларда – 16. Мәсәлән: *җәлпәк* ‘сплюснутый’, *сүлпән* ‘вялый’, *кылтык* ‘хвастливый’, *чандыр* ‘сухощавый’, *кылый* ‘косой’ һ.б.

Сыйфатлар алынма кушымчалар ярдәмендә ясала: *революцион* ‘революционный’, *объективный, популяр* ‘популярный’.

**Аналитик** терминнар башкача кушма терминнар дип атала. Алар икедән ким булмаган тулы мәгънәле тамыр сүзләрдән, яки бер тулы мәгънәле, бер ким мәгънәле сүздән ясалалар. Бу проблеманы җентекләп өйрәнгән Ф. Ганиев фикеренә караганда, татар телендәге иң күп аналитик сүз-терминнар ике сүздән ясалалар: *өчпочмак* ‘треугольник’, *ташбака* ‘черепаха’, *үзаң* ‘самосознание’. Аналитик сүз-терминнар өчәр, дүртәр сүздән дә ясалырга мөмкин: *үги ана яфрагы* ‘мать-и-мачеха’.

Кушма (аналитик) терминнарның бер төркемен катлаулы сүзләр тәшкил итә. Болар үзара атрибутив, предикатив, хәл яки тәмамлык мөнәсәбәтенә кергән сүзләрдән торалар. Бу төр кушма сүзләр аналитик сүзләрнең төп өлешен тәшкил итәләр. Ләкин, сүзтезмәләрдән аермалы буларак, катлаулы сүзләрне тәшкил итүче берәмлекләр, үзара кушылып, бер сүзгә әйләнеп киткән булырга, орфографиядә кушылып язылырга тиешләр. Билгеле булганча, кушылган нигезләр арасында тезүле мөнәсәбәт булса, бу нигезләр *парлы сүз* ясыйлар: *җир-су* ‘родина’, *явым-төшем* ‘осадки’. Парлы сүзләр термин буларак та кулланылалар: *аң-акыл* ‘разум’, *үсеш-үзгәреш* ‘развитие’, *аш-су* ‘кулинария’, *үгет-нәсыйхәт* ‘дидактика’, *әдәбият-сәнгать* ‘литература и искусство’, *фәнни-техник* ‘научно-технический’, *тел-әдәбият* ‘язык-литература’, *явым-төшем* ‘осадки’, *мин-минлек* ‘тщеславие, высокомерие’ һ.б.

Кушылган нигезләр арасында ияртүле мөнәсәбәт булса, алар кушма сүз ясыйлар. Компонентлары арасында ияртүле мөнәсәбәт урнашкан кушма исемнәр берничә төргә бүленәләр:

1. Компонентлары арасында атрибутив мөнәсәбәт урнашкан кушма сүзләр: *атнакөн* ‘пятница’, *ташъязма* ‘эпитафия’, *ярымутрау* ‘полуостров’, *тузбаш* ‘уж’, *кулъяулык* ‘носовой платок’, *каенсеңел* ‘золовка’, *суүсем* ‘водоросль’, *кулъязма* ‘рукопись’, *автохуҗалык* ‘автохозяйство’, *каз аягы* (ботан.) ‘гусиная лапа’, *күз кабагы* ‘веко’, *каен җиләге* ‘земляника’, *әдәбият белеме* ‘литературоведение’, *мәче борчагы* ‘алтей’, *терекөмеш* ‘ртуть’, *чынбарлык* ‘действительность’, *үзмаксат* ‘самоцель’, *янартау* ‘вулкан’, *кайтаваз* ‘эхо’.

2. Компонентлары арасында объект мөнәсәбәте урнашкан кушма исемнәр: *метеокүзәтү* ‘метеонаблюдение’, *елъязма* ‘летопись’, *көньязма* ‘дневник’.

3. Компонентлары арасында хәл мөнәсәбәте урнашкан кушма исемнәр: *күзаллау* ‘представление’, *беравыздан* ‘единогласно’, *бертавыштан* – ‘единогласно’.

4. Сүзтезмә лексикалашып та китә: *өчпочмак* ‘треугольник’.

5. Атрибутив сүзтезмәләр кушма сүзгә күчә: *бишпочмак* ‘пятиугольник’, *сигезаяк* ‘осьминог’, *каракош* ‘орел’, *озынборын* ‘комар’, *сорыкорт* ‘трутень’, *аю колагы* ‘медвежье ухо’, *күгәрчен күзе* ‘незабудка’, *эт эчәге* ‘вьюнок полевой’ һ.б.

6. Компонентлары арасында объект мөнәсәбәте булган сүзтезмәләр кушма сүзгә күчә: *үзсөяр* ‘эгоист’, *йөзьяшәр* ‘столетник’ һ.б.

7. Кушма исемнәрне төзегән нигезләр янында кушымчалар да килә: *хәреф җыючы* ‘наборщик’, *суүлчәгеч* ‘водомер’, *бишьеллык* ‘пятилетие’, *көнкүреш* ‘быт’, *карагруһчылык* ‘черносотенщина’ һ.б.

Термин-сүзләр арасында кушма сыйфатлар да очрый. Компонетлары арасында ияртүле бәйләнеш булса, кушма сыйфат барлыкка килә: *күпкатлы* ‘многоэтажный’, *дөньякүләм* ‘всемирный’, *ярымкыргый* ‘полудикий’, *шәһәрара* ‘междугородный’, *ультракыска* ‘ультракороткий’.

Алда билгеләп үтелгәнчә, терминнарның икенче зур төркемен термин-сүзтезмәләр хасил итә. Терминология фәнендә термин-сүз проблемалары шактый җентекле өйрәнелгән дияргә кирәк. Термин да сүз булып саналганлыктан, термин-сүзләрнең ясалыш ысулларын өйрәнгәндә, сүз ясалышын тикшерү нәтиҗәләренә таяналар. Шушы тәҗрибәдән чыгып фикер йөртсәк, термин-сүзтезмәләрне өйрәнүчеләр синтаксисның сүзтезмәләр өйрәтмәсенә таянып эш итәргә тиешләр. Ләкин термин-сүзтезмәләрне өйрәнүчеләр синтаксистагы сүзтезмәләр өйрәтмәсен гомумән исәпкә алмыйлар. Шуңа күрә тюркологиядә генә түгел, гомумән лингвистика фәнендә термин-сүзтезмәләрне өйрәнү канәгатьләнерлек түгел, сүзтезмәләр өйрәтмәсе термин-сүзтезмәләрне өйрәнү процессына гомумән кертелмәгән.

Мәгълүм булганча, лингвистикада термин-сүзтезмәләрне «термины-описания» (термин аңлатма) яки «термины-свернутые дефиниции» (термин – җыйнак билгеләмә) дип өйрәнү күзәтелә.

Терминология буенча танылган белгеч А. Исаченко үзенең «Термин-описание» или «термин-название» («Термин-аңлатма яки «термин-атама») дигән мәкаләсендә термин-атама дип гадәти бер

сүзле терминнарны таный, ә термин-аңлатмага термин-фразаларны кертә. Күп сүздән ясалган терминнар – төшенчәләргә бирелгән кыскартылган билгеләмә (дефиниция) була, дип яза. А. Исаченко, төшенчәне күп сүз белән аңлатудан, билгеләмә бирүдән әкренләп котылырга кирәк, дип белдерә (Исаченко, 1962: 17–20). Билгеле, терминнар ясауда сүзләрне сүзтезмә итеп оештыру юлы реаль һәм ул борынгы чордан ук килә: яңа төшенчәгә башта термин-сүзтезмә рәвешендә аңлатма бирәләр, әкренләп аның сүзе-термины пәйда була, дигән фикер әйтә ул. Кызганычка каршы, А. Исаченко фәнни төшенчәләрнең фәндә, тормышның төрле өлкәләрендә бик тиз арта торуын истә тотмый. Чыннан да, төшенчәләр бик тиз арта, аларның барысын да сүз белән генә белдерергә сүзлек составында сүзләр җитми башлый. Яңа төшенчәгә һәрчак яңа сүз ясап булмый, аны кыскартылган аңлатма белән бирү мөмкинлеге генә кала. А. Исаченко яңа төшенчәне сүзтезмә, яисә кыскартылган атама белән бирүдән котылырга өнди.

Терминология буенча «Общая терминология. Вопросы теории» дигән китапның танылган авторлары А. Суперанская, Н. Подольская, Н. Васильева А. Исаченконың бу фикерен кабул итмиләр, аңа каршы болай дип белдерәләр: атаманы аңлатмага каршы куярга ярамый, чөнки барлык терминнар да (бер сүзлесе дә, күп сүзлесе дә) фикер төшенчәсенең атамасы булып торалар. Алар фикеренчә, термин-фразалар төшенчәне бер сүз белән бирү мөмкинлеге булмаганда һәм төшенчәне тагын да төгәлрәк бирергә омтылганда барлыкка киләләр. Мондый термин-аңлатмалы фразалар бигрәк тә технология һәм җитештерү технологиясе өлкәсендә күп күзәтеләләр (Суперанская, 1989: 97–98).

Гадәттә башка телдән алынган терминнарга аңлатма бирергә туры килә, шуңа күрә аңлатмалар алынма терминнар сүзлеген төзегәндә киң кулланылалар. Мисалга «Русча-татарча икътисад терминнары сүзлеге»ннән *автаркия* һәм *арбитраж* терминнарына бирелгән аңлатмаларны китерергә мөмкин. ***Автаркия*** *– үз эшендә кайнау* ‘суетиться своими делами’; *беркем белән дә бәйләнеш тотмау; йомык милли яки региональ хуҗалык оештыру турындагы икътисади сәясәт.* ***Арбитраж*** *– арбитрлар суды; милек мәсьәләләрен карый торган дәүләт органы. Шул суд карары. Яклар арасында бәхәсләрне бәйсез арбитрлар катнашында хәл итү алымы.*

Татар сүзтезмәләренең барлык төрләре дә М. Зәкиевнең «Синтаксический строй татарского языка» (Закиев, 1963: 80–223) китабында һәм академик «Татар грамматикасы»ның III томында (Татар грамматикасы, 1998: 31–151) тасвирланганнар. Ә татар теленең термин-сүзтезмәләре Ф. Фәсиев хезмәтләрендә махсус өйрәнелгәннәр. Галим термин-сүзтезмәләрне «составные термины» дип атый һәм аларның түбәндәге модельләре барлыгын күрсәтә:

**А**. Атрибутив конструкцияле тезмә (составные) терминнар, болар аергыч һәм аерылмыштан торалар: *Кызыл Армия* ‘Красная Армия’.

**Б**. Объект-фигыль, ягъни «тәмамлык-фигыль» моделендәгеләр: *инкярны инкяр итү* ‘отрицание отрицания’.

**В**. Хәл конструкциясендәге сүзтезмәләрдән торган терминнар. Болар кайсы да булса бер хәл кисәге + фигыль моделендә булалар: *тиземле рәвештә коммунизмга күчү* ‘постепенный переход к коммунизму’.

**Г**. Предикатив конструкциядә булган тезмә термин, ягъни субъект-предикат мөнәсәбәтендәге сүзләрдән торганнары: *җир тетрәү* ‘землетрясение’, *кояш тотылу* ‘затмение солнца’ (Фасеев, 1961: 34).

Ф. Фәсиев тикшергән сүзтезмәләрнең төрләрен, модельләрен җентеклерәк билгеләргә кирәк. Моның өчен модельләрне төзүче билгеләр һәм аларның мәгънәләре белән укучыны да таныштыру урынлы булыр.

| | | |
|---|---|---|
| **И** – исем. | **Х** – төрле сүз. | → грамматик бәйләнеш → |
| **С** – сыйфат. | **У** – инфинитив (*у-ү*). | + нигезгә кушылу → |
| **Сн** – сан. | **-ыш** – фигыль-исем. | |
| **Рв** – рәвеш. | **-ы** – тартым *-ы/-е, -сы/-се* | |
| **Ф** – фигыль. | *-ның* – иялек килеше. | |

**Тартымлы тезмә терминнар**

1. И → (И + *ы*): *эш көче* – рабочая сила.

2. (И + *ның*) → (И + *ы*) *җитештерүнең үзәкләшүе* – централизация производства.

3. (И + *ләр*) → (И + *ы*): *Милләтләр Советы* – Совет Национальностей.

4. И → (И + *лар* + *ы*): *җитештерү мөнәсәбәтләре* – производственные отношения.

5. (И + *лар*) → (И + *лар* + *ы*): *эшчеләр поселогы* – рабочий поселок.

6. (И + *лык*) →(И + *ы*): *ыруглык строе* – родовой строй.

7. (И + *чылык*) → (И + *ы*) *җәмәгатьчелек фикере* – общественная мысль.

8. (И + *дашлык*) → (И + *ы*): *арадашлык операцияләре* – посреднические операции.

**Тартымлы булмаган тезмә терминнар**

9. И. → И: *нигез тел* – язык основа, *интернат мәктәп* – школа-интернат.

10. С. → И: *тигез хокук* – равное право.

11. С (сложный) → И: *икебуынлы тигезләмә* –двучленное уравнение.

12. Сн → И: *кырык карта* – сычуг.

13. (И + *лы*) →И; *тешле тәгәрмәч* – зубчатое колесо.

14. (И + *лык*) → И: *еллык баланс* – годичный баланс.

15. (Ф + *улык*) →И: *чәчүлек майдан* – посевная площадь.

16. С (катлаулы) → И: *бишьеллык план* – пятилетний план.

17. (Х + *лыклы*) →И: *хәбәрлекле тезмә* – предикативное сочетание.

18. (Х + *даш*) → И: *тамырдаш тигезләмә* – равносильное уравнение.

19. (Ф + *улы*) → И: *камаулы әйләнә* – вписанная окружность.

20. (Ф + *ышлы*) → И: *өзелешле функция* – разрывная функция.

21. (Ф + *ымлы*) → И: *күчемле фигыль* – переходный глагол.

22. (Рв + *гы*) → И: *түбәнге палата* – нижняя палата.

23. (И + *дагы*) → И: *агымдагы счет* – текущий счет.

24. (Ф + *ынкы*) → И: *кабарынкы линза* – выпуклая линза.

25. (И + *чы*) → И: *ярдәмче фигыль* – вспомогательный глагол.

26. (И + *дашчы*) → И: *арадашчы буын* – посредствующее звено.

27. (Х + *ач*) → И: *тиреләч ташбака* – мягкая (?) черепаха

28. (Сн + *нчы*) → И: *икенче дәрәҗә (квадрат)*– вторая степень.

29. (И + *чыл*) →И: *тәнкыйтьчел караш* – критический взгляд.

30. (Сн + *чыл*) → И: *беренчел материя* – первичная материя.

31. (И + *чан*) → И: *тормышчан конфликт* – жизненный конфликт.

32. (Ф + *учан*) → И: *җыелучан рәт* – сходящийся ряд (мат.).

33. (И + *ча*) → И: *санча кыйммәт* – численное значение.

34. (И + *ларча*) → И: *гражданнарча вакыт* – время гражданское.

35. (И + *лата*) →И: *тереләтә авырлык* – живой вес.

36. (И + *сыман*) → И: *кешесыман маймыл* – человекообразная обезьяна.

37. (И + *су*) → И: *комсу туфрак* – супесчаная почва.

38. (И + *сыл*) → И: *төксел материя* – ворсистая материя

39. (И + *чык*) → И: *башланчык органнар* – зачаточные органы.

40. (Ф + *(г) ак*) → И: *сынгак эт шомырты* – крушина ломкая.

41. (Ф + *гын*) → И: *уйгын форма* – адекватная (точная) форма.

42. (И + *гача*) → И: *мәктәпкәчә тәрбия* – дошкольное воспитание.

43. (Х + *дам*) → И: *бердәм фронт* – единый фронт.

44. (Х + *дай*) → И: *тимердәй дисциплина* – железная дисциплина.

45. (Ф + *вык*) → И: *чыртлавык коңгызлар* – щелкуны:

46. (И + *ый*) → И: *сыйнфый көрәш* – классовая борьба.

47. (И + *ви*) → И: *тәрбияви әһәмият* – воспитательное значение.

**Халыкара сыйфатлар белән**

47. (Х + ноль форма) →И: *абстракт төшенчә* – абстрактное понятие.

48. (Х + *ик*) → И: *коммунистик төзелеш* – коммунистическое строительство.

49. (Х + *аль*) → И: – *социаль тәэминат* – социальное обеспечение.

50. (Х + *ив*) → И: *индуктив метод* – индуктивный метод.

51. (Х + *ион*) → И: *позицион чиратлашу* – позиционное чередование.

52. (Х + *ар*) → И: *аграр мәсьәлә* – аграрный вопрос.

53. (Х + *ый*) → И: *массовый хәрәкәт* – массовое движение.

**Сыйфат фигыльле тезмә терминнар**

54. (Ф + *учы*) → И: *имезүче хайван* – млекопитающее; *йөртүче ракета* – ракетоноситель.

55. (Ф + *гыч*) → И: *тоташтыргыч тукыма* – соединительная ткань.

56. (Ф + *выч*) → И: *каплавыч кабырчыклар* – чешуйки кроющие.
57. (Ф + *ма*) → И: *кайтма нерв* – возвратный нерв.
58. (Ф + *ылма*) → И: *кулланылма математика* – прикладная математика.
59. (Ф + *малы*) → И: *ялганмалы телләр* – агглютинирующие языки.
60. (Ф + *гы*) → И: *менге ат* – верховая лошадь.
61. (Ф + *ган*) → И: *тупланган хезмәт* – накопленный труд
62. (Ф + *а торган*) → И: *кисешә торган сызыклар* – пересекающиеся линии.
63. (Ф + *мыш*) → И: *аерылмыш сүз* – определяемое слово.
64. (Ф + *дык*) → И: *калдык деформация* – остаточная деформация.
65. (Ф + *ык*) → И: *сузык аваз* – гласный звук.
66. (Ф + *ар*) → И: *очар тиен* – белка летучая.
67. (Ф + *рлык*) →И: *җитәрлек шарт* – достаточное условие.
68. (Ф + *рдәй*) → И: *чишелердәй мәсьәлә* – разрешимая задача.
69. (Ф + *ачак*) → И: *киләчәк заман* – будущее время.
70. (Ф + *асы*) → И: *киметәсе сан* – вычитаемое (К. Насыйрида).
71. (Сн + *арлы*) →И: *унарлы система* – десятичная система.

**Юклык мәгънәсендәге аергычлы тезмә терминнар**

72. (И + *сыз*) → И: *аныксыз зурлык* – неопределенная величина.
73. (Рв + *лыксыз*) → И: *бергәлексез вакыйгалар* – несовместимые события.
74. (Ф + *гысыз*) → И: *котылгысыз зарурлык* – неизбежный случай.
75. (Ф + *усыз*) → И: *кайтарусыз ссуда* – безвозвратная ссуда.
76. (Ф + *маучы*) → И: *өлгермәүче укучы* – неуспевающий ученик.
77. (Ф + *маучан*) → И: *эремәүчән матдә* – нерастворимое вещество.
78. (Ф + *маган*) → И: *түләнмәгән вексель* – неоплаченный вексель.
79. (Ф + *ышсыз*) → И: *затланышсыз фигыль* – безличный глагол.
80. (Ф + *ымсыз*) → И: *күчемсез фигыль* – непереходный глагол.

81. (Ф + *мый торган*) → И: *бүленми торган фонд* – неделимый фонд.

82. (Ф + *мас*) → И: *күренмәс нурлар* – невидимые лучи

83. (Ф + *маслык*) → И: *кабатланмаслык вакыйга* – неповторимый случай һ.б. (Фасеев, 1969: 162–165).

Болардан соң Ф. Фәсиев тезмә терминнарның башка төрләрен – ияртүче сүз белән иярүче сүз арасында тәмамлык яки хәл мөнәсәбәтләре булганнарын тасвирлауга күчә: *күмер казучы* – копатель угля, *сыер савучы* – доитель коров, *таш ватучы* – дробитель камня, *ат караучы* – конюх, *руда казучы* – копатель руды, *фикер алышу* – обменяться мыслями, *җирне дәүләтләштерү* – огосударствление земли, *чикләмәгә омтылу* – стремление к пределу, *җылыдан киңәю* – расширение от тепла һ.б.

Предикатив мөнәсәбәттәге тезмә терминнарга Ф. Фәсиев түбәндәге мисалларны китерә: *кояш тотылу* – затмение солнца, *күк күкрәү* – гром, *җир тетрәү* – землетрясение, *яшен яшьнәү* – сверкание молнии, *хәл бету* – уставать, *кояш сугу* – солнечный удар, *сару кайнау* – страдать изжогой, *һуш киту* – лишаться чувств, *сулыш тараю* – задыхаться, *күкрәк кысу* – одышка, *йөзе кара* – черноликий, *акылы кыска* – краткоумие, *кан азлык* – малокровие, *башы бозык* – его испорченная голова, *җир азлык* – малоземелье (Фасеев, 1969: 165–166).

Шулай итеп, татар лингвистикасында беренче буларак, Ф. Фәсиев термин-сүзтезмәләрне сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләреннән чыгып төркемли. Шуннан соң ул термин-сүзтезмәләрдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрнең кайсы сүз төркеменә каравын ачыклый һәм шуннан чыгып термин-сүзтезмәләрне тагын да кечерәк төркемнәргә аера.

Ф. Фәсиевнең бу төркемләвеннән тыш, татар теле терминологиясе буенча язылган кандидатлык диссертацияләрендә дә термин-сүзтезмә составын ачыкларга тырышу күзәтелә. Ләкин аларда термин-сүзтезмәләрне өйрәнү синтаксик бәйләнешләрнең һәм сүзтезмәләрнең үзенчәлекләре нигезендә бара дип әйтеп булмый. Менә шуның өчен биредә сөйләмдәге сүзләр бәйләнешенең синтаксик үзенчәлекләренә киңрәк тукталу урынлы булыр.

Кушма терминнарның нигезендә дә сүзтезмәләр ята. Кайбер сүзтезмәләр белдергән мәгънәләренең җыйнаклыгы, башка телләрдә бер генә сүз белән бирелүе, нигезләрнең кушылып китү

омтылышы нәтиҗәсендә, кушылып китәләр, бер сүз булып әйтеләләр *атнакөн* ‘пятница’, *кульяулык* ‘носовой платок’, *кульязма* ‘рукопись’.

Кушылып әйтелгән-язылган нигезләр арасында, сүзтезмәләрдәге кебек үк, ияртүле бәйләнеш, тезүле бәйләнеш була ала. Ияртүле бәйләнештәге барлык төр мөнәсәбәтләр дә күзәтелә.

Кушма терминнар белән термин-сүзтезмәләр бер-берсеннән кискен чик белән аерылып тормыйлар. Аларны гади генә бер үзенчәлек аерып тора: кушма терминдагы нигезләр – кушылып, сүзтезмәдәгеләре аерым язылалар. Мисаллар: 1) *субүләр* ‘водораздел’, *атнакөн* ‘пятница’, *кульяулык* ‘носовой платок’, *кульязма* ‘рукопись’, *үзмаксат* ‘самоцель’, *терекөмеш* ‘ртуть’ – болары һичшиксез кушма терминнар; 2) *күз кабагы* ‘веко’, *каен җиләге* ‘земляника’, *әдәбият белеме* ‘литературоведение’, *күгәрчен күзе* ‘незабудка’ кебек аерым язылган нигезләрдән торганнары термин-сүзтезмәләргә якын. Ләкин шунысы бар: боларны русча бары бер сүз белән генә тәрҗемә итәләр.

Русча сүзтезмә белән бирелгәннәре кушма сүз дип тә, сүзтезмә дип тә танылa алалар: *ат колагы* ‘медвежье ухо’, *эт эчәге/эт эчәгесе* ‘полевой вьюнок’.

Шулай итеп, кушма термин-сүзләр термин-сүзтезмәләргә бик якын торалар.

Татар термин-сүзтезмәләре, барыннан да элек, синтаксик сүзтезмәләрдән тора. Термин-сүзтезмәләр, әгәр дә бу төр бәйләнеш ныгып калган фразеологик берәмлеккә әйләнгән булса, үзара хәбәрлекле мөнәсәбәткә кергән сүзләрдән дә торырга мөмкин: *җир тетрәү, кояш тотылу*.

Тагын шуны онытырга ярамый: үзара төгәлләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләр дә, ныгып калып, фразеологик берәмлеккә әйләнергә мөмкин. Болары да термин-сүзтезмәләр рәтеннән каралалар. Мәсәлән, *үги ана яфрагы, эт шомырты* һ.б. Мондый фразеологик берәмлекләрдә сүзләр арасындагы реаль мөнәсәбәтләр югалган, ләкин бәйләүче чаралары сакланган була. Бу факт термин-сүзтезмәләрне тикшергәндә дә истән чыгарылырга тиеш түгел.

Кушма сүзтезмәләргә күп (икедән артык) компоненттан торган термин-сүзтезмәләр дә керәләр. Мисал өчен җинаять хокукы фәненә караган терминнарга тукталыйк: 1) ике компонентлылар: *җәмәгать иминлеге* ‘общественная безопасность’, *җинаятьчел гамәл*

‘преступное деяние’. Болары, билгеле, гади термин-сүзтезмәләр; 2) өч компонентлылар: *законсыз оборот ясау* ‘незаконное производство оборота’, *вәкаләтләрдән явыз файдалану* ‘злоупотребление полномочиями’, *прокурор эшчәнлегенә тыкшыну* ‘вмешательство в деятельность прокурора’; 3) дүрт компонентлылар: *җинаять законының кире көче* ‘обратная сила уголовного закона’ һ.б.

Шулай итеп, кушма сүзтезмә өч һәм өчтән артык компоненттан тора һәм, мәгънәгә зыян китермичә, гади сүзтезмәләргә таркала алмый.

Сүзтезмәләр, иң элек, ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменә каравыннан чыгып, зур төркемнәргә аерылалар. Ияртүче кисәк исем булса, ул *исем сүзтезмәгә* керә, ияртүчесе фигыль булса, *фигыль сүзтезмә* дип атала. Сөйләмдә иң еш очрый торган терминсүзтезмәләр шушылар. Термин-сүзтезмәләр, ияртүче компонентның кайсы сүз төркеменә каравыннан чыгып, тагын да ваграк төркемнәргә таркатыла. Мәсәлән, исемле исем сүзтезмәләр, фигыльле исем сүзтезмәләр, сыйфатлы исем сүзтезмәләр, алмашлыклы исем сүзтезмәләр, хәбәрлек сүзле исем сүзтезмәләргә таркатылалар.

Фигыль сүзтезмәләр дә, ияртүче сүзнең, кайсы сүз төркеменә каравыннан чыгып, бик күп төрләргә таркатылалар. Фигыль сүзтезмәләр, термин буларак, бары фигыль исемләшкәндә генә күзәтеләләр.

Бу урында шуны басым ясап әйтергә кирәк, исем урынында кулланылганда, фигыль (исем фигыль) үзенә ияреп килә торган сүзләрне исем кебек итеп тә, фигыль кебек итеп тә ияртә ала. Мәсәлән, *баланың укуы* сүзтезмәсендә *уку* дигән ияртүче компонент *бала* сүзенең иялек килешендә килүен таләп итә. Алар икесе III изафәгә туры килә торган термин-сүзтезмә төзиләр: *баланың укуы* ‘чтение ребенка’, чагыштыр: *авазның озынлыгы* ‘долгота звука’.

Исем фигыль үзенә буйсынган сүзне фигыль кебек итеп тә ияртә ала: *җитештерүне автоматлаштыру* ‘автоматизация производства’, *акчаны озакка салу = акчаны салу, озакка салу* ‘долгосрочное вложение денег’ = долгосрочное вложение, вложение денег.

## § 28. Терминологик һәм гомумкулланылыш лексикасының үзара мөнәсәбәте

Тел белемендә терминның гомумкулланылыш лексикасы рәтенә күчүен детерминлашу (детерминологизация) дип

атыйлар. Әлеге күренеш терминнар үстерүдә роль уйнамый, шул ук вакытта ул терминнарның санын киметми дә. Гомумкулланылыш сүзе булып киткән термин терминология системасында саклана, әмма аның мәгънәсе киң массаларга да аңлашыла, сөйләмдә актив кулланыла башлый.

Рус тел белемендә Н. Никитченко үзенең «Семантическая продуктивность терминов» дигән хезмәтендә, детерминлаштыруның төп сәбәбе итеп, фәннәрнең иҗтимагый әһәмияте артуны күрсәтә. Аның тикшеренүләре исбатлаганча, детерминлаштыру рус телендә 26 юнәлештә очрый. Бу темалар иҗтимагый тормышның түбәндәге юнәлешләренә карыйлар: хәрби, диңгезчелек, спорт һәм фәнни (химия, математика, физика, география), техник, медицина һ.б. (Никитченко, 1983: 26).

Татар телендә шушы ук мәсьәләне тикшергәч, А. Зинина детерминлаштыруның медицина-биология, хәрби-диңгезчелек, спорт, физика, география, музыка, театр юнәлешләренә каравын күрсәтә: транспорт *артерияләре*, хәрби *психоз*, урып-җыю *фронты*, химия *флагманы*, империализм сәясәте *фарватеры*, империализм *форпосты*, сөйләшүләрнең чираттагы *раунды* үткәрелде; хәзер объектта ташчылар *эстафетасы* отделкачыларга күчте; бу съезд *дирижерларын* бик канәгатьләндерә; инициативаларның киң *спекторы* һ.б. (Зинина, 1992: 43).

Рәсми терминнарның халык иркенләп куллана торган текстларга керүе – ул, бер яктан, детерминлашу күренеше булса, икенче яктан, ул сүзләрнең метафорик яктан үзгәрешен дә күрсәтә. Терминнарның әдәби телдә кулланылышы стилистик яктан да бик әһәмиятле, стильне тагын да аңлаешлырак итә.

Бу бүлекчәдә ретерминлашу (ретерминологизация) күренешенә, ягъни бер өлкәдәге фәнни терминның башка өлкәдә куллануына да тукталып үтәбез. Әлеге очракта терминга яңа билгеләмә бирелә һәм ул башка терминга әйләнә. Шуңа күрә ретерминлаштыру яңа термин ясау буларак өйрәнелә.

Ретерминлаштыруга мисал итеп, бирედә *хәбәр* һәм *операция* сүзләрен китерик. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә аларның төрле өлкәләрдә төрле мәгънәдә кулланылышы ачык күрсәтелгән.

**ХӘБӘР** *ис. гар.* 1) Белдерү, вакыйга, белешмә, мәгълүмат. *Соңгы хәбәрләр. Авыл хәбәрләре*; 2) вакытлы матбугатта басылган мәкалә, корреспонденция. *Газетка х. язу*; 3) *күч.* Төрле имеш-

мимеш, дөреслеге төгәл билгеле булмаган сүз, гайбәт. *Урам хәбәрләре*; 4) *сөйл.* Хат, мәгълүмат, белешмә сүз. *Улыңнан хәбәр бармы?* 5) *лингв.* Җөмләнең иягә буйсынган, башкарылган яки башкарыла торган эшне, вакыйганы, хәлне белдерә торган баш кисәге □ **Хәбәр итү (бирү, салу)** Сөйләү, белдерү, җиткерү. **Хәбәр җибәрү** 1) Мәкалә язып җибәрү; 2) Хат язып салу. **Хәбәр өзелү** 1) Мәгълүмат булмау; 2) Хаты килмәү ◊ **Хәбәр тарату.** Имеш-мимеш сөйләү, ялган сүз җибәрү. Хәбәре юк 1) Хаты юк, бернинди мәгълүмат юк; 2) Эше, мөнәсәбәте, бәйләнеше юк, кайгысы юк. **Хәбәрендә (дә) юк.** Уйлап та бирми, исе дә китми. **Хәбәренә дә алму** Бөтенләй игътибар да итмәү (ТТАС, 2005: 637).

*Хәбәр* сүзе 5 өлкәдә кулланылган, аларның һәрберсенә аерым билгеләмә (мәгънәсен аңлату) бирелә, шуңа күрә биредә *хәбәр* сүзләре омонимнар, димәк, аерым сүзләр булалар.

**ОПЕРАЦИЯ** *ис.* 1) *мед. лат.* Дәвалау максаты белән тән тукымаларын һәм әгъзаларны яру, кисеп ташлау, тегү һ.б. *Сукыр эчәккә операция ясау*. 2) *хәрби* Бердәм максат белән берләшкән гаскәрләрнең сугыш хәрәкәтләре. *Хәрби десант операциясе*; 3) *махс.* Технологик процессның билгеле бер стадиясе. *Биш-алты операцияне башкару*; 4) *махс.* Сәүдә яисә финанс алыш-бирешләре. *Банк операциясе* (ТТАС, 2005: 398).

*Операция* сүзе дүрт өлкәдә дүрт төрле мәгънәдә кулланылган, алар аерым сүзләр-омонимнар саналалар. Татар терминологик системасына, иң элек, *операция* сүзенең медицинадагы мәгънәсе килеп керә, соңрак хәрби өлкәдә кулланыла, матди байлыклар җитештерү өлкәсенә, сәүдә-финанс өлкәсенә, хәтта иҗтимагый-сәяси өлкәдә дә ныклап урнашып китә.

Бер фән өлкәсеннән башкага күчкәндә, терминнның мәгънәсе-семантикасы үзгәрә, дидек. Шуңа күрә бу күренешне *яңа мәгънә алу* (*новосемантизация)* термины астында тикшерү дә татар лингвистикасында гадәти күренешкә әйләнде.

А. Зинина үзенең «Новосемантизация в системе неологизмов современного татарского языка» дигән хезмәтендә терминнарның төрле өлкәләрдә төрле мәгънәдә кулланылуын конкрет мисалларда күрсәтә. Мәсәлән, *агым* (поток) башта су хәрәкәтен атаган, соңрак кешеләр хәрәкәтен атау өчен дә (*халык агымы* – людской поток), әдәби хәрәкәтне белдерү өчен дә (*әдәби агым* – литературное течение) кулланыла башлаган. Мисал: *Ремонтта һәр кайда прогрессив*

*агым-узел методы кертелде* («Ватаным Татарстан») – В ремонте повсюду был внедрен поточно-узловой метод; *Идарә үткәргеч торбалар кору эшендә агым-комплекс алымына күчте* («Ватаным Татарстан») – Управление перешло на поточно-комплексный метод сооружения трубопровода – җөмләләрендә *агым* термины эшне оештыру методының бер күрсәткече буларак кулланыла.

Яңа мәгънә алу термины астында А. Зинина тагын түбәндәге сүзләрне ретерминлаштыру очракларын тикшерә: *сизгер* – чуткий, догадливый, *әйләнеш* – виток, *баскыч* – ступень, *йөзү* – плавать, *төшү* – приземлиться. *Удар* сүзенең термин буларак төрле өлкәләрдә активлашуын да автор конкрет мисалларда күрсәтә: *удар эш* – ударный труд, *удар хезмәт вахтасы* – ударная трудовая вахта, *удар атна* – ударная неделя, *удар ике айлык* – ударный двухмесячник, *удар хезмәт елы* – год ударного труда, *удар объекты* – ударный объект, *удар төзү отряды* – ударный строительный отряд.

Ретерминлаштыруга түбәндәге мисалларны китерергә була: 1) *автомат* – хәрби. А. Калашников автоматы, *автомат* – газланган суныкы, *автомат* – әйберләр сату өчен; 2) *агглютинация* – биологиядә, *агглютинация* – лингвистикада; 3) *ассимиляция* – биологиядә, *ассимиляция* – лингвистикада, *ассимиляция* – иҗтимагый тормышта; 4) *басым* – медицинада, *басым* – лингвистикада, *басым* – физикада; 5) *бәйләнеш* – иҗтимагый тормышта, *бәйләнеш* – лингвистикада-синтаксиста, *бәйләнеш* – юриспруденциядә, *бәйләнеш* – физикада һ.б.; 6) *билге* – лингвистикада, *билге* – физикада; 7) *тавыш* – лингвистикада, *тавыш* – музыкада; 8) *идарә* – физикада, *идарә* – иҗтимагый тормышта; 9) *итәк* – күлмәктә, *итәк* – биологиядә, *итәк* – тау буенда; 10) *дәрәҗә* – иҗтимагый тормышта, *дәрәҗә* – лингвистикада һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, җәмгыять үсеше, анда барган актив процесслар телгә дә тәэсир итә. Татар теленең лексик системасының төрле катламнары үзара кисешү процессында һәрдаим алмашу, бер-берсен тулыландыру күзәтелә. Бу хәрәкәт терминологик системага да хас, фәнни казанышларның киң җәмәгатьчелеккә тиз арада таралуы терминнарның гомумкулланылыш сүзләре рәтенә күчүенә, я булмаса, төрле тармак терминологиясенең үзара берәмлекләре алмашынуына да китерә.

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ: ЭКСПРЕССИВ-СТИЛИСТИК КАТЛАМНАР

## § 29. Тел белемендә стильләр лексикасы формалашу һәм үсешен өйрәнү тарихы

Тел белемендә стильләр турында төшенчә, стильләр лексикасының кулланылыш үзенчәлекләре антик чорлардан ук риторика һәм поэтика кебек фәннәр эчендә өйрәнелә башлый. Рус милли әдәби теленең өч стиль теориясенә М. Ломоносовның «Российская грамматика» хезмәтендә нигез салына (Ломоносов, 1952: 558–592). Ул рус теле белемендә стиль турында төшенчә, стильләргә хас лексиканы өйрәнүнең беренче омтылышларын ясый.

Октябрь инкыйлабыннан соң рус теле белемендә стиль, экспрессив-стилистик катламнарга аеру мәсьәләләре А. Пешковский, Л. Щерба, В. Виноградов, Г. Винокур, Б. Томашевский кебек галимнәр хезмәтләрендә күтәрелә. XX гасырның 50 нче елларында стиль турындагы өйрәтмәләрдә «хәрәкәттәге тел» концепциясе В. Виноградов хезмәтләрендә чагылыш таба. Ул стиль турында өйрәтмәләрнең үсешен һәм нәзари-гамәли формалашуын, стильләр лексикасының үсеш-үзгәреш мәсьәләләләрен яктыртып, *тел стиле, сөйләм стиле, матур әдәбият стиле* төшенчәләрен аерып чыгара (Виноградов, 1946: 225).

XX гасыр ахырында рус теле белемендә лексиканы югары һәм түбән стильгә нисбәтле аеру мәсьләләсе О. Ахманова (Ахманова, 1957), А. Гвоздев (Гвоздев, 1965), А. Ефимов (Ефимов, 1969), Г. Погореленко (Погореленко, 1972), Б. Головин (Головин, 1980), Т. Винокур (Винокур, 1980), М. Кожина, (Кожина, 1983), И. Резниченко (Резниченко, 1984), И. Голуб (Голуб, 1986) хезмәтләрендә күтәрелә.

Рус теле белемендә стильләр катламы стилистика, лексикология һәм сөйләм культурасы кебек фәннәр белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә В. Коньков (Коньков, 1999), В. Меликян (Меликян, 2001), А. Введенская (Введенская, 2003), Ю. Бельчиков (Бельчиков, 2005), В. Максимов (Максимов, 2005) хезмәтләрендә өйрәнелә. Шулай ук рус теле белеме буенча хезмәтләрдә текст тирәлегендә эмоциональ бәяләмә бирә торган лексика (Колясева, 2008), рус матбугатында сөйләмә лексиканың кулланылышы (Шайдорова, 2009), хәзерге рус матбугатында китап теле һәм гади сөйләм теленең тәэсире (Свиридова, 2013) өйрәнелеп, фәнни-теоретик нигезләре ассызыклана.

Төрки тел белемендә стиль, стильләр лексикасының формалашу һәм үсеше мәсьәләләре тикшерелеп килә. Азәрбайҗан телендә стильләр лексикасы Т. Әфәндиеваның «Азәрбайҗан теленең лексик стилистикасы» (Эфендиева, 1973), С. Гәфәровның «Тәэсирле азәрбайҗан теле: лексика» (Гәфәров, 2007) хезмәтләрендә җентекле өйрәнелә. Башкорт телендә «Хәзерге башкорт теле: лексикология, фразеология, лексикография» хезмәтендә лексиканың экспрессив-стилистик катламнары аерылып күрсәтелә (Әхтәмов, 2002). И. Галәветдиновның «Башкорт теле тарихы» монографиясендә әдәби телнең матур әдәбият, публицистика, гыйльми һәм техник әдәбият, шәҗәрә, рәсми эш лексикасы аерып күрсәтелә, аларның төрле чорларда өстенлек тоткан яклары күзәтелә (Галәветдинов, 2008). Кумык теленең лексик стилистикасының функциональ һәм эмоциональ-экспрессив аспектлары А. Мусалаев хезмәтендә ачыла (Мусалаев, 2005). Төрек теле белемендә Н. Демир, D. Йылмаз (Demir, Yılmaz, 2005), М. Каплан (Kaplan, 2007), З. Кормаз (Korkmaz, 2007) хезмәтләрендә стильара сүзләргә китап теле сүзләре, сөйләм теле сүзләре каршы куелып өйрәнелә. Эмоциональ-экспрессивлыкны белдерә торган чараларның лексик-семантик аспекты шулай ук якут әдәби телендә (Николаева, 2006), эмоциональ-экспрессив тәгъбирләрнең лексик-сематик үзенчәлекләре кумык теленең үтәмеш сөйләшендә (Арсланбекова, 2007) тикшерелә.

Татар теле белемендә стиль, стильләргә хас лексик берәмлекләр мәсьәләләре XIX гасырда С. Күкләшев, М. Иванов, К. Насыйри, Н. Катанов хезмәтләрендә күтәреләләр. М. Иванов лексик чараларны ничек итеп файдалануга карап, татар теленең сөйләм

теле һәм китап теле лексикасы арасындагы аерманы күрсәтеп, тел материалыннан үрнәкләр тәкъдим итә (Иванов, 1859: 3). М. Иванов «Татар хрестоматиясе»ндә сөйләм теле өлгеләренә мәкаль һәм әйтемнәрне, җырларны, әкиятләрне, рус әдәбиятыннан тәрҗемә әсәрләрен кертеп караса, китап теле өлгеләренә тарихи-әдәби характердагы көнчыгыш әдәбияты үрнәкләрен, Нәвои, Фөзули кебек шагыйрьләрнең шигырьләреннән үрнәкләр бирә. Шул рәвешле, М. Иванов халыкның сөйләм телен халык авыз иҗатына якынайта һәм аны китап теленә каршы куя.

Татар теле белемендә өч стиль теориясе, беренчеләрдән булып, Салихҗан Күкләшевнең 1859 елда басылып чыккан «Татар хрестоматиясе»ндә очрый. Ул гади, эш һәм фәнни язма сөйләм төрләрен аерып, һәрбер төргә караган лексик берәмлекләрне күрсәтә: «гади тел сөйләшү теленә якын, эш теле гади һәм гыйльми телләрнең уртасында тора, гыйльми тел гарәп телен яхшы белүчеләр өчен аңлашыла, чөнки монда гарәп теле сүзләре, гыйбарәләре, тезмәләре өстенлек итә» (Күкләшев, 1859: 3).

XIX гасыр ахырында Н. Катанов та М. Ломоносовның өч стиль теориясе нигезендә урта, югары, халык стиле катламнарын аерып чыгара һәм һәрбер стильгә хас лексик берәмлекләрне күрсәтә: югары стиль катламының – гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган тел булуын, урта һәм халыкчан стиль катламына алынмалар кулланмыйча язылган әсәрләр керүен күрсәтә (Катанов, 1898: 5).

Н. Катанов стильләрне аеруда лексик чараларга гына таянып эш итә. Шуңа күрә стильләр арасында аерма ачылып бетми кала. Н. Катанов турыдан-туры язма әдәбиятның һәм халык авыз иҗатының төрле жанрлары белән эш итсә дә, стильләрне аеруда жанр принцибын алга куймый. Урта стильгә автор К. Насыйриның «Кырык вәзир» әсәрен, Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә», «Мәҗмәгыйль-әхбар», «Кабуснамә», Г. Фәезхановның «Тутыйнамә» һ.б. әсәрләрен кертә. Әлеге стиль өчен текстлар сайлаганда халыкка аңлаешлы булган язмаларга игътибар итә. Югары стильгә халык сөйләменнән шактый ерак булган катлаулы, гарәп, фарсы, төрек сүзләре белән чуарланган текстларны алмаска тырыша. Югары стильне шул чордагы әдәби тел дип саный. Монда автор К. Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса», фарсычадан тәрҗемә ителгән «Пәнднамә», Хисаметдин бине Шәрәфетдиннең «Таварихы Болгария» кебек хезмәтләренннән үрнәкләр китерә. Халык стиленә халык-

ның җанлы сөйләменнән язылган әсәрләр керә. Халык авыз иҗаты әсәрләре тулысынча шушы сөйләм төрен тәшкил итәләр. Н. Катанов монда Г. Фәезхановның «Хикәят вә мөлкәт», «Аю белән төлке», «Ябалак белән чыпчык турында», М. Салиховның «Табышмаклар һәм һәртөрле халык арасында әйтелә торган мәкальләр» һ.б.ны кертә (Катанов, 1898: 4).

XX гасыр башында Г. Ибраһимов «Әдәбият кануннары» (1913) хезмәтендә стиль, стильләр лексикасы мәсьәләләрен күтәреп чыга. Хезмәттә әдәби әсәрдә сүз һәм сүзтезмәләрнең нинди булырга тиешлеге ассызыклана, стильнең төп шартлары итеп әдип: 1) дөрестлек; 2) сафлык; 3) ачыклык; 4) уйгынлык; 5) аһәң кебек үзенчәлекләрне атап китә. Һәр әсәрнең телендә бу биш сыйфат табылырга тиеш дип саный һәм *садә өслүб, тасвири өслүб* төрләрен күрсәтә (Ибраһимов, 1913: 55).

XX гасырның 20–30 нчы елларында татар телен гамәлгә кую, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү юнәлешендә җитди максат-бурычлар куела. Шул уңайдан бөтен төр уку йортларында татар теле укыту киң җәелеп китә. Телне камилләштерү, канцелярия эшләрен татарча алып бару, татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә вакытлы матбугат басылып чыгу, шул уңайдан халкыбызның белем дәрәҗәсен арттыру өчен методик кулланмалар, дәреслекләр, дидактик материаллар, сүзлекләр бастыру, халыкка тел өйрәтү курслары ачу, шулай ук квалификацияле укытучы кадрлар әзерләү көнүзәк мәсьәләгә әверелә. Нәкъ шушы вакытларда стиль, стильләр лексикасын ныклап өйрәнү эше башланып китә. Әлеге юнәлештә Л. Җәләйнең фәнни һәм гамәли эшчәнлеген дә билгеләп китәргә кирәк. Кулъязма хәлендә сакланган «Стилистика һәм әсәрнең композициясе» (1934), «Стилистика һәм гомуми тел белеме буенча язмалар» (1938), «Мәгариф» журналында басылган «Практик стилистика алдында торган төп бурычлар» (1935) кебек мәкаләләрендә автор әдәби тел тарихы, стиль, функциональ стильләрнең үсеше, стильләрдә кулланылган лексик берәмлекләр турында төшенчә бирә. Югарыда телгә алынган хезмәтләрдә стильләр лексикасы әдәбият һәм тел белеме фәннәре белән мөнәсәбәт-бәйләнелештә өйрәнелә.

Г. Сәгъди «Әдәбият теориясе» хезмәтендә телне иҗтимагый күренеш буларак карап, ике төрле шәкелдә бирә. Беренчесе – морзалар, руханилар, алпавытлар теле, ягъни гарәп-фарсы сүзләре,

формалары, әйләнмәләре белән чурланган телдә язылган әсәрләр; икенчесе – демократик телдә, ягъни түбән катлауга аңлаешлы телдә язылган хезмәтләр. Галим әдәби стиль халык аңлый торган телдә язуны үз эченә ала дип саный (Сәгъди, 1939: 120).

XX гасырның 50–70 нче елларында стиль, стильләр лексикасы Л. Җәләй, Х. Бәдигый, В. Хаков, Н. Хәким, Ф. Хәмидулла, В. Хангилдин, Ш. Рамазанов, М. Зәкиев хезмәтләрендә яктыртыла. Аларда, нигездә, XX гасыр башы әдәби теленең үсеше, сүз мәгънәсенең киңәюе кебек мәсьәләләр урын ала.

Татар телендә стильләр үсешен телнең лексик катламнары үсеше белән бәйләп өйрәнгән хезмәтләрдән В. Хаковның «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» монографиясе игътибарга лаек. Әлеге монографиядә әдәби тел белән стильләр тарихының тыгыз бәйләнеше исбатлана. Автор һәр стильне татар әдәби теленең тарихи үсеше яссылыгында өйрәнә (Хаков, 1963).

Татар теле белемендә лексик стилистиканы аерып, аерым бер стильләргә караган лексик берәмлекләр өйрәнелә. Алар Х. Курбатовның «Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы» хезмәтендә карала. Галим сөйләшү стиленә караган сүзләргә – диалекталь һәм гади сөйләм сүзләрен, язма тел стиленә архаизм һәм неологизмнарны кертә (Курбатов, 1971, 54). Х. Курбатов әлеге бүленешне телнең кулланыштагы, хәрәкәттәге чагын өйрәнә торган стилистика тармагы эчендә карый.

В. Хангилдин «Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре» хезмәтендә әдәби телнең стильләре үсү этапларын күрсәтеп, һәрбер стиль катламына караган лексик чараларны билгели. Галим публицистик стильнең сөйләү сүзләренең күплеген һәм шул стильгә хас иҗтимагый-сәяси, икътисади атамалар һәм кайбер профессиональ-техник сүзләр кулланылуы белән үзенчәлекле булуын искәртә. Фәнни стильгә эзләнү-тикшеренү, фикер йөртү, гомумиләштерү кебек төшенчәләрне тәгъбир иткән махсус сүзләр, фәнни терминнарны кертеп карый. Эш кәгазьләре стилен, дәүләт аппаратының рәсми эш йөртүләрен чагылдырган һәм шуңа туры килгән лексиканы үз эченә алган, шулай ук үзенә хас язылыш формаларында нык калыплашкан сөйләм, дип атый (Хангилдин, 1976, 19). XX гасыр ахырларында И. Бәширова, З. Вәлиев, В. Гарифуллин, М. Зәкиев, Г. Зәйнуллин, Х. Курбатов, Р. Мөхиярова, И. Низамов, С. Поварисов, Д. Рамазанова, Ф. Сафиуллина, Г. Саттаров,

Р. Йосыпов, А. Тимерханов, Ф. Тарханова кебек галимнәрнең хезмәтләре әнә шул юнәлештә язылалар.

Татар теленең сүзлек составында экспрессив-стилистик катламнар мәсьәләсе Ф. Сафиуллинаның «Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология» хезмәтендә күтәрелә. Галим хәзерге татар әдәби теле экспрессив-стилистик катлам төрләренә стильара сүзләрне, көнкүреш сүзләрен, китапча сүзләрне кертә (Сафиуллина, 1999: 117–133).

Р. Мөхиярова 80–90 нчы еллар татар матбугаты телен күзәтеп, шул чорга караган татар теле лексикасының төп үсеш тенденцияләрен билгели (Мөхиярова, 1999; 2009). Аның фикеренчә, сүзләрнең мәгънәсе киңәю, яңа сүзләр ясалу, кулланылыш сферасы, дәрәҗәсе (активлыгы), стиле чикләнгән сүзләрнең әдәби телне баетуы, калькалаштыру юллары нигезендә татар лексикасы үсеш кичерә.

Р. Йосыпов «Әдәп башы – тел» хезмәтендә стиль, стильләр лексикасы мәсьәләсе сөйләм культурасы мәсьәләләренә бәйләнелешле анализлана. Сөйләмнең югары дәрәҗәдә булуы өчен сүзләрнең стиль ягыннан дөрес кулланырга кирәклеген ассызыклый (Йосыпов, 2000: 212).

И. Бәширова «Татар стилистикасының теоретик нигезләре» (Бәширова, 2005) методик кулланмасында стилистика фәненең өйрәнү объекты, максаты, проблема-категорияләре, метод-ысуллары, нәзари (теоретик) һәм гамәли (практик) әһәмияте турында мәгълүмат бирә. Рәсми-эш кәгазьләре, эпистоляр-хатлар, иҗтимагый-публицистик, матур әдәбият, фәнни әдәбият, дини-дидактика стильләрен аерып, аларга асыл төшенчә бирә, һәр стильгә караган лексик чараларны билгели.

Телнең экспрессив-стилистик катлам лексикасын өйрәнү мәсьәләсенә С. Поварисов хезмәтләрендә аерым урын бирелә. Галимнең «Тел рухияте» китабында төрле лексик мәгънәле сүзләрнең стилистик кулланылышы тикшерелә. Хезмәттә гомумкулланылыштагы гади сүзләрнең стилистик вазифасы тикшерелә, тупас, иске һәм яңа сүзләр хакында этрафлы анализ ясала (Поварисов, 2008). Соңгы елларда татар теле белемендә стиль катламнарының аерым төрләренә игътибар арта. Бигрәк тә татар теленең эмоциональ-экспресив катламнары игътибар үзәгендә тора. Аерым алганда, лексиканың эмоциональ-экспрессив катламы татар проза

әсәрләрендә (Галиева, 2016) һәм инглиз теле белән чагыштырма планда (Забавнова, 2016) анализлана.

Шулай итеп, татар теле белемендә стиль, эмоциональ-стилистик берәмлекләрнең формалашу һәм үсеше тарихы XIX гасырдан ук төрле нәзари-гамәли өйрәтмәләр нигезендә барлыкка килгән. Стиль, стильләр лексикасының үсеше кеше эшчәнлегендәге төрле өлкәләренең киңәюенә, кайбер функциональ стильләрнең тармаклануына бәйләп аңлатыла.

## § 30. Татар теле лексикасын экспрессив-стилистик яктан төркемләү

Стиль (латин. *stylus* – язу коралы, язу манерасы, таякчык) сүзе, термин буларак, лингвистика, әдәбият, сәнгать, музыка өлкәләрендә төрле мәгънәләрдә кулланыла. Тел белемендә стиль – телнең дифференциаль төрләренең берсе, үзенә хас сүз байлыгы, фразеологик берәмлекләре, конструкцияләре булган, төрле тел чараларын үз эчендә туплаган, телнең башка ассистемаларыннан эмоциональ-экспрессив үзенчәлекләре белән аерылып торган тел системасы (Ахманова, 2004: 455). Билгеле булганча, кешенең гамәли эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килеп, бу эшчәнлекне чагылдыруда тотрыклы бер система булдырган функциональ стиль катламнарының гомум тел белемендә аерым вазифалары бар. Иҗтимагый тормышта бара торган эшчәнлекне алып бару өчен барлыкка килгән, гасырлар дәвамында төрле вазифалар башкарган, калыплашкан сөйләм төрләрен функциональ стиль дип атыйлар. «Функциональ стиль – тарихи формалашкан төрле тел берәмлекләренең үзара бәйләнеш-мөнәсәбәте һәм сүз сайлауның сөйләмдә гамәлгә ашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән сөйләм тибы» (Стилистический энциклопедический словарь русского языка, 2003: 581). Бүгенге тел белемендә «функциональ стильләр, башка телләрдәге кебек үк, тел структурасына, шулай ук җәмгыять һәм аң-акыл системаларына» (Бәширова, 2005: 22) һәм заманга бәйле үзгәреш-үсеш мөнәсәбәтендә каралалар. Стиль билгеле бер лексик чаралар системасы белән характерлана (Сафиуллина, Зәкиев, 1994: 83; Кадирова, 2010: 16). Лексик чаралар нигездә ике катлам – язма (китап) һәм сөйләм төрләрендә билгеләнәләр.

Язма тел чынбарлыкның бер системасы булган җәмгыятьне яшәтү өчен кирәкле күп төрле иҗтимагый эшчәнлек алып бару про-

цессында, озын гасырлар узып формалашкан, аң-акыл тарафыннан кабул ителгән, махсус калыплашкан сөйләм (Баширова, 2012: 212). Аның гасырлар буе формалашкан, махсус рәвештә калыплашкан, аерым вазифалары белән билгеләнгән рәсми, фәнни, иҗтимагый, матур әдәбият теле кебек төрләре аерыла. Әлеге стильләрнең үзләренә хас булган табигате, чынбарлык һәм аң-акыл белән бәйләнеш мөнәсәбәте, шулай ук вазифалары – үзләренә йөкләтелгән эшне башкару процессы таләп иткән төрле жанр-төрләрдә булуы билгеләнә, тел берәмлекләрнең ни рәвешле сайлап алынуы һәм авторлык мөнәсәбәтенең чагылышы күзәтелә. Язма тел дәүләт эшендәге төрле хокукый эшләрне, фәнни танып-белүне теркәүдә, әдәбият, җәмгыятьнең барышы белән бәйле эшләрне бәян итүдә кулланыла. Язма телнең бер төре саналган китап телендә эш кәгазьләре стиле, иҗтимагый-публицистик стиль, фәнни стиль, дини-дидактик стиль, матур әдәбият стиле кебек сөйләм типлары аерыла. Тел һәм сөйләм процессында фәнни стиль – фәнни-коммуникатив, хәбәр итү вазифасы; иҗтимагый-публицистик стиль – өндәү-агитацияләү; рәсми эш кәгазьләре стиле – хәбәр итү; эпистоляр-хатлар стиле – тәэсир итү һәм хәбәр итү вазифалары белән аерылалар. «Язма телдә – төрле вазифа үти торган сөйләм типлары, ягъни функциональ стиль таләбенә туры килә торган ныклы тәртип саклануы, ягъни әйтелергә тиешле фикерне барлык төбәкләрдә яшәүче укучыларга төгәл итеп җиткерү, һәр стильнең һәм аның жанр төрләренең үзләренә хас булган төзелеш-структурасын, тәгъбирләү тәртибен катгый саклау, мөнәсәбәт белдерелү-белдерелмәүнең чамасын белү, орфографиянең әдәби дөрес булуын һәм даим аңлы рәвештә истә тоту таләп ителә» (Бәширова, 2012: 13). Һәр функциональ стиль структур яктан оешкан һәм системалы бөтен булудан тыш, билгеле бер вакыт аралыгында барлыкка килгән, расланган һәм шомартылган лексик чаралар белән билгеләнә. Билгеле булганча, сөйләмнең язма һәм сөйләм формаларына хас фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләре бар. Әлеге аермаларны телнең язма һәм сөйләм төрләренең икесендә дә бердәй хезмәт итә торган, барлык стильләр өчен дә уртак саналган стильара сүзләр тәшкил итә. Шулар фонында стилистик бизәкләргә ия сүзләрнең, сөйләм чараларының саны һәм сыйфаты ачыклана. Әлеге лексик чаралар һәр стильгә функциональ яктан беркетеләләр. Стильләрнең төрле катламнарын тәшкил иткән тел чаралары җыелмасы (лексик, морфологик, синтаксик, шулай ук

фонетик чаралар) система бөтенлеген тәэмин итә. Система бөтенлеге функциональ стильләрне оештырганда барлыкка килгән тел чараларының билгеле бер стильдә ныгуы нигезендә формалаша, шул рәвешле үзләренә мөстәкыйльлек булдыралар. Стиль катламнарын тәшкил итүче тел чараларының үзара бәйләнеше функциональ стильләрнең системалы-структур бәйләнешен барлыкка китерә. Лексик чараларның системалы бөтенлеге функциональ стильләрне аеру критерийларының берсе булып тора. Шул рәвешле, һәр стиль үз лексик берәмлекләреннән торган бербөтен формалаштыра, ягъни һәр стильнең үзенә генә хас лексик берәмлекләре барлыкка килә. Билгеле бер стильгә караган лексик чараларның икенче бер стильдә кулланылышы стилистик норма белән билгеләнә. Әлеге лексик чаралар стильләргә функциональ яктан беркетеләләр. Телдә бер стиль катламына караган лексик чараларның икенче стиль катламына керә алу мөмкинлеге чикле түгел (Сафиуллина, Зәкиев, 1994: 83). Мәсәлән, иҗтимагый-сәяси лексика рәсми эш кәгазьләре стилендә дә, фәнни һәм иҗтимагый-публицистик стильләрдә дә билгеләнә. Рәсми эш кәгазьләре стилендә иҗтимагый-сәяси лексика түбәндәгечә кулланыла: *Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты* ***Татарстан Республикасы законнары*** *рәвешендә әзерләнә һәм раслана,* ***җирле бюджетлар муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары*** *рәвешендә әзерләнә һәм раслана.* (Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, ТР Законнары). Сәяси темаларга кагылышлы газета-журнал мәкаләләрендә иҗтимагый-сәяси лексика шулай ук аерым лексик катлам барлыкка китерә: *18 сентябрьдә РФ ФҖның VII чакырылыш* ***Дәүләт Думасына депутатлар сайлауларда бер мандатлы округларда*** *җиңгән кандидатлар исемлеге мәгълүм* («Ватаным Татарстан»). Фәнни стильдә иҗтимагый-сәяси лексика социология, политологиягә караган өлкәләрдә еш кулланыла: ***Россия һәм Татарстан дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләр чикләрен бүлешү турындагы Шартнамәгә*** *кул кую үзәкнең безнең карашыбыз хаклыгын тану булды* («Фәнни Татарстан»). «Стилистик норма – стилистик мөмкинлекләрнең тарихи формалашкан һәм тел үсешендә кабул ителгән чаралар, кануннар системасы ул» (Стилистический энциклопедический словарь русского языка, 2005: 433).

Фәнни стильдә сүз мәгънәсенең төгәл, катгый бер кысаларга керүе таләп ителә, сүзләр нигездә туры мәгънәләрендә кулланылалар, сурәтләү чаралары, метафорик сүзләр, гиперболалар, эпитетлар очрамый, сөйләм махсус терминнар белән сугарылган була. Мәсәлән: ***Биотехнология молекуляр биология*** *һәм* ***генетика, микробиология һәм биохимия, физиология һәм цитологиянең*** *теоретик нигезләренә таяна һәм аны фән һәм техниканың катнаш өлкәсе дип карарга була* («Фәнни Татарстан»). Молекуляр биологиянең актуаль мәсьәләләрен яктырткан мәкаләдән китергән өзектә барлык сүзләр дә туры мәгънәдә кулланылганнар, образлы, метафорик сүзләр күзәтелми.

Матур әдәбият лексикасында сүз мәгънәсенең яңарып торуын, образлылыгын, хис-тойгыларны куерту, тәэсирлелекне арттыру максатында төрле лексик чаралар кулланылалар. Матур әдәбият телендә әдәби норма яки норма булмаган чараларга да – диалектизмга, гади сөйләм сүзләре, җаргоннарга да мөрәҗәгать ителә. Мәсәлән, матур әдәбият теле лексикасының функциональ-стилистик йөкләмәсе сүзләрнең семантик мәгънәләре киңәюе, яңа сүзләр яки окказиональ сүзләрнең барлыкка килүе, сүзнең комбинатор-структур мөмкинлекләрен файдаланып, яңа сүзләр иҗат ителүе, диалекталь сүзләрне куллану, гади сөйләм лексикасына мөрәҗәгать итү, тарихи сүзләр, архаизмнарны билгеле бер максат белән әсәр тукымасына кертеп җибәрү, экзотизмнар, парлы сүзләрне кулланудан гыйбарәт.

Шулай итеп, татар телендә һәр функциональ стиль структур яктан оешкан һәм системалы бөтен булудан тыш, билгеле бер вакыт аралыгында барлыкка килгән, расланган һәм шомартылган лексик чаралар белән дә билгеләнә. Телнең тарихи үсеше процессында әдәби тел вазифаларының киңәюе, кеше эшчәнлегенең яңа төр өлкәләрендә яисә коммуникатив процессларында файдаланылган әдәби тел чараларының һәм сөйләшүченең төрле иҗтимагый рольләренең үсеше стильләр, стильләр лексикасының формалашуына китерә.

Сөйләм ул – аерым бер шәхеснең конкрет максат (ният) тәэсирендә туган фикеренең икенче бер шәхескә юнәлтелеп, конкрет урынга, вакытка һәм башка шартларга бәйле рәвештә, нигездә тел ярдәмендә (шул ук вакытта телдән бүтән чараларны да кулланып) оешуы һәм теге яки бу реаль формага кереп адресатка җиткерү һәм

кабул итү системасы (Низамов, 2008: 10). Кешеләрнең үзара көндәлек тормышында көнкүреш аралашу вазифасын үтәгән сөйләм телендә тел берәмлекләрен куллануда, нигездә, әдәби норма ятса да, җирле урынчылыкка хас, сөйләүченең чынбарлыкка карата эмоциональ-экспрессив мөнәсәбәтен белдергән сүзләрнең кулланылышы да күзәтелә һәм әлеге лексик катламнар сөйләм теленең төп үзенчәлеген билгелиләр. Сөйләм теленә караган сүзләргә гадилек һәм әдәби телдән читләшү төсмере дә хас. Әйтик, гади сөйләм сүзләре сөйләм теленә карыйлар, сөйләмгә эмоциональ-экспрессивлык төсмерләре өстиләр, әдәби тел нормасының чигендә торып, кискен һәм төксе әйтелү белән аерылалар, әдәби телне баетуда чыганак булып торалар: *Ни өчендер үз тиңнәре белән дуслашмыйча безнең ише* ***ыбыр-чыбыр*** *белән мавыгырга яратуын авыл хатыннары өнәп бетермиләр иде* (Ф. Шәфигуллин). Әлеге өзектә ыбыр-чыбыр – бала-чага, кече яшьтәге балаларны белдерә торган сүз (ТТАС, 2005: 696). *Мыдырдау, шылу, пырлау, дөмбәсләү, түпәләү* кебек гади сөйләм сүзләре көндәлек тормышта кулланылып, сөйләмгә эмоциональ-экспeрссивлык төсмерләре өстиләр һәм татар теле лексикасын тулыландыруда әһәмиятле чыганак булып торалар: *Мин үлемнән курыкмыйм дип, кукыраеп киткән иде. Стало быть,* ***кәкерәйткәннәр*** (К. Нәҗми).

Татар теленең өч томлы аңлатмалы сүзлегендә сүз кулланылышының хәзерге нормаларына нигезләнеп, сүзләргә стилистик характеристика бирелә, аларның кулланылыш чикләре, эмоциональ төсмерләре күрсәтелә. Мәсәлән, *кит.* (китап теле сүзе), *диал*. (диалекталь сүз), *күч*. (күчерелмә мәгънәдә), *мыск*. (мыскыллап әйтү) һ.б. билгеләр белән сүзләрнең кулланылыш чикләре күрсәтелә (ТТАС, 1977: 476). «Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә» (ТТАС, 2005) сүзләрнең стилистик характерын ачуда *кит.* билге, нигездә, язуда гына, китап стилендә генә кулланыла дигәнне белдерә; мондый сүзләр еш кына чит телдән алынган була; *сөйл.:* бу билге – сүз гадәттә сөйләм стилендә, һәртөрле тормыш-көнкүреш мөнәсәбәтләрендә кулланыла дигәнне аңлата, әмма бу сүзләр әдәби тел чикләреннән чыкмыйлар; *рәсм.:* бу билге – сүз рәсми мөнәсәбәтләргә, канцелярия стиленә хас дигәнне аңлата; *гади с.:* бу билге – сүз гади халык сөйләменә хас дигәнне белдерә, сөйләмгә шаяру, ирония, тупаслык һ.б. шундый төсмерләр өсти. Еш кына, бу сүзләр нейтраль стильгә караган сүзләрнең экспрессив

синонимнары булып торалар, дигән искәртүләр кертелә. Бу карашка нигезләнү сүзлекләрдә мәгънә дифференциациясен тагы да тулырак чагылдыра, бер стиль катламына кергән сүзнең икенче стиль катламында билгеләнә алу мөмкинлеген чикләми.

Димәк, татар теле лексикасы экспрессив-стилистик яктан сөйләм теле һәм язма телдә билгеләнгән лексик чаралар нигезендә төркемләнә. Язма телдә рәсми лексика, иҗтимагый-публицистик лексика, фәнни лексика, матур әдәбият лексикасы билгеләнсә, сөйләм теле сүзләренә гомумкулланылыш сүзләре, диалекталь бизәкле сүзләр, гади сөйләм сүзләре карый.

## § 31. Татар телендә эмоциональ-экспрессивлыкны белдерүче чаралар

Экспрессив-стилистик лексиканың төп берәмлекләре – эмотив һәм экспрессив. Аларның беренчесе телдә эмотив функцияне, икенчесе  экспрессив функцияне үти. Әлеге функцияләр арасындагы аерымлык эмоциянең сурәтләү теле һәм чагылдыру теле була алуына бәйле.

Телдәге эмотив функция эмоцияне сурәтләүгә бәйле. Эмотивлык дип, кешеләргә тәэсир итүне максат итеп куймыйча, субъектның үз хис-кичерешләрен, халәтен белдерү процессын һәм нәтиҗәсен атыйлар, әлеге процесс эмотив функция дип атала. Мәсәлән: *Менә тагын яу көтә безне, Прокопий туганкаем. Тагын күпме ана улын югалтачак, күпме сабый ятим калачак. Син әйтмешли, ул* ***Ходай каргаган Киев тәхете*** *өчен кан коюлар кайчан тукталыр? Ата – улына, энесе абыйсына каршы кылыч күтәреп, бертуктамый гомер кыя торган, акылларын көя кискән нинди халык соң без?* (В. Имамов). Әлеге мисалда сөйләүче сугышның ахыры хәерле булмавын әйтә – *Тагын күпме ана улын югалтачак, күпме сабый ятим калачак*, ди. Әлеге мисалда икенче субъектның – реципиентның булганы аңлашылса да (*тагын яу көтә безне, Прокопий туганкаем*), сөйләүченең максаты үзенең моң-зарын, сугышка риза булмавын һәм сугышның икесе өчен дә билгеле булган нәтиҗәсен белдерү. Адресант *Ходай каргаган Киев тәхете* дип шәһәргә бәяләмәне үзенең тискәре эмоциясен чыгару өчен әйтә, әлеге сүтезмә адресатны гаҗәпләндерү өчен әйтелмәгән. Шуңа күрә әлеге мисалда *Ходай каргаган Киев тәхете* сүтезмәсе эмотив функцияне белдерә һәм эмотив берәмлек булып килә.

Экспрессивлык дип эмоцияне дөньяга белдерү процессын һәм аның нәтиҗәсен атыйлар. Экспрессив функциясен тәэсир итү функциясе дип атасак та хата булмас, чөнки әлеге функция аша хис-кичереш сөйләүченең үзенә, реципиентка һәм укучыга юнәлтелгән була. Мәсәлән: *Мондагы торгакларны җир йотканмы әллә, **эт еккыры**! Ачыгыз капканы, тизрәк ачыгыз, дим!* (В. Имамов). Әлеге мисалда кулланылган *эт еккыры,* сүзтезмәсе экспрессив, чөнки ул реципиентка тәэсир итү максаты белән әйтелә һәм адресантның тискәре эмоцияләре эксплицит, ачык рәвештә белдерелә.

Татар телендә эмоциональлек семантик, лексик, сүз ясалышы һәм грамматик чаралар ярдәмендә белдерелә.

Эмоциональлекнең барлыкка килүе өчен җаваплы булган аномалия күренеше сүзнең семантик һәм лексик катламында семантик күчеш, градуальлек, нормадан чигенү һәм капма-каршылык формасында реальләшә.

Аномалиянең әлеге формалары сүзнең семантик катламында коннотация семасы һәм аны тәшкил иткән микрокомпонентлары аша чагылыш таба. Әлеге микрокомпонентлар – сурәтлелек, бәяләү, интенсивлык һәм эмоциональлек. Бу микрокомпонентларның төрле комбинациясе нәтиҗәсендә эмоциональлек телдә ике формада – эмотивлык һәм экспрессивлык формасында чагылыш таба. Бәяләү, сурәтлелек һәм эмоциональлек компонентларының бергә кулланылуы – эмотивлыкны, интенсивлык, сурәтлелек һәм эмоциональлекнең бергә кулланылуы телдә экспрессивлык күренешен барлыкка китерә. В. Шаховский билгеләвенчә, экспрессивлык – көчлерәк/йомшаграк оппозициясе, эмоциональлек яхшы/начар оппозициясе белән билгеләнә (Шаховский, 1975: 17). Шуңа күрә экспрессивта интенсивлык, эмотив структурасында сурәтлелек компоненты өстенлек итә. Коннотациянең кайсы компоненты өстенлек иткәнен билгеләү когниция дәрәҗәсендә башкарыла. Мәсәлән: *Йә, йә, кыланма, **карт төлке!*** (Ф. Садриев) мисалында *карт төлке* метафорасының семантик структурасын сурәтлелек, бәяләү һәм эмоциональлек микрокомпонентлары тәшкил итә. Сурәтлелек микрокомпоненты кешене төлке белән чагыштырганда, бәяләү микрокомпоненты әлеге образны «яхшы образмы бу, яисә начар образмы» дигән ноктадан бәяли, һәм эмоциональлек микрокомпоненты әлеге бәяләмәгә кешенең реакциясе нәтиҗәсендә оеша. Шулай итеп, метафораның коннотациясен өч микроком-

понент оештыра, ләкин бәяләү микрокомпоненты өстенлек итә: метафора семантик күчеш нәтиҗәсендә барлыкка килә һәм субъект әлеге метафорага бәйле хис-кичереш кичергәнче үк, үзе өчен нинди эмоция кичерергә кирәк икәнлеген билгели, семантик күчешнең уңышлы яисә уңышсыз булуын бәяли. Шулай итеп, *карт төлке* метафорасы телдә тискәре эмоциональлекне белдереп килгән эмотив булып килә.

Экспрессивлыкта доминанта булып килгән интенсивлык микрокомпоненты нормадан авышу сәбәпле барлыкка килә һәм бу аның динамикасын билгели. Телдә динамика градуальлек белән билгеләнә. Мәсәлән: *Төннәрен йокы качканда тән сызлавы белән бергә килгән мондый авыр хатирәләр* ***күңелне бигрәк нык изә*** (М. Маликова). Әлеге мисалда кулланылган *күңелне изәргә* метафорасының градуальлеге түбәндәге баскычлардан оеша: *күңелне изәргә, күңелне нык изәргә, күңелне бик нык изәргә* һәм мисалда күрсәтелгән градуальлекнең иң югары дәрәҗәсе *күңелне бигрәк нык изәргә* формасында бирелгән. Шулай итеп, *күңелне изәргә* метафорасы экспрессив булып килә.

Эмоциональлекнең эмотив яисә экспрессив формасында реальләшүе, компонентлардан тыш, сөйләмнең нинди формада бирелүеннән дә тора. Диалогта гадәттә эмоциональлек экспрессив формасында, монологта – эмотив формасында реальләшә. Мәсәлән: *Син картлач та хатын турында сөйләгән буласың бит,* ***телеңне корт чаккыры****!* (В. Имамов). *Каргана, әпәй белән ант итә,* ***мур кыргыры*** *нәстә* (Т. Галиуллин). Әлеге мисаллардагы вульгаризмнар (*телеңне корт чаккыры, мур кыргыры*) диалогта кулланыла һәм экспрессив булып килә. *Табылган бер тәкъва! Шуның тәкъвалыгы белән юанып,* ***эт куышында*** *яшә менә!* (М. Маликова) мисалында *эт* зоонимы эмотив булып килә. Әмма әлеге зооним диалогта экспрессив берәмлек буларак кулланылырга мөмкин. Мәсәлән: ***Азгын ана эт!*** *Синең белән* ***өстерәлгән*** *көчекләр кулы бу* (Н. Гыйматдинова). Әлеге мисалда *эт* зоонимы диалогта кулланыла һәм экспрессив булып килә.

Метафора һәм метонимиядә эмоциональлек семантик күчеш аркасында барлыкка килә. Мәсәлән: *Шуңа күрә* ***тәмле телеңне, якты йөзеңне*** *кызганма, – диде* (Ф. Садриев). *Гайшәбикә, чабышта беренчелекне алган бия төсле башын югары тотып, җилфер-җилфер чыгып китүгә, кибет эчендә әлегәчә качып-посып*

*торган Вәлинең* ***нурсыз йөзе*** *пәйда булды* (Т. Галиуллин). Мисалларда кулланылган *тәмле тел, якты йөз, нурсыз йөз* метафоралары эмоциональлек белдерәләр һәм эмотив булып киләләр. Семантика дәрәҗәсендә эмоциональлек нормадан чигенү нәтиҗәсендә барлыкка килә ала. Мәсәлән: *Сабыр күперенә кадәр ишетелеп торды унбиш яшьлек абзыйсының* ***йөрәк ертып елаган тавышы*** (А. Хәлим). Әлеге мисалдагы *йөрәк ертып елаган тавыш* метафорасы эмоциональлекне белдерә һәм экспрессив булып килә. Семантика дәрәҗәсендә градуальлек тә эмоциональлекне тудыра. Мәсәлән: *Ярый, Шәвәлиевкә кәнәфиен сакларга кирәк. Ул* ***ялагайлансын да, алдашсын да, этләшсен дә***. Әлеге мисалда мәгънәләре ягыннан охшаш *ялагайланырга, алдашырга, этләшергә* лексемаларының бергә кулланылып килүләре градуальлек тудыра һәм ул синонимик рәт хасил итә. Монда *ялагайланырга, алдашырга, этләшергә* лексемалары эмоциональлекне белдерә һәм экспрессив булып киләләр.

Эмоциональлекнең тууына тәэсир иткән чираттагы фактор – бу капма-каршылык. Татар телендә капма-каршылык төрле гадәттән тыш сәбәпләр аркасында барлыкка килергә мөмкин һәм сүзләрнең капма-каршы мәгънәдә кулланылулары контекстта ачыла. Семантик дәрәҗәдә капма-каршылык оксюморонда ачык чагылыш тапкан. Мәсәлән: *Эт кенә түгел иде болар. Муса бабасы әйтмешли,* ***җәһәннәм сандугачлары*** (А. Хәлим). *Әнкәсе яңа туган бәрәнне пәлтә изүенә тыгып, теге ярдан басмага атлыйм дигәндә, янә бер* ***үлеп терелде*** (А. Әхмәтгалиева). Әлеге автор метафорасында татар теленең үзенчәлеген билгели торган һәм капма-каршы булган ике төшенчә – *җәһәннәм* һәм *сандугач* төшенчәләре кулланылган. *Җәһәннәм* татар халкының дини күзаллавын чагылдыра, ул тискәре эмоциональлекне белдереп килә. *Сандугач* – татар фольклорында матурлык, нәфислек, нәзакәтлелек билгесе булып тора һәм уңай эмоциональлекне тудыра. Икенче мисалда бер-берсенә каршы булган *үлү* һәм *терелү* сүзләре кулланылган. Шулай итеп, капма-каршылык нәтиҗәсендә эмоциональлекне белдереп килгән үзенчәлекле тел берәмлекләре туа.

Эмоциональлекне белдергән лексик чараларга фразеологизмнар керә: *җиде кат сират күперен үтәргә; әдәпле кыз сәдәпле; ашау – байдан, үлем – Ходайдан* һ.б. Мәсәлән: *Хуш килдең мәмләкәтебезгә, Андрей кенәз. Безнең халыкта канатлы бер сүз бар:* ***«Алты яшьлек читтән кайтса, алтмыш яшьлек күрә килер»***, –

*ди* (В. Имамов). Идиоманың эмоциональлеге капма-каршылык белән белдерелгән интенсивлык микрокомпоненты аша бирелә. Әлеге мисалда өлкән һәм яшь буын капма-каршы куела, өлкән буынның сәфәрдән кайткан яшь буынга күрсәткән ихтирамы *алты яшьлек – алтмыш яшьлек* сүзтезмәсе аша белдерелә. *Асылгәрәй хәзрәтнең Коръәнне яттан белгән* ***су сөлеге кебек*** *сылу кызы Гайшәбикәне дә, кулларын богаулап, Магнитка төрмәсенә озаттылар* (Ф. Бәйрәмова). Әлеге мисалда эмоциональлекне *сөлек* төшенчәсе тудыра. *Сөлек* ул – коннотатив дәрәҗәдә матурлык һәм камиллек билгесе, аны ир һәм кыз балага карата бер дәрәҗәдә актив кулланып була. Сөлек – татар халкына гына хас, кабатланмас матур һәм татар халкының милли үзаңын чагылдырган эмоциональ берәмлек.

Эмоциональлекне белдергән лексик чаралар кысаларында территориаль диалектизмнарны (*чәкәләшү, көрмәкләнү, чос, ору, комарлану, мунисләнү, чәүчәкләнү, апаем* һ.б.) һәм иҗтимагый диалектизмнарны карыйбыз (*шпана, ментовка, нема, вышибала*, *козырь тузы, пайга алырга, смертник, общага, понт, в натуре* һ.б.). Мәсәлән: *Гомере буе терлек-туар тотып картайган кеше өчен мал асрау, файда өмет итүдән бигрәк, яшәү рәвешенә дә әйләнәдер инде. Шуның белән* ***мунисләнгән*** *бит ул* (М. Кәбиров). Әлеге мисалда кулланылган *мунисләнгән* диалектизмы *эшкә җитди караучан, эшкә бирелгән, эшчән* (ТТЗДС, 2009: 487) дигәнне аңлата һәм уңай эмоциональлекне белдергән эмотив булып килә. *Менә монысы минем* ***прокол****, командир, оныткanмын* (З. Хөснияр). Әлеге мисалда кулланылган *прокол* социолекты кешенең үз гаебен таныганлыгын белдерә һәм уңай эмоциональлекне белдергән экспрессив булып килә.

Татар телендә эмоциональлекне сөйләм теле сүзләре дә белдерә. Алар көнкүреш сүзләре (*хөрәсән, башсыз* һ.б.), гади сөйләм сүзләре (*тыкшынырга, тыркылдарга, сабакы, тилебәдәр, ышкынырга, сөйрәлергә, ычкынырга* һ.б.). Мәсәлән: ***Чукындырам****, барыгызны да утыртам!* (З. Хәким). Әлеге мисалда *чукынырга* дигән гади сөйләм сүзе кулланылган һәм ул кешенең канәгатьсезлеген, ачуының нык дәрәҗәгә җитүен аңлата. Әйтергә кирәк, әлеге гади сөйләм лексемасының килеп чыгышы Явыз Иван чукындырулары белән бәйле. Бүгенге көндә әлеге сүз семантик көчеш кичергән һәм субъектның тискәре эмоцияләрен белдергәндә кулланыла.

Телдә эмоциональлекне ымлыклар да белдереп килә. Татар телендәге ымлыклар мәдәният, дин һ.б.ш. кебек экстралингвистик факторлар тәэсирендә оешкан. Алар татар халкының үзенчәлекле фикерләү рәвешен чагылдыра һәм аларны башка телләргә тулаем рәвештә, ягъни эмоциональлек факторын истә тотып тәрҗемә итүе дә кыен. Ымлыкларның денотатив мәгънәсе гадәттә икенчел, ә коннотатив мәгънәләре – беренчел булып килә. Шуңа күрә аларның эмоциональлекне белдерү потенциалы зур була. Эмоциональлекне түбәндәге ымлыклар белдерә: *валлаһи, билләһи, тәүбә, йа Раббым, әстәгъфирулла, Алла сакласын, бәрәч-пәрәмәч, менәтерәк, галәмәт, каһәр суккан нәрсә, харап булган икән, шайтан алгыры, ачуым килмәгәе, рәхмәт төшкере* һ.б. Мәсәлән: *Илле елдан артык көттем бит үзеңне, **рәхмәт төшкере*** (А. Әхмәтгалиева). Мисалда кулланылган *рәхмәт төшкере* ымлыгы уңай эмоциональлекне белдерә. Бер төрле ымлык телдә төрле эмоцияләрне белдерү өчен кулланылырга мөмкин. Мәсәлән: ***Шайтан алгыры!*** *Бу юлы чынлап та үзе буталган шул! Карале, малай* (М. Кәбиров). *Юк, бетми шул, бетми, **шайтан алгыры*** (Ә. Баянов). Беренче мисалда *шайтан алгыры* ымлыгы Фатыйма әбинең сөенеченнән туган гаҗәпләнүен – уңай эмоциональлекне, икенче мисалда өметсезлекне – тискәре эмоциональлекне белдерә.

Сүз ясагыч кушымчалар шулай ук эмоциональлекне белдерә ала. Мәсәлән: Бу *вакытта инде СССР таркалуга да өч ел вакыт үткән, яңа җәмгыять – **җинаятьчеләр, алдакчылар, ришвәтчеләр, эчкечеләр, наркоманнар, уйнашчылар** җәмгыяте туып килә иде* (Х. Ширмән). Әлеге мисалда кулланылган исем ясагыч *-чы/-че* кушымчасы исемнәргә ялганып килә һәм окказиональ синонимик рәтне хасил итә. Сүз ясагыч *-чы/-че* кушымчасы әлеге мисалда, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне белдергән сүзләргә ялганып, кешегә карата кулланыла, «профессия» мәгънәсен тудыра. Әлеге «профессия» ияләре – *җинаятьчеләр, алдакчылар, ришвәтчеләр, эчкечеләр, наркоманнар, уйнашчылар* шулай ук тискәре бәяләмәгә дучар, шуңа күрә әлеге мисалда сүз ясагыч кушымчасы тискәре эмоциональлекне белдерә.

Эмоциональлекне шулай ук исем ясагыч *-чык/-чек,* фигыль ясагыч *-ла/-лә, -лан/-лән, -лаш/-ләш, –ылда/-елдә, -да/-дә (-та/-тә);* сыйфат ясагыч *лы/-ле, -сыз/-сез*, *-чыл/-чел, -чык/-чек;* рәвеш ясагыч *-ча/-чә, -дай/-дәй* кушымчалары белдерә. Мәсәлән: *Комен-*

*дантның йөзе* ***шәмәхәләнеп*** *чыкты* (Ф. Бәйрәмова). Бу мисалда фигыль ясагыч *-лан/-лән* кушымчасы төсне атаган исемгә ялганып килә һәм кешенең хис-кичерешләренең йөзендә чагылуын билгели. Әлеге очракта *-лан/-лән* кушымчасы тискәре эмоциональлекне белдерә. *Юк!* ***Җылы җанлы, чиста күңелле, көчле*** *һәм якты мәхәббәт иясе генә сөю хакына  шулкадәр алтыннан баш тартыр!* (З. Хәким). Мисалда кулланылган сыйфат ясагыч *-лы/-ле* кушымчасы уңай эмоциональлекне белдерә. Аңа, гадәттә, *-сыз/-сез* кушымчасына каршы куела: ***Бәхетсез, шатлыксыз*** *бай тормыш кичерде ул* (Ә. Моталлапов). Әлеге мисалларда *-сыз/-сез* кушымчасы тискәре эмоциональлекне белдерә. Рәвеш ясагыч *-ча/-чә* кушымчасы нигез белән белдерелгән мәгънәгә бәйле һәм гамәлнең башкарылу рәвешен белдерә: *Әйдә инде, улым, исәнләш* ***егетләрчә*** *итеп, диде Мэлс* (Ф. Садриев). Мисалда *-ча/-чә* кушымчасы егетләр сүзенә ялганып килә, гамәлнең әйбәт итеп башкарылуын белдерә һәм уңай эмоциональлек тудыра.

Грамматик чаралардан исем сүз төркеменең сан категориясе, тартым категориясе эмоциональлекне белдерә ала. Мәсәлән: *Ул бер нәрсәне яхшы белә: андый әсәр тудыру өчен яңа* ***фикерләр,*** *кайнар* ***тойгылар****, зур рухи* ***омтылышлар*** *кирәк* (Ф. Садриев). Әлеге мисалда эмоциональ нейтраль булган *фикер, тойгы, омтылыш* сүзләре, күплек санда кулланылып, кешенең хис-кичерешләргә бирелгәнлеген билгели һәм әлеге контекстта уңай эмоциональлек тудыра. Тартым категориясе, гадәттә, тискәре мәгънәдә кулланылган исем ялганып килеп, уңай эмоциональлек белдерергә мөмкин. Мәсәлән: *Беләм мин үземнең* ***хәчтерүшемне****. Ирләр ялганлый беләмени* (Т. Галиуллин). Әлеге мисалдагы *хәчтерүш* сүзе гадәттә тискәре мәгънәдә кулланыла, ләкин *-ым/-ем/-м* тартым кушымчасы аңа уңай төсмер бирә һәм әлеге сүз уңай эмоциональлек белдерә.

Фигыль сүз төркеменең грамматик категориясе дә эмоциональлек белдерә ала. Бу – фигыльнең кайтым (*шашу-шашыну, агару-агарыну* һ. б.), йөкләтү (*көрәшү-көрәштерү, көлдерү-көлдертү* һ.б.), уртаклык (*гөжелдәү-гөжелдәшү, мырылдау-мырылдашу*) юнәлешләре һәм боеру категориясе. Мәсәлән: ***Ычкын*** *моннан яхшы чакта!* (З. Хәким). ***Китчәле****, Шәмсурттәй, син дә сөйләп торма инде* (А. Әхмәтгалиева). Әлеге мисалда күрсәтелгән катгый һәм йомшак боеру формалары адресатның сөйләм вакытында

туган эмоцияләрен белдерә, беренче мисалда – тискәре, икенче мисалда – уңай эмоциональлек формалаштыра.

Сыйфат сүз төркеменең дәрәҗәләре дә эмоциональлекне белдерергә сәләтле: *Уятсаң ачуын, ул **икеләтә чибәррәк** күренәчәк, каршы килгән шоферларның күзен чагылдырмыйк* (М. Галиев). Мисалда сыйфат *-рак/-рәк* кушымчалары ярдәмендә чагыштыру дәрәҗәсен белдерә һәм уңай эмоциональлекне белдерә.

Рәвеш сүз төркеменең грамматик күрсәткечләре дә эмоциональлекне белдереп килә ала. Мәсәлән: *Гөлсинә керфек төпләренә яшь бәреп чыкканчы рәхәтләнеп көлде, Мансур каш астыннан гына елмаеп утырды, Ибраһим исә, хатынының хикәятен **бөтенләй** ишетмәгәндәй, **бик** бирелеп, тавык боты кимерде* (А. Әхмәтгалиева). Мисалда кулланылган *бөтенләй* һәм *бик* рәвешләре субъектның теге яисә бу эшне гадәти итеп үтәмәвен белдерә һәм эмоциональлекне чагылдырып килә. Эмоциональлекне чама һәм дәрәҗәне белдереп килгән *шактый*, *искиткеч*, *бөтенләй* һәм максат яки сәбәпне белдереп килгән *юри*, *юкка, бушка, әрәмгә, тиккә, заяга, тикмәгә, тиктомалга* рәвешләре дә белдереп килә.

Әлбәттә, эмоциональлек һәм экспрессивлыкны белдерүдә стилистик *-чык/-чек, -кай/-кәй, -кәш* кебек кушымчаларның роле зур. Алар, нигездә, уңай эмоцияләр тудыру максатыннан ярату, иркәләү хисләрен белдерү өчен кулланылалар: *Күңел **күзкәйләремне** ачтың, Ходаем, инде моннан соң рәхмәтеңнән ташлама* (А. Әхмәтгалиева). *Нишләп минем күземә чалынмый икән **пәри җанкисәккәйләр**? Кысып-кысып кочаклар идем.* (Н. Гыйматдинова). ***Улыкаем минем**!... **Балакаем**!.. ...Менә бит син кайттың, **бердәнберем минем**...*; *И-и, **бәбкәччәем**! Ничек матур йоклый бит, сабый...* (Г. Гыйльманов). *Бик арыган бугай, **бәләкәчем*** (М. Кәбиров).

Эмоциональлекне белдерүдә кисәкчәләр (*-сана/-сәнә, -мы/-ме, -мыни/-мени, гына-/генә* һ.б.) актив катнаша. Мәсәлән, *Байлык өчен, кием-салым, акча, мал өчен кешеләр бер-берсен **үтермиләрмени**?* (З. Хәким) Әлеге сорау җөмләдә эмоциональлек сорау кисәкчәсе *-мыни/-мени* сорау интонациясе һәм сорауның риторик булуы белән белдерелә. *Ләкин сүзләрдә **генәмени** хикмәт?!* (М. Маликова) мисалында *-мени* сорау кисәкчәсе үкенү, сагыну хисләрен белдерү өчен кулланыла.

Шулай итеп, татар телендә эмоциональ-экспрессивлыкны белдерүдә телнең барлык катламына караган чаралар да катнаша ала.

Аларның бер өлеше сөйләм ситуациясенә бәйле аерым очракларда үзләренең төп вазифаларына өстәмә рәвештә белдерелсәләр, бер төркеме исә турыдан-туры эмоциональлек һәм экспрессивлык белдерү өчен телдә диами кулланылалар.

## § 32. Стильара лексика

Әдәби телнең китап теле лексикасы белән сөйләм теле лексикасы арасында әдәби телнең бөтен функциональ сөйләм төрләрендә дә очрый торган стильара сүзләр бар. Алар аерым гына торганда, үзләренең туры мәгънәләрендә бернинди функциональ сөйләм төрен күз алдына китермиләр, нинди дә булса әйбернең атамасы яки билгесе рәвешендә генә аңлашылалар (Курбатов, 2002: 69). Стильара сүзләр барлык стильләр өчен дә уртак саналып, эмоциональ-экспрессив төсмерләрдән азат, термин булып килмәгән предметларны, көндәлек тормышны, табигать күренешләрен, кеше тормышын һәм аның эшчәнлеген чагылдыралар. Тел белемендә аларны стилистик яктан нейтраль сүзләр дип атау да таралыш тапкан.

Стильара сүзләр исәпләү ноктасының башлангычы дип санала, әлеге исәпләү ноктасыннан чыгып, әдәби телдә китап теле лексикасы һәм сөйләм теле лексикасы аерыла. Бу төр лексика синонимик рәттәге сүзләрнең төп мәгънәви доминантасын, экспрессивлыктан азат, әдәби телнең функциональ-стилистик дифференциациясен чагылдырган парадигмасын тәшкил итә.

Телдә бер генә сүз яки гыйбарәнең дә мәгънәсе бердәй түгел. Нейтраль сүз фонында стилистик бизәкләргә ия сүзләрнең, сөйләм чараларының саны һәм сыйфаты ачыклана. Мәсәлән, ***яшәү*** дигән стильара сүзнең, ягъни доминанта сүзнең татар телендә бик күп төрле синонимик вариантлары бар: *яшәү, тору, гомер итү (сөрү, кичерү), тереклек итү (кылу), көн итү (күрү, киченү, үткәрү), дөнья көтү (куу, кичерү, кичену), тормыш итү (көтү, алып бару)* һ.б. *Яшәү* синонимик оясына караган сүзләр якын мәгънәгә ия сүзләр булсалар да, стилистик яктан бер-берсенә капма-каршы сүзләр булып торалар. Мисаллардан күренгәнчә, җан, тереклек иясенең үсеш процессын, тере булу хәлен белдергән бу синонимик ояда стилистик яктан нейтраль *яшәү* сүзе бөтен төр стильләрдә билгеләнеп, билгеле бер урында яки вакытта яшәүне белдерә; *тереклек кылу* – шуның искергән варианты; *гомер сөрү, гомер*

*һәм көн кичеру*дә тормыш, яшәешнең авырлыгы, каршылыкларны җиңү; *дөнья көтү, дөнья куу*да тырышып, көч куеп яшәү; *дөнья киченү*дә тормышның очын-очка ялгап, бик тә авыр тормышта яшәү; *тормыш итү, көтү, алып бару*да яшәү өчен кирәкле шартлар, хуҗалык өчен көрәшү төсмерләре чагыла. *Яшәү* стильара сүзенең синонимнары исә сөйләм һәм язма формада иҗтимагый-публицистик, эпистоляр-хатлар, матур әдәбият телендә киң кулланыла. Шуны билгеләү зарур: хәзерге татар телендә *яшәү* сүзенең семантикасы киңәя бара.

Сүзнең семантик үзенчәлеге, мәгънәне, төшенчәне барлыкка китерә торган билгеләре мәгънә төсмерләрен дә барлыкка китерә. Боларга сөйләмдә теге яки бу стилистик максатларда кулланылган төсмерләр керә (Ханбикова, Сафиуллина, 1999: 3). Сүзнең төп, атау мәгънәсен тулыландырып килә торган эмоциональ-экспрессивлыкка, стилистик бизәккә, төсмергә ия лексик мәгънә компоненты коннотатив мәгънә дип атала (Татар лексикологиясе, 2015: 59). Коннотатив мәгънә бәяләү, хис-тойгы, эмоциональлелек, экспрессивлык, ассоциатив-образлылык, стилистик элементлардан тора. Әлеге төсмерләр төрле стильләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, *чәнчү-кадау* яки *бату-чуму-күмелү* кебек сүзләрнең синонимик ояларындагы өстәмә төсмерләр сүзнең мәгънәләрендә үк чагылыш таба. *Кыйнау* стильара сүзенең синонимик оясында *чәкәләү* сүзе «сугышу, бәргәләү» сөйләм телендә кулланыла. *Тукмау* «бик каты сугышып, авырттырып кыйнау; дөмбәсләү» дигән мәгънә бирә (ТТАС, 2005: 562). *Күсәкләшү* сүзе бераз мәгънә дифференциациясе кичереп, «күсәкләр белән кыйнашуны (сугышуны) аңлата (ТТАС, 2005: 335). *Дөмбәсләү* «(дошманга) уңышлы һөҗүм ясау, сизелерлек зыян китерү» (ТТАС, 2005: 562) дигән мәгънәдә килә. *Яру* «кыйнау, сугышып яралау» дигәнне белдерә. *Уру* «нык кыйнау» мәгънәсендә килә. *Чыбыклау* «кыйнау, чыбык белән сугу» дигән мәгънәне аңлата (661). *Аркалау* «кыйнау; тупас рәвештә куып, төрткәләп чыгару» (46) мәгънәсен бирә. *Бирү* сүзе гади сөйләм телендә «кыйнау, сугу» дигәнне аңлата (ТТАС, 2015: 539), сөйләм телендә исә «чамалап әйтү, якынча гына кешенең яшен билгеләү»не белдерә (ТТАС, 2015: 539). *Изү* сүзе күчерелмә мәгънәдә гади сөйләм телендә «каты кыйнау, кыйнап хәлдән тайдыру»ны белдерә (ТТАС, 2005: 368). Шул рәвешле, *кыйнау* стильара сүзенең мәгънә дифференциациясе белән билгеләнгән сөйләм теленә хас синони-

мик парлары кулланыла. Шул рәвешле, стильара сүзләр экспрессивлык билгеләренең булу-булмавы һәм әдәби телдә кулланылыш ешлыгы белән аерылып тора.

Матур әдәбият телендә стильара сүз әдәби әсәрнең образлар системасын сурәтләү чарасына әйләнеп, нейтраль сүз булудан туктый, эстетик вазифа башкара башлый. Мәсәлән, «*Утка килгән хатынның* ***утыз авыз*** *сүзе бар*» (мәкаль). «*Аның исеменә тагылып йөри торан кушамат дисәң – кушамат түгел, ләкин гаҗәп сәер бер өстәмәсе бар: «Әйттем-бетте». Ягъни, «****Әйттем-бетте*** *Хәмит!»*» (Ә. Еники). Әлеге мисаллардагы *утыз, авыз, әйтү, бетү* сүзләре аерым-аерым торганда, нинди дә булса сурәтне күз алдына китерми. Әлеге мисалларда исә алар билгеле бер сурәтне белдерә торган сүзтезмәләрне хасил итәләр. Китап һәм сөйләм телләренә караган лексиканың стильара сүзләргә күчүе аларның сан артуына, һәрвакыт тулыланып торуына китерә.

Стильара сүзләр әдәби телнең төп өлешен тәшкил итәләр һәм әдәби телдә сүз байлыгы артуны, функциональ стильләрдәге лексиканың үсешен, семантик һәм стилистик төрлелеген тәэмин итәләр. Стильара сүзләр контекстта, фразеологик гыйбарәләр эчендә субъектив модальлелек һәм яңа мәгънә бирү өчен төрле күчерелмә мәгънәләрдә дә кулланыла алалар. Шулай ук стильара сүзләр фразеологик берәмлекләрне ясауда катнашып, терәк компонент булып та йөриләр. Мәсәлән, фразеологик берәмлекләрдәге бер үк терәк компонент төрле стильгә караргa мөмкин. Мәсәлән, *кәеф бозылу* һәм *кикриге шиңү* берәмлекләренең беренчесе – стильара сүзләр булса, икенчесенең эмоциональ-экспрессив дәрәҗәсе бердәй түгел: *... әллә инде бу арада* ***кәефе бозылганмы****?* (Г. Толымбай). *Шуннан чират көтүчеләрнең дә* ***кикриге шиңә*** (Г. Толымбай).

Димәк, стильара сүзләр сүз ясалыш ояларын һәм коннотатив, экспрессив төсмерләрне булдыруда, күчерелмә мәгънәләрне, терминологияне барлыкка китерүдә ясагыч-нигез вазифасын үтиләр.

## КИТАП ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫ

### § 33. Китап теле лексикасына гомуми билгеләмә

Китап теле – әдәби телнең язма һәм сөйләмә формаларында кулланылып, сөйләм теле лексикасы белән стильара лексика арасында торган мөһим бер төре. Китап теле лексикасы дип

нормага салынган әдәби сөйләмдә, иҗтимагый-публицистик һәм фәнни сөйләмдә, рәсми эш кәгазьләрендә, матур әдәбият телендә кулланыла торган сүзләрне атыйлар. Сөйләм телендә кулланылган тәкъдирдә дә бу төр лексика китапчалык бизәген югалтмый. Китап теленең функциональ төрлелелеге китап теле лексикасының тематик төрлелеген билгели (Стилистический энциклопедический словарь русского языка, 2003: 498).

Китап теленә хас лексика әдәби телнең язма төрләрендә – фәнни мәкаләләрдә, дәреслекләрдә, рәсми документларда, эш кәгазьләрендә, рәсми стильдә һәм матур әдәбиятта; сөйләү шәкелләрендә – фәнни доклад, репортаж, суд чыгышы, сәяси нотык, митинг һ.б. төрләрдә кулланыла. Китап теле лексикасына иҗтимагый-сәяси лексика (*коалиция, демократия, забастовка, сәяси фирка, конституция, закон*), фәнни терминнар (*фараз, гомуми, процесс, текст, прогрессив, температура, цикл, консолидация*), икътисади терминология (*керем, бюджет, дотация, банк, аукцион, кыйммәтле кәгазь*), рәсми эш лексикасы (*хезмәт, файда, тавыш, сайлау, суд*), канцеляризмнар (*түбәндәге, түбәндәгечә, югарыда әйтелгән, тәкъдим ителгән, тиешле, билгеләнгән срокларда, искә алынган*) керә. Килеп чыгышы ягыннан бу төр сүзлек составын гомумтөрки сүзләр, гарәп-фарсы алынмалары, славян һәм Европа алынмалары тәшкил итә.

Китап теле лексикасының семантикасына, сөйләм теле лексикасы белән чагыштырганда, гомумиләштерү һәм абстактлылык үзенчәлекләре хас. Билгеле булганча, китап теле сүзләренең мөһим төрен фәнни, иҗтимагый-сәяси һәм техник терминнар тәшкил итәләр (Стилистический энциклопедический словарь русского языка, 2003: 498). Термин – үз өлкәсендә бердәнбер мәгънәгә ия булган сүз (*сингармонизм, аллитерация, гипербола, стилистика, орфография* һ.б.). Фәнни терминнар реаль чынбарлык турында күзаллауларны киңәйтәләр һәм тирәнәйтәләр, укучының теоретик фикерләү үсешен тәэмин итәләр, публикацияләргә төгәл логик һәм фәнни характер өстиләр. Терминнар номинатив функция үтиләр һәм анык, конкрет булалар, аларга экспрессив, эмоциональ, модаль функцияләр хас булмый һәм шунлыктан алар контекстка бәйле түгел, аннан башка да аңлашыла. Мисал итеп, фәнни стильдә билгеләнгән медицина терминнары бер мәгънәдә килеп, эмоциональ-эксперссив, коннотатив төсмерләргә ия булмыйлар: «*Гай-*

*морит – өске казналык куышлыгының лайлалы каплаулы ялкынсынуы»* (Ветеринария-медицинасы: русча-татарча энциклопедик сүзлек, 2010: 113) «*Миопия – күрә карау, еректан начар күрү – күз рефракциясе кимчелеге, күзнең оптик системасының төп фокусы челтәр катлау һәм хрусталик арасында булу»* (Офтальмалогия: русча-татарча терминологик аңламалы сүзлек, 2011: 113). Махсус медицина белгечләре өчен язылган хезмәтләрдә терминнарның гадәттән тыш күп булуы күзәтелә.

Китап лексикасы нормалашкан булуы белән аерылып тора, аңа, югарыда билгеләгәнчә, семантик гомумиләштерү һәм абстрактлылык үзенчәлекләре хас. Мәсәлән, фәнни стиль өчен лексик чараларның төп максаты – предметларны һәм күренешләрне билгеләү, атау, аңлату. Шуңа күрә фәнни стильдә гомумиләштерү вазифасын уртаклык исемнәр үтиләр: *шартлылык, үткәрүчәнлек, үзьяшәеш, җитештерү, реализация* һ.б.: *Яңа гасыр информация технологиясенең үсеш-**чынбарлыкны** тирәнрәк аңлауга, ә информация технологиясеннең үсеше – чынбарлыкны борынгы тәгълиматлар белән хәзерге чор фәнен берләштергән яңа танып белү алымына китерәчәк* («Фәнни Татарстан»). Рәсми эш кәгазьләре стилендә иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле абстракт төшенчәләрне белдергән сүзләр аерым урын тота: *эшчәнлек, хезмәт, оешма, күмәк предприятие, контроль, тикшерү, үстерү, активлаштыру* һ.б.: *Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен **билгеләүне, детальләштерүне һәм урнаштыруны** җирле бюджетка кагылышлы өлешендә гамәлгә ашыра* (Татарстан Республикасы Бюджет кодексы). *Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының тиешле территорияләрдә уңай әйләнә-тирә мохитне һәм экологик иминлекне тәэмин итү өчен **җаваплылыгы*** (Татарстан Республикасы Экология кодексы).

Искергән сүзләр һәм эмоциональ-экспрессив неологизмнар шулай ук, китап теленең лексик катламында каралалар (Сафиуллина, 1999). Матур әдәбиятта автор неологизмнары аерым урын тота, мәсәлән: *фикер-тирмән, фикер-редиска, фикер-кыяр, фикер-кишер* (Сөләйман); *атылчак, чарлак, ай гөлгөле* (А. Хәлим); *илһамият* (Зөлфәт) сүзләрен китап теле сүзләренә кертергә мөмкин:

*Фикерләрнең бар төрлесе,*
***Фикер-кыяр, фикер-кишер**, редискасы,*

***Фикер-алма, фикер-йөзем*** *һәм башкасы* (Сөләйман).

Шагыйрь фикерне *алма, кишер, кыяр, йөзем* беләнчагыштырып, сүз-сурәт тудырырга омтыла.

*Әмәлләрен шуның*
*Эзләп уза гомер,*
*Тау юлында –* ***гомер-кулазак*** (Сөләйман).

*Кулазак*ны (бүрәнә тарттыру өчен җайланган ике тәгәрмәчле арба) тормышның авырлыгы белән тиңләштереп, парлы сүз шәкелендә сурәт-образ ясый.

***Хыяллар рәшәсе***
*Тирбәлә дөньяда*
*Офыктан-офыкка –*
*Ир бала.*
*Ир бала* (М. Вәлиев).

Шагыйрь хыялларның тормышка ашмавын аңлап, аны миражга (ТТАС, 2005: 255) тиңли.

Эмоциональ-экспрессив неологизмнар сүз остасы ярдәмендә яңа сурәт тудырып, яңа мәгънә төсмерләре өстиләр. Алар халыклашып китмәсәләр дә, шагыйрь әсәрендә яңа сүзләр буларак беркетелеп калалар.

Искергән сүзләр хәзерге көн тормышын, хәзерге көн уй-тойгыларын чагылдырган әсәрләрдә, шигъриятьтә, публицистикада кулланыла:

***Гавам*** *сырхау, иман сырхау,*
*Тәүбә, тәүбә чире йокса –*
*Кая барыйм – сезгә киләм,*
*Сездән дәва, шигырьләрем* (Сөләйман).

Әлеге шигырьдә автор *халык* төшенчәсен искергән сүз белән биреп, сүзне образ ясау максатында отышлы файдалана.

Иҗтимагый-публицистик стильдә тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә яңа сүзләр ясау, булганнарын яңа мәгънәдә куллану тенденциясе узган гасырның 80–90 нчы елларында газета-журнал битләрендә окказиональ сүзләр белән мавыгуның көчәюенә китерде (Мөхиярова, 2009: 49). Бу процесс хәзерге көндә дә дәвам итә. Мисал өчен, ***Көлкелешнең*** *беренче этабы тәмам. Яшәсен*

***көлкелизм*** («Идел»). *Рухи һәм матди яктан зур булышлык алган яшь **фәнсөярләр** инде бүген вуз укучылары* («Татарстан яшьләре»). Әлеге неологизмнар автор позициясен, фикерен тагын да индивидуальләштерү, укучыны гаҗәпләндерү, язмада сүзнең мәгънәви мөмкинлекләрен ачу максатында кулланылганнар.

Совет чорында архаиклашкан искергән сүзләрнең соңгы елларда активлаша башлавы күзәтелә (Мөхиярова, 2009: 58). Иҗтимагый-публицистик стильдә әлеге күренеш сүзтезмәләрне бер атама белән әйтү, төшенчәләрнең мәгънә төсмерләрен конкретлаштыру максатында да кулланыла: ***Горбәттә** татарның күзе, колагы, туган милләтнең җан авазы булып кала* (Казан утлары). *Бу кадәр мәрхәмәт һәм **ихсаннар** күреп тә, сездән аерылу зур ялгышлык булыр* («Идел»). *Утырабыз **истирахәт** кичереп ачык верандада* («Идел»).

Китап теле лексикасында экзотизмнар, варваризмнар һәм поэтик сүзләр билгеләнәләр (Сафиуллина, 1999: 129). Бу сүзләр фәнни, иҗтимагый-публицистик матур әдәбият телендә кулланылалар. Варваризмнар (гр. *barbarismos*) – чыганак телдәге билгеле бер төшенчәне укучыга җиткерү максаты белән кулланылган, китап теленә хас чит тел сүзләре. Автор варваризмны транслитерацияләп (сүзгә-сүз), яисә чыганак телдәге сүзнең язылышын саклаган хәлдә бирергә мөмкин. Варваризмнар – телдә гомумкулланылышта булмаган, телгә кереп җитмәгән сүзләр. Матур әдәбият стилендә авторлар варваризмнарны окказиональ чара итеп тә кертеп җибәрәләр, шуңа күрә әлеге сүзләр авторның яңалыгы, индивидуаль табышы булып китә. Варваризмнар поэзиядә еш очрыйлар. Мәсәлән, шагыйрь Сөләйман «Чикерткәстан» шигыренә русча, инглизчә эпигафлар куя:

*Трепещет знак – кузнечик*
*Над полем и под небом* (В. Хлебников)

*R-p-o-p-h-e-s-s-a-g-r*
*who*
*a) sw (e loo)k...*
*to*
*rea(be)rran (com)gi(e)ngly*
*Grasshopper*
(E. Cumminga).

Иҗтимагый-публицистик стильдә варваризмнар мәгълүматны төгәл итеп бирү максатында кулланылалар: *Бу хакта* ***Reuters*** *агентлыгына өч дипломатик чыганактан мәгълүмат* килгән (Татаринформ). *Франциядә чыгучы* ***Les Echos*** *вакытлы матбугатына нигезләнеп, бу хәбәрне* ***RNS*** *яза* (Матбугат ру). Әлеге мисалларда варваризмнар информацияне мөмкин кадәр тулы, дөрес бирү өчен контекстка кертеләләр.

Китап теле лексикасының тагы бер төркем экзотизмнар – теге яки бу халыкның милли үзенчәлекләрен чагылдыра торган, татар дөньясының менталитетына хас булмаган чит төшенчәләр, күренеш атамалары. Әлеге сүзләрнең татар телендә синонимнары булмый. Бу сүзләр матур әдәбият, иҗтимагый-публицистик стильләрдә еш очрыйлар. Әдәби әсәрдә аерым бер халыкка хас аш-су атамаларын, көнкүреш атамаларын, объект, урын исемнәрен аңлатканда экзотик сүзләр кулланылалар (*пәхләвә, кебаб, бишбармак, лаваш, ролл, суши, ром, пицца* һ.б.):

> ***Капалы чаршы***
> *Базар бу –*
> *Алтын балдаклар дөрли*
> *Бакырдан әрсез* ***азәри***
> *Сине эчкә өстери* (Р. Зәйдулла).

Әлеге шигырьдә *капалы чаршы* – Истанбул шәһәрендәге иң зур базарларның берсе. Мисал итеп, *Әфлисун төсендәге мамык тәлгәшләре төшерелгән* ***үзбәк пыяласы*** *(касә) аның уч төпләрендә боргаланудан туктап калды* (Р. Рахман). *Боцман Жора* ***бакшиш*** *(чәйлек) сорамадымы?* (М. Юныс). *Урта Азия халыкларында бакшиш – чәйлек, чәй өчен бирелгән акча.* ***Рагу. Азу. Бифштекс. Ромштекс. Бефстроганов.*** *Бар икән күрәселәр.* ***Тефтели. Лангет. Скоблянка. Пудинг. Зразы*** (М. Мәһдиев). Бу мисалда М. Мәһдиев төрле халыкларга хас булган ризык исемнәрен санап китә: *Узган атнаны башкалага йомыш белән килгән кардәше «студент халкына калория кирәк, “Арагви”га барып* ***цациви, чахохбили*** *аша”» дип, Багратның кесәсенә берничә кыштырдык кәгазь тыгып киткән иде* (М. Юныс).

Китап теле лексикасының тагы бер төрен поэтик (шигъри) лексика тәшкил итә (Кадирова, 2010: 16). Бу сүзләр үзләренең поэтик төсмерләре белән аерылып торалар, хикәяләүдә патетик,

тантаналы тон барлыкка китерәләр, самимилек, нәфислек белән характерлананалар. Поэтик сүзләр – матур әдәбият стилендә, поэтик сөйләмдә кулланылып, лиризм, югары пафос, тантаналы стилистик төсмердә килгән сүз яки сүзтезмәләр (Стилистический энциклопедический словарь русского языка, 2003: 498). Матур әдәбият телендә поэтик сүзләр күптәннән формалаша. Хәзерге телдә ул борынгы төрки сүзләрдән, китап теле сүзләреннән, кайбер халык авыз иҗатына хас сүзләрдән гыйбарәт: *җиһан, ай йөзле, алма кебек, кыйгач кашлы, камыш буйлы, зифа, тылсымлы, Ватан, мизгел, мәшһүр* һ.б.: *Менә, ди, Шаһи картның алма кебек кызы бар, эшкә дисәң, авылда бер. Үзе шундый* ***сылу,*** *шундый з****ифа*** *– бер кашык суга сал да йот* (Г. Ибраһимов). ***Зифа*** *буең,* ***талчыбыктай*** *билең, Эчләреңнән энә үтәрлек* (Г. Сәгыйтов). Шигъри лексика шагыйрьләрнең эстетик зәвыгына һәм идеалына бәйләнешле рәвештә матур әдәбият телендә аерым урын тоталар. Язучының үзенә генә хас күңел күзе белән күрү үзенчәлеге, әсәрдә төп образны барлыкка китерү өчен тормыштагы кайбер күренешләргә игътибарлы булуы поэтик сүзләр белән сурәт тудыруда зур роль уйныйлар.

Димәк, китап теле лексикасы сөйләмнең язма формасында кулланылган һәм аерым стилистик төсмерләргә ия, нигездә фәнни, рәсми, иҗтимагый-публицистик һәм матур әдәбият теленә хас сүзләрне тәшкил итә.

## § 34. Рәсми эш кәгазьләре лексикасы

Рәсми эш кәгазьләре лексикасы – рәсми эш кәгазьләре стилендәге, канцелярия, рәсми, документаль, юридик, дипломатик эшләрдә чагылыш тапкан сүз һәм гыйбарәләр. Рәсми эш кәгазьләренә караган лексик берәмлекләргә төгәллек хас, алар экспрессив-эмоциональ төсмерләр белән билгеләнмиләр, метафорик мәгънә белдермиләр.

Рәсми эш кәгазьләрен фәнни яктан өйрәнү XIX гасыр башларына карый. Казан университеты укытучысы И. Хәлфин Тимур Кутлуг тарханның ярлыгына шәрехнамә яза һәм ярлыкта кулланылган архаик сүзләргә анализ ясый.

С. Күкләшев «Татар хрестоматиясе» дәреслегендә XIX йөзгә караган берничә документны эш кәгазьләре үрнәкләре итеп бастыра. Автор үзенең хезмәтендә, татар сүзләре белән бергә, гарәп-

фарсы сүзләре дә бертигез кулланылган телне – эш теле дип атый (Кукляшев, 1859: 3).

Рәсми эш кәгазьләре телен өйрәнүдә кискен үзгәрешләр инкыйлабтан соңгы унъеллыкта күзәтелә. 1920 елда Татарстан автономияле республикасы оешканнан соң, татар телен гамәлгә кую, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү юнәлешендә җитди максат-бурычлар билгеләнә. Шул уңайдан, хөкүмәт органнарында, җирле үзидарәләрдә татар телен кулланышка кертү эше җайга салына башлый. Әлеге максат белән, 1920 елда үзәк терминологик комиссия төзелә. Бу комиссиядә иҗтимагый-сәяси терминология белән шөгыльләнү дә бурыч ителә (Эшче, 1926, № 126; Мәгариф, 1921, № 1–2). Комиссия составына фән һәм мәдәниятнең төрле өлкәләреннән галимнәр катнаша: М. Корбангалиев, Г. Шәрәф, Н. Хәким, Г. Алпаров, Ф. Сәйфи һ.б. 20 нче еллар ахырына таба 15000 термин ясала һәм кабул ителә (Мәгариф, 1927, № 10–11, б. 70–71). Төрле өлкәләргә караган, шул исәптән иҗтимагый-сәяси һәм юридик лексиканы, өлешчә идарә терминнарын үз эченә алган уннан артык сүзлек нәшер ителә.

Эш кәгазьләре стилен өйрәнү, шулай ук иҗтимагый-сәяси лексиканың үсеш этапларын тикшерү эше В. Хаков хезмәтләрендә яктыртыла (Хаков, 1963: 168).

Рәсми эш кәгазьләренең нәзари һәм гамәли мәсьәләләре Х. Курбатов хезмәтләрендә җентекле өйрәнелә (Курбатов, 1971: 11). Х. Курбатов хан ярлыкларын, хатларны, төрле чорларга караган шартнамәләрне, шәҗәрәләрне шушы стильгә кертеп карый.

Ф. Хисамова, XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, документлардагы лексиканы өч тематик төркемгә бүлеп карый: хәрби лексика; иҗтимагый-сәяси лексика; көнкүреш лексикасы. Документларның характерына һәм эчтәлегенә бәйле рәвештә хәрби лексиканың шактый зур урын алып торуын билгели (Хисамова, 1981: 24).

90 нчы елларда татар теленең эш кәгазьләре стилен өйрәнү гаять мөһим проблемаларның берсе санала. Югары һәм урта белем бирү йортларында документларны татарча әзерләргә өйрәтү максаты куела (Хәбибуллина, 1992: 22–24). Соңгы елларда рәсми эш кәгазьләрен, документларны татарча дөрес язу, терминнарны дөрес куллану кебек мәсьәләләрне үз эченә алган ярдәмлекләр басылып чыга .

З. Вәлиев «Эш кәгазьләре үрнәкләре» (Вәлиев, 1999) җыентыгында көндәлектә әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә кулланыла торган эш кәгазьләренең (бергәләп эшләү ширкәте төзү, хуҗалык бәхәсләре, сәүдә эшләрендә килеп чыккан низагларны хәл итү буенча судка мөрәҗәгать итү һ.б.) татарча һәм русча үрнәкләрен туплап бирә.

И. Бәширова рәсми эш кәгазьләре (рәсми-канцелярия) стиленең төрләре күплеген һәм аларның һәрберсенең үзләренә генә хас ныклы традицион калыпка салынуын, рәсми-хокукый мөнәсәбәтләр аша рәсми стандартлыкка корылуын билгели (Бәширова, 2005: 22; 2012: 212).

Әлеге стильне һәрьяклап өйрәнүче А. Тимерханов «Русча-татарча эш кәгазьләре лексикасы сүзлекчәсендә» рәсми-эш даирәсенә караган 3000 гә якын сүз һәм сүзтезмәнең татарча-русча вариантларын күрсәтә (Тимерханов, 2001). Сүзлекчәдә хәзерге күчеш чорына бәйле рәвештә, татар теленең лексик составы үсешендә, аеруча аның рәсми эш кәгазьләре, рәсми эш башкару өлкәсенә караган үзенчәлекләре яктыртыла. Галим «Татар документының теле һәм стиле» монографиясендә (Тимерханов, 2002), җәмгыятьтәге административ идарә һәм хокукый мөнәсәбәтләрне алып бара торган эшчәнлек төрләрен ике нигезгә утыртып карарга мөмкин, дип саный. Кануный стильдәгечә һәм администрация, канцелярия стилендәгечә төрләр ныклы традицион калыпка салынган, алар рәсми-хокукый мөнәсәбәтләр нигезендә рәсми стандартлыкка, төгәллеккә корыла. Бу хезмәттә бүгенге көндә татар телен гамәлгә кертү мәсьәләләренә зур урын бирелә.

Рәсми эш кәгазьләре стилендә төп лексик катламны юридик терминнар, иҗтимагый эшчәнлекне яшәтә торган төрле өлкәләргә караган терминнар, төп мәгънәдәге (эмоциональ-экспрессив мәгънәдән азат булган), ягъни язучының мөнәсәбәтен турыдан-туры чагылдыра алмый торган, гомумкулланылыштагы сүзләр тәшкил итәләр. Рәсми эш кәгазьләре лексикасында тормышның бөтен даирәләренә дә караган һәм төрле норматив документларда чагылыш тапкан стильара лексика билгеләнә, алар зур күпчелекне алып тора. Бу сүзләргә төрле эш-хәрәкәтләрне, вакыт төшенчәләрен, хайван, үсемлек атамаларын чагылдырган сүзләр керә: *яшәргә, әзерләү, җир, су, пычрату, агызырга, агач, уңыш, хайван* һ.б. *Татарстан Республикасы милкендәге* ***мөлкәт һәм җир*** *белән*

*идарә итү буенча, шул исәптән хосусыйлаштыру һәм эш итү буенча милекче вәкаләтләрен башкаручы республика башкарма хакимияте органы булып тора* (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре 22 август, 2007 ел, № 407). *Татарстан Республикасы территориясендәге* ***җирдән, җир асты байлыкларыннан, су, урман һәм башка табигать байлыкларыннан*** *файдалануның һәм аларны саклауның Татарстан Республикасының күпмилләтле халкының тормыш һәм эшчәнлек нигезен тәшкил итүен исәпкә алып, мәдәни һәм башка үзенчәлекләренә бәйле мәсьәләләрне уртак хәл итүне күздә тота торган килешүләр төзиләр* (Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамә).

Рәсми эш кәгазьләре лексикасының бер катламын юридик терминнар тәшкил итәләр. «Телнең юридик лексикасы дәүләт яшәешендә булган тарихи, иҗтимагый һәм сәяси процессларның функциональ-семантик, грамматик чагылышын тәшкил итә» (Файзуллина, 2012: 5). Юридик терминнар нигездә законнарда, боерыкларда, карарларда кулланылалар: *хокук, кулланучы, җаваплылык, күрсәтмә, урлау, хокук саклау органнары, җинаятьчеләр, арбитраж суды, юридик зат, балигъ булу, эксгумация, кассация инстанциясе, виндикация, экстрадация, диффамация, санкция, плебисцит* һ.б. А. Тимерханов фикеренә караганда, юридик терминнарны катгый аерымлау критерийлары юк (Тимерханов, 2002: 122). Шуңа күрә, хокук фәннәрендә кулланыла торган терминнар юридик терминнарның төп лексик катламын тәшкил итәләр. Мәсәлән: ***Хокук саклау органнары*** *республиканың оешкан җинаятьчелегенә нык удар ясыйлар* («Татарстан»). *Үтерүчеләрне, шул исәптән заказ буенча үтерүчеләрне тикшерү* ***законнар*** *нигезендә* ***прокуратура һәм Эчке эшләр министрлыгы органнарына*** *йөкләнгән* («Татарстан»). Юридик лексика теге яки бу төшенчәне төгәл һәм тулы итеп ачып бирә. Юридик лексикага хас семантик төгәллек авыр хокукый төшенчәләрне логик һәм эзлекле бер тәртиптә ачарга ярдәм итә. Шул рәвештә генә документ теленә төгәллек, авыр хокукый төшенчәләрне логик эзлеклелектә аңлату тәэмин ителә. Мисал итеп, *закон* сүзенә «Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә» «югары дәүләт органнарның билгеле бер тәртиптә кабул ителгән һәм юридик көчкә ия булган норматив акты; канун»

(ТТАС, 2005: 162) дип аңлатма бирелә. *Закон* сүзен аңлатуда төгәл билгеләмә һәм төп юридик терминнарның урынлы, логик һәм эзлекле бер тәртиптә урнашып мәгънә белдерә алулары мәгънә төгәллелеген тәэмин иткән.

Рәсми эш кәгазьләренең лексик катламында төрле өлкәгә караган терминология аерым урын тота. Билгеле бер өлкәгә караган терминнар, төшенчәләрнең тар күләменә карамастан, аерым бер өлкәгә функциональ беркетелеп, төгәл, конкрет эчтәлек бирәләр. Аерым бер өлкәгә караган терминнарның эш кәгазьләрендә чагылыш табуы табигый күренеш (Тимерханов, 2002: 113). Мисал итеп, Татарстан Республикасы экология кодексында экологик терминнар зур урын тоталар: *антропоген объект, су ресурслары, дәүләт экология мониторингы, туфракның деградацияләнүе, табигый экологик система* һ.б.: *Татарстан Республикасының **экология законнары** табигатьтән файдалану, **әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне** тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала* (Татарстан Республикасы Экология кодексы). Әлеге Кодекста кулланылган экологик терминнар экология мәсьләләренә караган эшчәнлекнең хокукый нигезләрен чагылдырып, документның максаты һәм эчтәлек характерына бәйле максатчан кулланылалар.

Икътисади терминнар икътисади процессларның рәсми эш кәгазьләрендә чагылышын яктырталар: *җирле бюджет, субвенция, бюджетара трансфер, керем, салым ставкалары, депозит, ассигнование* һ.б.: *Россия Федерациясе **бюджет** классификациясен куллану тәртибен Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кагылышлы өлешендә билгеләү, детальләштерү һәм урнаштыру* (Татарстан Республикасы Бюджет кодексы. ТР Законы); *Муниципаль үзара **хисаплашуларны** гамәлгә ашыру, **муниципаль гарантияләр** бирү, **бюджет кредитлары** бирү, **муниципаль бурычлар** белән эш итү һәм **муниципаль активларга** идарә итү* (Татарстан Республикасы Бюджет кодексы. ТР Законы). Нигездә бу сүзләрнең күпчелеген рус теле аша татар теленә үтеп кергән Көнбатыш Европа алынмалары тәшкил итә. Икътисад өлкәсенең үсеше телнең лексик үсешен дә билгели. Тормышта барлыкка килгән яңа төшенчәләрне белдерүдә яңа сүзләр куллану яки иске сүзләрне кире лексикага кайтару ихтыяҗы арта:

*керем, чыгым, бюджет, дотация, банк, кредит, депозит, акциз, исәп-хисап, товар, тариф, кыйммәтле кәгазьләр* һ.б. Икътисади терминнар арасында рус теле аша кергән рус теле һәм Көнбатыш Европа алынмаларының өстенлеге рус телендә барган тел күренешләренә бәйле килә. Бер дәүләт шартларында яшәгәнгә күрә, рус телендә барган тел күренешләренең татар теленә йогынтысы зур, чөнки рус һәм татар телләренең лексикасында неологизмнар өлкәсендә уртаклык бар. «Бу уртаклык икътисади терминнарның даими терминологик мәгънәләренең үзара туры килүендә, структур һәм фонетик төзелеш бердәмлегендә чагылыш таба» (Мөхиярова, 2009: 110). Шуңа күрә татар теленең икътисадка бәйләнешле терминнарында рус теле аша кергән алынмалар өстенлек итә.

Рәсми эш кәгазьләре лексикасында авыл хуҗалыгы өлкәсендәге әһәмиятле процессларны чагылдырган сүзләр билгеләнәләр: *игенчелек, игүлек, бөртекле культура, эшкәртү, саву машинасы, саклау, сугару, җирдән файдалану* һ.б.: *Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2004–2007 елларда* ***авыл хуҗалыгы*** *товар җитештерүчеләре,* ***агросәнәгать комплексы оешмалары (авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын*** *да кертеп) һәм* ***крестьян (фермер) хуҗалыклары*** *Россия кредит оешмаларында 5 елга кадәр вакытка алган инвестиция кредитлары буенча (шул исәптән үз илебездә эшләнгән* ***авыл хуҗалыгы техникасының*** *барлык төрләрен, нәселле терлек сатып алуга, күпьеллык үсентеләр, виноградлар утыртуга,* ***терлекчелек комплекслары****н, җитен һәм җитен җеп эшкәртү предприятиеләрен төзүгә һәм реконструкцияләүгә) процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында»* (Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек турында ТР Законы). Икътисади терминнарда, татар халкының борынгыдан килгән һөнәр традицияләренә бәйле рәвештә, авыл хуҗалыгы терминнарының нигезен төрки-татар катламы алып тора. Әлеге күренеш җир эшкәртү лексикасының генетик катламнарындагы үзенчәлекләр белән бәйләнешле аңлатыла (Гаффарова, 2003: 74).

Рәсми эш кәгазьләре лексикасында иҗтимагый тормыштагы процессларны җайга салган медицина терминнары да әһәмиятле роль уйный: *медицина, дару, профилактикалау, вакцина, шифаханә, йогышлы авыру* һ.б.: «*Татарстан Республикасында граж-*

*даннарның* ***сәламәтлеген саклау*** *өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында* (ТР Законы); «*2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри* ***медицина имияте фонды*** *бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында* (ТР Законы).

Дәүләттәге һәм тормыштагы иҗтимагый-тарихи ситуациягә бәйле рәвештә актив кулланылган *хәрби лексиканы* билгеләргә кирәк: *хәрби хезмәт, сугыш, җиңү, урнашу, пункт, гаскәри часть, хәрби комиссариат, хәрби гамәлләр* һ.б.: «***Сәяси репрессияләр корбаннарын*** *реабилитацияләү турында» Россия Федерациясе Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында ... номерлы федераль закон проектын (җинаять эшләре һәм административ эшләр материалына тикшерүләр үткәрү мөмкин булмаган очракта гражданнарны сәяси репрессияләр корбаннары дип тану өлешендә) хупларга* (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарыннан). «***Сугыш чоры балалары турында***» *федераль закон проектын закон инициативасы әртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә* (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарыннан).

Унификацияләнгән фикерне төгәл, логик эзлеклелектә тәгъбирләргә ярдәм итә торган тотрыклы структурага нигезләнгән сүзләр – канцеляризмнар, рәсми эш кәгазьләре лексикасында аерым урын тоталар: *түбәндәге, югарыдагы, тәкъдим ителгән, тиешле, мәгълүм үрнәктә* һ.б.: *Әлеге Кодекс максатларында* ***түбәндәге*** *төп төшенчәләр кулланыла* (Татарстан Республикасы Экология кодексы). *Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларына* ***түбәндәгеләр*** *керә* (Татарстан Республикасы Бюджет кодексы). Канцеляризмнар, тотрыклы тел формулалары буларак, текстның адресат тарафыннан төгәл, бер мәгънәдә аңлашылуын тәэмин итәләр.

Рәсми эш кәгазьләре лексикасында дәүләт органнары, идарәләре, бүлекләре, аларның вазифалары, почетлы бүләкләр һ.б.ш.ны чагылдырган атамаларны, номенклатур тамгаларны аерып күрсәтергә кирәк. Аларга *акт, әмер, анкета, аттестат, беркетмә, бәяләмә, бюллетень, вексель, беркетмәдән чыгарма, йомгакнамә, кагыйдәнамә, күрсәтмә, юнәлешнамә, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, Россия Федерациясенең атказанган*

*фән эшлеклесе* һ.б. сүзләр керә. Мәсәлән: *Икътисад һәм финанс эшчәнлегенең казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең финанс бүлеге мөдире Назаров Александр Ефимовичка «**Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы**» дигән мактаулы исем бирелде* («Ватаным Татарстан»). *Татарстан Респбуликасы **дәүләт бүләкләре** турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республкасының законын кабул итәргә* (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарыннан).

Чынбарлыктагы реалийларның үзгәреше сүзлек составының да үзгәрешенә китерә. Иҗтимагый тормыштагы һәм дәүләттәге законнарны җайга салу максатында аерым предмет һәм күренешләр барлыкка килү сәбәпле, яңа атамалар барлыкка килә, кайберләре исә юкка чыга. Шул рәвешле, гасырлар дәвамында барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, бүгенге көндә иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең һәм тарихи шартларның төрле этапларын чагылдырган рәсми эш кәгазьләренең бай актив лексикасы формалаша. Яңа фәнни юнәлешләрнең барлыкка килүе һәм тиз арада үсеш алуы хәзерге татар теле лексик составында да яңа сүзләр артуга китерә, бу исә, үз чиратында, яңа төшенчәләр лексикасын чагылдырган рәсми эш кәгазьләре стилен дә читләтеп үтми.

## § 35. Фәнни лексика

Фәнни лексика – төрле эзләнү-тикшеренүләр ярдәмендә тирә-юньне, чынбарлыкны өйрәнеп, фәнни нәтиҗәләрне чагылдыру өчен кулланылган, чынбарлыкны, фикерне логик эзлеклелектә, төгәл итеп, аерым бер фән тармагына гына хас булган фәнни төшенчәләр ярдәмендә чагылдырган сүзләр. Фәнни лексика яңа фәнни белемне мөмкин кадәр тулы итеп күрсәтүгә, хәбәр итеп чагылдыруга юнәлтелә, җәмгыять һәм кеше, табигать һәм тирә-юнь турында объектив мәгълүмат бирүне максат итә. Фәнни лексика сөйләмгә ачыклык, төгәллек, объективлык кертә: *Интеграль исәпләүне вакланма тәртиптәге интегралларга да киңәйтү мәсьәләләре күптән өйрәнелә һәм аңа карата хәзерге вакытта зур кызыксыну күзәтелә* («Фәнни Татарстан»). Әлеге мисалдан күренгәнчә, *интеграль исәпләү, интеграл, вакланма* кебек математик терминнар фәнни стильгә ачыклык, төгәллек объективлык өстиләр. Шулай

итеп, китап телендә аерым бер предмет яки чынбарлыктагы күренешләрне чагылдырган төшенчәләр, терминнар, гомумтерминнар фәнни лексиканың нигезен тәшкил итәләр.

XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөз башында татар мәгърифәтчеләренең эшчәнлеге һәм шул чордагы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар тәэсирендә татар теле белемендә фәнни стиль һәм фәнни лексика формалаша. XII йөздә Болгар чорында Ногман әл Бохариның «Болгар тарихы» китабында ук фәнни лексикага игътибар бирелә. Математика терминарына бөтен Идел буена мәгълүм математика буенча мөһим дәреслек ролен үтәгән «Мәҗмәгыл кавагыйд» («Кагыйдәләр җыентыгы», 1542) хезмәтендә шактый урын бирелә. XVI йөздә язылган Шәрәфетдин бине Хисаметдиннең «Тәварихе Болгария» әсәрендә тарихка кагылышлы лексика чагылыш таба. XVII йөздә Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъ-әт Тәварих» исемле тарихка кагылышлы хезмәтендә дә тарихи лексика актив кулланыла һәм ул шул чордагы фәнни лексиканың әһәмиятле чыганагы булып тора.

Татар тел белемендә фәнни лексика, беренчеләрдән булып 1859 елда С. Күкләшев хезмәтләрендә өйрәнелә башлый. Ул үзенең «Татар хикәяләре җыентыгы» («Диване хикайәте татар», 1859) хезмәтендә татар теленең язма телен гади, эш һәм фәнни төрләргә бүлеп карый. Аның фикеренчә, фән теле гарәп телен яхшы белүчеләр өчен аңлаешлы. Фәнни телдә язылган хезмәтләрдә гарәп сүзләре, тәгъбирләре өстенлек ала (Кукляшев, 1859: 3). Татар телендә гасырлар дәвамында үсеш алган фәнни лексика һәм терминнар мәсьәләсе К. Насыйри, Г. Ибраһимов, З. Вәлиуллина, Ш. Рамазанов, М. Корбан, Ф. Фәсиев, В. Хаков, Х. Курбатов, Ф. Сафиуллина, И. Бәширова, Л. Гыйләҗева һ.б. тарафыннан өйрәнелә, аның формалашу тарихы, үсеше, үзгәреше, системасы тикшерелә.

Фәнни лексиканың мөһим катламы – терминнар татар теленең үз сүзләре һәм башка телләрдән кергән алынмалар җирлегендә ясала. Фәнни термин – кулланылышы ягыннан чикле булган, бер мәгънәне төгәл, конкрет белдерүе белән телдәге башка сүзләрдән аерылып тора (мәсәлән: *ярымөзлексез функция, тулы чыгарма, Брианшон теоремасы, Бертран постулаты, Архимед спирале, Гельфонд теоремасы, геометрик сумма, агромелиорация, агрометеорология, агрикультура, астпрограмм, төймәсар, санак, сингармонизм законы, агглютинатив телләр, флектив телләр,*

*функциональ стиль* һ.б.). Терминнар номинатив функция үтиләр һәм анык, конкрет булалар, аларга экспрессив, эмоциональ, модаль функцияләр хас түгел[1].

Татар теле белемендә лингвистик терминология XVIII йөздә беренче татар грамматикалары үрнәкләрендә күренә башласа, XIX йөздә инде лингвистик терминологиянең кулланылыш даирәсе киңәя. XX йөздә чыккан дәреслекләрдә халык сөйләменә нигезләнгән грамматик атамаларга зур урын бирелә. Мәсәлән, 1887 елда Х. Фәезханов татар грамматикасына багышланган хезмәтендә *хәреф, асыл сан, тәртип саны, берлек, күплек, сан, дәрәҗә, артыклык, тәртип саны, билгесез замир, үткән вакыт, киләчәк вакыт, чикләү зарыфы, урын зарыфы* кебек терминнарны куллана. Ә. Сираҗетдин грамматика дәреслегендә (1902) *берлек, күплек сан, артыклык дәрәҗәсе, хәзерге вакыт, үткән вакыт* кебек терминнарны киң кулланылышка кертә. Г. Әхмәтов грамматикасында (1908) *төп сыйфат, нисби сыйфат, сан исемнәре, кечерәйтү исеме* терминнары очрый. М. Өметбаев грамматикасындагы (1901) *төп сүз, кушым сүз;* Ш. Иманаевтагы (1910*) сөаль җөмлә, баш җөмлә;* Һ. Максуди грамматикасындагы (1910) *максуд (максат) җөмлә, сәбәп җөмлә, шарт җөмлә, муәфәкать (ия) җөмлә;* Г. Сәгъдидәге (1913; 1915) *ким дәрәҗә (кимлек), ярдәмче фигыль;* Җ. Вәлиди грамматикасындагы (1915) *аваз, исем фигыль* кебек терминнар бүгенге тел белеме дәреслеклрендә дә чагылыш таба. Г. Нугайбәкнең 1911 елда чыккан «Төрлек» грамматикасындагы сөйләү теле җирлегендә ясалган терминнар (*тавышлык, тавышбаш, ялгаулар, азаклар, бирү төшеме, күчү төшеме, атлык, югары чик билге, түбән чик, атау төшеме* һ.б.) бүгенге грамматикаларда урын алмаган.

Лингвистик терминологиянең үсешендә һәм нормалашуында Г. Ибраһимовның роле зур. Аның «Сарыф», «Нәхү» кебек грамматикаларында элеккеге традицияләрне дәвам итеп, фәнни нигездә терминнарны системалаштыруы күзәтелә. Г. Ибраһимов тарафыннан кертелгән күп кенә лингвистик терминнар бүгенге фәнни грамматикаларда да чагылыш табалар: *кушымта (кушымча), чагыштыру дәрәҗәсе, төп сан, чама саны, алмашлар (алмашлыклар), зат алмашлыгы, хәл фигыль, ярдәмче фигыльләр, рәвеш,*

---

[1] Терминнарга хас үзенчәлекләр, аларның табигате «Татар теле терминологиясе» бүлегендә тулырак бирелгән.

*ярдәмлек, хикәя җөмлә, ярашу, баш кисәк, иярчен кисәк, ия, гади, кушма хөкем (хәбәр), аергыч, тәмамлык, вакыт, урын, сәбәп, иясез җөмлә, аергыч җөмлә, кире җөмлә* һ.б.

XX гасыр башында Г. Ибраһимов «Аң» журналының 24 санында «Фәнни истиляхлар» мәкаләсендә фәнни терминология мәсьәләләрен күтәреп, киләчәктә татар теленең үз сүзләре нигезендә фәнни терминологиясе булачагы, ләкин бу эшнең «татарчалашуы әдәбиятка караганда күп мәртәбә акрын баруы» турында искәртә (Ибраһимов, 1913: 439–442). XX гасыр башында башка фән тармакларында да терминологиянең үсеше күзәтелә.

XIX йөз ахыры XX йөз башында саннар, исәпләүләр белән бәйләнешле математик терминнар үсеш алалар. Мисал өчен, К. Насыйриның «Хисаплык» дәреслегендә (1873) *җыю* (хәзерге телдә кушу), *аеру* (алу), *сугу* (тапкырлау), *бүлү, җыясы сан* (хәзерге телдә кушылучы саннар), *сумма, киметәсе сан, алынган сан, калдык, сугылмыш сан, суккыч сан, чыгыш, бүлгеч сан, үлчәү саны, вакландыру, сан дәрәҗәләре, берләр, уннар, йөзләр, меңнәр, ун мең* һ.б. кебек стильара сүзләр терминлаша. XX йөз башында чыккан математика китапларында терминнарның камилләшә баруы күзәтелә: *кушу, алу, кимүче, киметүче, сумма, тапкырлау, бүлү, өлеш, мәсьәлә, гамәл билгеләре* һ.б. Бу чорда рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән дә математик атамалар керә: *плюс, минус, ноль, цифр, счет, куб, дистә, миллион, триллион* һ.б.

XX гасырның 20–30 нчы елларында фәнни стильне үстерү, әдәби телнең фәнни терминологиясен булдыру өстендә эш алып барыла. Шул нәүбәттә фән өлкәсендәге яңалыкларны халыкка җиткерү, фәнни төшенчәләрне халыкка якын, аңлаешлы сүзләр белән белдерү максат ителә. Гыйльми Үзәк бу бурычны махсус комиссиягә йөкли. XX йөзнең 20–30 нчы елларында мәктәпләрне яңача төзү, язу һәм имля хакында мәкаләләр языла; яңа фәнни-педагогик атамалар да матбугатта күренә башлый: *бюро, орган, номер, декрет, педагог, методика* һ.б. 20–30 нчы елларда «Мәгариф» журналы системалы рәвештә математикадан һәм башка фәннәрдән яңа атамаларны биреп бара. Фәнни төшенчәләрне бирүдә телнең үз мөмкинлекләреннән файдаланыла. Халыкның җанлы сөйләмендә йөргән сүзләр фәнни атама булып китә: *йөз, сызык, үлчәү, кыр, кабырга, ара, почмак, үрә, бүленүче, бүлүче, тапкырлаучы, тапкырланучы, күләм, авырлык* һ.б. XX гасырның 20 нче еллары ахырына

юридик терминология эшләнә башлый: *хөкем, васыять, дәүләт, җинаятьче, яла, ялган, мөлкәт, гаепләүче* һ.б. Совет чорында терминология комиссиясе тарафыннан төрле өлкәгә караган алынма сүзләр әдәби норма булып кабул ителә: *масштаб* («Мәгариф», 1921); *педагог, метод, комплекс, система, натурализм, психика, психолог, динамизм, статистика, биография* («Мәгариф», 1925); *проблема, процесс, экспонат, теория, практика, тема, термин, анализ, синтез, максимум, минимум* («Мәгариф», 1925); *флора, фауна, минерал, элемент, археолог, реформа, лаборатория* («Мәгариф», 1925) һ.б.

1929–1932 елларда яңалифкә күчү белән терминология формалашуының икенче этабы башлана. Күчеш процессында терминнар арасыннан күп кенә фарсы, гарәп сүзләре төшерелеп, алар урынына татарча, халыкара сүзләр һәм советизмнар керә башлый. Шушы чорда күпләп ясалган атамаларның мәгънәсе тәгаенләшә бара. 1932–1939 елларда билгеле төшенчәләрне аңлату өчен татар әдәби теле һәм сөйләү телендәге сүзләрдән термин ясау максаты куела (Рамазанов, 1935: 23), бер үк терминнарның төрлечә язылуын булдырмау чаралары күрелә (Корбан, 1935: 43). Термин төзү эшендә татар теленең үз байлыгын, сүз ясау ресурсларын исәпкә алып, мөмкин булган барлык чыганаклардан акыллы файдалану принцибы алга сөрелә (Фасеев, 1969). XX гасырның 40 нчы елларында ТАССР Югары Советы Президиумы каршында оештырылган терминология комиссиясе тарафыннан терминология өлкәсендә актив фәнни эшчәнлек алып барыла башлый. Бу комиссия 60 нчы елларга кадәр яшәвен дәвам итә. Терминологик комиссиянең эшчәнлеге һәм, гомумән, терминология өлкәсендәге фәнни эш «Татар әдәби телле терминология өстендә эшләү өчен практик күрсәтмәләр-инструкциясенә» таянып башкарыла. Ул хөкүмәт терминология комиссиясе тарафыннан эшләнеп, 1943 елда кабул ителә, 1958 елда, нигездә, үзгәртелмичә диярлек, кабат бастырылып чыгарыла (Зәкиев, Низамов, 1994: 31).

80 нче еллар уртасындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә, татар теленең терминологиясен яңадан тикшерү, яңа заман таләбе нигезендә барлыкка килгән төшенчәләргә атама бирү ихтыяҗы туа. Шул уңай белән, 1986 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында күптөрле бурычларны һәм, шул исәптән, терминология мәсьәләләрен дә хәл итү буенча коми-

тет оеша (Зәкиев, Низамов, 1994: 32). Бу елларда татар әдәби теленең терминологиясе тәртипкә китерелә, сүзлек хәзинәсен яңарту мәсьәләләре белән матбугатта мәкаләләр, чыгышлар ясала, җыентыклар чыгарыла. 1994 елның июль аенда Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты каршында Республика терминологик Комиссиясе оештырыла. Татарстан Республикасы Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бу комиссиянең эшчәнлеген әйдәп бара. Институтның лексикология һәм лексикография бүлегендә төрле өлкә терминнарына караган сүзлекчәләр эшләнә һәм нәшер ителә.

Фәнни стильнең тагын бер актив лексик катламын гомумфәнни лексика тәшкил итә: *мәгънә, өлеш, элемент, сан, процесс, функция, тигезләмә* һ.б. Мисал: *Японча санау системасында саннарның абстракт (ягъни сан буларак аерым гына кулланыла торган) мәгънәләре юк* («Фән һәм тел»). Татар телендә фәнни лексика алынма сүзләр белән билгеләнә: *тәшкил итә, тәэмин итә, фараз, гомуми, шәрехләү, мәгънәви, гипотеза, процесс, текст, материал, консолидация, проблема, система, этап, традиция* һ.б.: *Белемне билгеле бер формада үзләштерү, ягъни алган мәгълүматны* ***систематлаштыру,*** *истә калдыру һәм* ***тикшерү,*** *үзлегеннән* ***өйрәнү*** *һәм* ***үзләштерү,*** *интеллектуаль осталык* ***формалаштыра*** («Фән һәм тел»).

XX гасырда фәнни лексиканың үсешенә рус теленең тәэсире көчле була һәм ул күренеш, лексик планда гына калмыйча, морфология, синтаксис дәрәҗәсендә дә чагылыш таба. Үзгәртеп кору башлангач, югары уку йорты өчен дәреслекләр, фәнни мәкаләләр татарча языла башлый һәм элеккеге фәнни стильгә кайтуга омтылыш туа [Мөхиярова, 2009: 71]. Шуңа күрә үзгәртеп кору елларында фәнни лексикага гарәп-фарсы атамаларының киредән кайту процессы күзәтелә: *гонсырлар* (элементлар), *тыйб* (медицина), *фәлсәфә* (философия), *нәзарият* (теория), *лөгать* (тел) һ.б.

Фәнни лексикада фразеологик берәмлекләр аерым урын алып торалар: *калкансыман биз, ак шигырь, ак гөмбә, үги ана яфрагы* һ.б.: ***Меңьяфрак*** *– оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыруы. Чүп үләне. Татарстан Республикасында 6 төре бар, иң киң таралганы гади меңьяфрак. Аш тәмләткеч сыйфатында һәм дару үләне буларак кулланыла. Болыннарда, утлавыкларда, бакчаларда очрый, күпьеллык үлән чәчүлекләрдә үсә* (Татар энциклопедия сүзлеге). ***Ак шигырь*** *– рифмасыз шигырь. Татар поэзиясендә*

*Ә. Давыдов, Ш. Анак, К. Латыйп, Р. Фәйзуллин, Р. Харис һ.б. шагыйрьләр иҗатында очрый* (Татар энциклопедия сүзлеге).

Фән лексикасын эмоциональ-экспрессивлыктан азат, шуңа күрә «коры» лексика дип атыйлар. Фәнни стильнең фәнни-популяр төрендә, фәнни хезмәтнең ышандыру көчен тагы да арттыру максатында эмоциональ-экспрессив чараларны да очратырга мөмкин. Саф фәнни телдә исә эмоциональ-экспрессив, коннотатив эчтәлеккә ия сүзләр бөтенләй кулланылмый: *Геномны өйрәнү кеше организмының үсеш принципларын, нәселдән-нәселгә күчкән авыруларның генетик сәбәпләрен, картаю механизмын яхшырак аңлау һәм, шулай ук, Җирдә тереклек ияләренең эволюциясе турында караш булдыру мөмкинлеге тудыра* («Фәнни Татарстан»). Әлеге җөмләдән күренгәнчә, барлык сүзләр дә төп мәгънәләрендә бирелгәннәр, эмоциональ-экспрессив сүзләр бөтенләй кулланылмаганнар.

Фәнни лексиканың яртысы стильара (нейтраль) сүзләрдән тора. Китапның спецификасыннан, текстның төреннән (хикәяләү, бәян итү һ.б.) чыгып, адресатка бәйле рәвештә, стильара сүзләрнең саны күбәергә яисә кимергә мөмкин. Фәнни лексикада гади сөйләм сүзләре, сленглар, варваризмнар кулланылмый.

Фәнни стильдә абстракт сүзләрнең кулланылышы шактый актив күзәтелә: *күренеш, шарт, үсеш, мәсьәлә, яңалык, тәгълимат, үзгәреш, юнәлеш, тәэсир, эчтәлек, яссылык, мөнәсәбәт* һ.б.: *Археологларның фәнни-тикшеренү планнарында өстенлекле* ***юнәлеш*** *булып һаман да Татарстанның археологик картасын төзү темасы кала бирде* («Фәнни Татарстан»). *Этнорегиональ* ***аспект,*** *мәгълүм булганча, этносның төрле структур төркемнәрендә халык культурасы формалашу һәм аның гамәлгә кертелү үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә* («Фәнни Татарстан»).

Төгәл фәннәр өлкәсендәге хезмәтләрдә символлар да күп кулланыла. Билгеле булганча, физика-математика фәннәренең иң әһәмиятле компоненты булып математик символика санала. Бу символика фәнни төшенчәләрне абстракцияләп, төрле халыкларның фәнни стильләрен якынлаштыра, әлеге стиль төрендәге башка чараларның да катгый һәм объектив булуын таләп итә (Сафиуллина, 1997, 63). Символлар үзләренең табигатьләре белән интернациональ булулары, әлеге фәннәрнең изоляция хәлендә яши алмаулары, бөтендөнья фән һәм техника казанышларына бәйле рәвештә киң үсеш-үзгәреш кичерүләре белән аерылып тора.

Фәнни стильләрнең тагы бер үзенчәлекле лексик катламы булган аббревиатур сүзләр, шартлы кыскартылмалар фәнни хезмәтне җыйнакландыруда хезмәт итәләр, кабатлауларда коткаралар: *линг.* – лингвистика, *грам.* – грамматика, *алм.* – алмашлык һ.б.

Димәк, фәнни стиль – эзлекле рәвештә аңлатып бирүгә нигезләнгән, сүзләрне җентекле сайлауга, аларны туры мәгънәдә генә куллануга, терминнарның һәм аерым өлкәгә караган лексиканы файдалануда мәгънәви төгәллеккә, абстрактлылыкка, гомумиләштерүгә омтылган сөйләм тибы. Фәнни лексика исә тормыш-чынбарлыкны сурәтләүдә логик эзлеклелек, нигезле бәян итү белән билгеләнгән бер мәгънәле сүзләр, абстракт сүзләр һәм фәнни терминнарны тәшкил итә.

## § 36. Иҗтимагый-публицистик лексика

Иҗтимагый-публицистик лексика – җәмгыятьтәге эшхәлләрне, вакыйгаларны чагылдыруда авторның актив сәяси позициясен яктырткан, эмоциональ-экспрессив төсмерләр белән билгеләнгән сүз һәм стандарт сүз гыйбарәләре.

Татар теле белемендә иҗтимагый-публицистик стильгә хас лексика М. Гайнуллин, В. Хаков, Ф. Әгъзәмов, Х. Курбатов, И. Низамов, Р. Йосыпов, В. Гарифуллин, Р. Абдуллина, Р. Мөхиярова һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә шактый киң яктыртыла.

Татар телендә иҗтимагый-публицистик стильнең формалашуы һәм лексикасының үсеше XV–XVI гасырларга туры килә. XVIII–XIX гасырларда иҗтимагый-публицистик стиль һәм бу стильгә караган лексика тәмам ныгып, үсеп җитә, ә XX гасыр башында, Россия җирлегендә барган иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга аеруча бай чорда, әлеге стиль һәм иҗтимагый-публицистик лексика чынбарлык чагылышының иң нәтиҗәле формасына әверелә. Татар әдәби телендә иҗтимагый-публицистик лексика елъязма рәвешендә язылган хроникаль әсәрләрдә, вакыйгаларда, юлъязмаларда, төрле өндәмәләрдә, мөрәҗәгатьләрдә, нотыкларда, указларда, тарихи-публицистик очеркларда чагылыш таба. Әлеге тарихи чыганакларда шул чорның көнүзәк иҗтимагый-сәяси, тормыш-көнкүреш проблемалары гарәп-фарсы теленнән кергән иҗтимагый-публицистик лексика аша яктыртыла. Мәсәлән, «Ике хаҗиның рихләтнамәләре» исемле китапта ике татар кешесенең сәяхәтнамәсендәге өзектә иҗтимагый-публицистик лексиканың

чагылышын күрәбез: ***Тәхетенең*** *синең тагга охшар, халкың синең саян* ***дәүләткә*** *охшар. Затың синең мисалы айга охшар, хәерең синең диңгезгә охшар* ***Падишаһның падишаһлыгы*** *халык берлә торыр; халыкның дәүләте* ***падишаһ*** *берлә торыр*.

XVIII гасырга караган иҗтимагый-публицистик стильдә язылган сәяхәтнамәләр, юлъязмаларда түбәндәге иҗтимагый-публицистик лексикасының төрле тематик катламнарын очратырга мөмкин: *байлар, әфәнде, мәйдан, фәкыйрь, мөдәррис, шәкерт, сабак, остаз, карый, сәүдә;* дини лексика: *капу, зәкят, язык, дога*; хәрби лексика: *дошман, сакчы, башчы, көбә, яу, солдат* һ.б.

Билгеле булганча, XIX гасырда иҗтимагый-публицистик стильдә сәяхәтнамә жанры үсә (Алеева, 1990: 19). Ш. Мәрҗанинең 1880 елда Гарәбстанга барган сәяхәт язмалары, Р. Фәхретдиновның «Рихләт әл Мәрҗан» (1897) сәяхәте, Ф. Кәриминең «Европага сәяхәт»е (1907) һ.б. аерым басма булып чыга. Бу әсәрләрдә XIX гасыр иҗтимагый-публицистик лексикасының үсеше күзәтелә. Иҗтимагый-публицистик лексиканың түбәндәге лексик катламнарын билгеләргә мөмкин:

а) иҗтимагый-сәяси лексика: *мәгариф, мәдәният, зарурият, пайтәхет, хөкүмәт, прогресс, халык, фәлсәфә, демократия, газета, наданлык, матбугат* һ.б.;

ә) дини лексика: *капу, зәкят, язык, дога* һ.б.;

б) нейтраль лексика: *терсәк, йимеш, кош егет, сабан, хайван, бару* һ.б.;

в) мәгариф өлкәсенә караган лексика: *мөдәррис, шәкерт, сабак, остаз, галим* һ.б.

XIX гасырның иҗтимагый-публицистик лексикасында рус-европа катламы билгеләнә: *программа, адресат, жандарм, машина, коридор, велосипед, телефон, консул, эрмираж, салон, микроскоп, ресторан, композитор, бюст, плацкарт, фабрика, скрипка, артист* һ.б.

Билгеле булганча, XX гасыр башында – 1905 елда Петербургта беренче татар газетасы «Нур» чыга башлый. XX гасырның иҗтимагый-публицистик лексикасының үсешендә «Азат хатын», «Фикер», «Әлгасрелҗәдит», «Әлислах», «Уклар», «Яшен», «Ялт йолт», «Кармак», «Аң» кебек прогрессив-демократик газета һәм журналларның роле зур. XX гасыр башында татар телендә вакытлы матбугатның барлыкка килүе иҗтимагый-сәяси лексиканың, яңа төшен-

чәләрнең, фразеологиянең формалашуына һәм үсешенә төп сәбәп булып тора. Алдынгы иҗтимагый фикерне чагылдырган матбугат татар халкының иҗтимагый-сәяси аңын үстерә. Газеталарда иҗтимагый-демократик идеяләрне тараткан мәкаләләр, большевиклар сәясәтен аңлаткан прокламацияләр тәрҗемә ителә, шул рәвешле, иҗтимагый-публицистик лексикасының кулланылыш даирәсе киңәя, моңа кадәр булмаган терминнарны уйлап табу, рус теленнән тәрҗемә итү, калькалаштыру ихтыяҗы барлыкка килә. Татарча яңа иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне атау өчен халык телендәге сүзләргә яңа мәгънә биреп кулланыла башлый һәм алар термин булып та китәләр (Алиева, 2007: 12). Аерып алып әйткәндә, иҗтимагый-публицистик лексиканың, гомумән, публицистиканың активлашып китүе XX йөз башы инкыйлаб хәрәкәтенә бәйле карала. Иҗтимагый-публицистик лексика XX гасыр башында төрле иҗтимагый-сәяси вакыйгалар тәэсирендә аерым иҗтимагый-сәяси төшенчәләр барлыкка килү нигезендә үсеш ала. Алар татар теленең үз сүзләре нигезендә, шулай ук алынмалардан формалашып, төрле мәгънә төркемнәрен тәшкил итәләр: *патриот, хөррият, азат, демократия, коммунизм, марксизм* һ. б. Шулай итеп, XX йөз башы татар әдәби телендә иҗтимагый-публицистик лексиканың барлыкка килүе, үсеш-үзгәреше ягыннан гаять үзенчәлекле чор булып карала.

XX гасырда гомумкулланылыш лексикасына иҗтимагый-сәяси төшенчә бирә башлау күзәтелә: *Көрәшкә **сәяси төс** бирү* («Яңалиф», 1930); *Колхозларда терлек-туарны **уртаклашу*** («Яңалиф», 1930) һ.б. Бу чорда иҗтимагый-публицистик лексиканың түбәндәге лексик катламнары билгеләнә: икътисад белән бәйләнешле лексик катлам: *милек, хезмәт, сәүдә, базар, кризис, бюджет, мануфактура, кредит, кыйммәт, касса, бурыч, хезмәт сәгатьләре, дөнья базарлары, эш хакы, хезмәт вакыты, эш көне, кол хезмәте, вексель, банкрот* һ.б.; мәдәният, мәгарифкә бәйләнешле лексика: *мәктәп-мәдрәсә, мәгариф, гуманизм, гимназия, университет-дәрелфөнүн, ислахчы-реформаторчы, газета, театр, мәдәният-культура, белем, фән, гыйлем, мәгърифәт, мөдәррис* һ.б.; дини лексикага зур урын бирелә: *суфи, савап, мөселман, шәкерт, мулла, мөәзин, ишан, мөфти, хәзрәт, казый, мәчет, хаҗи, фатиха, газраил, исламият, җәннәт, җәһәннәм, кыямәт, тамуг* һ.б; хәрби лексика да чагылыш таба: *батальон, полк, демобилизация,*

*казак, полковник, подполковник, арсенал, сугыш, граната, офицер, рота, хәрби, дружина, орден, повестка, капитуляция* һ.б.

Шулай ук, XX йөзгә караган иҗтимагый-публицистик лексика эчендә совет чорының төрле өлкәгә караган терминологиясе үсеш ала: юридик терминология: *адвокат, судья, дипломат, амнистия, прокурор;* сәнәгать өлкәсенә караган терминология: *станок, машина, тукучы, ситсы, фабрика, завод, винт, машинист, промысел, мастерской, инженер* һ.б.; медицина өлкәсенә караган терминология: *доктор, чахотка, аптека, врач-табиб* һ.б.; канцелярия һәм администрация эшләренә караган терминнар: *план, отчет, писарь, жаргон, председатель, контора, бюро, акт, мэр, циркуляр, урна, доклад, реферат* һ.б.

XX гасыр башында иҗтимагый-публицистик лексиканың күп өлешен тәшкил иткән халыкара кулланылыштагы түбәндәге сүзләр татар теленең сүзлек составында ныгып кала: *пролетариат, большевик, революция, коммунистлар партиясе, крестьяннар массасы, социализм* һ.б.

XX йөз башында татар әдәби телендә иҗтимагый-публицистик фразеология дә киң кулланыла. Бу төр фразеология татар теленең үз сүзләре байлыгы хисабына үсә. Гарәп-фарсы алынмалары, сүзлек составына алынып, күптәннән татар телендә үзләштерелгән һәм терминлашу процессын үткән сүзләр фразеологик әйтелмәләр һәм сүзтезмәләр ясауда актив катнашалар: *авыз хәбәре, акылың әфләтун, баш өсте, бер сәгатьлек хәлифә, дуслык кулын сузу, дәүләт кошы, дөнья кайгысы, ил-көн итү, исеме җәелү, каняшь түгү, кеше хакы* һ.б.

Иҗтимагый-публицистик лексик катламны тәшкил иткән фразеологик әйтелмәләр эмоциональ-экспрессив, субъектив бәяләү төсмерләренә ия булалар: *җанлы мал, тере мал, җанлы корал* тезмәләрендә кешеләрнең авыр тормышы, аларның товар һәм корал ролендә йөрүләре күз алдына килә.

Хәзерге чор татар теленең иҗтимагый-публицистик лексикасы эчендә, стильара лексика белән беррәттән, иҗтимагый-сәяси өлкәгә генә хас лексика киң кулланыла: *дискриминация, геноцид, антогонизм, неофашист, агрессия, акция, ратификация* һ.б. Мәсәлән: ***Парламент** җитәкчесе әйтүенчә, **республиканың норматив хокукый актлары** һәм **гамәлдәге законнары** тупланган, рәсми системалаштырылган җыентык нәшер итү буенча башкарылган*

*эш әһәмияткә ия* («Ватаным Татарстан»). ***Дәүләт Советы Президиумы*** *регламентка таянып эш итте.* ***Президиумның*** *7 утырышында 146 карар кабул ителде* («Мәдәни җомга»). ***Татарстан Республикасының суверенлык Декларациясе****, бөтен халык тавыш бирү юлы белән билгеләгән статусы яңа* ***конституция*** *проектына нигез итеп алынды, халыкара стандартларга җавап бирә торган* ***конституция*** *эшләргә тырышылды* («Мәдәни җомга»). ***РФ Дәүләт Думасында*** *соңгы елларда урнашкан сәяси идиллия 11 октябрьдә үткән бердәм сайлау ноктасыннан соң бераз какшый төште кебек* («Мәдәни җомга»). ***Дәүләт Советындагы фракцияләр, депутат берләшмәләре*** *турындагы 7 нче маддә яңача бәян ителә* («Мәдәни җомга»).

Иҗтимагый-сәяси лексика гарәп-фарсы алынмалары нигезендә генә түгел, халыкара сүзләр нигезендә дә үсеш ала: *Туплар гөрелдәгәндә* ***демократия*** *турында сөйләү уңайсыз* («Татарстан»); ***Терроризмга*** *каршы көрәш ачарга кирәк булганда, яисә дус булмаган дәүләт белән хәрби каршылык булганда демократлар пәрдә артына кереп посу ягын карыйлар* («Татарстан»).

Иҗтимагый-сәяси лексиканың мәгънә ягыннан төрле төркемнәре бар. Иҗтимагый-сәяси сүзләр җәмгыять, дәүләт төзелеше, хөкүмәт, иҗтимагый тормыш мәсьәләренә караган һәм, шулай ук, икътисад-финанс өлкәсенә бәйләнелешле текстларда аеруча күп кулланыла: *Россия Федерациясе, акционерлашу, олигарх, валюта, көндәшлек* һ.б.: *Әлеге документта гамәли мәсьәләләрне чишү юллары, дәүләт дәрәҗәсендә* ***этник вазгыятьне*** *даими тикшереп тору зарурлыгы күрсәтелә* («Татарстан»). *Кайбер язмаларда хәтта* ***милли яңарыш*** *турында да сүз бара, әмма әлеге «яңарыш» төшенчәсенең нәрсәне аңлатуы турында берни дә әйтелми* («Татарстан»). ***Республиканың*** *гына түгел, башкаланың да* ***мәдәният концепциясе*** *төзелү хуплауга лаек* («Шәһри Казан»).

Хәзерге әдәби телнең иҗтимагый-публицистик лексикасы эчендә икътисад терминнарының алынма катламы сан ягыннан зур өлешне тәшкил итүе белән аерылып тора. Аларның бер өлеше, яңа күренешләрне атау өчен, телебезгә соңгы елларда кергән булса, телдә инде кулланылыш алганнары яңадан активлашып китә: *менеджмент, маркетинг, арендачы, аукцион, яллы хезмәт, икътисади кризис, депозит, дивидент, хосусый милек, валюта курсы* һ.б.: ***Бюджетка кергән акча****ларның күп өлеше, ягъни*

*40 проценты* ***өстәмә кыйммәт салымына*** *туры килә* («Ватаным Татарстан»).

Рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән телебезгә яңа алынмаларның үтеп керү процессы бүгенге көнгәчә дәвам итә. Аеруча иҗтимагый-сәяси һәм икътисади өлкәгә караган лексика һәрдаим баеп, тулыланып тора: *приватизация, брокер, дилер, референдум, мэрия, кризис, вотум, сепаратист, диаспора, гуманитар фонд, дотация, гиперинфляция, евро, электрон акча, дисконт карта*. Мәсәлән: *Өстәмә* ***брендларны*** *үстерүдә башка, һәрбер мәдәни мирас белән бәйле булмаган, әмма шәһәргә килүчеләрне төрлеләндерүче һәртөрле продукт формалаштыруы бурычы тора* («Татарстан»). *Бәлки* ***ной-хау*** *тәртибендә эшләргәдер*? («Татарстан»). «*Белем бирүдә* ***когнитив технологияләр*** *» – дигән* ***инновацияле проектны*** *сынау башланды* («Татарстан»).

Шулай ук иҗтимагый-сәяси сүзләрне ясауда алынма алкушымчалар (префикслар) катнаша ала: *архимөһим, супервакыйга, минисугыш, гиперинфляция, антикешелеклелек* һ.б. Мәсәлән: *Дмитрий Козак җитәкләгән* ***суперминистрлыкка*** *(алдын-артын уйламыйча) ышанып, административ реформа үткәрүне дәвам итте* («Татарстан»). *Гаҗәпләндерү дигәннән, шоу-бизнеста шаккатыру* ***пиар-адым*** *киң таралган* («Сәхнә»).

Хәзерге көндә иҗтимагый-сәяси, икътисади терминологиягә караган сүзләр кулланылыш ягыннан үзенчәлекле. Терминнарның семантик яктан үзгәреш процессларын деидеологизация термины белән атап йөртәләр. Бу күренеш сүзгә хас идеологик төсмерләрнең бетүе, яңа коннотацияләрнең барлыкка килүе, яңа һәм элеккеге коннотацияләрнең экспликациясе, лексемаларның телдәге пасссив фондка күчүе, яңа лексеманың барлыкка килүе, сәяси терминнарның идеологик коннотацияләрдән арынуы белән бергә үрелеп килә (Современный русский язык, 2008: 544). Мәсәлән: *инфляция, концерн, приватизация, эшкуар, эшсезлек* кебек сүзләр Совет чорында чыккан сүзлекләрдә капитализм һәм буржуазия төшенчәләре дип билгеләнсәләр, бүген исә бу алар икътисади терминология итеп кенә каралалар.

Моннан тыш, ярымкалька рәвешендә, татар теленең тезмә сүзләр калыбына нигезләнеп килеп кергән алынма сүзләр дә бар: *агросәнәгать комплексы, холдинг компаниясе, мобиль телефон, ислам фундаментализмы, дәүләт казнасы министры* һ.б.: *Русия*

*кайбер **гаммәви мәгълүмат чараларында** бу җәһәттән шундук, «Украина хакимиятләренең башбаштаклыгы», «тыныч акцияләрне тыю» кебек «гаепләүләр» пәйда булды* («Мәдәни җомга»).

Иҗтимагый-публицистик лексика эчендә юридик терминнар да каралалар: ***Җинаять кодексының** берничә маддәсе кысаларына эләгүче гамәлләрнең күбесе хокук саклау органнары тарафыннан ачыла* («Мәдәни җомга»). ***Министрлыклар, ведомстволар** һәм җирле үзидарә органнары үзләре әзерләгән **хокукый акт** проектына яки үзләре чыгарган хокукый актка коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында **Министрлар Кабинетына** тәкъдим кертергә хокуклы* («Мәдәни җомга»). *Татарстан буенча **Эчке эшләр Министрлыгының** икътисади җинаятьләргә каршы көрәш идарәсе оперативниклары фаш иткән очракны мисалга китереп була* («Мәдәни җомга»).

Иҗтимагый-публицистик лексика төрле өлкәгә караган терминнар һәм сөйләм теленә хас сүзләр нигезендә үсә. Иҗтимагый-сәяси терминнар, юридик терминнар, икътисад терминнары белән бергә, башка фән өлкәләренә караган терминнар *(медицина, психология, спорт, математика, биология, география, музыка, сәнгать)* катламы иҗтимагый-публицистик лексиканың үсешен тәэмин итә: ***Атеросклероз – артериядә** була торган **хроник авыру*** («Ватаным Татарстан»). ***Талпан үрмәкүчләре** – ... калкансыманнарның һәм **бөҗәкләрнең** ераграк туганы* («Татарстан яшьләре»). Аерым алганда, иҗтимагый-сәяси лексиканың үсеше терминнарның метафоралашуы нигезендә дә бара: *паспорт, банк «кенәгәсе», акча янчыгы, юл йөрү билеты* һ.б.: *Тиздән бу сүзләрнең барысын да бер сүзтезмә – **«электрон карта»** алыштырырга мөмкин* («Мәдәни җомга»). *Тиздән **«электрон капчык»** хезмәте кулланыла башлап, аңа акчаны кирәк булган теләсә кайсы вакытта салып булачак икән* («Ватаным Татарстан»). Биредә *электрон карта* сүзтезмәсе нигезендә *электрон капчык* сүзе барлыкка килә. Соңгы елларда иҗтимагый-публицистик лексика метафоралашу юлы белән барлыкка килгән лексик берәмлекләр исәбенә арта башлады.

Иҗтимагый-публицистик лексиканың эчендә газетизмнар да (газета телендә кулланылган лексик берәмлекләр) каралалар: *алдынгылар, йөкләмә, хәлиткеч, алдынгы саф, беренчеләрдән булып, глобализация, кризис, мәкалә, гәүдәләнеш, эчтәлек* һ.б. Шулай ук фразеологик газетизмнарны да билгеләргә мөмкин: *яшел урам,*

*буыннар ярышы, сәүдә челтәре, бай тәҗрибә* һ.б.: *Россиянең мәңге* ***«яшел» сораулары*** *– кем гаепле һәм нәрсә эшләргә?* («Ватаным Татарстан»). Газетизмнар даими рәвештә, вакытлы басмалар телендә күп тапкырлар кабатланып килеп, стандартлашалар һәм гомумкулланылыш сүзләреннән аерыла башлыйлар. Шул рәвешле, газета-журналларда оператив көндәлек характердагы калыплашкан гыйбарәләр барлыкка килә: ***Демократия җилләре*** *татарлар белән, татар теле белән кызыксынучы яшьләрне безгә алып килде* («Ватаным Татарстан»). *«Бердәм Россия» партиясе* ***сәясәт мәйданында*** *аерым урын алып тора. Иң мөһиме – җир республикада* ***халык файдасына*** *эшли»* («Ватаным Татарстан»).

Иҗтимагый-публицистик лексикада, иҗтимагый-сәяси лексикадан тыш, әдәби телнең төрле стильләрендә гомумкулланышта булган сүзләр, төрле лексик катлам берәмлекләре зур урын ала: дини лексика: *мулла, хәзрәт, диния нәзарәте, мөфти, мөәзин, шәригать, икона, патриарх, хач тагу* һ.б. Мәсәлән: *Татарстан Республикасы Диния нәзарәте һәм ТР Министрлар кабинеты каршындагы* ***Дин эшләре идарәсе мөфтият*** *бинасында күренекле* ***дин әһелебез*** *Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Основы исламской культуры» китабын тәкъдим итү кичәсе уздырылды* («Ватаным Татарстан»). *Раббыбызның кушканнары Коръәндә язылган һәм пәйгамбәребез* ***хәдисләре*** *аркылы безгә ирешкән* («Ватаным Татарстан»). *Коръән дә бөтен Галәмнең тәрбиячесен олылаган һәм мактаган* ***«Фатиха» сүрәсеннән*** *башланып китә* («Мәдәни җомга»).

Төрле урынчылыкка караган җирле сөйләм сүзләре дә иҗтимагый-публицистик лексика эчендә кулланылалар. Диалект сүзләргә мөрәҗәгать итү, беренчедән, авторның чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерү, тормыш-көнкүрешне тулырак сурәтләү һәм тирәнрәк ачуга ирешергә, икенчедән, мәкаләгә индивидуаль стиль төсмерләре бирү, сөйләмне җирле тел үзенчәлекләре белән баету, катнашучыларның гореф-гадәтләре, холкы, милли колориты белән тулырак таныштыру өчен төрле максатлардан чыгып эшләнә. Диалекталь сүзләр аерым стильләргә, шулай ук әдәби телгә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаганда, һәм публицистикада исә әңгәмәдәшнең, персонажның сөйләм үзенчәлекләрен сурәтләү өчен кулланыла (ул бигрәк тә, репортаж жанрында киң таралган): *«****Яренгә*** *тагын да зуррак уңышлар белән куандырырбыз әле», – диде колхоз рәисе* («Ватаным Татарстан»). Бередә *яренгә* – киләсе елга дигән-

не аңлата. Әлеге сүз урта һәм мишәр диалектларында билгеләнгән (ТТЗДС, 2009: 243).

Шулай ук газета-журнал битләрендә күп санда варваризмнарны – чит тел сүзләрен очратырга мөмкин: *Соңгы елларда шәһәр урамнарында төсле буяулар белән «**кальян** өчен катнашмалар», ‘**Aroma**’ дип язылган такталар эленгән кечкенә кибетләр пәйда булды. Инде алкоголь, тәмәке тарту белән генә канәгатьләнмәгән яшьләр **Spise, Tigrin, Dream** да шушы хуш исле катнашмаларга кызыга башлады. Ә нигә әле татып карамаска янәсе?* («Шәһри Казан»). *Инде **Gucci, Prada** брендлы киемнәргә килгәндә, мондый киемнәр безнең кебек гади халык сатып ала алырлык түгел шул* («Шәһри Казан»).

Иҗтимагый-публицистик лексика эчендә окказионализмнар да каралалар. Алар журналист неологизмы булып, телдә төшенчәне белдерү өчен сүз булмаган очракта *(култамга),* язмага иҗади җанлылык кертү максатында *(бәйрәмдәр),* предметка, күренешкә бәя бирү *(шаккатаризм),* кирәкле бәяләү төсмерен ассызыклау *(күпбелмешләр, үзбилгеләнү)* максатында кулланылалар. Әлеге сүзләр автор неологизмы, ягъни окказиональ лексика булып иҗтимагый-публицистик лексика составында карала: ***Әйдаманлык** ул – хезмәт, ялкауланырга ирек бирми* («Шәһри Казан»). *Башкалага **күпбелмешләр** килә* («Мәдәни җомга»). *Яңа елны чит илдә уздырган юк иде әле. Уйлаштык-уйлаштык та, юл букчаларын җилкәгә асып, юлга кузгалдык. Маршрутыбыз **шаккатаризм** үрнәге түгел* («Мәгърифәт»). ***Култамгалар** куеп урамга чыккач кына Зилә аякларының мамыктай йомшаруын сизә* («Сөембикә»).

Шулай ук иҗтимагый-публицистик лексика эчендә а р г о сүзләр дә очрый: *Бәлки, сез сөеклегезнең чираттагы «**пассиясе**» гендер* («Ватаным Татарстан»). *Бездә һаман шул инде – һөнәрманнарны **блатлылар** кысрыклый* («Татарстан яшьләре»).

Иҗтимагый-публицистик стильдә өстенлек алган бәяләү төсмере ялгызлык исемнәрен тәгъбир итүдә гаять үзенчәлекле прагматик вазифа үти. Ялгызлык исемнәрнең прагматик кулланылышы тискәре мөнәсәбәт белдергән терминнар ясалышына этәрә, алар публицистик стильдә зур урын алалар: *Гитлер Германиясе, Буш ботлары, Питрәч тавыклары* һ.б.: *Импортка табынучы «**Буш ботлары**»на да ихтирам белән карый, аның сөягенә кадәр черегән булуына күз йома* («Ватаным Татарстан»).

Иҗтимагый-публицистик лексика эчендә иҗтимагый-сәяси фразеология аерым урын тота. Иҗтимагый-публицистик фразеологиянең ясалу һәм үсеше төрле сәбәпләргә һәм чыганакларга барып тоташа. Илдә, җәмгыятьтә барган кискен, каршылыклы вакыйга, ситуацияләрне ачык һәм тәэсирле рәвештә укучыга җиткерү өчен аерым фраза килеп чыга. Әлеге фразеологик берәмлекләр килеп чыгышы ягыннан түбәндәгеләргә бүленәләр:

а) татар теленең үз сүзлек хәзинәсеннән үсеп чыккан фразеологизмнар: *Рәсәйдә беркайчан да карарга кытлык булмады. Киресенчә, халык **ачка кырылып яткан** елларда да югарыдан хөкүмәт карарлары яуды* («Ватаным Татарстан»);

ә) рус яки рус теле аша кергән Көнбатыш алынмалары хисабына формалашкан фразеологик берәмлекләр: *Ләкин алдан ук шуны да әйтеп куярга кирәк – халыкта Сталинга карата капма-каршы мөнәсәбәт иде: берәүләр аңа ачыктан-ачык, **итеген ялардай (лизать сапоги)** булып табынсалар, икенчеләр йөрәгендә бик тирән яшеренгән, мәңге бетмәс ачы ләгънәт ята иде* («Ватаным Татарстан»);

б) чит телдәге фразеологик әйтелмәләрене калькалаштыру ярдәмендә барлыкка килгән берәмлекләр: *Ул Россиядәге соңрак **«яхшырак булсын дигән идек тә» (хотелось как лучше)** дигән даһи тәгъбирдә чагылыш тапкан мәгълүм традицияне раслады* («Татарстан»);

в) гомумхалык теленә нигезләнгән индивидуаль-автор фразеологизмнары: *Чын, табигый ачлык әле башланмаган булса да, кытлыкның **сәяси-психологик өрәге** Совет кешеләренең бугазынаябышкан* («Ватаным Татарстан»);

г) халыклар, телләр арасында бәйләнеш нәтиҗәсендә рус телендәге фразеологизмнарның тәрҗемәсез бирелүе: *Пушкин бу турыда «**Не оспаривай глупца**» дигән. Инҗил исә «**не рассыпай свиньям жемчуг**», дип кисәткән* («Ватаным Татарстан»).

Гомумән, тематик яктан иҗтимагый-публицистик лексиканың гаять төрле, анда киң иҗтимагый-сәяси фразеология зур урын алып тора, тел хәзинәсен баетуда әһәмиятле вазифа үти. Хәзерге иҗтимагый-публицистик лексика бары тик иҗтимагый-публицистик стиль кысалары белән генә чикләнми. Әлеге төр лексика башка стильләргә дә күчә ала, ягъни сүзләр функциональ чиклелектән азат кыләләр. Функциональ яктан чикле булган сүзләрнең

(диалекталь сүзләр, жаргонннар, арго, сленг, гади сөйләм сүзләре) иҗтимагый-публицистик стильдә кулланылышы шулай ук гадәти күренеш.

## § 37. Матур әдәбият теле лексикасы

Матур әдәбият теле лексикасы дип әдәби текстта образлылык, конкретлык, эмоциональлелек максатларында кулланылган төрле сүзләр төркемен атыйлар (Словарь лингвистических терминов, 2010: 173). Матур әдәбият теле лексикасы үзенең сәнгати-эстетик сыйфатлары, образлылык, эмоциональ-экспрессивлылыкны формалаштыруда зур роль уйнаган лексик катламнарның кулланылышы белән дә аерылып тора. Укучыга эстетик тәэсир итү һәм тәрбияви йогынты ясау – матур әдәбиятның төп максаты. Язучы бу максатка ирешүдә, гомумкулланылыштагы сүзләр белән бергә, эмоциональ-экспрессив лексикага, көнкүреш лексикага, окказиональ сүзләргә, диалекталь лексикага мөрәҗәгать итә. Аерым әйткәндә, матур әдәбият теленең лексикасы катламнарга бай һәм һәрбер лексик катламга функциональ-стилистик вазифа йөкләнә. Сүз белән сурәт ясау, иң беренче, сүзнең номинатив мәгънәсенә нигезләнә. Матур әдәбиятта бары тик кешегә, укучыга тәэсир итү максаты гына куелмый, ә идея һәм фикерләрне сүз ярдәмендә үзенчәлекле ысул белән ачып бирү дә максат ителә.

Әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган мәгънә белән баетылган сүз сүз-сурәт дип атала. Ул тел сурәтләү чаралары белән үзара төрле мөнәсәбәтләргә кереп, әдәби әсәрдә образлы яңгыраш хасил итә. Татар әдәби теленең үсеше матур әдәбият теле лексикасының үсеше белән тыгыз бәйләнеш-мөнәсәбәттә булып, татар әдәбиятының төрле жанрларында чагылыш таба. Язучы теле – индивидуаль сәнгатьчә югарылыктагы халык теле. Сүзнең мәгънәви һәм стилистик мөмкинлекләре бары тик контекстта, әдәби әсәр эчендә ачыла (Бәширова, 2008: 25). С. Поварисов исә язучыларның, шагыйрьләрнең сүзнең тышкы матурлыгын ясау максатында, сүзнең эчке мөмкинлекләрен аңламыйча, сүз мәгънәсен үзгәртү, телгә төрле окказиональ сүзләр кертү белән мавыгу нәтиҗәсендә халыкка аңлашылмаган төрле абстракт сүз-образларның барлыкка килүен искәртә (Поварисов, 2009: 32). Хәзерге чорда язылган әдәби әсәрләрдә сүз байлыгы арта, киңәя бара. Матур әдәбият теленең лексик катламнарының үсеше сүз мәгънәләренең киңәюендә дә

чагыла. Телнең тарихи үсеше процессында сүзләр яңа мәгънәләр һәм төсмерләр белән баетылалар, шул рәвешле, сүзләрнең семантик кыры киңәя. Мәсәлән: *Дуңгызларның **җыбылдык** исе Хөсниттәйнең ихата-курасында икенче язга да сакланып калган иде әле* (М. Галиев). *Җыбылдык* сүзе бередә «әче ис» дигәнне аңлата.

*Үсегез, үс, ирек пәрвәрләре,*
*Чүпләр үстермәгез арага,*
*Егерме беренче гасырга кол керү*
*Гөнаһ татар дигән **карьяга*** (А. Хәлим).

Биредә автор *карья* сүзенең «даирә» мәгънәсендә бирә, искергән сүз образлы фикерне укучыга җиткерү максатын үти.

Югарыда искәртеп үткәнчә, матур әдәбият теле лексикасы кулланылышы ягыннан һәр катламны да чагылдырырга мөмкин. Биредә шактый иркен рәвештә китап теле лексикасы, сөйләм теле берәмлекләре янәшә кулланыла ала. Аның нигезен гомумкулланылыш сүзләре алып тора. Шулай ук кулланылыш даирәсе ягыннан чикле булган диалект сүзләр, фразеологик берәмлекләр, мәкаль һәм әйтемнәрне әдәби әсәр тукымасына кертеп, экспрессив-эмоциональ төсмерләрне артттыру максаты да үтәлә.

Диалекталь сүзләрнең әдәби телебезне баету мөмкинлекләре чиксез булып, әлеге сүзләр җирле төбәктәге вакыйгаларга бәйле рәвештә текстка гаять табигый килеп керәләр. Н. Әхмәдиевнең «Амбирак яки кара каен кыйссасы», Я. Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт» әсәрләрендә җирле сөйләш сүзләре урынлы кулланылалар һәм сурәт ясауда гаять матур яңгыраш алалар. «***Торна күз** (мүк җиләге) белән эч, кузыем, – диде Бибикамал әби, янып торган мүк җиләге салынган савытны миңа табан этәреп, – циягә (нарат җиләге) хәзер үзем җөри алмаем кый, узган көз оныгымның кызы җыеп алып кайткан иде* (Н. Әхмәдиев). *Торнакүз* сүзе бараба, тара, тобол сөйләшләрендә *мүк җиләген* аңлата (ТТЗДС, 2009: 640).

*Тезелегез рәткә сыбызгылар!*
*Мунча кертәм сезне ышыкта!*
*Үзегез күк сасык, бозлы суда,*
*Себеркесе яхшы **шелектән***.

Әлеге шигъри юллардагы *шелектән* сүзе урта диалектның стәрлетамак, минзәлә сөйләшләрендә теркәлгән (ТТЗДС, 2009:

785). *Мазар зиратына барып, **башбаталарны** укып кара, анда әкәмәт ташлар бар* (Э. Касыймов).

Матур әдәбият лексикасында тарихи сүзләр, искергән сүзләр әһәмиятле урын тоталар. 80 нче еллардан соң татар әдәбиятында тарихи мираска игътибар көчәю матур әдәбият телендә тарихи сүзләрнең артуына китерә: *корымлы*, *ата-кам* (Сөләйман) һ.б. Матур әдәбият телендә яңадан кулланылышка кереп бара торган, телдә кабат торгызылган тарихи сүзләр актив кулланылалар: *багавыл, баек, байса*, *балга* һ.б.: *Төлке тимернең боларга бик эче янса да, берни кыла алмый, кулларында – **хан байсасы*** (Р. Зәйдулла). *Байса* сүзе «аерым хокук бирелүе турында язылган тактачык» дигәнне аңлата (ТТАС, 2015: 385).

Автор тарафыннан матур әдәбият теленә кертелгән неологизм яки окказиональ сүз мәгънә төсмерен бирә, татар телендә предмет яки төшенчәнең мәгънәсе булмаган очракта гаять уңышлы файдаланыла:

*Сиңа ошармы бу бүләк – Ядкәрем?*
*Ни кичерсәм, язган көндәлекләрем...*
*Нindидер бер сихри нурың кагылгач,*
*Җанда үскән яңа **Гөлдәлекләрем!***
*Янган минем яшьлекнең шәп Китабы!–*
*Көле –монда, Сиңа **көлдәлекләрем?!***
*Күңелдәлекләремдә яңа Бәхетемме?*
*Булыр мәллә буш Өметдәлекләрем?!*
*Бел, дәфтәр түгел, антым көннәргә –*
*Ай елларга! Ул – **Гомердәлекләрем!*** (Р. Гаташ).

*Бөтерелә бөдрә **сырындылар,***
*Якын килергә дә шомлы ярда –*
*Гасырларның кара бураннары*
*Дулый бугай безнең карашларда* (Зөлфәт).

Зөлфәт «Сырындылар» исемле шигырендә көрт кәрнизен, бөдрә кар сырларын *сырындылар* дип атый.

***Санаклы**ны гына санлый дөнья*
*Таный дөнья, аңлый ... аңлаша;*
*Кырын ятып илләр чөкердәшә*
*Безгә кызык, безгә – тамаша*! (Г. Морат).

Бу очракта *санак* сүзе *компьютер* сүзе урынында кулланылган. Әйтергә кирәк, әлеге сүзләр хәзерге татар әдәби телендә бер синонимик парадигма кысасында кулланылалар:

> ***Җәйгорларны**ң*
> *Чагу төсе җитми*
> *Коеп яумый нигә яңгырлар?!* (Н. Сафина).

*Җәйгор* сүзе «салават күпере» дигәнне белдерә. *Ул зәңгәр һаваны күрде, төрле төсләргә буялганлыктан җиргә төшкән **җәйгорны** хәтерләтеп торган йортларны күрде* (М. Кәбиров). *Җәйгор* сүзе татар теленең аңлатмалы сүзлегендә билгеләнмәгән, әлеге сүз автор неологизмы булып тора. *...**кулчатыр** булмау, бигрәк тә яңгыр койганда, бик кыен хәл* (Р. Бәхтияр). *Кулчатыр* – зонтик дигәнне аңлата.

Соңгы еллар поэзиясендә яңа сүзләрне Х. Әюпов, Л. Зөлкарнәй, Р. Гаташ, Г. Морат, Р. Зәйдулла, Л. Шагыйрьҗан, М. Галиев һ.б. шагыйрьләр оста файдаланалар: *шатлыкташ, моңдаш, кайгыдаш* (Х. Әюпов), *халәттәш* (Л. Зөлкарнәй), *хыялдаш, хистәш* (Р. Гаташ), *сынчыбагар, талчук, гаптәш, шәриктәш, шәрабтәш* һ.б. (Г. Морат), *баш-изм* (Л. Шагыйрьҗан).

> *Явыз эттәй талашып*
> *Бу илне бүлешкәндә,*
> *Алтынчы палатада без,*
> *Илебез – **тилеханә*** (Зөлфәт).

Милләт, дәүләтчелек проблемалары турында язган шагыйрь Зөлфәт, дәүләтебезне образлы итеп *тилеханә* сүзе белән чагыштыра.

> *Татарстан – **ТӨТЕНСТАН**...*
> *Дәүләт тимерчелеге!*
> *Казан яшьләренең даны –*
> *Сугыш тукмаулар буенча*
> *Илдә «беренчелеге»* (Р. Фәйзуллин).

Экологик проблемадан чыгу юлларын эзләп, Р. Фәйзуллин Татарстанны *Төтенстан* белән тиңли. Шулай ук Татарстанны *Тетәрстан, Татырстан, Татарустан* кебек сүзләр белән дә алыштыруга корылган яңа сүзләр Р. Фәйзуллин иҗатының яңалыгын билгели.

Хәзерге поэзиядә күренекле шәхесләрнең фамилияләренә сүз ясагыч кушымчалар кушып, төрле мәгънәдәге сүзләр ясау бар-

лыкка килде: *Тукай+даш, Туфан+даш, Тукай+лык, Сәйдәш+лек, Такташ+лык,* һ.б. Әлеге сүзләр бөек шәхесләрнең иҗади мирасын киләчәк буынга җиткерү, күрсәтү кебек вазифа үтиләр.

*Тугандашлар –*
***Тукайдашлар, Туфандашлар***
*Шигъри сафка тезелгәч,*
*Дуслык юлы да нык булыр,*
*Җыр юлы да өзелмәс* (Ш. Галиев).

Матур әдәбият телендә кулланылган лексик берәмлекләргә *-даш/-тәш* сүз ясагыч кушымчалары ялганып, теләктәшлек, бергәлек мәгънәсен бирә: *камаздаш* (Р. Харис), *язмышташ* (Р. Харис), *күңелдәш, җандаш, кандаш* (Ш. Галиев), *кешедәш, шигырьдәш* (Зөлфәт), *бавырдаш* (М. Хөсәен), *сәламдәш* (Г. Садә), *шешәдәш* (Р. Мөхәммәдиев), *илдәш* (Ф. Дунай) һ.б.: ***Өстәлдәш, ризыкташ*** *булу – мәсләктәш булуга нигезләнгән* (М. Мәһдиев). *Яшәр идем мәгәр, әгәр җанга* ***җандаш*** *табылса* (Зөлфәт). ***Шәриктәшләр*** *идек без* (Р. Сибат) һ.б.:

*Шау шигырьле чорлар*
*Язгы шомырт*
*Чәчәк койган сыман сүтелде…*
*Шәриктәш тә,* ***шәрабташ*** *та булдык,*
*Бер иптәш тә булдык шикелле* (Зөлфәт).

Матур әдәбият телендә сүз сатира тудыру чарасы буларак та кулланыла. Мәсәлән, *-даш/дәш, -таш/тәш* кушымчасы ярдәмендә ясалган кайбер сүзләр сатирик пафосны бирү максатыннан кулланылалар. *Хөрмәтле* ***Кәҗәдәшләр*** *һәм кадерле кунаклар, – диде ул, сакалын селкетеп, – безнең бу съездыбыз ике мең дә өченче елның кәҗә тәкәләре елы булуга багышлана* (Т. Миңнуллин). Т. Миңнуллин парламентта утыручы депутатларны кәҗәгә охшатып, сатирик-юмористик пафоста *кәҗәдәшләр* дип атый.

Рус теленнән һәм рус теле аша кергән *интер-, -изм, микро-, супер-, макро-, нео-, мини-* кебек префикс һәм постфикслар ярдәмендә яңа сүзләр ясау киң кулланыла: *шаккатаризм, башизм, микроҗир, микрокешеләр, микробөекбозлавыклар, микрохалыклар, микродөнья* һ.б.: «*Миллилеге тәссезләнгән, ничәмә-ничә еллар урыс мәктәпләрендә үз тарихыннан, әдәбиятыннан аерылып*

*укытылган, татар теле кемгә кирәк, дип йөрүче ахмаклар сүзенә ышанып, чирләүче* ***«интертатарларыбыз»,*** *әйткәнемчә, тел дип сөйләшүчеләрне тар карашлылыкта, артта калганлыкта, милли чикләнүдә гаепли* (Т. Миңнуллин). *Илленче-алтмышынчы еллар арасында тормышыбызда хасил булган афәт –* ***интербарыбер*** (А. Хәлим).

Матур әдәбият телендә кушу юлы белән дә окказиональ сүзләр ясала: *сынчыбагар, талчук, моңсара, гөлбостан, шәһәрзадә, таңтирәк, автобашкала, илсез-өйсез, гөлсабыйлык* һ.б.:

*Мәңгегә ул сөйләсен*
*якты көн хатирәсен... –*
*Яулыгыңны да,* ***язгөл*** **(**Р. Гаташ).

*Сине уйлый, аргач, тәнең-җаныңны*
***Гөлсабыйлык*** *сагындырыр чагыңны* (Р. Гаташ).

Р. Гаташ кайбер нигез сүзләргә *гөл* сүзен кушу юлы белән яңа сүз барлыкка китерә. Нигездә *гөл* сүзе «матурлык, яшьлек» мәгънәсендә ачыла.

Димәк, матур әдәбият телендә окказиональ сүзләр фикерне укучыга көтелмәгән сүзләр ярдәмендә җиткереп, поэтик гаҗәпсенү хисе уятырга ярдәм итәләр. Автор тарафыннан билгеле бер максатларда кертеп җибәрелгән бөтен окказиональ сүзләр дә халык телендә актив кулланылышка кереп бетми. Бары тик уңышлы саналганнары һәм әлеге сүзгә ихтыяҗ булган очракта гына матур әдәбият теленең лексик составында тиешле урынын таба.

Матур әдәбият теленең лексикасында гади сөйләм сүзләре эмоциональ-стилистик максатларда аерым урын тоталар. Матур әдәбият телендә еш очраган һәм хәзерге әдәби телдә актив кулланыла торган гади сөйләм сүзләренең кайберләре: *бәлшәю, бәргәләш, беләмән* һ.б.: *Луизаның турсайган иреннәре* ***бәлшәйде*** (А. Гыйләҗев). Хәзерге татар әдәби телендә *бәлшәю* сүзе ямьсез булып җәелүне, чалшаюны аңлата (ТТАС, 2015: 461). *Бәлшәю* гади сөйләм сүзе автор тарафыннан экспрессивлыкны тагы да көчәйтү максатында кулланыла. «*Ну* ***умырасың!»*** *– диде Әхәт, ирен читләрен пөхтәләп сөртә-сөртә* (А. Гыйләҗев). Автор экспрессияне арттыру максатында күп итеп ашауны *умырасың* сүзе белән бирә.

Гади сөйләм сүзләренең матур әдәбиятка үтеп керү тенденциясе, татар әдәби телендә генә түгел, рус һәм башка әдәбиятлар-

да да чагыла (Сафиуллина, 1999; Рамазанова, 2006: 16). Алынмалар белән чагыштырганда, гади сөйләм сүзләренең күпләп үтеп керүе – әдәби тел лексикасына тискәре йогынты ясый торган күренеш. Әлеге процесс стильләрнең түбәнәюенә китерә, югары стиль юкка чыга, урта стиль аның урынын ала, түбән стиль урта стиль урынында кулланылышка керә, түбән стиль гади сөйләмгә әйләнә. Тормыштагы тискәре-дорфа күренешләрне чагылдыруны максат иткән язучылар вульгар сүзләрне дә экспрессив-стилистик максатларда әсәр тукымасына кертергә мәҗбүр булалар: *Ә инде* ***«уйнашчы», «фәхишә», «себерке»*** *кебек сүзләрне ишеткәч, килененең гөнаһ өстендә тотылуын фараз итте* (С. Поварисов). ***Әнәк эте*** *сыман шәһәр урамнары буйлап бик озак каңгырап йөрдек.* (З. Мәхмүди). ***Шарлатан! Дуңгыз! Буш куык! Хәшәрәт*!** (Р. Мөхәммәдиев).

Өч яки өчтән дә артык компонентлы парлы сүзләр матур әдәбият теле лексикасында эмоциональ-экспрессивлыкны, образлылыкны арттыру максатында кулланылалар. Парлы сүзләрнең функциональ-стилистик вазифаларын тикшереп, Ф. Сафиуллина әлеге сүзләрне «парлы сүзләрнең яңа бер төре» дип атый һәм урта буын романтик-лирик әдипләр иҗатына хас дип күрсәтә (Сафиуллина, 2006: 164–165). Өч яки дүрт компоненттан торган парлы сүзләр әдәби әсәрдә сурәт ясап, эмоциональ киеренкелекне арттыру максатында кулланылалар:

> ***Җандаш-кандаш-кардәш*** *буласылар –*
> *Тумаганнарым –*
> *Кояш күрмәгәннәрем* (Ш. Галиев).

*Безнең буын поэзиягә килгәндә, халык лирикага сусаган, лаф орулы* ***шалтыр-шолтыр-дөмберләрдән*** *тәмам гарык иде* (Ш. Галиев).

Матур әдәбият телендә кулланылган лексиканы тәшкил иткән сүзләр, поэтик чаралар авторның уй-кичерешләрен, яшәеш һәм көнкүреш үзенчәлекләрен, дөньяга карашын, образларның рухи дөньясын чагылдырырга ярдәм итәләр, шул ук вакытта язучының күренеш-вакыйгаларга, образларга мөнәсәбәтен дә ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Сүзнең сөйләүче яисә язучы өчен бик әһәмиятле, төрле образлар, сурәт ясау мөмкинлеге – аның мәгънә эчтәлегендәге билгеле бер образлылыкның булу-булмавы белән бәйле.

Матур әдәбият телендә кулланылган лексик берәмлекләр язучының поэтик акылын, уй-фикерләрен тел чаралары ярдәмендә тудырып, гомумиләштереп бирергә ярдәм итәләр. Әдәби әсәрдә тудырылган сүз, халыкның танып-белү эшчәнлегенә генә түгел, әдәби әсәрне сәнгати формалаштырган чынбарлык дөньясына да юнәлдерелә. Матур әдәбият телендә кулланылган сүзләр әсәрнең төзелеш материалын тәшкил итәләр һәм композицион элементлар белән турыдан-туры бәйләнештә торалар. Сүзнең мәгънәсе, әдәби әсәрдә үсеш алган сәнгати сурәтләүләр нәтиҗәсендә, мәгънәви яктан киңәя һәм байый, камилләшә. Татар әдәби телен баетуда мөһим роль уйнаган сүзләрнең семантик мәгънә үсешен өйрәнү – матур әдәбият теленең гаять актуаль бурычларының берсе булып тора. Матур әдәбият телендә, лексик катламнарында язучының сурәтләнгән дөньяга карата фикере, дөньяга шәхси мөнәсәбәте, тормышны күзаллавы чагыла.

## СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫ

### § 38. Сөйләм теле лексикасына гомуми билгеләмә

Тел һәм сөйләм уртаклыгын, милли телнең барлыкка килүен һәм үсешен, нормаларының билгеләнүен, стиль мәсьәләләре, функциональ стильләрнең бер-берсенә тәэсир итүен, әдәби әсәр телен өйрәнүне сөйләм культурасын, синтаксик синонимияне, диалект синтаксисын, фольклор синтаксисын, тел һәм сөйләм берәмлекләрен һ.б.ларның барысын да сөйләм теле үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча үтәп булмый (Сафиуллина, 1978: 6), чөнки с ө й л ә м т е л е – кешеләр белән аралашуда, фикер алышуда, гаилә, төбәк даирәсендәге көнкүрештә кулланылып, тормыш-көнкүрешне алып бару, сөйләшү һәм тәэсир итү вазифаларын башкара торган әдәби сөйләм төре. «Әлеге вазифаларның озын-озак гасырларга сузылган традициясе дәвамчан булган очракта, тел-сөйләм системасының җанлы сөйләмә һәм язма-әдәби формаларындагы яшәеше дә сөйләүче/язучы белән тыңлаучы/укучы арасындагы аралашуның нигезе булган фикерне хәбәр итүнең низам-тәртибен, ягъни сөйләмнең композицион төзелешен, сөйләүче/язучының мөнәсәбәтен белдерүдә тел берәмлекләренең дөрес сайлап файдалану үзенчәлеген тәшкил итә» (Татар әдәби теле, 2015: 10). Аралашуның гадәти шартларында әзерлексез башкарылган, стильара лексикадан бераз

түбән стильдә саналган сүзләр сөйләм теле лексикасын тәшкил итәләр. Әдәби сөйләм милләтнең формалашу чорында ук барлыкка килә, ул, милләт формалашканчы, диалектлар, ярымдиалектлар, шәһәр койнесе вазифасын башкара. Сөйләм теле тотрыклылыкка, диалекттан өстен булуга, күп функциональлек үзенчәлекләренә ия (Лингвистический энциклопедический словарь, 1990: 407). Ул кодификацияләнгән әдәби телгә каршы куела. Шуңа күрә, «сөйләм стиле» терминына синоним буларак, «түбән стиль» термины кулланылышта йөри (Винокур, 1980: 202).

Рус теле белемендә галимнәр арасында сөйләм теленә карата фикер төрлелеге яши: кайбер галимнәр аны, структур-системалы үзенчәлекләреннән чыгып, кодификацияләнгән әдәби телдән аералар, сөйләм телен мөстәкыйль бер тел күренеше итеп (Е. Земская, Ю. Скребнев) карыйлар; кайберләре исә аны әдәби телнең бер төре итеп (О. Лаптева, Б. Гаспаров) яки аерым бер стиль итеп (О. Сиротина, Г. Инфантова) билгелиләр. Рус теле белемендә сөйләм теле лексикасы шулай ук төрле юнәлешләрдә өйрәнелә: сөйләм телендә прецендент гыйбарәләрнең кулланылышы (Гунько, 2002); сөйләм теленең гендерлык аспекты (Беляева, 2002); метафора һәм чагыштыруларның сөйләм телендә образлы чара тудыру вазифалары (Яхина, 2007); рус сөйләм теле коммуникативларының лексикографик интерпретациясе (Казачихина, 2011) һ.б.

Төрки тел белемендә сөйләм теленең үзенчәлекләре, аның лексик катламнары башкорт телендә (Галяутдинов, 2008: 34–68), карачай-балкар телендә (Жашуев, 2009), якут телендә (Сорова, 2011), төрек телендә (Kaplan, 2005) өйрәнелгән.

Татар теле белемендә сөйләм теле мәсьәләсе инде XIX гасыр ахырына таба С. Күкләшев, М. Иванов, К. Насыйри, Н. Катанов хезмәтләрендә күтәрелә башлый. М. Иванов «Татар хрестоматиясе» хезмәтендә (Иванов, 1859: 3) сөйләм теле һәм китап теле төшенчәләрән аерып, сөйләм теле үрнәкләренә мәкаль һәм әйтемнәрне, җырларны, экиятләрне, рус әдәбиятыннан тәрҗемә әсәрләрен кертеп карый. Димәк, М. Иванов хезмәтләренә сөйләм телен халык җанлы сөйләменә тиңләштерү, халык авыз иҗатына якынайту омтылышы күзәтелә. Сөйләм теле турында мәгълүматлар С. Күкләшев, Н. Катанов хезмәтләрендә дә бирелә. К. Насыйри «Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах» хезмәтендә (1891) «сөйләм теле» төшенчәсенә түбәндәгечә аңлатма бирелә:

«сөйләм теле китап теленнән шактый аерыла, сөйләм теле гадирәк, китап теле гарәп һәм фарсы сүзләре белән чуарланган булганга, гади, укымаган халыкка авыр аңлаешлы була» дип яза (Насыйри, 1891: 3). XIX гасыр ахырында Н. Катанов сөйләм телен халык стиле белән тәңгәлләштереп, алынмалар кулланмыйча язылган әсәрләрне әлеге стиль катламында карый. Мәсәлән, Г. Фәезхановның «Хикәят вә мөлкәт», «Аю белән төлке», «Ябалак белән чыпчык турында», М. Салиховның «Табышмаклар һәм һәртөрле халык арасында әйтелә торган мәкальләр»ен ул шушы стиль катламына кертә (Катанов, 1898: 5).

XX гасыр башларында сөйләм теле мәсьәләсе, сөйләм теленә караган лексик берәмлекләрнең кулланылыш үзенчәлекләре Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Л. Җәләй, Ш. Рамазанов хезмәтләрендә күтәрелә. Сөйләм теленең синтаксик үзенчәлекләрен этрафлы өйрәнгән Ф. Сафиуллина сөйләм телен төгәл стиль үзенчәлекләре белән характерланган функциональ стильләрнең бер төре итеп карый (Сафиуллина, 1981: 87). Аның фикеренчә, сөйләм теле, нигездә, төгәл стиль үзенчәлекләре белән билгеләнә.

XX гасырның 90 нчы елларында сөйләм телен мөстәкыйль бер система буларак аерымлау тендециясе күзәтелә башлый. Бу тенденциянең башында И. Низамовның сөйләм телен милләтнең фикерләү һәм аралашу үзенчәлекләрен туплаган чагыштырмача мөстәкыйль система буларак билгеләве, хезмәтләрендә сөйләм телен беренчеләрдән булып сөйләмият дип атавы һәм аның төп берәмлекләре итеп, сөйләм иясен, сөйләм адресатын, сөйләм ниятен, сөйләм шартын күрсәтүе игътибарга лаек (Низамов, 1996; 2008: 1). Аның фикеренчә, «сөйләм – аерым бер шәхеснең конкрет максат (ният) тәэсирендә туган фикеренең икенче бер шәхескә (яки шәхесләргә) юнәлтеп, конкрет урынга, вакытка һәм башка шартларга бәйле рәвештә, нигездә тел ярдәмендә (шул ук вакытта телдән бүтән чараларны кулланып) оешуы һәм теге яки бу реаль формага кереп адресатка җиткерү һәм кабул итү системасы» (Низамов, 1995: 17; 2008: 10). Шул рәвешле, галим сөйләмне кешеләрнең үзара аралашу-аңлашулары вакытында уй-фикерләрен белдерү өчен кулланыла торган чаралар системасы итеп билгели.

Соңгы елларда татар теле белемендә сөйләм теле чикләрен билгеләү мәсьәләсе күтәрелде. Аны кодификацияләнгән әдәби телгә каршы куелган аерым бер система чикләрендә карау фикере ае-

руча игътибарга лаек (Галиуллина, Мубаракзянова, 2014: 58). Авторлар тарафыннан әлеге фикер берничә факторга таянып әйтелә: беренчедән, һәр кодификацияләнгән әдәби телнең функциональ стильләре аерым бер коммуникатив максатларда файдаланылса, сөйләм теле коммуникациянең һәм аралашуның бөтен төр чараларында да кулланыла; икенчедән, функциональ стильләргә хас булган аерым эмоциональ-стилистик чаралар белән билгеләнеп, бер элементлар белән икенче бер элементлар арасында контраст барлыкка килергә мөмкин. Сөйләм теле исә нейтральлек белән билгеләнә, сөйләм теленә генә хас аерым эмоциональ-экспрессив чаралар күзәтелми, шуңа күрә сөйләм телендә кулланылган чараларны башка функциональ стильләрдә катнашкан элементлар белән чагыштырып булмый (Галиуллина, Мубаракзянова, 2014: 59). Язма-китаби телнең җанлы сөйләм теленә тәңгәл күренеш булмавы, аларның кулланылышларында үзләренә генә хас хосусый вазифалары булуы турында «Татар әдәби теле тарихы»ның академик басмасында да әйтелә (Татар әдәби теле тарихы, 2015: 9).

Әдәби телнең сүзлек хәзинәсен үстерүдә һәм функциональ стильләрне төрле яклап баетуда җанлы сөйләм үзенчәлекләре зур урын тота (Хаков, 1985, 48; 2003: 13). Шуңа күрә әдәби телнең үсүе һәм камилләшү дәрәҗәсе аның халык сөйләменә якынлык дәрәҗәсе белән билгеләнә (Зәкиев, 1967, 22). Сөйләм теле лексикасы диалог һәм монологларда формалаша, әмма аңа сөйләшү процессында кулланыла торган барлык сүзләр дә керми, ирекле әңгәмәнең нигезен стильара лексика тәшкил итә. Сөйләм теле, аерым алганда сөйләү формасындагысы, генетик яктан, язма тел белән чагыштырганда, беренчел санала. Ул, нигездә, китап теленнән алданрак барлыкка килә (Земская, 2004: 4).

Сөйләм теле түбәндәге лексик катламнардан тора: 1) диалекталь сүзләр; 2) гади сөйләм сүзләре. Кулланылышы ягыннан чикле булган диалекталь сүзләр сөйләм телен баетуда аерым урын тоталар.

Татар халкының җанлы сөйләм үрнәкләрен теркәү, өйрәнү эше XVIII гасыр урталарыннан ук, Россия Фәннәр академиясе тарафыннан оештырылган, профессор Г. Миллер җитәкчелек иткән Себер экспедициясеннән башлана. А. Бессонов, Г. Әхмәров, Җ. Вәлиди, Л. Җәләй, Л. Мәхмүтова, Н. Борһанова, Д. Тумашева, Ф. Йосыпов, Д. Рамазанова, Ф. Баязитова, Т. Хәйретдинова, З. Садыйкова, Л. Арсланов кебек галимнәрнең татар диалектологиясе

үсешендә өлешләре зур. Диалекталь сүзләр сөйләм теле сүзләре белән һәрдаим бәйләнеш-мөнәсәбәттә булып, тулыланып торалар.

Алардан аермалы буларак, гади сөйләм сүзләре теге яки бу урынчылыкка, сөйләшкә карамыйлар, бәлки барлык диалект вәкилләренә дә аңлаешлы булалар. Гади сөйләм сүзләре конкрет күренеш әйберләрен белдерәләр һәм сөйләм экспрессиясенә бай булалар, мәгънәләре һәм эмоциональ төсмерләре ягыннан аерылалар. Аларның әдәби телдә кулланылырга яраксыз артык тупаслары да, битараф семантикага ия булган төрләре дә, матур әдәбият стилендәгеләре дә очрый: *Ә Илһам хан дошманга каршы һөҗүм оештырырга тиешле кеше, мәҗлес корып,* ***кыҗыкыян-дупыян*** *килеп эчеп ятты* (М. Әмирхан). *Эш дигәндә* ***урык-сурык*** *йөрмәде,* ***шырды-бырды*** *кеше белән сүз дә, табын да уртаклашмады* (А. Хәлим). Гади сөйләмнең бер төре саналган вульгар сүзләр – кешене кимсетеп, хурлап кешенең үзенчәлекле якларына, вульгар рәвештә, тискәре мөнәсәбәтен белдерәләр: *хәсис* «әшәке, түбән, начар», *бүкән* «кыска буйлы, юан, авыр хәрәкәтле яки булдыксыз, аңгыра кеше»: *Чыгып китегез,* ***хәсисләр,*** *өемнән, ханыгыз юк, мин Мәскәү патшасы Иван Васильевичның ышанычлысы, – дип зәңгәрлеяшелле кычкырды* (М. Әмирхан). *Мондый чибәрлеге бар чагында бу* ***хәчтерүш*** *белән очрашып базарны төшермәскә иде* (М. Юныс). Матур әдәбиятта яки публицистикада вульгар сүзләр тискәре күренешләрне яки кешеләрнең үзенчәлекләрен тупас шәкелдә фаш итү өчен стилистик чара буларак кулланылалар. Вульгар сүзләр теге яки бу күренешне атап кына китмиләр, ә әлеге күренешкә булган тискәре мөнәсәбәтне дә ачык сиздерәләр.

Димәк, сөйләм теле – диалогик сөйләмгә корылган, билгеле бер затка юнәлдерелгән, рәсми булмаган, табигый шартларда башкарылган, кодификацияләнгән әдәби телгә каршы куелган сөйләм төре. Сөйләм теле лексикасының аерым бер чиге юк, ул китап теле лексикасына да, стильара лексикага да күчәргә мөмкин.

## § 39. Сөйләм теле лексикасының төрләре

Сөйләм теле лексикасына иреклe әңгәмәләрдә, көндәлек тормышта сөйләшүче, бер вакыйга турында хәбәр итүче, гаилә эчендә сөйләшүчеләр тарафыннан кулланылган сүзләр, сүз формалары, сүзтезмәләр керә. Сөйләшү стиленең әдәби төре ул – әдәби нормага салынган сөйләм. Сөйләм теленең әдәби төрен төрле лексик-

семантик төркемнәргә аерып карарга мөмкин. Әлеге классификациягә нигезләнеп, сөйләм теле лексикасына аерым тукталып үтү урынлы булыр.

Эш яки хәлне белдергән сөйләм теле сүзләре иң зур тематик төркемне тәшкил итәләр. Алар үзләре берничә төркемчәгә бүленә:

1) башка функциональ стильләрдә дә синонимик парлары булган эш яки хәлне белдерә торган сөйләм теле сүзләре: *затсызлану* (оятсызлану), *әдәпсезләнү* (тәртипсезләнү), *кырку* (кисү), *бөтәрләү* (йомарлау, җыеру), *зурлану* (масаю, эреләнү, тәкәбберләнеп китү), *зәхмәтләнү* (интегү, азаплану, җәфалану, җәфа чигү), *итләнү* (тулылану, симерү, тазару), *калкыну* (кузгалу, күтәрелү), түңкәрү (егу, аудару), *түңелү* (йөз чөерү, ваз кичү), *пырлату* (очырту, ачулану, әрләү, тиргәү), *күшәнү* (ашау), *майтару* (башкару, эшләү, булдыру), *кырлау* (кычкыру), *кыйралу* (кырылу, җимерелү, ватылу), *кыздыру* (тиргәү, орышу, ачулану), *чутлау* (исәпләү, хисаплау), *кортлану* (капризлану, көйсезләнү), *аңгыралану* (миңгерәүләнү), *бугазла*у (сую), *ябышкаклану* (бәйләнчекләнү, сылану), *ыжламау* (пошынмау, борчылмау, игътибарсыз калдыру), *юнәю* (савыгу, сәламәтләнү), *юнәйтү* (төзекләндерү, рәтләү, булдыру), *аймыллану* (саташу, сантыйлану) һ.б. Мәсәлән: «*Шикәрне кем **чәлдерде**?» – дип сораудан файда юк* (Т. Галиуллин). Мисалдагы *чәлдерү* сүзе «урлау» дигән мәгънәдә килә. Язучы экспрессив төсмерләрне бирү максатында *урлау* сүзен *чәлдерү* сүзе белән алыштыра. *Беркөнне әтисен **тукмап** киткән* (М. Юныс). *Ә бөтен районныкын **чутласаң,** күпме җир харап була, бөтен республиканыкын*? (Г. Бәширов). *Мәҗлес җыю – карт ханбикә вазифасы, **тыкшынасы** булма* (М. Әмирхан). Әлеге мисалларда «*тукмау», «чутлау», «тыкшыну*» кебек сүзләр экспрессияне арттыру максатында, сөйләмнең образлылыгын арттыра;

2) синонимик парлары билгеләнмәгән эш-хәлне белдергән сөйләм теле сүзләре: *айлау* «кайда да булса ай буена тору», *тожҗрайту* «күзләрне зур итеп ачу», *ихтималлану* «берәр эш-хәл мөмкин булыр дип уйлау», *ихахайлану* «оятсызланып шаркылдап көлү, чытлыклану» һ.б.: *Ул **ихахайланып,** аның күзенә черки булып кадалды* (Ш. Маннур);

3) эш яки хәлне метафорик мәгънәдә атый торган сөйләм теле сүзләре: *этләнү* «интегү», *кәҗәләнү* «киреләнү, көйсезләнү», *козгынлану* «ерткычлану, козгын кебек ташланырга тору» һ.б.: *Шулай иртәдән-кичкә кадәр «**кырмыскаланабыз**»* (Ә. Гадел);

4) кешенең физик үзенчәлекләрен, характерын билгели торган сөйләм теле сүзләре үз эчендә дә берничә төркемчәгә аерыла:

а) кешенең төс-кыяфәтен ачып биргән сөйләм теле сүзләре: *акай* «акай күзле» (ТТАС, 2005: 28), *җимерек* «*күч.* чытык, бозылган (чырай, йөз)», *мыеклач* «мыеклы кеше», *пытый-патый* «сакау» (ТТАС, 2005), *күрексез* «матур түгел, чибәр булмаган» (ТТАС, 2005), *күрекле* «1. Матур, чибәр; 2. Матур, чибәр кеше» (ТТАС, 2005: 333), *курну*с «1. Почык. 2. Почык борынлы», *көяз* «купшы, чибәр, матур» (ТТАС, 2005: 298), *фырт* («франт» сүзеннән сөйләм теле аша фонетик үзгәреш кичергән) «көяз, купшы» (ТТАС, 2005: 628), *шөкәтсез* «ямьсез, шыксыз, килбәтсез» (ТТАС, 2005: 678) һ.б.: *Кияү бик **фырт** күренә* (Т. Галиуллин). ***Фырт** күренә, киемнәр дә әйбәт* (М. Әмирхан). *Подъездларда, чүп түгү урыннарында алар йорт хуҗаларын ашардай ризык чыгаруын көтеп йокы симертәләр, ә йокылары да, тамаклары туйса, **фырт** егетләр сыман, кырт-кырт басып, песибикәләр янына китәләр* (М. Кәбиров);

ә) кешенең психологик үзенчәлекләрен ачып бирә торган сөйләм теле сүзләре: *алты-биш* «аңгыра-сантый, тиле-миле, аңгы-миңге» (ТТАС, 2005: 37), *ахмак* «акылсыз, аңгыра, тинтәк; исәр, сантый» (ТТАС, 2005: 56), *акыш-макыш* «ахмак-дивана» (ТТАС, 2005: 32), *алмаша* «акылга тулы түгел, исәр» (ТТАС, 2005: 36), *аңгыра* «аңсыз, надан, ахмак, сай белемле; тинтәк, сантый, юләр» (ТТАС, 2005: 63), *исәр* «акылсыз, юләр, ахмак, дивана» (ТТАС, 2005: 199), *хәшәп* «надан, ахмак» (ТТАС, 2005: 640), *кызма* «кызулы, ярсулы», *чәнчүле* «төртмәле, кинаяле, усал» (ТТАС, 2005: 668), *кырлы-мырлы* «бер болай, бер тегеләй, каршылыклы» (ТТАС, 2005: 308), *летун* «эштән-эшкә күчеп йөрүче, эшен еш алыштырып торучы кеше» (ТТАС, 2005: 344), *рәтле* «яхшы, әйбәт, юньле кеше» (ТТАС, 2005), *пытымы*р «күп сөйләшүчән кеше» (ТТАС, 2005: 434), *му*т «артык хәйләкәр, үткен, зирәк; шаян, шук, азгын» (ТТАС, 2005: 372), *мышкылдык* «әкрен кыймылдаучы кеше» (ТТАС, 2005: 381), *нахал* «артык әрсез кеше; оятсыз» (ТТАС, 2005: 381), *нәзберек* «аш суны бик сайлаучан, талымчан» (ТТАС, 2005:383), *очанак* «бик тиз кызып, ярсып китүчән» (ТТАС, 2005: 403), *тырым-тырагай* «җәмгыятьтә әһәмиятле урын тотмаган, җитди булмаган кеше» (ТТАС, 2005: 575), *кыбырсык* «тынычсыз, тиктормас» (ТТАС, 2005: 229), *бытылдык* «тиз күп сөйләшә торган кеше» (ТТАС, 2005: 83),

*быжгак* «гел зарланып торучан кеше» (ТТАС, 2005: 83), *аумалы* «кеше сүзенә тиз бирелүчән» (ТТАС, 2005: 55), *азулы* «үткен, усал телле» (ТТАС, 2005: 26), *уенчак* «шаян, шук; сикерергә, уйнакларга, чабып йөрергә яратучан; җитди түгел, шаян; тыйнаксыз» (ТТАС, 2005: 604), *утлач* «җитез, кыю, көчле» (ТТАС, 2005: 614): ***Йомыкый*** *гына бәндә иде* (М. Әмирхан). *Теге беркатлы* ***дивана,*** *моның сүзләренә чын күңелдән ышанып, тырышып-тырышып ертык ямап утырганда, бу хәйләкәр төлке, күзләрен кыздан һич ала алмыйча, шул бер урында кадакланган да калган* (Ф. Хөсни). *Әтисе* ***бүкән*** *кебек утыра* (Т. Галиуллин);

б) кешенең характер үзенчәлекләрен метафорик мәгънәдә биргән сөйләм теле сүзләре: *козгын* «*күч.* комсыз» (ТТАС, 2005: 264), *кәҗәле* «кире, көйсез» (ТТАС, 2005: 318), *йөзсез* «оятсыз, тупас» (ТТАС, 2005: 213), *битсез* «оятсыз, намуссыз» (ТТАС, 2005: 88), *такырбаш* «*күч.* надан, гыйлемсез» (ТТАС, 2005: 504), *муенсыз* «йомшак характерлы, принципсыз» (ТТАС, 2005: 372), *оялы* «үз гаиләле, үз тормышлы» (ТТАС, 2005: 406), *пәриле* «аз вакыт эчендә бик күп эшләр эшләп ташлаган кеше» (ТТАС, 2005: 437) һ.б.: *Ирләрнең азгынлыгыннан диикме,* ***сыерлыгыннанмы*** *(хәер, аермасы юк) туйган кайберәүләр, аларга карап, эчтән генә тормышка ашмастай хыяллар белән яндылар* (Р. Рахман). *Һәрхәлдә алардан* ***этлек*** *көтми иде* (М. Әмирхан). *Кан исе бабаларыбыздан килгән* ***ерткычлык*** *хисләрен бар көчкә улатып җибәрде* (М. Әмирхан). *Балалар да (хәтта балалар да!)* ***ерткычлыкка*** *табынып үсәләр ...* (М. Кәбиров).

5) эш-хәлнең билгесен белдергән сөйләм теле сүзләре: *кырын-кырын* «туры карамыйча, йөзне бормыйча» (ТТАС, 2005: 308), *мыштыр* «әкрен» (ТТАС, 2005: 378), *юрамалый* «чынлап түгел, сынап карар өчен генә; юри» (ТТАС, 2005: 723), *ыңгыр-шыңгыр* «хәлсезләнеп, ыңгырашып, көч-хәл белән; ризасызлык белдереп, ыңгырашып» (ТТАС, 2005: 701), *өфелдәтеп* «бик кадерләп, саклап» (ТТАС, 2005: 754), *этелә-төртелә* «тыгын булган урыннарда орынып, бәрелеп, төрткәләшеп» (ТТАС, 2005: 712), *алагаем* «бик артык, чамадан тыш» (ТТАС, 2005: 32), *ашык-пошык* «ашыгып, кабаланып, каударланып; бик тиз» (ТТАС, 2005: 60), *бәйнә-бәйнә* «бик җентекләп, җентекле тасвирлап» (ТТАС, 2005: 102), *зерә* «бик, нык, артык, көчле» (ТТАС, 2005: 161), *алмаш-тилмәш* «алмашлап, чиратлап, әле берсенә, әле икенчесенә» (ТТАС, 2005:

36) һ.б.: *Эчми эчкән Заһидулла чираттагы кружкадан соң* ***лыкма*** *исерде* (Р. Сибат). ***Мәш*** *киләләр кошкайлар...* (Ә. Гадел);

6) медицина белән бәйле җанлы сөйләм теле сүзләре: *бума ютәл* «коклюш» (ТТАС, 2005: 97), *тамак бакасы* «ангина» (ТТАС, 2005: 512), *коры сызлау* «сөяк туберкулезы» (ТТАС, 2005: 282), *чатан* аксак (ТТАС, 2005: 648), *кылтамак* «аш үтмәү чире» (ТТАС, 2005: 306), *зыяндаш* «кинәт көзән җыеру һәм аң югалту рәвешендә өянәкле нерв авыруы үзбума чире, бума чире» (ТТАС, 2005: 168), *миндаль* «миндальсыман биз» (ТТАС, 2005: 366); *кытыр* «берәр әйбер өстендәге төерчек, кечкенә чыгынты» (ТТАС, 2005: 312), *йөткерек* «ютәл» (ТТАС, 2005: 215): *Моннан бер ай чамасы элек кенә* ***кызамыктан*** *көч-хәл белән котылган, инде хәзер тәненә ит утыртып, Гарифулласына охшаш бит алмалары, иреннәре алланып-балланып үсә башлаган ун айлык Тансык ... савыкты* (А. Хәлим);

7) санны, микъдарны, күләмне белдергән җанлы сөйләм теле сүзләре: *түтәрәм* «1. Нәрсәнең дә булса дүрттән бер өлеше; 2. Бер кадак чамасы авырлык берәмлеге» (ТТАС, 2005: 602), *кырыклы* «кырыгынчы үлчәм» (ТТАС, 2005: 308), *алтмышлы* «алтмышынчы үлчәмле» (ТТАС, 2005: 37). *Безнең кар базында бер* ***йомарлам*** *май саклана иде* (Ә. Гадел). *Әрекмәннәр арасында агарып утырган пыяла* ***чирекн****е абайлап алды* (А. Хәлим);

8) җир, урын, рельефны белдергән һәм сыйфатлаган сүзләр: *сөренте* «сөреләә торган» (ТТАС, 2005: 500), *калкым* «калкып торган урын» (ТТАС, 2005: 225), *калдау* «иген чәчелмичә калган, яткын җир» (ТТАС, 2005: 225), *әҗәтханә* «бәдрәф, әбрәкәй» (ТТАС, 2005: 753), *җәп* «тунга сөрелгән җир» (ТТАС, 2005: 788) һ.б.: «***Мәйханә»*** *эшләнгән чорда авыл яшьләре арасында үз-үзенә кул салучылар, асылынып үлүчеләр дә бермә-бер артты* («Мәдәни җомга»). *Тау* ***кырлачында*** *аларның булуы мөмкин дә түгел иде* (А. Хәлим);

9) нәрсәне дә булса сыйфатлаган сөйләм теле сүзләре: *тозлырак* «кыйбатрак» (ТТАС, 2005: 546), *кысык* «тар, кысрык» (ТТАС, 2005: 311), *маемсыр* «каешланган, майланган сыман ялтырап торган» (ТТАС, 2005: 352), *миңгерәткеч* «хәлсезләндерә, аңгы-миңге хәлгә китерә торган» (ТТАС, 2005: 366), *кыеш-мыеш* «кыек, авыш» (ТТАС, 2005: 302), *берәгәйле* «иң югары сыйфатлы, бөтен таләпләргә дә җавап бирүче» (ТТАС, 2005: 83) һ.б.: *Әйе, барысы да затлы, килешле һәм үлчәп теккәндәй* ***таман*** *иде* (М. Кәбиров). *Ул,*

***арурак*** *акча түлибез дисәләр, зоопаркта маймыл булып урнашырга да әзер иде* (М. Кәбиров):

10) көнкүреш атамаларын белдергән сөйләм теле сүзләре: *нар* «тактадан ясалган урын, ятак, сәке» (ТТАС, 2005: 381); *кәҗүл* «кәҗә күненнән тегелгән» (ТТАС, 2005: 318), *лагун* «агач чиләк, агач мичкәнең кечкенә күләмлесе» (ТТАС, 2005: 339); *яңгырлык* «яңгырда кия торган махсус кием, ябынча», *будыргыч* «тарттырып будырып куя торган сузылмалы тасма» (ТТАС, 2005: 740), *тәнҗылыткыч* «куфайка» (ТТАС, 2005: 585), *миски* «ашау ризыклары салу өчен кулланыла торган савыт» (ТТАС, 2005: 368), *подаука* «бер пот әйбер сыешлы агач яки калай савыт» (ТТАС, 2005: 420), *сетка* «әйбер салып, сумка урынына йөртә торган җәтмә әсбап» (ТТАС, 2005: 470), *уравыч* «чормау» (ТТАС, 2005: 610), *кыпсуыр* «келәшчә» (ТТАС, 2005: 307), *кәзәки* «озын камзулга охшаган җиңле һәм кечкенә утыртма якалы өс киеме» (ТТАС, 2005: 315), *кушкөбәк* «ике көпшәкле ау мылтыгы» (ТТАС, 2005: 299), *кырынгыч* «кырыну әсбабы» (ТТАС, 2005: 309) һ.б.: ***«Уфалла»*** *дип аталган ике тәгәрмәчле бәләкәй арбага утыртып тартып йөртә идек без аны* (Т. Миңнуллин). *Ак Чишмә елгасыннан таш чыгарып,* ***«уфалла арбасы»*** *белән ике ай ташыды ташны егетең* (Ә. Гадел).

Төсмерләр белән билгеләнмәгән, әдәби телдә кулланылган көнкүреш лексика, көнкүреш тормыштагы предмет атамаларын, көнкүреш вакыйгаларының атамаларын, кеше тормышындагы гореф-гадәтләрнең атамаларын белдергән сүзләр дә бу төркемгә керә (Земская, 2004: 31). Димәк, әлеге сүзләр кеше тормышы, көнкүреше, көндәлек эшләре белән бәйле төшенчәләрне белдерәләр: *алдыр чүмеч, ипи табак, тустаган, мичкә, ләгән, кисәү агачы, лакан, чапчак* һ.б (Хайрутдинова, 2000: 116–123), *хрущовка* (Хрущев идарә иткән чорда төзелгән йортлар, биналар), *сталинка* (Сталин идарә иткән чорда төзелгән биналар) һ.б. Бу төркем лексик берәмлекләр сөйләм теленең үзәген тәшкил итәләр, әдәби телнең бер төре саналалар, шулай да функциональ нормалар белән чикләнәләр. Мәсәлән: *Соңрак мондый йортларны мыскыллап,* ***«хрущовка»*** *дип атадылар* (М. Маликова). *Мәскәү базарыннан ерак түгел, галәмәт биек түбәле, филләр кереп йөрерлек зур тәрәзәле с****талинк****а дип аталган фатирда торалар икән* (Т. Галиуллин);

11) кешене белдерә торган атамалар: *карт-коры, кыз-кыркын, марҗа, көмән, хатынша, кеше-кара, киленчәк, мир* «авыл

халкы, күп кеше, халык», *кортка* «1. Ире үлгән яисә ирсез калган олы яшьтәге хатын-кыз; 2. Гомумән, хатын-кыз, әби кеше» (ТТАС, 2005: 282) һ.б.: *Инсаннарның үзләре дә белмәгән Иң Олы Бәхете дә әнә шундадыр мөгаен, чөнки бу бәхет кемдә дә бар, хәтта иң пычрак вә **хәсис адәмчекләр, бәндәчекләр** дә аңа ия* (Р. Сибат);

12) профессия, эш яки мәсләкне белдергән сөйләм теле сүзләре: *кухарка* «аерым өйдәге ашчы, пешекче хатын» (ТТАС, 2005: 299), *кашевар* «хәрби бүлектә яки эшчеләр артелендә аш пешерүче» (ТТАС, 2005: 244), *болынчы* «болында печән чабучы» (ТТАС, 2005: 91), *җөйче* «тегүче» (ТТАС, 2005: 790), *кыршауч*ы «мичкәләрне, кисмәкләрне һ.б.ш.ны кыршаулаучы, аларга кыршау кидерүче» (ТТАС, 2005: 309) һ.б.: *Тик акциядә катнашучылар **«гаишник»ларга** ошап бетмәгән күрәсең* («Ватаным Татарстан»);

13) ашамлык, ашау-эчү атамаларын белдергән сөйләм теле сүзләре: *кумышка* «өйдә ясалган үзкуган» (ТТАС, 2005: 295), *кыты-мыты* «вак-төяк ашамлык, калдык-постык» (ТТАС, 2005: 312), *көмешкә* «ашлыктан һ.б.ш.дан өй шартларында ясалган эчерткеч эчемлек» (ТТАС, 2005: 320), ачыткы «камыр башы, чүпрә» (ТТАС, 2005: 58), *закуска* «1. Тиз генә капкалап алу өчен төрле салкын кабымлык; 2. Ачы-төче азыклар, кабымлык» (ТТАС, 2005: 162): *Укытучының яраткан **кәлҗемә-мәлҗемәләре, боламыклары**, пешмәгән шалканнары, пешкән шалканнары – барысы бергә колагына тыгылгандай булды* (Р. Рахман). *Тагы шуны әйтим, буш вакыт килеп чыкканда, Шакир кода ара-тирә **мәй-хәмер** белән «чуалып» китүдән дә тартынмый иде* (Ә. Гадел);

14) йорт хайваннарын, җанварларны белдергән җанлы сөйләм теле сүзләре: *бахбай* «ат яки тай» (ТТАС, 200: 785), *тити* «тавык» (ТТАС, 2005: 544): ***Бахбай** керт-керт итеп солысын чәйни, мин тирә-якны манзара кылам* (М. Әмирхан);

15) вакытны белдергән җанлы сөйләм теле сүзләре: *атнакич* «атнаның дүртенче көне; пәнҗешәмбе» (ТТАС, 2005: 54), *атнакөн* «атнаның бишенче көне; җомга» (ТТАС, 2005: 54) һ.б.;

16) бәддога һәм теләк сүзләре: *билләһи, билләһи газыйм, икмәктер, ипидер, җир йотсын, чәчрәп китим* һ.б.: *Шунда минем бер укучым, **аты коргыры**, исемен атаганда да телеңне сындырырлык* (Ф. Хөсни);

17) сөйләм теленә караган фразеологик берәмлекләр: *тел-теш тидерү, эһ дигәнче, ә дигәнгә җә дип тору, акылга утырту, тел*

*тыю, кыйбат алмау, ми чертү, сәнәктән көрәк булу, бер дигән* һ.б. (Ахунҗанов, 1972). Әлеге фразеологик әйтемнәрнең китап телендәге вариантлары да күзәтелә. Мәсәлән, *сәнәктән көрәк булу* фразеологик берәмлегенең *түбәннән күтәрелү* кебек китап теленә караган варианты бар. *Ис китмәү* фразеологик әйтелмәсе «кызыксынмау» стильара сүзе белән алыштырыла, ә *ике ятып бер төшкә кермәү,* сөйләм теленә карап, экспрессивлык дәрәҗәсе белән аерыла.

Димәк, сөйләм теле лексикасы дигәндә кешеләрнең көндәлек әңгәмәләре процессында диалогик яки монологик сөйләмнәрендә барлыкка килгән сүзләр яки гыйбарәләр күздә тотыла.

## § 40. Гади сөйләм лексикасы

Гади сөйләм – милли тел яшәешенең субстандарт формасы, ягъни гомумбилгеле субстандарт тел берәмлекләрен (сүз, мәгънә, форма, конструкция һ.б.) үз эченә алган сөйләм системасы (Еремин, 2001: 50). Гади сөйләм лексикасы – әдәби норма итеп алынмаган, көнкүрештә төрле социаль катлам кешеләре тарафыннан кулланылган сүзләр җыелмасы. Әдәби сөйләмгә керми торган сүзләр, тәгъбирләр, әйләнмәләр, сүз төрләнеш формалары, билгеле бер колорит тудыру өчен, еш кына, әдәби әсәрләрдә һәм сөйләм телендә дә кулланылалар (Ахманова, 1966: 368).

Тел белемендә гади сөйләм лексикасын куллану тел нормаларын бозуның бер шәкеле итеп карала (Л. Щерба, А. Гвоздев, О. Ахманова, С. Кац). Кайбер галимнәр гади сөйләм лексикасын гадилеге һәм коммуникатив процесстагы әзерлексез башкарылуы белән билгеләнгән әдәби телнең стилистик бизәкле бер катламы итеп, әдәби телне тулыландыруда зур роль уйный дип саныйлар (А. Ефимов; Ф. Сафиуллина).

Татар теле белемендә гади сөйләм теленең әдәби тел белән җирле диалектларга мөнәсәбәте (Хаков, 1971: 14), экспрессив-стилистик табигате (Абдуллин, 1968: 129), стилистик катламдагы урыны (Сәгыйтов, 1976: 46) хакында фикер төрлелеге яшәп килә. Х. Курбатов гади сөйләм сүзләрен, әдәби телдән читтә торган билгеле бер диалектта гына кулланылмый торган сүз һәм әйтелмәләр, грамматик һәм фонетик формалар куллануда барлыкка килгән сөйләм сүзләре, дип атый (Курбатов, 1971: 14). Ф. Сафиуллина исә гади сөйләм сүзләрен гомумхалык сөйләм теленә кертеп, сөйләмгә эмоциональ-экспрессив төсмер бирүләрен, күбесенчә, матур

әдәбиятта персонаж сөйләмендә кулланылуларын, әдәби тел нормалары чигендә торып, кискен һәм төксе әйтелүләре белән аерылуларын ассызыклый (Сафиуллина, 1999: 121). Соңгы чорга караган хезмәтләрдә дә гади сөйләм мәсьәләсе тикшерелә (Галиуллина, 2013; 109; Кадирова, 2010; Хаҗиева, 2011: 36–42).

Һәрбер милли әдәби телдә гади сөйләм сүзләре кулланылышының аерым бер чоры була. Әдәби телдә гади сөйләм сүзләренең активлашуы милли әдәби телнең интенсив үсеше белән бәйләнешле (Поварисов, 2009: 56). Гади сөйләм лексикасы өч критерий нигезендә – кулланылыш даирәсе, эмоциональ-экспрессив табигате, әдәби телгә мөнәсәбәте буенча билгеләнә.

Гади сөйләм лексикасын үз эчендә ике төргә бүләргә мөмкин: а) әдәби тел нормалары чигендә булган гади сөйләм сүзләре; ә) кулланылышы ягыннан катгый чикле булган, әдәби телгә бөтенләй кертелмәгән вульгар сүзләр.

Әдәби тел нормалары чигендә булган гади сөйләм теле сүзләре – әдәби тел нормаларына буйсынмаган, сөйләмгә эмоциональ-экспрессив төсмер бирә торган, башлыча тупас, төксе формада кулланыла торган сүзләр, формалар (Галиуллина, 2013: 103). Беренче төркемгә әдәби тел чигендә торган, әдәби норма булып саналмаган гади сөйләм сүзләре керә: *исерек баш, лаштор-лоштыр, эт булып ару, баш катыру, башың яшь, бакыру, хөрти, шымытыр* һ.б.: *Һи, **тишек баш**! – диде ул, үз-үзен тиргәп. Мин бит менә* (Ә. Мәхмүди). *Әй, сез, **кәмшек танаулар**! Әгәр хәзер үк тыңламасагыз, мин сезнең тоякларыгызны сындыра башлаячакмын!* (Ә. Мәхмүди). *– И-**и маңкуш!** – Алай әйтмә – дип еласам да, барыбер тыңламаячак»* (Р. Рахман,). ***Җилбәзәк**! – дип кычкырып ук җибәрде дә, тупсага килеп төште* (Р. Рахман). *«**Тиле!** Укыйсы бар бит әле!» – Рәшит сүзләреннән Зөләйханың күзләре маңгаена менгән иде* (Р. Рахман). *Телгә килдеңме, **күзле бүкән**!* (Г. Гыйсметдин). *Карале бу **күсәкне!** Минем чаклы булгансың бит! – диде* (Г. Бәширов). *Сез нәрсә?! **Әҗәтканалар**! Ашлыкны әрәм итеп! – Бик ачуы чыккан-да гына әйтә торган сүзләрнең мәгънәсен аңламасам да, куркып киттем* (Р.Рахман). *Өйдә Миләүшә ялгыз үзе генә калган булган. Кергән теге **тозлы күз,** – Фарукны шулай дип әйтәм, – кергән и шуннан теленә салынырга тотына* (Ф. Хөсни). *Шәмсия. Нишлисең, **убыр авыз?!** Әйдә чыгыйк...* (Ф. Садриев). *Шәмсия. Җитте сиңа, **карт иблис!*** (Ф. Садриев). *Сабит (үз-үзенә). **Мөшкә авыз!.***

*Чөмереп бетерә язган!* (Ф. Садриев). *Никләр генә шушында калмаганмын,* ***тинтәк баш*** (Ф. Сафин). ***Тәре баганасы, иблис,*** *әрәм итте бер дигән кешене* (Ф. Сафин).

Гади сөйләм сүзләре матур әдәбиятта махсус стилистик чара буларак кулланылалар. Аларны лексик-тематик яктан түбәндәгечә аерырга мөмкин:

1. Эш яки хәлне белдерә торган гади сөйләм сүзләре: *бүсү* «күп итеп талымсыз ашау», *сеңдерү* «тора-кузгала алмаслык итеп егу», *табалау* «нәрсә өчен булса да шелтәләү, әрләү, хурлау», *айгырлану* «йөгәнсезләнү, артык тотнаксызлану; азгынлыкта йөрү», *һапылдау* «итекләр белән идәнгә басып, әкрен генә һапылдау», *үрләтү* «кабызып җибәрү», *ырылдау* «кемгә дә булса кычкыру, усал итеп ачулану», *ычкыну* «һәлак булу, үлү», *хөрәсәнләнү* «ялкаулану, ялкауга әйләнү, эшлексезләнү», *лыкырдату* «пычрату, пычракка буяу», *челәю* «күзне челәйтеп карап тору, күзне текәп карап тору», *өфертү* «урлау», *динсезләнү* «явыз, әшәке кешегә әйләнү, бозылу» һ.б.: *Күтәрелеп караса, Волганың ике күзе дә* ***акаеп*** *Камилгә төбәлгән* (Г. Бәширов). *Акаю* «ачулы яки усал итеп карау» мәгънәсендә килә (ТТАС, 2005: 280). Биредә *карап* сүзен *акаеп* – гади сөйләм сүзе алыштырып килгән. *Акаеп* сүзе эмоциональ-экспрессивлыкны арттыру функциясен үти. «*Үз халкына кул күтәргән ирне,* ***Өегешкән*** *этләр таласын!*» (Н. Акмал). *Мөхәммәтәмин бу вакытта, тәмле төшләр күрә-күрә, хатынының кайнар кочагында рәхәтләнеп йокы* ***бүсә*** *иде* (М. Әмирхан).

2. Кешенең төс-кыяфәтен, характерын сыйфатлаган гади сөйләм сүзләре аерым урын алып тора һәм сан ягыннан күпчелекне тәшкил итә. Әлеге сүзләр яратып эндәшү формасын да алырга мөмкин: *хәчтерүш* «шыксыз, кыяфәтсез, ямьсез», *барчук* «эш сөймәс аксөяк бала яки яшүсмер», *лыкырдык* «шапшак, пычрак кеше», *хөрәсән* «үтә эшлексез, ата ялкау кеше турында», *хәшәрәт* «әшәке, кабахәт кеше», *өстерәлчек* «уйнашлык итүче, уйнашчы», *изелдек* «бик йомшак, акрын, мәлҗерек кеше» һ.б.: *Ишегалдында бер түти алак-****шалак*** *карана-карана керләр элә иде* (М. Шаһимәрдән). *Алак-шалак* «җилбәзәкләнеп» дигән мәгънәдә килгән.

3. Кешенең характерын метафорик мәгънәдә сыйфатлаган гади сөйләм сүзләре: *мазель* «җилбәзәк хатын-кыз», *селәгәй* «булдыксыз, җебегән, ихтыярсыз булган кеше», *маңка* «кече яшьтәге яки тәҗрибәсез һәм кулыннан эш килмәгән кешеләргә карата

кимсетеп, мыскыллап әйтелгән сүз», *бүре* «усал кеше», *итекче* «эш рәтен белмәгән, белер-белмәс эшләгән кеше» һ.б.: *Алдаша белмим, дөресен әйтсәң, ничектер оят**, селәгәй малай** гына икән әле син дип уйлавы бар* (М. Әмирхан). *Артыгын эчмәскә иде, **карт шайтан**! (*Ә. Гадел). *Селәгәй малай, карт шайтан* кебек гади сөйләм сүзләре әлеге өзекләрдә геройны метафорик сыйфатлап, образлы итеп бирүгә нигезләнәләр.

4. Алынма сүзләрне бозып әйтү җирлегендә барлыкка килгән гади сөйләм сүзләре, фразеологик гыйбарәләр аерым бер урын тоталар. Әмма гади сөйләм сүзләрен әдәби булмаган әйтелеш очраклары белән генә чикләргә ярамый, матур әдәбият стилендә алар бары тик персонаж сөйләмен стильләштерү максаты белән генә кулланылалар: *Кечкенә өстәл, кыскыч, тимер пычкысы, тишкеч ята иде өстәлдә. Һәм эреле-ваклы **әлүмин** көпшәләр* (Ф. Сафин). *Райкум-парткумнар да юкмыни инде хәзер **идрит-кудрит**?* (Д. Гыйсметдин). *Юк бит, юк, жәлке, анасын **корт чаккыры*** (Т. Миңнуллин). ***Ривәлүтсия** чыкты иеме?* (Т. Миңнуллин). *Бәлки, мин дә, Зәкиулла абый шикелле, төпләнеп яшәү авырлыгыннан куркып, «**пүчтәк эш»** артыннан гына йөри торганмындыр!* (М. Юныс). *Сугыш бетте, сазлык киптерәбез дип, – тугайларга, чишмәләргә, иген мәйданы арттырабыз, ялгызак агачларны төплибез дип, – урманнарга каршы **наступлинҗә** башланды* (А. Хәлим). *Аһ, бу **күмпликсләр**! Колакка «кәмпүтер» сыман гайре табигый яңгыраган бу нәмәстәкәйне татарча «бистә» дип тәрҗемә итәргә мөмкиндер* (А. Хәлим). *Мондый чакларда ул үзен көлеп, **«йөрмәлист»** дип атый, «сүз остасы» имеш* (А. Хәлим). Фразеологик берәмлекләрдән *дастуен булу* (Исәнбәт Н., 230); *фарсит итү* (Исәнбәт Н., 206); *чистый аптыраш* (Исәнбәт Н., 234); *прәмәдән туп-туры* (Исәнбәт Н., 54); *пунимаешь, артта каеш, билдә бау* (Исәнбәт Н., 54); *акча үзе образауный* (Исәнбәт Н., 48) һ.б.ларны санап үтәргә була.

5. Гади сөйләм сүзләре арасында тотрыклы гыйбарәләр, мәкаль-әйтемнәр аерым урын тота: *ипи шүрлеген җимерү* «авызын, авыз тирәсен сугып имгәтү» (ТТАС, 2005: 189), *төптән юан чыккан* «базык гәүдәле, карсак, нык кеше» (Исәнбәт Н., 177); *төнлек тишегеннән чыккан күк* «каралган, буялган кеше» (Исәнбәт Н., 175); *төртсәң түнәрлек, әйтсәң көләрлек* «аннан-моннан гына корыштырып эшләгән каралты-мазар, көчкә генә, чак кына аумый торган нәрсә» (Исәнбәт Н., 178); *авызын җылыту* «авызына сугу,

авызын канату; аракы белән сыйлап, йомшак кешене кулга алу» (Исәнбәт Н., 24); *авызы ершаеп киту* «берәр нәрсә капканда, еларга иткәндә авыз ихтыярсыздан бер якка кыегаеп талшаеп киту» (Исәнбәт Н., 18); *тасраеп кату* «аптырауга төшеп, күзне киң җәеп ачу» (Исәнбәт Н., 115); *юл маештыру* «адашу, юл чатында ялгыш киту» (Исәнбәт Н., 289); *ырҗыктай ир* «таза, нык, калын» (Исәнбәт Н., 262): *Уйлыйм да, шаклар катам, **эт өрә, бүре улый, чучка мырылдый,** һәркайсы үзенчә аңлашу җаен таба* (Ф. Сафин). ***Ходай ташламаса, дуңгыз ашамас** дип, татар мәктәбенә бирергә мөмкин* (Т. Галиуллин). Гади сөйләм теленә караган фразеологик берәмлекләрнең шул ук вакытта стильара лексикага караган вариантлары да бар: *коеп куйган* (стильара) – *суйган да каплаган* (гади); *җан алыну* (стильара) – *кот ботка төшү* (гади); *акылың алтын икән* (стильара) – *әбиеңә сәләм әйт* (гади) һ.б.

6. Теләк-бәддога сүзләре, гыйбарәләре: – *Кара син аны, **җир бит!** Көпә-көндез таларга, ә!* (Г. Бәширов). – ***Чукынып китегез**! Ник шунда бөтен йортын ишеп төшермисез!* (М. Маликова). *Дөньяның әллә кай җирләренә мөгез чыгара. Җирне күтәргән үгез мөгезе тишелеп чыккан диярсең! Журналның мөндәриҗатының мисалларын күрмәк теләсәңез, «Йолдыз»ның фәнни кәшфиятен укыңыз**! Җир йотсын** – шундый, **күк капсын –** шундый! Пычагыма кирәк, ант итәм тагы!* (Г. Тукай).

Сөйләм теле лексикасында кулланылыш ягыннан катгый чикле булган в у л ь г а р  с ү з л ә р (лат. *vulgaris* – гади) аерыла (Стилистический энциклопедический словарь русского языка, 2005: 34). Вульгаризм – әдәби тел нормаларыннан читләшкән, гади сөйләм сүзләренең бер төре булган дорфа, тупас лексика (Галиуллина, 2013: 109). Алар әдәби телгә кермиләр, гаять дорфа, төксе сыйфатка ия: *бүселү* «артык симерү, тазару» (ТТАС, 2005: 108); *дөмегү «*1. Бик авыр хәлгә төшү; 2. Юкка чыгу каядыр югалып тору; 3. Каргау нәфрәтләнү сүзе» (ТТАС, 2005: 154); *бөкләү* «берәр әйберне тиз арада ашап бетерү», *кукыраю* «һавалану», *лыгырдау* «кирәкмәгәнне, ярамаганны сөйләү. Артык күп сөйләү, әһәмиятсез, җитди булмаган сүз яисә гайбәт сөйләү» (ТТАС, 200: 346); *төшерү* «кемгә булса да сугу» (ТТАС, 2005: 596); *чукындыру* «җәзалау, кирәген бирү» (ТТАС, 2005: 659); *бер тиен өчен чукынып тору* һ.б. Аларны икенче төрле *какофемизмнар* дип атау да очрый (ТТАС, 2013). Какофемизмнар – сөйләмгә һөҗүмчәнрәк характер бирү максаты

белән кулланылган, төрле каты һәм хәтта тупас сүзләр яки әйтелмәләр (ТТАС, 2013).

Вульгар сүзләр синонимик оядагы сүзнең түбәнәйтелгән варианты: *ашау – сосу «*әдәпсез рәвештә күп итеп ашау*»; үлү – дөмегү* «1. Үлү; 2. Бик авыр хәлгә төшү; 3. Каядыр югалып тору; 4. Каргау, нәфрәтләнү сүзе» (ТТАС, 2005: 154); *югалу – олагу* «1. Кая да булса китеп югалу, юкка чыгу; 2. Өченче зат боерык фигыль формасындагы каргышлы теләкне белдерә» (ТТАС, 2005: 396) һ.б. *Бармак саен озак кына* ***олагып*** *торса да, йорт яңартырлык акча, авылдашларын сокландырырлык кием киеп кайта алмадым* (М. Юныс). Вульгар сүзләр әдәби тел нормаларына туры килми. Алар матур әдәбиятта, публицистикада тискәре күренешләрне яки дошманнарны фаш итү максатында стилистик чара булып кулланылырга мөмкин.

Вульгар сүзләр, сөйләм теленнән тыш,публицистик стильдә, матур әдәбият стилендә кулланылалар. Башка стильләрдә кулланылышы чикле булырга һәм стиль таләпләренә туры килмәскә мөмкин: *Фашистларны* ***дөмектереп*** *кайткан гвардия, ә авызыңнан сүзеңне алып булмый* (Ф. Хөсни). – *Түбән очның Мәүлә малаен әйтәсеңме? – Сахивәттәй казаннан бәрәңге* ***соса*** *торган җиреннән кызга текә генә бер карап алды* (Ф. Хөсни).

Вульгар сүзләр арасында рус сүзләре дә шактый урын алып тора: *Әй,* ***припоцанный*** *(*аңгыра, юләр кеше мәгънәсендә), *нәрсә карап каттыгыз!* (М. Юныс). ***Жлоб ул! Хмырь болотный*** (саран, начар кеше мәгънәсендә)*, ул мине ач калдырды!* (М. Юныс). *Умырзаядагы вакыйгаларны тикшергәндә артык «тырышканы» өчен аңа шактый* ***«муклашка»*** *эләккән иде* (Т. Галиуллин). Әдәби әсәрдә әлеге сүзләр стилистик яктан акланып кулланылалар.

Вульгар сүзләр арасында шулай ук тотрыклы гыйбарәләр дә шактый зур урын алып тора: *тәкә мөгезе күрсәтү, кәҗә тоягы күрсәтү* (Исәнбәт Н., 168), *артына корт төшкән* «тиктормас, сабырсыз» (Исәнбәт Н., 90), *адәм үләксәсе* (Исәнбәт Н., 35), *бет чәйнәгән* «бик вак сүзле, бәйләнчек, вакчыл, сатулашырга яратучы» (Исәнбәт Н., 175), *селәгәй авыз* «җебегән, юньсез, булдыксыз кеше» (Исәнбәт Н., 70), *майт якасы! Майт якасына!* (Исәнбәт Н., 12) һ.б.

Шулай итеп, гади сөйләм – катгый нормалар белән билгеләнмәгән, тартынусыз сөйләм. Аның бер өлеше әдәби кулланылыш чи-

гендә тора, икенче өлешен әдәби булмаган сүзләр тәшкил итәләр. Функциональ-стилистик яктан караганда, гади сөйләм лексикасы телне образлы-экспрессив чаралар белән баетуга хезмәт итә.

## § 41. Экспрессив-стилистик лексиканың функциональ вазифасы

Тел, иҗтимагый күренеш буларак, кеше эшчәнлегенең теге яки бу өлкәләренә бәйле аралашу, хәбәр итү вазифасыннан тыш, тыңлаучыга, укучыга, адресатка эмоциональ-экспрессив лексика ярдәмендә тәэсир итә. Җәмгыять тарафыннан кабул ителгән, тарихи формалашкан сөйләм һәм китап теленә караган экспрессив-стилистик лексиканың үз функциональ йөкләмәсе бар. Алдагы параграфларда билгеләнгәнчә, матур әдәбият лексикасы – тәэсир итү; иҗтимагый-публицистик лексика – хәбәр итү, тәэсир итү; фәнни лексика – хәбәр итү; сөйләм теле лексикасы – аралашу кебек функциональ вазифалар башкаралар. Җәмгыятьтәге шартларга мөнәсәбәтле рәвештә телнең вазифалары үзгәрергә, катлауланырга, яңа стильләре барлыкка килергә мөмкин. Билгеле булганча, тел – аралашу чарасы булса, сөйләм – аралашу нәтиҗәсе. Тел сөйләм системасы эчендә карала. Сөйләм – телнең иҗтимагыйлык асылын ачарга, хәрәкәт итәргә реаль җирлек тудыра. Шул рәвешле сөйләм һәм китап теленең максат-бурычларына, эчтәлегенә, композициясенә бәйле, экстралингвистик факторларга мөнәсәбәтле аерым эмоциональ-стилистик лексикасы аерымлана.

Билгеле булганча, китап теле лексикасы әдәби телнең язма һәм сөйләү формаларында кулланылып, сөйләм теле лексикасы белән стильара лексика арасында тора. Китап телендә билгеләнгән һәр функциональ стильнең максатына яраклы рәвештә актив лексик берәмлекләр формалаша. Бер стильгә караган лексик берәмлекләрнең икенче бер стильгә дә үтеп керү мөмкинлеге чикле түгел, шуңа күрә функциональ стильләр лексик берәмлекләр өчен ачык система тәшкил итәләр. Китап теленең матур әдәбият лексикасында автор неологизмнары, диалекталь сүзләр, гади сөйләм сүзләре эмоциональ-экспрессив максатларда функциональ вазифа башкаралар. Матур әдәбият телендә автор неологизмнары, традицион образлар системасын баету, поэзиянең фикерләү рәвешен киңәйтү максатыннан тыш, эмоциональ-стилистик вазифа да үти. Мәсәлән:

*Татарстан – **Тетәрстан** ...*
*Бу да шулай, әйе*
*Түбән Кама, Чаллы янә*
*Тетрәп түбәнәйде!*
*Без дә яшибез, әйе* (Л. Лерон).

Әлеге өзектә автор, экологик куркынычны образлы чагыштыру аша, шигырьнең тәэсирлелеген *Тетәрстан* сүзе белән арттыра. Г. Афзалга багышлап язылган эпиграммасында да Л. Лерон тәэсирлелек көчен арттыру максатында ***бюрократ*** сүзен кулланмыйча, «түрәкрат» сүзен иҗат итә:

*«Кәгазь кортларын» да тетә Афзал,*
***Түрәкратларны** да тетә Афзал.*
*Читтә калмый хәтта куштаннар да...*
*Әллә аңа өстән кушканнармы.*

Диалекталь сүзләрнең әдәби телебезне баету мөмкинлеге чиксез, шулай ук җирле төбәктәге үзенчәлекләрне автор тарафыннан әдәби әсәргә кертелүнең эмоциональ-стилистик йөкләмәсе зур.

*Җанны телә*
*Нәфес, нәфес, нәфес...*
*Җан тетелә **фикер-тирмәндә*** (Сөләйман).

Әлеге өзектә Сөләйманга *тирмән* диалекталь сүзен *фикер* сүзе белән янәшә кую, фикергә эмоциональ образлылык төсмерләрен киңәйтергә ярдәм итә. *Тирмән* сүзе мишәр диалектында тегермән дигәнне аңлата (ТТЗДС, 2009: 635). Биредә автор тегермән сүзен фикер сүзе белән тиңләштерә. Аерым язучыларыбыз әсәрләрендә диалекталь сүзләр, эмоциональ-стилистик вазифа башкарудан тыш, аерым лексик фон да барлыкка китерәләр. Н. Әхмәдиевнең «Амбирак яки кара каен кыйссасы», Я. Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт» әсәрләрендә җирле сөйләш сүзләре урынлы кулланылалар һәм алар сурәт ясауда гаять матур яңгыраш алалар.

Китап теленең иҗтимагый-публицистик лексик катламына караган автор неологизмнары, диалекталь сүзләр, гади сөйләм сүзләре, варваризмнарның, шулай ук экспрессив-стилистик вазифада функциональ киңлекләре ачыла: *Альбина кечкенә вакытында бик **чос*** (минзәлә сөйләшендә *әвәс* (ТТЗДС, 2009: 758) дигәнне аңлата) *кыз булган* («Мәдәни җомга»). *Галия үзен киләчәктә каланың*

*тормыш дип аталган* ***матавыгында*** (*матавык* сүзе диалектларда *комачау* (ТТЗДС, 2009: 469) дигән мәгънәдә килә) *калырмын дип күз алдына да китерә алмады* («Идел»). *Терлек-туар күп. Бакчабыз алагаем зур* («Татарстан яшьләре») (*алагаем* сүзе минзәлә сөйләшендә *чамадан тыш, гаять, артык* (ТТЗДС, 2009: 35) дигәнне аңлата). Иҗтимагый-публицистик стильдә кулланылган әлеге диалекталь сүзләрнең төрле эмоциональ-стилистик вазифасы рәсмилектән качу, халык теленә якынаю максатыннан кулланылуын искәртергә кирәк.

Шулай ук иҗтимагый-публицистик стильдә җаргон сүзләрне куллану сөйләмне тәэсирле итеп, фикерне кыска формада төгәл белдерү өчен дә хезмәт итә. Мисал итеп, газета-журнал битләрендә жаргон сүзләрнең кулланылышына игътибар итик: *Халыкта* ***«сары билет»*** *дип йөртелүче документ ияләре буа буарлык булды* («Мәдәни җомга»). *90 нчы елларда галәмәт зур сумкалар сөйрәп ил, дөнья гизеп товар ташып иза чиккән халыкны* ***«челнок»лар*** *дип атыйлар иде* («Татарстан яшьләре»). *Студентларны иң куркыткан «төш» сессия булса, егетләрне армиядәге* ***«бабайлык»*** *өркетә* («Ватаным Татарстан»). *Халыкның социаль яктан якланмаган әлеге катламын төрле* ***«хуҗа»лар*** *бу эшкә яллый яки мәҗбүр итә* («Татарстан яшьләре»). *Аның транспортта* ***«куян»*** *булып йөрү буенча тулы бер стратегиясе бар* («Татарстан яшьләре»). Мисаллардан күренгәнчә, журналист мәкаләсендә жаргон сүзләрне игътибарны җәлеп итү максатында яки битараф сүзнең синонимы буларак эмоциональ-стилистик төсмерләр өстәү өчен дә кулланган.

Иҗтимагый-публицистик стильнең лексик катламында автор неологизмнары предметка, күренешкә бәя бирү, сөйләмнең эмоциональ җирлеген тудыру, сөйләмгә пафос бирү, кирәкле бәйләү төсмерен ассызыклау вазифаларын башкаралар: *Мин чын мәгънәсендә* ***уйдар,*** *уйларга яратучы* ***уйсөяр*** («Мәдәни җомга»). *Яшьләр хатын-кызлар* ***сихәтханәсенә*** *килеп керделәр* («Идел»).

Сөйләм теле лексикасында да эмоциональ-экспрессив вазифаны кешенең физик һәм психологик үзенчәлекләрен яктырткан сөйләм сүзләре аерым урын тота: *Күпме әйттем, койрыгы киселгән тиреләрнең ярты бәясе төшерелә дип, ә, башсыз* ***бүкән*** (Н. Гыйматдинова). Сөйләм теле лексикасында билгеләнгән *бүкән* сүзе – кыска буйлы, юан, авыр хәрәкәтле яки булдыксыз, аңгыра кешене аңлата (ТТАС, 2015: 636). *Янына* ***быткыч****, явыз, тешләк, ачәрвах,*

*тилемсә, вак, ахмак, өчләтә юньсез тоткыннарны китереп тыга* (А. Гыйләҗев). *Быткыч* – «вак һәм бәйләнчек» дигән мәгънәдә килә (ТТАС, 2015: 650).

Сөйләм теле лексикасы арасында эш-хәрәкәтләрне белдерә торган сүзләр төрле төсмерләрне чагылдыру максатында да экспрессив-стилистик чара буларак кулланылалар: *Әле синең шулай* ***быткычланып****, күзәтеп һәм донос ясап йөри торган гадәтең дә бармыни?* (А. Гыйләҗев). Әлеге өзектә *быткычлану* – «әһәмиятсез нәрсәләргә бәйләнү» (ТТАС, 2015: 650) дигәнне аңлата. *Мин мич башында гел ымсындырып, чакырып торган мичкәләрдән янә бер иркәне үзенә* ***бушаткач,*** *күңеленә тагын талымсыз рәхәтлек белән бергә кыюлык иңә* (Т. Галиуллин). Автор *бушату* сүзе аша «эчү, ашау» (ТТАС, 2015: 629) дигән мәгънәне бирә. *Аксу төсендәге барлык милли көчләрне таркату, халыклар арасын* ***бутау*** (Ф. Сафин). Биредә автор *бутау* сүзен «кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бозу» (ТТАС, 2015: 623) дигән мәгънәдә куллана.

Сөйләм теленә караган гади сөйләм лексикасы эмоциональ-стилистик максатларда кулланыла: *Ә син,* ***селәгәй,*** *башың белән уйлап йөрер урынга, йомшак төшең белән фикер йөртергә өйрәнмә* (Ә. Гадел). *Селәгәй* – булдыксыз, җебегән, ихтырсыз булган кешене хурлау мәгънәсен бирү максатында кулланыла торган сүз (ТТАС, 2005: 468). *Ничек әле ул минем белән биергә чыкмады, ә ниндидер* ***килмешәк*** *белән бии, аңа елмая, аның кочагына сыенып әйләнә* (Ә. Гадел). *Килмешәк* – каян булса да килгән, үз булмаган, чит кеше (ТТАС, 2005: 251).

Димәк, китап һәм сөйләм телендә кулланылган эмоциональ-стилистик лексиканың функциональ вазифалары максатка, эчтәлеккә, урынга карап киңәю процессы кичерә. Кеше эшчәнлегенең яңа төрләрендә яисә коммуникатив процессларда билгеле бер стилистик катламга караган эмоциональ-стилистик лексиканың полисемантик үзенчәлекләре нигезендә, лексик чараларның максатка яраклы кулланылышы нәтиҗәсендә функциональ вазифалары тагы да байый. Һәр функциональ стильнең үзенә генә беркетелгән лексик берәмлекләр җыелмасы булуга карамастан, бер стиль катламына кергән лексик берәмлекләрнең икенче стиль катламында кулланылуына чик куелмый.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ: КУЛЛАНЫЛЫШ АКТИВЛЫГЫ

Телнең сүзлек составы, аның башка катламнарына (фонетика, грамматика һ.б.) караганда, тизрәк үзгәрә, чөнки җәмгыять тормышындагы үзгәрешләр телнең лексикасында турыдан-туры чагылыш таба. Яңа предметлар, күренешләр барлыкка килү белән аларны атый торган яңа сүзләр ясала, ә тормыш-көнкүрештән төшеп калган, юкка чыккан күренеш, предметларның атамалары да акрынлап кулланылыштан чыга. Шул ук вакытта күпчелек күренеш, төшенчәләр гасырлар дәвамында яши һәм аларның атамалары да телдә даими кулланыла. Шуңа да кулланылыш дәрәҗәсе буенча лексиканың ике төп катламы аерып карала: актив сүзләр (актив лексик фонд) һәм пассив сүзләр (пассив лексик фонд).

### § 42. Тел белемендә кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составын өйрәнү тарихы

Сүзлек составын актив һәм пассив лексикага аерып өйрәнә башлау, нигездә, сүзлекләр төзү теориясе һәм практикасы, ягъни сүзлекләргә нинди сүзләрне кертү, нindиләрен кертмәү мәсьәләсе белән бәйләнгән. Рус тел гыйлемендә актив һәм пассив сүзлек запасы төшенчәсен беренче булып академик Л. Щерба үзенең «Опыт общей теории лексикографии» дигән хезмәтендә 1940 елда куллана. Пассив сүзлеккә ул сирәк һәм тар даирәдә генә кулланылучы сүзләрне кертә (Щерба, 1994; беренче тапкыр басыла: Известия Академии наук СССР. Отделение литературы и языка. 1940. № 3. С. 89–117). Лексикология буенча моннан соң чыккан хезмәтләрдә пассив лексика чикләрендә, беренче чиратта, искергән һәм яңа сүзләрне тикшерәләр. Әмма актив һәм пассив лексик фондның чикләрен

билгеләүдә әлегә кадәр төрле карашлар яшәп килә. Бер төркем галимнәр чикле кулланылышта булган барлык сүзләрне дә (терминнар, профессионализмнар, диалектизмнар, китап һәм гади сөйләм сүзләре, реалия исемнәре һ.б.) пассив лексикага кертә (Л. Булаховский, Б. Баранникова, А. Реформатский, М. Арапов, Е. Диброва).

Күпчелек лексикологлар исә пассив лексик фонд төшенчәсен таррак мәгънәдә кулланалар һәм аңа бу телдә сөйләшүче барлык кешеләргә дә аңлаешлы, әмма сирәк кулланылган, ягъни инде искергән, кулланылыштан чыккан яки чыгып баручы, яисә әле киң кулланылышка кереп өлгермәгән яңа сүзләрне генә кертәләр (Н. Шанский, М. Фомина, Ф. Сороколетов, В. Максимов, З. Белянская һ.б.).

Кайбер телчеләр фикеренчә, *актив* һәм *пассив сүзлек* төшенчәләре телгә түгел, ә сөйләмгә, кешеләрнең сөйләм эшчәнлегенә карый, шуңа да төрле иҗтимагый һәм территориаль катламга караучы кешеләрнең актив һәм пассив запаслары бердәй булмаска мөмкин. Н. Шанский хаклы рәвештә кисәткәнчә, телнең пассив сүзлек запасын аерым кешенең «һөнәренә, белем дәрәҗәсенә, көндәлек эшенә һ.б.га бәйле пассив сүзләр белән бутарга ярамый» (Шанский, 1964: 140). Аерым галимнәр пассив сүзлек термины урынына «активлык дәрәҗәсе төрле булган» (П. Черных), «периферия зонасындагы» (П. Денисенко), соңгы елларда исә рецептив, ягъни аңлашылучы, әмма кулланылмаучы сүзләр атамаларын да файдалана.

Пассив лексикага караган сүзләрнең бер өлеше В. Даль сүзлегеннән башлап, рус теленең барлык аңлатмалы сүзлекләрендә чагылыш таба. Шул ук вакытта аларга багышланган махсус сүзлекләр дә бар. Мәсәлән, 1971 елда Н. Котелова һәм Ю. Сорокин редакциясендә «Новые слова и значения» дигән сүзлек чыга. Анда XX гасырның 60 нчы елларында барлыкка килгән лексик һәм семантик неологизмнар тупланган. 70 нче елларда барлыкка килгән яңа сүзләр 1977–1985 елларда дөнья күргән «Новое в русской лексике» дигән җыентыкларда чыгылыш тапкан. Бу сүзләр 1995 елда «Словарь новых слов русского языка» дигән зур сүзлектә яңадан басыла. XX гасырның азагы – XXI гасыр башы рус неологизмнары түбәндәге сүзлекләрдә чагылыш тапты: «Новые слова и значения. Словарь-справочник по материалам прессы и литературы 1980-х гг.» (под ред. Е. Левашова. М., 1997); «Толковый словарь русского языка конца XX века: языковые изменения» (под ред. Г. Скляре-

ской. М., 1998); «Толковый словарь русского языка начала XXI в.: актуальная лексика» (под ред. Г. Скляревской. М., 2008); «Словарь перестройки» (Максимов В. М., 1992); «Новый словарь иностранных слов. 2012» һ.б. Бу сүзләрнең шактые, аеруча чит телләрдән алынган яңа сүзләр, татар теленә дә үтеп керде.

Рус теленең искергән сүзләре исә аерым чор лексикасына багышланган тарихи сүзлекләрдә теркәлгән. Аларның иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләр: И. Срезневскийның «Материалы для словаря древнерусского языка» (1883, 1902, 1912 елларда өч том булып басыла, 1958 елда берләштерелгән хәлдә яңадан дөнья күрә); «Словарь русского языка XI–XVII вв.» (Вып. 1–11. М., 1975–1986); «Словарь русского языка XVIII века» (под ред. Ю. Сорокина. М., 1984); Р. Рогожникова белән Т. Карскаяның «Школьный толковый словарь устаревших слов русского языка (по произведениям русских писателей XVIII–XX вв.) (М., 1996) һ.б.

Төрки телләрдә актив һәм пассив сүзлек составы турында мәгълүмат лексикология буенча хезмәтләрдә һәм югары уку йортлары өчен эшләнгән дәреслекләрдә XX гасыр урталарыннан башлап рус лингвистикасында кабул ителгән төркемләү принциплары буенча бирелә. Казакъ һәм нугай телләрендә искергән лексикага багышланган махсус кандидатлык диссертацияләре дә яклапды. Аларда бу телләрдәге архаизмнар һәм тарихи сүзләр төрле яклап җентекле анализлана (Махмутов, 1963; Каракаев, 1999 һ.б.).

Кулланылыш активлыгы ягыннан татар теленең сүзлек составы монографик планда махсус тикшерелмәсә дә, аның аерым катламнарына караган хезмәтләр шактый. В. Солтанов 1918 елда, ук шул чорда пассив лексикага караган, искергән сүзләрнең бер өлешен туплап, кереш мәкалә белән «Онытылган сүзләр» исемле аерым сүзлекчә-брошюра бастыра (Солтанов, 1918) .

Күренекле язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов әдәби тел һәм терминологиягә багышланган хезмәтләрендә 1920 елларда ук «борынгы онытылган сүзләр» (Ибраһимов, 1987: 262), «яңа сүзләр» (Ибраһимов, 1987: 185) турында аерым мәгълүмат бирә, инкыйлабтан соң кайбер сүзләрнең яңа мәгънәләре барлыкка килүен конкрет мисаллар белән дәлилли (Ибраһимов, 1987: 185–189).

Телебездәге искергән сүзләргә беренче гомуми классификация Ш. Рамазанов хезмәтләрендә ясала. Шунысы аеруча әһәмиятле,

«Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» мәкаләсендә галим, сүзләрнең искерү дәрәҗәсен билгеләгәндә, бүгенге әдәби тел нормалары белән теге яки бу язучы иҗат иткән чор арасында аерма үткәрү кирәклеген дә искәртә (Рамазанов, 1954: 77).

Актив һәм пассив кулланылышы ягыннан татар теленең сүзлек хәзинәсенә беренче системалы анализ 1965 елда югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек буларак дөнья күргән «Хәзерге татар әдәби теле» дигән коллектив хезмәттә ясала. Китапның К. Сабиров тарафыннан язылган «Лексикология» бүлегендә рус тел гыйлемендә күпчелек галимнәр тарафыннан кабул ителгән концепция яктылыгында актив һәм пассив сүзлек составы турында төшенчә бирелә, искергән һәм яңа сүзләрнең төрләре һәм үзенчәлекләре кыска, әмма шактый тәфсилле яктыртыла. Биредә шулай ук кайбер искергән сүзләрнең кушма сүзләр, фразеологизмнар составында, ономастикада, башка төрки телләрдә сакланып калулары, сурәтләү чарасы буларак, матур әдәбиятта кулланылулары күрсәтелә, лексикабызда совет чорында барлыкка килгән үзгәреш-яңалыклар яктыртыла (Сабиров, 1965: 59–67, 77–88). Бу хезмәтнең бераз кыскартылып, яңа мисаллар белән баетылган варианты 1969 елда Мәскәүнең «Наука» нәшриятында рус телендә чыккан «Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология» дигән академик басмада да урын алган (Сабиров, 1969: 72–79).

Хәзерге татар әдәби теле һәм лексикология буенча югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслекләрдә кулланылыш активлыгы (дәрәҗәсе) ягыннан сүзлек составына багышланган махсус бүлекчәләр бар. Аларда теория өлеше, нигездә, Н. Шанский хезмәтләрендәгечә яктыртыла, искергән һәм яңа сүзләргә күпләп мисал китерелә (Әхәтов, 1979: 72–78; 1995: 74–78; Сафиуллина, 1999: 100–116; 2002: 90–98; Галимов, 2001: 89–98; Галиуллина, 2007: 49–53, 74–75; 2013: 69–75 һ.б.).

Г. Әхәтовның 1971 елда «Совет мәктәбе» журналында басылган «Татар телендә актив, искергән һәм яңа сүзләр» дигән мәкаләсе бу өлкәдә беренче махсус хезмәт буларак әһәмиятле (Әхәтов, 1971).

Татар әдәби теленең төрле вакытларда үсешен өйрәнүгә багышланган диссертация, монография һәм мәкаләләрдә шул чор сүзлек составындагы актив, яңа һәм искергән сүзләр дә җентекле анализлана. С. Бурнашеваның кандидатлык диссертациясендә

XX гасыр уртасына кадәр совет заманында татар теле лексикасының төрле катламындагы үзгәрешләр өйрәнелә (Бурнашева, 1952).

Хронологик яктан бу үзгәрешләрне өйрәнү А. Зинина хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Аның икетеллелек шартларында татар әдәби теле лексикасының үсешенә багышланган кандидатлык диссертациясендә һәм мәкаләләрендә XX гасырның икенче яртысында әдәби телебездәге искергән сүзләрнең төрләре, яңа сүзләр һәм мәгънәләр барлыкка килү юллары күрсәтелә (Зинина, 1987; 1992).

Р. Мөхиярова XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәби телендә ясалган һәм чит телләрдән алынган яңа сүзләргә күзәтү ясый, совет чорында пассив лексик фондка күчкән кайбер сүзләрнең яңадан активлашуын дәлилли (Мухиярова, 1999; Мөхиярова, 2000; 2009).

Г. Сабированың кандидатлык диссертациясендә 1991–1998 еллар вакытлы матбугаты һәм төрле һөнәри тармак сүзлекләрендә чагылыш тапкан яңа сүзләр һәм мәгънәләр барлана (Сабирова, 1999). Алар аерым сүзлек рәвешендә дә бастырып чыгарыла (Сабирова, 2000). М. Хәйруллинның хәзерге татар әдәби теле лексикасы үсешенә багышланган докторлык диссертациясе һәм монографиясендә актив һәм пассив лексиканың төрле катламнары аерып күрсәтелә, актив кулланыла торган яңа сүзләр исемлеге дә бирелә (Хайруллин, 2000: 110–124). Бу авторның неологизмнарга багышланган мәкаләләре дә бар (Хәйруллин, 1979; 1995).

В. Хаков татар әдәби теле тарихы һәм стилистика буенча хезмәтләрендә лексикабызның төрле чорларда кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан үсеш-үзгәрешләрен дә билгели (Хаков, 1999: 139–140, 144–147; Хаков, 1985: 42–44, 52–62, 76–84).

Пассив лексиканың аерым тармакларына караган махсус хезмәтләр дә бар. З. Сәлахетдинова мәкаләләрендә лексиканың кулланылыш дәрәҗәсе буенча төрләре, искергән сүзләрнең тематик һәм генетик төркемчәләре күрсәтелә (Салахетдинова, 2007 һ.б.).

Ф. Зөлкарнәй, Ә. Йосыпова, Ф. Сафиуллина һәм башка авторлар төрки-татар, гарәп-фарсы чыгышлы «онытылган» сүзләрне әдәби телнең аерым стильләрендә яңадан куллану мәсьәләсен күтәрәләр (Зөлкарнәй, 1996; Йосыпова, 1997; Сафиуллина, 1997; Юсупова, 1997). Гомумән, XX гасырның 80–90 нчы елларында әдәби телебезгә рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән алынган сүзләр урынына совет чорында пассив запаска күчкән кайбер

сүзләрне кайтару турында матбугат битләрендә язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, төрле тармакта эшләүче галимнәр еш кына чыгыш ясады, татар теленең үз җирлегендә ясалган яңа сүзләр дә тәкъдим ителде. Телебездәге яңа сүзләр, аларның ясалу ысулларына багышланган кайбер мәкаләләр исә XX гасыр башында ук дөнья күргән иде инде (Илгизәр, 1927; Хәсәнов, 1939).

Искергән сүзләр нигездә халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият әсәрләрендә чагылыш таба. Шуңа да аларның тел-стиль үзенчәлекләренә багышланган хезмәтләрдә пассив лексика мәсьәләләре дә яктыртыла. Әйтик, Р. Мөгътәсимованың «Татар халык мәкальләренең лексикасы» дигән кандидатлык диссертациясе һәм монографиясенең беренче бүлеге тулысынча искергән сүзләргә багышланган. Аларда мәкальләрдәге бүгенге көн күзлегеннән караганда архаизм һәм тарихи сүзләргә әйләнгән берәмлекләр лексик-грамматик, этимологик һәм тематик яктан анализлану белән беррәттән, искергән сүзләрне өйрәнү тарихына кыскача күзәтү дә ясала (Мугтасимова, 2004: 7–13; Мөгътәсимова, 2005: 11–89).

Төрле чорга караган әдәби ядкәрләр турындагы хезмәтләрдә аларның лексикасы да өйрәнелә. Мәсәлән, Э. Кадирова Мөхәммәдъяр поэмаларында кулланылган төрки-татар чыгышлы сүзләрне 1) хәзерге татар әдәби телендә үзгәрешсез кулланылучы, 2) фонетик һәм морфологик үзгәреш кичергән, 3) мәгънәсе үзгәргән, 4) диалектларда сакланган һәм 5) хәзерге татар телендә кулланылмаучы сүзләр дигән биш төркемгә бүлеп тикшерә (Кадирова, 1999: 7–16). Соңгы дүрт төркем бүген пассив лексикага карый.

Аерым язучыларның, әсәрләрнең тел үзенчәлекләренә багышланган тикшеренүләрдә гадәттә пассив лексиканы стилистик чара буларак куллану мәсьәләләре дә киң яктыртыла, автор кулланган яңа сүзләр барлана. Г. Әмировның Габдулла Тукай (Амиров, 1968), С. Поварисовның Галимҗан Ибраһимов (Поварисов, 1978: 59–69), З. Сәлахетдинованың Вахит Имамов әсәрләренең лексикасы турындагы (Салахутдинова, 2010: 8–16) диссертацияләре һәм башка хезмәтләрендә пассив сүзлек катламнары авторлар яшәгән чорга нисбәтле анализлана.

Лингвопоэтика, стилистика, сөйләм культурасы, әдәбият теориясе буенча хезмәтләрдә дә искергән һәм яңа сүзләр стилистик чара буларак өйрәнелә (Курбатов, 1978: 74–76; 2002: 76–79; Поварисов, 1982: 40–45; Юсупов, 1975: 24–25; 2005: 132–135; Хати-

пов, 2000: 127–131 һ.б.). Лексиканың төрле катламнары (һөнәри лексика, терминнар һ.б.) турындагы кайбер хезмәтләрдә дә пассив лексика турында мәгълүмат бирелә.

Хәзерге татар теле турында сүз барганда, беренче чиратта, актив лексика күз алдында тотыла. Шуңа да бүгенге лексикага кагылышлы хезмәтләрне, гомумән, нигездә актив сүзлек фондын өйрәнүгә багышланган дип исәпләргә була.

## § 43. Татар теленең актив һәм пассив лексик фондына гомуми билгеләмә

Актив лексикага мәгънәләре бүгенге көндә татарча сөйләшүчеләргә таныш булган, сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләр керә. Кайчан барлыкка килүләренә бәйсез рәвештә, аларда искергәнлек яисә яңалык төсмере сизелми. Актив лексика сүзлек составының нигезен тәшкил итә. Бу катламга караган сүзләр, гадәттә, күп мәгънәле була, башка лексемалар белән иркен синтагматик бәйләнешкә керә. Сүз төркеме, килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм стиль ягыннан алар төрле катламнарга карый.

Хәзерге татар әдәби теленең актив лексик фонды берничә дистә мең берәмлектән тора[1]. Морфологик яктан актив лексика барлык сүз төркемнәрен иңли. Мәсәлән, исемнәр: *абага* – «тармакланып торган челтәрсыман споралы үсемлек» (ТТАС, 2005: 15)[2], *ботка* – 1) «Ярмадан суда яки сөттә пешерелгән куе ашамлык; 2) Тәртипсез буталчыклык, <...>» (ТТАС, 2005: 94), *тормыш* – «1) Кешенең җәмгыятьтә яшәү хәле, яшәве; 2) Гаилә корып яшәү хәле, җефетлелек; 3) Гомер юлы, яшәү; 4) Яшәү-эшләү, эшчәнлек күренешләре» (ТТАС, 2005: 549); сыйфатлар: *ак* – «1) Кар, сөт, акбур төсе; 2) Якты, аксыл төстәге; 3) Чал, чаларган; 4) Чиста, керсез <...>» (ТТАС, 2005: 28), *сусыз* – «1. 1) Суы булмаган; 2) Дымнан мәхрүм» (ТТАС, 2005: 488), *язгы* – «1) Яз белән бәйле; яз көне була торган» (ТТАС, 2005: 726); саннар: *ике* – «1) Бер белән өч арасындагы сан <…>; 2) Ике санының микъдары <…>»

---

[1] 2005 елны дөнья күргән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (ТТАС) 58 мең сүз теркәлгән (ТТАС, 2005: 4), аларның берничә меңе генә «искергән», «борынгы» яисә «тарихи сүз» билгесе белән бирелгән.

[2] Сүзләрнең мәгънәләре 2005 елгы аңлатмалы сүзлек буенча бераз кыскартып, грамматик һәм стилистик билгеләрсез, мисалларсыз бирелә.

(ТТАС, 2005: 174), *унау* – «1) Ун булып, ун санында, микъдарында» (ТТАС, 2005: 609), *җидешәр* – «1) Һәр төркемнән җиде итеп» (ТТАС, 2005: 776); алмашлыклар: *без* – «1) <…> Сөйләүченең үзе һәм аның белән бергә булган ишләре, әңгәмәдәшләре, фикердәшләре; 2) Авторның үзе турында белдерүе» (ТТАС, 2005: 79), *бу* – «1) Үзенә якын торган кеше яки әйберне күрсәтү өчен кулланыла; 2) Кемгә яки нәрсәгә дә ишарә итү, ымлау өчен кулланыла» (ТТАС, 2005: 95), *кем* – «1. 1) Нинди яки кайсы кеше икәнен белергә теләгәндә кулланыла <…>. 2. Баш җөмләдәге ул, шул сүзе белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла» (ТТАС, 2005: 246); фигыльләр: *ашату* – «1) Ашарга бирү; 2) Азык белән тәэмин итү, туендырып, тәрбияләп тору; 3) Туену чарасы, яшәү чыганагы булып тору» (ТТАС, 2005: 59), *игү* – «Бөртекле культураларны чәчеп үстерү (ТТАС, 2005: 172), *талпыну* – «1) Очып китәргә теләп, канат кагу <…>; 2) Һавадан һөҗүм итү; <…>, укталу; 3) Чайкалу, селкетү; 4) Көчле омтылу; 5) Омтылыш ясау, дәртләнеп кую» (ТТАС, 2005: 511); рәвешләр: *еш* – «1) Тыгыз, куе; 2) Бер-берсенә бик якын; 3) Бер-бер артлы тиз кабатланып; 4) Әледән-әле,бераз вакыт үткән саен <…>» (ТТАС, 2005: 160), *бүген* – «1) Шушы сөйләнә торган көн; 2) Шушы сөйләнә торган вакыт, хәзерге заман (ТТАС, 2005: 107), *юри* – «1) Чынлыкны хәйлә белән яшерен сынап; 2) Махсус рәвештә, белмәмешкә салынып» (ТТАС, 2005: 723); теркәгечләр: *әмма* – «1) Тезмә кушма җөмләләрдә икенче җөмләнең башында килеп, аны беренчесенә каршы куя; 2) Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен бер-берсенә каршы куя» (ТТАС, 2005: 748), *чөнки* – «1) Иярчен сәбәп җөмләне баш җөмләгә бәйли торган ярдәмлек сүз» (ТТАС, 2005: 671), *яисә* – «1) Үзе теркәгән сүзләр яки җөмләләр белдергән предмет, хәл, вакыйгаларның берсе генә реаль булырга мөмкин икәнен күрсәтә; 2) Санап киткән тиңдәш кисәкләрнең соңгысы башкаларына каршы куела; 3) Әйтелгән фикерне ачыклый яки аңа нәрсә дә булса өсти, конкретлаштыра торган сүз яки җөмләне берләштерү, теркәү өчен кулланыла» (ТТАС, 2005: 726); бәйлекләр: *белән* – «1) Бердәй эш итүне, бердәмлекне, юлдашлыкны белдерә; 2) Берәр объектка төбәлүне, аңа мөнәсәбәтләрне белдергәндә кулланыла; 3) Эш яки хәрәкәтнең нәтиҗәсен, сәбәбен, шартын, максатын белдерә <…>; 5) Эш яки хәрәкәтнең нинди корал, чара белән башкарылуын белдерә <…>» (ТТАС, 2005: 80), *кебек* – «1) Бер нәрсәне икенче нәр-

сәгә чагыштырып, охшатып әйткәндә кулланыла; 2) Берәр нәрсәне шартлы рәвештә чамалап әйткәндә кулланыла; 3) Берәр нәрсә турында чамалауны, икеләнүне, шөбһәләнүне белдерә <…>» (ТТАС, 2005: 245), *хәтле* – «1) Эш-хәрәкәтнең таралыш даирәсен, чиген билгеләү өчен кулланыла; 2) Вакыт һәм сан чиген билгеләү өчен кулланыла; 3) Күрсәтелгән вакыйгадан алда булган эш-хәрәкәтне билгеләү өчен кулланыла <…>» (ТТАС, 2005: 640); хәбәрлек сүзләр: *бар* – «1) Барлыкны, булуны, булганлыкны белдерү сүзе <…>; 2) <…> мөмкин, ихтимал мәгънәсендә; 3) <…> эшләргә кирәклекне белдерү <…>» (ТТАС, 2005: 71), *мөмкин* – «1) Нәрсәне дә булса эшләргә, башкарырга шартлар бар <…>; 2) Нәрсәне дә булса эшләргә рөхсәт ителә, ярый; 3) <…> булуы бар, булуы ихтимал <…>» (ТТАС, 2005: 378), *юк* – «1) Алда бирелгән сорауны, билгеле сүзне кире кагу, аның нәкъ киресе булуын белдерү өчен кулланыла; 2) Нәрсәнең дә булса чынбарлыкта булмаганлыгын белдерә; <…>; 12) Катгый каршы булу мәгънәсен бирә <…> (ТТАС, 2005: 719); модаль сүзләр: *димәк* – «Башкаларның сүзләренә яки үзеңнең алда әйткән фикереңне йомгаклау яисә аңа нәтиҗә ясау алдыннан әйтелә торган сүз» (ТТАС, 2005: 145), *зинһар* – «1) Үтенеп, ялварып мөрәҗәгать иткәндә кулланыла; 2) Кереш сүз тезмәсе составында кулланыла» (ТТАС, 2005: 165–166), *икенчедән* – «Нәрсәне дә булса санаганда тәртип, эзлеклелек ягыннан икенче урында торуны белдерә» (ТТАС, 2005: 178); кисәкчәләр: *иң* – «1) Асыл сыйфат алдында килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый; үтә, бик; 2) <…> Һәммәсеннән артыграк, аеруча; 3) Нәкъ» (ТТАС, 2005: 205), *ләбаса* – «Сөйләмдә әйткән фикернең эчтәлеген көчәйтә» (ТТАС, 2005: 349), *инде* – «1) <…> эшнең тәмамлануына ишарә итә; 2) Боерык фигыльләрдән соң килеп, аңа үтенү, сабырсызлану төсмере кертә <…>» (ТТАС, 2005: 186); ымлыклар: *аһ* – «Түземсезлек, сабырсызлыкны яки тирән борчылу, дулкынлануны белдерә» (ТТАС, 2005: 64), *әһә* – «Нәрсәне дә булса аңлап яисә күреп алганда әйтелә» (ТТАС, 2005: 753), *ура* – «1) Сугышчан өндәү, атакага күтәрелергә чакыру сүзе; 2) Шатлануны, хуплауны белдерү сүзе» (ТТАС, 2005: 610); ияртемнәр: *жу* – «<…> төрле авазлар кушылмасыннан барлыкка килгән шау-шуны белдерә» (ТТАС, 2005: 161), *мияу* – «Мәче кычкырган тавышны белдерә» (ТТАС, 2005: 561).

Этимологик яктан актив лексиканың нигезен гомумтөрки чыганаклы (*алтын, аяз, бай, булу, ике, кара, мин* һ.б.) һәм татар

теленең үз җирлегендә ясалган (*абый, бәләкәй, кулъяулык, савымчы, үткен, эчтәлек, юлдаш* һ.б.) сүзләр тәшкил итә. Башка телләрдән, аеруча гарәп (*азат,вакыт, илһам, кәеф, милләт, фаҗига, хәрби* һ.б.), фарсы (*атна, әгәр, дус, зиндан, карбыз, мәйдан, һәм* һ.б.), рус (*арыш, буразна, завод, күчтәнәч, пароход, өстәл, самолет* һ.б.) һәм рус теле аша Европа телләреннән (*автор, бинт, инженер, кәбестә, машина, операция трактор* һ.б.) алынган сүзләрнең дә күпчелеге хәзерге татар теленең актив фондына керә.

Кулланылыш даирәсе буенча актив лексика, беренче чиратта, гомумхалык теле сүзләреннән тора: *ак, биш, имән, кеше, мин, тиз, язу* һ.б. Үз даирәсендә бүгенге көндә актив кулланыла торган диалектизмнар (*ихата, карагат, пима* һ.б.), жаргон сүзләр (*калым* – табыш, *телик* – телевизор, *сызу* – качу һ.б.), һөнәри сүзләр һәм терминнар (*иҗек, кислород, нурланыш* һ.б.) да актив лексик фондка карый.

Стилистик яктан стильара лексика (*аяк, җылы, йорт, кем, китап, уку, яхшы* һ.б.), тулысынча диярлек, актив лексик фондны тәшкил итә; югары, ягъни китап теле стиле (*былбыл, дәрья, инсан* һ.б.) һәм гади сөйләм (*дөмегү, йолкыш, чучка* һ.б.) сүзләре дә (матур һәм фәнни әдәбиятта гына кулланылган искергән һәм яңа сүзләрдән башкалары) актив лексикага керә. Ягъни актив сүзлек фондын «шушы телдә сөйләшүче барлык кешеләрнең дә көндәлек практикасында куллана торган актив сүзләре дип карау дөрес түгел» (Сабиров, 1965: 59). Аерым территориаль яки иҗтимагый төркем, конкрет стиль өчен генә актив сүзләр дә була. Яшенә, белем дәрәҗәсенә, һөнәренә һ.б.га бәйле рәвештә төрле кешенең актив сүзлек байлыгы төрлечә булырга мөмкин. Мәсәлән, Ф. Сафиуллина билгеләвенчә, «аерым фән белгечләренең телендә актив кулланылыштагы сүзләр икенче бер фән белгечләре телендә, төрле катлам кешеләр телендә бөтенләй кулланылмаска һәм аларга хәтта таныш булмаска мөмкин. Физикларның бик катлаулы актив терминологиясен филологларның бөтенләй белмәве ихтимал; эмоциональ-экспрессив бизәкле сүзләр рәсми мөнәсәбәтләрдә, фәнни хезмәтләрдә бөтенләй урынсыз булырга мөмкин. Шулай да бу сүзләр хәзерге телебезнең актив сүзлеген тәшкил итә» (Сафиуллина, 1999: 100). Башкача әйткәндә, телнең актив яки пассив фонды бу телдә сөйләшүче аерым кешенең сүзлек запасына тәңгәл түгел. Шуңа да сүзнең кайсы катламга каравын билгеләүдә төп критерий – аның бүгенге көн күзлегеннән караганда

телдә кулланылу дәрәҗәсе. Аралашу өчен кирәк булган һәм барлык яки аерым өлкәдә кулланылучы сүзләр актив, ә инде аралашу өчен кирәге калмаган яисә әлегә киң кулланылышка кермәгән сүзләр пассив лексиканы тәшкил итә.

Актив фондка караган сүзләрнең кулланылу ешлыгы төрле була. Кайбер сүзләр, искелек яисә яңалык төсмере булмыйча, сирәк яисә аерым кешеләр тарафыннан гына кулланыла, алар сүзлекләрдә «сирәк кулланылышта» дигән тамга белән бирелә, мәсәлән: *басмак* – «*ис. сир.* Уен коралы теле» (ТТАС, 2005: 73), *имегү* – «*фг. сир.* Имәсе, ашыйсы килү» (ТТАС, 2005: 184), *каракаләм* – «*җый.ис. сир.* – Кара, каләм, карандаш шикелле язу әсбаплары» (ТТАС, 2005: 233).

П а с с и в л е к с и к а дип бүгенге көндә аралашу, аңлашу өчен кирәге булмаган, сирәк кулланыла торган сүзләр атала. Алар яки инде тулысынча кулланылыштан чыккан яисә чыгып бара, я булмаса, әле яңа гына барлыкка килү сәбәпле, киң кулланылышка кереп өлгермәгән. Шуңа да телнең пассив лексик фондын, бердән, теге яки бу кешенең аның һөнәренә, белеменә, яшәешенә бәйле пассив сүзлек запасы белән, икенчедән, кулланылыш сферасы яки стиль ягыннан чикләнгән сүзләр белән бутарга ярамый. Пассив лексика нигездә тарихи темага караган әсәрләр, фәнни әдәбият һәм, өлешчә, көндәлек матбугат телендә генә чагылыш таба.

Пассив сүзлек фонды ике зур төркемгә аерыла: искергән сүзләр һәм яңа сүзләр.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИСКЕРГӘН СҮЗЛӘР

И с к е р г ә н с ү з л ә р дип инде көндәлек тормышта бөтенләй кулланылмый торган яисә төрле лингвистик һәм экстралингвистик сәбәпләр аркасында актив кулланылыштан чыккан сүзләргә әйтәләр. Кулланышта булмасалар да, искергән сүзләрнең мәгънәсе, гадәттә, аңлаешлы була: *алпавыт, аршын, чабата, кабилә, ясак* һ.б.

Кайбер искергән сүзләрнең мәгънәсен исә төрле белешмә әсбаплар, сүзлекләр аша гына ачыклап була: *мәгыйшәт* (тормыш), *буга* (үгез), *барымта* (мал тартып алу өчен яу) һ.б.

Сүзләрнең искерү дәрәҗәсе, сәбәбе, хәзерге әдәби телдә кулланылу мөмкинлеге һәм характеры төрлечә була.

Күп сүзләрнең искерүе экстралингвистик, ягъни телгә бәйле булмаган, иҗтимагый сәбәпләр белән аңлатыла. Мәсәлән, нинди дә булса предмет, күренешләрнең юкка чыгуы аларны атаган сүзләрнең дә юкка чыгуына китерә: *чабата, киле, көбә, айбалта, ыруг, ышна, ясак* һ.б. Җәмгыять тормышындагы кискен үзгәрешләр сүзләрнең күпләп, хәтта тулы тематик төркемнәр белән искерүенә китерә. Мәсәлән, 1917 елгы инкыйлабтан соң капиталистик җәмгыять (*алпавыт, барщина, бояр, имана, кенәз, оброк, фабрикант* һ.б.), иске идарә системасы (*патша, губерна, волость, жандарм, кантон, наместник, өяз, урәтник* һ.б.), дин (*ахун, зәкят, имам, мәдрәсә, мәзин, фәтва, хөтбә* һ.б.) белән бәйле күп сүзләр пассив лексикага күчте. 1990 еллардагы үзгәрешләр, киресенчә, совет җәмгыятенә, коммунистик идеологиягә мөнәсәбәтле сүзләрнең искерүенә китерде (*автономияле республика, агитпункт, колхоз, совхоз, комсомол, октябрят, милиция* һ.б.).

Аерым сүзләрнең искерүе лингвистик сәбәпләр белән дә аңлатыла. Әйтик, телдәге экономия законы уңышлырак синонимнары булган кайбер сүзләрнең пассив лексикага күчүенә китерергә мөмкин: *гандәлиб* – сандугач, былбыл; *көтепханә* – китапханә, библиотека; *наиб* – ярдәмче, урынбасар; *баструк* – төрмә, зиндан; *мәхкәмә* – суд һ.б. Авыррак әйтелешле (*груһ* – төркем, *тәрәккыят* – алгарыш, прогресс һ.б.), телдә башка омонимы булган (*ат* – исем, *ут* – үлән һ.б.) синоним сүзләр беренче чиратта искерә.

Сүзләрнең, искереп, пассив лексик фондка күчүе гадәттә озак вакытларга сузыла. Кайбер сүзләр әдәби телдә кулланылыштан чыксалар да, гади сөйләм стилендә, көнкүрештә кулланышта калалар. Мәсәлән, *аршын, пот, сажин* кебек иске үлчәү берәмлекләре өлкәннәр, аеруча авыл кешеләре сөйләмендә әле дә кулланылалар. Шул ук вакытта телдә бик аз гына яшәп искергән сүзләр дә була. Мәсәлән, *комбед, коммун, ликбез, нэпман* кебек сүзләр XX гасырның 20 нче елларында кулланышка кереп, 30 нчы елларда ук пассив сүзлеккә күчтеләр. XX гасыр ахырында гына телгә кергән *ваучер, видеосалон, пейджер, хәбәрдарлык* кебек сүзләр дә кыска гомерле булды.

Шул ук вакытта кайбер искергән сүзләр вакытлар үтү белән яңадан активлашырга мөмкин. Мәсәлән, совет чорында кулланыштан төшеп калган яисә чит ил реалиясе буларак кына кулланылган *гимназия, лицей, бакалавр, магистр, Дума, губернатор,*

*меценат* кебек сүзләр XX гасыр ахыры татар әдәби теленең актив лексикасына кайтты. 1979–1981 елларда дөнья күргән татар теленең өчтомлык аңлатмалы сүзлегендә «искергән сүз» тамгасы белән бирелгән *абунәче, алтатар, басмаханә, зыялы, иганәче, йолдызнамә, кизү, корылтай, чәчтараш* сүзләре дә хәзерге матбугатта шактый еш кулланыла: *Әгәр баллистик тикшерү* ***алтатарны*** *атуга яраклы дип тапса, милициядә әлеге коралны кабул итеп алачакла*р («Мәдәни җомга»). *Безнең эшнең нигезендә* ***әбүнәчеләр*** *санын арттыру тора* («Кызыл таң»). *Безнең Казанда гына да 20 дән артык татар* ***басмаханәсе*** *эшли* («Сабантуй»). *Шуңа күрә... малтабарларны, кооператорларны, конкурсның* ***иганәчеләре*** *булырга чакырабыз* («Сөембикә»). *Шул нигездә, дин, фән, гореф-гадәтләр, сихерчелек, ырымнар,* ***йолдызнамә*** *һ.б. бик күп, бик күп гыйлем тупланган* («Сөембикә»). *– Крайкомга шалтыратыгыз, әмер булса, озатам, – ди* ***кизү*** *кыз* («Ватаным Татарстан»). *Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең XV* ***корылтайда****н соңгы беренче утырышы булды* («Казан утлары»). *Әмма алар без йөри торган* ***чәчтарашка*** *яисә теш дәвалаучыга бара бит* («Татарстан яшьләре»).

XX гасыр башында пассив сүзлеккә күчеп, әдәби телдә гасыр азагында яңадан кулланыла башлаган сүзләр арасында гарәп-фарсы алынмалары аеруча күп, алар, еш кына, рус сүзләрен һәм рус теле аша Көнбатыш телләреннән кергән кайбер халыкара сүзләрне алыштыралар: *вазгыять* (ситуация), *вакыф* (фонд), *ватандар/ватанпәрвәр* (патриот), *вәсика* (документ), *гаделия* (юстиция), *гаммә* (масса), *гамәлият* (производство, операция), *дәһри* (атеист), *зәнки* (негр), *икътисад* (экономика), *иттифак* (союз), *канун* (закон), *кәсәбә* (промысел), *кыйтга* (материк), *маддә* (статья), *матбага* (типография), *мәхкәмә* (суд), *мирасханә* (архив), *моназарә* (дискуссия), *мөддәт* (срок), *мөхбир әгъза* (член-корреспондент), *мөһәндис* (инженер), *мөһер* (печать, штамп), *нашир* (издатель), *низамнамә* (устав), *нотык* (доклад), *өслүп* (стиль), *сәнәгать* (промышленность, индустрия), *сәрмая* (капитал, инвестиция), *сәясәт* (политика), *тәрәккыят* (прогресс), *фазә* (пространство), *һиҗрәт* (эмиграция), *шартнамә* (договор), *шәкел* (форма), *шигарь* (лозунг), *ширкәт* (компания, предприятие), *шура* (совет) һ.б.

Пассив лексикага күчү сәбәбе буенча искергән сүзләр ике төркемгә бүленә: тарихи сүзләр һәм архаизмнар.

## § 44. Татар телендә тарихи сүзләр һәм аларның төрләре

Тарихи сүзләр – кулланылыштан төшеп калган предмет, күренеш, төшенчәләрнең атамалары, ягъни мондый сүзләр үзләренең денотатлары белән бергә искерә. Тематик яктан караганда аларның күпчелеге түбәндәге төркемнәргә карый:

1) төрле тарихи сословие, вазифа, һөнәр исемнәре: *алпавыт, армай, асламчы, атчабар, аякчы, әкә, әмирдар, бабачы, барабызчы, барчук, баскак, батрак, бәк, би, бояр, бурлак, вәзир, дисәтник, ишан, каган, кара, каравыш, карачы, кенәз/князь, колхозчы, коллаучы, комсомол, корыкчы, көң, кулак, куравыч, кургавыл, күремче, кылавыз, лашман, морза, октябрят, олугбәк, патша, сарраф, тархан, тоснак, хан, чапкын, чура, чыракчы, ялчы, ямчы, ясакчы* һ.б.;

2) хәрби өлкәгә караган сүзләр: *айбалта, аткыюч, әдернә, әләмән, балга,барымта, бунчук, бычкы, баскын, гүәрдин, йөзбаш, кирмән, козак, корак, кутаз, көбә, меңбаш, найдә, нөгәр, никрут, садак, саин, телем, тукташ, туплан, туснак, төмән, шайман, ярак* һ.б.;

3) элек кулланылышта булган үлчәү берәмлекләре: *аршын, әчмуха, батман, бизмән, биршук, гөрәнкә, дисәтинә, илле, кадак, карыш, киләп, мыскал, подаука, почык, сажин, сөян, тотам, түтәрәм, чакрым, фәрсах* һ.б.;

4) элеккеге административ-территориаль берәмлек һәм төрле оешма исемнәре: *ВЛКСМ, волость, кабилә, каганлык, ханлык, кантон, колхоз, коммуна, кор, КПСС, совхоз, СССР, өяз, урда, ыруг* һ.б.;

5) үткәндәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган сүзләр һәм хуҗалык кирәк-яраклары атамалары: *әвен, әстә, барабыз, гөбе, дорба, җилпуч, зобана, зурат, имана, каба, казаки, кәкерчек, киле, кирге, кисап, кисет, көнҗәлә, лакан, саба, сәндерә, сәке, сука, талкы, тастар, тимерхут, торыпча, турсык, чабагач, чабата, чарык, чата, чуман, шөшле, шүре, ышна, ыштыр, япанча, ясак* һ.б.

Кайбер хезмәтләрдә *тарихи сүзләр* төшенчәсенең мәгънәсен киңәйтеп, алар исәбенә *букча, камзул, түбәтәй, сәүдә, таҗ, казна* (Әхәтов, 1979: 75), *тылмач, кассап, имче, ганимәт, улҗа* (Мөгътәсимова, 2005: 52, 55), *алай, мәргән, һөрүр* (Салахутдинова, 2010: 13) кебек искергән сүзләрне дә кертәләр. Әмма моның белән тулысынча килешеп булмый, чөнки бу сүзләрнең денотатлары әле кулланыштан чыкмаган: *букча* – сумка, *тылмач* – тәрҗемәче, *кас-*

*сап* – мал суючы, *ганимәт, улҗа* – трофей, *алай* – гаскәр, *груһ/ һөруһ* – төркем һ.б.

Кайбер сүзләрнең аерым мәгънәләре генә искерә. Мәсәлән, хәзер *кура* сүзе «биек үләнчел үсемлекләр һәм куак сабакларыннан тотылган киртә, койма» (ТТАС, 2005: 296), *курган* сүзе «кальга, кирмән дивары» (ТТАС, 2005: 297), *тамга* сүзе «имза функциясендә йөргән <... > шартлы билге» (ТТАС, 2005: 512), *әдәбият* сүзе «әдәпкә өндәгән әсәрләр» (ТТАС, 2005: 742) мәгънәләрендә кулланылмый.

Денотаты кулланылыштан төшеп калып, төп мәгънәләрендә пассив сүзлеккә күчкән сүзләр күчерелмә мәгънәсендә актив сүзлектә калырга яки кире кайтырга мөмкин. Мондыйларга мисал итеп *калкан* сүзен «саклагыч, сакчы», *набат* сүзен «тревога, ярдәмгә чакыру», *сөңге* сүзен «формасы белән сөңгегә охшаган нәрсә (мәсәлән, боз сөңгесе)» (ТТАС, 2005: 501), *тугра* сүзен «эмблема, вензель», *ярлык* сүзен «әйбернең бәясен, атамасын язып ябыштырган кәгазь (кием ярлыгы) (ТТАС, 2005: 734) мәгънәсендә куллануны күрсәтергә мөмкин.

*Куык* сүзе «лампа кебек яктырткычларның пыяла торбасы» мәгънәсендә *лампа* сүзе кебек үк хәзер искерде, әмма «1. Сыеклыкта барлыкка килеп, һава яки берәр газ тулган үтә күренмәле шар», 2) *махс.* Тереклек ияләрендә һава яки сыеклык тулган кечкенә янчыксыман әгъза» (ТТАС, 2005: 300) мәгънәләрендә актив кулланылышта. Гадәттә күпмәгънәле сүз беренче, туры мәгнәсендә искереп, пассив сүзлеккә күчсә дә, күчерелмә, яңа мәгънәләрендә актив сүзлек фондында кала. Мәсәлән, *җәя, кылыч, калкан* кебек сүзләр сугыш коралы мәгънәсендә бүген инде тарихи сүзләр, әмма күчерелмә мәгънәләрдә, аерым алганда, спорт инвентаре атамасы буларак, актив лексикага карыйлар. Шуңа да мондый очракларны семантик тарихи сүзләр, ягъни аерым мәгънәләре генә пассив фондка күчкән лексемалар дип карарга була.

Мисаллардан күренгәнчә, тарихи сүзләр, барысы да диярлек, исем сүз төркеменә карый, чөнки бары тик зат, предмет, күренешләр генә кулланыштан чыга ала. Ә башка сүз төркемнәренең денотатлары, гадәттә, искерми.

Этимологик яктан тарихи сүзләрнең зур күпчелеге төрки-татар чыгышлы: *алпавыт, армай, барабыз, барымта, баскын, батман, бәк/би, гөбе, җилпуч, каган, кадак, карачы, кәкерчек, киле,*

*кирге, көбә, көң, саба, урда, чабагач, чыракчы, шүре, ыруг, ышна, ямчы, ярлык, ясак* һ.б.

Гарәп (*әләмән, кабилә, мыскал*) һәм фарсы (*аршын, найзә, патша*) чыгышлы тарихи сүзләр күп түгел.

Рус теленнән (*әчмүха, батрак, гөрәнкә, дисәтинә, көнҗәлә, өяз, подаука, сука*) һәм рус теле аша Европа телләреннән (*жандарм, лашман, кантон*) күптән үзләштерелгән сүзләр белән беррәттән, XX гасырда гына кулланышка кергән кайбер рус алынмалары да пассив сүзлеккә күчте: *большевизм, ВЛКСМ, колхоз, комсомол, меньшевик, НЭП, октябрят, парторг, совхоз, СССР*. Бу сүзләрнең искерүе илнең иҗтимагый тормышындагы үзгәрешләр белән бәйле.

Көнкүрештәге үзгәреш, алга китеш тә кайбер сүзләрнең кулланылыштан чыгуына китерә. Әйтик, хәзер *көянтә* (ике чиләк белән су ташу җайланмасы), *чут* (исәпләү әсбабы) кебек эш кораллары кулланылмый диярлек.

Кайбер тарихи сүзләрнең актив лексик фондта омонимнары бар. Мәсәлән, элек буйсынган кешеләрне атау өчен кулланылган *кара* исеме сыйфат һәм «язу әсбабы» мәгънәсендәге исем; *түрә* I – *тар.* «1) Закон, зан. 2) Закончы, хәким, судья» һәм *түрә* II – 1) Идарә баскычында эшли торган яисә урын алган кеше, чиновник...» (ТТАС, 2005: 602); *ук* – «ераклык берәмлеге, атылган ук ераклыгына тигез ара» һәм «җәядән ату өчен җиңелчә нечкә чыбык башына үткен очлы металл беркетеп ясалган корал», «ана бөҗәкләрдә агу җибәрү органы», көчәйткеч мәгънәле *ук* сүзләре һ.б.

Илдәге, тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, кайбер тарихи сүзләр, мәгънәләрен үзгәртеп, яңадан кулланышка кайта ала. Мәсәлән, *баскын* – «*тар*. 1. Тыныч халыкларга, кабиләләргә каршы оештырылган талау походлары. 2. *диал*. Баскынчы» (ТТАС, 2005: 73) – сүзе Чечнядагы вакыйгалар уңаеннан «агрессор» мәгънәсендә яңадан кулланышка кайтты: *Рәсәй* ***баскыннарының*** *бу сугышы Әлмәт шәһәрен дә читләтеп үтмәде* («Ватаным Татарстан»). Аерым газета-журнал битләрендә шушы ук мәгънәдә *баскак* – «*тар.* Алтын Урда чорында хан биләмәләрендә халыктан салым җыю өчен куелган кешеләр» (ТТАС, 2005: 73) – тарихи сүзен дә куллаңалар: *Чәчәннәр әле һаман Рәсәй* ***баскакларына*** *каршы тора* («Шәһри Чаллы»). *Җыен* – «*иск*. Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен җыйналган җәмәгать җыелышы» (ТТАС, 3 т., 1981: 796) – сүзе,

шундый җәмәгать башлангычында эшләүче оешмалар уздырган ирекле халык җыелышларының яңадан гамәлгә керүе нәтиҗәсендә активлашуы белән бергә, сбор, сессия, конференция сүзләре урынына, ягъни яңа мәгънәдә дә кулланыла башлады: *Узган елның август аенда балалар оешмасы активистларының ... «Лидер» республика **җыены** (сборы) булган иде* («Сабантуй»). Т*атарстан Фәннәр академиясендә узган олуг **җыенда** күпләр күңелендә яңарды бу фикер...* («Ватаным Татарстан»). *Ким дигәндә 200 кеше катнашачак **җыенда** Свердловск өлкәсе татарлары дүртенче корылтайга делегатлар да сайламакчы* («Ватаным Татарстан»).

Төшенчәләрнең бердәнбер атамасы буларак, тарихи сүзләрнең актив лексикада синонимнары юк. Шуңа да бүгенге көндә дә алар тарихи хезмәтләрдә һәм дәреслекләрдә, шулай ук төрле тарихи чорларга багышланган әдәби әсәрләрдә, фильмнарда гына кулланылалар. Мәсәлән, Н. Фәттах, М. Хәбибуллин, В. Имамов кебек язучыларның тарихи романнарында мондый сүзләрне күпләп табарга була. Чөнки тарихи сүзләрдән башка конкрет чорның иҗтимагый, икътисади, сәяси, хәрби, мәдәни, көнкүреш үзенчәлекләрен чагылдырып булмый.

Бу фикерне дәлилләү максатыннан тарих дәреслегеннән һәм фәнни монографиядән ике өзек китерәбез:

*Идарә итүдә беренче планга ир-егетләр чыга. **Матриархат патриархат** белән алмашына. **Община** әгъзалары арасында хезмәтнең яшькә һәм җенескә карап бүленеше (җыючылар һәм аучылар) үз урынын катлаулырак бүленешкә бирә.<...>*

*Кешеләр берлегенең яңа формасы – **кабиләләр** барлыкка килү социаль үзгәреш була. **Кабиләләр** бер-берсенә якын торган, **ыруг башлыклары,** ягъни **аксакаллар** җитәкләгән авыл **общиналары** берләшмәсеннән гыйбарәт була. **Ыруг** башлыклары **общинаның** бүтән әгъзаларыннан көчле һәм кыю, батыр һәм тапкыр, тәҗрибәле һәм үз тәҗрибәләрен **кабиләдәшләренә** тапшырырга сәләтле булулары белән аерылып торган. Алар **кабиләнең ыруг** башлыклары советын хасил иткән. **Кабиләнең** абруйлы әгъзалары җыелышы – **Җыен** – кабилә эшләрен алып барыр өчен хәрби отряд (**дружина**) белән бергә **кабилә башлыгын** билгеләгән. Билгеләнгән **кабилә башлыгы кабилә** гореф-гадәтләре нигезендә һәм **кабилә** ихтыярына таянып эш иткән* (Сабирова Д., Шәрәпов Я. Ватаныбыз тарихы. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 15).

*Бөтен татар халкын чукындыруга керешер алдыннан Петр* ***патша*** *татар* ***аксөякләре – морзаларны*** *урыс диненә күчереп бетерүне тели. Сәбәбе: 1704–1711 еллардагы Идел–Кама буйларында яңа салымнарга түзә алмыйча күтәрелгән* ***восстаниеләрдә морзалар*** *һәм* ***йомышлы татарлар*** *бик актив катнашалар, татар авыллары тирәсендәге урыс авылларындагы чиркәүләрне җимерәләр. Восстаниенең төп оештыручылары* ***морзалар*** *затыннан булганлыгын яхшы аңлаган хакимият бу* ***феодал*** *катлавын юкка чыгару өчен бик мәкерле эш башлый. Русия илендә яшәгән мөселманнарны христианлаштыру һәм урыслаштыру юлында киртә булган авторитетлы* ***аксөяк-морзаларны*** *юкка чыгару кирәклеген* ***патша*** *яхшы аңлаган бугай.* ***Морзаларның*** *язмышында Петрның фәрман-указлары иң мөһим рольне уйныйлар.*

*1713 елның 3 ноябрендә кабул ителгән указ нигезендә Казан һәм Азов* ***губерналарында*** *яшәгән мөселман* ***морзаларның утарларында*** *православие динендәге крәстияннәр булса, алар да ярты ел эчендә чукынырга тиеш булалар.* (Ислаев Ф. Батырша восстаниесе. 1755 ел: Тарихи очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 17).

Әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан тарихи сүзләргә мисаллар пассив лексиканың функциональ-стилистик вазифасына багышланган бүлекчәдә китерелә. Татар әдәби телендә төрле чорларда кулланылып, бүген пассив лексикага күчкән тарихи сүзләрне татар әдәби теле тарихына багышланган хезмәтләрдә күпләп табарга мөмкин (Хаков, 1993: 195 һ.б.).

## § 45. Архаизмнар һәм аларның төрләре

Архаизмнар – нинди дә булса предмет, күренеш, төшенчәнең искергән атамалары. Тарихи сүзләрдән аермалы буларак, архаизмнарның актив лексикада синонимнары була. Башкача әйткәндә, архаизмнар – төрле сәбәпләр аркасында башка сүзләр тарафыннан телдән кысрыклап чыгарылган сүзләр. Архаизмнарны гадәттә саф лексик, лексик-семантик, лексик-фонетик һәм лексик-морфологик дигән төрләргә аерып карыйлар (Әхәтов, 1971 һ.б.). Без аларны К. Сабиров һәм Ф. Сафиуллина хезмәтләрендәгечә лексик, семантик, фонетик һәм морфологик архаизмнар дип атыйбыз.

1. Лексик архаизмнар – барлык мәгънәләрендә дә кулланыштан чыккан, искергән сүзләр: *алтатар* – наган, револьвер, *ат* – исем, *арзу* – дәрт, азарт, *аяк* – савыт, касә, *бетек* – язу, *бо-*

*радәр* – ир туган, *болак* – чишмә, елга, *дәкыйка* – минут, *җәридә* – газета, *зынҗыр* – чылбыр, богау, *изах* – имла, орфография, *ирекле* – доброволец, *ислах* – реформа, *истирахәт* – ял, рәхәт, *ихтилал* – бунт, *ифадә* – аңлатма, *казамат* – төрмә, *кафия* – рифма, *кү* – дан, *матбага* – типография, *мәдех* – мактау, *моназара* – бәхәс, *нар* – дөя, *сала* – авыл, *талуй* – диңгез, *туг* – байрак, *турун* – онык, *үкүш* – күп, *чиру, сү* – гаскәр, *чыгай* – ярлы, *яблак* – явыз һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, бу сүзләр белдергән төшенчәләрнең хәзерге актив лексик фондта башка атамалары кулланыла.

2. Семантик архаизмнар – аерым мәгънәләре генә искергән сүзләр: *әрдәнә* сүзе «запас», *ил* сүзе «кабилә берлеге; халык» , *йорт* сүзе «ил; нәсел-нәсәп, династия», *кап* сүзе «тире, мех», *капот* сүзе «киң итеп тегелгән күлмәк», *кара* сыйфаты «укымаган, надан», *кот* исеме «бәхетле», *кән* сүзе «кояш», *тары* сүзе «иген җире», *тун* сүзе «гомумән кием», *түрә* сүзе «закон», *ялчы* исеме «хезмәтче», *ярлык* сүзе «указ, грамота» мәгънәләрендә бүгенге көндә кулланылмый.

Кайбер архаизмнарның актив сүзлек составында омонимнары да бар. Мәсәлән, «исем, дан» мәгънәле *ат* архаизмына «эре йорт хайваны» мәгънәсендәге ат сүзе, «савыт» мәгънәсендәге *аяк* сүзенә «кеше һәм хайваннарның басып йөри торган әгъзасы» мәгънәсендәге аяк исеме, элек «үлән» мәгънәсендә йөргән *ут* сүзенә «яна торган әйберне чолгап алган ялкын» мәгънәле ут сүзе омоним булып торалар һ.б. Аларны семантик архаизмнар белән бутарга ярамый.

3. Фонетик архаизмнар – аваз составы үзгәргән сүзләр: *аглау* – елау, *арыг* – ару, *баг* – бау, *берлә, берлән, илән, илә* – белән, *богдай* – бодай, *еглау* – елау, *имди/имде* – инде, *Итил* – Идел, *кеби* – кебек, *кечег* – кече, *кодык* – кое, *кыйхытлык* – кытлык, *маҗар* – мадъяр/венгр, *мәсҗид/мәсҗет* – мәчет, *олуг* – олы, *ошбу/ушбу* – бу, *сарыг* – сары, *сасык* – сасы, *сач* – чәч, *төя* – дөя, *угыл* – ул, *харита* – карта, *чыраг* – чыра, *ягмур* – яңгыр һ.б. Сүз үзе сакланып, аның аерым авазы гына үзгәргәнлектән, тел белемендә бу төрне лексик-фонетик архаизм дип атау да күзәтелә (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 540).

Бу төр архаизмнарда төрки телләр, шул исәптән татар теленең элекке чорлары өчен хас булган түбәндәге фонетик күренешләр сакланган: сузык авазларның ирен гармониясе, хәзерге [э] авазы

урынына югары күтәрелешле [и] сузыгын куллану, сүз ахырында һәм сүз уртасында [г] авазы куллану, сүз башында саңгырау [т] урынына яңгырау [д] авазы әйтү, аерым сүзләрдә *рл, лт* аваз тезмәләре куллану һ.б. (Хаков, 1993: 101–125).

4. Морфологик архаизмнар – грамматик формасы үзгәргән (искергән) сүзләр. Мондыйларга мисал итеп исемнең *-мыз,-ңыз* тартым кушымчаларын (*раббымыз, йортыңыз*); фигыльләрдә инфинитивның *-мак/-мәк, -мага/-мәгә* (*атламак, кылмак, санламак, түзмәк, үтәмәк; бармага, йөрмәгә*), исем фигыльнең *-ыш/-мыш* (*азмыш, барыш, бармыш, йөреш, килеш*), боерык фигыльнең *-гай/-гәй, -гыл/-гел,...әйлә* (*бармагыл, кылгыл, килгәй, гафу әйлә*), сыйфат фигыльнең *-мыш* (*картаймыш көн, күрмәмеш булды*) формаларын күрсәтергә була. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә III зат тартым белән төрләнгән исемнәргә төшем килешендә *-н* урынына иске татар әдәби теле өчен хас булган *-ыны/-ене* кушымчасын ялгау сакланган: *Түземлегә таулар ияр* ***башыны****, түземсезгә этләр җияр* ***башыны;*** *Хак* ***җирене*** *табар* (Г. Мөгътәсимова). *-чак/-чәк* (*иренчәк, онытчак, оялчак*) һәм *-как/-кәк/-гак/-гәк* (*сөзгәк, өркәк, очкак*) кушымчалы исемнәр һәм сыйфатлар да хәзер пассив лексикага карый (Җәләй, 2000: 46, 49).

Сүз үзе сакланып, аның аерым формасы гына үзгәргәнлектән, тел белемендә бу төрне лексик-морфологик архаизм дип атау да күзәтелә (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 540).

Генетик яктан архаизмнарның күпчелеген төрки-татар чыгышлы сүзләр тәшкил итә: *аба, абсә, азман, айдын, аймыл, акку, акман, албай, алпар, алып, амрак, әкә, бикә, борак, буга, бүз, букча, дәхи, җик, җиү, заң, иге, илә, им, иркәк, иргәш, йорчы, кадаш, казгану, кам, камуг, каруг, маң, тикән, олата, олыс, өкәү, саба, сагым, соңра, сөлтәр* һ.б.[1].

Гарәп һәм фарсы телләреннән кереп, XX гасыр урталарында архаиклашкан сүзләр тагын да күбрәк: *абыз* – укымышлы, *анар* – гранат, *армут* – груша, *әҗнәби* – чит кеше, *баб* – бүлек, *борадәр* – ир туган, *дәкыйка* – секунд, *дәфга* – мәртәбә, *горбәт* – чит җирләр, *задә* – ир бала, *игътираз* – бәхәс, *имля* – орфография, *имтияз* –

---

[1] Кара: Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. 1. 543 б.; Т. 2. 567 б.

мактау кәгазе, *ислах* – реформа, *истирахәт* – ял, *иттифак* – союз, берлек, *кари* – яттан Коръән укучы, *карья* – авыл, *матбага* – типография, *мәркәз* – үзәк, *миһман* – кунак, *сәях* – сәяхәтче, *сәмән* – акча, *таифә* – төркем, *фасикъ* – азгын, *хәттат* – каллиграф, *шималь* – төньяк һ.б.

Рус теленнән һәм рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләр арасында архаизмнар аз: *баструг, бутышник, жалунҗә, казамат, милиция, экю* һ.б. Бу сүзләр башта рус телендә искереп, татар телендә дә пассив фондка күчте.

Лексик-грамматик яктан архаизмнарның күпчелеге исем (*арзу, әл, балпан, багбан, бетек, лөгать, сөаль, сырга, шәкел, хөррият, һәндәсә, фида*) һәм сыйфат (*алгыр, бортак, бүз, җыбыткы, карсак, койты, ку, купай, нәкыс, туксак, ялман*) сүз төркеменә карый. Фигыльләр (*аңгару, дүнү, җию, казгану, котаю, йөгенү, эстәү*), рәвешләр (*әүла, битәр, даим, дәхи, тиген*) һәм алмашлыклар (*кемсә, ошбу, шунча*) азрак. Ярдәмлек сүз төркемнәреннән теркәгечләр (*вә, вәләкин*), бәйлекләр (*берлә, илә, кеби*), кисәкчәләр (*имди*) арасында да архаик сүзләр очрый.

Архаизмнарның тематикасы төрле. Татар халык мәкальләрендә кулланылган искергән сүзләргә җентекле анализ ясаган Г. Мөгътәсимова исем сүз төркеменә караган лексик архаизмнарны гына да 15 тематик төркемчәгә бүлеп тикшерә: 1) хис итүче, теләк белдерүче, фикерләүче зат буларак кешегә хас булган сыйфатлар: *ырыс* – бәхет, *шәһвәт* – женси дәрт, *рия* – икейөзлелек, *гасый* – Алладан баш тарткан, *иҗтиһад* – тырышлык, *хәя* – оят, *ноксан* – җитешсезлек, *шәхсият* – шәхси мәнфәгатьләр, *миннәт* – бурычлылык, *хасият* – үзенчәлек, *фәләкат* – бәхетсезлек, *гыйльләт* – кимчелек, *һиммәт* – тырышлык, *шәүкәт* – көч, *чап* – дан, *сәгадәт* – бәхет, *гөнаһкарь* – гөнаһ, *тәүбәкарь* – тәүбәче, *гуаһ* – шаһит, *насрат* – котылу, *җәсарәт* – гайрәт, *вафа* – тугрылык, *кибер* – горурлык, *фәһем* – акыл, *менәз* – гадәт, *кон* – кыяфәт, *зарурат* – чарасызлык, *касд, каст* – максат, *ырай* – уй, фикер, күңел, *тәмгы* – зур теләк, комсызлык, *талига* – кеше, шәхес табигатенең уңай яклары, әйбәт характер, ипле холык һ.б.; 2) абстракт төшенчәләр: *мән* – зат, мәгънә, *кару* – каршылык, *маза* – тынычлык, *йот* – афәт, *төһмәт* – гаеп, *нөктә* – кер, *җөя* – система, *моназара* – бәхәс, *дим* – өндәү, үгет, *мәслихәт* – киңәш, *тәкаллеф* – шартлы тәртип, *назар* – каршы, *мәел* – теләк, *нәкыйль*– күчереп алынган сүз, *зәвал* – чик һ.б.;

3) табигатькә бәйле атамалар: *Өлкәр* – Үгез Бозау йолдызлыгындагы Иләк йолдыз төркеме исеме, *асман* – күк, *как* – корыган, *сил* – хәтәр ташкын, *болак* – чишмә, *чаң* – тузан, *татыр* – тарлавык җир, *тарлан* – сөрелгән җир, *уба* – чокыр һ.б.; 4) зодиак йолдызлыгы һәм ай исемнәре: *гакрәп, сөнбелә, сәвер, хут, җәүзә, кавәс* һ.б.; 5) кешене иҗтимагый зат буларак билгели торган сүзләр: *саилче* – хәерче, *көнлекче* – эшкә ялланган кеше, *хәрәмзә (әрәмзә)* – ялганчы, *дана* – белгеч, *ирән* – ил башлыгы, *коемчы* – алтын-көмештән йөзек-беләзек коючы, ювелир һ.б.; 6) нәсел-нәсәп атамалары: *нагачы* – ана ягыннан кардәш, *җиян* – хатын ягы туганнары, *арчи* – кызны кияү йортына озата баручы ирле-хатынлы кешеләр яки кызлар, *абысын* – апа-сеңел, *тума* – җитлекми туган, ташландык бала, *турун* – онык һ.б.; 7) зоонимнар: *кузы* – бәрән, сарык бәтие, *нар* – дөя, *тазы* – ау эте, *коралай* – кыр кәҗәсе, *колан* – кыргый эт, *утлак* – утлавык, көтүлек, *ат-тун* – мал-туар һ.б.; 8)көнкүрештә һәм авыл хуҗалыгында кулланыла торган предметларның атамалары: *кодык* – кое, *чарлак* – балкон, *күпчек* – мендәр, *мазар* – кабер, *сырга* – алка һ.б.; 9) үсемлек атамалары: *баг* – җимеш бакчасы, *каудан* – корыган үлән сабагы, *каудар* – коры үлән, *савыл* – каен, *бүтәгә* – үлән, *бурыя* – чыпта камышы, *тикән* – үсемлекләрдә була торган чәнечке, тигәнәк һ.б.; 10) кош атамалары: *аңгыт* – ябалак, *эшләки* – песнәк, *каргы* – карчыганың бер төре, *кыргавыл* – фазан һ.б.; 11) бөҗәк атамалары: *копшангы* – тирес коңгызы, *карышлавык* – яфрак ашаучы корт һ.б.; 12) ризык атамалары һәм ашау белән бәйле исемнәр: *эркет* – катык, *кәрчемә* – ачыган катык, *канд* – камыш шикәре, *катрә* – тамчы һ.б.; 13) металл атамалары: *тутыя* – цинк, *зир* – алтын, *булат* – нык корыч һ.б.; 14) сәламәтлеккә бәйле исемнәр: *зыяндаш* – нерв авыруы, *кыргын* – үләт, *карый* – бик карт кеше һ.б.; 15) балыкчылык атамалары: *шамбы* – налим һ.б. (Мөгътәсимова, 2005: 20–28).

Архаизмнар бүгенге көндә, нигездә, фольклор әсәрләрендә, язма истәлекләрдә һәм тарихи әсәрләрдә генә очрый, моннан тыш алар әдәби әсәрләрдә югары, китап теле стиле тудыру чарасы буларак та кулланыла.

Кайбер архаизмнар үзләре актив сүзлектән төшеп калсалар да, ясалма сүз компоненты, яки ялгызлык исем буларак актив кулланылалар. Мәсәлән, «исем» мәгънәсендәге *ат* сүзе *адаш, атама, атаклы, атау, атказанган, атсыз* (бармак), *яманат* сүзләрендә;

«савыт, касә» мәгънәле *аяк* сүзе *чынаяк* кушма сүзендә; «үлән» мәгънәсендәге *ут* сүзе *утау, утар, утлау, утлык, сарут* сүзләре составында; *буга* (үгез) сүзе *Алабуга* шәһәре атамасында; «бай, би хатыны» мәгънәсендәге *бикә* сүзе ялгызлык исемнәрендә (*Гөлбикә, Миңлебикә*); «дару, дәва» мәгънәсендәге *им* һәм «мәҗүси дога» мәгънәсендәге *том* сүзләре (ТТАС, 2005: 547) *им-том* парлы сүзендә; «терлек, мал» мәгънәсендәге *туар* сүзе (ТТАС, 2005: 558) *мал-туар* парлы сүзендә; «күн капчык, посуда» мәгънәле *саба* архаизмы (Әхмәтьянов, 2015, 2 т.: 124) *савыт-саба* парлы сүзендә; «фураж, ризык» мәгънәле *төлек* сүзе (Сафаров, 2012: 22) *азык-төлек* парлы сүзендә; «көбә күлмәк; амуниция» мәгънәле *ярак* сүзе (Сафаров, 2012: 22) *кирәк-ярак* парлы сүзләрендә кулланылуларын дәвам итәләр.

Кайчандыр күмәклек исем буларак та кулланышта йөргән кайбер архаизмнар хәзер антропоним буларак кына телдә саклана: *Әхсән* (иң күркәм), *Галләм* (зур укымышлы), *Өлфәт* **(**дуслык), *Шәүкәт* (көч, куәт), *Хәбип* (сөекле) һ.б. Аерым сүзләр апеллятив исем буларак кулланылыштан чыкса да, ялгызлык исем – топоним буларак яшәешен дәвам итә, мәсәлән, *болак* сүзе элек гомумән «елга, чишмә» (ТТАС, 2005: 90) сүзләре урынына кулланылса, хәзер Казандагы бер елга исеме буларак сакланган, *идел* сүзе элек «зур елга» мәгнәсенә ия булган (Әхмәтьянов, 1 т. , 2015: 124).

Фразеологизмнар составында барлык төр архаизмнарны да очратырга мәмкин:

а) лексик архаизмнар: *аз – азыклы, күп –* ***языклы*** (*язык* – гөнаһ), *ай йөр,* ***аман*** *йөр* (*аман* – исән-имин), *ай җык тигере* (*җык* – авыру);

ә) семантик архаизмнар: ***акшарлы*** *кыз* (*акшарлы* – сатлык, фәхишә), ***елдырым*** *камчысы* (*елдырым* – яшен);

б) морфологик архаизмнар: *Алланың* ***бирмеш*** *көне*, ***алмакка –*** *бар*, ***бирмәккә*** *– юк*;

в) фонетик архаизмнар: *аю юктан* ***чыраг*** (Татар лексикологиясе, 1 т., 2015: 211).

Татар халык мәкальләрендә архаизмнар аеруча күп сакланган:

а) фонетик архаизмнар: *Яхшының үзе* ***кечек***, *уе бөек* (*кечек* – кече); *Бер хатынның хәйләсе, кырык* ***төягә*** *йөк булыр* (*төя* – дөя); *Патшаны күргән күз* ***санатынна****н курыкмас* (*санат* – сенат) һ.б.;

ә) лексик архаизмнар: *Гүзәлдә **вафа** юк* (*вафа* – тугрылык); *Кызлар артыннан йөрүче **каемчыга** еш йөрер* (*каемчы* – ювелир); ***Җимәк** тоз белән, тоз чын белән* (*җимәк* – азык) һ.б.;

б) семантик архаизмнар: *Куйны – **курадан**, ашлыкны бурадан сат* (*кура* – йорт, ишек алды); *Ирнең **атын** хатын чыгарыр, хатынның **атын** ятим чыгарыр* (*ат* – исем); *Бер **аяк** кымызның ике аяк җиле бар* (*аяк* – савыт) һ.б.;

в) морфологик архаизмнар: *Ир **бирмәк** – җан **бирмәк***; *Яшең җитмеш, эшең **бетмеш***; *Юаш адәм **оялчак** булыр, ертлач адәм **соранчак** булыр* һ.б. (Мөгътәсимова, 2005: 17–44).

Элек әдәби телнең актив лексик фондында булган кайбер сүзләр аерым диалектларда гына сакланган. Мәсәлән, Э. Кадирова Мөхәмәдьяр поэмаларында еш кулланылган *алча* (якты чырайлы), *әл* (кул), *әмрак* (сөекле), *бичин* (маймыл), *йавукда* (тиздән), *күни* (хак, дөрес) сүзләренең хәзер татар теленең аерым сөйләшләрендә очравын билгели (Кадирова, 1999: 14–15).

Аңлатмалы сүзлекләрдә тарихи сүзләр гадәттә «борынгы сүз» һәм «тарихи сүз», архаизмнар «искергән сүз», «сирәк кулланылыштагы сүз» билгеләре белән тамгалана. Дөрес, еш кына архаизм белән тарихи сүз арасындагы чикне билгеләү авыр. Мәсәлән, *аякчы* сүзе татар теленең 2005 елда чыккан аңлатмалы сүзлегендә «сый мәҗлесендә кунакларга исерткеч эчемлек-шәраб таратып йөрүче, шул эшнең җаваплы кешесе» мәгънәсендә (ТТАС, 2005: 62) тарихи сүз буларак теркәлгән, әмма аны *көрәгәче, официант* сүзләренең элгәре буларак архаизмнар исәбенә дә кертергә була. *Катау* – «1) Балчык стена белән әйләндереп алынган ябулы кура, кутас; 2) Балчык стеналы ныгытма, кальга, крепость» сүзе исә «искергән сүз», ягъни архаизм билгесе белән бирелгән (ТТАС, 2005: 240). Хәзер инде мондый корылмалар төзелмәвен исәпкә алганда, аны тарихи сүз дип исәпләргә дә була. Кайбер сүзләр мәгънәләре ягыннан төрле төркемгә карый, мәсәлән: *төмән* сүзе «ун мең; ун меңлек берәмлек» мәгънәсендә архаизм, ә «ун мең кешелек гаскәри берәмлек; ун меңле гаскәр бирергә тиешле өлкә, губерна» мәгънәләрендә тарихи сүз буларак теркәлгән (ТТАС, 2005: 591).

Мисаллардан күренүенчә, тарихи сүзләр, экстралингвистик сәбәпләр аркасында, үзләре атаган предмет-күренешләр юкка чыгу нәтиҗәсендә, пассив лексик фондка күчәләр, ә архаизмнарның искерү сәбәпләрен бер төрле генә аңлату мөмкин түгел. Алар,

нигездә, сүзнең семантик структурасындагы үзгәрешләр (мәгънә киңәю яки тараю, синонимик бәйләнешләр), башка телләрдән сүзләр алу, яисә, киресенчә, телнең үз материалы нигезендә уңышлырак яңа сүзләр ясау, өлешчә телнең фонетик һәм морфологик системасындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, акрынлап, пассив сүзлеккә күчәләр һәм башка яңа сүзләр белән алыштырылалар.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ НЕОЛОГИЗМНАР

Неологизм (грекча *neos* – яңа, *logos* – сүз) дип телдә аерым бер чорда барлыкка килгән сүзләрне, сүзләрнең мәгънәләрен һәм сүзтезмәләрне атыйлар (Языкознание, 1998: 331).

Тормыштагы яңа күренеш, төшенчәләрне атау өчен тел яңа сүзләр исәбенә байый тора. Мондый сүзләр аеруча җәмгыять тормышындагы кискен үзгәрешләр чорында күпләп барлыкка килә. Әйтик, 1917 елгы инкыйлабтан соң татар телендә *совет, комсомол, совхоз, коммунизм, трактор, бишьеллык, колхозчы* кебек бик күп яңа сүзләр барлыкка килде. XX гасырның 80 нче елларында башланган иҗтимагый-икътисади үзгәрешләр дә лексикага зур йогынты ясады, телебездә яңа төр лексика актив кулланыла башлады, мәсәлән, *хәбәрдарлык, шартнамә, үзгәртеп кору, ТИҮ, акцияләр, кертем, телефакс* һ.б.

Яңа сүзләр, гадәттә, башта мәгълүмат чаралары телендә чагылыш таба, һәм, акрынлап, актив лексикага, гомумкулланышка кереп китә. Кайбер тел галимнәре мондый соңгы чорларда барлыкка килеп, актив кулланылучы сүзләрне *яңа сүз*ләр дип, әле актив сүзлеккә күчмәгән, ягъни мәгънәләре күпчелек халыкка аңлаешлы булмаган, сирәк кулланылучы яңа сүзләрне генә *неологизм* термины белән атыйлар. Ягъни теге яки бу сүз киң кулланылышка керсә, телдә яңарак барлыкка килүенә карамастан, ул неологизм булмый (Шанский, 1964: 77). Бу хезмәттә традиция буенча *яңа сүз* һәм *неологизм* атамалары, абсолют синонимнар буларак, телдә соңгы чорда барлыкка килгән сүзләрне атау өчен кулланыла.

Рус лексикологиясе буенча иң яңа хезмәтләрдә неологизмнарга үзгәртеп кору елларында һәм аннан соң барлыкка килгән сүзләрне кертәләр һәм аларны ике төркемгә бүлеп карыйлар: 1) актив запаска кергән сүзләр: *офис, менеджер, саммит, компакт-диск;* 2) бу чорда барлыкка килеп, инде кулланыштан чыккан һәм телнең

пассив запасына күчкән сүзләр: *гласность, кооперативщик, перестройка* һ.б. (Максимов, 2016: 187).

### § 46. Неологизмнарның төрләре

Хәзерге татар телендә кулланыла торган яңа сүзләрнең берничә төре бар:

1) телдә күптән кулланылып килгән сүзләргә яңа мәгънә өстәү юлы белән ясалган неологизмнар (семантик неологизмнар);

2) телнең үз чаралары ярдәмендә ясалган яңа сүзләр (лексик неологизмнар);

3) башка телләрдән алынган яңа сүзләр (алынма неологизмнар).

Соңгы төр неологизмнар, башка телләрдәге кебек үк, татар телендәге неологизмнарның зур күпчелеген тәшкил итә. Чөнки тормышта барлыкка килгән яңа төшенчәне атау өчен, яңа сүз уйлап-ясап торганчы, әзер атама куллану уңайлырак. Шулай да беренче ике төргә караган неологизмнар да хәзерге татар телендә шактый. Түбәндә татар әдәби телендә XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында барлыкка килгән яңа сүзләрнең төрләрен карап үтәрбез.

Семантик неологизмнар дип актив лексикадагы сүзнең яңа барлыкка килгән мәгънәсен атыйлар. Тел белемендә бу төр яңа сүзләрне атау өчен *лексик-семантик неологизм, мәгънә-неологизм* атамалары да кулланыла.

Соңгы чорда татар сүзләренең мәгънәләре киңәю, нигездә, ике төрле юл белән бара:

1) җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән яңа күренешләрне атау өчен, телдә инде яшәп килгән сүзләрне яңа мәгънәдә куллану;

2) алынма сүзләрне алыштыру өчен, телнең үз сүзләрен яңа мәгънәдә куллану.

XX гасыр ахырында җәмгыятьтәге иң зур үзгәрешләр – финанс системасының үзгәрүе, икътисадның базар мөнәсәбәтләренә күчүе, шәхси эшмәкәрлекнең үсүе. Болар лексикада да үз чагылышын тапмый калмады, яңа мәгънә төсмере алган сүзләрнең дә шактые шушы өлкәләргә карый, мәсәлән: *эшкуар, эшмәкәр, малтабар, йөкләмә, ташлама, юллама* һ.б.

*Эшкуар* – «эшләрне (бигрәк тә коммерция эшләрен) бернинди ысулдан да чирканмыйча, оста итеп алып баручы» (ТТАС, 3 т.,

1981: 549). 1981 елгы бу билгеләмәдән тискәре эмоциональ-экспрессив төсмер аңкып торса, хәзер ул стилистик яктан нейтраль һәм күпкә киңрәк «шәхси эшмәкәрлек, табышлы эш (бизнес) белән шөгыльләнүче» мәгънәсендә кулланыла: *Чаллы **эшкуарлары** ярдәме белән изге Болгар җиренә сәяхәт оештырылды* («Шәһри Чаллы»).

*Эшмәкәр* – «*диал*. Эшчән, уңган, эшлекле» (ТТАС, 3 т., 1981: 536). Бу сүз дә хәзер, нигездә, «предприниматель» мәгънәсендә *эшкуар* сүзенең синонимы буларак кулланыла: *Дөрес, шуннан соң ике елга «Бөрсет»тән китеп, үзен **эшмәкәр** буларак сынап караган* («Мәйдан»).

*Ташлама* – «1. Кемгә дә булса гомуми таләпләрне йомшарту, аның хаталарын һ.б. өлешчә гафу итү. 2. Хак-бәя мәсьәләсендә үзара тизрәк килешүгә юнәлтелгән тәкъдим» (ТТАС, 3 т., 1981: 58). Бу сүз «льгота, гомум кагыйдәләрдән чыгарма буларак, ниндидер өстенлек бирү» мәгънәсендә кулланыла башлады: *«Хезмәт ветераны» таныклыгы алдым, әмма миңа **ташламалар** бирүдән баш тарттылар* («Ватаным Татарстан»).

Элек, нигездә, китап теле стилендә һәм сирәк кулланылган *юллама* – «*и*. 1. Берәр кешене кая да булса билгеләүне яки юнәлтүне белдергән рәсми документ, путевка. 2. Дөрес юлга юнәлтү, фатиха бирү» (ТТАС, 3 т., 1981: 609) – сүзе, үзенең сүзлектә теркәлгән мәгънәләреннән тыш, яңа «рәсми мөрәҗәгать, послание, ягъни дәүләт җитәкчесенең иҗтимагый закон чыгару органнарына әһәмиятле мәсьәләләр буенча язма мөрәҗәгате» мәгънәләре белән баеды: *Президент Дәүләт Советына еллык **Юлламасында** тормыш сыйфатын яхшырту максаты куйды», – дип кабатлавын истә тотканда, министрлыкның кыйбласы ачык сыман тоела* («Ватаным Татарстан»).

Телне алынма сүзләрдән арындыру тенденциясе тәэсирендә дә узган гасырның 80 нче елларыннан күп кенә сүзләр бөтенләй яңа мәгънәдә кулланыла башладылар. Мәсәлән, *берлек, бәяләмә, ия, узаман, узыш, төзекләндерү* сүзләре күрсәтелгән яңа мәгънәләрендә активлаштылар.

*Берлек* – «1. Бер сум акча. 2. *лингв*. Сүз бер генә кеше яки предмет турында барганда кулланыла торган төрләнү формасы. 3. Бердәмлек, оешканлык. // Ныклы, тыгыз бәйләнеш. // Уртаклык, тулы охшашлык» (ТТАС, 1 т., 1977: 153). Бу сүз хәзер «Дәүләтләр

берләшмәсе» һәм «Җәмәгать оешмасы» (Толковый словарь русского языка, 1998: 753) мәгънәләрендә *союз* һәм «бер юнәлештәге эшчәнлек белән шөгыльләнүче кешеләр яки оешмалар берләшмәсе» мәгънәсендә *ассоциация* сүзләре урынына актив кулланыла. Хәзер *Татарстан журналистлар берлеге, кинематографистлар берлеге, профессиональ берлекләр, рәссамнар берлеге, Татарстан хатын-кызлары берлеге, Татар яшьләре берлеге, Язучылар берлеге* кебек сүзтезмәләрне һәрбер газета-журналда күпләп табарга була: *Санкт-Петербург* ***Рәссамнар берлеге*** *бинасында Габдулла Тукайның 120 һәм Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды* («Казан утлары»).

*Бәяләмә* – «*кит*. Берәр эшнең, хезмәтнең гомуми сыйфатын, әһәмиятен, кыйммәтен күрсәтеп, гадәттә язма рәвештә бирелә торган рәсми бәя, фикер» (ТТАС, 1 т., 1977: 212) – сүзе соңгы елларга кадәр телебездә үз атамасы булмаган *характеристика* һәм *заключение* сүзләрен алыштырып, берьюлы ике яңа мәгънә алды: а) «кемгә яки нәрсәгә дә булса хас сыйфатлар, үзенчәлекле яклар турында бәя» (характеристика): *Сез аңа, бик яхшы офицер, профессионал, дигән* ***бәяләмә*** *бирдегез* («Ватаным Татарстан»); ә) «нәрсәне дә булса тикшереп өйрәнгәннән соң ясалган нәтиҗә, йомгак, раслау» (заключение): *Владимир төрмәсенә алып килгәндә, Пауэрс, врачлар* ***бәяләмәсе*** *буенча, психик өзлегү алдында була* («Ватаным Татарстан»).

Элек, нигездә, русча вариантта кулланылган атамаларны алыштыручы *бистә* – «1. *тар*. XI–XVIII гасырларда феодаль Русьтагы бәйсез дәүләт кулында яки шәхси милектә булган җирләргә үзләре теләп килеп утырган крестьяннар, һөнәрчеләр һ.б. яши торган пункт, гадәттә кечерәк шәһәрчек. 2. Шәһәрнең аерымрак урнашкан өлеше, районы» (ТТАС, 1 т., 1977: 169). Бу сүзнең дә мәгънәләре киңәйде. Беренчедән, ул аңлатмалы сүзлектә тарихи сүз буларак теркәлгән 1 нче мәгънәсендә түгел, ә гомумән «шәһәр тибындагы зур авыл, торак пункт» мәгънәсендә поселок сүзен тулысынча диярлек алыштыра, икенчедән, хәзерге зур шәһәрләрдәге төзелгән яңа берәмлекләрне атау өчен префектура, микрорайон, комплекс сүзләре урынына кулланыла, ягъни сүзлектә теркәлгән икенче мәгънә конкретлаша: *Саба районының Шәмәрдән* ***бистәсендә*** *бөтен уңайлыклары булган ясле-бакча ачылды* («Ватаным Татарстан»). *Казандагы 50 нче* ***бистәне*** *газлаштырып бе-*

*терәсе бар ...* («Татарстан яшьләре»). *Ирландия Уфаның Сипайлова **бистәсендә** сәүдә үзәге ... төзергә ниятли* («Өмет»).

Күпмәгънәле *җирлек* – «1. Җирнең мул уңыш бирә алу сәләте. 2. Төп төс, фон. 3. Берәр нәрсәнең арткы планы яки күренеше. <...> 5. Эшнең уңышын тәэмин итә торган шартлар» (ТТАС, 2005: 780) – сүзе, беренчедән, төп фон нигезендә грунт, грунтовка, ягъни «буяр алдыннан өслекне тигезләү өчен кулланылучы махсус составлы буяу, арадаш катлам» мәгънәсе белән баеды. Бу мәгънә инде русча-татарча сүзлекләрдә дә чагылыш таба (Русско-татарский словарь, 1985: 119). *Эшкәртелгән түшәмне **җирлек** (грунтовка) белән каплыйлар* («Ватаным Татарстан»). Икенчедән, хәзер *җирлек* сүзен элеккеге авыл советы, торак пункт урынына русча поселение атамасының тәрҗемәсе буларак кулланалар: *Участок милиционерлары район **җирлегендә** патрульлек иткән вакытта Боголюбово һәм Ает авыллары арасында шик уяткан бер төркемне туктата* («Өмет»).

*Ия* – «*ис*. 1. Берәр нәрсәнең, милекнең хуҗасы. 2. Нинди дә булса сыйфатка, сәләткә, дәрәҗәгә һ.б.га ирешкән кеше // Нәрсәгә дә булса ... лаек. 3. Берәр эш белән шөгыльләнүче, көн күрүче кеше. 4. Уйлап чыгарган, язган яки әйткән кеше, автор. 5. ... мифик зат. 6. *иск. дини*. Тәңре, Алла. 7. *лингв*. Җөмләдә ... баш кисәк» (ТТАС, 1 т., 1977: 443). Бу сүз *лауреат* алынмасын алыштырып, бүләк компоненты белән берлектә, «фән, әдәбият, сәнгать, халык хуҗалыгы өлкәсендә күрсәткән зур хезмәтләре өчен махсус бүләк, премия алган кеше» мәгънәсенә «ия булды»: *Габдулла Тукай исемендәге премия **ияләре** исемлеге апрель аенда ук билгеле булса да, аларны рәсми рәвештә ел саен Республика көнендә генә бүләклиләр* («Ватаным Татарстан»).

*Кайнатма* – «берәр дару үләне яки җиләк-җимеш һ.б. салып махсус кайнатылган су (дәвалау өчен)» (ТТАС, 2 т., 1979: 25) – соңгы елларда, күбрәк *варенье* сүзен алыштырып, «җиләк-җимешне шикәр комында кайнатып, пешереп яисә изеп ясалган татлы чәй ризыгы» мәгънәсендә кулланыла: *Мондый **кайнатманы** чәй эчәргә генә түгел, ә мич ашлары пешергәндә дә файдаланып була* («Шәһри Казан»).

*Колакча* – «1. *к*. Колакчын. 2. *диал*. Колак алкасы. 3. *сөйл*. Күзлек сабы» (ТТАС, 2 т., 1979: 192) – сүзен *наушник,* ягъни «колакка киелә торган тыңлау приборы» мәгънәсендә куллануны да

сүзнең мәгънәсе киңәю дип карарга кирәк, чөнки бу мәгънәләр, төрле предметларны атасалар да, бер үк тамырга карыйлар: *Әллә аңа үз телендә чыгыш ясарга рөхсәт бирмәделәрме, яки синхрон тәрҗемәне тыңлау өчен кулына **колакча** (наушник) тоттырмадылармы?* («Татарстан яшьләре»).

*Култамга* – «*бор*. Имза мәгънәсендә йөри торган тамга» (ТТАС, 2 т., 1979: 188) – сүзе, бердән, төп мәгънәсен киңәйтеп, ягъни *имза* дигән гарәп алынмасын алыштырып активлашса, икенчедән, «танылган шәхеснең үз кулъязмасы яки имзасы» мәгънәсендә *автограф* сүзе урынына да кулланыла башлады: *Виленнан «улы белән беркайчан да очрашу-күрешүне таләп итмәскә», дигән **култамга** алганнар* («Мәдәни җомга»). *...атаклы шәхесләребезнең истәлекле **култамгаларына** да ия булачаксыз* («Мәдәни җомга»). Бу сүзне шулай ук «бармак эзләре» мәгънәсендә рус телендәге *отпечатки* сүзе урынына файдалану да очрый: *Әмма кәгазьдәге **култамгалар** тәрәзәдә калган сызыкларга тәңгәл килмәгән* («Ватаным Татарстан»).

*Төзекләндерү* – «яшәү яки файдалану өчен уңайлы, яраклы хәлгә китерү, рәтләү // *с. мәгъ*. Яшәү яки файдалану өчен уңайлы, яраклы хәлгә китерү белән шөгыльләнә торган» (ТТАС, 3 т., 1981: 244). Бу сүз *реконструкция* алынмасы урынына «яхшырту, камилләштерү максаты белән, нәрсәне дә булса тамырыннан үзгәртү, яңадан кору, төзү эше» мәгънәсендә кулланышка керә бара: *Татарстандагы шикәр заводларында **төзекләндерү** уздырганнан соң, оештыру куәтләре ике мәртәбә диярлек артты* («Ватаным Татарстан»). *Төзекләндерү* сүзе кайбер очракларда «реставрация» мәгънәсендә дә кулланыла: *Экспонатлар акрынлап искерәләр, тузалар – алар **төзекләндерүгә**, тузаннан, температура үзгәрешләреннән, дымнан, музей бөҗәкләреннән саклауга мохтаҗлар* («Шәһри Казан»).

*Тугра* – «*бор*. Урта гасыр төрки дәүләтләрдә (мәсәлән, Казан ханлыгында) хан мөһере; хан исеме матур итеп боргалап-сыргалап язылган мөһер» (ТТАС, 3 т., 1981: 148) – *герб* сүзе урынына, ягъни яңа «дәүләт, өлкә, шәһәр һ.б. ның махсус тамгасы, дәүләт билгесе» мәгънәсендә актив лексикага кайтып бара, үзенең беренчел мәгънәсендә ул тарихи әсәрләрдә генә очрый: *Үзебезнең **туграбыз** була торып, күрше Рәсәй дәүләтенең туграсы төшерелгән документ бирү – минемчә, Татарстан гражданнарын кимсетү ул* («Шәһри Чаллы»).

*Узаман* – «*иск. кит*. Уенда башлап йөрүче, оештыручы. Нинди дә булса төркемнең башлыгы, нинди дә булса (гадәттә яман) эшнең башында йөрүче» (ТТАС, 3 т., 1981: 297). Бу сүз, «нинди дә булса хәрәкәтнең, оешманың һ.б.ның җитәкчесе, башлыгы» мәгънәсендә, актив лексикагадагы *лидер* сүзен әдәби телдән кысрыклый башлады: *Азау теше чыккан, буар елан булып чыкты элекке комсомол* ***узаманы*** («Казан утлары»).

*Узыш* – «1. Йөгерү, ат узыштыру спортында алга чыгу өчен оештырылган ярыш. 2. Өстен, алдан чыгу өчен ярыш, көрәш» (ТТАС, 3 т., 1981: 298) – *ралли* сүзен алыштыру өчен «автомобильләрдә һәм мотоциклларда ерак араларга оештырылган ярыш» мәгънәсендә конкретлашты, моңа КамАЗ автомобильләренең бу узышларда актив катнаша башлавы да этәргеч бирде: *Татарстанның профессиональ командасы ике елда әлеге* ***узышта*** *«КамАЗ-Мастер» исеме белән катнашты* («Ялкын»).

Югарыда китерелгән мисаллар соңгы 20–30 елда татар телендә шактый сүзләрнең яңа мәгънәләре барлыкка килүен раслый. Алар, кайбер яңа төшенчәләрне атау белән бергә (җирлек, юллама һ.б.), әдәби телдә рус-европа алынмаларын төрки-татар чыгышлы сүзләр белән алыштыруга да хезмәт итә (*ташлама, берлек* һ.б.).

Лексик неологизмнар дип телнең үз чаралары ярдәмендә ясалган яңа сүзләрне атыйлар (Шанский, 1964: 77). Мәсәлән, *әйдәман, глобаль челтәр, чакырунамә*, *куларкадаш* һ.б.

Алынма неологизмнар дип яңа төшенчәләрне атау өчен башка телләрдән алынган яңа сүзләрне атыйлар. Соңгы чорда татар әдәби телендә урын алган неологизмнарның зур күпчелеген алынма, беренче чиратта Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр тәшкил итә. Чөнки XX йөз ахырыннан илнең иҗтимагый-сәяси һәм икътисади нигезләрен Көнбатыш үрнәгендә үзгәртеп кора башлау яшәешнең төрле өлкәләренә караган күп чит ил сүзләренең рус теленә һәм аның аша татар теленә үтеп керүенә юл ачты. Җәмгыять тормышындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән яңа күренеш, төшенчә, оешма һ.б.га исем биргәндә дә, гадәттә, чит сүзләр өстенлек ала. XX йөзнең ахырында Европа телләренә хас булган лексиканың интернациональләшү тенденциясе көчәюе дә хәзерге татар теле лексикасында чит тел сүзләренең күбәюенә китерде.

Бу төр алынмалар татар теленә, барысы да диярлек, рус теле аша кергән. Дөрес, арада соңгы елларда еш күрсәтелгән чит ил

телесериаллары аша турыдан-туры татар сөйләм теленә кергән *фазенда* кебек алынмалар да бар. Рус теленә исә яңа алынмалар, нигездә инглиз теленнән, аеруча аның америкалы вариантыннан кергән (Крысин, 1997: 85). Татар теленә соңгы елларда кергән яңа алынмаларының да 70 проценты инглиз сүзләре: *аудит, бартер, дилер, дистрибьютор, инвестор, инфраструктура, лизинг, менеджер, менеджмент, офф-шор, риэлтор, спонсор, тендер, трансфер, холдинг, чартер; диссидент, импичмент, инаугурация, кластер, лобби, пиар, рейтинг, саммит, спикер; брифинг, пресс-релиз, респондент; киллер, рэкет, рэкетир; клип, дискотека, продюсер, хит-парад, шоу; дисплей, компьютер, интернет, интерфакс, листинг, монитор, принтер, картридж, ксерокс; ралли, бодиболдинг, аэробика; гамбургер, сандвич, киви; зомби, уфология, хилер; дизайн, гламур, имидж, имиджмейкер, кемпинг, шоп, нонсенс, супермаркет; армрестлинг, кикбоксинг; скаут, тинейджер, панк, хиппи* һ.б.

Башка телләрдән кергән алынмалар күп түгел: француз теленнән – *анклав, визажист, дискета, интерпол, кадастр, коллаж, сертификат, сутенер, токсикомания*; немец теленнән – *менталитет, паритет, путч;* итальян теленнән – *мафия, мафиози, пицца;* испанчадан – *хунта, фейхоа* һ.б. Мондый алынма неологизмнар бик күп телләрдә кулланыла һәм халыкара, ягъни интернациональ сүзләр булып санала.

Яңа неологизмнар арасында рус теленең үз сүзләре бик аз. Соңгы чорда матбугатта урын алган рус сүзләренә мисал итеп аббревиатуралар (*АО, бомж, ГИБДД, ГКЧП, НЛО, омон* һ.б.) һәм кайбер сүзләрнең гади сөйләм, жаргонга хас булган яңа күчерелмә мәгънәләрен генә (*братва, крутой, крыша, ломка, частник, челнок*) китерергә мөмкин. Яңа төшенчәләрне белдергән рус неологизмнары, әйтеп үтелгәнчә, татар әдәби теленә, гадәттә, калькалаштырып алына.

Неологизмнар пассив сүзлектә озак тоткарланмый, төрле стильләрдә һәм күпчелек халык тарафыннан кулланыла башлаган яңа сүзләр актив лексикага күчә. Алда саналган сүзләр, нигездә, шундыйлар исәбенә керә. Кайбер неологизмнар исә, пассив лексиканың икенче төркеменә күчеп, архаизм яисә тарихи сүзгә әйләнә. Мәсәлән, *видеосалон* (видеомагнитофон тасмасына язылган фильмнарны күмәкләп карау урыны, кечкенә кинотеатр) сүзе XX гасырның 80–90 нчы елларында актив кулланышта булды, күп-

челек гаиләләр шәхси видеомагнитофонга ия булганнан соң, гасыр ахырында тарихи сүзгә әйләнде, *пейджер* (абонент белән компьютер системасы аша берьяклы элемтә урнаштыру өчен дисплейлы шәхси кабул иткеч җайланма) неологизмы кыска вакыт эчендә кесә телефоны тарафыннан кысрыклап чыгарылды, *экю* (Евросоюз илләренең бердәм валюта берәмлеге) сүзе 1979 елда кулланышка кереп, 1999 елда инде *евро* сүзе белән алыштырылды.

### § 47. Татар телендә неологизмнарның ясалыш юллары

Яңа төшенчәләрне атау өчен XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар телендә төрле ысуллар белән яңа сүзләр ясалды. Бу неологизмнарның зур өлеше – морфологик юл белән төрле кушымчалар ялгап ясалган исемнәр. Синтаксик ысуллар белән ясалган неологизмнар да күп, шулай да яңа сүзләрнең күпчелеген калькалар тәшкил итә.

Кушымчалау ысулы «кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясаудан гыйбарәт (Татар грамматикасы, 1998, 1 т.: 208). Неологизмнар телдә продуктив булган кушымчалар ялгау юлы белән, нигездә, исемнәр һәм фигыльләрдән ясала. Бу ысул белән ясалган неологизмнар үзләре дә күпчелек шушы сүз төркеменә карый.

Исем сүз төркеменә караган яңа төр лексика ясауда актив кушымчаларга тукталып үтәбез:

*-чы/-че* кушымчасы ярдәмендә XX гасыр азагы – XXI гасыр башында алтмышлап яңа сүз ясалган. Әмма аларның зур күпчелеге әлегә окказиональ кулланышта (*көйче, мөлкәтче, оранчы*), рус һәм интернациональ алынмалардан ясалганнары ярымкалькалар булып торалар (*арендачы, дизайнчы, компьютерчы, омончы, рэкетчы* һ.б.), зур күпчелек тәшкил иткән гарәп-фарсы компонентлыларының (*гамәлче, зәрканчы, иминиятче, инсаниятче, иттифакчы, кәсәбәче, хакимиятче, нәзариятче, сәнәгатьче, тәфтишче, фиркачы* һ.б) ясагыч нигезләре үк актив кулланышта түгел. Актив кулланылышка кереп бара торган берничә яңа сүзгә тукталып узу урынлы булыр.

*Икътисадчы* – гарәп алынмасы булган *икътисад* сүзеннән ясалган һәм «икътисад белгече, җәмгыятьнең хуҗалык тормышын өйрәнүче галим» мәгънәсендә *экономист* сүзенең «татарчалаштырылган» синонимы буларак кулланыла: *Фәһим Ибәтуллин – белеме буенча* ***икътисадчы*** («Мәдәни җомга»).

*Нәкышче* сүзе «агач, сөяк кебек нәрсәләргә кисеп, уеп, сырлап яки чокып ясалган бизәк, орнамент, яисә чигү, чигеш» дигән мәгънәне аңлаткан алынма тамырдан (*нәкыш*) ясалган һәм «төрле материалга чокып, сырлап яисә чигеп бизәк, рәсем төшерүче», ягъни *гравер* мәгънәсенә ия: *Бу күргәзмәдә без Алсу Тимергалинаны* ***нәкышче*** *рәссам буларак таныдык* («Сөембикә»).

Соңгы елларда бик активлашкан *хәйрия* – «Мохтаҗларга күрсәтелә торган изгелек, яхшылык» (ТТАС, 2005: 638) алынмасыннан ясалган *хәйрияче* сүзе «мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтүче, изгелек эшләүчене аңлата: *...гомеренә бер мәртәбә мохтаҗларга ярдәм кулы сузган кеше дә үзен* ***хәйрияче*** *яки волонтер итеп тоя башлый бездә* («Ватаным Татарстан»).

*Химаяче* сүзе «кемгә дә яисә нинди дә булса эшкә матди ярдәм күрсәтүче» мәгънәсендә *спонсор* сүзе урынына кулланыла: *Китапның ел ахырында дөньяга чыгасына ышанам. Бары тик* ***химаячеләр*** *генә табасы калды* («Ватаным Татарстан»).

*Кертемче* – «саклык банкында акчасы булган кеше», *вкладчы* сүзенең ясагыч нигезе дә әле яңа: *Банк яки компания банкротлыкка чыкса, алар* ***кертемчеләргә*** *түләүләрне башкарырлар* («Ватаным Татарстан»).

*-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә соңгы елларда, беренчедән, яңа төшенчәләрне атау өчен, рус телендәге *-н-, -ость, -ств* һәм латин чыгышлы суффиксларны алыштырып, халыкара һәм рус сүзләреннән ярымкалькалар (*акционерлык, аудиторлык, спонсорлык, суперменлык, фермерлык* һ.б.); икенчедән, гарәп-фарсы алынмаларыннан әдәби телебездә элекке елларда кулланылмаган бик күп яңа сүзләр (*вәкарьлек, дәһрилек, мөһәндислек, мигъмарлык, мөкәмәллек, һөнәрмәнлек* һ.б.) ясалды. Соңгылары, нигездә, халыкара алынмаларга алмаш буларак төзелгәннәр һәм күбесенчә окказиональ кулланышта йөриләр. Шул ук вакытта *-лык/-лек* ярдәмендә телнең үз сүзләре базасында да шактый гына уңышлы неологизмнар ясала, аларның күпчелеге һөнәр, эшчәнлек төренең җыелма атамасын белдерәләр: *алыпсатарлык, малкуарлык, эшкуарлык, эшмәкәрлек:* ***Алыпсатарлыкның*** *төшемлелегенә хәзер күпләр төшенде, базар урамы көннән-көн озыная* («Ватаным Татарстан»). *Безнең халыкка борынгыдан ук* ***эшкуарлык, малтабарлык*** *хас* («Татарстан»). ***Эшмәкәрлек*** *белән шөгыльләнергә теләүчеләр саны кими бара* («Казан»).

*Иганәчелек, хәйриячелек, химаячелек,* ягъни «нинди дә булса эшне башкаруда шәхсән яисә оешма исәбеннән акчалата ярдәм күрсәтү», *кәсәбәчелек* (предпринимательство) сүзләре дә мәгънәләре буенча югарыда саналганнарга аваздаш: ***Химаячелек*** *турында сүз чыккач, әйтеп үтсәгез иде: хезмәтегезне бастыруда кем ярдәм итте?* («Ватаным Татарстан»). ***Иганәчелек*** *– җәмәгать оешмалары, дәүләт учреждениеләре һәм аерым затларның мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр ачу һәм тотуга, ятим-мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтүе* («Мәдәни җомга»). *«Алайл» ябык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Риф Вәкил улы Вафин инде күп еллар Аллаһы Тәгалә кушкан игелекле эш –* ***хәйриячелек*** *белән шөгыльләнә икән* («Мәдәни җомга»). *Без алга таба да кече һәм урта* ***кәсәбәчелекне*** *үстерүгә җитди әһәмият бирергә тиешбез* («Мәдәни җомга»).

*Тыю* – «1. Кемгә дә булса берәр нәрсә эшләргә рөхсәт итмәү // Берәр нәрсәне куллануга, чыгаруга юл куймау, рөхсәт итмәү» (ТТАС, 3 т., 1981: 204) – фигыленнән ясалган *тыюлык* сүзе «сирәк очрый торган кыргый үсемлек яки җәнлекләрне саклау һәм үрчетү урыны» мәгънәсендә *заповедник* алынмасын әдәби телдән кысрыклый: *Җиңүчегә Татарстан Әйләнә-тирә мохитне саклау министрлыгы ...Түбән Кама – Раифа* ***тыюлыгы*** *маршруты буенча автобуста сәяхәт әзерли* («Татарстан яшьләре»).

*-даш/-дәш, -таш/-тәш* кушымчасы белән ясалган яңа исемнәр арасында иң активы – *рәистәш* сүзе. Ул «ниндидер оешмага башка кем беләндер бергәләп җитәкчелек (рәислек) итүче кеше» мәгънәсенә ия һәм рус телендәге *сопредседатель* сүзен алыштыра: *«Төрле телләрдә сөйләшүче күпмилләтле илләрдә билингвизм проблемасы яши»,– ди Россия Хөкүмәте каршындагы урыс теле буенча комиссия* ***рәистәше*** *академик Е. Челышев* («Ватаным Татарстан»).

Ясаучы нигез белдергән предмет белән уртаклыгы буенча зат атамаларын белдерүче аерым сүзләр күбрәк окказиональ кулланышта йөри: *кавемдәш, телдәш, мәсләктәш, төстәш (двойник)* .

*-ма/-мә* кушымчасы белән фигыльләрдән процесс нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән предмет, төшенчәне белдерүче дистәгә якын яңа исем ясалды. Шулардан иң активы – *нигезләмә* «нәрсәнең дә булса тормышка ашырылырга лаеклы булуын исбатлаучы дәлил» мәгънәсендә рус телендәге *обоснование, положение* сүзләре

урынына кулланыла: *Бу программаның асылын түбәндәге концептуаль* ***нигезләмәләр*** *тәшкил итәргә тиешләр* («Казан утлары»).

*Тәгаенләмә* (эшкә билгеләү кәгазе, направление), *бәһаләмә, сыйфатлама* (характеристика), *раслама* (утверждение) неологизмнары әлегә сирәгрәк кулланыла.

*-ыр / -р* кушымчалары белән узган гасырның 90 нчы елларында *әйдәр* һәм *буйсыныр* сүзләре ясалды.

*Буйсыныр* исеме «кемгә дә булса буйсынган, ягъни аның хакимлеге, җитәкчелеге астында булган кеше» мәгънәсенә ия: *Ул һәм аның* ***буйсынырлары*** *тәтәйләр йортында тотылганнар* («Шәһри Казан»).

*Әйдәр* неологизмы *лидер* сүзе урынына *узаман* сүзенең синонимы буларак очрый, шулай ук, әйдәүче варианты белән бергә, рус телендәге *ведущий* сүзен дә алыштыра: *Аны (сугышны) кузгатучылар ... Ауропаның* ***әйдәр*** *иленә әйләнүне максат итәләр* («Идел»).

*-ем/-әм* кушымчасы белән *кертем* һәм *өчләм* сүзләре ясалды. Аларның беренчесе *вклад* сүзе урынына «гражданнар яисә оешмаларның банкка салган (керткән) акчасы» төшенчәсен бирү өчен кулланыла: *Гражданнарның* ***кертемнәре*** *2,2 триллион сум тәшкил итте* («Ватаным Татарстан»).

*Өчләм* – триптих – «бер төп идея белән бәйләнгән өч сәнгать әсәре»: *Нәкъ менә шул күзгә күренмәүче җеп Габдулла Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим ителүче әсәрләр – Тукай, Дәрдемәнд портретларын, Бакый Урманчега багышланган «Язмыш»* ***өчләмен*** *(триптих) үзара бәйләп тора* («Мәдәни җомга»).

*-к* кушымчасы ярдәмендә XX йөзнең 90 нчы еллары уртасында *санау* фигыленнән *санак* исеме ясалды. Ул «электрон-хисаплау машинасы» мәгънәсендә китап теле стилендә *компьютер* алынмасы белән параллель кулланыла.

*-ман/-мән* кушымчасы белән кешене характерлы билгесе, һәвәслеге, шөгыле буенча атаучы берничә сүз ясалды. Аларның икесенең ясагыч нигезе киләчәк заман сыйфат фигыль формасы: *көярмән* (болельщик), *сөйләрмән* (оратор).

Татар телендә лексик неологизмнар фигыль сүз төркемендә дә шактый күзәтелә. Исемнәрдән аермалы буларак, соңгы елларда рус теле аша кергән сүзләрдән алардагы *-аци-, -ализаци-, -изаци-,-изирова-, -ирова-* формантларын *-ла/-лә, -лан/-лән, -лаш/-ләш, -лаштыр/-ләштер* кушымчалары белән алыштырып, бик күп

яңа ярымкалька ясала. Алар арасында чыганак (арадаш) телдәге исемнәрдән алда күрсәтелгән формантларны кыскартмый гына, кушымча өстәп, фигыль ясау очраклары да бар: *Шау-гөр килеп Президентыбызны **инаугурацияләгән** генә идек, азык-төлеккә һәм аракыга бәяләр сикереп куйды* («Мәгърифәт»).

Җәмгыять тормышындагы яңа күренешләрнең атамалары буларак гарәп-фарсы алынмаларыннан *-лаштыр/-ләштер* кушымчасы ярдәмендә берничә яңа фигыль ясалды. *Хосусый* сыйфатыннан ясалган *хосусыйлаштыру* сүзе «дәүләт милкен хосусый, шәхси милеккә күчерү»не аңлата, ул узган гасырның 90 нчы еллары башында илдә киң җәелгән процессларга бәйле рәвештә туды: *«Яр буе паркында 1995 елда ук төзелә башлаган спорт-сәламәтләндерү бинасын... **хосусыйлаштырып**, аукционга кую мәсьәләсен депутатлар бертавыштан кабул иттеләр* («Шәһри Чаллы»). Бу сүз шулай ук исем фигыль буларак *приватизация* алынмасы урынына да кулланыла: *Татарстан **хосусыйлаштыруның** үз программасын кабул итте* («Татарстан яшьләре»). *Сәяси* сыйфатыннан ясалган *сәясиләштерү* – «сәяси төсмер бирү» фигыле дә актив кулланылылышка керде: *... һәр елны бюджетны **сәясиләштереп**, аңа артык йөк салып, без беркайчан да савыктыруга ирешә алмаячакбыз* («Ватаным Татарстан»). *Иминият* – 1. ... Куркынычсызлык, хәвеф-хәтәрсезлек. 2. Ышаныч – (Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, 1993: 738) – алынмасыннан ясалган *иминиятләштерү* неологизмы татарчага авыр тәрҗемәләнүче *страховать* фигылен алыштырды: *Йортыбыз мәҗбүри һәм ирекле рәвештә **иминиятләштерелгән** булганлыктан, «Тасфир» страховкалау акционерлык җәмгыятенең Минзәлә бүлегенә мөрәҗәгать иттек* («Ватаным Татарстан»).

Хәзерге татар теле өчен продуктив булмаган *-дер* кушымчасы ярдәмендә ясалган *тернәкләндерү* «сәламәтләндерү, аякка бастыру» (ТТАС, 2005: 533) фигыле *реабилитация* төшенчәсен бирү өчен кулланыла: *«Изгелек» инвалидларны **тернәкләндерү** үзәгенә, Боз сараена, «Бердәм Россия» физкультура-сәламәтләндерү комплексына Россиядә тиңнәр юк* («Шәһри Чаллы»).

Синтаксик юл белән ясалган неологизмнар сан ягыннан кушымчалау ысулы белән ясалган яңа сүзләрдән дә күбрәк. Соңгы елларда барлыкка килгән аналитик сүзләрне, язылышларыннан чыгып, өч традицион төркемгә – кушма, парлы, тезмә

сүзләргә бүлеп карарга була. Кушма сүзләргә компонентлары үзара ияртүле бәйләнеш нигезендә кушылып ясалган һәм сүзтезмәләрнең лексикалашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүзләр, тезмә сүзләргә – ияртүле бәйләнешкә кереп лексикалашкан бер төшенчә белдерүче сүзтезмәләр, парлы сүзләргә компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып, сызыкча аша языла торган сүзләр кертелә .

Парлы сүзләр «ике яки сирәк кенә берничә гади нигезнең бер сүз булып кушылуыннан гыйбарәт» (Татар грамматикасы, 1998, 1 т.: 210).

Соңгы еллар татар язма әдәби теленең төп үзенчәлекләреннән берсе – сызыкча аша язылган сүзләрне күп куллану. Бу, барыннан да элек, телебезгә яңа төшенчәләр белән бергә башка телләрдән һәм, өлешчә, диалектлардан яңа сүзләр керү белән бәйле. Чөнки, галимнәр әйтүенчә, парлы сүзләр беренче чиратта төрле тел һәм диалект лексикасын сөйләмдә аңлашылырлык итеп куллану хаҗәтеннән ясала (Дегтерева, 1964: 136; Ганиев, 2010: 422). Икенчедән, парлы сүзләр телне алынма сүзләрдән арындыру юлында бер күчмә этап хезмәтен үти; өченчедән, алар яңа төшенчәнең мәгънәсен тулырак, төгәлрәк аңлата.

Семантик үзенчәлекләре буенча парлы неологизмнар ике төркемгә бүленә:

1) бер үк мәгънәдәге төрле чыгышлы компонентлардан төзелгән парлы сүзләр. Алар телне «татарчалаштыру» максатыннан ниндидер төшенчәнең автор тәкъдим иткән татарча атамасын, укучы ныграк аңласын өчен, телдә электән кулланылган алынма («чит») атамасы белән парлап бирү нәтиҗәсендә туган. Компонентларның чыгышы ягыннан алар алты төркемчәгә бүленә:

а) рус-европа алынмасы + татар сүзе: *булавка-каптырма, монстр-албасты, оратор-сөйләрмән, план-ният, пост-кәнәфи, предприятие-оешма, пропуск-юллама, рецензия-бәяләмә, секция-төркем, талант-сәләт*;

ә) татар сүзе + рус-европа алынмасы: *белгеч-кадр, оешма-учреждение, тотык-заложник, чыгыш-лекция, эшкуар-бизнесмен*;

б) татар сүзе + гарәп-фарсы алынмасы: *астөшермә-хашия, боерык-фәрман, бүләк-ришвәт, өндәмә-шигарь*;

в) гарәп-фарсы алынмасы + татар сүзе: *фәрман-боерык, шигарь-өндәмә;*

г) рус алынмасы + гарәп сүзе: *теоретик-нәзари*. Мәсәлән: *«Татарстан» бер үк вакытта **теоретик-нәзари** журнал да* («Сөембикә»).

2) аталган предметларның күплек-җыелмалыгын яисә киңрәк, гомумиләштерелгән мәгънә белдерүче парлы сүзләр, нигездә, татар телендә әлегә берсүзле үз атамалары булмаган, яисә яңа төшенчәләрне белдерү максатыннан ясалган. Аларның мәгънәләре һәр компонент мәгънәсеннән киңрәк. Компонентларның чыганаклары буенча мондый лексемаларны өч төркемгә аерып карарга була.

а) ике компоненты да татар чыгышлы парлы сүзләр: *аракы-сыра* (исерткеч эчемлекләр), *баш-сын* (бюст), *белгеч-зыялы* (интеллигенция вәкиле), *биләмә-урын* (территория), *икмәк-печән* (авыл эшчәннәренә натуралата түләм), *төбәк-почмак* (регион);

ә) татар һәм гарәп-фарсы компонентлы парлы сүзләр: *бәйсез-мөстәкыйль* (суверен), *бизәк-нәкыш* (узор), *богау-зынҗыр* (наручник), *һөнәр-белгечлек* (специальность);

б) рус-европа һәм гарәп-фарсы компонентлы парлы сүзләр: *поликлиника-хастаханә* (дәвалау учреждениесе).

К у ш м а  с ү з л ә р парлы сүзләрдән ияртүле бәйләнешкә нигезләнүләре һәм кушылып язылулары белән аерыла. Соңгы елларда барлыкка килгән яңа кушма сүзләр, барысы да диярлек, халыкара һәм рус сүзләрен «татарчалаштыру» максатыннан ясалганнар. Ясалыш үзенчәлекләре буенча аларны өч төргә бүлеп карарга була:

1) ияртүле бәйләнештәге компонентлар (исемнәр) кушылып ясалган неологизмнар: *алтакта* ‘вывеска’, *алхәбәр* ‘передовица’, *анайорт* прародина, *аскорма* ‘инфраструктура’, *аскуйма* ‘постамент’, *аһәңсаз* ‘композитор’, *җанисәп* ‘халык санын алу, перепись’, *җансакчы* ‘телохранитель’, *илбаш* ‘президент, дәүләт башлыгы’, *куларкадаш* ‘партнер’, *кулчатыр* ‘зонтик’, *тактаташ* ‘мемориаль такта’, *үзкичереш* ‘рефлексия’;

2) сүзтезмәләрнең лексикалашуы нәтиҗәсендә ясалган кушма сүзләр тулысынча диярлек ‘исем+киләчәк заман формасындагы сыйфат фигыль’ моделе буенча ясалганнар: *җанатар* ‘болельщик, поклонник’, *җанкыяр* ‘палач’, *йортбасар* ‘фатир басучы карак’, *күзбуар* ‘гипнозчы’, *күпбелер* ‘күп белергә яратучы, всезнайка’, *таугизәр* ‘альпинист’;

3) икенче компонентка кушымча өстәп лексикалашкан сүзтезмәләр: *астөшермә* ‘сноска’, *башбирмәслек* ‘беркемгә дә буйсынмау’, *сансанак* ‘калькулятор’.

Җәмгыятьтәге җитди үзгәрешләр чорында телдә бик күп тотрыклы сүзтезмәләр барлыкка килә, алардан исә яңа аббревиатуралар ясала. Татар телендә к ы с к а р т ы л м а  с ү з л ә р башка телдәге (нигездә рус) кыскартылмаларны кабул итү яки шуларга охшатып яңа сүз ясау юлы белән барлыкка киләләр. Соңгы елларда татар матбугатында кыскартылма сүзләрнең күбесе чыганак телдәгечә үзгәрешсез кулланылса да (*ТНВ* – Татарстан – «Яңа гасыр» телеканалы, *КПРФ* – Россия Федерациясе коммунистлар партиясе, *ФСБ* – куркынычсызлык буенча Федераль хезмәт, *пиар* – PR, *СМС* – SMS һ.б.), шактый аббревиатуралар телнең үз материалында, ягъни татарчалаштырылган сүзтезмәләрне кыскарту юлы белән ясалган: *БДИ* – бердәм дәүләт имтиханы (ЕГЭ), *БТИ* – бердәм төбәк имтиханы (ЕРЭ), *ДТРК* – дәүләт телерадиокомпаниясе (ГТРК), *ҖЧҖ* – Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (ООО), *ИПИ* – икътисадый планлаштыру идарәсе (УЭП), *ТКН* – тормыш куркынычсызлыгы нигезләре (ОБЖ), *ЭХТ* – электрон-хисаплау техникасы (ЭВТ) һ.б:

Шулай ук рус теленә бәйсез рәвештә, ягъни башлап татар теленең үз җирлегендә туган сүзтезмәләрне кыскарту нәтиҗәсендә барлыкка килгән аббревиатуралар да шактый очрый: *БТК* – Бөтендөнья татар конгрессы, *ТИҮ* – Татар иҗтимагый үзәге, *ТДН* – Татарстан Диния Нәзарәте, *ҮДН* – Үзәк Диния Нәзарәте, *ХТЯБ* – Халыкара төрки яшьләре берлеге һ.б

XX гасырның 80–90 нчы елларында телне «татарчалаштыру» тенденциясе тәэсирендә к а л ь к а л а ш т ы р у, ягъни рус сүзләрен татарчага морфемалап тәрҗемә итү ысулы белән бик күп яңа сүзләр ясалды. Аларның күбесе – илнең иҗтимагый-сәяси тормышы һәм финанс-икътисад өлкәсендәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә туган яңа төшенчәләрнең сүзгә-сүз тәрҗемәләре. Дөрес, барлык яңа калькаларны да уңышлы дип булмый, арада ашыгып ясалган, «кытыршылары» да шактый күп очрый. Түбәндә уңышлы дип саналган структур-семантик (сүзьясалыш) һәм семантик (мәгънәви) калькалар гына карала.

*Структур-семантик калькалар* рус сүзенең морфологик кисәкләрен татарчага тәрҗемә иткәндә барлыкка килә (Сафиуллина,

1997: 63). Аларның ике төре бар: тулы калькалар һәм ярымкалькалар. Структур яктан алар гади, кушма һәм тезмә сүзләргә бүленә.

*Тулы*, ягъни барлык компонентлары да татарча яисә күптән үзләштерелгән элементлардан торган калькаларга тукталып үтү урынлы булыр.

Гади сүзләр: *акчалаштыру* 'монетизация', *әйдәүче* 'ведущий', *бәрмә* 'ударный', *мәгълүматлаштыру* 'информатизация', *орлыкландыручы* 'осеменатор', *сөйләүлек* 'разговорник', *туңдыргыч* 'морозильник', *тыгызлаткыч* 'уплотнитель', *уйнаткыч* 'проигрыватель', *укылыш* 'чтение', *чүкелмә* 'чеканка'.

Кушма сүзләр: *бөекмәмләкәтчел* 'великодержавный', *катнашазык* 'комбикорма', *күктерәү* 'небоскреб', *төбәкара* 'межрегиональный'.

Тезмә сүзләр. Бу төр калькалар сан ягыннан иң зур күпчелекне тәшкил итәләр. Тезмә калькаларның күбесе рус телендәге сүзтезмәләрне сүзгә-сүз тәрҗемәләү юлы белән ясалган: *антлы утырышчылар* 'присяжные заседатели', *базар икътисады* 'рыночная экономика', *базар мөнәсәбәте* 'рыночные отношения', *газ санагыч* 'газовый счетчик', *җаваплылыгы чикле ширкәт / чикләнгән җаваплылыктагы ширкәт* 'общество ограниченной ответственности', *җирле үзидарә* 'местное самоуправление', *икътисади тотрыклылык* 'экономическая стабильность', *икътисади тотрыксызлык* 'экономическая нестабильность', *кече эшмәкәрлек* 'малое предпринимательство', *куллану кәрҗине / кулланучылар кәрзине* 'потребительская корзина', *кәрәзле элемтә* 'сотовая связь', *кыйммәтле кәгазьләр базары* 'рынок ценных бумаг', *махсус икътисади зона* 'особая экономическая зона', *мәҗбүри иминият* 'обязательное страхование', *мәшгульлек үзәге* 'центр занятости', *милли-мәдәни мохтәрият* 'национально-культурная автономия', *торгынлык еллары* 'застойные годы', *үстерешле / үстерелешле укыту* 'развивающее обучение', *хезмәт базары* 'рынок труда', *һөнәри берлек* 'профессиональный союз', *шарчыклы каләм* 'шариковая ручка' һ.б.

Калькалаштыру процессында кушма сүзләрнең тезмә сүзләргә әверелүе татар теле өчен типик күренеш булган кебек (Сафиуллина, 1997: 64), кайбер рус телендәге гади сүзләрне тезмә сүз рәвешендә татарчага күчерү дә очрый. Шундыйлардан *үзгәртеп кору* 'перестройка', *тәкъдим итү тантанасы* 'презентация',

*күчемсез/күчми торган милек* ‘недвижимость’ кебекләре инде әдәби телдә бик актив кулланыла, башкалары, гадәттә, җәя эче аңлатмасы белән бирелә: ***Сәүдә бәясе*** *(наценка) төрле җирдә төрлечә* («Татарстан яшьләре»). *Ә бит эстрада артистының, бигрәк тә җырчының* ***сәхнә чырае*** *(имидж) бик күп төрле вак нәрсәләрдән туплана* («Татарстан яшьләре»). ***Товар алмашу*** *(бартер) операцияләрен ясау өчен махсус түләү турында...* («Ватаным Татарстан»).

*Ярымкалькалар* чит телдәге сүзнең бер өлешен генә тәрҗемәләп ясала.

Гади сүзләр. Калькаларның бу төрендә алынма сүзнең тамырын саклаган хәлдә кушымчалары гына «татарчалаштырыла». Гади ярымкалькалар арасында исемнәр чагыштырмача аз, чөнки тел гади алынма исемнәрне үзгәрешсез куллануга өстенлек бирә. Чагыштырмача актив кулланылучы яңа ярымкалькалар зат исемен белдерүче *-чы* һәм абстракт исем ясагыч *-лык* кушымчалары белән төзелгән: *гэкачэпэчы* (гэкачэпист), *дизайнчы* (дизайнер), *контрактчы* (контрактник). *маникюрчы* (маникюрщица), *омончы* (омоновец), *рэкетчы* (рэкетир), *легитимлык* (легитимность), *казначылык* (казначейство), *элитарлык* (элитарность) һ.б.

Сыйфатлар арасында исә ярымкалькалар күп, чөнки татар һәм рус телләрендә сыйфатлар грамматик төзелеше ягыннан бер-берсеннән нык аерыла һәм аларны үзгәртмичә кабул итеп тә булмый. Бу ярымкалькалар рус сыйфатларын татар әдәби теленә үзләштерүнең Ә. Ахунҗанов тарафыннан ачыкланган (Ахунзянов, 1968: 310–315) барлык ысулларын да диярлек файдаланып ясалганнар:

а) *-н-* суффиксын *-лы* кушымчасы белән алыштыру: *ликвидлы, льготалы, инновацияле* һ.б.;

ә) *-ск-* һәм *-н-* суффиксын күпмәгънәле *-лык* кушымчасы белән алыштыру: *акционерлык, аудиторлык, менеджерлык, продюсерлык, фермерлык* һ.б.;

б) алынма *-озн-* формантын *-чел* кушымчасы белән алыштыру: *мафиячел* һ.б.

Яңа ярымкалькалар арасында фигыльләр дә шактый. Алар барысы да диярлек рус теленең үзе өчен дә алынма булган сүзләрдәге *-аци-* аффиксына *-ла/-лә* кушымчасы өстәлеп (а), яисә *-аци-, -изаци-, -ирова-* формантларын *-ла, -лап, -лаш, -лаштыр* кушымчалары белән алыштырып (ә) ясала: *а) адаптацияләү, конверта-*

*цияләү, сертификацияләү* ә) *акционерлаштыру, ваучерлаштыру, газлаштыру, легальләштерү* һ.б.

Кушма сүзләрдән ясалган ярымкалькаларның беренче компонентлары гадәттә халыкара сүзләрдән тора, ә рус чыгышлы икенче компонентлары татар сүзләре белән алыштырылган: *авиаһәлакәт, автоузыш, аудиоҗыентык, аэротамаша, аэрочана, биотышча, биоягулык, видеотасма, видеоязма, суперзаманча, телекүпер, фотокүчермә, этносәяси, фоторассәм* һ.б.

Тезмә сүзләр. Ярымкалькалар арасында тезмә сүзләр иң зур күпчелекне тәшкил итә: *депозит кертемнәре* ‘депозитные вклады’, *иминлек советы* ‘совет безопасности’, *ирекле әйләнештәге валюта* ‘свободно-конвертируемая валюта’, *лазер тәлинкәсе* ‘лазерный диск’, *мәҗбүри медицина иминияте* ‘обязательное медицинское страхование’, *милли инвестиция фонды* ‘национально-инвестиционный фонд’, *пластик карточка* ‘пластиковая карточка’, *салым полициясе* ‘налоговая полиция’, *сәүдә-сәнәгать палатасы* ‘торгово-промышленная палата’, *уен бизнесы* ‘игорный бизнес’, *уртак предприятие* ‘совместное предприятие’, *хезмәт һәм мәшгульлек бюросы* ‘бюро труда и занятости’, *хисап палатасы*‘ счетная палата’, *Федераль җыен* ‘Федеральное собрание’ һ.б.

Семантик калькалар, ягъни рус теле тәэсирендә яңа мәгънә алган, дөресрәге, рус телендәге үзенә тәңгәл лексеманың җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән яңа мәгънәсен күчергән сүзләр гадәттә куштырнаклар эчендә языла:

*Зәңгәр каскалар* (голубые каски) – гражданнар сугышы барган ил территориясенә тәртип саклау өчен БМО тарафыннан кертелгән төрле, яисә бер нейтраль илнең ялланган солдатларыннан торган гаскәр (баш киемнәренең төсе буенча): *Төрек* ***«зәңгәр каскалары»*** *безнең дошманнарыбыз булмаса да, аларның туфрагыбызга аяк басуын да теләмибез* («Шәһри Казан»). *Кайнар нокталар* (горячие точки) – элекке СССР территориясендә милли, сәяси каршылыкка нигезләнеп кабынып киткән сугышлар, төрле чуалышлар барган урын: *Ә* ***«кайнар нокталарга»*** *Татарстан егетләрен җибәрү мәсьәләсендә комиссарның фикере катгый* («Татарстан яшьләре»). *Кайчы* (ножницы) сүзе рус телендәге күчерелмә «үзара бәйле әйберләр арасында кискен аерма» (Толковый словарь русского языка, 1998: 420) мәгънәсендә дә кулланыла башлады: ...*транспорт һәм башка төр хезмәтләргә түләү* ***«кайчысын»*** *урнаштыруны*

*үз өстенә алырга разый* («Ватаным Татарстан»). *Коңгыз* сүзе *жучок* сүзенең күчерелмә «яшерен тыңлау җайланмасы» (Толковый словарь русского языка, 1998: 196) мәгънәсен үзләштерде: *Аппаратка да* ***«коңгыз»*** *куярга мөмкин, ләкин бу үзешчәннәргә хас нәрсә* («Ватаным Татарстан»). *Тәлинкә* (тарелка) сүзе тышкы форма охшашлыгы буенча чит планеталардан килгән космик корабль, НЛО мәгънәсен алды, күбрәк сөйләм теленә хас: ***«Тәлинкә»****дән өч сары гәүдә чыга...* («Ватаным Татарстан»). *Тере акча* (живые деньги) – хезмәт хакын төрле продукция белән түләү, үзара исәп-хисапны бартер ысулы белән ясаудан үзгә буларак кулланылган чын акча: *Мәсәлән, коррупция, акча талау, наркотиклар, корал белән сату бары тик* ***«тере» акчага*** *бәйле* («Шәһри Чаллы»). *Түбә* (крыша) – махсус түләү бәрабәренә, яисә хезмәт урыныннан файдаланып, кемнәрнедер яклап, саклап торучы кешеләр яки оешма: *Эшкуарларның байтагы, милициянең ярдәм итәчәгенә ышанмыйча,* ***«түбә»*** *эзләп, эчке эшләр органнарына түгел, җинаятьчел төркемнәргә мөрәҗәгать итәләр* («Ватаным Татарстан»). *Текәләр* (крутые) – төрле юллар белән акча табып, аны теләсә ничек туздырып йөрүче, башкалар белән үзләрен бик дорфа тотучы кешеләр: ***«Текә»ләр****, бик аз гына акча түләп, Медведевтан яхтасын ял итү өчен алып торалар һәм аны, һәрвакыт диярлек, җимереп кайтаралар* («Татарстан яшьләре»). Бу сүз хәзер берлек сан формасында һәм сүзьясагыч нигез буларак та кулланыла: *Авыл яшьләре дә шәһәрнекеләрдән калышмаска тырыша, бу бит –* ***«текә»лек*** *билгесе* («Ватаным Татарстан»). *Яңа урыслар* (новые русские) – яңа заманга яраклашкан, бизнес, шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче кешеләр: ***«Яңа урыслар»*** *шәһәр читләрендә коттеджлар салуны өстенрәк күрәләр* («Ватаным Татарстан»). Бу сүз йогынтысында хәзер *яңа татарлар* сүзтезмәсе дә кулланышка керде, ул татар милләтеннән булган яңа чор «каһарманнарына» карата кулланыла: ***«Яңа» урыслар*****,** ***«яңа» татарлар*** *арасында туберкулез белән авыручылар шактый* («Ватаным Татарстан»).

Аерым авторлар тарафыннан төрле максатларда ясалган, гадәттә бер тапкыр гына кулланылучы *индивидуаль неологизмнар* да була, аларны шулай ук *окказионализмнар,* сөйләм неологизмнары, стилистик неологизмнар дип тә йөртәләр. Мондый яңа сүзләрнең кайберләре пассив лексиканың функциональ-стилистик вазифасына багышланган алдагы бүлекчәдә каралачак.

## § 48. Пассив лексиканың функциональ-стилистик вазифасы

Пассив лексик фондка карау бу сүзләрнең телдә бөтенләй кулланылмавын яисә әдәби-тарихи язма ядкәрләр һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә генә очравын аңлатмый. Лексик стилистикада һәм әдәбият белемендә алар үзенчәлекле сурәтләү чарасы буларак карала. Язучы һәм тел галиме С. Поварисов архаизмнарны, образлы итеп, чормага ташланган әйбер белән чагыштыра: «Әйбернең кирәге беткән, ләкин хуҗа чүплеккә ыргытмаган, махсус урынга куйган. Вакыты белән ул аны янә ала, әйләндереп-әйләндереп карый, яңа әйбергә караганда да өстенрәк ягын күрә. Язучының да сүзгә таләбе шулай. <…> Актив лексикада канәгатьләнерлек сүз тапмаса, ул "чормага ыргытылганын" таба һәм аның "яңаларга караганда отышлырак икәнен сизә"» (Поварисов, 1982: 43). Искергән, аеруча тарихи сүзләр төп номинатив функциясендә, беренче чиратта, фәнни-тарихи хезмәтләрдә, тарих дәреслекләрендә кулланыла. Чөнки теге яки бу тарихи чорны сурәтләгәндә шул дәвернең колоритын бирү, аның төшенчәләрен, кешеләрен, предметларын, көнкүрешен чагылдыру өчен, шул чорга туры килгән, шул вакытта кулланылышта булган сүзләрне файдалану таләп ителә. Мәсәлән, Равил Әмирханның XVI гасыр уртасы вакыйгалары турындагы фәнни-популяр хезмәтеннән бер өзек: *1554 елның көзендә Казан* ***воеводалары*** *Кебенәк* ***бәк*** *һәм Кулай* ***мирзаны*** *буйсынган,* ***ясак*** *түләргә ант иткән кешеләргә җитәкчелек итеп, Болын ягы баш күтәрүчеләренә каршы җибәргәннәр. Ләкин Кебенәк тә, Кулай* ***мирза*** *да, халык белән сугышмыйча,* ***ихтилалчылар*** *ягына чыкканнар. Азатлык көрәшенең башында элеккеге* ***ханлыкның*** *Болын ягы* ***хөкемдарларының*** *берсе,* ***йөз бәге*** *(сотенный князь)* ***баһадир*** *Мамыш Бирде тора. Берничә мең кешелек* ***чирү*** *туплап, бу* ***каһарман*** *Иделнең Казаннан югары ягында хәрәкәт итә һәм урыс* ***хакимиятенең*** *Зөя белән Васильсурск арасындагы элемтәләрен өзә* (Р. Әмирхан).

Төрле тарихи чорларга, шәхесләргә багышланган әдәби әсәрләрдә тарихи сүзләр дә, архаизмнар да номинатив-стилистик функциядә кулланыла. Чөнки, беренчедән, «әдип борынгычылыкка хас күренешләрне яктыртырга тели икән, ул аларны шул дәвердәге исемнәре белән генә белдерә ала» (Хатипов, 2000: 129), икенчедән, үткән чорлардагы тормыш-вакыйгаларны чагылдыру белән бергә, бу сүзләр шул дәверне сәнгатьчә тасвирлаучы стилистик чара

да булып торалар. Сурәтләнгән чорның үзенчәлекләрен тулырак ачып, әсәрнең ышандыру көчен арттыралар: – ***Баһадирым,*** *балам,* ***оланым,*** *– дип, бертуктаусыз* ***тәкрарлады төптәңре****. – Өметем минем, бердәнберем. Исән имин, сау-таза илдәсең... – Табынга! Табынга дәшә* ***олуг хан!*** *– дип кычкырды* ***табынбаш****. Бары тик бер* ***җам*** *эчемлек эчкәч кенә,* ***төптәңре*** *табындагыларга күз йөртеп чыкты.* ***Олуг ханның*** *уң кулында философ утыра, философ янәшәсендә –* ***төптимерче*** *Агасике, ханның сул кулында – Илбарыс* ***баһадир, баһадир*** *янәшәсендә –* ***алостаз*** *Дәян.* ***Җамнарга*** *эчемлек коелгач, Кубрат* ***хан*** *сүз алды.* ***Олуг хан*** *башта табындагыларга күз йөртеп чыкты. Ул теләгән* ***аксакаллар, кавханнар, илханнар*** *монда иде. –* ***Аксакаллар, кавханнар,*** *мин* ***ошбу*** *мәҗлестә* ***угланым*** *Илбарыс* ***баһадирга буйтур*** *титулы бирәм! –* ***Хан*** *шау-шу тынганны көтеп торды. –* ***Сөрәнче,*** *иртәгә көн тугач, минем боерыгым халыкка җиткер. Мин әйттем* (М. Хәбибуллин). *«Без тәкъдим иткән* ***инсанның*** *чын* ***солтан*** *булуына инанганда гына ябай* ***халаек*** *аерым* ***ханлык*** *өчен* ***яу*** *чыгачак.Өстәвенә әле төрек* ***солтаны*** *Әхмәт Өченче* ***илә*** *Кырым* ***ханы*** *Дәүләтгәрәйнең дә яклау-хуплау күрсәтүе* ***лазим.*** *Ә мин инде алар янында* ***сәфирләр*** *юлларга да, безне үз канатлары астына алып мәрхәмәт-ярдәм күрсәтүләрен сорарга да өлгердем. Хәзер, менә, тәкъдир сезнең кулда. Ил агалары Хаҗи* ***солтанны*** *булачак* ***хан*** *итеп тәкъдим* ***кыла*** *икән, кара* ***халаек*** *сарык көтүе сыман кылыч* ***вә*** *ут астына баш салачак»* (В. Имамов).

Тарихи шәхесләргә багышланган шигъри әсәрләрдә дә искергән сүзләр һәм формалар нигездә персонажлар сөйләмендә кулланыла:

*Авыр төш күрдем, хәерлегә* ***улсын,*** *–*
***Итил****, имеш, болытларга ашкан*
*Коеп ява җиргә кызыл яңгыр,*
*Күкләр кешни,*
*Кан* ***ягмуры*** *коя*
*Бертоташтан* (Р. Әхмәтҗан).

Башка тематикадагы әдәби әсәрләрдә, аеруча поэзиядә, искергән сүзләр стилистик функциядә генә, ягъни әсәргә тантаналылык, күтәренкелек бирү чарасы буларак кына кулланылырга мөмкин:

*Мин төн кичтем...*
*Өйдә түгел...*

*Җирдә дә түгел хәтта...*
***Сөюнең гарше** көрсие*
*Урнашкан бөек катта* (Р. Харис).

Аеруча газәл, касыйдә кебек электән килгән, традицион жанрдагы әсәрләрдә архаизмнар күп очрый:

*Газәл **диваным,** ит **сәйран:***
*җаның, аһ, булса хәйран!*
*Гаташ – **сакый, шәрабы –** җыр,*
*мәңге сусау сизмәссең!* (Р. Гаташ).

Архаизмнар, шулай ук, рифма-ритм, тавтологиядән котылу яисә градация – мәгънә көчәйтү чарасы буларак, актив сүзләрнең синонимы функциясендә шактый еш кулланыла:

*...Ничәнче көн камалышта шәһәр,*
***Кальга** өсләрендә ак төтен...*
*Сиңа шатлык каян килсен, Казан,*
*Сатлыклардан булгач бәхетең?!* (Х. Әюпов).

*Куанмадым белгәнемнән риза булып, –*
***Җәһаләтен** күреп миннән наданнарның* (Н. Арсланов).

*Туфрагыннан башка*
*Кем соң уңган, булган канәгать?!*
*Зур бәхеттер – китсәң, кайта алу,*
*Кайтыр урының булу – **сәгадәт...*** (Р. Гаташ).

Аерым очракта архаизмнар һәм тарихи сүзләр юмор-сатира, ирония чарасы итеп тә кулланыла:

*Җаен белеп сорасам аңлар, димен:*
*Бир, Ходаем, **гәләфи** чалбар, димен.*
*Өстәвенә ялтыр-йолтыр **күн итек,***
*Йөримче ике дөньяны бер итеп.*
***Хром пинжәк**, һәм наган тагып билгә,*
*Куй гайрәтле **камисар** итеп илгә...* (Г. Афзал).

Х. Курбатов билгеләвенчә, «хәзерге заман әйберен узган чор әйбере исеме белән атау тыңлаучыда елмаю уята» (Курбатов, 2001: 77):

*Әдәби...Мәдәни үзәктә*
*Мактау ул искиткеч җайланма:*

*Мактауда майлана-майлана,*
***«Әмирләр», «вәзирләр»*** *сайлана* (Ф. Гыйззәтуллина).

Архаизмны яңа сүзләр белән бергә куллану юмор-сатираның көчен тагын да арттыра:

*Байлык төяргә меңләп «КамАЗ» килде.*
*Бер водолаз, бер противогаз килде.*
*Әйтте Әгъләм, шатланып: «Байлык чиртте!*
*Тын кал,* ***гавам,*** *тарихи мизгел җитте!..»* (И. Юзиев).

Поэзиядә искергән сүзләрне яңа, күчерелмә мәгънәдә куллану да очрый. Түбәндәге мисалларда *остаз* сүзе «мастер, наставник», ә *шәкерт* – «өйрәнчек, кемнең дә булса эшен, идеяләрен дәвам итүче» мәгънәсендә кулланылган:

*Кемне калдырасың,* ***остаз,***
*Шигърият* ***багына,***
*Гаделлек сагына?..* (Р. Әхмәтҗанов).

***Шималдә*** *шәрык гөлләрен үстергән*
*Бер фәкыйрь мин – газәлдә* ***шәкертегез*** (Р. Гаташ).

Актив лексикадагы рус теленнән яки рус теле аша Европа халыклары телләреннән алынган сүзләр урынына аларның элек кулланышта булган синонимнарын куллану шигъри әсәрләрнең аһәңлелеген, тәэсир көчен арттыра:

*Нәкъ кырык ел – мәктәп бетергән идем,*
*Аннан – Уфа, Казанда* ***дарелфөнүн.***
*Мәскәүдә дә* ***шәкерт*** *идем. Кем булдым?*
*Түземле бу дөньяга: «Гафу* ***кыл!»*** *– дим* (Р. Гаташ).

XX гасырның 80 нче еллары ахырыннан вакытлы матбугатта да рус алынмалары һәм интернационализмнар урынына Октябрь инкыйлабына кадәр кулланышта булган сүзләрне кире кайтару тенденциясе күзәтелә (Гарифуллин, 1998: 17).

Төрле сәбәпләр аркасында, актив лексик фондтан төшеп калган сүзләр белән беррәттән, ясалма искергән сүзләр дә кулланыла. Аларга кайчандыр журналистлар, язучылар, лексикографлар тарафыннан уйлап табылган, әмма телдә ныгып кала алмаган сүзләрне кертәләр. Р. Сәфәров мондый сүзләргә мисал итеп, 1926 елда чык-

кан «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге»ндә китерелгән *ниргә* (ряд), *рятдәге, дәрәҗәсез* (рядовой), *төккөч, шөбөн* (шампол) атамаларын китерә (Сафаров, 2012: 23). XVIII гасыр азагы – XX гасыр башында дөнья күргән татарча үзөйрәткечләр һәм сөйләүлекләрдә теркәлгән *агачлы юл* (аллея), *бина кылучы* (архитектор), *ислекче* (парфюмер), *җимешле аш* (соус), *кырдыручы* (токарь), *суык тимерче* (слесарь), *төс төшерүче* (фотограф), *ут көймәсе* (пароход), *яшел җиләк* (крыжовник) кебек сүзләрне дә (Юсупова, 1994: 15), хәзерге чорда иҗат ителгән тарихи әсәрләрнең авторлары уйлап тапкан *алостаз* (шымчылар башлыгы), *ермач* (разведка гаскәре), *коралханә, тугабаш* (ишек төбендә торучы сакчы), *утлы таяк* (мылтык), *яутун* (сугыш киеме) сүзләрен дә ясалма иске сүзләргә кертергә була.

Яңа күренеш, предмет атамасы буларак неологизмнар, нигездә, номинатив функциядә генә кулланыла (Фомина, 1978: 231). Әмма матур әдәбиятта алар стилистик максаттан тантаналылык, заман сулышын чагылдыру яки, киресенчә, сатирик-юмористик образлар тудыру чарасы буларак та кулланыла ала:

> ***Илбашының*** *юлы бүген – Иранга!*
> *Якташың ул... Кагылырмы Ширазга?* (Р. Гаташ).

> *Өметләндек, хыялландык,*
> *Нинди булыр килер заман?*
> *Кара битлек киеп килде*
> *Гел көтмәгән* ***«киллер»*** *заман!»* (Ш. Галиев).

> *...Марсель Гали үзен бәхетле тояр:*
> *«Ниһаять ,* ***биллиардер*** *булдым!» – дип куяр...* (И. Юзиев).

Телнең үз сүз ясагыч чаралары ярдәмендә язучылар көтелмәгән, кабатланмаган сүз сурәте ясый. Мондый индивидуаль неологизмнар аеруча поэзиядә еш очрый. Мәсәлән, *-стан* компоненты белән ясалган кушма исемнәр әсәргә милли аһәң, патетик рух бирә. Р. Гаташ шигырьләрендә генә дә *бехетстан, белемстан, былбылстан, моңстан, хыялстан* кебек дистәләгән окказиональ сүз көчле стилистик чара булып хезмәт итә. *-даш/-дәш, -таш/-тәш* кушымчасы белән шагыйрьләр бергәлекне, дуслыкны, бер караштa булуны белдерүче матур сүзләр ясап кулланалар: *рухташ, уйдаш, эштәш, һөнәрдәш* (Ш. Галиев), *җырдаш, кайгыдаш, шатлыкташ,*

*чирәмдәш* (Х. Әюпов), *җирдәш, иңдәш* (Ф. Яруллин) һ.б. Бер контекста кулланганда аларның тәэсире тагы да көчлерәк була:

*Ул хәлләрне син аңларсың инде...*
*Әхсән туган, **тамырдаш** ла син!*
*Күктән ишеп яуган **кардаш** та син,*
*Таңда койган **яңгырдаш** та син!* (Зөлфәт).

Башка кушымчалар белән ясалган окказиональ сүзләр дә шигъри әсәр телен аһәңле итә:

***Бахбайчы,***
